ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

6.2001



# Tatarstan Respublikası Prezidentı

# UKAZI

## 2001 yılda Tatarstan Respublikasının Ğ. Tuqay isemendəge dəwlət büləkləren birü turında



**Robert Əxmətcanov**



**Anatoliy Şutikov**

Tatarstan Respublikasının Ğ. Tuqay isemendəge Dəwlət büləklərə komitetı təqdimnəren qarağannan son, **qarar birəm**:

2001 yılda Tatarstan Respublikasının Ğ. Tuqay isemendəge dəwlət büləkləren tübəndəgelərgə birergə:

1. Şağir **Robert Wəli ulı Əxmətcanovqa**—«Turğay tərəzəse» *(Tatarstan kitap nəşriatı, 1995 yıl)* həm «Kiçke qoşlar» *(«Məğarif» nəşriatı, 1999 yıl)* kitapları öçen.
2. Dirijor **Şutikov Anatoliy İvanoviçqa**—Tatarstan Respublikası Dəwlət xalıq uyın qoralları orkestrının 1995-1999 yıllardağı konsert programmaları öçen.

Tatarstan Respublikası Prezidentı **M. Ş. ŞƏYMİEV**

Qazan, Kreml' 2001 yıl, 25 aprel'
№ VII-288

# Казан утлары
# Qazan utları

2001

**6**

(944)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов,**
**Зилә Вәлиева,**
**Фоат Галимуллин,**
**Тәлгат Галиуллин,**
**Миркасыйм Госманов,**
**Аяз Гыйләҗев,**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары),*
**Салих Маннапов,**
**Туфан Миңнуллин,**
**Хатип Миңнегулов,**
**Гәрәй Рәхим,**
**Факил Сафин,**
**Ренат Харис,**
**Зиннур Хөснияр,**
**Розалина Шаһиева.**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Шамил Маннапов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова, Асия Рәхимова** (баш бухгалтер).

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎: Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 49-36-63,
гамәли хезмәткәрләр — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Газинур МОРАТ. Сабантуй. *Шигырь* ........ 5
Фоат САДРИЕВ. Бәхетсезләр бәхете. *Роман (Ахыры)* ........ 6
Фәнис ЯРУЛЛИН. Кереп барам урманга мин. *Шигырьләр* ........ 62
Кояш ТИМБИКОВА. Уртак яр. *Хикәя* ........ 67
Бикә РӘХИМОВА. Алтын-кызыл яшен яшьни күктә. *Шигырьләр* ........ 81
Габделхәй САБИТОВ. Туган җир туфрагы. *Хикәя. (Марс Шабаевның кереш сүзе белән)* .. 87
СӨЛӘЙМАН. Җиде күккә күтәрел дә... *Шигырьләр* ........ 90
Сафуан МУЛЛА ГАЛИ. Таллар нидер тыңлый бик тынып. *Шигырьләр* ........ 93

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ. Яңа җилләр исеме? ........ 95
Факил САФИН. Хыянәтсез иҗат ........ 102

**ФӘН**

Вил ГАНИЕВ. XX йөз татар әдәбияты ........ 113
Булат ХӘМИДУЛЛИН. Таулы Алтай—төрки халыклар этногенезының бер үзәге. 119
Җәмил ЗӘЙНУЛЛИН. Гарәп илләрендәге тел проблемалары ........ 128

**ДИН ҺӘМ ТОРМЫШ**

Харис хәзрәт САЛИХҖАН. Ислам вә хәят ........ 131

**КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ**

10—Юныс (Юныс) сүрәсе ........ 138

**ТАРИХ**

Мөсәгыйт ХӘБИБУЛЛИН. Хазарлар ........ 145

**ХӘТЕР**

Гарәфи ХӘСӘНОВ. Язмышлар уртаклыгы *(М. Шабаев кереш сүзе белән)* ........ 168

**ЯШЬ ТӘНКЫЙТЬЧЕ СҮЗ АЛА**

Гөлнара ШӘМСИЕВА. Кешеләрнең чын йөзе ........ 176

**ӘДӘБИ МИРАС**

«Котадгу белек»не беләбезме? ........ 180

**ЮБИЛЕЙЛАР**

Мәгъсум ХУҖИН. Туры юлдан. *(Радик Фәизовка 70 яшь)* ........ 185
Тәслимә СИБГАТУЛЛИНА. Шәфкатьлелек *(Роза Хәлиуллинага 70 яшь)* ........ 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 192

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: Ф. САДРИЕВ. Роман «Счастье несчастных *(окончание)*; рассказы К. ТИМБИКОВОЙ «Общий супруг», Г. САБИТОВА «Вкус родной земли» *(с предисловием М. Шабаева)*, стихи Г. МУРАТА, Ф. ЯРУЛЛИНА, Б. РАХИМОВОЙ, СУЛЕЙМАНА, С. МУЛЛА ГАЛИ.
«Литературная критика»: статьи А. ЗАКИРЗЯНОВА «Взгляд на литературную критику последних лет»; Ф. САФИНА «Преданность к творчеству», истјрико-библиографическое обозрение В. ГАНИЕВА «Татарская литература XX столетия *(окончание)*, Г. ШАМСИЕВОЙ о творчестве Н. Гиматдиновой.
«История»: статьи Б. ХАМИДУЛЛИНА «Горный Алтай - один из центров этногенеза тюрко-татар», М. ХАБИБУЛЛИНА «Хазары».
«Наука»: Дж. ЗАЙНУЛЛИН «Языковые проблемы в Арабских странах»; Х. САЛИХЗЯН «Ислам и общество».
«Коран на татарском языке».
«Литературное наследие»: Отрывки из «Котадгу белек» в переводе А. Синугыл.
В номере отмечается 100-летие Я. Карима, 80-летие Г. Хасанова, 70-летие Р. Фаи-зова, 70-летие Р. Халиуллиной (статьи Р. Гаташа, М. Шабаева, М. Хузина Т. Сибгатуллиной).
Дневник общественно-культурной жизни.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and Poetry": F. SARDIEV'S novel "The happiness of unhappiness"*(ending)*, K. TIMBIKOVA'S story "Common husband", G. SABITOV'S story "The prime of native land" *(with preface M. Shabaev)*, the verses of G. MURAT, F. YARULLIN, B. RAKHIMOVA, SULEIMAN, S. MULLA GALY.
"Literary criticism": A. ZAKIRZHANOV'S article "About literary criticism of last years", F. SAPHIN'S article "Devotion to creation", V. GANIEV'S historical and bibliographical review "Tatar literature of XX century" *(ending)*, G. SHAMSIEVA'S article about N. Gimatdinova's creative works.
"History": B.KHAMIDULLIN'S article "About ethnography of Altai Turkic peoples", M. KHABIBULLIN "Khazary".
"Life and religion": Koran in Tartar language, H.SALIKHZAN "Islam and society".
"Science": G. ZAINULLIN "Language problems at the Arabic countries".
"Literary legacy": The fragments from "Kotadgu belek" A. SINUGUL'S translation.
"Our jubileers": Y. Karim, G. Khasanov, R. Faizov, R. Khaliullina (article of R. Gatash, M. Shabaev, M. Khuzin, T. Sibgatullina.)
The diary of social and cultural life.

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-34-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянен компьютер үзәгендә жыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 18.05.2001 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы $70X108^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8619 Заказ А-170
Журнал Татарстан Республикасынын Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

---

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2001 ел.

# Ğazinur Morat

## Saban tuyı

Məydan urtasında–irlər,–
Alıp batır ulları.
Kərəşçe xalıqnıqı ul
Yazğı Saban tuyları.

Babaylardan qalğan yola
Bügen bezne cilketə...
Ənə, məydan, tın da almıy,
Kərəş batırın kətə.

Yə, kem ul batır kərəşçe?
İl yəzen aqlarlıqmı?
Tuğan ciren tərle zalim
Zatlardan saqlarlıqmı?

Ruxı nıqmı, tüzərlekme,
Əzerme zur alışqa?
Nıqlı dəwam bulırmı ul
Xalqım ulı Alıpqa?

Bu kərəştə berkemgə də
Yuq bernindi taşlama.
Tatarnıŋ Saban tuyı da
Alıplardan başlana...

**Фоат Садриев**

# БӘХЕТСЕЗЛӘР БӘХЕТЕ

РОМАН

* * *

Иртән ул беркайчан да калдырмый торган зарядкасын бүген ясамады. Кичәге борчылулардан һәм берни ашамыйча эчүдән аның башы чатный иде. Бер чынаяк кайнар кофе йоткалады да эшенә китте. Райкомга якынайган саен, кичәге сораулар борчый башлады һәм ул, бүлмәгә керү белән, Батталовка чылтыратты. Кичә үзен мыскыллаучыны, кемнәрнең үзеннән кычкырып көлүен беләсе килеп, ул Гайсәнең телен чишмәкче булды, әмма теләгенә ирешә алмады.

Вак-төяк эшләрне бетергәч, ул «Коммунизм» колхозына юл тотты. Максаты бер генә—Хәкимовтан кичә кем үзе турында теш ыржайтырлык сүз әйткәнне ачыклау иде. Явымлы көн булганлыктан, Хәкимов бүлмәсендә плащын кигән көе утыра, эшләпәсе дә телефон янында гына иде. Арслановны күргәч, ул, ишек янына ук килеп, аны каршылады, эшләпәсен алып элеп куйды, утырырга урын тәкъдим итте.

—Әйдә, фермаларыңны әйләник әле,—диде Арсланов Хәкимовка.

Алар дуңгызчылыкта да, сыерчылыкта да булдылар, бәйләнерлек әллә нәрсә күренмәде. Ләкин күренсә дә, Арсланов бүгенгә бәйләнмәс иде. Соныннан алар ферма өенә керделәр. Шунда Арсланов саргаеп беткән йөкләмәләрне карап йөри башлады.

—Әле барысы да җәйләүдә бит,—диде Хәкимов.—Торакларга кайткач яңартылыр.

—Ә мин бер әйбер дә әйтмим,—диде Арсланов. Аннары Хәкимовка борылды да:—Зариф Шәймөхәммәтович, кичә сез кинәшмәдән соң бик күтәренке күнел белән таралышкансыз дип ишеттем.

Хәкимов сагаеп калды:

—Кинәшмә күнелле итеп таралырлык булмады шул.

—Сезгә анда берәү мин килгәндә нишләргә кирәген дә әйткән бугай.

Хәкимов сүзнең кая таба барганын шунда ук аңлап алды. Ләкин юри:

—Анлатыбрак әйтсәгез иде, Миңзаһит Усманович,—диде.

---

Ахыры. Башы 4, 5 саннарда.

—Йә, йә, кыланма, карт төлке!—диде Арсланов елмаеп, анын инбашыннан кага-кага.—Мин бит сине гаепләмим. Кем иде сон ул шундый үткән телле? Печ итү урынына зуррагын эшләргә кушучы?

—Әйтмим,—диде Хәкимов, хәйләкәр елмаеп.

—Ә нигә әйтмисен?

—Кешенен уйнап әйткән сүзен дә сезгә житкерергә түбәнсенәм.

—Түбәнсенү микән сон бу?

—Анысын үзегез бәялисез инде.

—Юк, Зариф Шәймөхәммәтович, шулай да әйт әле син ул кешенен исемен.—Арсланов елмайды, ләкин бу чын елмаю түгел, көчәнеп ирен кыйшайту гына иде.

Анын шушы кыяфәтен күргәч, Хәкимов Беренченен эчендә ниләр кайнавын тулысынча анлады.

—Сорамагыз, әйтмим.

—Ярар, ул чакта сезнен янда тагын кемнәр бар иде?

—Анысын да әйтмим, Минзаһит Усманович. Әйдәгез, кереп чәй эчеп чыгыйк,—диде Хәкимов, сүзне икенчегә борып.

—Син инде чәенне әнә шул миннән яшерә торган үз компанияң белән эчәрсен.—Арсланов ишекне дөпелдәтеп ябып чыгып китте.

Хәкимов юри ишек төбенә чыкмады. Ә Арсланов, машинасына кереп утыргач, әле өч минутлап аны көтте, чыгар, әйдәгез керик, дияр, барысын сөйләп бирер дип өметләнде. Хәкимов күренмәгәч, шоферына кузгалырга кушты. Рамазанов житәкчелек итә торган Ильич исемендәге колхозга төшлектә генә барып житте, аны эзләтеп таптырды. Рамазанов анын каршына утка-суга төшкәндәй килеп басты. Тездән сазда председательнен чиста туфлиләрдән, үтүкләнгән чалбардан, ап-ак күлмәк, зәнгәр галстуктан булуы Арслановнын янә ачуын китерде. Гомумән, житәкчеләрнен бу дәрәжәдә пөхтә киенүе ана ошамый иде.

Яхшылап ашагач, чәй эчкәч, алар идарәгә барып, Рамазанов бүлмәсенә керделәр. Рамазанов элек инженер иде, аны Арсланов экономикада сай йөзәдер дип уйлап, колхозның экономик күрсәткечләрене өчен югары яисә түбән булуы хакында сораулар белән сәгатькә якын утыртты. Ләкин председатель хужалыкнын хәлен бөтен ваклыкларына кадәр белүен күрсәтте. Арсланов аны берәр нечкәрәк урында эләктерермен, китереп кысармын һәм шул моментта үзе эзләп килгән сорауны кузгатырмын дип уйлаган иде.

—Экономикада син, Рамазанов, ярыйсы гына йөзәсен,—диде ул ана.—Элекке кебек «давай, давай» белән халыкны куалый торган чаклар үтеп бара. Мин сина үзен кебек яшьләр белән бергәрәк булырга кинәш итәр идем. Ә син инде хәзер гомере үтеп бара торган кешеләр белән аралашасын.

—Сез кемне күздә тотасыз?—диде Рамазанов.

—Хәкимовны.

—Картлардан тәжрибә алырга кирәк,—диде Рамазанов.

—Ә нинди тәжрибә алдыгыз сон анда кичә?

Рамазанов аптырап, инбашын сикертте.

—Анда Хәкимовка кинәшләр дә биргәннәр бугай. Сазламык басу белән бәйләп.

Шунда Рамазановнын чырае кызарып куйды. Арсланов аны ачык күрде.

—Кем бирде ана ул кинәшне?—диде ул.

—Мин белмим, ишетмәдем,—диде Рамазанов, баш чайкап.

—Мин бит синен ишетеп, күреп торганынны белгәнгә күрә әйтәм. Нәрсә, алар якынракмыни?

—Юк, мин ишетмәдем,—диде Рамазанов, күзен дә йоммыйча.

—Рамазанов, син бала-чага булма. Кем әйтте ана теге сүзне?

—Нәрсә әйткәнен дә, кем әйткәнен дә белмим, мин киткәч, булгандыр ул.

—Ә син киткәнче кемнәр бар иде соң анда?

—Белмим, мин анда булмадым бит.

—Әйтмисеңме?!—диде Арсланов, тавышын күтәреп.

—Белмәгәч, ничек әйтим?

Арсланов, тешләрен кысып, йодрыгы белән дөпе-дөпе аның өстәленә сукты:

—Син, егеткәем, допрыгаешься! Яхшылап уйла, Хәкимовлар компаниясе сине югары күтәрә алмас, юкка гына чыгарыр! Һәм мыегыңа чорнап куй: мин сине бүгеннән үземә каршы оешкан компаниядә дип беләчәкмен, шулай дип санаячакмын. Әгәр син шунда кемнәр барын, теге сүзнең кем авызыннан чыкканын әйтсәң, син минем уң кулым булырсың. Аңладыңмы?

Рамазанов дәшмәде. Арсланов саубуллашмый-нитми, ишеген дә япмыйча җил-җил чыгып китте. Күңеленнән ул елап кайтты. Шушы сәләгәй малай, ул председатель иткән шалапай хәзер аңа баш имәсен әле! Ул бит Арслановның табанын яларга тиеш! Ит изгелек—көт явызлык—менә шул буладыр инде ул...

Иртәгәсен ялтырап кояш чыкты, көчле җил исә башлады, димәк, төштән соң теземнәрне әйләндерергә мөмкин булачак. Арсланов Шәвәлиев белән Гаскәровка төштән соң бөтен халыкны басуга мобилизацияләргә кушты да үзе «Авангард»ка юл тотты. Әлеге «көйгән икмәк» аның күңеленнән чыкмады, ул моны өзмичә туктамаячак иде. Инде аның бөтен өмете Батталовта калды. Ул Арслановны ачык йөз белән каршы алды, кунак йортына чәйгә чакырды. Беренче секретарь баш тарткач, үз бүлмәсенә кофе керттерде. Кофены вак-вак итеп йота-йота, алар әкрен генә әңгәмә куерттылар. Өченче көнгә кинәшмә турында сүз кузгатып, Арсланов теге сүзне әйтүчене сорады. Ләкин Батталов чишелергә ашыкмады. Әйдә йөри бирсен, вакыты күп, шоферы белән машинасы бар, акчасы әйбәт. Эзләп карасын, беренче булып кем әйтер икән? Әгәр беркем дә чишмәсә, Батталов аннан соң үзе чамалар.

Арсланов юл буе ачуына буылып кайтты. Әллә соң ул Гайсә үтә хәйләкәр, астыртын бер бәндә булып чыктымы? Аның ул сыйфатлары барын Арсланов инде белгән иде, ләкин алар беренче секретарьга каршы кулланыла алмыйлар, башкаларга гына юнәлтеләләр дигән карашта яшәде ул бүгенгә кадәр.

Тукта, тукта! Әгәр дә берәү дә теге кешенең кем икәнен әйтми икән, димәк, алар аңардан куркалар. Хәкимовны да куркытырлык районда кем бар соң? Димәк, бу сүзне Батталов үзе әйткән булырга тиеш. Әгәр ул әйткән икән, ул бер яклап Арслановка якын дус булып кылана, икенче яклап, аңа каршы кешеләр белән бергә аның абруен төшерә торган сүзләр сөйли. Димәк, аны беренче секретарьлыктан алып ату җаен эзли. Өлфәт Җәлиловның әйтеп бетермәве дә Батталовтан куркудан булырга тиеш. Әле бу районга килеп, ничә ел эшләп, аның үзенә каршы юнәлгән мондый оппозиция күргәне юк иде. Моның башында йә Батталов, йә Хәкимов тора. Әгәр Батталов белән өлкә комитеты секретаре бер сүздә булсалар? Соңгы килүендә дә Батталовта кунды ич ул. Арслановка салкын караш шуннан соң башланды да бит! Акылы белән Батталов турындагы бу начар фикерләргә килсә дә, Арслановның йөрәге моңа ышанырга теләмәде. Чөнки аларның икесенең бергә эшләгән, беркем белми калган, алар икесе генә алып барып чыккан, йөрәкләрендә үлгәнче сер итеп саклана торган бик күп эшләре бар.

Төштән соң аның йөрәге түзмәде, ул тагын Хәкимовка юл тотты. Идарә бикле, барлык халык басуда, ындыр табагында иде. Ул кешеләр белән күрешеп, сөйләшеп алды. Басуда сәнәк тотып эшләп йөрүче Хәкимовны очратты. Монда халык арасында сүз кузгатмады, читкә алып китсә, үзенә тагын нәфрәтләнеп караячакларын уйлады. Шулай итеп, ул берничә хуҗалыкта булып кайту белән чикләнде. Бөтен халыкның

күтәрелеп басуга чыгуы, ашлыкны коткаруга омтылуы куандырырга тиеш булса да, аның күңеле куанмады, үпкәләтелгән сабый баланыкы кебек төшенке иде. Шулай итеп тагын бер көн үтте.

Бүген Хәкимовны ул иртүк эләктерде. Әле иртәнге сәгатьтә председатель янына керүче-чыгучылар шактый иде. Бүлмәгә Арсланов килеп кергәч, урындыкларда утырган биш-алты кеше өреп очыргандай юк булды.

—Менә мин барысын да ачыкладым, Зариф Шәймөхәммәтович,—диде.—Кемнәр булганын да, кем әйткәнен дә белдем. Ә шулай да сине сыныйсым килә. Чын коммунист микән син? Ышанырга, таянырга ярый микән сиңа?

—Әгәр дә сезнең ышанычыгыз шушының белән генә бәяләнә икән, мин сезнең өметегезне аклый алмам,—диде Хәкимов.—Мин сезгә баштук әйттем, кеше сата торган гадәтем юк. Кемнәр тели, шулар сатсыннар.

—Менә шушы сүзләрең белән син үзенне-үзең фаш иттең инде!—дип кычкырды Арсланов.—Мин ачыкладым, районлагы бөтен этлекне син оештырасың. Председательләр белән синең яшерен оешман бар, дигәч, мин башта ышанмаган идем. Менә хәзер ышандым.

Кичке алтыга ул Рамазановны чакырырга кушты.

Нәкъ вакытында Рамазанов аның бүлмәсендә иде инде. Арсланов теземнәрне ничек әйләндерүләре, әле сугарлыкмы-түгелме икәнен сораштырып утырды. Аннары кинәт һөҗүмгә күчте:

—Ни өчен ашлыкны дәүләткә чыгармыйсыз?

—Коры ипи юк,—диде Рамазанов акланып.—Сушилка тәүлек буе эшләп тора.

—Коры ипи көтсәк, без ул планны кайчан үтәрбез соң?

—Бүген комбайннар суктыра башлады инде.

—Син миңа суктыра башлаган комбайн турында сөйләмә, өч көн эчендә күпме ипи чыгара аласың?

—Суы агып торган ипине мин ашлык кабул итү пунктына илтә алмыйм бит.

—А это не твоя забота. Син китер, эшкәртү аларның эше.

—Мин, анда бер мәртәбә дымлы ашлык китереп, күрдем инде хәлләрне. Күрә торып, ипине юкка чыгарырга җаным тартмый минем. Халык аны бик авырлык белән үстерә.

—Кара әле син нинди тирәннән уйлыйсың икән, ә?! Каян килгән намус иясе! Будешь сдавать как миленький!—ул йодрыгы белән өстәлне төйде.—Өч көннән бюрода җавап бирәчәксең. И кстати, синең хәзер уйларлык вакытың булды. Әйт әле теге компаниядә кемнәр булганлыгын.

—Мин бернинди компания дә белмим.

—Соңгы мәртәбә сорыйм, Рамазанов. Моның азагы әйбәтлек белән бетмәячәк.

—Кысыр хатыннан бала таптырмагыз, Минзаһит Усманович.

—Хәзер үк чыгып ычкын!—дип кычкырды Арсланов.—Мин эшләгәндә, сиңа беркайчан да рәхим-шәфкать булмас! Мин моны сиңа ачыктан-ачык әйтәм.

Инде аның бердәнбер кешесе Батталов калды. Ул аны идарәдән дә, өеннән дә эзләтте. Өч-дүрт инструктор оештыру бүлеге җитәкчелегендә кичке тугызга кадәр Батталовны эзләделәр. Ләкин ул беркайда да юк иде. Гайсә Батталович икенче көнне иртәнге тугызларда гына телефон аша Арсланов белән элемтәгә керде.

—Син кайда югалдың?—диде аңа Арсланов ярым үпкәле, ярым кисәтүле тавыш белән.

—Төнге уникегә кадәр комбайннарны эшләттек,—диде Батталов.

Асылда ул теге урман аланындагы йортта Хасбулатованы сыйлаган иде.

—Хәзер ташлыкка килеп җит әле,—диде Арсланов.

Бер сәгатьтән алар Ык аръягының куе әрәмәләр белән капланган

ерактагы бер почмагында иделәр инде. Машиналарын яшереп куйдылар. Ыкка төшә торган сукмактан су өсте ялтырап күренә. Клеенка җәеп, колбаса, ит турадылар, бернichә консерв банкасы ачтылар. Арсланов кунакка да, үзенә дә бәллүр стакан куйды.

Кояш инде сүрелә башлаганда, тәмамысы кызышып беттеләр. Бик күп нәрсә сөйләшенде, киләчәккә бик күп планнар корылды. Инде кайту турында да уйларга вакыт иде.

—Минем синнән башка, Гайсә Батталович, бу районда бер генә якын кешем дә юк,—диде Арсланов, аның иңбашыннан кочаклап.—Эти кебек син мина.

—Рәхмәт, рәхмәт,—диде Батталов аңа каршы.

—Мин синнән башка беркем белән дә йөрешмим. Тик теге көнне күнелдә төер калдырдың син.

—Нинди төер ул?

—Ә менә теге Хәкимов кырындагы компания. Кем анда минем абруйны төшерерлек сүз әйткән? Син шуны миннән яшердең.

Батталов гыйгылдап көлде:

—Әле син аны һаман белмәдеңмени, Миңзаһит Усманович? Мин инде белгәнсендер дигән идем.—Батталов бераз уйланып торды.—Мин аны юри әйтмәгән идем, башка берәү әйтсен дип. Күрдегезме соң кешеләрнең нинди икәнен?

—Әйе, күрдем, ышанычлы кешеләр аз икән. Йә, әйт.

Батталов хәйләкәр елмайды:

—Мин әйтүен әйтермен, сез ул кешене нишләтерсез соң?

—Анысы инде минем эш,—диде Арсланов.

Батталовка Григорьевны батырырга кирәк түгел иде, алар күптәнге әшнәләр. Дымлы ипине бер-бер артлы борып җибәреп торганда да, Александр Григорьев Батталовның лычкылдап торган ашлыгын кабул итә. Алай эшләмәгән сурәттә дә батырмас иде ул аны. Батталовның районда женен котырткан Сабитовлар бар иде әле. Өлкәненә карата ул нидер эшли алды, менә хәзер икесе йөриләр. Мэлс җитәкләгән совхоз хәзер «Авангард»ны этеп-төртеп узып бара. Ул малай турында әле газетадан, әле радиодан мактау сүзләрен кыстырып кына торалар, аның һәрберсе Гайсәнең йөрәгенә барып тия. Шуңа күрә ул:

—Сезнең хакта андый сүзләрне ычкындыручы Мэлс Сабитов,—диде.

—Ах, сволочь!—диде Беренче, кулларын йодрыклап.

—Ә сезгә, Миңзаһит Усманович, моны беркемнән дә сорап торырга да кирәк түгел иде. Бик җиңел хисаплап таба торган нәрсә бу. Сабитовларның бәләкәй мүкләге дә беренче булып сезне сөзде бит.

Арсланов кинәт айнып киткәндәй булды. «Ничек соң мин моны башыма китерә алмадым?»—дип, үзен-үзе тиргәде. Әйе, бу сүзләрне бары тик Сабитовлар гына әйтә ала иде.

—Моны Сабитовка сиздерергә ярамый, икебез генә белик,—диде Батталов.—Әгәр сез аңа иртәгәдән һөҗүм башласагыз, моның сәбәбе шундук беленәчәк. Бик кыен булса да, сабыр итәргә туры килә. Башкаларны тиргәгәндә дә, ана эндәшми калу кирәк булачак.

Ярты чиләк аракы эчсә дә, Батталов дөрес әйтә иде. Сиздермәскә, тешеңне кысып түзәргә кирәк. Әкрен генә, җәнлекне почмакка кысрыклап кертеп, тозакка төшергән кебек, тиешле урыннан каптырырга.

Алар, нәкъ шулай эшләргә сүз бирешеп, янә «юл аягы»на эчеп куйдылар да, башта Арсланов, ул тәмам күздән югалгач, Батталов машинасы кайтырга юл алды.

Әрәмәләрне үтеп, олы юлга күтәрелгәч, Арсланов үзләренә таба килүче сары УАЗикны күрде. «Кем булыр бу?» дип уйлады ул. Машина якынлашкач, ул рульдә—Шәвәлиев, артта Сөембикә утырганлыгын таныды. Кара-каршы тукталдылар.

—Кая болай юл тоттыгыз, Зөфәр Шәрипович?—диде Арсланов.

—Менә Шуваловога бара идем әле. Эшне ничек оештырганнар,

бераз төрткәләп кайтырга. Ашлык чыгаруларының да рәте юк.

—Төягән йөген бик сөйкемле күренә.

—Сабитова ул, күчмә китапханә алып бара.

Арсланов ишекне ачты да почмакта бурлаттай кызарып утырган Сөембикәгә:

—Исәнме,—диде.

—Исәнмесез, Минзаһит Усманович...

Сөембикәнең янында кәгазь бау белән бәйләнгән ун-унбиш китап бар иде. Арсланов китапларны алды да, аларның тышлыкларына күз салып:

—Әйбәт, әйбәт. Шувалово урысларын күптән укырга өйрәтергә кирәк иде инде,—диде. Китапларны куеп, ишекне япкач, Шәвәлиевкә:—Давай, барыгыз, эткәләп, төрткәләп кайтыгыз,—диде һәм машинасына утырып, китеп барды.

Шәвәлиев, уклау йоткандай, аптырап катып калды. Батталов, аның машинасын алдан ук күргән һәм әрәмә арасына кереп, икенче юлга борылган иде. Шәвәлиев Беренченең исерек икәнен сизсә дә, кем белән эчкәнлеген белә алмады. Сөембикәне Шәвәлиев машинасында күрү Арслановны тагын әллә нишләтеп җибәрде. Аның хәзер алар артыннан борыласы, килгән шәпкә кырдан китереп бәреп, машиналарын аударасы, аркылы-торкылы йөреп таптыйсы, изәсе килде. Аның каршысында алар икесе дә иң кабәхәт хыянәтчеләр иде. Әгәр болай икәнен белгән булса, Арсланов бу хатынны район китапханәсе директоры итеп куюга һич тә ризалык бирмәгән булыр иде. Менә ни өчен Шәвәлиев элеккеге директорны куган, менә ни өчен аның урынына мактый-мактый Сөембикәне тәкъдим иткән икән. Ә теленне тешләп таң калырлыгы алдан ук эшләнгән: аның Сөембикә белән тәүге мәртәбә бергә булуын да ул оештырды ич! Урманда, зур кунакларны сыйларга баргач... Гомергә андый җирләрдә күренмәгән Сөембикә аш-су әзерләүче кызлар арасында иде. Шәвәлиев шунда шаяртып:

—Бу Сөембикә күзен гел сездән алмый, мин аны шалашны җыештырырга калдырмагаем,—дигәч, Арсланов ризалык биргәндәй көлеп куйган иде.

Кунаклар таралгач, алар Сөембикә белән икәүдән-икәү калган булып чыктылар...

«Бу Сөембикә шундый тәртипсез хатын микәнни соң?» дип рәнҗеп уйлап куйды ул эченнән. Ул аны бары тик үзенеке генә, аңа беркем дә кагылмаска тиеш дип саный иде. Бәлки монда бер әйбер дә юктыр? Ләкин ник соң ул анда күчмә китапханәне үзе алып бара? Нигә моның белән махсус шөгыльләнүче хатынны алмаган? Ник Шәвәлиев шоферын калдырган? Нишләп ул икәүдән-икәү юлга чыгу инде сәгать өчтән сонга, Сабитовның Мәскәүдә командировкада вакытына туры килгән? Юк, аек акыл белән уйласаң, аларның чиста уй белән чыкмаганлыгы күренеп тора. Әллә соң бөтен дөнья урталай ярылып, аның бер яртысында Арслановка каршы кешеләр туплана башладымы? Казанда ул башка район секретареннан берүзе аерылып калды. Кайтуына Хәкимовлар, Сабитовларның оешуы мәгълүм булды. Инде хәзер икенче секретарь белән «бажалар» икәнлеге билгеле булды. Ләкин бу туган бажа түгел, дошман бажа булып чыга. Ә дошманны җиңәргә кирәк, әмма ордым-бәрдем кыланмаска. Ул кызган вакытында тойгылар өермәсеннән чыга алмый, шуның аркасында яшьлегендә дә, соңрак та шактый юләрлекләр кылып ташлады. Батталов аның бу кимчелеген белә, шуңа күрә Мэлс Сабитов мәсьәләсендә кисәтте. Юк, Батталов, ни әйтсәң дә, аның иң якын кешесе. Тик нишләптер беркөн Батталовка карата туган шиге һаман күңеленнән китмәде, ул, болганчык суның пычрагы чиләк төбенә утырган кебек, аның күңел төбенә ятты. Бу юшкынны киләчәктә юып алырлык берәр дулкын булырмы, әллә ул тагын да калыная төшәрме—анысын алдагы көннәр генә әйтә алачак иде...

Гайсә дә юл буе ашыкмыйча гына үз уйларының йомгагын сүтте дә сүтте. Сүз дә юк, ул аның кем икәнлеген аңлый, дуамаллыгын да күрә. Җитәкче буларак, ул аңа бөтенләй ошамый һәм кирәк тә түгел иде. Ләкин килгән дәвереннән башлап, Арсланов аның сүзеннән чыкмады, хәзер дә әле ул Гайсә кулында курчак урынына бии. Әгәр төптән уйлабрак эш итә торган берәр кеше килсә, Батталов аны болай кулында тота алыр идеме икән? Ул гына да түгел, киләчәк көннәрдә аның председатель булып эшләү-эшләмәү мәсьәләсе дә көн тәртибенә килеп басачак. Хуҗалыкны ул әлегә тимер йодрыкта тотып бара, ләкин ул сизә: халыкта ниндидер хәрәкәт бара. Элек мыжгып кайнап торган авыллар бушап калды. Авыл кешесенә паспорт бирү коточкыч нәрсә булды. Мондый юләр алымны ясаган өчен ул эченнән хөкүмәтне, партияне эт итеп сүкте. Хәзер колхозның бер аягы пенсия яшенә җитеп килүчеләрнең һәм пенсионерларның ябык җилкәсенә таяна. Болай итеп озак атлап булмаячагын сизә Гайсә. Шуңа күрә аның өчен нык терәк кирәк. Ул терәк—Арсланов. Аңа бүтән бернинди арслан да, юлбарыс та кирәкми, шушы арсланны әлегә ул курыкмыйча башыннан сыйпый, аны теләгән җиренә ырылдатып җибәрә, теләгән корбанын будырып аттыра. Бу арслан исән чакта, аның колхоз дип аталган бакчасына бер генә чит җанвар да үтеп керә алмаячак...

## 28

Укулар башланганчы, кайтып килү өчен төгәл бер атна вакыт бирелде. Әгәр бер генә көнгә соңарсагыз да, курслардан чыгарылачаксыз, дип кисәттеләр. Шул ук көнне кич җыенып, Ирек поездга утырды. Тәүлектән артык кайтырга кирәк, аның вакыты күп иде. Кайткач, эшләрен ничек җайлау турында бертуктаусыз баш ватты. Инде укырга керелгән, ә менә ничек китәргә? Райком мондый гамәлне тавышсыз гына үткәрмәячәк...

Ул кайтып төшкәндә, инде соң, райкомга да, эшкә дә кереп торырлык түгел иде. Сөембикәдән районда хәлләрне сораштырды, булган яңалыклар белән танышты. Икенче көнне сәгать алтыда ул Шәвәлиев янында иде инде.

—Ну, ничек?—диде Шәвәлиев.

—Кердем бит, Зөфәр Шәрипович.

—Котлыйм алайса, котлыйм! Әйдә, хәзер эшкә тотынырга вакыт.

—Беләсезме, аның бит читтән торып уку бүлеге бетерелгән икән,—дип алдашты Ирек, алдан уйлап куйган сүзләрен тезеп.—Абитуриентлар юк ди. Шуңа күрә мин торып укый торганына кереп кайттым инде.

—Син бит алай димәдең.

—Димәдем дә бит. Читтән торып укырга унлап кына кеше килгән. Барыбыздан да имтиханнарны бергә алдылар да, бернинди читтән торып уку булмаячак, көндезге бүлек кенә эшләячәк, диделәр. Мине җибәрерсез инде, Зөфәр Шәрипович.

—Соң, мин нәрсә?—диде Шәвәлиев.—Укырга киткән кешене тоткарларга берәүнең дә хакы юк. Аннары син бит районга бердәнбер кеше. Син үсәргә тиеш.

Ирек шатлыгыннан нишләргә дә белмәде.

—Алайса сез минем китүгә каршы түгел?—диде ул, йөзенә чыккан шатлыгын яшерә алмыйча.

—Ә ник каршы булыйм? Рәхим ит, укый бир.

—Рәхмәт сезгә, Зөфәр Шәрипович. Мин бюро исеменә гариза язган идем, аны сездә калдырыйммы?

—Син аны Минзаһит Усмановичның үзенә керт,—диде Шәвәлиев.

Ирек аның бүлмәсеннән кош тоткан кебек чыкты. Кабул итү бүлмәсендә утыручы инструктордан Арслановның үзендәме икәнлеген сорады. Беренче үзендә, әлегә аның янына кергән кеше дә юк икән. Ирек тәвәккәлләп ишекне ачты һәм «Мөмкинме?» диде. Арсланов

телефоннан сөйләшә иде, «кер» дигән мәгънәдә баш какты. Ирек өстәл янына якынлашкач, ул аңа уң кулын сузды. Алар күрештеләр. Арсланов трубкасын куйганнан соң:

—Ну, ничек анда Мәскәү?—диде.

—Мәскәү гөрли.

—Нәрсә булды соң анда? Семинар-фәләнмени?

Ирек Беренченең сүзләренә аптырап китте, минем ник киткәнне белми микәнни ул, дип уйлады эченнән. Бер атна буе Шәвәлиевтән дә сорамады, кызыксынмады микәнни?

—Мин бит укырга керергә киттем,—диде ул.

Беренченең кашлары җыерылды.

—Нинди укырга керергә?

—Драматурглар өчен... Сезгә Зөфәр Шәрипович әйтмәдемени?

—Ул миңа сезне Казаннан командировкага җибәрделәр, диде.

—Нинди командировка булсын!—диде Ирек, ниндидер күңелсез хәлнең туасын бөтен күңеле белән сизеп.—Мин бит аерымачык әйтеп киттем.

—Кызы-ык,—диде Беренче.—Дальше?

—Укырга кереп кайттым инде мин, Минзаһит Усманович. Аны башта читтән торып дигәннәр иде. Ә ул торып укыйсы икән. Бер еллык югары курслар. Миңа укырга китәргә кирәк.

—Уку әйбәт нәрсә инде ул,—диде Беренче.

—Безнең бер атнадан укулар башлана. Шуңа күрә миңа эшне тапшырып китәргә кирәк.

—Син, йомшак кына җәеп, катыга утыртмакчы булдың инде, Сабитов, ә? Не получится!

—Нинди катыга утырту?—диде Ирек.

—Син мине юләргә санама. Алай булган, тегеләй булган да, хәзер сиңа укырга китәргә кирәк булган. Не поедешь!—диде ул, кинәт өстәлгә йодрыгы белән дөпелдәтеп сугып.

—Ә нишләп мин бармаска тиеш?

—Әйтимме ни өчен икәнен? Партия райкомын алдаганга күрә.

—Ничек алдаганга?

—Командировкага дип киткәнсең дә укырга кереп кайткансың. Мөнә бит ничек ансат, ә? Ә монда дураклар җыелган, сиңа «хуш, хәерле юл», дип кул болгап калалар.

—Мин алай димәдем.

—Райкомны алдаганың өчен, бер атна прогулың өчен без сине строго накажем по партияной линии!

Ирек урыныннан сикереп торды:

—Әйдәгез, Зөфәр Шәриповичтан сорыйк алайса.

Арсланов, селекторга басып, Шәвәлиевне чакырды. Ярты минуттан ул алар каршында иде инде.

—Тыңлыйм, Минзаһит Усманович,—диде ул, гадәттәгечә Беренченең теләсә нинди теләген үтәргә әзер икәнлеген күрсәтеп.

—Сез нишләп Сабитовны командировкага җибәрделәр, дип мине алдадыгыз?

—Ул миңа шулай диде.

Ирек әллә нинди ямьсез тавыш белән кычкырып җибәрде:

—Зөфәр Шәрипович, сез ни сөйләгәнегезне беләсезме?!

—Сез, Ирек Хәйриевич, кайда икәнегезне онытмагыз әле. Бу бит сезгә ат абзары түгел.

Ләкин Ирек аның сүзен ишетмәде дә:

—Хәзер үк әйтегез: кайчан мин сезгә Мәскәүгә командировкага китәм дидем?

—Иртәгә китәсе көнне әйттегез. Сез үз ялганыгыздан котылу өчен мине пычратмакчы буласыз. Боргаланма!—диде Шәвәлиев, бармак янап.—Гаеп эшләгәнсең икән, җилкән белән күтәрә белергә дә кирәк!

Ирек агарып катты, аның бөтен тәне дерелди иде. Ул ни утырырга, ни торырга белмәде, кулларын куяр урын тапмады, аның мондый оятсызлыкны үз гомерендә беренче мәртәбә күрүе иде.

—Сез... сез... сез кабәхәт кеше икәнсез!..—дия алды ул көч-хәл белән.

—Син чамалап, Сабитов!—диде Шәвәлиев.—Сиңа әле бу сүзең өчен гафу үтенергә туры килер!

—Ярый, аңлаштык бугай,—диде Арсланов.—Бар, Сабитов, кайт, эшлә. Янадан болай итеп йөрмә.

—Юк, мин кайтмыйм әле!—диде Ирек һәм урынына утырды.

—Миңа чыксам, ярыйдыр бит, Миңзаһит Усманович?—диде Шәвәлиев һәм Беренчегә елмайды.

—Әйе, барыгыз.

Шәвәлиев чыгып китте.

—Ничек сез ана ышана аласыз?—диде Ирек, Беренчегә каш астыннан карап.

—Үзеңнең уң кулыңа да ышанмагач, мин сезгә ышанырга тиешмени?

—Күпме вакыт бергә эшләп, минем сезне алдаганым булдымы?

—Болар барысы да сүзләр, Сабитов. Әйбәтләп алдасаң, ул шул килеш кала. Ярый, бу хакта бетте,—ул учы белән өстәлгә шапылдатып сугып куйды.—Давай, эшкә, друг. Болай да бик озак күңел ачкансың син Мәскәү калаларында.

Ирек, кесәсеннән алып, Беренченең алдына гаризасын салды.

—Мин барыбер укырга китәчәкмен. Гаризамны бюрода ашыгыч карап, эштән азат итүегезне сорыйм.

—Син аны каралды дип сана. Белеп торасың бит: мин ничек әйттем, шулай булачак.

—Миңзаһит Усманович, сез мине бер генә минут тыңлый аласызмы?

—Әйдә сөйлә.

—Бу тормышта миңа бер генә нәрсә бар. Яшәвем шуның өчен генә... Ул—иҗат! Хыялларым, гомерем дә шунда... Ә белемем җитми! Вакытны әйткән дә юк... Аңлагыз зинһар! Әгәр ул булмаса, миңа яшәү дә кирәкми... Минем вакытым бетеп килә... Әле һаман юньләп язып караганым юк.

—Нинди вакыт бетү? Аксаков әнә илле ике яшьтә яза башлаган, Шагинянны кара син тагы, Леоновны ал. Хәзер йөзгә җитеп киләләр, рәхәтләнеп язалар.

—Үзегез әйткәндәй, болар барысы да сүзләр бит. Шагинян гомере һәркемгә дә бирелми. Үтенеп сорыйм: тоткарламагыз мине! Хыялыма барып карыйм инде бер...

—Әллә минем хыялым юк иде дип беләсеңме син?—диде Арсланов, сизелер-сизелмәс елмаеп.—Мин яшь чакта очучы булырга хыяллана идем. Тик менә бит нишлисең, җирдән күтәрелеп булмады. Чөнки партия синең шушында эшләвең кирәгрәк, диде. И никуда не денешься. Хәзер дә бик очасы килә.

«Вакыты җиткәч, очырырлар сине, тик бик нык ябышып утырасың шул әле», дип әйтәсе килде Ирекнең. Беренченең беркайчан да очучы булырга хыялланмаганын ул аңлап утырды. Арсланов, курчак уены уйнаган кебек, аның белән уйный, ләззәтләнә һәм Ирек әйткәннәрне аңлау теләге анарда бөтенләй юк иде. Шуна күрә сөйләшүдән файда чыкмасын ул аңлады.

—Гаризаны үзем катнашында бюрода каравыгызны үтенәм,—диде дә урыныннан торып чыгып китте.

Кабул итү бүлмәсендә шактый кеше җыелган иде. «Шәвәлиевнең әллә йөзенә төкереп чыгыйм микән?» дип уйлады Ирек, ләкин бу уеннан кайтты. Ул коридорда һушына килә алмыйча шактый басып торды. Мәскәүләргә барып, күпме борчылулар, күпме йокысыз төннәр уздырып, инде укырга кереп кайткач кына, аның юлын шушы бәндәләрнең рәхимсез

кисүенә ышанасы килми, бу төш кенәдер, менә хәзер уяныр да, бөтенләй икенче дөнья ачылыр кебек иде.

Профсоюз комитетына кайтып утыргач, аның кулыннан эш коелды. Кемнәрдер ниндидер сораулар белән керделәр, ул аларны бөтенләй үзенә кагылмаган кебек, ничектер өстән генә хәл итте, әйтерсең лә ул тере кеше түгел, электрон хисаплау машинасы иде. Ә тере кеше Ирек үзе, тәмам көеп, бәләкәй генә булып калган һәм ул бернинди чарасыз, бернинди гамәл кыла алмаган хәлдә, ниндидер бер күренмәс ярыктан чыгарга да куркып утыра иде кебек. Ул жанына урын тапмады, нишләргә икәнен дә хәл итә алмады. Ниндидер чара күрергә кирәк иде. Ләкин нәрсә? Әллә абыйсы янына барыргамы? Тик абыйсының ни әйтәсен Ирек яхшы белә: «Кит, бернигә карамыйча кит»,—диячәк ул аңа. Әти-әнисе янына кайтса, әнисе аптырар, елый башлар, әтисе исә райкомга каршы барасыңмы, дип, тиргәп ташлар. Ул аның нәрсәдер яза алачагына беркайчан да ышанмады, яисә ышанса да, моны файдалы эш дип санамады, ахрысы...

Шул вакыт аңа Язучылар союзыннан шылтыраттылар.

—Без синең укырга китәргә тиешлекне партия өлкә комитетының мәдәният бүлегенә житкердек,—диде идарә председателенең урынбасары.—Син китү мәсьәләсендә менә шушы телефон белән (ул номер әйтте) мәдәният бүлеге инструкторы Хисаметдиновка чыгасың, шуның белән даими элемтәдә торасың. Безгә дә шылтыраткала.

Хисаметдинов белән Ирек таныш иде инде. Мине укырга жибәрүгә райкомның беренче секретаре каршы килә дип аңа зарланудан үзе өчен унай нәрсә булыр дип күз алдына китерә алмады ул. Ирек әле һаман укырга жибәрәселәренә ышанды, бюро әгъзалары аңларлар, күрәләтә аның юлына аяк чалмаслар, дип өметләнде. Әлбәттә, бу жинел булмаячак. Аннары әле бит иң куркынычы—Шәвәлиев. Беренче чиратта, тешне кысып булса да аңа керүдән башка юл юк иде һәм ул шулай эшләде дә. Хәзер түбәнлеккә төшеп, аның алдына тезләнү зарур иде. Ирек бу эштән дә жирәнмәде, үзенең булган артистлык сәләтен эшкә жигәргә тырышты.

—Зөфәр Шәрипович,—диде ул, ишек катыннан үтмичә, башын аска иеп.—Мин кызып киттем. Минзаһит Усманович бүлмәсендә әйткән сүзләрем өчен мин сездән гафу үтенәм.

Ул тынып калды һәм керфек астыннан гына Шәвәлиевне күзәтте. Ышандымы, юкмы? Үзенә калса, ышанган кебек иде. Секретарьның ул килеп кергәндәге төссез йөзенә ниндидер нур ингәндәй булды.

—Нык рәнжеттең син мине, Сабитов,—диде ул.

—Соң сез дә инде, ниндидер командировка уйлап чыгарып...

—Минем урында булсаң, син ни уйлап табар идең икән?—дип ярсып китте Шәвәлиев.—Укырга керергә жибәргән өчен рәхмәт укыйсы урында сүзгә бәйләнеп ятасың. Командировкага барган идем, шунда кереп кайттым, дисәң булмый идеме?

Ирек аңа каршы бер сүз дәшмәде. Хәзер ул Шәвәлиев ни әйтсә дә, түзәчәк иде. Әйдә, сүксен, жикерсен, ачуын чыгарып бетерсен.

—Син дә дөрес эшләмәдең,—диде Шәвәлиев.—Алдашканыңны укырга керүеңне әйткәч тә аңладым. Мин бит синең ижади үсүең өчен һәрвакыт юл ачып тордым. Син аның барысын да белмисең.

—Мин сезгә рәхмәттән башка бер әйбер дә әйтмим,—диде Ирек, икейөзлеләнүен дәвам итеп. Сезнең район халкы алдында да, бюро әгъзалары арасында да абруегыз зур. Бер авыз сүзегез бюроны йә бу якка, йә теге якка бора ала. Зинһар яклагыз мине!

Аның сүзләренә Шәвәлиевнең тәмам күнеле эреде.

—Баштук әйттем ич: мин синең китүенә каршы түгел.

—Миңа сезнең бюрода яклап сүз әйтүегез кирәк.

Шәвәлиев бер генә минутка уйланып торды.

—Ярый, мин сине яклармын. Ләкин Арслановның фикерен

үзгәртермен дип ышандыра алмыйм. Аннары шуны да онытмыйк: бюрога кадәр ситуация бөтенләй үзгәрергә мөмкин...

—Ничек инде?—диде Ирек, аптыраштa калып.—Берсекөнгә бюро бит.

—Татарның: «Төн чыкканчы йон чыккан»,—дигән сүзен ишеткәнең бармы синең? Биредә ситуация сәгать саен үзгәрә. Нигә икәнен әйтимме? Минем үземнең дә синең кебек үк авыр хәлдә калу ихтималым бар. Тормышның кая китереп сукканын белеп булмый. Безнең өстә бит мең төрле эш. Шуның кайсыдыр син гел уйламаганында ЧП килә дә чыга. Ул чакта, гафу ит, мин инде сине яклый алмыйм.

Шәвәлиевнең бу сүзләре Ирекне пошаманга салды. Әле генә әйткән сүзеннән теләсә кайсы вакытта кыякларга мөмкинлек калдырды Шәвәлиев. Ирек, күп уйлый торгач, икенче секретарьның хәзер генә үзенә әйткән сүзләрен ныгытып куясы килде. Тотты да Хисаметдиновка шылтыратты. Ул биредәге хәл белән нигездә таныш иде.

—Нинди яңалык бар?—дип сорады инструктор.

—Мин әле генә Икенче яныннан чыктым. Ул мине укырга җибәрү ягында. Әгәр Шәвәлиев теләсә, Арслановка да йогынты ясый ала.

—Шуннан?

—Шәвәлиев белән сөйләшеп карый алмассыз микән дигән идем. Сез әйтсәгез,бәлкем ул Беренчене дә күндерер.

—Яхшы,—диде Хисаметдинов.—Сез үзегездә генә булыгыз әле.

Ирек, берни эшли алмыйча, бүлмәсе буйлап йөренде. Телефон шылтыраса, Хисаметдинов шатлыклы хәбәр әйтер дип, очып барып трубкага үрелде, ләкин хәбәр юк иде әле. Егерме минутлар үткәч, телефон озын-озын шылтырый башлады. Трубкада ул көткән ягымлы тавыш урынына Хисаметдиновның ачулы, кисәтүле тавышы яңгырады:

—Слушай, Сабитов, син нәрсә баш катырып ятасың анда?!—диде ул.—Синең китүгә икенче секретарегыз теш-тырнагы белән каршы.

Ирек башта өнсез калды, аннары көч-хәл белән зиһенен җыйды.

—Иптәш Хисаметдинов, партия намусым белән ант итәм, мин бит, аның яныннан сөйләшеп чыккач, шылтыраттым сезгә. Ул бит, минем китүемне яклап, бюрода чыгыш ясарга вәгъдә бирде!..

—Юкны сөйләмәгез!—диде инструктор.—Мин Беренчегез белән дә сөйләштем. Алар икесе дә бер үк фикерне әйтәләр, райкомны алдаган өчен партия җәзасына тартабыз, диләр.

—Иптәш Хисаметдинов, алар уйлап чыгарган әйбер бу, сылтау гына...

—Слушай,—дип бүлде аны инструктор.—Ботканы ничек пешергәнсең—шулай аша. Үзең уйлап кара: мин моннан торып райкомга нинди күрсәтмә бирә алам? Алдан ук чиста башларга кирәк иде. Ә хәзер син үзең пычратканны безнең кул белән чистарттырмакчы буласың. Алай эшләргә ярамый.—Ул, саубуллашып-нитеп тә тормыйча, трубкасын куйды.

Әйтерсең лә Ирекнең өстенә тимер рәшәткәле читлек төшеп утырды. Әле күңел түрендә соңгы өмет булып торган өлкә комитеты юкка чыкты. Ирек, Трубканы алып, Шәвәлиевнең номерын җыйды. Аның «әйе» дигән тавышын ишетүгә:

—Зөфәр Шәрипович, ситуация үзгәрде дә мени инде?—диде.

—Син нәрсә турында, Сабитов?

—Хисаметдинов миңа барысын да әйтте. Сез бит минем китүгә теш-тырнагыгыз белән каршы икәнсез.

—Нәрсә бутап ята ул анда?—диде Шәвәлиев.—Минем каршы дигәнем юк. Нишләп мин аяк атлаган саен үз сүземнән чигеним? Син аны аңлап бетермәгәнсеңдер.

—Сезгә ачыктан-ачык: «Мин сине җибәрүгә каршы»,—дип әйтергә ярамадымыни соң?

—Кит син укырга, Сабитов, кит! Әйттем бит мин сиңа китүеңне яклап сөйләячәкмен дип. Йә Хисаметдиновны мин аңламаганмын, йә

син Хисаметдиновны аңламагансың. Юкка борчылма, әллә кайларга шылтыратып, тавыш-гауга кубарма! Сабыр булырга кирәк, Сабитов!

Ирек бу юлы аңа хәтта кабахәт дип тә кычкыра алмады. Чыннан да аңа үзе пешергән ботканы үзенә ашарга калды. Ул бюро әгъзаларын эзли башлады, Вафин гына урынында туры килде.

—Лотфулла Габдрахманович,—диде Ирек.—Минем сезнең белән икәүдән-икәү генә сөйләшәсе сүзем бар иде. Вакытыгыз булмас микән?

—Сезнең өчен табарбыз инде,—диде Вафин, шаярткан кебегрәк итеп.

Берничә минуттан Ирек аның танкта янып җөйләнгән кулын кыса иде инде. Әйтүләренә караганда, чишенгән хәлендә Вафинга күз салырга куркыныч: аркалар, аяклар, күкрәк—һәммәсе янып, эреп, тиреләре тартышып каткан, ди. Аның хәтта бер як ирен почмагы да янып-эреп бер-берсенә ябышкан. Шунлыктан Вафин авызын бик ныгытып ачып та сөйләшми, ничектер аның сүзләре теш арасыннан гына чыга. Ирек, бу кешенең үзешчәннәр олимпиадаларында, мәдәният йортындагы концертларда тальян гармунда уйнавын күреп, хәйран калганы бар. Ул чакларда Вафин унҗиде яшьлек егетләр кебек яшәрә, аның күзләре очкынлана, йөзенең янган урыннары кып-кызыл була, бөтен гәүдәсе гармун моңнары белән тибрәнә башлый, гүя ул үзе юкка чыгып, тере җаны гына кала. Вафин бик пөхтә киенә, һәрвакыт ак күлмәктән, галстуктан йөри, күкрәгенә орден-медаль планкалары тагылган була. Көмештәй чал чәчләрен ул беркайчан да озын итеп үстерми, ике-өч сантиметрдан беркайчан да артмый, ул аларны тарамый да, үз унайларына үсә бирәләр кебек.

Ирек ике сүз белән генә аңа эшнең нәрсәдә икәнен аңлата ала иде. Ләкин ул үзенең иң изге хыялыннан башлады. Шул хыялларның ни рәвешле җимерелүен сөйләде һәм укырга кереп кайтканнан соң булган хәлләргә тукталды.

—Берсекөнгә чираттагы бюро,—дип дәвам итте Ирек.—Мин сездән, Лотфулла Габдрахманович, мине яклавыгызны үтенәм.

Аның бу сүзеннән соң Вафин тәмәке кабызды, тирән итеп суырып, ашыга-ашыга тарта башлады. Бармаклары сизелер-сизелмәс кенә калтырый иде.

—Ирек туган, сезнең нәселгә, шул исәптән сиңа да, минем хөрмәтем зур,—диде ул.—Минем аңлавымча, синең китүең хәзер принципиаль мәсьәләгә әйләнгән. Беренче дә, Икенче дә чигенмәячәк. Мин сине укырга җибәрү ягында торачакмын. Билгеле, бу миңа азактан бик каты сугачак.—Ул шактый вакыт эндәшмичә торды. Авыр сулап Ireккә карады да:—Әйтмәсәм дә булыр иде дә инде, шулай да әйтим әле,—дип, сүзен дәвам итте.—Син бит яза торган кеше, тормыш турында уйлана торган зат. Миңа акыл җитмәслек бер әйбер турында әйтим әле мин сиңа. Мин унҗиде яшьтән сугышка киттем, үз теләгем белән. Йөрәкне учка кысып, бетү шушы икән, дигән вакытлар күп булды. Куркудан акылдан язгандай, кая йөгергәнеңне, нишләгәнеңне белмәгән чаклар да булды... Мине батыр сугышчылар исемлегендә йөрттеләр. Командирлар да яратты. Сугыш беткәндә мин инде өлкән лейтенант идем. Һәм менә кайтып, тыныч тормышта эшли башладык. Мине дә, синең кебек, райкомга инструктор итеп алдылар. Шулай да без ничектер иркенрәк эшләдек. Үзеңне кеше итеп тоя идең. Минем сүз озынга китте, ахрысы,—дип, туктап калды Вафин.

—Юк, юк, зинһар дәвам итегез...

—Әз генә сабыр ит, хәзер бетерәм. Әйтәсе килгән нәрсәм шул: сугышта батыр идек, хәзер нишләп шундый хәлгә төштек микән без?— Вафин, урыныннан күтәрелеп, ничектер сәер итеп Ireккә таба үрелде һәм пышылдап:—Хәзер сенеп беттек бит, тын алырга куркып утырабыз,— диде. Аннары, урынына утырып, кабат тәмәке кабызды.—Җиңелү өчен җиңдек микәнни соң без? Бөтен Европаны буйсындырган фашизмнан

да дәһшәтлерәк ни соң бу? Без әнә Александр Григорьев белән кайттык. Аның белән сөйләшә башласак, ул кул гына селти: безнең күкрәк киереп, гайрәт чәчеп сугышып йөрүләребез ул пүчтәк булган, ди. Белмим, белмим, әллә без куркакка әйләндек, әллә бездән көчлерәк әйбер бар?

Ирек чыгарга кузгалды.

—Син борчылма, мине үзеннең якта дип уйла,—диде Вафин аның артыннан.

Ирек аннан чыкты да Гаскәровкә менде. Ләкин ул өйдә юк иде. Ахырда ул—бюро әгъзасы Нәҗмиевне тапты, һәм аның бүлмәсенә керде.

—Минем гаризаны әле сезгә чыгармадылармы?—дип сорады ул Нәҗмиевтән.

—Нинди гариза?

Ирек аңа тагын барысын да сөйләп бирде.

—Берсекөнгә буласы бюродан берүк калдыра күрмәгез,—диде Ирек.— Ләкин мин сезгә аның өчен генә кермәдем.

—Тагын нәрсә бар соң?

—Миңа сезнең ярдәмегез кирәк.

Нәҗмиев ике каш арасына бөгәрләнеп-төртелеп торган чәчен өскә таба сыпырып куйды. Ләкин ул шундук тагын мангаена төште.

—Нинди ярдәм?

—Сез мине укырга җибәрү ягында торсагыз иде...

Нәҗмиевнең йөзенә елмаюга охшаш ниндидер нәрсә җәелде, ләкин бу елмаю да түгел иде бугай. Ул ашыкмыйча гына иреннәрен чәпелдәтте, кесәсеннән папирос кабын алып өстәленә куйды, бер папиросын суырып чыгарып, кабына бәреп, эчендәге тәмәкесен койгалады, ләкин кабызмады.

—Ә син мине Мәскәүгә алып китәсеңме соң?

Ирек аңа аптырап карап торды.

—Син китәсең, без калабыз. Мин синең өчен тавыш бирсәм, синең белән китәргә тиеш булам бит, Сабитов. Син шуны аңлыйсыңмы?

—Ә ни өчен китәргә?—диде Ирек.

—Әйтеп торам ич, сине яклап тавыш биргәнгә. Мин бит райкомның оештыру бүлеге мөдире.

—Укырга теләгән кешене беркемнең дә тоткарларга хакы юк.

—Әгәр дә бу урында утырмасам, мин сине укырга җибәрү өчен кулымнан килгәннең барысын да эшләр идем,—диде Нәҗмиев.—Ә менә хәзер, мин үзем теләмәсәм дә, кеше буларак миңа авыр булса да, мин сине укырга җибәрмәс өчен хәлемнән килгәннең барысын да эшләргә тиеш. Чөнки минем вазифам шундый. Миңа беркемнең дә күз яшьләре белән хисаплашырга туры килми.

—Болай эшләве бик кыендыр бит сезгә, Кәрәм Нәҗмиевич?

—Кайсылай эшләве?

—Йөрәгегез бер яктан кешене кызганып телгәләнә, икенче яктан, сез шул кешенең күз яшьләрен агызасыз.

—Кыен, әлбәттә,—диде Нәҗмиев.

—Йөрәгегезне урталай ярып, болай интеккәнче, әйтик, урта мәктәпкә директор булып китсәгез, җинелрәк булмасмы? Акчасы да сезнең мондагы эшегездән ике мәртәбә күбрәк.

—Инде ачыктан-ачык сөйләшә башлаганбыз икән, мин сиңа бер әйбер әйтим әле, Сабитов. Акча кирәкми миңа. Иркен урында тавык булганчы, тар урында әтәч булганың артыграк...

Башка бюро членнары да Ирек өчен борчылуларын белдерсәләр дә, өметле сүз әйтмәделәр.

Бюро утырышы райкомның уку залында үтте. Чөнки икмәк сату буенча бер колхоздан биш-алты кеше, урып-җыюны начар оештырган икенче хуҗалыктан тагын шулкадәр кеше чакырылган иде. Кыска гына бер өстәлне алгарак чыгарып куйдылар да, аның урта бер җиренә Арсланов, уң ягына Шәвәлиев, сул ягына Гаскәров утырды. Гаскәров кырында Нәҗмиев белән Батталов урын алды, Гәрәйшинны өендә авырып ята,

диделәр, авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигын ниндидер зона семинарына чакырып алганнар. Шулай итеп, арттагы дүрт урындыкта Вафин белән Әхнәф икесе генә утырдылар. Өч кешене партиягә кабул иткәннән соң, әлеге хуҗалыклар тикшерелде. Икенчесен тикшергәндә, инструктор Хисмәтуллин Гаскәровка ниндидер язу кертеп бирде. Гаскәров аны укыды да Арслановка сузды. Анда Чаллыдан төзелеш тресты начальнигы килгәнлеге турында хәбәр ителгән иде.

—Барыгыз,—дип пышылдады Арсланов.

Шулай итеп, беренче мәсьәлә тикшерелеп бетәр-бетмәстә, бюро членнарыннан нибары алты кеше калды. Тагын ниндидер вак-төяк мәсьәләләрдән соң, ниндидер чаралар планнары раслагач, Ирекне чакырдылар. Ул кереп аларның каршысына басты.

—Менә монда бюрога безнең профсоюз лидерыннан гариза керде,—диде Арсланов.—«Мәскәүгә берьеллык театраль курсларга укырга керүем сәбәпле, мине авыл хуҗалыгы работниклары профсоюзы райкомының председателе вазифаларыннан азат итүегезне сорыйм һәм укырга китәргә рөхсәт бирүегезне үтенәм.»

—Ул нәрсә, артистлыкка буламыни?—дип куйды Батталов, көлемсерәп.

—Шул чама инде,—диде Арсланов.—Бюро членнарына шуны әйтергә тиешмен: мин Казанда чакта Сабитов икенче секретарьны, Мәскәүгә командировкага барам, дип алдап китә. Укырга кереп кайтып, хәзер безне перед фактом калдыра. Без аны мондый алдау белән шөгыльләнгәне өчен каты партия җәзасына тартырга тиешбез. Ләкин ул эшләгән чорында чыгымчылап, тәртәгә тибеп куйгаласа да, үзен начар яктан күрсәтмәде. Бүген бюрода аны кисәтергә кирәк һәм киләчәктә тегенди-мондый уйларсыз гына эшен дәвам итсен. Кем дә кем Сабитовның үтенечен кире кагарга ди, шул бюро членнарының тавыш бирүен сорыйм.

Арсланов, Шәвәлиев, Батталов, Нәҗмиев бердәм кул күтәрделәр. Артта утыручы Вафин белән Әхнәф тавыш бирмәде. Арсланов та, беркем дә аларга таба борылып карамады.

—Төшерегез,—диде Арсланов һәм Ирекка:—Давай, эшкә, Сабитов,—дип баш какты.—Бюро тәмам.

Ирек моны болай тиз булыр дип башына да китермәгән иде. Ул әле үзеннән чыгыш ясатырлар, бюро әгъзаларын йомшартырлык дәлилләр китерермен дип өметләнгән иде. Ә бу бюро утырышы аның гаризасын «өф» дип өреп җибәргән кебек кенә булды. Ул, ачуыннан кайнап, эш урынына кайтты һәм кабат КПСС райкомының беренче секретаре Арслановка гариза язарга утырды:

*«Кичәге бюро утырышы мине Мәскәүгә берьеллык Югары театраль курсларга укырга җибәрмәү турында карар чыгарды. Утырышта тугыз бюро членының алтысы гына катнашты, аларның икесе мине укырга җибәрмәү өчен тавыш бирүдән баш тартты. (Алар—Л. Вафин һәм Ә. Шәрифуллин)*

*Шушылардан чыгып, бюро утырышын вәкаләтле түгел дип саныйм һәм минем бу гаризамны ике көн эчендә кабат каравыгызны сорыйм. Чөнки өч көннән мин укыячак Югары курсларда дәресләр башлана».*

## 29

Иртәнге алтыда Арслановның кабул итү бүлмәсендә ни гаҗәптер секретарь хатыннан башка кеше юк иде.

—Беренче үзендәме?—дип сорады Ирек.

—Минзаһит Усманович Казанга китте.

—Ә кайчан кайта?

—Йә иртәгә кич, йә берсекөнгә иртән.

Бусы бик начар иде. Ул Нәҗмиевкә керде.

Гаризаны укыган саен, оештыру бүлеге мөдиренең күзләре түгәрәкләнә барды.

—Нәрсә... алар кул күтәрмәдемени?

—Күтәрмәделәр шул,—диде Ирек.

—Нәрсә, сез алар белән сөйләшеп куйган идегезмени?

—Сөйләшүнең монда ни әһәмияте бар соң? Кайберәүләр белән сөйләшеп тә караган идем дә бит...

—Ярар, ярар, төрттермә,—диде Нәҗмиев.

—Кәрәм Нәҗмиевич, куркыта да димәгез, сезгә әйтеп куям, мин үз дигәнемне итмичә туктамаячакмын. Шуңа күрә гаризаны беренче секретарь кайту белән каравыгызны сорыйм. Һәм миңа һәр ике бюро утырышы карарының күчермәсе кирәк булачак.—Ирек урыныннан торып чыгарга әзерләнде.

—Бер генә минутка тукта әле, Сабитов,—диде Нәҗмиев.—Син бу гаризаң белән Берләшкән Милләтләр Оешмасына барсаң да, берни дә кыра алмаячаксың.

—Карарбыз,—диде Ирек һәм чыгып китте.

Шул ук көнне ул Язучылар берлегенә шылтыратып, хәлнең катлаулануын сөйләп бирде.

* * *

Казаннан алар кичке бишләрдән соң гына чыгып киттеләр. Арсланов күрше район секретаре белән юл буе туктый-туктый кайтты. Унбер тулганда, ул инде өендә иде. Хәятнең өстәл әзерләргә йөрүенә кул гына селтәде.

—Нәрсәләр бар дөньяда?—диде ул.

—Артык берни дә юк бугай,—диде хатыны.—Сабитов мәсьәләсендә генә халык бик шаулый. Нигә җибәрмисең соң шуны? Юкка үзеңнең абруеңны төшерәсең.

—Не твое собачье дело!—диде Арсланов.—Бар, йокла!

Аннары Шәвәлиевкә шылтыратты.

—Хәерле төн,—диде ул.—Яңалыклар юкмы?

—Барысы да әйбәт. Анда Сабитов кына кабат бюро җыюны сорап гариза керткән.

Арсланов сүгенеп куйды.

—Иртәгә алтыда сөйләшербез әле.

Шәвәлиев аны алтынчы яртыдан сагалый башлады. Ләкин Арсланов килеп житә алмады. Чөнки ул төнге бергә кадәр йоклый алмады. Әйтерсең лә бөтенесе дә махсус аның нервысына тию өчен оештырылган иде. Өлкә комитетындагы киңәшмә бик киеренке барды. Аңа да ару гына эләкте. Җитмәсә, тәнәфестә пропаганда бүлеге мөдире аны култыклап читкә алып китте, Сабитовны укырга китүдән тоткарламаска үгетли башлады. Арсланов аның авызына чапкандай китеп барды. Чөнки ачуы килгән иде. Инде кайтуына хатыны, ул гына да түгел, Шәвәлиев тагын шуны әйтә. Каян килгән ил масштабындагы хәл ителергә тиешле олы мәсьәлә! Әйтерсең лә бөтен житәкчелек шуның белән генә шөгыльләнә.

Арсланов сәгать жидедә генә килеп житте. Аның күзләре кызарган, чырае ап-ак иде. Ул Шәвәлиев белән Нәҗмиевны икесен бергә чакырып кертте. Нәҗмиев ана Ирекнең гаризасын бирде.

—Боларның кул күтәрмәве хакмы соң?—диде Арсланов.

—Хак булмаса, язмас иде,—диде Нәҗмиев.

—Ну, биетәм әле мин аларны!—Арсланов ачу белән тешләрен кысты.—Безгә хуҗалык житәкчеләрен җыярга кирәк.—Арсланов, йодрыгын төйнәп, шыкы-шыкы өстәлгә сукты.—Карыйбыз аның гаризасын. Бу бюро башкаларга сабак булырга тиеш. Янадан мондый хәл кабатланмасын өчен. Шуна күрә хәзер безгә бераз шөгыльләнеп алырга кирәк.

—Аның Шәрифуллины бер атнага Казанга китте бит әле,—диде Шәвәлиев.

—Әйе, беләм.

—Чакыртып кайтарыйк без аны, Минзаһит Усманович.

—Ярый, кайтарт. Бусын ару гына селкетергә кирәк. Хәзер син миңа, Нәҗмиев, башта Сабитовны китер, сәгать тугызга Вафинны чакыр.

Шәвәлиев белән Нәҗмиев чыгып китеп, ярты сәгать үттеме-юкмы, ишектә Ирек күренде.

—Әйдә, уз әле, студент,—диде ана Арсланов.—Менә монда мин Казаннан кайтып керүгә, бик олы эш итеп, синең гаризаңны кертеп бирделәр.—Арсланов ашыкмыйча гына Ирекнең гаризасын укып чыкты.—Әгәр син моны язмаган булсаң, бөтенесе әйбәт кенә кала иде. Ә менә хәзер без сине партия җәзасына тартачакбыз.—Ул, сүзеннән туктап, аңа карап торды.

—Анысы инде сезнең эш,—диде Ирек.

—Хәзер ни өчен җәзага тартылачагыңны әйтәм. Син монда, бюрода алты кеше катнашкач, ул тулы вәкаләтле түгел, дип язгансың. Тугыз кешедән биш кенә катнашса да, бюро тулы вәкаләтле. Сиңа, ничә еллар буе райкомда инструктор булып, район газетасы редакторы булып эшләп, бу әйберне дә белмәү бик оят. Аннары. Син ике бюро членына яла ягасың.

—Ничек яла ягам?—диде Ирек аптырап.

—Шулай. Безнең бюро членнары белән алдан ук сөйләшеп куелган сүз бар: әгәр дә кем дә кем каршы, яисә битараф икән, ул, кул күтәреп, бюроны алып баручыга хәбәр итә. Вафин да, Шәрифуллин да моны эшләмәделәр. Димәк, алар безнең белән бергә кул күтәргәннәр.

—Алар кул күтәрмәделәр, мин карап тордым,—диде Ирек.

—Анысын тикшерербез. Шулай итеп, сине, райкомны алдап Мәскәүгә киткәнең һәм райком бюросына гаеп ташлаганың өчен партия җәзасына тартачакбыз.

—Тартыгыз,—диде Ирек.—Сезнең кулыгыздан бит барысы да килә. Ләкин мин гаризамның бүген йә иртәгә каралуын таләп итәм. Чөнки минем укуым башланыр вакыт җитте.

Арсланов, көләсе килмәсә дә, ясалма көлеп куйды:

—Син, Сабитов, Җир шары үзеңнең теләк белән генә әйләнә икән дип уйлыйсың булса кирәк. Ә бит аның үз законнары бар.

—Җир шары сезнең теләк белән генә дә әйләнми, Минзаһит Усманович,—диде Ирек, аның кызарган күзләренә туп-туры карап.

—Син аның кем теләге белән әйләнгәнен тиздән белерсең.

Ирек кабул итү бүлмәсендә Вафин белән очрашты. Аның йөзе борчулы иде.

—Сез кемгә?

—Минзаһит Усмановичка,—диде Вафин.

Ана Ирек тагын нидер әйтмәкче булды, ләкин секретарь хатын Вафинга керергә кирәклеген әйтте.

Арсланов Вафинны чытык йөз белән каршы алды. Күрешмәде, утыр димәде:

—Син нәрсә, Лотфулла Габдрахманович, подложил мне свинью?—дип, аны шелтәләргә керешә.

—Нәрсәне әйткәнегезне аңламадым.

—Менә моны укы әле,—беренче аңа Ирекнең гаризасын бирде.—Ну, дөрес язганмы, Сабитов, юкмы?

—Дөрес.

—Ә нигә сез ул вакытта кул күтәреп миңа әйтмәдегез?

—Анда вакыт калмады, сез шундук бюро тәмам дидегез.

—Ә соңыннан?

—Соңыннан аның әһәмияте юк иде инде...

—Әйбәт түгел, Лотфулла Габдрахманович. Сез район җитәкчеләре арасында минем иң хөрмәт итә торган кешеләрнең берсе идегез, үзенә ышанган кешене подводить итәргә ярамый. Дөрес әйтәмме мин?

—Дөрес, билгеле,—диде Вафин.—Ләкин, Минзаһит Усманович, моны

ни өчен сезне подводить итү дип анларга соң әле? Мин Сабитов укырга китәргә лаеклы дип саныйм. Әйбәт эшләде, укып кайтсын.

—Ярый, мин сезне тоткарламыйм.

Вафин аптырап урыныннан күтәрелде.

—Ә сез мине нәрсәгә чакырган идегез соң?

—Менә шушы мәсьәләдә фикерегезне белим дип. Ачыктан-ачык әйтүегез өчен рәхмәт. Хушыгыз.

Кабул итү бүлмәсенә чыгуга, секретарь хатын Вафинга:

—Сезне Зөфәр Шәрипович чакыра,—диде.

Ул кергәч, Шәвәлиев язып утырган кәгазен читкәрәк алып куйды да, күрешеп, аңа утырырга урын күрсәтте.

—Сез инде минем пленумга доклад белән утырганны беләсез,—дип башлады Шәвәлиев.—Бик авыр тема булып чыкты бу. Коммунистларның җаваплылыгын һәм үтәүчәнлеген күтәрү мәсьәләсе. Бюро әгъзаларының эшчәнлегенә аерым-аерым тукталмыйча булмый. Менә минем алдымда бюро утырышының апрельдә кабул ителгән карары. Анда районның ит хәзерләү планы куркыныч астында торуы күрсәтелә. Моның бер сәбәбе—колхозларда итне әрәм-шәрәм итү, эчке хуҗалык исәбенә күп тоту, законсыз сату дип басым ясала. Әнә шул сәбәпне бетерү бюро карары белән сезгә йөкләнгән. Сез алты хуҗалыкны тикшергәнсез, берничә җитәкченең хезмәт хакын тотып калу турында карар чыгаргансыз һәм шуның белән бетте. Бюродан соң үткән дүрт айда колхоз-совхозларда аерым кешеләргә генә дә дүрт тоннага якын ит сатыла. Ни өчен бюро карарын үтәү буенча башка чаралар күрелмәде?

Вафин кып-кызыл булды.

—Чаралар күрелде инде, нишләп күрелмәсен.

—Кая, әйтегез,—диде Шәвәлиев.

—Кайсын кисәттек, кайсыларына урынга барып, кайсыларына телефоннан әйтелде. Сез менә алты хуҗалык, дисез, җиденчесенә комитет утырышына «Үрнәк» колхозын әзерләгән идек. Колхоз председателе Өлфәт Җәлилов утырышка килүдән баш тартты. Ә хуҗалыкта документсыз шул айда гына ике сыер түшкәсе юкка чыккан иде. Мин тавыш кубардым, Минзаһит Усмановичка барып җиттем. Ул, хәзергә сабыр итегез, чара күрербез, диде. Яңадан кузгаттым, чара күрелә, диде. Күрелгәндер инде, шулай булгач.

—Димәк, Минзаһит Усманович гаепле?

—Юк, мин алай дип әйтмим,—диде Вафин.

—Сезгә йөкләнгән «Ярыш» колхозын алсак та, хәлләр мактанырлык түгел. Иген уңышы түбән, ашлык сату планы җитмеш процент, тунга сөрү акрын бара, шулай итеп миңа ни язарга кушасыз инде?

—Асылда ничек, шулай языгыз,—диде Вафин.

—Ә сез теге бюро карарының ни өчен үтәлмәве турында миңа информация язып кертегез. Кемгә сатылган ул шулкадәр ит?

—Аның кемгә сатылганын белмәгән кебек утырмагыз инде, Зөфәр Шәрипович.

—Кемгә соң?—диде Шәвәлиев.

—Кемгә булсын, сезгә.

—Ничек, ничек?!

—Сезгә.

Шәвәлиев хуҗалыклардан күпләп ит алучы җитәкчеләр исемлеген Вафинның алдына китереп салды.

—Табып күрсәтегез әле шушыннан минем фамилияне.

—Ягез инде, Зөфәр Шәрипович, уен уйнап утырмыйк. Сезнең фамилиягез анда булмау ул бит әле бәрәңге шулпасы эчеп кенә торасыз дигән сүз түгел.

—Ә сез дәлилләр белән сөйләгез!—дип җикерде Шәвәлиев.

—Дәлилләрен дә табып була. Итнең бит колхозлардан бөтенләй фамилиясез, акча түләмичә алына торганы да, башка фамилия язып, бик

очсыз хак белән китә торганнары да бар. Моны белмәгән кеше юк.

—Сез әле шуларны тикшереп йөрисезмени?

—Мин барысын да тикшерергә тиеш.

—Рәхмәт, пленум докладына кертерлек материал булды. Ә информациягезне иртәгәдән дә сонартмагыз.

Вафин бу сөйләшүдән үзен ни өчен чакыртканнарын тәмам аңлап чыкты.

## 30

Ирек кичке сигездә әллә ничә төрле дару эчеп йокларга ятты. Ләкин күпме генә ятмасын, күзенә йокы кермәде. Ул кулларының, башының җинелчә калтыранып торуын сизде. Мондый хәлнең аның белән беркайчан да булганы юк иде. Кинәт ул елаганга охшаш тавыш ишетте, одеалын өстеннән алып атты, һәм чыннан да кухняда ниндидер хатын-кыз сөйли, үзе елый иде:

—... Көне буе эшли алмадым... Житмәсә янымда утыручылар пышы-пышы киләләр... Инде өйгә тентү кертәселәре генә калды... Әхнәфне эзләп, кич бер инструктор килгән...

Ирек шунда гына елаучының Әхнәф хатыны икәнлеген таныды. Ул, сикереп торып, кухняга чыкты.

—Исәнме, Фәһимә, нәрсә бар?

—Безнең башка житәләр бугай инде,—дип, тагын да катырак елый башлады Фәһимә.

—Нәрсә бар? Аңлатып сөйлә әле.

—Иң элек «Ирең кайда? Адресын бир!»—дип Шәвәлиев шылтыратты. «Мин аны каян белим? Ул үзенең институтта бергә укыган дустында куна»,—дим. Ә ул ышанырга да теләми. «Юри яшерәсең, барыбер табарбыз»,—ди. Мин әйтәм: «Нишләгән соң ул? Нинди җинаяте бар?»—дим. «Ашыгыч кирәк, ничек булса да тап, әйт, райком белән элемтәгә керсен!»—ди. Көне буе инструкторлар җанымны ашадылар. Кичтән Хисмәтуллин, әллә тентү ясарга килгән, «Кайткан бит ул, нигә әйтмисез?»—ди. Нәрсә булган соң? Ник эзлиләр аны?

—Бюрога кайтармакчы булалар,—диде Ирек.—Минем гаризаны кабат караячаклар.

Алар, Фәһимәне юатып, чәй эчереп, бер нәрсәгә дә борчылмаска кушып, Сөембикә белән икәүләп өенә илтеп куйдылар. Кайтып керүләренә өйдә зыр-зыр телефон шылтырый. Төрепкәдә—Әхнәф иде.

—Нәрсә булды анда?—диде ул.

—Әле берни дә булмады.

—Монда хәзер мина Казан урамында йөрерлек рәт калмады. Радиога барсак та, Шәвәлиев эзли, шылтыратырга кушты, диләр. Телестудиягә барсак та, шул сүз. Кичә Химиклар сараена концерт белән барсак, сарайның директоры сәхнәгә йөгереп килгән: «Телефонда—икенче секретарегыз, әйдә, сөйләш»,—ди. Таба алмадым дип әйт, дип җибәрдем. Нәрсә бар соң?

—Мин бюрога гариза яздым. Китүемне кабат карауны сорап. Ике көннән бюро. Алар сине минем китүгә каршы тавыш бирдерәчәкләр.

Әхнәфнең көлгәне ишетелде.

—Мена анысы булмас инде!—диде ул.

—Мин инде, Әхнәф, сина берни дә әйтә алмыйм. Бар ягын да уйла, үзенә кыенга туры килмәсен.

—Минем дә хәзер әллә ни югалтасы әйбер калмаган,—диде Әхнәф.—Әллә сине сатып, урынымны саклап калыр дип ышанасыңмы? Әгәр алай уйласаң, син мине белмисең, Ирек.

—Рәхмәт, Әхнәф, беләм мин сине. Шулай да Шәвәлиевкә шылтырат син. Качып котыла торган әйбер түгел бу.

Аның белән сөйләшкәннән соң, Ирекнең тагын баш өянәге кузгалды.

Ынгырашып шактый ятканнан сон, ул түзә алмыйча урамга чыгып китте. Сәгать инде ун тулып киткән, урамда сирәк-мирәк парлашып йөргән яшьләр күренә. Электр яктырткан урыннарда аяк астында күренүче яфраклар, салкынча һава инде көз житкәнлеген сиздерә. Әнә кыз белән егет култыклашып кайта. Ирек аларның ни сөйләшкәннәрен ишетми, ләкин аларның авызлары—авызда. Менә кызы кинәт егетне этеп жибәрде, тегесе читкә сөрлекте, аларның кычкырып көлгән тавышлары ишетелде. Ул да булмады, кыз егетнен муенына асылынды. Ирек инде аларга шактый якынлашкан иде, акрын гына борылды да кирегә атлады. Аңа бик тә ямансу булып китте. Баллы Төбәк урамнарында Зәнфирә белән берниндигамьсез, берниндиуйсыз шаярышып йөргән чаклары әле менә бүген генә кебек иде бит. Шушы ук йолдызлар, аларның куанышып йөрүенә кызыгып карап торалар, жем-жем итеп күз кысалар иде. Яшьлек үтеп тә киткән. Ин коточкычы—беркая да юл юк. Кешенен тормышы, шулай матур башланып, шушындый фажига белән төгәлләнә микәнни? Әле бит, уйлап карасаң, гомер уртасы, таулар күчерер чак. Әмма тау күчерү түгел, теләгән жиренә дә күченә алмыйсың икән. Кешеләрнең тормышы шушы йолдызлар кебек матур булырга тиеш түгел микәнни? Бу галәмнен үзеге нәрсә икәнен кешелек әле һаман төшенеп житмәгән... Ин кадерлесе ни? Кешенең тәнеме? Шул тәннең тере торуымы? Юк. Тере жан ияләре күп. Кешедән кечкенәләре һәм зурлары да, кешедән көчсезләре һәм көчлеләре дә, кешегә караганда бик аз яшәүчеләре дә, бик озак яшәүчеләре дә күп.

Иң кадерлесе—һәрбер адәм баласының уй-омтылышлары, хистойгылары. Бары шул булганга гына, бәндә Кеше дип атала. Аның бөек жиһан тарафыннан бүләк ителгән һәм мәңгелек бизмәненнән караганда, бер генә дөртләп алуга тиң күнел тибрәлешләре, хыял-омтылышлары кагылгысыз! Ин бөеге, ин кадерлесе шул. Аңа тукыну—вәхшилек. Чөнки кеше гомере мәнгелектә бер генә, яна да сүнә, бүтән беркайчан да кабатланмый... Бөтенесе аңа баш иярге, аны аңларга, аңа хезмәт итәргә тиеш. Хәтта күкләрнең дә аңа табынулары зарур... Ирек яза торган яна Коръәннең нигезендә шушылар ятачак. Әгәр яшәеш шулай корылган булса, Ирек мондый хәлдә калмас та иде. Киләчәктә язам, тулаем ижатка керәм дип көндәлек мәшәкатьләр казанында кайнаганда, гомернең ин көчле чагы янып беткән. Киләчәк ул—бүген икән һәм ул көн саен ваклап-ваклап узган да киткән. Аны эләктереп калмасаң, вакыт ишегенен теге ягына «келт» итеп кенә чыга да үткәнгә әверелә икән...

Кешегә ярдәм кирәк! Аның бит жанын яралганнан бирле бутаганнар. Бөтенесе кешедән сорый, таләп итә, аны нинлидер кысаларга куып кертеп, яхшы сыйфатларын гына калдырмакчы, камилләштермәкче булалар. Ә каян килгән аңа әшәке сыйфатлар? Бары бер нәрсә—әйбер аркасында. Кешене үзе яралганнан бирле, әйбер белән алдап, һәлакәткә сөйрәү дәвам итә. Нинди фажига, нинди монафикълык-икейөзлелек: бер яклап, адәм балаларының күнелләренә әйбер дигән агулы орлыклар чәчеп, иң әшәке, иң кабахәт сыйфатларны үстерү, икенче яклап, изге сүзләр белән аны шул сыйфатларыннан баш тартырга, тыелырга, камилләшергә чакыру. Ләкин бит, беренчеләре—жисми булганлыктан, котылгысыз таркату, жимерү көченә ия, ә икенчеләре нибары буш сүзләр, һава тибрәлешенә генә кайтып кала.

... Иртә көзнең салкынча төнендә, йолдызлы күккә карап, Ирек ант итте: ул үзенең гомерен кешегә ярдәм итүгә багышлаячак! Аның китабы әнә шул юлда байрак булачак!

* * *

Шәвәлиев стенадагы барометрны карыйм әле, дип, кузгалган иде, телефон шылтырады. Тавышына караганда, ул шәһәрара станциядән иде. «Сәгать жиденче унбиш минутта кем борчый икән?»—дип уйлады Шәвәлиев һәм трубканы алды.

—Исәнмесез, Зөфәр Шәрипович.

—Шәрифуллин, синме бу?!

—Әйе, мин.

—Нәрсә син анда качып йөрисең? Мин бит сине эзләп, хәзер ярты Казанны аякка бастырдым.

—Миңа кичә кичтән генә әйттеләр,—диде Әхнәф.—Туры килә алмаганбыз бит. Нәрсә бар соң?

—Нәрсә барын кайткач белерсең. Хәзер үк кайтып җит. Беренче рейс белән.

—Сез ни сөйлисез, Зөфәр Шәрипович? Казанга шушы кадәр кеше алып кил дә кайтып китеп буламыни? Бүген иртәнге якта телестудиядә безнең репетиция, ә төштән соң төшерәчәкләр, беркая да китә алмыйм мин.

—Синнән башка төшерерләр. Син минем әйткәнне аңлыйсыңмы?

—Кайтмыйм, Зөфәр Шәрипович. Анда минем чыгыш та бар.

—Синең ул чыгышыңны икенче секретарең сөйләр. Мин сиңа кайтып җитәсең, дим!

—Кайтмыйм, исән булыгыз!

—Шәрифуллин!—дип кычкырды Шәвәлиев, ләкин трубкада «түт-түт» дигән өзек-өзек тавыштан башка берни дә ишетелми иде.

* * *

Телестудиядә репетиция әле башланган гына иде. Әхнәфне «Сезне бер кеше чакыра» дип, дәшеп алдылар. Кем икән дип чыгып, үзенең ин актив комсомолларының берсе—район эчке эшләр бүлеге сотруднигы Урусовны күргәч, аптырап китте.

—Син нишләп йөрисең монда, Ваня?—диде ул.—Әллә безнең белән чыгыш ясарга килдеңме?

—Әхнәф абый,—диде Урусов, аңа ни фамилиясе белән, ни исеме белән эндәшергә белмичә икеләнеп торганнан соң.—Мине сезгә җибәрделәр.

—Нәрсә, чыгыш ясаргамыни?—диде Әхнәф.—Әйдә, кертәбез.

—Юк, мине сезне алып кайтырга җибәрделәр.

—Алып кайтырга?! Кем җибәрде?

—Райком. Икенче рейс белән без кайтып җитәргә тиеш.

—Син монын ни икәнен беләсеңме соң? Минем бит милиция сагы астында кайтырлык берниндн дә җинаять кылганым юк. Без район яшьләре белән монда эш эшләп йөрибез.

—Мин берни дә әйтә алмыйм,—диде Урусов.—Начальник кушты, мин килдем.

—Бар, син тыныч кына кайтып кит,—диде Әхнәф аңа.—Эш беткәч, мин үзем кайтып җитәрмен.

—Юк инде, Әхнәф абый, мин бит приказны үтәргә тиеш. Сездән башка кайтып керә алмыйм мин.

—Ә мәнә мин сиңа комсомолларча кушам. Курыкма, берни дә булмас. Барлык җаваплылыкны үз өстемә алам.

—Сездән башка кайтмыйм инде мин, Әхнәф абый...

Бик тә үтәүчән кеше иде шул Ваня. Аның кайтып китмәячәген Әхнәф яхшы аңлады.

—Ул вакытта көтәсең инде,—диде ул.

Репетиция барган урынга кереп, Әхнәф тапшыруны әзерләүче редакторга эшнең нәрсәдә икәнен аңлатты. Ул, әлбәттә, арттан милиция җибәргәннәр, димәде, райкомда ашыгыч эш килеп чыккан, бүген үк кайтып житүне таләп итәләр, диде. Шуннан соң аның чыгышын яздырдылар да, ул Урусов янына чыкты.

—Әйдә, Ваня, «Казан» кунак йортына киттек,—диде ул.

Троллейбус белән кайтып, портьега кергәч, Әхнәф:

—Хәзер монда безнең икенче секретарь килергә тиеш,—диде.—Карап кына тор, аны күрү белән туктат, мине көтсен. Мин хәзер әйберләремне җыеп, бүлмәмне тапшырам да чыгам.

Урусов урамнан керүче ишек турында басып калды. Әхнәф ашыга-ашыга уң якка китеп барды. Урусов башта бик озак стенага сөялеп торды, ярты сәгатьләп вакыт узгач, ул, түземсезләнеп, сәгатен карый башлады. Ахырда бер сәгать тә, сәгать ярым да үтте. Ул, тынычсызланып, дежурный янына китте. Әхнәф Шәрифуллинның кайсы бүлмәдә яшәвен сорады. «Икенче катта андый кеше яшәми», диде дежурный, кенәгәсеннән тикшереп чыккач.

—Ә ничек белергә була соң?

Дежурный хатын, администраторга шылтыратып, Әхнәфнең кайсы бүлмәдә торуын сорады. Өченче катта, өч йөз уникенче бүлмәдә, диде ул. Әллә нинди кәкре-бөкре коридорларда адаша-адаша, икенче катка кабат төшеп, янадан менеп китеп, ниһаять, әлеге бүлмәгә килеп төртелде Урусов. Ләкин аның ишеге бикле иде. Ул аны тарткалап та, шакып та карады, эчтән тавыш-тын ишетелмәде. Урусов дежурныйга мөрәҗәгать итте.

—Әйе, алар анда ике кеше тора,—диде дежурный.—Ләкин хәзер беркем дә юк. Шәрифуллинмы? Шәрифуллин моннан ике сәгать элек ачкычын калдырып, чыгып китте.

—Бүлмәсен тапшырдымы соң ул?—дип сорады Урусов.

—Тапшырмады, нишләп тапшырсын? Ул бит әле бирedә тора, акчасы түләнгән.

Урусов аптырап, беренче катка төште. Әллә ашап утыра микән, дип, ресторанга кереп карады. Ләкин Әхнәф анда да юк иде. Инде икенче рейс самолет очар вакыт житеп килә. Ул, Куйбышев мәйданындагы телефон станциясенә төшеп, начальнигы белән элемтәгә керде.

—Ачык авыз!—дип кычкырды ана Мәрдиев.—Син берни дә аңламыйсыңмыни?! Ул сине кәкре каенга терәтеп качкан! Трубканы куймый тор, мин райком белән элемтәгә керим әле,—диде ул. Аннары бер-ике минуттан Урусовка:—Бүген кич эзләп кара, теге чыгыш ясаучылар янына килми калмас ул. Әгәр тапсаң, шылтыратырсың. Төнлә теләсә кайсы вакытта машина җибәрербез. Иртәгә сигезгә кайтып житмәсә, аның кирәге юк.

Урусов, телеграфтан чыгып, кая барырга белмичә, аптырап басып калды.

Әхнәф Урусовтан ычкыну белән ВЛКСМ өлкә комитетына юл тотты. Телестудиядән чыкканда, ул аның белән бергә Болынкырга очарга ниятләгән иде. Ләкин акрынлап әлеге уеннан кире кайтты, үзе өчен язмышының йә тегеләйгә, йә болайга хәл ителү сәгате сукканлыгын аңлады. ВЛКСМ райкомы секретаре булып пенсиягә кадәр утыра алмасын ул яхшы белә һәм хәзер башка эшкә күчү мәсьәләсен шушы киеренке моментта йә бер якка, йә икенче якка хәл итмичә булмый иде. Ничә еллар буе сорап йөреп, Арсланов аны аспирантурага җибәрмәде. Уку яше чыккан булса да, аспирантурага керергә иде исәбе. ВЛКСМ өлкә комитетының беренче секретаре бүлмәсен ачып керүгә, теге аңа ташланды:

—Син кайда йөрисең, Шәрифуллин?!—диде ул, тавышын күтәреп.—Райкомыгыз сине эзләп желеккә төште ләбаса!

—Минем кайда йөргәнне сез яхшы беләсез,—диде Әхнәф.

—Ә нәрсә булган соң анда ул кадәр?

Әхнәф ана барысын да аңлатып бирде.

—Хәзер мине алып кайтырга милиция җибәргәннәр. Әле мин, шуннан качып, синең янга килдем.

—Бу сезнең районда, гомумән, хәзер нишләгәннәренә исәп-хисап бирми башладылар. Ничек инде комсомолның беренче секретарен Казаннан алып кайтырга милиция җибәрергә мөмкин?!—дип ярсыды ул.—Мин моны болай калдырмаячакмын! Мин өлкә комитетының беренче секретарена керәчәкмен бу мәсьәләдә.

—Йөрмә, файдасы булмас. Мин инде бюрога кайтмаска карар кылдым. Син мине күрмә дә, белмә дә.

—Үзеңә кара инде, Шәрифуллин. Мин күрмәдем, белмәдем, сине таба алмадым. Вәссәлам!

—Мин бер нәрсә генә сорыйм, миңа читтән торып аспирантурага керергә кулдан килгәнчә ярдәм итсәгез иде. Укыйсы килә минем.

—Анысына ярдәм итәрбез.

Әхнәф чыкты да Дербышкида яшәүче дустына китте...

## 31

Иртәгә бюро дигән көнне Вафинны Нәҗмиев үз бүлмәсенә чакырды.

Вафин ишекне ачу белән тәрәзә кырында басып торучы КГБ хезмәткәре Йөзлебаевны күрде. Алар танышлар иде, Йөзлебаев районга килгәләп тора, үзе Бөгелмә шәһәрендә яши, аларның элегрәк «Татарстан» кунак йортында берничә көн буе бергә дә торганнары бар иде. Шуннан соң, Йөзлебаев районга килгәч, Вафин аны үзләренә чакырып, алар бик күңелле генә кич утырганнар иде. Шуңа күрә, иске танышлар кебек, җылы итеп кул кысыштылар.

—Мине монда чакыралар, дигәннәр иде...

—Йә инде, Лотфулла Габдрахманович,—диде Йөзлебаев, кочаклагандай аның иңбашына кулын салып.—Нинди чакыру ди! Просто бер сөйләшеп утырасы килде. Әле менә оныкка сезнең универмагтан пальто алыйм дип килгән идем. Размеры туры килмәде. Сезнең оныклар бармы соң?

—Минем оныкларның инде балалары үсә,—диде Вафин.

Алар янәшә утырдылар.

—Картаябыз, картаябыз,—диде Йөзлебаев. Аннары нәрсәдер уйлап торган кебек итте дә Вафинга бөтен гәүдәсе белән борылды.—Безнең, Лотфулла Габдрахманович, эшләребез дә, фикерләребез дә охшаш. Хәтерлисезме Казанда сөйләшеп утырганны?

—Хәтерлим, билгеле.

Алар ул чакта партиянең дә, хөкүмәтнең дә тетмәсен теткәннәр иде. Шунысы кызык, фикерләренең уртаклыгы аларны гомер буе бергә яшәгән кешеләрдәй якынайтты, иң яшерен серләрен чиштерде. Безнең иң зур чиребез—бер партиялелектә, дигән ныклы карарга килүләре хәтергә уелып калды. Бу чир партиянең югары органнарында утыручыларның котылгысыз культын тудыра, фикер көрәшенә, тәнкыйтькә урын калдырмый, бер кешенең сүзе, дөреслегенә-ялгышлыгына карамастан, законга әверелә, җәмгыять тынчый, таркала. Брежневның герой арты герой, маршал исемнәре, кат-кат дәүләт бүләкләре, Җиңү ордены алуына, илнең тормозына әверелүенә нәфрәт белдергәннәр, әрнегәннәр, сызланганнар иде...

—Мин дәүләт иминлеген саклыйм, сез дә халыкның күзе-колагы,—дип сүзен дәвам итте Йөзлебаев.—Шуңа күрә килү белән иң элек сезгә мөрәҗәгать итәргә булдым. Безгә бер сигнал кергән иде.

—Нәрсә ул?

—Районда җитәкчеләрнең яшерен оешмасы бар, ди. Сез шул хакта нидер белмисезме?

—Беренче мәртәбә сездән ишетәм. Авыл җирендә нинди оешма булсын инде...

—Колхоз председательләре советы дигән нәрсә колагыгызга чалынмадымы?

—Юк...

Йөзлебаев үпкәләгән кебек читкә китте.

—Ә бит андый сүз йөри, ди. Ничек сез генә ишетмәдегез икән?

—Бәлкем мина андый сүзне әйтергә куркалардыр?

—Ихтимал, бик ихтимал.—Йөзлебаев никтер өстәл лампасының яндыргычына, черт-черт итеп, берничә мәртәбә баскалап алды.—Ул чакта, Лотфулла Габдрахманович, сез миңа берничә җөмлә генә аңлатма язып бирерсез инде...

—Нинди аңлатма?

—Яшерен оешма барлыгын белмим, председательләр советы турында да ишеткәнем юк, дип язып бирсәгез, шул җитә.

—Габбас Йөзлебаевич, биредә минем ни катнашым бар соң?

—Ягез инде, юкка сүз озайтмыйк,—диде Йөзлебаев, дустанә тавыш белән.—Сездән дә алмагач, кемнән алыйм мин аны? Без бит сезгә таянып эшләргә тиеш. Миңа теге сигналны калыпка кертеп, нокта куярга кирәк.

—Сәер, бик тә сәер,—диде Вафин аптырап.

—Мин шушындый ук аңлатманы хокук саклау органнарыннан да алачакмын.—Йөзлебаев, өстәлдәге кәгазь битләрен рәтләп, алар янына ручка куйды.—Язып кына бирегез инде зинһар.

Вафинның күңеленнән нindидер бер шомлы нәрсә йөгереп узды, ләкин ул аның тәгаен генә сәбәбен белә алмады.

—Сәер... Мондый хәл үз гомеремдә беренче мәртәбә...

Йөзлебаев кинәт тураеп басты, аның болай да озын гәүдәсе тагын да сузылыбрак киткәндәй тоелды.

—Гафу итегез, Лотфулла Габдрахманович,—диде ул башын иеп, күзлек өстеннән карап.—Сезнең бөтен кыяфәтегез, үз-үзегезне тотышыгыз аңлашылмый. Миндә бер фикер туды: сез бу оешма хакында әллә беләсезме? Алай гына да түгел, анда әгъза булып та тормыйсыңдыр бит?

Юк, алдаша Йөзлебаев. Ул Лотфулланың үзен тотышыннан гына мондый нәтиҗәгә килә алмый. Димәк, ул нидер чамалый, яисә, барысын да белеп, юри яшерә, Лотфулланың үзенең тануын тели.

—Кешенең тышкы кыяфәтеннән генә чыгып, аңа гаеп ташлау... бу инде... мин хәтта сүз таба алмыйм...

—Ярый, мин хаксыздыр. Ә шулай да, баягы сорауга сез ник борчылдыгыз? Әгәр ул совет дигән әйбергә бернинди мөнәсәбәтегез юк икән. Ник?

—Мине сезнең тора салып сорау ала башлавыгыз аптыраштa калдырды, хәтта каушатты.

—Нишләп?

—Утызынчы еллар җиле искәндәй булды.

—Утызынчы еллар үтсә дә, тәртип бер үк,—диде Йөзлебаев, тимер тавыш белән.—Кем илнең иминлегенә тукына, җинаятенә карап җәзасын ала һәм алачак. Үтәр гомерләр, килгән буыннарны безнең белән өркетерләр, һәр чор үз бүкәйләрен тудыра. Сыйныфларны бетерсәк тә, бай белән ярлының психологиясе аларның эчендә пычакка-пычак каршы хәлдә яши бирә. Моны ачыклау ай-һай кыен! Әйтик, менә сездә кем утыра: себергә сөрелгән әтиегезме, әллә аның өчен үч алу тойгысымы?

Вафин гаҗәпләнүдән баш чайкап куйды.

—Сезгә шул кирәкме? Мин югары белем алган кеше, утызынчы еллардагы хәлләрне җентекләп өйрәндем. Ул чорда булсам, кем белә, мин күбрәк тә хаталар ясар идем. Шуңа күрә микроскоп аша карасагыз да, сез миндә күрергә теләгән нәрсәне таба алмассыз.

Йөзлебаев кояштай ягымлы итеп елмаеп җибәрде.

—Гафу, гафу! Аңлаштык—бетте. Язып кына бирсәгез...

Вафин, һаман да нәрсәдәндер шикләнә-шикләнә, аңлатмасын язып бирде.

—Рәхмәт, булган бу,—диде Йөзлебаев.

—Мина китсәм ярыйдыр бит?

—Юк әле, хөрмәтле Лотфулла Габдрахманович,—диде Йөзлебаев, уң күзен кысып елмайды.—Утырыгыз! Сезнең белән гәпләшеп утыру үзе бер гомер бит.—Ул папкасыннан берничә бит кәгазь алды.—Менә монда район председательләр советында сезнең әгъза булып торуыгыз турында хәбәр ителә...

Вафин, үзе дә сизмәстән, торып кәгазьгә үрелде:

—Кая, күрсәтегез әле!

—Чү, чү, Лотфулла Габдрахманович! Сездә шактый нык чәүчәләклек галәмәтләре сизелә.—Аның бая елмайганда кысылган уң күзе зураеп китте.—Бик теләсәм дә, хәтта өстәрәк утыручыларга да минем аны күрсәтә алмаганымны сез яхшы беләсез. Шулай булгач, чәбәләнмичә генә сөйләшик, аңлашыйк.

—Барысын да белгәч, бу өч тиенгә ярамый торган аңлатманы яздырып, нигә вакыт уздырдыгыз?

Йөзлебаев куанычыннан шаркылдап ук куйды:

—О-о-о! Сез тирән ялгышасыз!—Ул Вафинның аңлатмасын күкрәгенә кысты.—Бу—иң мөһиме. Сез ихлас күңелле, тугры коммунистмы, әллә инде битлек киеп йөрисезме?.. Бу аңлатма—шуны раслаучы документ. Аңлыйсызмы: до-ку-мент! Димәк, сез председательләр советы барлыгын да, анда әгъза булып торуыгызны да катгый рәвештә кире кагасыз. Шулаймы?

Йөзлебаевта асылда бернинди мәгълүмат та юк, ул Нәҗмиев авызыннан чыккан әллә кайчангы имеш-мимешне генә файдалана иде. Кызганыч ки, Вафин аны болай кабул итә алмады.

—Без бит якын танышлар,—Йөзлебаев чыраен Вафинга шулкадәр якын китерде, ул аның авызыннан бөркелүче тәмәке катыш авыр тынчу истән чак укшып җибәрмәде.—Әйдәгез, болай килешик: анда сезнең әгъза булып торуыгызны беркем дә белмәс. Бусына мин йөз процент гарантия бирәм. Тик бер шарт белән: анда кемнәр барлыгын әйтегез генә. Бернинди язусыз-имзасыз...

Менә шунда Вафин күңеленнән әле генә үткән шомның нәрсә икәнен аңлады.

—Мин сезнең бер соравыгызга да җавап бирмәячәкмен!—диде ул, аягүрә басып.

—Ни булды, Лотфулла Габдрахманович?—Йөзлебаев аңа таба кулын сузды.

—Кагылмагыз мина!

—Зинһар аңлатыгыз, ни булды?

—Сезнең яшькә җиткәч, шестерка[1] булып йөрергә мин оялыр идем! Ул чакыру белән килеп җиттегезме?

Йөзлебаевның чыраендагы ясалма елмаю сөртеп алгандай юкка чыкты.

—Мина шуның өчен хезмәт хакы түлиләр.

—Алайса шулар белән эш итегез инде. Минем сезнең белән сөйләшер сүзем юк.—Вафин ишеккә юнәлде.

—Минуточку!—диде Йөзлебаев.—Безнең сөйләшер сүзләребез бик күп, хөрмәтле Лотфулла Габдрахманович.

Ул тәрәзә төбендәге диктофонны җибәрде. Вафин үз колакларына үзе ышанмады: аннан «Татарстан» кунак йортында теге чакта сөйләшкән сүзләр яңгырый башлады...

—Туктагыз!—дип ялварды ул.

—Бөтенесе бер җепкә теркәлә,—диде Йөзлебаев, диктофонны туктатып.—Сыйнфый ачу сездә. Ифрат та куркыныч сезнең кебекләрне

---

[1]Шестерка—жаргон сүз. Әләкче, кемнәрнеңдер табанын ялаучы дигән мәгънәне белдерә.

партиядә тоту. Чын дошманлык! Сезнең кебекләрдән котылу гына житми, халыкка матбугат, радио, телевидение аша сөйләргә кирәк!

Вафин берничә мәртәбә авызы белән тирән-тирән итеп сулыш алды, аннары, ничектер кыйгаеп китеп, урындыкка таянды һәм дөпелдәп идәнгә ауды. Йөзлебаев кызу-кызу чыгып китте һәм, Нәжмиев бүлмәсенә кереп:

—Тизрәк ашыгыч ярдәм чакырыгыз, ул егылды,—диде.

Ашыгыч ярдәм линиясе буш түгел иде. Нәжмиев баш врачның үзенә шылтыратты.

—Хәзер үк килеп житегез!—диде ул.

Нәжмиев Вафин яткан бүлмәгә йөгереп кергәндә, аның иреннәре күкшелләнгән, йөзе ап-ак булган иде.

—Хәзер аңына килә, мин аңа салкын су бөркедем,—диде Йөзлебаев, Вафинның күлмәк якасын ычкындырып.

Ул тәрәзәне ачып жибәрде, бүлмәгә саф һава керде. Ашыгыч ярдәм машинасының райком ишек алдына кереп туктаганы күренде. Аннан төшеп, баш врач, терапия бүлеге мөдире, калай тартмасын тоткан шәфкать туташы йөгерешеп бүлмәгә килеп керделәр. Вафин инде күзен ачкан иде, ул, берни аңламагандай, битараф карашын түшәмгә төбәп ята бирде. Терапевт аның авыруын белә иде, бармагы белән пульсын тикшерде дә шәфкать туташына нинди уколлар ясарга кирәклеген әйтте. Иң элек аның кан тамырына укол бирделәр. Йөзлебаев белән Нәжмиев ишеккә юнәлделәр, соңгысы баш врачка: «Әйдәгез әле безнең белән»,—дигән мәгънәдә ым какты.

Йөзлебаев тәмәке тартырга китте. Нәжмиев баш врачны бүлмәсенә алып керде:

—Ничек аның хәле?—диде ул.

—Хәзер үк больницага салабыз. Йөрәк, нервылар—бөтенесе бергә.

—Беләсезме, мин сезгә Минзаһит Усманович исеменнән мөрәҗәгать итәм. Сез аны өендә килеш кенә дәвалый алмыйсызмы?

Баш врач, аңа аптыраулы карашын төбәп, сүзсез калды.

—Беләсезме, эш нәрсәдә? Иртәгә безнең бюро. Һич югы бер ярты сәгать кенә булса да Вафин шунда катнашырга тиеш. Бу шулкадәр мөһим, нинди генә дарулар биреп булса да, менә шушы әйберне эшләргә кирәк.

Баш врач маңгаен ышкый-ышкый уйланып торды.

—Ну, әгәр сез теләсәгез... Хәзер терапия бүлеге мөдире белән киңәшеп карыйм...

Бераздан ул Нәжмиев бүлмәсенә керде:

—Тәвәккәлләп карыйбыз инде...

Врачлар Вафинга бүгенгә кайтып ял итәргә, борчылмаска куштылар, дарулар биреп, өендә калдырдылар.

Нәкъ шул вакытта Ирек беренче секретарь бүлмәсенә килеп кергән иде.

Арсланов аның сәламен алмады, күз кабаклары астыннан тишәрдәй итеп карап торды да:

—Син ни белән шөгыльләнәсең?—диде.—Ник син шундый пычрак әйберләр белән эш итәсең?

—Нинди пычрак әйбер?

Арсланов аңа машинкада пөхтәләп басылган һәм бергә беркетелгән ике бит кәгазь атты. Шул арада телефон шылтырап, ул кем беләндер сөйләшә башлады. Ирек ашыга-ашыга кәгазьне укып чыкты. Район газетасы коллективының аны укырга жибәрүне сорап, Арсланов исеменә язган хаты иде бу.

Ирек берәм-берәм имзаларны карап чыкты. Редактор Хасбулатовадан башка, коллективтагы барлык кешеләр дә кул куйган иде. Ирекнең таштай каткан күңеле йомшап китте. Шулай да, мәрхәмәтле кешеләр бар әле дөньяда, дип уйлады ул. Аның уйларын Арслановның тавышы бүлде:

—Әйбәт оештыргансыз, просто молодец!

—Гафу итегез, минем бу язманы беренче күрүем.

—Акланма, кирәкми!—Арсланов үтүк баскан төсле чыраен Ирекка таба иде.—Тик сиңа бер нәрсәне белергә кирәк: Үзәк Комитетка җибәрсәң дә, башта обкомга, аннары,—ул имән бармагы белән өстәленә төрткәләде,—менә монда кайта ул... Ай-яй башыгыз йомры! Шәрифуллин аспирантурага китмәкче, син—артистлыкка. Башкасы башка җиргә. Син анда... Мәскәү маржалары өстендә ятканда, мин монда пахать должен, да?! Синең бу сасыган районыңа әллә мине үзем теләп килде дип беләсеңме?!

Ул йодрыгы белән өстәлне дөпе-дөпе төйде һәм, тешләрен кысып, юкарып алга чыккан иреннәре арасыннан:

—Не поедешь!!!—дип ысылдады.

—Ә мин барыбер китәчәкмен!—диде Ирек, түрә котырган саен, күңеленең нишләптер тынычлана баруын тоеп.

—Поедешь только через мой труп!

—Мин барыбер укыячакмын!—диде ул һәм, ишеген каты ябып, чыгып китте.

Ул кайтуга, Казаннан Әхнәф шылтыратты.

—Йә, буламы бюро?—диде ул.

—Әйе, иртәгә.

—Ничәдә?

—Сигездә,—диде Ирек.

Аннары үзенең бүген Арслановта булуын, соңгы ике көндәге хәлләрне сөйләп бирде.

—Ярар,—диде Әхнәф.—Мин бюро исеменә телеграмма сугам. Сине укырга җибәрү өчен тавыш бирәм, дип.

—Үзеңә начар булмасмы?

—Хәзер туктау юк! Дәшмичә күп яттык инде. Җитәр!—диде Әхнәф.

* * *

Икенче көнне иртән җиденче яртыга Вафинны беренче секретарьга чакырдылар. Ул тынычлану өчен берничә төрле дару кабып барды. Арсланов, өстәле артындагы дүрт-биш метр арада йөри-йөри, кулын артка куеп, сүз башлады:

—Лотфулла Габдрахманович, безгә соңгы вакытта булган мөнәсәбәтләрне ачык бер хәлгә китерергә кирәк. Аның иң беренчесе—теге чакта сезнең «Авангард» колхозында керемгә алынмаган дүрт центнер йон табуыгыздан башланды. Ну, алынмаган, вакыты житкәч, алыныр дип аңлаттык. Ә син шуның белән республикага шауладың.

—Яңадан туктадык бит,—диде Вафин.

—Әйе, республика прокуратурасыннан китереп кыскач. Сез кендегегездән биегрәк сикерергә азапланасыз. Үткән бюрода сез тагын миңа каршы... Мин ачуланмыйм да, кычкырмыйм да. Мондый төрле фикер белән эшләү сезгә дә, миңа да кыен. Моннан котылырга кирәк.—Арсланов, бер кулына ручка, икенче кулына бер бит кәгазь тотып, Вафин каршына килде дә аларны аның алдына куйды.

Вафин аптырап, аңа күзләрен тутырып карады.

—Языгыз гариза,—диде Арсланов тыныч кына.

—Нинди... гариза?..

—«Сәламәтлегем какшау сәбәпле, үз теләгем белән эштән азат итүегезне сорыйм», дип языгыз.

—Сез нәрсә, Минзаһит Усманович? Мин андый гаризаны яза алмыйм.

—Нишләп яза алмыйсыз сез аны?

—Миңа бит яшәргә кирәк. Миңа пенсиягә чыгарга ел ярымнан артык вакыт калды.

—Анысы минем эш түгел. Языгыз.

—Минем йорт салганда алган унбиш мең ссудам да түләнеп бетмәгән. Оныгым баласы белән минем өйдә утыра.

—Лотфулла Габдрахманович, болар барысы да сүзләр. Языгыз гаризагызны.

—Сез мине үтерергә телисезмени?—Вафинның тагын бөтен тәне калтырый башлады. Аның танкта янган урыннары кан төсле кып-кызыл булды. Уң як кашы өзлексез сикерде.

—Киресенчә, мин бит аңлатып әйттем: миңа каршы килгәч, башка юл юк бит инде...

Вафинның күзеннән яшь бәреп чыкты.

—Минзаһит Усманович, сезнеңчә булыр... Бары сезнеңчә генә...—Ул, күз яшьләрен күрсәтмәс өчен, ике битен кулы белән каплады һәм тавышсыз-тынсыз, иңбашларын селкетеп елый башлады.

—Ну, ярый, ярый, тынычланыгыз,—диде Арсланов, аның алдындагы кәгазь белән ручканы алып.—Ышанып карыйм мин сезгә тагын беркадәр...

—Рәхмәт... Рәхмәт сезгә...

Вафин битен кулъяулыгы белән сөртә-сөртә чыгып китте. Кабул итү бүлмәсендәгеләр аның исерек кеше кебек чайкала-чайкала атлавын гаҗәпләнеп тә, кызганып та карап калдылар...

Бюро нәкъ сигездә башланды.

Иң элек партиягә алынучы биш-алты кеше кереп чыкты. Аннары «Тугай» совхозының терлекләрне торакларга кайтару буенча канәгатьләнмәслек эшләве турындагы мәсьәлә каралды. Аны тикшергән вакытта кабул итү бүлмәсенә секретарьга телеграмма китереп тоттырдылар. Ирек шунда утыра иде, урыныннан торып күз төшермәкче булды, ләкин секретарь аны күрсәтмәде, шундук Арслановка алып кереп китте. Ирек тиз генә чыкты да, буш бүлмәгә кереп, телеграфка шылтыратты. Анда аның күрше кызы Халидә эшли иде.

—Райкомга хәзер генә килгән телеграмманың эчтәлеген әйт әле зинһар,—диде ул.

Халидә пышылдап кына аның эчтәлеген әйтте. Телеграмманы Әхнәф суккан, «Сабитов укырга китәргә тиеш, шуның өчен тавыш бирәм», дигән. Ирек җиңел сулап куйды. Бераздан совхоз кешеләре чыккач, аны чакырдылар. Ирек кереп баскач, бюро членнары барысы да кызыксынып, ана төбәлделәр. Арсланов кычкырып аның гаризасын укып чыкты.

—Сабитовның язуынча,—диде ул,—ике бюро члены аны укырга җибәрмәү өчен тавыш бирмәгән. Сез кул күтәрмәдегезмени, Лотфулла Габдрахманович?

Вафин чайкалып торып басты. Бер генә мизгелгә аның күз карашы Ирекнеке белән очрашты. Ләкин Вафин керфекләрен аска төшерде, бурлаттай кызарган яраларын кулъяулыгы белән сыпыра-сыпыра:

—Мин ул чакта нәрсәдер уйлап буталганмын... аңлап җиткермәгәнмен...—Аның сүзләре авызыннан ватыла-җимерелә чыккандай ишетелделәр.—Мине калганнар белән бергә дип санагыз...—Ул, калтыранган куллары белән битен сөртә-сөртә, урынына утырды.

—Без бюро члены Шәрифуллиннан да телеграмма алдык,—диде Арсланов.—Ул хәзер Казанда безнең районны пропагандалап йөри. Рөхсәт итегез бюро членнарын шул телеграмма белән таныштырырга. «Я голосовал и голосую против отъезда Сабитова на учебу. Шарифуллин.»

—Алай түгел бит, ник алдыйсыз?—диде Ирек.

Арсланов, елмаеп, бюро протоколын алып баручы гомуми бүлек мөдиренә телеграмманы сузды.

—Укытыгыз аңа...

Ирек хәйран калды: телеграмма нәкъ Арсланов укыганча иде!

—Безнең бюроның ни дәрәҗәдә монолит икәнлеген күрдеңме инде, Сабитов?

Ирек дәшмәде.

—Бүген безнең каршыда басып торучы Ирек Сабитов, райкомны алдап, Мәскәүгә китте. Икенчедән, ике бюро члены, аларның тавыш бирүләрен юкка чыгарырга теләп, пычрак атты. Сабитов, редакция һәм типография коллективы исеме астында хат язып, үзен Мәскәүгә җибәрүне сората. Ниһаять, инде соңгы чарага керешә: абыйсы Мэлс Сабитовны миңа өстереп кертеп җибәрә, һәм ул Беренче секретарьга физик көч куллану белән янап чыгып китә. Шушы эшләр өчен Ирек Сабитов каты партия җәзасына тартылырга тиеш. Кемнәрдә нинди фикерләр булыр?

—Мин, сезнең сүзегезгә өстәп, бер генә нәрсә әйтергә теләр идем,— диде Нәҗмиев басып.—Сабитов бюро членнары арасында, үзен укырга җибәрүне сорап, астыртын эш алып барды. Кайсын җайлап, кайсын майлап, үзе өчен тавыш бирергә чакырды. Шундый ук омтылышны ул миңа карата да ясады. Мин Сабитовның Минзаһит Усманович санаган һәм мин әйткән эшләре бернинди партиялелек рамкаларына сыймый дип саныйм һәм аны КПСС сафларыннан чыгарырга тәкъдим итәм.

Аннары Батталов күтәрелде.

—Сабитовның санап кителгән эшләре,—диде ул,—безнең Беренче секретаребыз Минзаһит Усмановичның, димәк, райкомның абруен төшерә. Аның абыйсы да шул ук эш белән мәшгуль. Киңәшмәләрдә, гомуми бюроларда күренгәнчә, ул Беренче секретарьның кушканнарын үтәми, тәнкыйтьне кабул итми. Гомумән, районда кайберәүләр тарафыннан партиянең абруен, җитәкчелек ролен киметү эше алып барыла. Моны партиягә һөҗүм дип бәяләргә кирәк. Әлеге кешеләр нигездә җитәкчеләр арасында һәм бу шуның белән куркыныч та. Моңа чик куелырга тиеш. Шуңа күрә бүген бюро катгый сүзен әйтер дип уйлыйм. Сабитов, мин сине яклап та карадым. Тик үзгәреш булмады. Гел райкомга каршы бардың. Мондый кешеләрдән партиягә зарардан башка файда юк. Шуңа күрә аларны КПСС сафларыннан чыгарырга кирәк дип саныйм. Аның каравы, сафларыбыз чистарып калыр, бүтәннәргә сабак булыр.

—Миңа мөмкинме?—диде Шәвәлиев.

—Рәхим итегез.

—Мин бу мәсьәләдә фикер алышып тормаска кирәк дип саныйм. Башкалар ничектер, мин үзем арыдым Сабитовтан. Бер кеше белән күпме баш катырырга мөмкин? Карагыз әле, ничек оста, астыртын эш итә Сабитов. Райком органы булган газета коллективы исеменнән. Мин ул хатны укыдым. Аның кулы икәне әллә каян сизелеп тора. Мондый астыртын юллар белән эш итүче кеше иң каты җәзага лаек. Сабитов теләсә кайсы вакытта, теләсә кайсыбызның аркасына арттан пычак кадарга сәләтле кеше. Аңа безнең арада урын юк.

—Тагын бармы сөйләүчеләр?—диде Арсланов.

—Булды, аңлашылды, җитте,—дигән тавышлар ишетелде. Арсланов торып басты.

—Монда Сабитовны иң каты җәзага тарту, ягъни партиядән чыгару тәкъдиме керде,—диде ул.—Мин үзем принципта бу тәкъдим белән килешәм. Шулай да минем тагын бер мәртәбә Сабитовка ышанып карыйсым килә. Үз-үзен кулга алып, әйбәт кенә эшләсә, минемчә, район партия оешмасына файда китерә ала. Шуңа күрә мин бюро членнарын тагын бер мәртәбә олы җанлылык күрсәтергә һәм кешелеклелеккә чакырам. Әйдәгез, без аңа, учет карточкасына язып, каты шелтә белдерик. Ә укырга китәргә сорап биргән гаризасын кире кагарга, дигән карар кабул итик. Ничек карыйсыз?

—Килешәбез, риза, шулай кирәк,—дигән тавышлар ишетелде.

—Кем дә кем шушы карарны кабул итәбез, ди, шул бюро членнарының тавыш бирүләрен сорыйм.

Сигез бюро членының барысы да бердәм кул күтәрде.

—Төшерегез. Димәк,бертавыштан. Ә сезгә, Сабитов, китәргә мөмкин. Тырышып эшләгез, бирелгән сүзләргә үч саклап йөрмәгез. Вакыт җитәр, үзеңне әйбәт яктан күрсәтсәң, без ул шелтәне кире алырбыз.

Ирек бер сүз дә әйтмичә чыгып китте.

Ул кабаланып эшенә кайтты. Секретарьны чакырып кертте, аның куркаклыгын белгәнгә күрә:

—Миңа Мәскәүгә китәргә рөхсәт иттеләр, вакытлыча профсоюз председателе вазыйфаларын сезгә йөкләргә куштылар,—диде.

Сейфны ачып, тиешле документларны бирде. Барлык эшләрне үзенең укырга китүе сәбәпле, профсоюз председателе сайланганга кадәр, секретарьга йөкләү турында боерык язды. Шактый карышканнан соң, секретарь, боерык белән таныштым, дип, кул куйды.

Шулчак телефон шылтырады. Ирек теләр-теләмәс кенә трубканы алды.

—Ирек Хәйриевич... кичерегез...—Вафинның хәлсез тавышын таныган иде инде ул.—Мине мәҗбүр иттеләр... Миңа сезгә карата этлек эшләргә яраса да, үләргә ярамый. Аңлагыз зинһар!..

Вафин башка бер сүз дә әйтмәде.

Ирек кайтканда, Сөембикә өйдә иде инде. Айгөлне сөйде, мин командировкага китәм, диде, кайтканны көт, диде. Сөембикә аның рөхсәтсез китүен өнәмәде, мәгәр бер сүз дә дәшмәде. Ирек ашык-пошык капкалап алгач, профсоюз машинасында Бигеш аэропортына юл тотты...

* * *

Әхнәф, чыгыш ясарга килүчеләрне автобус белән кайтарып җибәргәннән соң университетта булып, таныш укытучысын күрде, читтән торып аспирантурага керү, башланган фәнни эшен дәвам итү юллары турында озаклап сөйләштеләр. Икенче рейс белән ул Болынкырга кайтып төште. Бер атна эчендә агачлар да ныграк саргайган, алардан явучы яфрак яңгыры да куера төшкән иде. Профсоюз райкомы турыннан узганда, Әхнәф күз чите белән генә аның тәрәзәләренә күз төшереп алды, күңелен, энә очы белән сызгандай, нидер көйдереп үтте... Ирекнең Мәскәүгә китеп барганын телефоннан сөйләшкәндә хатыны әйткән иде инде аңа. Ул, юлын кыскартырга теләп, мәктәп янындагы агачлык аша гына китте һәм биредәге тынлыкка хәйран калды. Җилнең әсәре дә юк. Инде яшеллеге уңа башлаган бәпкә үләне өстендә коелучы сары яфракларга баскач, аларның кыштырдавы колак төбендәге кебек ишетелә. Казан шау-шуыннан соң биредә оҗмах иде. Ул туктап бер генә минутка күзләрен йомды, сентябрьнең чиста, әз генә салкынча һавасын битләре белән тоюдан искиткеч рәхәтлек кичерде. Әхнәф, керфекләрен ачуга, үзенә таба килүче Ләлә Хәмитованы күрде. Алырга мөмкин булган барлык исемнәрне дә алган бу карт укытучының үз-үзен тотышын, киенүен, кыяфәтен беркемнеке белән дә бутау мөмкин түгел. Кара эшләпәсе астыннан тузгып чыгып торучы чал чәчләре, бер як очы итәгенә кадәр сузылып төшкән кара шарфы, аксыл плащы, иңбашына эленгән нәни сумкасы һәм кәкре башлы затлы таягы аны ничектер борынгы заманнардан кунакка кайткан зыялы бер аксөяккә охшаш итеп күрсәтәләр. Вак җыерчыклар белән капланган ак чырае һәрчак уйчан булыр, ә тере яшькелт күзләре бер генә хәрәкәтенне дә игътибарсыз калдырмас. Әхнәф, үз юлын ташлап, бакчаның икенче читенә—аңа таба китте. Өч ел буе үзләренең класс җитәкчесе булган укытучысы белән һәрбер очрашу, ул әйткән мактау сүзләре Әхнәфкә тормышында дәрт-дәрман өсти, үзенә күрә кечкенә бәйрәме дә була иде.

—Хәерле көн, Ләлә Хәмитовна!—дип, ерактан ук елмаеп сәлам бирде Әхнәф.

Укытучысы аның сәламен әллә алды, әллә алмады, сизелер-сизелмәс баш кагып кына куйды кебек...

—Их, Шәрифуллин!..

Бу нинди елак тавыш? Мәктәпне тәмамлаганнан бирле, Ләлә Хәмитовнаның ана фамилиясе белән дәшкәне юк иде!

—Их, Шәрифуллин, Шәрифуллин!—Укытучының үткен карашы Әхнәфне кылыч белән чапкандай өттереп алды.—Ничә еллар буе мин сезнең каршыгызда, кешелеклелек, рәхим-шәфкать, намус-вөждан турында сүз алып бардым... Ә сез... Шәрифуллин... мин алданган икәнмен...

—Ләлә Хәмитовна!—дип ялварды Әхнәф.—Зинһар анлатыгыз: ни булды?!

—Сез вөжданыгызны саткансыз, Шәрифуллин...

Аның беркайчан да «сез» дип дәшкәне дә юк иде.

—Апа! Анлатып бирегез!

Ләлә Хәмитовна, авыр итеп сулыш алгач, күзләреннән нәфрәт очкыннары чәчеп:

—Сез дустыгызның укырга китүенә каршы килгәнсез!—диде.

—Бу бит ялган! Моны кемдер махсус тараткан!

—Шуны онытмагыз, Шәрифуллин: дәрәҗә ул—вакытлы гына әйбер. Ә менә кеше булып калу—мәңгелек!..

Ләлә Хәмитовна китәргә кузгалды.

—Апа, туктагыз әле!..

Карт укытучы туктап артына борылды да, кулындагы таягын Әхнәфкә ыргыткандай, берничә генә сүз ташлады:

—Ә минем... минем әле һаман... ышанасым килә сезгә...

Ул китеп барды. Әхнәф, яшен суккан кебек тәэсир иткән бу сөйләшүдән айный алмыйча, укытучысы бакчадан чыгып киткәнче басып торды. Аннары, өенә кайту юлыннан кырт борылып, элемтә бүлегенә китте. Анда тикшергәч, телеграмманың нәкъ ул биргәнчә кабул ителүен белде. Райкомның гомуми бүлек мөдире аптырап кулларын җәйде:

—Сабитовның персональ эшендә бернинди дә телеграмма юк,—диде ул һәм, Әхнәф ышансын өчен, документлар тегелмәсен биреп, аның үзенә актартты.

Әхнәф Шәвәлиевкә өермә кебек килеп керде, исәнлек-саулык сорашып та тормастан:

—Кайда мин суккан телеграмма?!—дип кычкырды.

—Ә нәрсәгә ул сиңа?—диде Шәвәлиев тыныч кына.

—Тикшерү өчен кирәк. Минем Сабитовның укырга китүенә каршы телеграмма сукканым юк.

—Бюрога ник кайтмадың соң? Синең этлегенә җавап ул. Анладыңмы?

—Мин сезне судка бирәм!

—Партиягә каршы суд тапсаң, бирерсең! Иң элек без сине, үзебезнең суд каршына бастырып, җиде тиреңне каезлыйбыз әле!

—Кулыгыз житсә, карарсыз!—диде Әхнәф һәм чыгып китте.

—Кеше бармы?—дип сорады ул кабул итү бүлмәсендәге секретарь хатыннан, Беренченең бүлмәсенә таба ымлап.

—Әлегә үзе генә.

Әхнәф, рөхсәт-мазар сорап тормастан, Арслановка кереп китте.

—Кайтырга уйладыңмыни?—дип каршылады аны Арсланов, яңагын чәйни-чәйни.

—Эшне бетергәч, кайттым әле.

—Нишләп без чакыргач кайтмадың?

—Бер кул күтәрү өченме?

—Кул күтәрү ул—яшәү дә, үлем дә. Син шуны беләсеңме?

—Минем фикерем сезгә билгеле иде, ә мин аны кайберәүләр кебек җил искән саен үзгәртмим. Ирек Сабитовка күрсәтәсе комедиядә миңа роль бирүегез өчен рәхмәт. Әмма Казан тикле Казаннан аны уйнарга кайта алмау өчен гафу итерсез.

Әхнәф бу сүзләрне, теш арасыннан чыгарып, ачуыннан кайный-кайный әйтте. Арсланов ялт сикереп торды, дөпелдәтеп идәнгә типте һәм күзләрен алартып төкерек чәчте:

—Гафу итмибез!—Бусы однозначно. Сез монда берничә группа хәзер. Партиядән иң элек синең күтенә тибәбез! С позором! Анладыңмы?!

—Алайса мин дә әзерләнә торыйм әле,—диде ул, аягүрә басып. Аннары авыз эченнән генә мыгырдангандай итеп:—Иң элек теге кызларны күрергә кирәк,—диде.

Арсланов саңгырау кеше кебек башын кыйгайтты.

—Нәрсә, нәрсә?!

—Олы кунаклар килгәч, чакыра торган...

—Шәрифуллин! Бала-чагаланма, ир-ат булыйк...—диде Арсланов.

—Нишләптер сезгә теш кайраганнары күп аларның. Әллә инде сүзегездә тормагансыз шунда. Күбесе гаиләсез—аларга ике дөнья—бер моржа...

Әхнәф ишек тоткасына үрелгәндә, Арсланов аны арттан килеп туктатты.

—Әхнәф, үтенәм... Әйдәле минем бүлмәгә... сөйләшик.

—Юк, Минзаһит Усманович!—диде Әхнәф, анын кулыннан ычкынып.—Эшләр болайга киткәч, мин берни каршында да туктап калмыйм! Йә минем шартка күнәсез, яисә...

—Күнәм, күнәм!—диде Арсланов өтәләнеп.—Әйт шартыңны!

—Сез аны күптән беләсез ич, Минзаһит Усманович.—Комсомолдан җибәрегез дә, йә мәктәпкә укытырга, йә архивка куегыз. Мин бит тарихчы, районның тарихын язам.

—Куям архивка куям, тарихка куям!—диде Арсланов, тотанаклана-тотанаклана.—Тагын нинди теләгең бар?

—Комсомолдан киткәндә, берәр мактау кәгазе бирсәгез, шул җитә.

—Булыр, килештек!—диде Арсланов, аңа кулын сузып.

Ләкин Әхнәф вәгъдәне кул бирешеп ныгытырга ашыкмады, юри сүзсез генә чыгып китте...

## 32

*«Сәлам, Әхнәф! Сиңа Ирек Мәскәүски яза. Инде монда килгәнгә атнадан артты, ә вакыт җиткереп булмый. Көннәр, поездда барганда артка йөгерешкән агачлар кебек, чагылып-чагылып кына үтәләр. Хатымны күптән башлаган идем, һаман төгәлли алмыйм. Беләсеңме, мин бит хәзер яңа дөньяда. Бала туып, кендеге өзелеп, сулый башлагач, адәм балалары белән бер төрле яшәешкә күчә. Бу чагыштыру бик төгәл булмаса да, минем халәтемне күпмедер чагылдыра. Син инде минем ничек киткәнне беләсең. Укуларга дүрт көн соңарган идем. Курслар җитәкчесе Иван Иванович ярты сәгатьтән артык тиргәде. Гомер буе министрлыкта утырган, кешеләр өстеннән командалык итеп өйрәнгән, югарыга караган чагында, чыраена курку билгеләре чыга торган бу кеше мине яман каты кыздырды. «Әгәр дә яңадан ярты гына көн дәрес калдырсагыз да, сөйләшеп тә тормыйм, курслардан куачакмын»,—диде. Шулай итеп, мин үз гомеремдә беренче мәртәбә читтән торып түгел, көндезге студент булып укырга бардым.*

*Укытучылар арасында гаҗәеп зур белемле, театр, тәнкыйть дөньясының күренекле кешеләре бар. Безгә шулар лекцияләр укый. Партияне тәнкыйтьлиләр, үзәк Комитетны тәнкыйтьлиләр, Министрлар Советын тәнкыйтьлиләр. Яңа дөнья, яңа рух монда, дустым!*

*Бер көн бүлмәдәш егетләр белән Мәскәү буйлап йөрергә чыктык. Кызыл Мәйданда өчебез кочаклашып фотога төштек. Аннары Останкино телевизион манарасына мендек, бераз гына чайкалып торган залдан чип-чиста сентябрь күге аша бөтен Мәскәүне күзәттек. Күңел нишләргә белми, кичергән тойгыларымны аңлатып бетерә алмыйм. Күз күреме җирдә Мәскәү җәйрәп ята. Әйтерсең, мин канатланып очам. Син беләсеңме, Мәскәүдә көз, сары яфраклар коела, зәңгәр күк биекләнгән, өрфиядәй томан аша биек манаралар урманы җемелди. Ләкин минем өчен бу көз түгел, ә яз. Сары яфраклар—язгы бөреләр, көзге яңгырлар—язгы ләйсән. Мәскәү урамнарының кайсына гына аяк бассам да, алтын яфраклар түшәлгән парклар аша үтсәм дә, мин язгы җанлану гына күрәм. Их! Хатымны бит сиңа рәхмәт әйтүдән башлыйсы иде. Рәхмәт сиңа,*

*дустым, мең рәхмәт! Әле бит Казаннан кайткач, сиңа ниләр күрсәткәннәрен дә белмим. Тик йөрәгем белән дә, күңелем белән дә яхшы аңлыйм: мондый адымны алар гафу итмәсләр...*

*Әхнәф, бу хатның очы-кырые булмастыр кебек. Мин сине сагынганмын икән. Бу хат язу түгел, синең белән сөйләшеп утыру икән ләбаса. Менә бит мин синең зәңгәр күзләреңне, коңгырт кашларыңны, ничектер матур итеп тыелып көлүеңне күрәм. Сызылып киткән мыегыңны, мин синең ияк янындагы Аллаһы тәгалә нишләптер чибәр кызларга гына төртә торган матур миңеңне күрәм. Бу хатны язганда син һәрвакыт минем каршымда тордың, дустым. Бу минутларда мин синең белән рәхәтләнеп сөйләштем, эч серләремне бушаттым. Бу юлларны укыганда, син дә мине күрерсең, минем сүзләремне ишетерсең һәм минем белән сөйләшерсең.*

*Ярый, дустым, мин синең кулыңны кысам. Түземсезлек белән җавап көтеп: Ирек дустың.*

*P. S. Нәрсә диләр әле, үләсе әби үлмәгән, чыгасы килен чыкмаган дигәндәй, кичә хатны сала алмадым. Конверт ясадым, клей булмады. Менә бүген, занятиеләргә баргач, инде ябыштырып җибәрдем дигәндә, шатлыклы хәбәр әйттеләр: Мәскәүнең зур концерт залында кич Татарстан сәнгать осталары концерты була икән. Башым күкләргә тиде! Тра-та-та, тра-та-та, бүген театр була! Күңелдәге шатлыкны язып бетереп булмый. Әйтерсең лә Казанга кунакка кайтып киләбез. Шушы шатлыгымны да сиңа әйтим дидем. Тагын бер мәртәбә хуш-сау бул!*

Ирек хатны салып кергәндә, аны ишек төбендә группаның старостасы Слободчук каршы алды. Ул, ничектер сәер елмаеп, аягын ишеккә аркылы куйды. Ирек аның яшел күзләреннән нидер эзләде, ләкин берни дә таба алмады.

—Әллә кертмисен?—диде Ирек елмаеп.

—Беләсеңме, нәрсә,—диде Слободчук.—Сине Иван Иванович чакыра.

Ирек аптырап, җилкәләрен сикертте.

—Ни булган?

—Белмим,—диде Слободчук.

Ул конгырт чәчле матур башын артка ташлады да, кырт борылып, коридордан аудиториягә таба китте. Староста кызлар кебек чибәр йөзле, һәркем белән күгәрчендәй гөрләп сөйләшә, үзе көләч, үзе итагатьле, сүзләре җанына үтеп керә. Тик шунысы начар: ул тыңлаучылар арасында булган һәр нәрсәне көне-сәгате белән курслар җитәкчесенә җиткереп бара. Бер көн дә дүрт егет төне буе утырганнар, шаулашканнар. Араларында староста да булган. Аны сыйлаганнар, кунак иткәннәр. Слободчук егетләрнең һәрберсенә аларны хөрмәт итүен, аларның талантына соклануын кат-кат белдергән. Ә иртән занятиеләр башланганчы, Иван Ивановичка барып, аларны сатып кайткан. Өч егеткә шелтә эләкте, Слободчук «судан» коры килеш чыкты.

Ишек янагына кулын куйган килеш, Ирек ни эчкә үтәргә, ни тышка чыгып китәргә белмәде. Бераздан ул, башын аска игән хәлдә, ГИТИС бинасына таба юнәлде. Курслар җитәкчесе шуннан ерак түгел генә булган кечкенә бинада утыра иде.

Дәрестән бүлеп чакырмас иде, димәк, нидер булган. Йә өйдә берәр бәхетсезлек, яки... Ул бит әле өч кенә көн элек Мәлс абыйсы белән телефоннан сөйләшкән иде. Әти-әниләре дә, Сөембикәләр дә бер килеш яшәп яталар, диде.

Ирек авыр уйлар белән курслар җитәкчесенең ишеген ачты.

—Мөмкинме?

—Кер,—диде Иван Иванович, алдындагы язуларыннан башын күтәрмичә.

Узыгыз димәде, утырыгыз димәде. Бераз калтырап тора торган башын югары күтәрмәде, тып-тын тора бирде. «Нәрсәгә чакырдыгыз?»—димәкче булды Ирек, ләкин тыелып калды.

Ниһаять, Иван Иванович, акрын гына башын күтәреп, Ирекккә нәфрәтле караш ташлады. Аның майланып торучы кызгылт күз кабаклары уртасындагы тоныкзәңгәр күзләре Ирекккә ашардай булып карадылар. Башы шактый сизелерлек булып дерелди башлады.

—Менә, егеткәем,—диде ул, ниндидер кырыс, үтергеч тавыш белән.—Мин сезне курслардан куып чыгару турында приказ әзерләдем. Сез үз теләгегезгә ирештегез.

Ирек, йөрәк турына китереп суккандай, чайкалып куйды. Тәненнән, бөтен гәүдәсеннән утлы дулкын йөгереп үтте.

—Гафу итегез, Иван Иванович,—ул бер тын сүзен әйтә алмый тотлыгып торды.—Мин нинди гаеп эш эшләдем соң әле?

—Сез миңа шундый сорау бирә аласызмы?!—Иван Иванович, ыргылып торып сугып җибәрергә теләгәндәй, аңа якын ук килде. Аннары, курыккандай, кырт борылып, кире үзенең өстәленә барды, бер зәңгәрсу кәгазь кисәген эләктереп, аны селкә-селкә, тагын Ирекнең каршына килде.—Нәрсә бу?!—Иван Ивановичның тавышыннан тәрәзәләр селкенеп куйды кебек.

Ирек кәгазьне алды һәм аның телеграмма икәнен күрде. Ул Иван Ивановичның кабат өстәл артына барып басканын да сизмәде, күз алдында йөгерешкән хәрефләрне төтен ачыттыргандай кабаланып йөгереп үтте.

*«Мәскәү шәһәренең Кызыл Пресня партия райкомының беренче секретарена Татарстанның Болынкыр районы КПСС райкомының беренче секретаре Арслановтан. Партия райкомын алдап, бюро карарына буйсынмыйча, беркемнән рөхсәт алмыйча, бездә учетта торучы коммунист Ирек Сабитов сезнең карамактагы Югары театраль курсларга укырга киткән. Партия райкомы моңа категорически каршы, Сабитовның эше тапшырылмаган. Аны курслардан азат итүегезне һәм тиз көндә райком бюросы утырышына персональ эшен карау өчен кайтарып җибәрүегезне сорыйбыз.»*

Телеграмманың почмагына «Ашыгыч чара күрергә!» дип язылган, имза куелган иде.

Иван Иванович телеграмманы шарт итеп тартып алып китте. Һәм аның баш очында селки-селки:

—Шушыннан соң сез миңа оялмыйча «мин нинди гаеп эш эшләдем?» дип ничек әйтә аласыз?!—дип кычкырды.

Курслар житәкчесе өстәлгә аның паспортын ыргытты һәм сөенгәндәй:

—Ярый әле паспортыгызны пропискага кертеп өлгермәгән идек,—дип куйды.

Ни булганлыгы Ирекккә шунда гына аңлашылды.

—Иван Иванович, мин сезгә аңлатыйм әле,—Ирек аңа таба берничә адым атлады.

Иван Иванович, йөзенә таба очып килгән әйберне тыярга теләгәндәй, ике кулын сузып, учларын Ирекккә каршы куйды.

—Кирәкми берни дә аңлатуыгыз!

—Эш бит болай тора...

Курслар житәкчесе бармакларын бөкли-бөкли сөйләргә керешә:

—Беренчедән, сез партия райкомын алдагансыз. Икенчедән, сез партия учетыннан төшмичә, рөхсәтсез киткәнсез. Өченчедән, сез эшегезне тапшырмагансыз.—Аның тавышы күтәрелгәннән-күтәрелә барды.—Дүртенчедән, сез коллоквиум вакытында партия органнары ризалыгы белән килдем, дип безне алдадыгыз. Һәм шушыннан соң сез нәрсәләр аңлатырга телисез.

—Бу бит Беренче секретарьның миңа үчләшүе генә. Ышанмасагыз, менә хәзер республика партия өлкә комитетына шылтырата аласыз. Идеология секретарена яисә...

Иван Иванович, учларын аңа таба каратып, кулларын тагын өскә күтәрде.

—Егеткәем, мин гомерем буе партия эшендә, министрлык эшендә.

Өлкә комитеты риза булса, райком да риза. Ә син мине шушының киресенә ышандырмакчы булып азапланасың.

—Тормыш бит әзер схемаларга сыеп бетми.

—Бар әле син, егеткәем...—Иван Иванович, күзләрен елтыратып, берничә секундка гына туктап калды.—Әйтер идем инде мин сезгә, хезмәт урыным ирек бирми. Сөйләшү тәмам. Обходной листыгызны тутырыгыз, алган әйберләрегезне тапшырыгыз, иртәгәдән тулай торакта урыныгыз бушаган булсын!

Ул шулай диде дә телефоннан сөйләшергә кереште. Сүзен бетереп, трубкасын куюга, ана борылды һәм башы калтырарга тотынды.

—Сез әле һаман чыгып китмәдегезмени?

—Иван Иванович,—диде Ирек, батып баручы кеше саламга ябышкандай.—Зинһар өчен мине ирекле тыңлаучы итеп булса да калдырыгыз. Минем укыйсым килә...

Бу сүзләрне ишеткәч, Иван Ивановичның кашлары, маңгаенда вак жыерчыклар ясап, өскә күтәрелде, күзләре түм-түгәрәк булып киерелделәр. Ул әлеге телеграмманы кулына алды да икенче кулы белән ана шап-шоп китереп сукты.

—Нәрсә, сез ирекле тыңлаучы, ә мин урамда ирекле йөрүче булып каламмы?! Хәзер үк ишекне теге ягыннан ябыгыз!

Ирек, кабат бер сүз дә әйтмичә, бүлмәдән чыгып китте.

Ул барганда, өченче лекция бетмәгән иде әле. Ирек, ни кылырга да белмичә, коридор буйлап йөрде дә йөрде. Хәзер инде ана иптәшләре белән хушлашудан бүтән чара калмаган иде. Менә аудитория ишеге ачылып китте, аннан бер-бер артлы тыңлаучылар чыга башлады. Ин беренче аның янына Скоморохов килеп житте.

—Йә, ни бар? Берәр күңелсез хәбәрме әллә?

—Мине курслардан чыгардылар,—диде Ирек, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән.

—Әкият сөйләмә!—диде Скоморохов һәм артына борылды.—Барыгыз да жыелыгыз әле!

Үзе, Ирекне житәкләп, аудиториягә сөйрәде һәм такта каршына алып килде. Ирекне бөтенесе сырып алдылар. Ул эшнең ничек булганлыгын жентекләп сөйләп бирде. Арада иң өзгәләнгәне Слободчук булды. Ул Ирекнең һәр сүзен «Вәт син, агай, менә сина кирәк булса, кара син аны!» дигән сүзләр белән ах-вах килеп тыңлады. «Мондый нәрсә була алмый!» диделәр күпләр.

—Жәмәгать,—диде Скоморохов.—Әйдәгез занятиене ташлыйбыз да барыбыз да Иван Ивановичка барабыз.

—Дөрес, кеше язмышы белән шаярмасыннар!—дип өстәде күпләр.

—Ярамый, бусы бала-чагалык була.

—Жәмәгать, эмоциягә бирелмичә генә хәл итик әле!

Шулчак Слободчук барысын да тынычландырды:

—Акырып-бакырып, дәрес ташлап, житәкчеләрнең ачуын кабартып, без берни дә кыла алмаячакбыз,—диде ул.—Әлбәттә, Сабитов безнең белән калырга тиеш. Ләкин акыл белән эш итик. Занятиеләр беткәч, барыбыз да Иван Ивановичка керик. Ә мин аны кисәтеп куярмын.

Аның фикеренә кайберәүләр каршы килсә дә, күпчелек шушы юлны сайлады. Сөйләшеп бетерергә мөмкинлек булмады, кыңгырау чыңлады. Барысы да урыннарына ашыктылар, Слободчук чыгып китте. Аудиториядә шау-шу көчәйгәннән-көчәя барды. Кайсыберләре Иван Ивановичка баруның файдасы юк, райкомга мөрәжәгать итәргә кирәк дигән фикерне алга сөрде. Тавышлар ишектә Слободчук белән Шульф күренгәч кенә тынды. Слободчук урынына утырды, Шульф гадәттәгечә исемлек тикшерә башлады. Башка укытучылар инде бу эшне күптән ташлаган булсалар да, Шульф үзенең һәр занятиесендә тыңлаучыларны барлый, кем соңара, кем юк—билгеләп бара иде. Менә ул Сабитов фамилиясен атады, Ирек басып «әйе» диде.

—Гафу итегез,—диде Шульф,—миңа бүгенге көннән башлап курсларда Сабитов дигән тыңлаучы юк дип әйттеләр.

Аудитория шау-шуга күмелде.

Шульф үзенең нәфис бармаклары белән алдындагы кәгазьләрен җыеп папкасына сала башлады.

—Әгәр дә сез минем лекциямне тыңларга теләмисез икән, рәхим итегез, мин хәзер үк чыгып китәм.

Шунда Зубов торып басты:

—Без сезнең лекциягезне рәхәтләнеп тыңлыйбыз, ләкин Сабитов безнең белән тыңларга тиеш.

—Сабитов тыңлаучы булмагач, минем аны кертергә хакым юк. Икенең берсен сайлагыз.

Шунда Ирек торып урыныннан чыкты, аудиториягә дымланган күзләре белән карады һәм тоныкавыш белән:

—Чын күңелдән рәхмәт сезгә!—диде.—Ә дәресне өзмәгез...

Ул башын түбән иде дә акрын гына чыгып китте, ГИТИС каршындагы артлы эскәмияләрнең берсенә барып утырды. Көн тыныч, кояшлы, күк йөзе зәп-зәңгәр иде. Агачлар шәрәләнеп бара, аяк асты сап-сары яфраклар белән түшәлә. Әле монда, әле тегендә студентлар төркеме ни турындадыр бәхәс алып бара, китап-конспектларын тотып каядыр ашыга. Бу дөнья инде Ирек өчен ят иде. Бу минутларда аның башына хәтта нишләргә дигән уй да килә алмады. Ул сөяп куелган мәет хәлендә иде. Шушы хәлдә күпмедер утырганнан соң, аның башына ниндидер фикерләр килә башлады. Ярар, Иван Ивановичка керсеннәр, ә Ирек анда керергә тиешме соң? Моның бернинди дә файдасы булмаячагын ул инде аңлады. Ирек тулай торакка кайтты да караватына ауды.

Күпме яткандыр, белми. Бервакыт шау-шуга уянып китсә, бүлмәгә курсташлары килеп кергәннәр иде. Тагын файдасыз митинг башланды. Боларның киләсен белеп, Иван Иванович бөтенләй чыгып качкан булып чыкты. Иртәгә аның үзен аудиториягә чакырырга, җыелыш үткәрергә, дигән карарга килеп таралыштылар.

Ирек, киемнәрен үтүкләп, концертка әзерләнә башлады. Ләкин бүлмәгә кереп, әле бер, әле икенче курсташының аны кызгануын, райкомны һәм Иван Ивановичны сүгүен, теге яки бу киңәшләр бирүен тыңлау аның өчен тоташ газапка әйләнде. Урамга чыккач, ул үзен бераз җинеләеп киткәндәй тойды. Бәлки соңгы мәртәбә күрүемдер дип, кибетләрнең һәрберсен кереп карый-карый, акрын гына Кызыл Мәйданга таба атлады. Вакыт күп, ашыгасы юк иде. Җиденче яртыларда инде әңгер-меңгер төшкән иде, ул кассадан билет алды да, урамга чыгып, һавада йөрергә теләде. Ләкин ун адым да китә алмады, кемдер, арттан килеп, аның ике күзен кысты. Ирек елмаеп куйды. Башкорт егетләре якташлары янына киткәннәр иде, концертка кайтып житкәннәрдер, дип гөманлады ул.

—Рәҗәп, син бит?—диде ул, тотучының кулларын кулы белән алып атмакчы булып.

Арттагы кеше дәшмәде.

—Әнвәр, синме?

Бусына да җавап булмады. Ирекнең борынына аракы исе килеп бәрелде. Мөгаен Скоморохов буталып йөридер.

—Коля, җибәр, таныдым,—диде ул һәм кинәт кенә артына борылды. Ирек аптыраудан чак кына егылып китмәде: аның каршында, авызын ерып, Арсланов малае Рашат басып тора иде! Ул сүз әйтергә дә өлгерә алмады, Рашат аны кысып кочаклап алды. Аннары, әйбәтләбрәк карыйм әле дигәндәй, читкәрәк этеп җибәрде дә кул сузды:

—Привет!

—Исәнме,—диде Ирек, аның шактый зур, каты учына кулын салып.

Рашат аны култыклап алды, ишеккә таба атлады, үзе туктаусыз сөйләнде:

—Мин синең билет алганыңны читтән күзәтеп тордым. Шулмы соң бу, мәйтәм, түгелме? Син дә кебек, син дә түгел кебек. Үзгәргәнсең дә, үзгәрмәгәнсең дә.

Рашат башын артка ташлап көлде. Аның кием-салымы аһ итәрлек иде. Өр-яңа зәңгәр костюм-чалбар, ап-ак күлмәк, зәңгәрсу галстук, затлы туфлиләр. Тик үзе генә шактый өлкәнәйгән иде. Чем-кара чәчләренең чигә турларында аклары күренә, битләрдә вак кына җыерчыклар сызылышкан, уң яктан ике тешенең тәшкәнлеге күренә.

—Әйдә, керик, буфетка кагылырбыз,—диде ул.—Син ничек килеп чыгасы иттең соң?

Ирек ни дип җавап бирергә белмәде. Бу очрашудан ул әле һаман да айный алмый иде. Шушында килеп, Арсланов малаең очратырмын дип кем уйлар!

—Мин монда укыйм бит.

—Кайда?

—Югары курсларда.

Рашат тагын көлеп җибәрде.

—Язучы булыргамы?

—Шул чама. Ә син үзең?—диде Ирек.—Кайда эшлисең?

—Мин гади эшче, заводта.

Ирек бик карышса да, Рашат аның ай-ваена карамыйча, йөзәр грамм затлы коньяк, кызыл уылдык ягылган ипи һәм шоколад алды. Алар бер почмаккарак килеп урнаштылар. Мәскәүгә килеп, беренче мәртәбә Ирек татар кызларының, әбиләренең, татар агайларының үзләренчә сөйләшкәнен шушы буфетта ишетте.

—Әйдә, очрашу хөрмәтенә,—диде Рашат чәкештереп.

Алар бер-ике йотым коньяк кабып куйдылар.

—Шулай да, дөнья тар, дип белеп әйткәннәр,—диде Рашат, уылдык ягылган ак ипи кисәген чәйни-чәйни. Аннары капылт кына сорап куйды:— Әле һаман шул хатының белән торасыңмы соң?

Аның бу соравы Ирекне ничектер гаҗәпләндереп куйды.

—Торабыз, кыз үстерәбез.

Рашат тагын чәкештерде.

—Бүген кунарга миңа кайтабыз,—диде ул, коньягын йотып куйгач.

—Юк, юк, төнлә кеше борчып йөрмим!

—Кем ул кеше? Минме?

—Син, гаиләң.

—Минем гаилә бер берәмлектә.—Рашат көлеп, сул кулының имән бармагын тырпайтып күрсәтте. Ул бармакның өстән бер буыны юк иде.

Ирек аңа башка сорау бирергә кыенсынды. Күрәсең, аерылгандыр дигән нәтиҗә ясады. Ул Рашатның әти-әниләре турында сораштыруын көтте, ләкин көткәне акланмады.

—Мәскәүдә семья кирәк түгел. Мәскәү—үзе бер олы семья ул, диде Рашат, тагын көлеп.

Шул вакыт Ирек күләгә кебек тавыш-тынсыз гына үзенең уң ягына бер кеше килеп басуын сизде һәм ялт итеп борылып карады. Гаҗәп озын гәүдәле бу кешенең ап-ак чырае, озынча тар башы, эчкә батып каралып торучы күзләре скелетне хәтерләтәләр иде. Аның чыраен берничә тирән җыерчык ярып үтә, тар маңгаеның урта бер җирендә, чигәдән чигәгә сузылып, шундый ук бер тирән эз ята. Өстендә көл төсле костюм-чалбар, ак күлмәк һәм күбәләк рәвешендәге кара галстук. Ирекнең борылып каравына игътибар да итмәстән, сәхнәгә чыгып баскан конферансье кебек, үкчәләрен бер-берсенә терәп куйган хәлдә, ул ишетелер-ишетелмәс тавыш белән:

—Мин көтәм,—диде.

Рашат гасабиланып куйды, кулларын әле төшерде, әле күтәрде, өстәлдәге әйберләрне күчергәләде һәм борын эченнән генә:

—Күрәсең бит, минем кунак бар, туган килде,—диде.

—Әйдә, сөйләшик,—диде теге кеше, таш төсле йөзенә берникди билге чыгармыйча һәм Рашатның җавабын көтмәстән, корольләрчә мәһабәт атлап, аулаграк почмакка китте.

—Бер генә минут көт,—диде Рашат, аның артыннан ияреп.

Ирек күз чите белән генә аларны күзәтте. Әлеге бәндәнең кылыч борыны, кысылган юка иреннәре, бөкләнгән тез башы төсле куәтле ияге аның үз кадерен үзе белүе, теләсә кемне буйсындыра алуы турында сөйлиләр иде. Ул мәрмәр сын кебек тик басып тора, ә Рашат, кулларын болгый-болгый, аңа нидер аңлата. Аннары ул акрын гына борылды да, Рашатның сөйләп бетерүен дә көтмәстән чыгып китте. Өстәл янына килгәндә, Рашатның маңгае вак тир бөртекләре белән капланган иде. Ул, чәкештереп тә тормастан, коньягын эчеп бетерде.

—Бу нинди кеше булды?—диде Ирек, кызыксынуын баса алмыйча.

Рашат, пүчтәк, дигәндәй кулын селтәп куйды. Шулчак концертка өченче звонок булды.

—Бергә утырабыз,—диде Рашат.—Минем билет ике урынлык.

Концерт искиткеч иде. Җырчыларны, биючеләрне, нәфис сүз осталарын Ирек күзе белән карады, колагы белән ишетте, әмма күңелендә бушлык иде. Тәнәфес вакытында Рашат аны тагын буфетка сөйрәде, тагын коньяк эчтеләр.

Концертның икенче өлеше дә Ирек өчен чит дөньяда барган кебек тоелды. Хәзер инде ул шактый нык исерергә өлгергән Рашаттан ничек котылу турында баш ватты. Ул һәр чыгышка бөтен залга ишетелерлек итеп озаклап кул чапты, туктаусыз «браво, браво!» дип кычкырды, сәхнәдән әз генә юмор яңгыраса, шарык-шарык көлде. Ирек, уйлый торгач, бер бик яхшы фикергә барып чыкты. Әгәр Рашатны кунарга тулай торакка алып кайтсаң? Яхшылап сыйласаң? Бәлкем Арслановка шылтыратып, аны укуда калдыру мәсьәләсендә йогынты ясый алыр?..

Концерт беткәннән соң ярты сәгать тарткалашкач, Ирекнең үзенә бармаячагын Рашат, күрәсең, аңлады—алар тулай торакка кайттылар. Бүлмәдә кеше юк иде. Ирек, суыткычтан алып, колбаса, кыяр турады, алма һәм апельсин юып куйды, юл уңае алган яртыны чыгарды.

Рашат рюмкаларны тутырды.

—Әйдә, Болынкыр егетләренең Мәскәүдә очрашуы өчен!

Алар эчеп, сүзсез генә ризык каптылар.

—Рашат, син ничек Мәскәүгә эләгәсе иттең?

Рашат, затлы сигарет кабызып, төтенен түшәмгә таба өреп җибәрде.

—Очень просто. Мин бит армиядә Мәскәүдә хезмәт иттем. Ә калганы... Ловкость рук и никакого мошенничества!

Шунда бервакыт үзен сәерсендергән хәл келт итеп Ирекнең хәтеренә төште. Инструктор чагында райкомның кабул итү бүлмәсендә дежур торганда, аны Арсланов чакырып кертте дә: «Шушы телеграмманы хәзер үк җибәр әле»,—диде. Телеграммада Мәскәү округындагы ниндидер бер генералны туган көне белән котлау язылган иде. Ирек аны почтага илтүен илтте, әмма сәбәбенә төшенә алмаган иде. Менә хәзер барысы да аңлашылды.

Рашатның инбашына китереп төртүе аны бу уйларыннан арындырып җибәрде.

—Слушай,—диде ул, бу юлы төтенен Ирекнең йөзенә туп-туры өреп.—Син ничек картаеп беткәч Мәскәү тикле Мәскәүгә укырга киләсе иттең?

Ирек аңа үзе кичергән хәлләрне сөйләп бирде. Рашат аны утырып тыңлый алмады, ике кулын артка куеп, арлы-бирле йөрде һәм тулай торакның коридорына ишетелерлек итеп туктаусыз бер үк сүзләрне кабатлады:

—Ох, и сволочь же он! Ну и сволочь!

Ахырда ул Ирекнең каршына килеп утырды, йөзен аның йөзенә тәрәлерлек дәрәҗәдә якын китереп һәм ачуыннан буылган тавыш белән:

—Син аның сволочь икәнен беләсеңме?—диде.

—Кемнең?

—Арслановның!

Ирек айнып киткәндәй булды.

—Соң, синең бит ул үз әтиең, үги түгел!

—Может, үги булса, әйбәтрәк тә булыр иде. Мин аннан бер юньле сүз ишетмәдем. Һәркөн эт сыман өрде. Ә күпме кыйнады!—Рашат кинәт елап җибәрде, кулъяулыгын алып, борынын сөртте.

Рашат, терсәкләрен өстәлгә куеп, ике учына маңгаен терәп, бик озак мышык-мышык елады. Аны тынычландыру өчен Ирек рюмкаларга салып:

—Әйдә, берне тотыйк әле,—диде.

Рашат яшен тизлеге белән рюмканы авызына каплады да кызарып беткән күзләрен сабый бала кебек йодрыклары белән уарга тотынды. Ирек йомшак кына итеп сүз башлады:

—Син яхшылык күрмәдем, дисең. Сине армия хезмәтенә Мәскәүгә җибәрүче дә, биредә урнаштырып калдыручы да әтиең бит.

—А как же!—диде Рашат ярсып.—Мине үз янына кайтармас өчен, кулыннан килсә, Америкага ук олактырыр иде әле ул. Ненавидит ул мине, беләсеңме?! И мин дә күралмыйм аны. Ят кешеләр без.

Ул кинәт Ирекне кочаклап алды, сагышлы күзләрен ана төбәде. Алар мөлдерәп яшь белән тулган иде.—Кызганам мин сине...

—Ник?

—Гаепле мин синең алда!—Ул бераз тынып торды.—Әйтсәм, ачуланмассыңмы?

—Нишләп ачуланыйм ди!

—Хатының шаяра синең.

Ирекнең өстенә коточкыч авыраяк баскан кебек булды.

—Шаяра? Нинди мәгънәдә?

—Һе... Кызык кеше син... Ирләр белән шаяра!..

—Ышанмыйм.

Рашат тагын сикереп торды, урындыкларга бәрелә-сугыла, бүлмә буйлап йөрергә тотынды, тарта торган тәмәкесен өстәлгә атып бәрде.

—Әйдә, берне тотыйк та ятыйк,—диде Ирек, аны тынычландыру өчен.

Бу сүзгә Рашат шундук күнде.

—Ирек, ышанма син мин әйткәннәргә, яме. Башкалардан ишетсәң дә, ышанма. Эчсәм, шулай теләсә нәрсә сөйли торган гадәтем бар минем.

Бу сүзләрдән соң Ирекнең өстеннән тау төшкәндәй булды.

—Сәгать ике инде, әйдә йоклыйк.

—Кайтам мин!

Ирек чын-чынлап хафага төште.

—Кая барасың син бу вакытта? Метро эшләми.

—Кайгырма!—Ул Ирекнең инбашына сугып куйды.—Рашат югалмас. Минем монда квартал саен адрес. Ах, да,—ул кесәсеннән чыгарып, Ирекка визиткасын бирде.—Менә адрес, бер бүлмәле квартира, барлык унайлыклары белән. Тамагың тук, өстең бөтен булыр. Әгәр килмәсәң, үзем эзләп табып, сөйрәп алып барам!—Ул эчкерсез көлеп куйды.—Ә хәзер юлга берне тотабыз да, хуш!

Рашатны озатып кереп, өстәлләрне җыештырып, йокларга ятканда, Кремль сәгатьләре өчне сугарга җыена иде инде...

## 33

Икенче көнне Ирек тагын дәрескә барды. Укытучылар әллә юри белмәмешкә салындылар—аңа бәйләнүче булмады. Ләкин соңгы лекция бетүгә, Иван Иванович аудиториягә килде дә керде. Барысы да тып-тын калдылар. Ул, һәрбер тыңлаучыга күз йөгертеп чыкканнан соң, карашын Иректә туктатты.

—Димәк, бунт?

Анының башы бик нык калтырарга тотынды. Мондый очракларда беренче булып күтәрелүчән Зубов торып басты:

—Нинди бунт булсын инде! Без аңлашырга теләп барган идек сезгә...

—Утырыгыз, Зубов! Биредә бөтенесе дә аңлаешлы. Кем курслардан канәгать түгел, рәхим итеп китә ала. Ә без булышырбыз.

—Нигә соң әле сез куркытудан башлыйсыз?—диде Мираби, озын гәүдәсен чайкалдырып.—Помор улы Ломоносов та укыган. Ә сез юк сәбәп өчен кешене белем алудан мәхрүм итәсез.

—Ләкин Ломоносов партияне алдамаган!—диде Иван Иванович, кызып китеп.

Бөтенесе дә тыела алмыйча көлеп җибәрделәр.

—Ул бит меньшевик булган, большевик булса, ана да юлны ябарлар иде!—диде Скоморохов, учакка утын өстәгәндәй, көлүгә яна көч биреп.

—Без мәдәният министрлыгына барабыз!—бусын чечен кызы Замира әйтте.

—Барыгыз! Соңгы вакытта мондый хәл өч мәртәбә булды. Ә нәтиҗәсе бер генә төрле.

—Аңлашылды...

Тыңлаучылар урыннарыннан тора башлауга, Иван Иванович кулын күтәрде.

—Әле сезнең арада гөнаһлылар шактый. Алты кешенең хезмәт кенәгәсе һаман юк, паспортлары пропискадан төшерелмәгәннәр дә бар. Югары тонда сөйләшер вакыт житте, дускайларым. Ә сез, Сабитов, рәхим итеп...

Ирек аудиториядән чыгып китте һәм туп-туры Кызыл Пресня райкомына юл тотты. Ул бер сәгать утырмады, пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире Николаев тарафыннан кабул ителде. Ирек үзенен кем икәнлеген, нинди мәсьәлә белән керүен сөйләп тә бетермәде, ул, алдында яткан телеграмманы күтәреп, селкеп куйды.

—Менә бусы бүген килде. Беренчегез сезне бюрога чакыра, безгә ЦК белән яный. Сез йә бик зур гөнаһлар эшләгәнсез, йә райком өчен бик кирәк. Мин дөрес әйтәммe?

Ул, саран гына елмаеп, Ирекка төбәлде.

—Юк, ни беренчесе, ни икенчесе түгел.

Николаев җитдиләнеп китте.

—Ә нәрсәдә соң хикмәт?

Ирек берничә сүз белән үзенең китү тарихын сөйләп бирде. Николаев аны бер генә мәртәбә дә бүлдермәде. Соңыннан аның сүзләрен бастырып куйгандай:

—Мин сезгә ышанам,—диде.—Кызганычка каршы, бу очракта мин көчсез.

—Мин безнең өлкә комитеты белән сөйләшә алмассызмы дигән идем.

—Юк, берни дә барып чыкмаячак,—диде Николаев, кискен итеп.—Мин сезнең Беренче секретарегызга чыга алам. Уртак тел таба алсак...

Ирек ул сөйләшүдән нидер өмет итмәсә дә, ятып калганчы атып кал, дигәндәй:

—Мин сезгә бик рәхмәтле булыр идем,—диде.

—Әйтегез координатларын.

Ирек Арслановның телефон номерларын, үзенең һәм әтисенең исемен әйткәч, Николаев шундук Болынкырга шылтыратты. Ул үзе белән таныштыруга, Арсланов:

—Ни өчен сез безнең коммунистны җибәрмисез?—диде.

—Югары курсларга теләсә кем кабул да ителми, кирә дә алмый. Сезнең район кадры укып кайтса, начар булмас.

—Сез бит кемне яклаганыгызны белмисез!

—Акыллы, төпле иптәш ул. Укысын, үссен.

—Сезненчә, акыллылар Мәскәүдә, ә ангыралар авылда яшәргә тиеш?

—Сезнең белән сөйләшүгә әрәм иткән өч минут вакытым кызганыч,—диде Николаев, трубкасын куеп. Аннары Ирекқә мөрәҗәгать итеп:—Мин шушыннан башкасын эшли алмыйм,—диде.

—Әгәр мин Үзәк Комитетка барсам?

Николаев ярты минутлап уйлап торды.

—Теләгәнегезгә ирешә алуыгызга шикләнәм. Хәер, кемгә эләгәсез инде... Тырышып карагыз. Сез бит вакыттан бүтән берни дә югалтмыйсыз. Ә вакытыгыз муеннан. Иҗат өчен дә, чират көтү өчен дә.

Ирек рәхмәт әйтеп чыгып китте.

Тулай торакка кергәндә, вахтада утыручы хатын аның каршына чыгып басты.

—Сезне кертмәскә куштылар.

Ирек барысын да аңлады.

—Бүген төн кунарга гына рөхсәт итегез инде.

—И, балакаем, мина нәрсә? Комендант кушты бит.

Ирек комендант яши торган бүлмәгә китте, ишеген шакыды.

—Керегез!—дигән тавыш ишетелүгә, бусагадан атлады.

—Ольга Ивановна, мине тулай тораktан чыгаргансыз икән.

—Инде минем түзәрлегемне калдырмадылар. Һәркөн өч-дүрт мәртәбә телефоннан кысалар. Моңа кадәр, сезне борчымыйм дип, әйтмичә торган идем. Төрлечә алдаштым, квартира эзли, хәзер чыгып китә дип. Ә бүген сезнең урынга кеше киләсе.

—Кем әйтте?

—Слободчук. Мин сезне бүтән бүлмәгә дә урнаштырып торыр идем... Ул иртәгә үк житкерәчәк. Коточкыч бәндә... Сизәм, үзенең кемендер урнаштырырга җыена ул.

—Бәлкем иртәгәгә кадәр калдырырсыз? Мин әйберләремне җыйнап куям. Кемдер килсә, шундук чыгып китәрмен.

—Ярый, ләкин бик күренеп йөрмәгез.

Ирек үзләренең бүлмәсенә кергәндә, аның урынына берәү килгән булып чыкты. Башкорт егетләре мәет озаткан кеше кебек кәефсез иделәр. Ирек ашыга-кабалана әйберләрен чемоданына, сумкасына тутырды. Обходной кәгазенә кул куйдырып килгәндә, бүлмәдә дага мыеклы кеше басып тора иде инде. Ирек аны шундук таныды: ул Югары курсларга керергә йөргәндә дә, коллоквиумнан уза алмаганнан соң да, гел Слободчук белән көне-төне бергә буталган украин егете иде. Ул арада Слободчук та күренде. Ирекне кызганып ул ах-вах килде, инбашларыннан кагып юатты, югары органнарга мөрәҗәгать ит, ә без монда кулдан килгәнне эшләрбез, әйеме, егетләр, диде. Ирек, аның йөзеннән күзен алмыйча, хәрәкәтсез басып торды. Слободчук шикелле чибәр кешеләр сирәк очрыйдыр. Дулкынланып торучы конгырт чәчләр, куе кара кашлар, озын керфекләр, яшькелт күзләр, мөлаем йөз, теләсә кемне әсир итәрлек сөйкемле елмаю, озын төз гәүдә, сирәк очрый торган ягымлы тавыш... Үзенең ничектер бер сөйләгәне хәтердә: аларның нәселендә туксан яшьне узмыйча үлгән кеше әлегә юк икән... Ни өчен табигать, йә булмаса, Ходай Тәгалә шушындый гаделсезлекне эшләгән соң? Пакъ күңелләрне ак итеп, кара күңелләрне кара итеп булмый микәнни? Кешенең җисеме белән рухы һич тә туры килмәгәч, аларның икесен ике зат тудырып, өченче зат бергә китереп кушмагандыр ич? Бәлкем чыннан да шулайдыр? Юкса, алар гомер буе сугышмаслар иде...

Ирек чемоданнарын кайтып киткәнгә кадәр бирегә калдырып торырга булды. Башкорт егетләре белән ул Рига метросында кочаклашып аерылышты. Язмыш аны котылгысыз рәвештә бер урынга—Рәшат янына алып китте...

* * *

Ирек, өч кич кунгач та, Рашат белән яшәүнең проблемасыз гына түгеллеген анлады. Ике тәүлек буе ул бөтенләй күренмәде, аннары кайткач, туктаусыз эчте дә тагын юкка чыкты. Суыткычында болай азык-төлек тулы булса да, Рашат урын-җир җыю, савыт-саба юу, квартира җыештыру дигән нәрсәләрне белми иде. Оекбаш, майка-трусик, күлмәк, кулъяулык ише әйберләр ванна бүлмәсенә болгап-болгап кына катырылган. Кибеткә-мазарга чыкканда, ишек бикләү, кайтып кергәч, тышта йөргән аяк киемен салып кую, чүәк кию кебек гадәтләр биредә юк булып чыкты. Ул югалып торган ике тәүлектә Ирек, йокыга гына бүленеп, беркая чыкмыйча, шушы лакашып каткан, тәмәке төпчеге, азык калдыклары белән буталган әйбер өемен аралады, чистартты, юды, тәртипләп урнаштырды. Кайтып кергәч, Рашатның исерек күзләре шакмак булды.

—Вот ты даешь!—диде ул сызгырып.

Ирек аны туфлиларын салмыйча уздырмады. Ишек катына үзе сатып алып кереп куйган чүәкләргә төртеп күрсәткәч, Рашатның буйсынмый чарасы калмады.

Бүген ул ярты көн суыткычны чистартты. Анын эчендә йонланып, күгәреп, кибеп, бозылып беткән азык-төлекне каләм белән язып, тел белән сөйләп бетерерлек түгел иде. Төштән соң Югары курсларда дәресләр бара торган урынга китте. Расписание буенча бүген иҗат психологиясеннән Алексей Абрамович Гроссманның лекцияләре булачак, Ирекка ничек тә булса аны күрергә, кинәшергә кирәк, анын сонгы өмете Гроссманда иде. Беренче лекциясеннән үк барлык тынлаучылар да аны яратып өлгерделәр, чөнки ул үзенең искиткеч гадилеге, һәр нәрсәне үз исеме белән атап, ачыктан-ачык сөйләшүе, тирән белемгә ия булуы белән әсир итте. Анын вакыты секундлап бүленгән, кайдадыр очрашулар, кайдадыр лекцияләр, әмма анын кулында бернинди папка да, блокнот та юк, нәкъ вакытына керә дә инде әллә кайчан укый башлаган лекциясен нәкъ шуннан дәвам итеп алып китә. Ана туктаусыз сораулар яудыралар, ул һәрберсенә җавап бирә, Гроссман инде киенә башлый, ул инде урамга чыга, ә тынлаучылар өерләре белән, җеп белән таккандай, һаман ана ияреп баралар.

Ирек бүген урамда йөренә-йөренә аны көтә. Алексей Абрамович белән очрашырга теләве дә юкка түгел. Тынлаучылар арасында мәскәүлеләр шактый, алар бөтен нәрсәне белә, шуларның әйтүенә караганда, Мәскәүдә Гроссманның элемтәләре булмаган бер генә урын да юк, имеш...

Менә Гроссманнын кин мангае, көмештәй ак бөдрә чәчләре күренде. Кызу-кызу атлап килүче бу бәләкәй генә гәүдәле кешедә әллә нинди эчке куәт талпынуы ерактан ук сизелеп тора иде. Ирек анын каршына килеп:

—Исәнмесез, Алексей Абрамович!—диде.

Гроссман ана кул биреп исәнләште.

—Минем сездән кинәш сорыйсым килә иде.

—Тынлыйм сезне.

Ул, адымнарын акрынайтса да, атлавын дәвам итте. Ирек, мөмкин кадәр кыска итеп, ана үзенең ничек итеп укырга керүен һәм чыгарылуын сөйләп бирде.

—Миннән ни телисез?

—Кинәш.

—И, жанкисәгем, кайтыгыз да китегез. Укыгыз үзлегегездән. Беләсезме, иҗат кешесе өчен иң кирәге—үзлегеннән, үзен теләгәнне уку. Башкалардан аерылып тору өчен шулай яхшы. Дөресен генә әйткәндә, бу курсларда артык чүп-чар бик күп...

—Мин авылдан...

—Алай булса, башка мәсьәлә. Мәскәү һавасын сулау зарур.

—Минем Үзәк Комитетка кереп карыйсым килә. Калдырмаслар иде микән курсларда...

Гроссманның йөзендә сынар төк тә селкенмәде, күзләре генә житдиләнеп китте кебек. Ул, шактый вакыт сүзсез баргач:

—Мин сезгә булышып карыйм,—диде.—Сез хакыйкатьтән ни дәрәжәдә ерак икәнлегегезне күз алдыгызга да китерә алмыйсыз. Ул жир белән күк арасы гына түгел... Бик яхшы кәгазьгә «КПСС Үзәк Комитетының идеология бүлегенә» дип хат языгыз. Югары театраль курслардан ни сәбәпле чыгарылуыгызны аңлатыгыз һәм кабул итүне сорагыз. Машинкада булуы хәерлерәк. Шул хатыгызны алып, берсекөнгә иртәнге унга мина килегез.

Ул эш урынын ничек табарга икәнен өйрәтте.

—Гафу итегез, берсекөнгә ял көне бит...

—Безнен ял көне шимбә,—диде ул елмаеп һәм жәһәт-жәһәт китеп барды.

Ирек кайтты да эшкә чумды. Ул хат башта дүрт бит булды. Бу коточкыч озын, моны беркем дә укымаячак иде. Алтынчы мәртәбәсендә язганда, ул бит ярымга калды. Икенче көнне иртән саф баштан кыскарта торгач, хатның күләме бер биттән азракка калды.

Ирек якшәмбе көнне унынчы яртыда ул әйткән урынны эзләп тапты. Бу яшькелт төстәге ике катлы зур гына иске йорт иде. Ул мәнге таба торган түгел, ни урамы, ни саны юк, үзе әллә кайда ташландык бер куаклык эченә урнашкан. Йортның нәкъ урталагы бердәнбер ишеге шар ачык. Ирек баскычка килеп житүгә, аның каршына ап-ак свитер кигән таза гына гәүдәле егет чыгып басты.

—Сез кемгә?

—Алексей Абрамовичка.

Егет аны башыннан аягына кадәр жентекләп карап чыкты.

—Бүген ул булмаячак.

—Ул мине үзе чакырган иде.

—Сәгать ничәгә?

—Унга.

—Унга килерсез.

Ишек шапылдап ябылды. Ун тударга әле егерме минут вакыт бар иде. Ирек шактый еракта агач күләгәсендә торган бер иске эскәмиягә барып утырды. Ул Гроссманны мәһабәт бинага урнашкан берәр институтта яисә академиядә эшлидер дип уйлаган иде. «Штукатурлары коелган бу иске йортта нинди генә оешма урнашкан икән сон?» дип баш ватты ул. Сәгать ун тулганда, ишек ачылып китеп, аннан ике ир кеше төште һәм икесе ике якка китеп барды. Бераздан дүрт кеше берьюлы чыкты, аннары бер, ике, алты, тагын, тагын... Күрәсен, бирсдә ниндидер жыелыш булган. Сонынан Гроссман бер кешене озата чыкты. Ул кеше үзенең кыяфәте, баш иеп саубуллашуы белән гел Аркадий Райкинны хәтерләтә иде. Күрәсен, бу соңгы кеше булды, Гроссман тәмәке кабызды һәм кул изәде. Ирек ашыгып аның янына килде, алар кул биреп күрештеләр. Гроссман кешенең уен әйтеп бирә дигәннәрен ишеткәне бар иде аның. Моңа ул үз мисалында ышанды.

—Күзләрегездән сизәм, сезне мине бу йортта күрү гажәпләндерде. Сер итеп кенә әйтәм, мин биредә тәзүче буларак утырам. Бер чит ил фирмасына булышуымны югарыдан сорадылар. Жаваплылык зур, әмма эше бәләкәй, акчасы күп.

Ул саран гына көлеп куйды.

Алар кабул итү бүлмәсенә керделәр. Биредә язу машинкасы, ксерокс, телефон һәм бер кызый утырып тора иде. Ике катлы тимер ишек аша узып, утырышлар залын хәтерләтүче гаять зур бүлмәдә дә искитәрлек нәрсә күренмәде. Алексей Абрамович түрдәге озын өстәл артына барып утырды. Ирек тәрәзәләрнен тимер белән рәшәткәләнгәненә игътибар итте. Түрдән ишеккә кадәр ике рәт итеп сузылган өстәлләрнен ике ягына да, стена буйларына да урындыклар тезелгән. Буявы купшакланган тәрәзә төбенә графин белән су, биш-алты стакан куелган. Гроссманнан

ерак түгел стена буенда кеше биеклеге ике сейф тора. Ирек кереп утырырга да өлгермәде, икенче катка күтәрелүче агач баскычтан плащ, куртка кигән яшьләр дөбер-дөбер төшәргә тотындылар. Алар башларын иеп чыга тордылар. Соңыннан ак күлмәк-ыштан кигән, кара билбау бәйләгән ялан аяклы бер адәм күренде. Аның кысык күзләре, саргылт йөзе японны хәтерләтсә дә, ул саф русча сөйләшә булып чыкты. Ирекка баш кагып алгач, Гроссманга:

—Бүген кичкә булмаячак,—диде.

—Нишләп?

—Төрле сәбәпләр. Кемдер авырган, кемнендер финанс ягы.

—Акча сорамагыз хәзергә. Йөрсеннәр. Мин ярты сәгатьтән бушыйм.

Көрәшче өскә менеп китте. Аннары Гроссман Ирекка борылды.

—Каратэга өйрәтүне тыя торган закон чыгарып утыручы ахмаклардан ни көтәргә мөмкин?!

Шулчак йортның баскыч төбенә үк кара «Волга» килеп туктады.

—Сезгә кирәк кеше килде. Барыгыз, алгы якта көтеп торыгыз.

Ирек алгы якка чыкты да диванга утырды. Ул арада Гроссман үзе дә күренде һәм машинкада басып утыручы күзлекле кызга:

—Аида, Сергей Иванович килде,—диде.

Аида өстәлендәге кечкенә көзгегә карап чәчләрен рәтләштерә башлауга, ишек ачылып китте һәм анда ак күлмәк, кара костюм-чалбар кигән, кызыл галстук таккан эре гәүдәле кеше күренде. Аның жыерчыклы йөзендә арыганлык билгеләре ярылып ята иде. Ул, беркая да күз төшермичә, кулындагы папкасын Аидага бирде дә Гроссман белән эчкә кереп китте. Аида ксерокс аппараты каршына утырды, теге папканы ачып куйды да, эчендәге кәгазьләрен берәм-берәм алып, ксерокс аша чыгара башлады. Ирек, акрын гына килеп, аппаратның ничегрәк эшләвен карамакчы булды. Шунда күзе ничектер папкага төште. Анда шикәрдәй ак кәгазьнең өске өлешенә эре хәрефләр белән «Об идеологической гипертонии в партии» дигән сүзләр язылган иде. Ирек шуннан тыш бер генә сүз дә укырга өлгермәде, Аида, папканы ялт кына ябып, ачулы тавыш белән:

—Сез нишләп мина комачаулыйсыз?!—дип кычкырды.

Аның күзләренә курку чыккан иде. Ирек «ә» дигәнче артка чигенде, кыенсынудан йөзенә ут капты.

—Гафу итегез, ксерокс аппаратының ничек эшләвен генә карамакчы идем...

—Утырыгыз урыныгызга!

Ул тагын бер мәртәбә гафу үтенде дә диванга чумәште. Теге язуның сүзләре күз алдында биеде: «Партиядә идеологик гипертония турында...» Аңа хәтта куркыныч булып китте. Идеологиядә югары кан басымы... Ирек папкадан күзен алмады. Андагы документларны уку өчен ул хәзер жанын да бирергә әзер иде. Аида эшләде дә эшләде, күчереп бетергәч, кәгазьләренең төп нөсхәсен шул папкага, ә яналарын яшел папкага салды, Ирекка калын күзлекләре аша кисәтүле караш ташлап алгач, Гроссман бүлмәсенә кереп китте. Бераздан ул чыгып:

—Керегез,—диде.

Ирек бүлмәгә узды. Алексей Абрамович, өстәл башында утырган килеш, теге яшел папканы ачкан һәм бер кәгазьне кулына тоткан. Алар икесе дә рәхәтләнеп көләләр иде.

—Бөтен бер ил рюмка эчендә. Ха-ха-ха!—диде Гроссман, яшел папканы сейфка бикләп.

Теге кеше Ирекка борылды һәм көлүеннән туктап:

—Мин барысын да беләм,—диде.—Партбилетыгыз белән хатыгызны бирегез әле.

Ирек, папкасыннан алып, хатны, аннары партия билетын бирде. Теге кеше аларны тиз генә карап чыкканнан соң:

—Болар миндә кала,—диде.—Мин Сергей Иванович булам. Ләкин

сез миңа керә дә, телефон аша да чыга алмыйсыз. Менә шушы номер белән шылтыратырсыз. Трубканы бер хатын-кыз алыр. Фамилиягезне әйткәч, ул сезгә җавап бирер.

—Хәзергә шушы гына,—диде Гроссман.

Ирек үзенең чыгып китүен аларның түземсезлек белән көтүен сизде.

—Рәхмәт, бик зур рәхмәт,—диде Ирек һәм саубуллашып чыгып китте...

## 34

Ничә көннәр Ирек ни җирдә түгел, ни күктә түгел дигәндәй—ике уртада асылынып тора. Ни Мәскәүдә, ни Болынкырда түгел, ни эштә, ни укуда түгел, ни иректә, ни тоткынлыкта түгел.

Ул баштарак язып маташты. Әмма шушы билгесезлек халәте аның бөтен җанын суырып алды, көнгә берничә мәртәбә кузгала торган баш өянәге тоташ газапка әверелде. Бүген иртүк ул каты чәй эчте, башын, краннан салкын су агызып, шуның астында тотканнан соң, сулы сөлге белән маңгай турыннан кысып бәйләде. Бераз ял итеп алыйм дип, диванга сузылып ятуга, ишек шылтыравыгы тавыш бирде. Төнлә Рашат кайтмаган иде, шулдыр дип ачса, уттай күзләрен елтыратып, Рәсүл басып тора. Тораташ кара сакал-мыек баскан егерме биш яшьләрдәге бу егет Рашатның хезмәтчесе кебек ике көн саен килеп тора, кибеттән ризык ташый, әмма күпме генә сораштырсаң да, үзенең кем икәнен дә, нинди эш белән шөгыльләнүен дә әйтми, ап-ак тешләрен күрсәтеп елмая гына иде. Ирек аны керергә, чәй эчәргә кыстады, әмма Рәсүл гадәттәгечә баш тартты.

—Рома кайтса, әйтегез, бүген кич мәгарәгә кагылсын,—диде.

—Нинди мәгарә?

—Кафе, үзе белә ул...

Ирек башын тотып уйга калды. Ничә миллион халык яши торган Мәскәүдә бер генә ныклап таяныр кешесе юклыгы аның бәгырен телгәләде. Рашат аны, таныш врачына алып барам, дип, инде кайчаннан бирле вәгъдә бирә, кайтып күренгәндә исенә төшергәч, «бүген» ди һәм шундук оныта. Аның әйткән сүзләре дә, биргән вәгъдәләре дә стенага сипкән борчак кебек... Сергей Иванович белән очрашканга да унөченче көн. Бүген тагын теге хатынга шылтыратырга кирәк. Квартирада телефон юк, Рашат аны әтиләр туктаусыз тикшереп, чемчекләп тормасын өчен юри керттермим, диде. Ирек урамга автоматка чыкты. Октябрь башы булуга карамастан, көн болытлы, шыксыз икән, күктән оныткан да бер бөртек коры кар очып куна. Исәнләшеп, фамилиясен әйтү белән теге хатын:

—Бүген уникенче яртыга Үзәк Комитетка барыгыз, ишек янында гына көтегез, сезне Сергей Иванович үзе чыгып алыр,—диде.

Аның үлеп барган тормышына килеп кергән кайнар агым иде бу. Ирек, булдыра алганча киенеп-ясанып, Үзәк Комитетка китте. Аны чыннан да Сергей Иванович үзе алып керде, партбилетын бирде, үзе артыннан ияртеп, борылмалы коридорлардан шактый йөрткәч, бер ишек каршына алып килде.

—Керегез,—диде ул пышылдап.—Кыска сөйләгез. Мөмкин кадәр кыска!

Бүлмә артык зур түгел, өстәл артында күзлек кигән, пеләш башлы бер кеше ручка тоткан килеш ниндидер кәгазьләргә иелгән иде.

—Сөйләгез!—диде кеше, кырыс кына.

—Мин Татарстаннан.

—Татариядән,—дип төзәтте аны теге кеше.—Эш нидә?

Ул, башын күтәреп, Ирекка беренче мәртәбә күз салды, әмма ручкасын куймады, сул кулының бармак арасына кыстырып, яртылаш ачкан кәгазе дә шул килеш калды.

—Мин Югары театраль курсларга укырга кергән идем. Партия райкомы каршы килде. Хәзер укудан куалар.

—Миңа ник кердегез?

—Укуымны дәвам итүдә булышуыгызны үтенәм...

Кеше ручкасын өстәлгә ташлады да, урыныннан торып, тәрәзә каршына баргач, кулларын чалбар кесәсенә тыкты.

—Әгәр Үзәк Комитет түбәндәге органнарның карарын юкка чыгарып утырса, ни буласын беләсезме сез?

Кырын баскач, Ирек аның мангаенның коточкыч кинлегенә һәм сөзәклегенә игътибар итте.

—Миңа бит үчләшеп аяк чалалар...

—Димәк, райком шулай кирәк дип тапкан. Хушыгыз!

Ирекнең йөрәге өзелеп төшеп киткәндәй булды. Ул бит биредә аны аңларлар, булышырлар дип өметләнгән иде. Ирек сикереп торып:

—Мин Үзәк Комитетны иң гадел урын дип килгән идем...—диде.

Кеше ялт итеп башын аңа таба борды, әмма гәүдәсе, тәрәзәгә ничек торган булса, шулай калды. Шунлыктан аның муены куркыныч булып җыерылды.

—Без беркайчан да һәрбер кешегә гадел була алмыйбыз. Гаделлек—халык өчен.

—Мин бит коммунист.

—Күрәм, сезне әле тиешенчә кыйнамаганнар икән. Барыгыз, Татариягезгә кайтыгыз. Яңадан биредә күренеп йөрмәгез!

Кеше башын тәрәзәгә таба борды. Ирек сүзсез генә сөйрәлеп чыгып китте. Ничек чыкканын тоймады, беркемне күрмәде. Ул кургаштай тетрәнү томаны эчендә иде. Гомер буе табынган, ышанган, гарше-көрси кебек күргән изге урын... Ни соң бу? Үзәк Комитетка кермәдемме соң ул әллә? Ышанмыйча, ул күтәрелеп биек соры бинаның иң өстендәге алтын хәрефләр белән язылган язуны кабат укып чыкты: «Центральный Комитет Коммунистической Партии Советского Союза».

Ирек кайтып кергәндә, Рашат кухняда эчеп утыра иде. Ул рюмка алып Ireккә дә салды.

—Әйдә, бүген очрашу хөрмәтенә!

Ирек карышмады. Дөрләп янып китмәс өчен эчәргә кирәк, дип уйлады ул.

—Син нишләп бик кәефсез?—диде Рашат, ботинкаларын аяк бармаклары белән генә салдырып, читкәрәк типкәч.

Ирек баягы очрашуны энәсеннән җебенә кадәр сөйләп күрсәтте.

—Ә күпме биргән иден?—дип сорады Рашат.

Ирек берни дә аңламады:

—Нәрсә?!

—Конверт белән акча күпме бирдең?

—Син нәрсә?! Әллә син анда базар дирекциясе дип беләсеңме?!

—Дурак булып тугансың, дурак булып үләчәксең син!—Рашат өметсез төстә кул селтәп куйды.—Хәзер син Мәскәүдә ниләр барганын күз алдына китерсәң, чәчләрең үрә торыр иде.

—Ә нәрсә бара соң?

—Әйтеп-аңлатып булмый аны... Беләсеңме: берсе дә чын түгел! Астан, метродан эскалатор белән чыккан кебек икенче тормыш килә. Рәхимсез тормыш! Кем ничек булдыра ала—умыра, алдый, үтерә...

—Син аңлатып сөйлә.

—Аңлата торган түгел. Бөтенесе югарыдан килә. Аннан соң икенче баскыч кабахәтләр, аннары өченче баскыч кабахәтләр. Может, йөзенче баскычта бездер...

Ул шаркылдап көлде һәм сүгенеп куйды. Аның сүзләреннән берни дә аңларлык та, аларга ышанырлык та түгел иде.

—Син мондагы кабахәтлекне күрсәң! Биредә йөрәксез кешеләр генә яши. Йөрәклеләргә урын юк. Аңладыңмы?

Ул аның инбашына шундый итеп китереп төртте, Ирек бик аздан гына урындыгы-ние белән артка барып төшмичә калды. Рашат рюмкаларны тагын тутырды. Ирек теге кургаш томаныннан чыгып килә иде, бусын сүзсез генә эчтеләр. Рашат, авызына капкан колбасасын чәйнәп бетерер-бетермәс, рюмкаларның икесен дә эләктереп алып, шкафка куйды, яртының калганын шапылдатып өстәл астына утыртты да, сикереп торып, костюмын төймәләргә керешге.

—Әйдә, киттек.

—Кая?

—Теге врачка.

Ирек ни әйтергә дә белмәде.

—Соң врачка аракы эчеп баралармыни?

—Эчү-эчмәүнең әһәмияте юк. Ул бүген дежурда. Мин аңа киләбез дидем.

—Мин бармыйм!—диде Ирек киреләнеп.—Баштук әйтергә иден.

Рашат кычкырып көлеп җибәрде.

—Баштук әйтсәм, син эчми иден. Курыкма, ул синнән авыруыңны гына сораштырачак.

—Куып чыгарыр...

—Ышан инде: ул безнең үз кешебез.

Ирек кул селтәп ризалашты, лимон чәйнәде, канәфер капты. Аннары, исенә төшеп, иртән Рәсүлнең килүен, аны бүген мәгарәгә чакыруын әйтте.

—Вакыт калса, сугылырбыз,—диде Рашат.—Барысына да Рома кирәк, ә Рома койрыкны тоттырмый! Ха-ха-ха!—Көлеп туктагач, ул Ирекка мөрәҗәгать итте:—Яшерен-батырын түгел, аңа бераз акча бирәсен булыр. Мәскәүдә хәзер шундый гадәт. Алдан акча йөри, аннан соң гына—кеше. Син ул югарыдагыларның күпме взятка алуларын белсәң! Безнең акчалар, кесәдән чыгып, чыпчыклар кебек пырхылдашып югарыдагыларның кесәсенә тула. Даже... үзең генә бел... минем бер банда башлыгы белән салып утырган бар. Бездән дә алалар, ди. Бирмәсәң, крышка, ди.

—Кем ала?

—Банда башлыгыннан кем аладыр—мин белмим.—Ул чыннан да аптырап, җавап көткәндәй, Ирекнең күзләренә сораулы карашын ташлады. Аннары көлеп җибәрде, гаҗәпләнгәнен белдереп, башын чайкап куйды.—Кайчакта әллә нинди сораулар биреп ташлыйсың син. Молодец!—Ул Ирекнең инбашына шапылдатып кулын салды да, без бит якын дуслар, дигәндәй, үзенә таба кысып куйды.

Алар хастаханәгә шактый озак—метрода да, троллейбуста да, җәяүләп тә бардылар. Ишек төбендә сакта утыручы карчык Рашатка, күрәсең, таныш иде, исәнләштеләр дә эчкә үттеләр. Өченче катка күтәрелгәч, Рашат, көтеп торырга кушып, каядыр югалды. Ирек тагын аптырашта калды. Иң беренче гаҗәпләндергәне—хастаханәнең тышкы ишеген ачып керүгә үк күзгә бәрелгән чүп-чар, юылмаган идәннәр булды. Мондый идәннәрне, баскычларны бары тик тәртипсез тулай торакларда гына күрергә мөмкин. Бу бит больница, СССРның башкаласы Мәскәү хастаханәсе! Болынкыр хастаханәсенә өс-башыңны салмыйча, халат кимичә эчкәре үтеп кара син! Ә биредә... аның башы бу күренешне бәяли-анлый алмыйча җәфаланды. Рашатны көтеп торган арада, ул палатага тышкы киемнәрдән кереп-чыгып йөрүчеләрне күреп хәйран калды. Авырулармы соң болар? Әгәр авырулар икән, алар больница киеменнән булырга тиеш ләбаса! Менә Иректән өч кенә адым ераклыктагы палатадан ыңгырашкан тавыш ишетелде. Ул сабый бала елавына охшаган иде. Менә ишекне нәрсәдер кытыр-кытыр тырмый башлады, ул ачылып та китте. Иң элек бусага аша нечкә озын бармаклы, сап-сары кул күренде һәм ул теге себерелмәгән, тәмәке төпчекләре, канлы мамык кисәкләре, ампула ватыклары, тагын әллә нәрсәләр аунап яткан идәнгә таянды. Аннары шундый ук сап-сары баш күренде, сары тоныкл күзләр Ирекка

таба төбәлделәр. Ул арада кеше ыңгыраша-ыңгыраша коридорга үрмәләде. Аның кара ыштаны эченнән чыгып торучы аяклары да зәгъфрандай сары иде. Ул күзләрен тагын Ирекккә төбәде, ыңгырашулы тавышы ишетелде:

—Алла хакы өчен... ярдәм итегез...

Ирек аның янына килде, ләкин нишләптер иң элек палатага күз атасы итте. Палата караңгы, анда дүрт койка. Берсендә гипсланган аягы күтәрелгән кеше ята, икенчесендәгесен күрерлек түгел, өстенә одеал бөркәлгән, өченчесенең урын-җире тәртипсез рәвештә өеп куелган.

—Туалетка барырга иде...

Ирек әлеге кешене, култык асларыннан тотып, аягына бастырды.

—Үзегез бара аласызмы?

—Юк...

Авыруның уч төпләре канап, күгәреп беткән, бер тез башы ыштанын тишеп чыккан, үзеннән әллә нинди укшыткыч исләр килә иде... Ирек аның тире белән сөяктән торган кулын үзенең иңбашына салды да коридор буйлап акрын гына алып китте. Идәннең кайбер урыннары чистарак, кайбер урыннары чүпле иде. Ирек моның сәбәбен сорады. Кеше ыңгырашып җавап бирде:

—Авыруларның туганнары... Шулар үз палаталарын себерәләр.

—Санитаркалар нишли?

—Юк алар.

—Нишләп?

—Килүче юк. Акчасы бәләкәй ди.

—Бүтән чакта бәдрәфкә ничек барасыз соң?

—Үрмәләп. Кайчакта күрше палатадагылар ярдәм итә. Курыкмагыз, сары чире түгел минем. Йокмый.

Игътибар белән карагач, ул бу кешенең әле илле яшьләр тирәсендә генә икәнен чамалады.

—Беркемегез дә юкмыни?

—Бер абыем зур урында эшли. Сирәк киләләр. Җирәнәләр. Хатын белән кыз наркоманкалар. Өйдә моннан да хуже...

Алар бәдрәфкә килеп җиттеләр. Ирек, аның ишеген ачып, теге кешене кертеп җибәрде.

—Рәхмәт сезгә. Мәңге онытмам,—диде ул, күз яшьләрен сөртеп.

—Көтәм мин сезне.

Ул арада Рашат күренде.

—Кая югалдың? Мин сине эзләп йөрим.

—Бәдрәфкә килгән идем.

—Әйдә керәбез.

Алар врач бүлмәсенә үттеләр. Өстәл артында коточкыч зур башлы, җирән чәчле, җирән мыеклы, кәкре борынлы ир утыра иде. Ул Ирекккә җирән төк баскан кулын биреп күреште дә:

—Башыгызның ничек авыртуы турында сөйләгез,—диде.

Ирекнең хатын-кызларныкы кебек мондый нечкә тавышлы ир-атны беркайчан да очратканы юк иде.

—Кайчаннан авырта?

Ирек туктаусыз сөйләде, аның сорауларына да җавап бирде. Соңыннан врач сейфыннан пластмасса флаконга тутырылган дару алды.

—Көнгә дүрт мәртәбә берәр капсула эчәсез.

—Рецепт бирә алмассызмы?

—Юк ул. Эзләмәгез. Бу туп-туры чит илдән...

Ирек акча чыгарды.

—Мин күпме тиеш?

—Өч йөз илле.

Ирек бу кадәр акча кирәктер дип уена да китермәгән иде.

—Йөзегездән күрәм... Дару кыйммәт, ләкин сез тереләчәксез. Шушыны эчеп бетерегез. Аракы, хәтта сыра да капмыйсыз. Әгәр булдыра

алмасагыз, даруны әрәм итеп алып та маташмагыз.

—Мин сез кушканны төгәл үтиячәкмен,—диде Ирек.

Инде эш бетте, ләкин нишләптер Рашат кузгалырга ашыкмады. Бераздан урта яшьләрдәге медсестра чыгып Рашатка акча янчыгы кадәр генә төргәк бирде. Алар чыгарга кузгалдылар.

—Син сак бул,—диде врач Рашатка.

—Ник?

—Вышка котыра ди анда.

—Котырсын. Аңа күп калмады инде.

—Да?—врачның йөзенә гаҗәпләнү билгеләре чыкты, мыегы елмаюдан җәелеп китте.

—Бу больницаның адресы ничек соң?—диде Ирек, урамга чыккач.

—Юк бу больница бер җирдә дә.

—Бар бит. Әнә тора.

—Юк. Аңлыйсыңмы? Юк! Оныт син аны, монда булганыңны беркемгә дә әйтмә!

Рашат бөтенләй кайту ягына булмаган каршы якка кызу-кызу атлый башлады.

—Кая барабыз?

—Баргач, күрерсең.

Алар, такси яллап хәтсез баргач, бер ун-унбиш катлы йортка килеп туктадылар. Кояш баеп килә иде инде. Беренче подъездга якынлашкач, Рашат:

—Туктап торма, миннән калма,—диде һәм кызу-кызу эчкә атлады. Рашат керү белән йөгереп диярлек подвалга төшеп китте. Ирек, ни уйларга да белмичә, аңа иярде. Рашат стенадан берничек тә аерылмаучы ишекне ачты да, алар эчкә үттеләр. Бу—тәмәке төпчеге, чүп-чар белән тулы подвал, түшәмдә сүрән генә ут яна иде. Ирек ике генә адым ераклыкта тагын бер ишек барын күрде. Рашат аны ачып җибәрүгә, музыка тавышы ишетелде, ялт-йорт итүче сүрән яктылыкта кеше шәүләләре күзгә чалынды. Ишекнең уң ягында муенына нindидер ялтыравык әйбер таккан, чәчләре тырпайган бер әзмәвер басып тора иде. Аның өстенә ни кигәнен дә чамаларлык түгел. Кара френч, кара чалбар, ялтырап торган аеллы киң каеш, беләкләре сызганулы, үзе туктаусыз сагыз чәйни, йөзен төк баскан, башында кара берет. Рашат аңа сүзсез генә күпмедер акча биргәч, алар эчкәре уздылар. Аркылысы алты-җиде, озынлыгы ун метрлар чамасы подвал нәрсә беләндер эчләнгән, анда шәрә ирләр хатын-кызларның әллә нинди бозык рәвешләрдә өчәрләп, дүртәрләп төрлечә җенси мөнәсәбәткә керүләрен күрсәткән зур-зур рәсемнәр ясалган. Төсле яктырткычлар, музыка тактына бер сүнеп, бер янып, әллә нинди серлелек бирәләр. Инглиз телендә булса кирәк, бер карлыккан тавышлы ир-атның ярылырлык булып җырлавы ишетелә, ничәдер пар бер-берсенә сыланып танцевать итә. Стенага якынрак итеп урнаштырылган тимер аяклы өстәлләр тирәсендә ир-ат, хатын-кыз шәүләләре абайлана. Уң якта барга охшаш урында кара киемле егет эчемлек сата. Ул арада, җир астыннан килеп чыккандай, Рәсүл пәйда булды. Аның белән Рашат аракы, сыра, кабымлык алып, өчесе бер өстәлгә урнаштылар.

—Миңа алмаска иден.

—Ник?

—Дару эчәсе бар бит.

—Иртәгәдән башларсың. Бүген эчмичә ярамый.

—Бүген нинди көн соң?

—Төшемле көн,—диде Рашат, һәм алар Рәсүл белән серле елмайдылар.

Йөз иллешәр грамм итеп салынган аракының яртысын кабып куйгач, Ирек өстәл уртасындагы кабымлыкка үрелде.

—Ни соң бу?

—Күрмисеңмени—вакланган сохари бит.

Шатыр-шотыр сохари чәйнәп, шешә борынынннан сыра эчтеләр.

—Кабарга бүтән әйберләре юкмыни?

—Не положено. Җыештырып, чүп түгеп йөри торган жир түгел. Яшерен эшли... Мәгарә шушы була инде.

—Милиция сизмиме?

—Кереме аларның күзен капларга гына житә. Тагын әллә кемнәргә...

Алар калган аракыларын чәкештереп эчәргә генә маташканда, ишек ачылып китте һәм анда идәнгә тиеп торучы кара плащ кигән озын гәүдә күренде. Ирек чак кычкырып җибәрмәде. Бу теге концерт көнне очраган адәм иде. Аның ап-ак башы, кара күз төпләре тәмәке төтене аша йөрәгенне ярырлык булып күренде.

—Вышка!—диде Рәсүл.

Рашат скелет башка күз генә сирпеп алды да мангаен өстәлгә тери язып иелде.

—Капла мине!—диде ул, гырылдык тавыш белән.

Ирек, шундук өстәлнең каршы ягына чыгып, ишеккә сырты белән басты. Рәсүл өстәл яныннан бөтенләй юкка чыккан иде. Ирек, башын юньләп бормыйча, күз кырые белән генә карашын ишеккә юнәлтеп алды. Вышка чыгып китеп бара иде.

—Нишләп кермәде ул?—дип сорады Ирек.

—Керсә, аның монда күкәеннән асалар,—диде тагын әллә каян пәйда булган Рәсүл.

Алар, аракыларын эчеп бетергәч, хәтсез генә гәп куерттылар.

—Кызык күрү өчен сиңа монда төнлә килергә кирәк,—диде Рашат.— Шәрә кызлар биегәнне карарга. Ә атнага ике көн кәрт сугучы шулерлар җыела. Вот анда күрәсең инде! Теге атнада берәү, киемнәрен оттырып бетергәч, үзен салды.

—Оттымы соң?

—Ота алмады шул. Син аның ялынып елаганын күрсәң! Алып чыгып киттеләр. Бер сәгатьтән килделәр. Һәм кеше юк...

—Курыкмыйлармы?

—Алар бернидән дә курыкмый. Бөтенесе бергә. Менә бу боргаланучы кызларга кара әле! Алар сатыла. Телисеңме, икесен алабыз?

—Син нәрсә?! Юк, юк!—диде Ирек, коты очып.

—Ник? Әллә кая барасы түгел. Әнә шул үзебез кергән подъезддан бер генә кат өскә күтәреләсе.—Рашат бармагы белән түшәмгә күрсәтте.— Нәкъ менә шушы турлап. Ну, малай, болар күрмәгәненне күрсәтә инде! Югары класс профессионаллар. Бер сәгатең бер минут кебек үтә дә китә.

—Әйдә кайтыйк,—диде Ирек, аның шактый нык исерүен күреп.

—Кайтырбыз. Мин берсен алып кереп чыгам. Сез Рәсүл белән көтеп торыгыз.

—Мин китәм, сез калыгыз.

—Ярый, черт с ними! Иртәгә... Тагын берәрне чеметәбезме?

—Кайткач.

—Ярый алайса.

Рашат ишек янындагы теге әзмәвергә уң кулын күтәреп сәлам бирде дә, алар урамга чыктылар.

Кояш баеган, караңгылык инеп килә иде инде.

—Болар кемнәр соң?—дип сорады ул, Рашат папирос кабызган арада.

—Болармы... болар бөтен нәрсәне үз кулларына алмакчы булалар...

—Син алар беләнмени?

—Кирәкләре бар иде! Шизиклар шайкасы. Мин—үземә-үзем бер дәүләт...

Алар подъездлар алдыннан атлап, йортның почмагыннан борылуга, теге озын затка бәрелә язып туктап калдылар. Аның артында читтәрәк биш-алты кешелек төркем көлешә-көлешә нидер сөйләшә иде. Вышка,

башын артка ташлап, күрә карау кеше ниндидер вак язуны укып азаплангандай, аларга төбәлде. Шул мизгелдә Рәсүл жир тишегенә төшкәндәй юк булды.

—Сәлам, Ро!

—Сәлам,—диде Рашат, аның кулын кысып.

Ул Ирекка дә кул бирде. Вышканың кулы коточкыч зур, саллы һәм тимердәй каты иде.

—Кемең бу?

—Танышым гына,—диде Рашат.

Вышканың йөзенә елмаюга охшаш ниндидер астыртын бер нәрсә эленде.

—Шәп сыйладылармы соң?

Аның нечкә иреннәре пырхылдап көлеп жибәрергә әзерләнгән кешенеке төсле кабарды.

—Без үтеп барышлый... бер генә минутка...

—Ро?!—Ул озын кулларын як-якка жәйде.—Акланырга кирәкми. Мин бит синнән сорау алмыйм. Якын дустым буларак кына белешүем.

—Рәхмәт инде,—дип, Рашатның авыз эченнән генә мыгырдаганы ишетелде.

—Әйдә, бер сыйлыйм әле үзеңне.

—Тиясең син.

—Син нәрсә?! Кореш?! Тырнак белән дә чиртмим!

—Ике көн көт... Беркөн алдаганым өчен гафу ит. Шулай килеп чыкты. Ике көннән тиенен тиенгә бирәм...

—Мин синнән акча сорадыммыни әле?

—Беркөн әйткән сүзләреңне яхшы хәтерлим мин синең...

Рашатның тавышы бөтенләй юашланып, ишетелмәслек булып калды.

—Ро!—Вышка Рашатның аска иелгән башын имән бармагы белән иягеннән этеп турайтты да һәр сүзенә басым ясап:—Бүген кәеф әйбәт минем,—диде.—Тагын да әйбәтрәк булуын телисеңме?

—Телим...

—Киттек алайса.

—Без ашыгабыз...

—Неужели син дустың белән бер рюмка эчәргә жирәнәсең?

—Мин беләм: син кыйнатасың егетләреңнән.

—Валлаһи, беркем бармак белән дә кагылмаячак!—Вышка чукынып куйды.

Ул Рашат белән Ирекне култыклап алды да юл буенда торган машиналарга таба алып китте. Алар өч машинаның алдагысына килделәр. Вышка руль артына, аның янына Рашат, Ирек артка утырды.

—Кая барабыз?—дип сорады Рашат, Вышкага төбәлеп.

—Ерак түгел. Әнә тегендә иң читтәге йортны күрәсеңме? Шунда гына.

Ул төштән инде басу-кырлар башлана иде. Ике машина төялгән егетләр, аларны узып китеп, машиналарын йортның арткы ягына туктаттылар. Вышка үзенең машинасын урта подъезд турына китереп үк терәде.

Машинадан төшкән арада, Рашат Ирекнең куртка кесәсенә нидер салды. Ирек кулын тыккач, бармаклары он шикелле йомшак нәрсә тутырылган пакетка тиде. Теге врач биргән әйбер иде бу, ахрысы...

Егетләр йөгерешеп кереп тә киттеләр. Вышка Ирек белән Рашатны алдан жибәрде, үзе аларга ияреде. Биредә төзүчеләрнең күптән булмаганлыгы сизелеп тора. Баскыч урынына да өч калын такта гына салынган. Алар райкомның утырышлар залы кадәр бер бүлмәгә килеп керделәр. Дүрт урында тәрәзә уемы, бер ишек урыны калдырылган бу бүлмәнең идәне жәелмәгән, аяк асты тулы вак таш, кирпеч ватыклары, такта башлары, пыяла кыйпылчыклары ауный иде.

Вышканың егетләре, тәрәзә төбенә такта куеп, аның өстенә өч

стакан, ачылган сыра шешәләре куйдылар, стаканнарга яртыдан күбрәк итеп аракы салдылар. Вышка өч стаканны да бер кулы белән эләктерде дә Рашат белән Ирекkә сузды.

—Мәңгелек нәрсәләр өчен! Кисәтеп куям: калдырыш түгел.

Рашат «эч» дигән мәгънәдә Ирекkә баш какты да, өчәүләп эчеп җибәрделәр. Кабарга шул ук стаканнарга сыра салдылар, тәмәке кабыздылар. Егетләр дә эчеп куйдылар. Әкрен генә гәп куерды.

—Ро, беләсеңме, мин бер кызык уен уйлап таптым бит әле.

Рашатның йөзенә курку билгеләре чыкты.

—Нинди уен?

—Менә хәзер уйнап карыйбыз. Моннан алдагысы әйбәт чыккан иде...

Егетләр сикерешеп тәрәзә турына бастылар.

—Син бит тимәскә сүз бирден,—диде Рашат, өметсез тавыш белән.

—Ә кем тияргә җыена? Мин сүземдә тора беләм. Беркем дә сезгә тырнак белән дә кагылмаячак. Уен мондый. Хәзер танышын белән икегез билгә кадәр чишенегез.

Рашат пыяла ватыклары, кирпеч калдыклары өстенә тезләнде.

—Геракл! Җибәр син безне...—Ул елый башлады.

—Син нәрсә елыйсың? Уен гына дим бит. Ярдәм итегез әле!

Егетләр, төреп алып, тарткалый-йолыккалый башлауга, алар ничек чишенгәннәрен дә сизми калдылар. Киемнәрен каядыр ыргыттылар. Куркудан һәм салкыннан алар икесе дә калтырыйлар иде.

—Син, Ро, ике яклы пычак булып күпме йөрден әле?

—Мин бирәм ул акчаларны...

—Сүз ул хакта бармый. Теге дөньяда түләрсең. Күпме йөрдең?

—Ике яклы пычак түгел мин,—дип мыгырданды Рашат, каш астыннан сөзеп карап.

—Исәп-хисап вакыты житте. Моңа кадәр син уйнадын, хәзер мин шаярып карыйм.

Рашатны өч егет Ирекkә каршы стенага таба чигерделәр. Кулына, каяндыр чыгарып, озын хәнҗәр тоттырдылар:

—Тәрәзәләрен томаларга!—диде Вышка.

Ул арада Рашатның күзләрен кара тасма белән капладылар. Ирек, башына сугып аңгырайтылган кешедәй, һаман берни дә аңламый иде әле. Кинәт аның да күзенә тасма ябыштырдылар, кулына авыр саплы хәнҗәр тоттырдылар. Вышка егетләренең аяк астындагы ташларны, кирпеч ватыкларын шалтыратып ишеккә йөгергәннәре ишетелде, аннары тып-тын калдылар... Ирек үзенең йөрәгенең күкрәк читлеген жимереп чыгарлык булып тибүен, еш-еш сулыш алуын аермачык ишетте...

Рашат тагын елап җибәрде:

—Геракл! Үлгәнче колың булам...

—Җитте! Минем команданы тыңлагыз: кайсыгыз җинә—аны исән калдырам. Хәйләләргә уйласагыз, икегезне дә пычакка эләчәкмен! Башладык!

—Геракл! Без бит синең белән...

—Ро, мин сиңа тормыш бүләк итәм. Сайланып торасы юк.

Ирекнең тәнендәге каны катты, теше-тешкә шакы-шокы бәрелде. Ул моның өн икәненә әле һаман ышанып бетә алмый иде. Вышканың тагын кисәтүле тавышы ишетелде:

—Ро, син минем ике сөйләшмәгәнне беләсен... Сузма, никадәр тизрәк булса, шулкадәр шәбрәк ич...

Каршыда табан астында вак таш шылтыравы ишетелде. Бер, ике... Рашат туктап калды. Ирек, бераз чүгәләп, хәнҗәрен артка таба каратып сул кулына күчерде.

—Ирек, саклан!

Рашатның хырылдаулы тавышы Ирекнең бугазыннан эләктергән шикелле тәэсир итте.

—Рашат, ялгыша күрмә!—диде ул, авырлык белән тын алып.—Мин сина кагылмаячакмын!

—Сөйләшмәскә!!!

Шулчак Ирекнең сул кулын арттан кемдер әләктерде һәм колагына бала йоннарын кабартырлык итеп пышылдады:

—Үтер! Юкса үзенне бетерәбез!

—Ну-у-у?!!—дип үкерде Вышка.

Рашатның тагын шыбырдатып атлаганы ишетелде. Ирек, аяк очларына гына басып, чигенә башлады, әмма барыбер тавыш чыгармыйча хәрәкәтләнү мөмкин түгел иде. Уң кулы белән үрелеп, ул стенаны эзләде, бармаклары кирпечкә тигәч, бераз җинел булып киткәндәй тоелды. Кинәт Рашатның дөбер-шатыр чабып килгәне ишетелде. Ирек, стенадан кулын аермыйча, кабаланып почмакка таба атлады. Рашатның әле генә Ирек торган урынга гөрселдәп барып бәрелгәне, әшәке итеп сүгенгәне ишетелде. Ишек турыннан, йортның түшәмен күтәрерлек булып, кыргыйларча бердәм көлү янгырады.

—Молодец, Ро! Әйдә, әйдә!

Ирек акрын гына стенага тотынып баруын дәвам итте. Хәзер Рашат та аның кайсы юнәлештә хәрәкәтләнүен төшенде, туп-туры Ирекка таба якынлашты. Ирек тавыш чыгармаска тырышып чигенә башлады. Әмма үкчәсе нәрсәгәдер эләгеп, чалкан барып төште һәм аркасының авыртуына түзә алмыйча ыңгырашып җибәрде. Сикереп торырга өлгерә алмады, Рашат аның турында иде инде. Ул сузылып яткан килеш стенага сыланды. Рашатның еш-еш сулыш алганы ишетелде. Ул Ирекнең кырына гына ухылдап хәнҗәрен китереп кадады, ташка бәрелеп, корыч чыкылдаганы ишетелде. Берничә мәртәбә шулай кадагач, Рашатның хәнҗәрен як-якка уйнатып, һава ярганын Ирек тәненең һәр күзәнәге белән сизде... Вышканың егетләре ләззәтләнеп шаулаша, көч биреп кычкырыша башладылар:

—Әйдә, Ро, кыюрак!

—Айкап җибәр, айкап!

Рашат аның еракка китеп өлгерә алмаячагын чамалый иде, шуңа күрә читкә атылмады, стенаны капшаштыра башлады, хәнҗәре белән стенаны кытырдатып алды. Аның кулы стенадан һаман түбәнрәк шуышты... Ирек тын алудан да туктагандай булды. Аның тәнен тир каплады. Ул уң кулын йодрыклаган хәлдә күтә башлады. Аңа хәтта Рашатның тән кайнарлыгы да килеп орынгандай булды һәм... Рашатның кулы аның йөзенә килеп төртелде. Пружина кебек киеренке хәлдә яткан Ирек йодрыгын яшен тизлеге белән каршы якка селтәде. Йодрык Рашатның әллә касыгына, әллә эченә туры килде, аның кычкырып җибәргәне һәм вак ташларны шылтырата-шылтырата барып төшкәне ишетелде. Ул ыңгырашып җибәрде, озын итеп сүгенде. Аларны тамаша кылучылар кыргыйларча сикерешә-сикерешә көлештеләр.

Шул арада Ирек, Рашаттан качып, каршы як стенага барып сөрлекте. Тез башларының һәм кулларының авыртуына кычкырып җибәрмәс өчен иренен тешләде. Аның чамалавы буенча ул хәзер тоташ стена янында, ә Рашат тәрәзә каршындарак булырга тиеш иде. Ирек аның торып басканын, бер урында таптанганын сизде. Ул аркасын стенага терәде.

—Тукта сволочь!—Рашат кабахәт сүзләр белән сүгенде.—Барыбер үтерәм! Син түгел, мин яшәргә тиеш!

Ул котырынып уңга ташланды, ах-ух килде, күрәсен, хәнҗәрен селтәде һәм аның болайга атлавы ишетелде. Тагын куалашу башланды. Рашат аңа әллә ничә мәртәбә сикерде, Ирек торган урыныннан йә алга, йә артка качты, үзе бер генә мәртәбә дә аңа укталмады. Менә ул, кыргый ерткыч тавышлар чыгарып, тагын аңа ташланды, Ирек уңга ыргылды, ләкин ишек турында хихылдаучы шайкадан кемдер аның инбашына китереп сукты.

—Пассивлык өчен!—дигән тавышы ишетелде Вышканың.

Сугу шулкадәр көчле булды, Ирек тигезлеген югалтты, уртага таба сөрлегеп, бер адым атлады да сул ягы белән барып төште, борыныннан гөрләп кан китте һәм ул авыртудан кычкырып җибәрде. Ирек, күтәрелергә теләп, терсәгенә таянмакчы булды. Нәкъ шулчак Рашат, ташларны шылтыратып, аның кырына ук килеп басты. Ирек читкә ыргылырга

омтылды, әмма тораташ каткан гәүдәсе аны тыңламады... «Беттем!» диде ул үз-үзенә, тормыш белән хушлашып. Гомеренең шушылай коточкыч тәгәлләнүенә ярсулы үкенү аның йөрәген ачыттырды. Рашатның хәнҗәре яндырып аның эченә кереп тә китте...

—Эләктеңме, мерзавец!—дип үкерде Рашат.—Хәзер эшеңне бетерәм мин синең!

Ирек коточкыч авыртудан эченә таба җыерылган тезләрен языдыра алмады, үз-үзен саклау өчен ачыргаланып, кулларын аңа каршы сузды һәм Рашатның хәнҗәргә килеп кергәнен тойды. Аның тавышы «ык» кына итеп киселде, авыр гәүдәсе, Ирекнең кулларын сытып, өстенә ауды. Ирек соңгы мизгелдә җылы кан исен һәм башының коточкыч авыртуын гына сизеп калды...

* * *

Ничек болай бөтен дөнья гөлт итеп нурланып китте соң әле? Бу әллә нинди ят яктылык иде. Каршысында да, як-ягында да ниндидер көмештәй ак көпшәләр, алар төрле озынлыкта, төрле юанлыкта ялык-йолык киләләр, көмеш нур сибәләр. Чалкан яткан Ирекне ниндидер көч шул исәпсез-хисапсыз көпшәләр уртасыннан күренми торган арбада дөмбер-дөмбер зур тизлектә алга куалый. Дөмбер-дөмбер, дөмбер-дөмбер... Бу әллә нинди моңлы, ят, матур тавыш югарыдан ук—бик тә, бик тә ерактан бар тарафны яңгыратып килә, килә торгач, әллә моңга бүленеп, кабат кушыла, шуның һәрберсе барлык әгъзаларга, һәр күзәнәгеңә тула. Ә син доңгыр-доңгыр һаман каядыр алга очасың, көпшәләр келтер-келтер тезелеп кала, яшен яктысына тартым сәер яктылык тагын да көчәя, теге моңлы җыр төсле тавыш, төрледән-төрле төсмерләргә кереп, сине үз кочагында изрәтә, тибрәлдерә һәм бик-бик еракларга алып китә, аңардан аерылу мөмкин түгел, чөнки бу моң синең күзәнәкләрең эчендә яңгырый торган һәм бөтен якка тарала торган моң. Шундый рәхәт, гәүдәнең авырлыгы юк, бернинди уй юк, бөтен барлыгыңны шушы яктылык, шушы моңлы көй, шушы син ике якка ярып бара торган көмеш дивар биләгән. Бүтән берни кирәкми, гүя син гомер буе шушы рәхәтлек эчендә тирбәлгәнсен һәм бу мәңге дәвам итәр төсле...

...Кинәт ул сәер дөнья югалды... Ирек бөтен гәүдәсендә, һәр әгъзасында таш бастыргандай авырлык, ою тойды. Күз кабакларын бик озак тырыша торгач кына селкетә алды. Йөзенә якын гына ниндидер шәүлә селкенде, аннары томан арасыннан ул аның кеше йөзе икәнлеген чамалады. Әмма күз кабаклары авыраеп ябылдылар, ул онытылды. Күпмедер вакыт үткәч, тагын уянды, борынына кергән дару исләреннән, ак колпак, ак халат кигән кешеләрдән үзенең хастаханәдә икәнлеген аңлады. Ләкин нишләп бирегә ятуын төшенә алмады, моның аның өчен бернинди әһәмияте дә юк иде. Аңа бер генә нәрсә—су гына кирәк иде.

—Су, су...—дип пышылдады ул.

Шәфкать туташы марля уралган юеш чәй калагын аның яргаланган иреннәренә тигерде. Суның салкынлыгын, юешлеген тойган Ирек уттай телен комсызланып сузды, калакны йотып җибәрергә теләгәндәй, тешләре белән кысты.

—Сезгә су эчәргә ярамый,—диде шәфкать туташы һәм, калакны алып, сулы стаканга салды. Стакан якын гына, караватның теге башындагы тумбочкада гына иде, Ирек аңа күз карашы белән тартып китерерлек булып карады.

—Тагын бер генә тамчы...

Шәфкать туташы калакны аның иреннәренә ышкып кына алды да каядыр еракка ук алып куйды.

... Өч көннән соң, Ирекне реанимациядән ике кешелек палатага күчерделәр. Бу вакытта ул үзенең биш сәгатькә якын операция кичергәнен белә иде инде. Шул ук көнне кич палатага ак халат кигән Рәсүл килеп керде.

—Хәлең ничек?

—Шәп... Рашат кайда?

—Ул юк инде... Синнән килеп сорау алсалар, берни дә белмим, диген... Мин үзебезнекеләрне җыйнап алып килмәгән булсам, син дә исән калмый идең...

Ирек чытырдатып күзләрен йомды. Димәк, ул—кеше үтерүче...

Рәсүл аның тумбочкасына өрек җимеше, виноград куйды.

—Мин янадан килмим, безгә очрашырга ярамый. Син больницадан чыгу белән Мәскәүдән юк бул. Рашатның квартирасы тирәсендә, гомумән, күренмә...

Унҗиде көн дигәндә, Ирекне хастаханәдән чыгардылар. Ул, тулай торакка барып, чемоданнарын алды да, «Татарстан» поездына утырып, Казанга юл тотты...

*Беренче кисәк тәмам.*

## Соңгы сүз урынына

Романның сезгә тәкъдим ителгән беренче кисәген мин 1991 елның ахырында Малеевка иҗат йортында нигездә төгәлләгән идем. Соңрак «Аргамак» журналында *(1995 ел, 1, 2 сан)*, «Мәдәни җомга»да аннан өзекләр дә бирелде *(1996, 19 июль саны)*.

Әсәрнең күңелемдә сер итеп кенә йөрткән исеме дә ул чор өчен чәчләрне үрә торгызырлык иде: «Партиягә кабер ташы». Коммунистлар партиясенең әле дөньяны дер селкетеп торган чагы бит! Югарырак рангтагы партия җитәкчесенең бер сүзе синең әсәреңне юк итә ала торган чор бу. Романны язганда да КПССның хакимлеге бетү ихтималы минем башыма хәтта ялгыш та кереп карамады. Кая ди сиңа кеше хыялы җитмәс андый уй!

Алайса, каян килгән шулкадәр усал исем? Бу сорауга мин ике-өч җөмлә белән дә җавап бирә алам. Ләкин алай итмим әле. Бераз ерактанрак башласам, җавабым дәлиллерәк булыр шикелле.

Мин егерме бер яшемдә КПСС сафларына кердем. Минем өчен бердәнбер дөрес юл шул дип кердем. Турысын гына әйткәндә, мин ул хакта артык уйланмадым да шикелле. Бу инде минем өчен авыл мәктәбенә укырга кергән кебек табигый хәл иде. Ул елларда туган авылым Олы Чакмакта китапханәдә эшлим, Казан дәүләт университетында читтән торып белем алам, партия тарихын, философияне, марксизм-ленинизм тәгълиматын шактый ук тырышып һәм мөкиббән китеп өйрәнәм, политукуларга йөрим, үзем дә комсомол политмәгарифендә яшьләрне укытам. Үземә күпләп өелгән партия поручениеләрен алны-ялны белмичә фанатикларча үтәргә тырыштым, пропагандист, агитатор, политинформатор, лектор, стена газетасы редакторы, минем шәхси уй-максатларыма туры килмәсә дә, югары партия органнары күрсәтмәсенә буйсынып, район газетасы редакторы, райком члены, тагын әллә кемнәр булдым. Әлеге эшләр әйтеп бетергесез күп физик һәм акыл көчен суырсалар да, моңа үкенмим. Алар һәммәсе дә бер игелекле омтылышка—тормышыбызны күркәмрәк итүгә, кешеләрне тәрбияләүгә бирелделәр. Гел үк йогынтысыз булмагандыр, кешеләрдән рәхмәт сүзләрен еш ишетә идек.

Кемнәрдер наданлыкта, сәяси сукырлыкта гаепләсәләр гаепләрләр, мин партиянең егерме елда коммунизм төзү программасын да хуплап каршыладым, аңа шактый вакытлар инанып яшәдем, аны пропагандаладым. Ә нигә ышанмаска? Мин гади колхозчы егет (урта мәктәптән соң бер ел колхозда төрле эшләрдә эшләдем) университетка укырга керергә дигән татлы хыялымны үз көчем, үз ихтыярым белән тормышка ашырдым. «Үз» дип басым ясавым юкка түгел. Минем әтием сугышта үлгән, әнкәй белән без икәүдән-икәү генә, ни арттан этәрлек, ни алдан тартырлык кешебез юк. Мин, күпмедер акча җыештырып, иске фанер чемоданыма шыплап китаплар тутырып, аны дүрт ягыннан нечкә сүс бау белән атландырып бәйләдем дә авылдан Бөгелмәгә чыгып киттем. Аннан поездга утырып барып, Казанда

имтиханнар тапшырдым, бер урынга дүрт кешелек конкурстан үттем, университет студенты булдым. Авылларда керосин лампасы урынына гөлт итеп Ильич лампалары янды, басуларга үзе йөри торган комбайннар килде, борчакны чалгы белән чабудан котылдык, фермаларга механизация керде, салам түбәләрне шиферга алыштырдык, кешеләр җиңел машинага ябырылды, колхозчылар пенсиягә чыга башлады. Чоры өчен болар бик зур үзгәрешләр иде. Халыкның тормыш хәле яхшырачагы турында сөйләп-язып торалар. Күбесе рас килә. Әйбер бәяләре дә һаман төшүгә таба. Фән өлкәсендәге казанышларны әйткән дә юк. Гагаринның космоска очуы гына да ни тора! Без бит! Тарихта беренче мәртәбә! Капиталистлар белән дә аяк терәп сөйләшәбез, безнең белән шаяра алмыйлар. Телибез–чирәм җирләрне үзләштерәбез, телибез–Себерне үзгәртәбез. Ил буена бер-бер артлы күтәрелүче гигант төзелешләр, яңа шәһәрләр белән бергә күз алдында гына Азнакай, Әлмәт, Октябрьск танымаслык үсә, Түбән Кама, Чаллы калалары, агрошәһәрләр калка, химия, шин заводлары төзелә. Шулай булгач, нигә әле коммунизмга ышанмаска?

Менә хәзер мәзәк ул ичмасам. Тәүлек буе без ни күрәбез, ни ишетәбез? Шартлаган йортлар, егылып төшкән самолетлар, баткан кораблар, утсыз, жылысыз, газсыз калган шәһәрләр, хаерчелеккә түзә алмыйча, ачлык игълан итүче шахтерлар, забастовка күтәрүче укытучылар, халкыбызның ничәмә-ничә буыны тудырган байлыкларны эһ иткән арада бер тиенсез элэктереп алган ят фамилияле магнатлар, үтерүче һәм талаучы мафиоз катламнар, ничә еллар буе алып барылган сугышлар һәм шәһәр-авыллардагы эшсез яшьләр, караклар, наркоманнар, кесәләрендә дәрәҗәле мандат йөртүче җинаятьчеләр, ач хаерчеләр... Санап кына бетерерлекме соң! Хәзер әнә шул демократик җәмгыять казанышлары тәэсирендә һәр иртәдә: «Бүген исән калып булыр микән, Ходаем?»–дип (беркемгә дә ышаныч калмагач, Ходай искә төште), йөрәгең ярылып йокыдан торасың. Ә ул елларда без һәркөн иртәнге биштә Уфа радиосыннан башкорт концерты тыңлап уяныр идек, дәртләнеп эшкә китәр идек. Тамагыбыз тук, өстебез бөтен, күңелләребез якты хыяллар белән тулы иде.

Коммунизм булачагына нилектән ышанганымны үтә гадиләштереп булса да аңлатырга тырыштым. Берсеннән-берсе тәрбияви фильмнар, әдәби әсәрләр, спектакль-концертлар да шуңа ышандырды, без алардагы геройлар кебек яшәргә, шулар үрнәгендә үзебезне камилләштерергә омтылдык. Хәзерге «әдәбият-сәнгать әсәре» дигән исем астында яшәешебезне баскан нәрсәләр халыкны миһербансызлыкка, һәртөрле бозыклыкка, көчләү, талау, үтерү технологиясенә генә өйрәтәләр. Без авылда юньләп ишек бикләмәдек, чөнки кеше әйберсенә кагылу коточкыч хурлык, андый хәлләр сирәк иде. Хәзер генә ул кайберәүләр никадәр күбрәк урласа, җәмгыятьтә шулкадәр югарырак абруй һәм дәрәҗәләр белән файдалана.

Алайса, партиягә кабер ташы белән кизәнергә мине нәрсә мәҗбүр итте соң?

Алтмышынчы елларның икенче яртысыннан мин партия тегермәнендә ныклап торып тартыла башладым һәм тартылган, уалган саен, бер коточкыч нәрсәне аңлый бардым. КПСС тормышында урнашкан тәртип–Генераль секретарьдан алып райком секретарена кадәр тезелгән культларның азынуы, аларның һәр сүзен, нинди генә ахмак һәм көлке булуына карамастан, барлык халыкның бернинди тәнкыйтьсез кабул итәргә һәм берсүзсез үтәргә тиеш булуы акылга сыймаслык хәл иде. Шушы гаделсезлеккә ничә еллар буе бәгырьләр телгәләнде. Башка партияләр юк, оппозиция юк, тәнкыйть юк. Бөтен ил башын игән һәм буйсынган хәлдә. Шушы шартта теләсә нинди юллар белән партиянең җитәкче органнарына үрмәләүчеләр арткannан арта барды. Бездә райкомның бер вәкиле турында мондый сүз йөри иде: «Фәлән Фәләнечкә әтиең белән әниеңнең башын кисеп алып килсәң, сине райкомның беренче секретаре итәбез, дисәң, шундук икесенең дә башын капчыкка салып алып киләчәк.» Мин район газетасы редакторы булып эшләгәндә (1972—1981 нче еллар), бер редакторның райкомның беренче секретаре бүлмәсенә аяк киемен салып, оекбаштан кергәнлеге турында сөйләделәр. Бу хак булгандырмы, юктырмы–анысын әйтә алмыйм. Әмма ул беренчеләрнең кодрәтлелек һәм дәһшәтлелек дәрәҗәсен бик ачык күрсәтә.

Партия җитәкчеләре законнан өстен торалар, үзләренә каршы ялгышып бер сүз әйткән, яисә алар өнәмәгән эш эшләгән теләсә кемне, теләсә нишләтә алалар иде. Шундый шартларда бу роман чыгачак идеме соң? Юктыр. Партия хакимияте кысаларында иҗат итү (бигрәк тә аңа тел тигерсәң) ул–1,5 метр биеклектәге корылма эчендә 2 метрга сикерергә азаплану кебегрәк иде. Ләкин юлларын таптык. 1989 нчы елда минем «Шаһзаманов эше» дигән повестем дөнья күрде. Гади коммунистның

тормышындагы бер фаҗигале вакыйга нигезенә алынса да, ул әсәрдә партиянең эчке тормышындагы череп таркалу билгеләрен шактый калку күрсәтә алдым кебек. Ике авыз сүз белән әйткәндә, эчтәлек мондыйрак: өлкә комитеты секретаре күрмәсен өчен, солыча баскан борчак басуын төнлә сөрдереп ташлыйлар, халык байлыгы туфракка күмдерелә. Аны чабып, терлекләргә азык иткәндә дә күпме файда килер иде! Бу корткычлыкка тиң эшне эшләгән кешене төрмәдә черетерлек югыйсә. Черетерсең! Ул бит райком секретаре. Аның хәзер җаны тыныч, кәнәфиенә куркыныч янамый. Мин моны уйлап чыгармадым, үзебезнең җирлектә булган хәлдән алып яздым. Әсәрне тоткарламасыннар өчен миңа «партия органнарында кайбер карьеристлар да очрый» дигән фикерне уздырырга туры килде. Шул «кайбер», «очрый» аркасында гына ул матбугатта дөнья күрә алды.

«Кабер ташы»н язганда да, ниндидер өмет чаткысы булгандыр инде ул. Әсәрнең эченә тирәнрәк керә барган саен, мин ул шомлы исемнән ерагая бардым. Беренчедән, «партиягә» дип әйтү дөрес түгел: 17-18 миллион гади коммунистның ни гаебе бар? Икенчедән, партиянең гадел, игелекле максатларына, кешелекле идеологиясенә нигә дип тукынырга? Хикмәт аның барлык изге ниятләрен харап итүче эш алымнарында, эчке тормышында, картлар йортына әверелгән Кремлендә эгоистик максатларыннан югары күтәрелә алмаган җитәкчеләрендә бит. Өченчедән, мондый исемнең матур әдәбият әсәренә батмавы көн кебек ачык. Бу минем эчке фикерем, романны инстинкт дәрәҗәсендә сугаручы дәрт-омтылышым иде.

Әсәрне чыгаруны суза килүнең дә сәбәпләре күп. Кинәт кенә партия үзе дә бетеп китте бит. Туйдан соң дөмбергә дигәндәй, киргәге булырмы соң инде романның, ник чаңны вакытында сукмадың, дип әйтерләр кебек тоелды миңа.

Халык бәгырен телә торган тагын бер нәрсә: партия үлде, безгә ана сөте белән кергән, ата-бабаларыбыз каннарын һәм гомерләрен биргән идеалларыбыз да җимерелде. Халык нишләргә тиеш? Күп партиялелек шартларында, үзенең яңа тәртипләре белән халык идеалларын байрак иткән коммунистлар партиясе кирәк иде. Әгәр шулай булмаса, халык КПРФ лидеры Зюганов өчен тавыш бирер идемени? Халык биле сынып егылган атның аякка басуын көткәндәй партиянең терелүен көтте. Шундый чакта романны чыгару әхлаксызлык кебек тоелды. Йорт дөрләп янганда аның эчендәге тәртипләрне сүгү кебегрәк булачак иде бит инде бу.

Хәзер инде көтү чоры үтеп китте. Аннары хикмәт партиядә генә дә түгел ләбаса. Халык тормышының теләсә кайсы чоры олы сабак алырлык. Һәр чорның үз хакыйкате әйтелергә тиеш. Шул дәвер тегермәнендә тартылган кеше буларак, аны мин дә әйтмәсәм, кем әйтер? Әле социализм, капиталистик система элементларын да кертеп, һичшиксез кабатланачак. Тик хаталары кабатланмасын иде. Минем бүгенге позициям шундый.

Сүз күрәләтә озынга китеп бара. Түгәрәклим. Өч китаптан торачак романның беренче кисәге тәмам. Калганнары язылу процессында. Әле бит минем геройларымның язмышлары төйнәлгән, чуалган килеш калды. Әле алда очсыз-кырыйсыз тормыш давыллары. Әле партиянең таратыласы бар. Әле халыкка, күрелмәгән сынаулар алып, бүгенге көннәр киләсе бар. Алда—без яшәгән бүгенге заман, без кичергән газап-әрнүләр...

Әгәр бу романны укучылар арасында: «Их, тормышның мондыйрак вакытлары да чагылсын иде, алардан башка чорыбызның сурәте тулы булмаячак...»— диючеләр табылса, авторга нәшрият аша, яисә турыдан-туры мөрәҗәгать итә алалар.

Бер мөһим искәрмә. Әсәрдәге персонажларның кайбер биографик моментлары бүгенге тормышта яшәүче кешеләрне, бигрәк тә үземне хәтерләтсәләр дә, аларның хыялымда тудырылган әдәби образлар икәнлеген онытмасагыз иде.

Соңгы сүзне ник язуым белән кызыксынучыларга шуны да әйтим: алты дистәне түгәрәкләгән кешенең үз максатына ирешергә өлгермәве дә бар бит. Шуңа күрә ниятләгәнемне ачыктан-ачык әйтү кирәк дип санадым. Мин төгәлли алмаганны, бәлкем, башка берәүнең дәвам итәсе килер.

Һаман сузыла. Әйтер сүзләр бик күп та, бу юлга калып торсын инде. Романның икенче, өченче кисәкләрендә очрашып, иркенләп аңлашырга язсын. Амин!

*Мөслим*



## Фәнис Яруллин

### КЕРЕП БАРАМ УРМАНГА МИН

**Өмет сибик алар өчен дә**

**Өметләрне чәчтем аланнарга,
Кар өстенә кара буранда.
Бәлки алар җиләк булып пешәр
Кышкы салкын кара урманда.**

**Ул җиләкне төннең уртасында
Барып җыяр ятим Үги кыз.
Бәхетеннән йөзе балкыр аның,
Күңелендә эрер калын боз.**

**Өметемне сиптем Зөһрә кызның
Зәңгәр чиләкләре эченә.
Чиләкләрдә кинәт су чайпалды
Кереп төнге күкләр төсенә.**

**Шул чагында кинәт көянтәгә
Тулган Ай да кунып өлгерде.
Алып менеп китте Зөһрә кызны
Һәм гүзәл Ай кызы иттерде.**

**Өметемне сиптем юл читенә,
Һичбер гөл дә үсмәс җирләргә.
Мөмкин аны атлар таптарга да,
Юл тузаны мөмкин күмәргә.**

Фәнис ЯРУЛЛИН *(1938) — Татарстанның халык шагыйре (2001), Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, күпсанлы шигырь китаплары авторы. Өч томлык «Сайланма әсәрләр»е дөнья күрде. Проза һәм драматургия жанрында да эшли. Казанда яши.*

Ә кем белә? Чәчәк чыгып куйса,
Юл ташларын ярып, шартлатып.
Шул чәчәккә сөенеп юлчы карар
Аруларын онытып, шаккатып.

Өметемне сиптем кара төнгә,
Балкып янмаса да һәрберсе.
Мәхәббәтен җуйган гашыйк җанга
Йолдыз булыр бәлки берәрсе.

Бар нәрсәсен җуйганда да кеше
Сыңар өмете калсын эчендә.
Күпләргә бит дөнья—үги ана,
Өмет сибик алар өчен дә.

## Сөеп-сөелеп гомер итәргә

Йолдызларда кеше яши диләр,
Мин ышанам моңа, ышанам.
Йә кайсыбыз җир кызларын онытып,
Бер дә йолдыз кызы кочмаган?

Йә кайсыбыз хыял атларында
Йолдызларны урап кайтмаган?
Йә кайсыбыз кояштан ут алып,
Зәңгәр күккә учак якмаган?

Ник атыла дисез йолдызларны,
Күкне ярып, кара төннәрдә—
Төшә алар әверелер өчен
Без соклана торган гөлләргә.

Ә күктә бит бар да йолдыз кызы,
Бөтенесе йолдыз егете.
Ни кызыгы бар соң яр итүнең
Нәкъ менә шул үзең кебекне.

Җир улларын әсир итәр өчен,
Яулар өчен алар йөрәген,
Йолдызлардан кызлар төшеп тора
Ташлап туып-үскән җирләрен.

Сөю өчен ахры Җир кирәктер,
Сөю юктыр ахры күкләрдә.
Адәм белән Хава да бит әнә
Оҗмахлардан җиргә төшерелгән
Сөеп-сөелеп гомер итәргә.

## Табылып тора оя эзләүчеләр

Мин бик озак тордым инде Җирдә,
Яши-яши хәтта арыдым.
Давылларда күптән авар идем,
Тотып тора бары тамырым.

Яфракларны җилләр чүпләп бара,
Кәүсәм көпшәк, кәүсәм куышлы.
Кемнәр оя итәр икән диеп
Көтеп алам язын һәр кошны.

Табылып тора оя эзләүчеләр,
Мамык түшәүчеләр куышка.
Ботагыма кунып сайраса да
Мин рәхмәтле булам ул кошка.

Ә бит җирдә күпме агачлар бар,
Оя кормый торган бер кош та.
Минем кошлар һәркөн хәрәкәттә,
Минем кошлар һәркөн очышта.

Шулар моңы тамырларга сеңә,
Шулар моңы җанны сугара.
Шулар җыры бәйләп куйган мине
Йолдызлардан төшкән нурларга.

Җир белән күк арасында яшим,
Бишек бавым—нурлар чылбыры.
Егылырмын җиргә шунда гына
Тик өзелсә җырлар чылбыры.

## Үлемгә мәдхия

Кирәксезләр, артык җаннар белән
Тулыр иде күптән җиһаннар—
Ярый әле җирдә әз булса да
Мәрхәмәтле изге җаннар бар.

Ә шулай да бездә «артык»лар күп,
Сыйдырмыйбыз барсын—күңел тар.
Кая барыр иде кадерсезләр?—
Ярый әле җирдә үлем бар.

Күпләрнең бит соңгы өмете—Үлем,
Башка өмете инде юк аның.
Учларына салып илтә алар
Әҗәл сандыгына үз җанын.

Тик әҗәлнең генә күңеле киң,
Бөтенесен сыйдыра үзенә.
Учларына үз җаннарын салып
Әҗәленә таба барганнарның
Җилләр туфрак сала эзенә.

## Кереп барам урманга

Көннәр гел кыскарып бара,
Ә төннәр—кара урман.
Ай-йолдызларның һәммәсен
Каплаган кара буран.

Ерак юлга чыкканнарның
Юнәлеше югалган.

Җен-пәриләр кулын сузып
Тора төнге урманнан.

Мине дә кабып йотмакчы
Кара урман авызы.
Ярый әле җырым белән
Алдалыйм бу явызны.

Йотам дип авызын ачуга
Җырым белән тондырам.
Мин диеп җырымны чәйни
Шытырдатып төн-урман.

Озак дәвам итә алмас,
Беләм, бу уен туктар.
Каптырырга җырым беткәч
Төнге карурман йотар.

Әкияти сәмруг кошка
Чукытып йөрәк итен,
Урман, диңгез өсләреннән
Инде күп очып үттем.

Көн кыскара, төн озая,
Тын кысыла җырларга.
Кара төндә тыныч кына
Керееп барам урманга.

* * *

Кайларда гына йөрсәк тә
Яулап дәрәҗә, зур дан.
Халкыбыздан өстен булмыйк
Һәм түбән булмыйк—җырдан.

## Без сөешкән язга охшаган

Үпкән-кочкан көннәр,
Җилгә очкан диләр,
Юк, очмаган әле, очмаган.
Хисләр һаман татлы,
Язлар һаман якты—
Без сөешкән язга охшаган.

Күктә кошлар юлы,
Йөрәкләрдә моңы,
Ул моңнарны онытып буламы?
Кара офыкларга
Зәңгәр болытларга,
Шуннан үтә сөю юллары.

Үпкән-кочкан көннәр
Җилгә очкан диләр,
Юк, очмаган әле, очмаган.
Әгәр очкан булса,
Язмыш кушкан булса,
Кайтартырбыз аны кошлардан.

## Үткәннәрдән мине эзләмәгез

Үткәннәрне сагынып торырга да,
Борылып карарга да вакыт юк.
Алда яңа юллар көтеп тора,
Алда әле эшләр артык күп.

Яңа хисләр, яңа ашкынулар
Туктама дип тора камчылап.
Йөрәгемне кыссам учым белән
Шигырь тама тып-тып тамчылап.

Күз алдыннан ажаганнар үтә
Кыргый атлар кебек чабышып.
Киләчәккә барам шуларның мин
Утлы ялларына ябышып.

Учлар пешә, чәчләргә ут каба,
Ялкыннарга кереп уралам.
Кул ычкынса, читкә оча калсам,
Бер тәгәрәп калсам—торалмам.

Артка кире борылып кайтмаска дип
Юлларымны барам яндырып.
Ярсу атлар оча киләчәккә
Тояк эзе генә калдырып.

Үткәннәрдән мине эзләмәгез,
Теләсәгез әгәр табарга.
Мин булырмын ерак офыкларда,
Мин булырмын туар таңнарда.

* * *

Иртәдән үк иренеп ята идем,
Бик төшенке иде күңелләрем—
Күкрәгемнән очып чыгып китте
Язып куелмаган шигырьләрем.

Тотып калалмадым һичберсен дә,
Ә бит алар бик тә матур иде.
Бер каурый да ташлап китмәделәр,
Үпкәләре, ахры, бик зур иде.

Ак канатлы елгыр кошкайларым
Очып китсә әгәр еракларга—
Язылмаган шигырьләрем булыр,
Ук атмагыз берүк сез аларга.

Бәлки алар миңа кайтыр әле
Рәнҗүләре беткәч җаннарында.
Ә кайтсалар башым иярмен мин
Рәнҗетелгән шигырь алларында.

Язып куймам бәлки мин аларны,
Кәгазь өсләрендә кара уңа.
Йөрәкләрне сагыш баскан чакта
Уйлар яктысы кирәк була.

*2000*

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр



## Кояш Тимбикова

## УРТАК ЯР

хикәя

Көлемсәр йөгерә-йөгерә, сулышына ут кабып килеп житкәндә, автовокзал мәйданында бер генә машина да калмаган иде инде. Кыз, бөгелмәле озын керфекләре аша сөзеп кенә тирә-юньдәге һәммә нәрсәне озаклап барлап чыкты. Карашын жәлеп итәрдәй бернәрсә дә таба алмагач, урам ягын да тикшерергә кирәк дип тапты. Башка чакта анда жинел машиналар, таксилар тезелгән була. Дөрес, андыйлар күбрәк иртәнге якта жыела, алар кичкә кадәр янадан Казанга әйләнеп кайту турында ныграк кайгырталар. Мондый сәгатьләрдә шәхси машиналар көтеп торуга бөтенләй өметләнәсе юк.

Кыз урам якка чыккач теләр-теләмәс кенә атлады. Күнелендәге сәер бер өмет галәмәте кызны барыбер тукталып калырга, якын араны тагын бер кат күздән кичерергә мәжбүр итте. Ул сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куйды: автовокзал почмагында бер шәп машина елкылдап тора, иномарка, ягъни мәсәлән... Мондыйлар, әлбәттә, ерак авылларга йөрмиләр, юлда очраган кешеләрне дә утыртмыйлар. Бу машина хужаларына юлда очраган бичараларның утыз-кырык сум акчасы кирәкми. Мохтаж хәлен мохтаж кеше генә анлый.

Башка чарасы калмаганны белеп кыз, үзе дә сизмәстән, әлеге ят машина ягына бара башлады. Ник мондый жиде чат кисешкән жирдә тукталды икән ул? Ватылып-фәлән калган булса, янында ыгы-зыгы килүчеләр күренер иде. Монда исә бер жан иясе дә юк. Көлемсәр, бу затлы машина тирәсендә кеше таба алмагач, анын кин тәрәзәсе аша эчкә төбәлде. Руль артына утырган егет, икенче урындыкка таба янтаеп, йокыга талган. Шулай да, кыз аны-моны әйткәләгәнче үк, ул торып утырды, теләр-теләмәс кенә сорап та куйды:

---

Кояш ТИМБИКОВА—*язучы, Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Х. Ямашев исемендәге бүләк иясе, «Тәңкале тау», «Ярлар биек», «Табылган хатлар сере» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

—Кемне эзлисез, апасы?

Күнелендәге өмет дигәне тәмам канатланып киткәнне тоеп, Көлемсәр дә кыюланды:

—Алай, мина энекәш булырга алынгач, әйдә, илтеп куй туган авылыма!

Егетнең йокысы качты. Кыска, юан бармаклары белән куе чәчләрен артка сыпырып куйды. Күзләрен кыздан алмады. Бераз уйланып, күнеленнән хәтерен яңарткандай тукталыбрак торды. Аннары сабыр гына:

—Таныдым, бугай,—диде. Син—Чишмәле Ярның Хәкимҗан абый кызы түгелме соң?

Көлемсәр ятьмәгә эләккән күбәләк кебек бер урында сикергәләп куйды. Бу сорауга шатланыргамы, әллә, җавап та биреп тормастан, китеп барыргамы икәнен белми иде әле ул. Теге өмет дигәне генә шашынып-шашынып талпынды, аны-моны уйлап та карамаска, тизрәк, ачылып сөйләшергә, киңәшергә этәрде.

—Каян белдең? Нишләп мин сине танымыйм соң? Кем соң син?..—Кыз бер соравына да җавап алып өлгермәде, ә үзе янадан-яңа сораулар тезеп китте.—Ник монда туктап калдың? Кемне көтәсең?..—Алайса, минем этине дә белгәч, Чишмәле ярны дә хәтерләгәч, бер егетлек эшлә әле: илтеп куй мине авылыма! Әле—яп-якты, кире әйләнеп тә кайтып өлгерәсең...

—Ашыкма! Башта танышып бетик: мин бу машинаның йөртүчесе генә. Хуҗамны көтеп утырам. Шушында очрашырга килешкән идек. Ул хәзер килеп җитәргә тиеш. Инде-е-е, әйләнеп кайтуга килгәндә-ә-ә, безгә кире Казанга кайтуның ике тиенгә дә кирәге юк, без бит монда—йомыш белән генә...

Көлемсәр аны-моны аңлап өлгергән арада, бу елкылдавык машина янына кара «Волга» килеп туктады. Аннан төшеп калган ир-ат туп-туры алар янына юнәлде.

—Әнә ул!—дияргә генә өлгерде шофер.—Калганын үзең кара!

Көлемсәрне аларга таба атлап килүченең үзеннән бигрәк өсте-башы, хәрәкәте, ышанычлы адымнары хәйран итте. Аңардан зәңгәрсу нур бөркелә иде. Өстендәге сыек зәңгәр төстәге джинсы дигән киндер костюмы; аягындагы зәңгәр киндер туфлиләр; елмаю белән тулы күзләре дә зәп-зәңгәр...

Ул, Көлемсәрне бөтенләй күрмәмешкә салышып, рульдәге егет белән сөйләшә башлады. Кыз шактый ук читкә китеп басты.

—Әй, Каракүз! Кил бире!—Бу тавыш әллә каян, мәрхәмәтле күкләрдән ингән кебек иде.—Кузгалабыз!—Бу сүзләрнең кем тарафыннан әйтелүен белә иде инде Көлемсәр

Ул арада, Көлемсәрнең утырганын гына көтеп торгандай, машина кузгалып та китте. Шактый ара сүзсез бардылар.

—Әле узган атнада гына Хәкимҗан агай минем янга кергән иде...—Хуҗаның сүзләре Көлемсәрне тәмам чарасыз калдырды. Гомерендә беренче күргән кешесе аның әтисен шулай үз итеп сөйләсен әле!—Газ кертер өчен чоланын җайлыйсы бар икән...

—Сез кем соң ул кадәр?—Көлемсәр гел шундый инде ул, аны-моны чамалап тормыйча, күнелендәгесен туп-туры ача да сала.

—Ю-у-ук, беркем дә түгел мин. Фирмада кирпеч сугабыз. Шул гына. Хәкимҗан агай кызыл кирпеч сораган иде...

—Ие шул, биш елдан бирле газ кертергә азапланалар, кемнәрнең генә табан астында олтан булмадылар инде!—Көлемсәр күнелендәгесен ачты да бирде.—Шул газ-газ дия-дия өйләреннән чыгып китәргә куркалар. Янәсе, алар юкта гына газ кертүчеләр килерләр дә болар колак кагып калырлар. Бичара авыл кешеләреннән ничек кирәк шулай көләләр инде...

Аннары Көлемсәр сүзләренең бик үк урынлы булмавын чамалады. Кызыл кирпеч бирә алган кешенең газ кертеп азаплаучыларга катнашы булмавы да бик ихтимал лабаса! Кыз тынып калды. Аның шиккә бирелүен сиземләгән Хуҗа сүзне үзе теләгән якка борып җибәрде.

—Аллага шөкер! Хәзер авыллардагы тормыш шәһәр кешесен көнләштерерлек. Безнең әниләр исән-имин чакта шушы шартлар булсамы?! И-и, шөкерана кылып туймаслар иде!..

—Анысы шулай инде, дип, Хужаның сүзен Көлемсәр дә хуплап алып китте.—Бүгенге мөмкинлекләре булса мин дә авылдан китмәс идем. Без укыганда авылда мәктәп тә юк иде. Беренче класска ук, ат жигеп, күрше авылга ташыдылар...

Шуннан китте сүз, китте бәхәс, китте уртаклашу. Бер-ике сәгатьлек юлның узганын сизүче дә булмады. Алай дисәң дә, Көлемсәрнең күңелендәге сакчы аек килеш үз вазифасын үтәгән икән: кирәкле чатка житүгә, кызның сүзе «шып» туктады.

—Минем сукмак якынлаша,—диде ул.—Алдагы борылышта туктатырсыз!

—Нигә?—Хужаның тавышында ризасызлык сизелде.—Без сине Чишмәле Ярның үзенә үк кертеп калдыра алабыз, юл шуннан уза бит!

—Юк, юк, мин, хәтта автобуска утырып кайтканда да карамалыклар янында төшеп калам. Үз сукмагым бар минем. Сезнең машина урап-урап, безнең авыл яныннан үтеп киткәнче, мин, үз сукмагым буйлап, кайтып та житкән булам инде...

Машина туктар-туктамаста, кыз, ишекне ачты да, әчтәгеләргә беләкәй учын болгый-болгый, юл читендәге әрәмәлекләр арасына кереп тә китте.

Көлемсәр бу уңышлы сәфәргә үзе дә гажәпләнеп бетә алмады. Гомер булмаганча, бу атна азагында аларга әллә нинди бер тикшерү комиссиясе килгән иде, шуңа йомгак ясадылар. Аны жомга көнне оештырмасалар да яраган булыр иде дә бит—кем соң аны Көлемсәрдән сорап тора? Шуңа күрә ул сонга калды, шуңа күрә әллә нинди серле кешеләр белән очрашты. Хәерлегә булсын!

Болай көтелмәгән очрашу Көлемсәрнең язмышына мәңгелек эз салды. Кыз, икенче атнада автобуска алдан ук килеп житсә дә, аны инде әүвәлге мәртәбәдә очраткан ялтыравык машина көтеп тора иде. Каршысына да йөртүче генә түгел олуг түрә үзе килеп чыкты:

—Каракүз!—диде ул, әйтерсең лә, монарчы кызга гел шулай эндәшкәннәр,—кемне эзлисең? Мин монда бит! Әйдә, әнә машинаң!

Көлемсәр дә, шул чакыруны гына көтеп торган кебек, кеткелдәп көлеп, аңа тартылды:

—Сез тагын мондамыни?—дигән булды кызый...

—Үзең әйттең бит. Һәр атнада кайтып йөрим, диден...

—Соң?..

—Бер дә соң түгел, нәкъ вакытында...

Әллә сүз уйнаштылар, әллә чыннан да бер-берсенең хәлен белешеп сөйләштеләр—һич аңламассың. Әмма да ләкин алар икенче атнада да шул ук жайлы машинада Чишмәле Ярга табан юл алдылар.

Көлемсәр бу юлы үзен иркенрәк, хәтта хужаларча тота башлады.

—Карале, мин гел сезнең кубызыгызга биеп йөрим, үзем сезнең исемнәрегезне дә белмим. Кем соң сез? Ни дип эндәшергә? Теге атнада әтиемнән сораштырып караган идем—ул да исемнәрегезне белми. Минеке—Көлемсәр...

—Бөтен дөньяга елмаеп көлеп кенә карый торган кызны болай да белерлек инде,—диде Хужа кеше.—Әти-әниең исеменне бик дөрес кушкан. Ярар. Минеке—Хәсәнжан. Әтиеннекенә охшавына исең китмәсен. Шулай кушканнар бит.

—И-и-и, мин дә нәкъ шулайдыр дип уйлап куйган идем аны.

—Ничек? Син дә минем хакта уйландыңмы?..

—«Син дә» дидеңме?..

Аларның күзләре юл күзәтүчегә генә кирәкле көзгедә очрашты. Карашлар очрашты—күңелләр сулкылдап куйды. Көлемсәргә сабырлык дигәне чамалы бирелгән. Ул утырган жиреннән сикереп чыгардай иттереп талпына башлады. Күңеле сизә бит: бу очрашулар—бер дә юкка гына

түгел. Инде тел яшереп азаплануларның да әллә ни кирәге юктыр, Ходаем. Күпме көтәргә, тагын күпме азапланырга кирәк соң?

—Ни әйтсәм—шул инде. Киттек!..

Шоп-шома юл сузылды да сузылды. Шофер көзгесендәге карашлар, бер-беренә әллә ниләр вәгъдәләшкәндәй, серләштеләр дә серләштеләр. Тел тибрәтеп сүз әйтешмәгәндә дә Көлемсәр белән Хәсәнҗан үзара әллә ниләр хакында сөйләштеләр кебек тоелды.

Шофердан яхшысынмадылармы, үзләре үк үз хәлләрен чамалап бетерә алмадылармы—тел тибрәтеп әллә ни зур «мәсьәләләр» хакында сөйләшү булмады. Юлда очраган юк-барны тәфсилләгән булып кына бардылар-бардылар да... тагын Көлемсәрнең төшеп кала торган урынына килеп җиттеләр.

—Йә, бу юлы киреләнмә, авылга чаклы ук бар инде!—диде Хуҗа.

—Юк!—дип кырт кисте Көлемсәр—Дистә ел буе тоткан гадәтемә хыянәт итәр хәлем юк.—Зур-зур рәхмәт яусын, ява-ява башыгызны тишеп бетерсен!—дип, кеткелдәп көлә-көлә тагын төшеп калды Көлемсәр.

Сукмагыннан тәгәрәгәндәй аска ашыкса да, үзе тукталып, сусаганын баса торган ташландык чишмә янына якынлашкач, артына әйләнеп карады ул. Юл өстендәге машина һаман шунда тора иде әле. Көлемсәрнең игътибарын күргәч, алда утырган Хәсәнҗан, машина ишеген ачып, ике кулын болгады. Әй кызык та булды инде Көлемсәргә!..

Ул машина, Көлемсәр куе урманга кереп киткәнче, шунда торды. Ник алай иткәндер?..

Кыз исә үзе салган сукмактан, кәҗә бәтиедәй сикергәли-сикергәли, алга китте. «Куе урман» дигәне аңа гына билгеле бер урында ачыла да китә. Ул ачыклыкта әллә ни биек булмаган бер үр бар. Сырт өстендәге наратлар, гаскәриләр кебек рәт-рәт тезелеп, тоташ дивар хасил иткән. Әмма арадан бер нарат, тамырдашларыннан шактый арага аерылып, үр итәгенә, Көлемсәр сукмагына якынаеп үскән. Бу ялгыз нарат сукмактан килүчегә каршы атлый, аны күтәреп алырга тели кебек.

Шушы турыга житәрәк Көлемсәр дә адымнарын салмаклатты, аннары сукмагыннан чыгып, үзенә таба «атлаучы» наратка карап китте. Бу ара ерак түгел. Алар бик тиз бер-берсенә елыштылар. Кыз карт наратның кытыршы кайрысын сыйпагандай итте. Сыйпап-сыйпап килде дә сәер бер тамгалы урынны учы белән каплап куйды.

—Син һаман елыйсың... Елама! Житте, булды...—Наратның кайрысы чокылып тирән тамгалардан чәер саркый иде. Көлемсәр шул чәер тамчыларына карап сөйләнде.—Күп еладык. Син дә мин дә... Ул боларны белми дә бит. Сине дә бер дә юкка гына чокыган. Ул теләгән тамга да килеп чыкмады. Икебезнең исемнәрнең баш хәрефләрен яза имеш... Башка гашыйклар моны ак каен кәүсәсенә уеп калдыра. Минем хыялый Зәйнуллам, сине сайлады.—Кыз никадәр генә карышса да, күзләрен барыбер яшь пәрдәсе каплады. Көлемсәрнең еларга исәбе юк иде. Еллар буена бәгырен телгәләгән хәсрәт турында пышылдаса да аның бүген елыйсы килми иде инде.—Житте, булды. Бүтән еламыйбыз, наратым, яме!—дип кабатлады.—Әнә бит: ул уйган «К», «З» хәрефләре танырлык та түгел. Синен чәерен күмеп каплап китте. Яраларны еллар чәере каплады. безгә дә туктарга вакыт...

Көлемсәр, нарат белән серләшүен «кырт» туктатып, сукмагына таба атлады. Җанына да рәхәт булып калды. Ничәмә-ничә еллар буена кызның гөнаһсыз күңелен талкып торган хәсрәт шәүләсе артка, калын пәрдә артына китеп бара шикелле. Сабый чактан бер-берсен белеп, үсә төшкәч, гашыйк булып, инде бүген-иртәгә өйләнешәбез, дип, вәгъдәләр бирешкән һәм бу хакта ялгыз нарат янында ант итешкән Зәйнулла белән Көлемсәр кисәктән мәңгелеккә аерылыштылар. Зәйнулла, йөрәк өянәгеннән айның алмыйча, үлде дә китте. Бары да калды: Сөйгән яр да, туган авыл да, мәхәббәткә шаһит булган нарат та. Бу гаделсез кайгыга ачу иткәндәй, Көлемсәр баштан-аяк укуга, аннары эшкә чумды. Ана беркем дә, бернәрсә дә кирәкмәс булды. Шул битарафлыкта утыз яшен тутырды.

Көлемсәр бу аланга инде кечкенәдән килеп йөрде. Әтисе белән икәү киләләр иде. Моның үз сере—тирәнгә киткән сәбәбе бар. Алан Көлемсәрнен әти ягыннан ерак әбисе Мөгълифә исемен йөртә. Элеккеге елларда бу аланны Мөгълифә үз кул көчен түгеп кинәйткән. Кәкре-бөкре агачларны, тамыр-томырларны төпләп, жирне йомшартып, үзләренә әкияти бер хужалык корганнар алар.

Тарихы исә аннан да иртәрәк башланган. Чишмәле Яр авылыннан бик унган бер агай яшәгән икән. Унган-булган, шуна да бик бай булган, хезмәтчеләр дә тоткан, әлбәттә. Жәйләрнен берсендә ул умарталар үрчетеп жибәргән. Бал вакыты житкәч, умарталарын урман аланына күчереп куйган. Шуларга күз-колак булып торсын өчен ин яшь, ин гайрәтле хезмәтче егетен, кечкенә генә бер өй кисәге салып куеп, урманга яшәргә жибәргән. Егет мона бик теләп риза булган. Бераздан анын бу сөенеченен сере ачылган: егет урман аланында бай абзыйнын сылу кызы Мөгълифә белән очраша икән. Алар монарчы ук бер-берсен яратышып йөргәннәр, тик иркенләп очрашырга жае гына табылмый торган. Егет аланга күчкәч, кыз, жаен табып, урманга үзе килеп йөри башлаган. Өйдән китеп йөрүләренен төрледән төрле сәбәпләрен уйлап чыгарган кызый: әле дуслары белән—жиләккә, әле чишмә буена балтырган жыярга, әле...

Тик егет белән кызнын сере озакка бармаган. Ямьсез буяуларга манылып, хәбәр әтисенә дә ирешкән. Бай агай кызын бик ярата торган булган. Шуна да нәселсез-нәсепсез хезмәтче белән чуалуына тиз арада чик куярга теләгән. Тирә-күрше авыллардагы нык хужалыклы кешеләрнен өйләнердәй уллары турында белешергә тотынган. Мөгълифә күнел ачуларыннан, урманга йөрүләреннән тыелып калган. Боеккан, сулган, суырылган. Әти-әнисе тарафыннан һичнинди усал сүзләр, янаулар ишетмәсә дә эшләрнен кай якка таба юнәлеш алуын сизеп торган. Көннәрнен берендә исә, ни бар сабырлыгын, көч-куәтен, акыл-фикерен туплап әтисе белән кинәшергә рөхсәт сораган.

—Һай минем кызым. Һай матурым минем, кил, кил, баламканатым!—дип, ата кеше аны, ике куллап каршы алган.—Кил, утыр яныма, ни йомышын бар—сөйлә, сора: ниләр кирәк, кайларга бармакчы буласынмы, бирнәлек әйберләргә акча биримме? Күпме, ниләр алырлык?..

Кыз, әтисенен, үзенчә, тагын нинди яхшылыклар эшләргә жыенуын санаттырып та бетермәгән, кинәттән тәмам юашланып китеп, анын аяк астына килеп егылган. Үкси-үкси:

—Әтием, бәгырем, бөтен кылган яхшылыкларынны мәнге онытмам, тик бүген мина башка берни дә кирәкми, бер генә теләгемне үтә—матур итеп, туйлап, шул умартачы егеткә кияүгә бир мине! Бу якты дөньяда мина башка һични кирәкми—аны гына яратам, көям, янам анын утында. Ул булмаган һәр жир—салкын, карангы гүр кебек тоела мина...

Хәйран калган ата кеше. Бу хакта тел тибрәтергә дә куркып, кызын үпкәләтмәс өчен, бөтен ярсуын көчкә-көчкә тыеп торган... Ярь-яшь баласынын, тәвәккәлләп, хәл мөшкеллегенен бөтен авырлыгын берүзенен сыек кына жилкәсенә алып, ачыктан-ачык шулай үтенеп үрсәләнүе бай агайны чарасыз калдырган. Өне-теле качкан, ни дияргә дә, нәрсә эшләргә дә белми торган. Ул арада кызы һаман саен тәкрарлый икән:

—Әтием-бәгърем, әтием-канатым, икебез дә аяк астында туфрак булырбыз, башка һичнинди әмереннән дә чыкмабыз, колдай буйсынырбыз—аерма гына, бер-беребезне күрми яшәү газабына гына салма. Безгә, ялгыз-ялгыз жир өстендә яшәүгә караганда, бергә-бергә жир куенына кереп бикләнү жинелрәк...

Әтисе тын алып өлгергәнче, кыз мен дә бер мәртәбә үтенергә өлгерә икән:

—И әтием, и канат кисәгем, монарчы, сина сиздермичә генә, гыйшык утларында янып күпме газаплар кичерүемне белсән-анласан иде! Синен катына килеп бу хакта авыз ачарга кыймый йөрдем—Ходаем шушы анлашу мизгелләрен никтер гел кичектереп торды. Сина әйтми генә янып-көюләрнен никадәр авыр жәза булганлыгын төшендереп бирергә сүзләр таба алмадым. Әтием-канатым, мин син өйрәткәннәргә буйсынудан

туктамадым, сафлыгым-инсафлыгым бозылмады, тик... умартачы егетне күрергә генә урманга барып йөрдем. Ул умарталыкка күчкәч, аны күрми тору әҗәл газабыннан да авыррак булды. Кичерә күр, әтием, аны күрер өчен беренче тапкыр барганда ук синең белән кинәшергә кыюлыгым җитмәде—шуның өчен ялынып-ялварып гафуларыңны сорыймын...

Үз җаныннан да газизрәк күргән баласының бу сүзләре агайны акрын-акрын бер нәтиҗә ясарга мәҗбүр итә. Аның башында мең сорау берьюлы баш калкыта: «Нишләргә? Шушы бердәнбер балакайны михнәт чокырына салып, бай туган-тумача белән аралашып яшәрлек башка бер нәселгә күз ташларгамы? Әллә инде бәгыреңнән өзелеп төшкән бу кадерле йөрәк парәнне тамак ялына көне-төне бил бөгүче шыр ятим затка тоттырып җибәрергәме дә балаңа хыялый бер мәхәббәт дәрьясы бүләк итәргәме? Нишләргә? Гомер буе тырышып бар иткән бөтен малыңны, җәмәгать алдында ялтыратып, авылларны-шәһәрләрне бер итеп, гөрләттереп кода-кодагый уйнашып, бай кардәшләр белән аралашып китәргәме дә... бер сыныкка риза булып яшәгән малайны кияү итәргәме?

Ул егет бик яшьли ятим калган иде. Йорт борынча теләсә нинди эш эшләгән булып, аннары күрше авылларда да йомышчы малай хезмәтен үтәп көн күргән иде. Сүз тыңлаучан, эш яратучан булганга, бай агай аны үзендә яшәп калырга чакырды. Кечерәк чакта Мөгълифә белән гел бергә чуалдылар: бакча эшендә дә, сарыклар кыркыганда да, урак урганда да, аларның чыр-чу килеп эшләп йөрүләрен, шаярышуларын көлеп кенә күзәтәләр иде. Ул дәверләрнең үтеп киткәнен сизми калганнар бит әнә...

Кызына җавап сүз әйтеренә кадәр агай күп хәлләрне хәтереннән кичерә. Аннары, тәвәккәлләп, Мөгълифәгә, кызның үзе кебек үк иттереп ачыктан-ачык аңлатып бирә:

—Ярар, кызым, балам минем, бар шатлыгым, бар кайгым минем! Тор иданнан, башка берәү алдында да болай түбәнсенеп ялварма! Бүген ярый, минем алда ярый әле. Беренчесе вә соңгысы шул булсын! Хуш, ярар, син дигәнчә, нәкъ менә үзең сораганча булыр. Умартачы егет белән никахлашырсыз. Үзем башлап йөрермен, үз ризалыгым белән бирәм, диярмен, шуннан артыгына өметләнмәгез—мәһәреңә... сынар кашык та юк. Үзен үстергән хуҗасының кызын гашыйк иткән егет һәр кирәген үз көче белән тапсын!..

—Мин дә булышырмын аңа, әтием-канатым!—дигән кыз. Атасын ризалатуына шатланудан сабырлыгын да чатнатып җибәргән.—Кашыкны өрәнге тамырыннан уеп ясарбыз, әтием...

Көлемсәр—әнә шушы Мөгълифә карчык оныгының баласы ул.

Көлемсәр гомеренә кадәр сулар шактый күп аккан шул.

Бүген исә—башка хәл. Бүген Көлемсәр үткәннәргә бөтенләй яңача караштa булырга тели. «Җәяүле» нарат белән дә ара ачыкланды, инде «Мөгълифә аланы»на да бүгенгечә, иркен, кин, шау чәчәкле, ял итү өчен рәхәт бер урын итеп карар чак җитте...

Кызның капкадан килеп керешеннән үк өйдәгеләр дә хәлне аңлап алды кебек. Үзгәреш аның бөтен тарафыннан бөркелә иде: кием-салымның да иң затлысын кигән, йөреше дә, очам-очам, дип тора, ә күзләре нур чәчә, балкый, бу дөньяда миннән дә бәхетле кеше юк, дип, өзлексез кабатлый сыман.

Шулай да әтисе дә, әнисе дә бу яңалык турында тел тибрәтергә ашыкмадылар. Күз тиеп куюы, кызның тагын да үз күңеле эченә кереп бикләнүе бар. Бик озак көттеләр бит алар бу көнне. Зәйнулласының вафатыннан соң Көлемсәр инде ничәмә-ничә еллар ачылып китеп сөйләшмәде. Яшьтәшләре белән күрешсә дә үзенә кирәклесен генә әйтә иде дә, минем хәлем турында сорый күрмәсеннәр тагын, дигәндәй, юк йомышын бар итеп, ары уза торган иде. Туган-тумачага кырт кисеп белдереп куйды:

—Җитте, миңа адым саен акыл сатмагыз! «Үлгән арты үлеп булмый»—дигән сүзегезне бүтән ишетмим!—диде. Шуңа күрә кыз белән сөйләшенгән сүзләр тирәнгә керә алмый, су өстендә йөзеп йөргән май бөртекләре

кебек өстә генә, әйләнеп-тулгаланып торалар иде. Бу юлы исә кыз, бөтен җанын урап алган ялкынлы хисләренә чыдаша алмыйча, сүзне үзе үк кисәк башлап җибәрде:

—Йә инде, шул кадәр дә кыюсыз булмагыз, сорагыз, нинди утларда янасын?—дип сорагыз!—диде.—Хәер, сорамасагыз да сөйлим...

Көлемсәр күнелендәгесен тезде дә тезде. «Җәяүле нарат»ны, «Мөгълифә аланы», алар белән яңа мөнәсәбәткә кичүен дә сөйләде. Үзен гыйшык утына салган затның кайдалыгын һәм исемен генә әйтеп бетермәде.

Кыз әйтеп бетермәде, әти белән әни кеше исә, күптән көткән бу сөенеч турында әллә ниләр беләселәре килсә дә, артык кызыксынып баланы унайсыз хәлгә куймас өчен, телләрен аркылы тешләп, сабыр итүне хуп күрделәр. Акрын-акрын үзе барын да әйтеп бетерер: кемлеген дә кайдалыгын да, кайда ничек дуслашуларын да, бу дуслыкның ахырлары нинди булачагын да...

Ял көннәре тиз узды. Кыз, ничек шаулап-гөрләп кайтып кергән булса, шулай ук ашкынып китеп тә барды. Өйдәгеләр аның сөенечле юлга ашыгуын хуплап кына тордылар. Бу юлы Көлемсәрнең әнисе күчтәнәчләрнең ин затлыларын тутырган, күп итеп куйган. Тиздән кияү булачак кешегә дә авыз иттерсен, дигәндер инде.

Көлемсәр гомерендәге иң озын атна, мөгаен, шушы арадагысы булгандыр. Көндезләрен эш сәгатьләренең үтүен көтеп алуы кыен булса, төннәрен йокыга китмичә интекте ул. Төннәрнең шулкадәр озын икәнлеген монарчы башына да китерми иде бит Көлемсәр. Хәер, монысына үзенчә бер чара да тапты кыз: киләсе җомгада, Хәсәнҗан белән очрашкач, ана нiләр әйтәчәген ныклы бер тәртипкә салып куярга ниятләде. Мәктәптә инша язган кебек...

Күп кенә сорауларны күнеленнән уздырды: очрашкач та сәламны ничек бирергә? Машина кузгалып киткәч, сүзне ничек башларга? Юлда нiләр хакында сөйләшергә? Төшеп китәр чак житкәч, егетне дә үзенә ияртерлек нинди сәбәп табарга?.. Шуңа охшаш мәсьәләләрне чишәргә алынгач, йокы килмәү кайгысы артка чикте. Киресенчә, иң кирәкле җавапларны таба алмый интеккәндә, үзе дә сизмәстән, йөзендә елмаю балкытып, йоклап китүчән булды Көлемсәр. Уяна да, төп сорауларының күбесе әле һаман җавапсыз икәнлекне чамалап, тагын хафалана башлый иде.

Ничек итсә итте—җомга көн уянуга Көлемсәр һәр хәрәкәтен атна буе төзегән планы буенча башлап җибәрде. Юлга киячәк күлмәк тә, туфли дә әллә кайчан билгеләнгән. Кулга әллә ни зур сумка алмаячак, башка атналардагы кебек ипи-күмәчләр дә күтәреп йөрмәячәк: бер кило әфлисун, бер кило банан, бер кап печенье, бер шешә су—житте шул.

Эшнең соңгы сәгатьләре житә башлагач, Көлемсәрне курку алды. «Әгәр ул бу юлы килә алмаса?»—дигән шик аны әледән-әле сискәндереп уза иде. Икенчедән, очрашсалар, алдан ниятләгән гамәлләрен башкарып чыга алырмы соң ул? Бу сорау кызны барыннан да ныграк вәсвәсәләндерә, чөнки нәкъ шул мәсьәлә аның бөтен язмышын хәл итәргә мөмкин...

Машина рәхмәт төшкере, кызны нәкъ әүвәлге төштә көтеп тора иде. Хәсәнҗан, Көлемсәрнең чалымы күренүгә, кабинадан чыгып арттагы ишекне ачып куйды, кызга каршы атлады.

—Котылдынмы, Каракүз? Эштән ычкынуыңны әйтәм. Нихәлләр, исән-иминме? Күлмәгең бигрәк матур инде!

—Нишләп күлмәгем генә әле?—Кыз рәхәтләнеп көлде. Ана бик рәхәт иде.—Туфлием ямьсезме? Ә үзем, үзе-ем ямьсезме?!

—Минем барын да санап чыгарга кыюлыгым житмәде. Барысы да бик матур, бик килешле!

—Ник шулай икәнен беләсеңме соң? Мин бит сезгә, сезнең менә бу затлы «кәчтүнегезгә», ялт-йолт килеп торган «заграничный» машинагызга лаек буласым килә! Көне-төне шуна дип тырышам бит мин!

Көлемсәр тагын көлде һәм җайлап кына арткы урынга кереп утырды.

—Тегендәрәк күчсән, мин дә синең янына гына утырыр идем,—диде Хәсәнҗан.

—Анысы нинди яңалык инде тагын?—Кыз шулай сораган булды, үзе исә хәлнең мондый юнәлешкә борылып китүеннән бик канәгать иде.

Рәттән утыргач, Көлемсәр егетнең әрсезрәк кылануын тели иде кебек. Күнеленнән аның хәрәкәтләренә каршы торырга да әзерләнгәндәй булды. Кулларын инбашыма салса, юри генә, «ялт» иттереп алып куярмын, дип тә уйлаган иде. Әмма егет актан-карадан сүз дә эндәшми барды. Машина выжлата да выжлата, инде юлның яртысына житәләр бугай. Кызның сабырлыгы да, чакрым саен төкәнә, кими тора иде.

—Әллә, Ходаем, суккан кирпечләрегезне алучылар беттеме—ник шул кадәр боегып калдыгыз? Икегезнең берегездән бер авыз сүз чыкмый—әти әйтмешли, балтасы суга төшкән урыс кебек барасыз...

Хәсәнжан алга гына карап барган жиреннән кызга таба борыла төште.

—Юк, юк, Каракүз, завод эшли, Аллага шөкер, дияргә кирәктер. Алучылар житәрлек. Безнең завод зур түгел бит ул.

—Ә-ә-ә, менә кайда икән ул һәрьяктан түгәрәк дөнья-а-а!—Көлемсәр тагын көлде.—Безнең директорга ирештерергә иде сездәге бу шөкераналыкны! Гомер туймас кебек кылана: әле бер яңалык уйлап чыгара, әле—икенчесен, аннары кичә генә керткән яңалыгын ботарлап ташлый...

—Бар ул андыйлар. Шулай эзләнмәсә, сезнең комбинат бер-ике ел эчендә генә алай киңәеп тә китә алмас иде әле...

—Бәрәкәт! Минем ул комбинатта эшләгәнне кайдан белден?—Бу яңалык Көлемсәрне тәмам чарасыз калдырды.—Әйткәнем юк бит әле!?

—Белдем инде!—диде дә егет бик тирән сулап, уфтанып куйды.—Барын да белдем...

Ул арада машина Көлемсәргә кирәкле борылышка якынлаша иде.

—Бу юлы авылга чаклы бар инде!—диде егет. Аның тавышындагы ялварулы үтенеч аерымачык яңгырады.—Йә инде, карышма!

Хәсәнжанның мондый соравын алдан ук көтеп утырган Көлемсәр, атна буе ятлаган сүзләрен хәтереннән чыгарып, гади генә иттереп әйтте:

—Карышудан түгел, үземнең дә бер теләгем булганга күрә, мина нәкъ шунда төшәргә кирәк.—Әйдә, икәү төшик! Мин сина үзем генә белгән чишмәнең суын эчерермен. Машинаң авылга үтсен, син аны куып тотасың...

Егетнең үзенә каршы сүз әйтүен Көлемсәр һич тә күтәрә алмас иде, шуна күрә ул чигенмәслек чара күрде: юл буенча кымшанмый да кайткан Хәсәнжанның көрәктәй зур кулына үзенең кеп-кечкенә учын куйды:

—Әйдә инде!..

Ул арада егет белән кыз яшел чирәм каплаган сөзәк калкулык өстеннән аска, Көлемсәр генә белгән чишмә ягына төшә башладылар. Көчле кул кызның нәни бармакларын иплән кенә үз карамагына алган. Абына күрмә, егылып китмә, дигәндәй, бу нык кул кызның һәр хәрәкәтенә юнәлеш бирә кебек.

—Менә ул минем газиз чишмәм!—дип кычкырып жибәрде Көлемсәр.—Күр син аны!

Берничә карт карама үсеп утырган аулак кына бер аралык иде бу. Карамаларның чабуы астында тагын ниндидер вак куаклар үсеп утыра. Шуларга ияреп үк камышлар да үрчегән. Нәкъ менә шул берничә төп камыш төбеннән чүмеч кадәр генә уентык хасил булган да чишмә тибеп чыккан. Чишмәнең суы кызлар толымы кадәр генә тарлыкта агым да хасил иткән.

Көлемсәр, ашыгып барып, шул шарлавыкта кулын юды, юеш учы белән битен дә сыйпап куйды. Аннары, учларын бер-беренә аркылы тотып, чишмәнең үзәгеннән су алып эчте. Сусаганын баскач, егеткә карады:

—Эч син дә! Курыкма! Бу—минем чишмә. Һич зыяны юк. Адәмнәргә зыян салмасын өчен мин аңа кулъяулык биреп куйдым, әнә!..

Бер камышның койрык жибәрергә әзерләнгән туры кәүсәсендә, чыннан да, кечкенә генә чүпрәк кисәге тибрәлә иде.

—Эч инде!

—Кызык икән син! Башта: «Эчертермен», диден, хәзер шул кадәрле

жаваплы эшне мин берүзем башкарырга тиеш булып чыктым, ә?

И-и-и, кин дөнья! Сина рәхмәт яусын! Көлемсәргә бит нәкъ менә шул ишарә, шул ым гына кирәк иде! Егетнең мондый урыннарда үзен-үзе ничегрәк тотышын чамалау да кирәк иде ана. Бөтенләй үк тун күчән түгелме? Табигать хозурлыгын сиземләве бармы? Көлемсәр илаһилаштырган нәрсәләрне һич анламаслык «бүкән» түгелме? Кызга әнә шуларны ачыкларга кирәк иде. Шөкер, егет шәп, ул барын да Көлемсәр теләгәнчә үк, тирәннән анлый.

Кыз, сөенеп, чишмәнең үзәгеннән сап-салкын су җыйды:

—Эч! Шифасы тисен!

Хәсәнҗан, суның соңгы тамчысына кадәр эчеп бетерде дә, кызның ике кулын үзенең ике кулына алды. Үзе нык, көчле, үзе йомшак та назлы да учлар иде алар.

—Рәхмәт, яме!

—Йә,—диде Көлемсәр.—Ярар, әйдә, киттек!

Киттеләр. Бераз үткәч, Көлемсәр анлата башлады.

—Әнә, күрәсеңме, мине җәяүле нарат каршылый. Гел шулай мине каршылап, озатып калып гомер уздыра ул... Менә монысы—»Мөгълифә аланлыгы». Мондагы бөтен чәчәкләр—минеке!—Кызның моңарчы шактый каушап сөйләнгән сүзләренә, ниһаять, табигый оялчанлык өстәлде.—Юк, диде ул.—Хәзер инде минеке генә түгел, безнеке булсын!..

Аланның уртасына җитәрәк, кыз адымнарын акрынайтты, егет учындагы кулын да иплэп кенә тартып алды, Хәсәнҗанга карады:

—Әйдә, аз гына ял итик, ә?! Бер-ике минут кына утырып торыйк!

—Мондый җирдә утырып булмый,—диде егет. Сукмактан аз гына эчкәре үтте дә сузылды да ятты.—Ят син дә!

Алар, бер-берсеннән шактый ара калдырып, һичнинди болыт әсәре булмаган аяз күккә карап, чәчәкләр хуш-исенә исереп, шактый вакыт сүзсез яттылар. Көлемсәрнең сабырлыгы сынмаса, әле тагын күпме яткан булырлар иде икән?! Кызның күңеле ашкынды шул, чыдамлыгы ахыр чигенә килеп терәлде, сикереп торып утырды:

—Беләсеңме?! Беләсеңме, мин сина хәзер нәрсә әйтәм?

—Юк, анысын ук әйтә алмыйм. Бик күп нәрсәләрне белсәм дә...

—Шул кадәр нәрсәләр беләсең?

—Синең турыда бөтенесен беләм: Хәкимҗан абый ягъни, Мөгълифә карчыкның оныгының кызы, Зәйнулланың яратканы, «Китаплар» фирмасының экономисты, Казанда ике бүлмәле фатиры бар, кияүгә чыкмаган, үлгән егетенә тугрылык саклый ...

—Түгел, юк, юк!—дип кычкырып җибәрүен Көлемсәр сизми дә калды.—Бетте! Сине күргәннән бирле бары да үзгәрде. Зәйнулла хәтирәләренә—нокта! Беләсеңме—мин сиңа кияүгә чыгам!

Кыз күңелендәге иң зур серен кычкырып әйтеп салды да тып-тын калды. Аның, чыннан да, башка сүзе юк иде инде. Ярый әле, әйтеп өлгерде, уйлана калса, тәвәккәлли алмас иде.

Бөтен тирә-юнь тып-тын булып калды. Чәчәкләр арасында сызгыргалап йөргән чикерткәләр дә, куак башларындагы кошлар да, якындагы инешнең челтерәве дә туктадылар кебек иде. Көлемсәр хәтта куркуга төште. Бу—ни бу? Нигә егет шатлыгыннан сикереп тормый? Үзе булдыра алмаган кыюлыкны кыз кеше тәвәккәлләгән икән—нигә ул моңа үз мөнәсәбәтен белдерми тора? Егет, кинәттән, һич сүз катмыйча, күккә карап торган җиреннән авышып, йөзтүбән капланды да, адәм баласының күңеле генә сыйдыра алмаслык аһ-зар белән:

—Уфф Аллам!—дип куйды.

Көлемсәр инрәп китте.

—Һай Аллам, ник шул кадәр уфтанасың, мин, синең урынында булсам, каршымдагы кызлар: «Мин сиңа кияүгә чыгам!»—дип торсалар, шатланыр идем?!.

—Көлемсәр, мин синнән шактый олы бит?..

—Булсын!

—Көлемсәр, син—кала кызы инде, минем бөтен тамырым—авылда?..

—Булсын!

—Көлемсәр, мин—өйләнгән кеше бит...

Юырттырып баручы атның башына суктылар диярсен—кыз: «һык», дип тә куйды хәтта. Тик аның чигенер урыны юк иде инде. Тагын:

—Булсын!—дип кабатлады.

Бу хәлиткеч сүз дә яңгырагач, егет берара тын алды.

—Син үзеңнең ниләр сөйләгәнеңне чамалап барасыңмы соң, әллә мине үчекләргә генә азаплануыңмы?—Ул шушы башлавыннан барын да әйтеп бетерергә ниятләде кебек, чын-чынлап кызды, каударланды, битәрләнде.—Кем инде, иректе баштан, өйләнгән кеше белән әкешмәкеш килеп йөрсен? Синең кебек, бөтен яктан килгән кызлар...

—Минем бер ягым да килмәгән.

—Килгән. Син ягымлы. Син булган. Син тугрылыклы. Син...

—Җитте. Мин—бәхетсез бер җан. Тик мин бу сүземне, беренче башлап, сиңа гына әйтүем. Миңа...—Кыз, үзен-үзе белештермичә, сулкылдап куйды.—Миңа син кирәк!

Икесе дә, кабаттан, дөпелдәп, чәчәкле җиргә капландылар.

Бу юлы егет өлгерлек күрсәтте, якын килеп, Көлемсәрнең җыйнак җилкәсенә кагылды:

—Әйдә, торыйк! Акыллы булыйк әле!—Безне көтәләр бит.

Көлемсәр дә торып басты.

—Мин барыбер сиңа кияүгә чыгам!

—Бернәрсәдән дә курыкмасаң, чыгарсың. Уйлашырбыз. Минем хатын чирле бит. Сау-сәламәт булса, ике дә уйламас идем. Чирле хатынны рәнҗетергә батырлыгым җитми...

—Булсын!—дип кабатлады, Көлемсәр.

—Шулай ук нык торасың икән, безгә бүтәннәрнекенә охшамаган, яңа төрле тормыш корырга туры киләчәк бит?!

—Корырбыз. Мин риза.

—Менә рәхмәт!..—Зәңгәр нурлы егет, көчле күкрәген җәеп, непнечкә гәүдәле Көлемсәрне кочагына алды.—Рәхмәт сиңа, миңа нәкъ синең кебек кеше кирәк иде. Бик авыр миңа. Өйләнүемә унбиш ел узды, гаилә рәхәте дә, бала елавы да, хатын назы да күрә алганым юк. Туебыздан соң ук авырган иде... Күз тидерделәрме—белмим. Үзем теләп өйләнгән хатын бит инде... Чирләде дә китте. Йөртмәгән шифаханәләр калмады. Булмаса да булмас икән, Ходаем. Юк бит, юк, юк! Ни алга юк, ни—артка. Сине күргәч, саташам дип торам, икенче яшьлегем кайткан кебек булды—юк шул, бернәрсә дә икенче кат кайтмый. Бел, Каракүз, мин чирле кешене җәберли алмыйм. Ул да сау-сәламәт булса, ике дә уйламас идем, кайтыр идем дә әйтер идем: «Мин җир йөзендәге бердәнбер тинемне очраттым, кичер, аңа китәм»,—дияр идем дә, чын-чынлап, китеп тә барыр идем.

Көлемсәр, Хәсәнҗан авызыннан чыккан һәр аваз саен, куырылабөрешә барды. Әмма егетнең бер генә сүзе дә кыз күңелендәге әүвәл кабынган дәрт-омтылышны сүндерерлек түгел иде. Хәсәнҗаннын бөтен аңлатмаларын ишетеп бетергәч тә ул үзендә:

—Булсын,—диярлек көч тапты.—Мин сиңа кияүгә чыгам,—диде.—Язмышларыбыз шундыйдыр, күрәсең...

—Ничек син шулай тиз генә хәл итәсең? Мин сине күргәннән бирле баш ватам: бөтен дөньямны ут алды, күз алдымда синең гәүдәң тора, колагымда гел синең тавыш, синең сүзләр, жаным-тәнем сиңа тартыла. Күреп кайтуымның икенче көнендә үк синең турыда барлык мәгълүматларны белешеп чыктым, тик... Ә син минем хакта сорашыпбелешмәдеңмени?!

—Сораштым. Үз-үземнән сораштым. Күңелемнән сораштым. Җавап бер генә төрле булды: нинди генә каршылыклар очраса да, сиңа кияүгә чыгарга! Миңа башка чара юк кебек тоелды. Инде менә-ә-ә... Ай Аллам!

Көлемсәр, Хәсәнҗанның нык, киң күкрәгенә сеңеп бетәргә теләгәндәй, тагын да катырак сыенды. Күзләре, егетнең җилкәсе аша, еракка, биек наратлар белән читләтеп куелган офыкка төбәлде. Шактый

вакыт шул билгесезлек тынлыгында басып торгач, ниһаять, кыз тагын:

—Ай Аллам!—дип кабатлады. Аннары, егет кочагыннан чыгып, үзалдына сөйләнгәндәй генә иттереп, баядан бирле күнелен кытыклап торган шигъри юлларны тезеп китте:

... Яратмавынны да йотар язмыш,
Тик син бер сорауга җавап табыш—
Нишләтерләр газиз башкаемны
Яна хәсрәт белән сары сагыш?

—Юк. Монда ярату-яратмау турында сүз булмаска тиеш!—диде Хәсәнжан.

—Минем бөтен курыкканым бары шул гына иде. Өйләнүләрен хакында башыма да кереп чыкмады. Әгәр яратмасан, ничекләр итеп чыдармын дип куркып яшәдем...

—Тукта. Башка бу хакта сөйләшми торыйк! Әйдә, безне көтәләр. Уйлашыйк әле. Киттек. Бүтән автовокзалга килеп йөрмә. Кайтасы көнне мин сине үзем эзләп табармын. Яме?!.

* * *

Якшәмбе көн, вакыт төштән авышып килгәндә, Чишмәле Ярнын үзәк урамына машина килеп керде. Ул Хәкимжан-укытучылар капкасы төбендә тукталды. Шоферның ишеге ачылып китте дә аннан зәңгәр киндер костюмлы егет килеп чыкты. Капкага юнәлде. Ишегалдында аны Хәкимжан-укытучы үзе каршы алды. Кеше-фәлән каршыларга чыгуы түгел иде анын. Юк эшен бар итеп мыштырдап маташуы иде шунда. Капка төбендә машина тукталганны чамалагач, кирәсе кешене көтеп торды.

—Исәнмесез, Хәкимжан ага!

—Ә-ә, сез икәнсез, Соруретдинов иптәш, исәнмесез!—Чал чәчле укытучы карашларын аска төбәде.—Карт башларымны кара кайгыларга салдыгыз, кызым барын да сөйләде бит миңа...

—Яхшы булган,—диде егет. Хәзергә ул турыда сөйләшмик әле. Машина көтә. Казанга барыш. Көлемсәргә дә юл уңае бит...

Ул арада болдыр баскычына Көлемсәр дә чыгып басты. Ана, кызынын күләгәсенә сенеп бетәргә тырышкандай, әнисе дә ияргән иде.

Кыз, гүя әтисе белән әнисен күрми дә:

—Исәнмесез Хәсәнжан әфәнде!—дип сәлам бирде ул.

Анын бу сүзләреннән һични аңларлык түгел иде: шаяртырга тырышамы ул, мыскыл итәме, аллә мина барыбер,—дип, лаф орамы—һич белмәссен?! Шулай да кызның сүзләренә әтисе үзенчә җавап кайтарды:

—Матур сүз ул—«әфәнде!» Безгә тимәде инде, әфәнделәр булып яши алмадык.

—И-и, алайса, менә үзем әйтим әле!—дип, бу сүзне Хәсәнжан күтәреп алды.—Хәкимжан әфәнде, мин сезнең кызны алып китәргә генә кергән идем калганын башка вакытта хәл итәрбез, яме?!

Ата белән ана ни диярга дә белми калдылар. Кыз аларның әле берсенә, әле икенчесенә тартылды:

—Әткәем, әнкәем, мине, кайткан саен шулай каршы алып торуыгыз өчен, рәхмәт яусын! Исән-сау торыгыз! Тагын кайтырмын!—диде дә, хәтта Хәсәнжанның кабат чакыруын да көтеп тормастан, капкадан чыгып китте.

Шулай да кыз машинага кереп утырырга ук базмады. Хәсәнжаннын чыгып, кабина ишекләрен ачып куюын көтте кыз. Әмма монда да ул көткәнчә генә булмады. Егет машинаның алгы ишеген түгел, ә арткысын ачып куйды.

—Әйдә, Көлемсәр! Утыр!

Анын тавышы ук үзгә иде. «Көлемсәр» дип, исем белән эндәшүе дә—беренче тапкыр. Моңарчы гел «Каракүз» дия иде бит ул. Әлеге көтелмәгән хәлләрдән тәмам аптырап калган Көлемсәр, аны-моны исәпләп тормастан, машина эченә чумды. Шунда гына арткы утыргычта тагын

бер хатын-кыз барын чамалап алды ул. Тик актан-карадан сүз әйтмәде, йомылды да калды. Белер хәл юк бит, бу кеше янында нәрсәне әйтергә ярый, ни хакта тел тибрәтергә дә ярамый?..

Машина, шактый ярсып, искән җилне дә узарга тырышып, авылдан чыгып китәргә ашыкты. Чыктылар. Басуны уратып олы юлга да төштеләр. Моңарчы һич ни эндәшми килгәннәрнең тынлыгын бозып Хәсәнҗан:

—Көлемсәр,—диде.—Танышыгыз, бу—минем хатыным Гөлсем була...—Машина выжлавы да, тыштагы җил дулавы да кинәт тынып калгандай булды. Гүя, болар гына түгел, бөтен дөньяның яшәү агымы тукталган кебек иде. Көлемсәрнең тамырларында кан йөреше дә катып калды кебек.

—Туктат, зинһар, машинаңны! Мин автобусны көтәрмен...

Хәсәнҗан кыз теләгән урында машинаны шып туктатты. Бераз гына сабыр итеп торганнан соң ул хәтта Көлемсәр ягындагы ишекне дә ачты. Теләгән кешегә—ихтыяры. Әмма кыз төшеп китәргә өлгермәде, кара кәшемир шәлгә төренеп утырган хатын сүз башлады.

—Ашыкмагыз әле! Яп әле, Хәсән, ишегеңне! Әкрен генә алып бар, сөйләшик!

Гөлсемнең тавышы Көлемсәр моңарчы ишеткән кешеләрнең берсенекенә дә охшамаган иде. Үзе боеручан да, үзе ялваручан да кебек. Мондый тавышны тыңламыйча, бу үтенечне башкармыйча калу мөмкин дә түгел кебек. Көлемсәр тышка атылып чыгудан тыелып калды, ишеген ябып куюларына да сүз әйтмәде. Машина акрын гына алга юыртты. Инде мондагыларның барысына да мәгълүм: алдагы сүзне Гөлсем дәвам иттерәчәк. Һәм ул озак көттермәде дә.

—Акыллым,—диде ул, Көлемсәрнең җен ачуларын чыгарып.—Ашыкма, мин әлегә сине ничек атарга да белмим. «Сеңелем» димме, «Кызым» димме?.. Син ничек теләсәң, шулай булыр...—Ул тагын тынып калды. Көлемсәргә исә аның шундый чигенеш ясавы шактый унай тәэсир итте. Ул да басыла төште.—Хәсән миңа барын да сөйләде. Хәер, ул сөйләмәсә дә, өч атна элек үк мин аның хәлен аңлаган идем инде. Авыр бит аңа. Шул авырлыкта еллар буе тере мәет хәлендә яши ул... Гел эш тә эш. Ярый әле шул эше бар. Эшен бик яхшы эшли анысы. Бөтенесе яраталар үзен. Шуңа таянып кына яши дә инде. Мин бит аңа—муенына бәйләнгән таш кебек.

—Кирәкми!—диде Хәсәнҗан.

—И-и, Хәсән, алай димә, мин дә әйтмәсәм, кем аңлатыр бу балага синең хәлне?!

Көлемсәрне сәер сорау биләп алды: «Ник инде аңа «Хәсән» дип кенә дәшә икән бу апа? Мин булсам, «Хәсәнҗаным!» дияр идем???»

Гөлсем исә үзе теләгәннәрне тезә бирде.

—Хәсән абыен—бик игелекле кеше. Без бергә укыдык. Институтта. Диплом алган елны өйләнешеп, Хәсәннең туган авылына кайттык. Аз гына яшәп калдык, мин авыруга сабыштым. Хәсән абыең мине ташлый алмый, минем аны-моны кылырлык чамам юк. Әстерхан ягында бер энем бар, алып китәргә дә ымсынып карады. Хәсән белә, аларның үз хәлләре—хәл, ире-хатыны егылып эчәләр, җиде балалары, анда мина—ни сан? Үзем, теләсәм-теләмәсәм дә китәр идем инде—Хәсәннең күнеле ризалаша белмәде. Мин аңа гел әйтеп киләм, бар, дим, тап бер кызны, үрчет гаиләңне, җәлләмә мине, дим. Бер җае чыгар әле, урамда калмам. Инвалидлар йорты да бар бит. Мәктәптә эшләрлек хәлем булмаса да, мин бит—педагог кеше, инвалидлар йортында да берәр файда китерер идем, бәлки... Юк, Хәсән мине чыгарып җибәрергә теләмәде... Докторлардан ярдәм тимәсен аңлагач, бик бетерешкән идем. Хәсәннең нинди юлга басасын да белмәдем. И-и бәргәләндем дә инде. Хәсән соңгарак калып кайткан көннәрдә җанымны кая куярга аптырап, аны күрүгә, зур тавыш чыгара идем. Хәсән шунда да күңелне рәнҗетерлек бер сүз ычкындырмады—ничек түзгәндер. Аның ныклыгы миңа да сабырлык индерде. И Өммегөлсем, мондый ирнең соңга калып кайтуына гына түгел, көне-төне эчеп-исереп йөрсә дә, янына ук көтүе белән

азгын хатыннар алып кайтып, кәеф-сафа корса да, син: «Әлхәмдүлилләһ, биргәненә шөкер!»—дип кенә торырга тиешсең бит. Кемең бар? Мондый затны тагын кайлардан табарсың, дим.

Ходайның мина шәфкать күрсәтергә яраткан бер бәндәсе ул—Хәсән. Авыр сүз әйтү түгел, караңгы йөзен дә күрсәтмәде. Иртән, ике бит алмамнан үбеп чыгып китә, елмаеп кайтып керә. Кулында—кучтәнәч ризыклар, кочагында өй кирәк-яраклары, мина дигән яңа кием-салым була. Алланың рәхмәте яусын!

Көлемсәр, бу хатынның, үз башына төшкән коточкыч язмышы турында, шундый сабырлык белән сөйләвенә хәйран калды. Нәрсәдер әйтергә, аларның хәлен жиңеләйтергә кирәк иде кебек, тик—мондый чакта нишләргә кирәген Көлемсәр белми иде шул. Моны, мөгаен, берәү дә белмидер. Гөлсем исә үзенчә бер нәтижә ясаган булып чыкты.

—Безне башкача тәрбияләделәр. Хәзер менә бераз кешечә уйлауга күчәбез шикелле. Мин дә өйрәнә башладым. Тарихыбызны, нәселләребезне, әхлак кагыйдәләребезне... Алар барысы да ислам дине белән бәйләнгән булган. Безгә динне өйрәтмәделәр. Тирәннән анласаң, шул кадәр кирәкле нәрсә булган бит. Шул ук Хәсән абыенның язмышын гына ал: Мөхәммәт галәйһиссәләм хәдисләренә карасаң, ул—мөэмин-мөселман өммәтен күбәйтергә, ишәйтергә тиешле зат, минем кебек авыру, бала таба алмаган хатынны, ике дә уйламыйча, аерып жибәрергә, икенче хатын алырга тиеш. Мөхәммәтнең үзенең дә башта балалары булмаган. Хатыннары—әллә ничәү. Мин Хәсәнгә мең мәртәбә әйттем инде... Кыюлыгы житмәде. Хәзер, сине очраткач, Көлемсәр акыллым, ул да каршы түгел. Син генә каршы тормасаң иде!

—Нәрсәгә?—дип сорап куйды Көлемсәр.

—Ана кияүгә чыгарга.

—Ә... Сез... сез кая китәсез?

Хатын-кызларның нечкә, еламсырак тавышларын Хәсәнжанның боерыктай көчле яңгыраган сүзләре басып китте:

—Ул беркая да китми! Мин аны беркемгә дә бирмим! Гөлсем—минем хатын.—Аннары аның тавышы сүрелә төште.—Син дә, Көлемсәр, минем хатыным бул!

Иренең сүзләре түгәрәкләнергә дә өлгермәде, Гөлсем ялгап алып китте:

—Мөселманнарга кагыйдә буларак та рөхсәт ителә ул. Берсен-берсенә каршы куярга гына ярамый. Мин мең риза. Өйләнешегез, балаларыгызны карашырмын... Үзара ачыктан-ачык: ризалашып яшәсәк, кемгә, ни зыян салабыз без?.. Мин сезгә һич комачауламам. Кайчан тели, шунда синең янында булсын. Бер сүз дә әйтмәм.

Алдагы юлга туп-туры карап барган килеш кенә Хәсәнжан да өстәп куйды:

—Мин сезнең икегезне тиң күрермен, берегезне дә кимсетмәм, ни ярамаган эш кылсам, әйтә торган булырсыз.

—И-и-и,—дип сузды Гөлсем. Мин гомердә дә сезгә үз таләпләремне куймам. Рәхәт яшәгез. Мин, болай да инде, Хәсән, сиңа күп хафалар салдым, Алланың рәхмәте яусын, һич зарым юк. Урам чатында калдырмавына рәхмәт. Үз тормышыңны да бер жайга салырга кирәк бит инде. Синең әллә нигә бер генә хәлемне белүенә дә мең риза булачакмын. Мең риза!

Һич көтмәгәндә Көлемсәр дә:

—Мин дә!—дип куйды.—Ризамын. Барына да ризамын...

* * *

Олы юлдагы шушы киңәшү-сөйләшүдән соң дөньяда башкаларныкына һич охшамаган яңа бер гаилә барлыкка килде. Гөлсем тәмам тынычланды: ул бит еллар буе нәкъ менә шул рәвешле корылган бер тату гаилә турында хыялланган иде. Көнелләр киң булса, ата-баба күрмәгән шушындый тормышка да ирешү мөмкин икән ләбаса!

Көлемсәр үзенең бу язмышына ышанырга да ышанмаска да белми йөрде. Хәсәнҗанга булган тойгылары үзгәрмәде аның. Киресенчә, кыз аны янача ярата иде: табигый тартылышы—бер хәл, бу егеттәге бетмәс-төкәнмәс шәфкать, җирдәге барлык кешеләрне бәхетле итәргә тырышкандай, гел яхшылыкка гына омтылуы Көлемсәрне соклandырганнан-сокландыра барды.

Хәсәнҗан исә берсе—мәгъриптә, берсе мәшрикъта дөрләүче ике учакка утны гел тигез бүләргә тырышты. Атна көннәре авылдагы өй белән Казандагы Көлемсәр арасында уртагыннан аралашты. Табылган мал да ике өйгә тигез төшә иде. Көлемсәр авыл өенә кайткач, гөрләшеп табынга җыелалар, бергәләшеп хуҗалык эшен түгәрәкләп куялар, төн уртасына кадәр көлешә-көлешә телевизор карап утыралар да өчесе өч җирдә көйләнгән түшәкләргә ятып йоклыйлар. Бары да риза, бары да канәгать, хәтта шат иделәр. Хәсәнҗаннын исемен дә урталай бүлделәр: Гөлсем, гадәтенчә, аңа: «Хәсән! Хәсәнкәем!» дип эндәшә. Көлемсәр исә, Гөлсем-туганының өлешенә керергә теләмәгәндәй: «Җан, Җа-ан, Җанкаем, җанашым!»—дияргә өйрәнде...

* * *

«Мөгълифә аланы» чәчәкләренең яңа буыны бөре бөрттергәндә, Хәсәнҗан, Гөлсем вә Көлемсәр гаиләсендә тумрап торган малай дөньяга килде. Бу өчәүнең шатлыгын башка һичкем аңларлык түгел иде. Гөлсем авыру икәнлеген, еллар буе сыкранып, алдагы көненнән куркып—шикләнеп ятуын оныткандай булды. Аш арты саен эчә торган даруларын да сирәгәйтте. «Кабармын да башым әйләнеп китәр, баланы кулымнан төшереп җибәрермен, Алла сакласын» ди торган иде. Көлемсәр атна саен туктала торган «Мөгълифә» сукмагын тукталмыйча үтеп китә башлады: «Сукмак саен тукталсам, әле кайчан гына кайтып житәм, әти-әни янына да сугыласым бар бит, район үзәгендә Хәсәнҗаным көтә. Гөлсем-туганым да бала белән алҗып беткәндер...»

Алар, өчәүләшеп, Камил исемле малай үстерделәр. Кайбер айларда Гөлсем, Казанга килеп, Көлемсәр фатирында яшәде. Балага ничек җайлы булса, шулай килештеләр. Җылы, тыныч айларда Көлемсәр авылга кайтып йөрде. Малайны кулдан да төшермәделәр. Чишмәле Ярны да читкә кагучы булмады. Хәтта Көлемсәрнең әти-әнисе вафат булгач та Хәсәнҗанның машинасы бу авылда туктала, авылдашларның хәл-әхвәлен белешеп китә иде. Авыл халкы: «Булса да булыр икән игелекле җан!»—дип, аңа хәерле юл теләп кала торган иде.

Башкалардан шактый аермалы шушы тормышка тәмам ияләнеп життеләр алар. Көлемсәр чираттагы җомга көненең эшен түгәрәкләп, ашыгып, урамга чыкты. Аны Хәсәнҗан машинасы көтәргә тиеш иде. Бу ни хәл соң, юк бит?

—Апа, сезме ул Гөлсем апа туганы?—диде берәү.

—Ә? Әйе. Син кем?..

—Әйдә, утыр әле, аннары әйтермен...

—Нәрсә булды? Ник?..

Көлемсәр, сорауларына актан-карадан җавап таба алмыйча, яшь кенә егет өндәгән якка китеп, билгесез бер машина эченә кереп утырды. Кузгалдылар.

—Апа, миңа ачуланма,—диде егет. Аның иреннәре дерелди иде.—Хәсәнҗан абый кайнар кирпеч өеме астында калды...

* * *

Бер булмаса, булмый икән. Камил-бала мәктәпкә китәсе елны дөньяда өч яңа ятим артты: Камил, Көлемсәр, Гөлсем. Алар, үзара тату-дус яшәргә ниятләп, Казанга, Көлемсәр фатирына күчеп киттеләр.



## Бикә Рәхимова

### АЛТЫН-КЫЗЫЛ ЯШЕН ЯШЬНИ КҮКТӘ

**Кертегез!**

**Рухым белән, сүзем белән**
**Керәсе бар Казанга...**
**(Татар башкаласы! дисәк,**
**Без көткәннәр аз анда...)**

**Рухым белән мин Казанга**
**Керим кайсы капкадан?**
**Кайсы капка миңа ачык,**
**Кайсы капка япмаган?**

**Сүзем белән мин Казанга**
**Керим кайсы капкадан?**
**Әйткән сүзем җилгә очмас,**
**Читләр-ятлар какмаган...**

**Үзем булып мин Казанга**
**Керим кайсы капкадан?**
**Кайсы—маңгайга кундырмый,—**
**Мине читкә атмаган?**

**Мин бит саташып та хәтта**
**Чит капканы какмаган!**
**Мин үз капкамны шакыйм ич,**
**Аһ, кертегез капкадан!**

---

Бикә РӘХИМОВА—*шагыйрә, «Сәрвиназ», «Ачыл, күңел», «Иделләр казанында» һ. б. китаплар авторы. Проза, публицистика, тәрҗемә өлкәсендә дә эшли. Казанда яши.*

Рухым, сүзем, үзем бергә—
Бербөтенгә укмашыйм,
Тибәрү белән хушлашыйм—
Кереп түргә урнашыйм.

Мин керим—мең елдан узган
Мөселманлык таҗымны
Шаһадәтле өскә куеп,—
Горур тотып башымны!

## Төркиядә җир тетрәү уңаеннан төрек дустыма

*1999, август*

Гүзәл, гүзәл, мәңге гүзәл, диеп,
Мактап язган идем илеңне,
Шомлы хәбәр килгәч, тетрәндем дә
Тешләдем мин ике ирнемне.

Зилзиләләп чыга дәһшәт җирдән,
Дүнәрләрдәй[1] киләә, әйләнеп,
Чабып барган җәйран сөрлеккән күк,
Сибелгән күк кәләш сәйләне.

Тау-ташларны урыныннан алып
Күчерердәй көчләр чыккач, йә,
Җир өстендә торган өйләр ни соң?—
Бу көч өчен җиңел йомычка.

Гүзәл, гүзәл, диеп, күп сокланса ң,
Күз тидереп була гүзәлгә...
Шатлыкларны куып, кинәт килгән
Кайгыларга ничек түзәргә?

Ләкин илдә хөкемдарлар түгел,
Хаким булса туган—үз телең,
Яраларың ялап төзәтәсең,
Дәвам итә көнең һәм төнең.

Төрек халкы, сезнең яраларны
Күңел җепләрем дә бәйләшә—
Кыйтта аша сезгә йөрәк дәшә:
«Янәдән тор, дустым, сөй, яшә!»

## Питрәчтә очрашу

Көйле-моңлы, җирле-сулы төбәк,
Булдың беркөн минем җыр башым.
Җыелышкан идек танышырга,
Йөрәгемне ачтым—җырлаштым.

Тел бәйләде безне, татар теле,—
И туган тел, изге, шәфкатьле...
Ышандыра безне тик ул гына
Таң җиңәр дип кичке шәфәкъне.

[1]Ит кыздыру өчен әйләнеп торган жайланма.

Ераклардан бергә бәйләп безне—
Татарларның барлык кавемен,
Урталыкта килгән туган телем—
Гүя туйда кода савыме[1].

Күңелләрнең салкынлыгы эреп,
Җыр җылына, хистән кабына,—
Гүя кемдер кинәт ут элдерде
Туп-тулы бер шырпы кабына.

Изгеләргә карагандай хөрмәт,
Нинди изгелекләр кылган мин?
Сезнең белән бер сулыштан сулап,
Күңелгә моң алдым, җырга—җим.

## Без ят түгел

Урманымда йөрим. Чыршы, нарат—
Яшь кияү һәм яшь-яшь кәләшме?..
Калды инде, калды яшь вакытлар,
Гомеркәйләр—әй, үпкәләшмик...

Чытырманнар монда ергылыксыз,
Кайда тагын күрәм боларны?..
Уемда да яшен болыты түгел,
Яшеннәрдән азат ак кары...

Чытырманлык, ешлыкларны йөртәм
Күңелемнең тирән җирендә...
Бер булса да, күңел, ачылып кит—
Бикләреңне алдыр, иренмә.

Бу ешлыклар саклый, яклый ала,
Кемнәр түгел, аю килсә дә...
Урман-хисем рәнҗетүчеләр бар,—
Үтмәс пычкы белән кисәләр...

Әллә урман елый, әллә үзем,
Әллә син ул, туган як кынам...
Күпме сагынсам да, саргайсам да,
Китсәм—ерак, кайтсам—ят сыман.

Кайтсам тагын, туган ягым, сиңа,
Давылланып, күңел айкыйсың...
Сагынычлы сәлам юллап торам:
Безгә үз син, ятлар ятсынсын.

## Яшен ташы—Сөю...

Мәхәббәтнең юлы күктән үтә,—
Кыр казлары белән янәшә.
Ишетәсеңме, каңгыраган моңлы
Бер ялгызак булып ул дәшә...

---

[1]Савым—туйга кодаларның бүләк ашы.

Күктә генә яшен ташы йөри,
Яшен ташы—сөю-сөелү...
Шуңа да син күкне өстен күрдең,
Ят ул сиңа җиргә иелү.

Иелмәдең, җилләр каршы, диеп,
Җилләрдән дә өскә мендең син.
Ни дәрәҗә давыл йөрткәнеңне
Үзең генә, бәлки, белдең син—

Давылыңның эсселеген тойдым...
Боз тавыдай салкын икәнен...
«Йә утка сал, йә суга сал» көе
Аңлатамы минем үткәнем?..

Алтын-кызыл яшен яшьни күктә—
Йөрәклердән алган укмыни?
... Канап торган яраларың белән
Җиргә төшүләр ул юк инде...

## Табып булырмы?..

Җилләр генә хәбәр китерделәр,
Җилләр генә исте ул чакта...
Мин күкләргә карап хәбәр көттем,
Утлар сүнгән чакта учакта.

Утлар сүнгән, бер җылы юк җанда,
Сулар гына ага үтәли,
Салкын сулар күңел салкынайта,
Йөрәк кага, йөрәк үпкәле...

Чәнчеп сүзләр очты, ылыс кебек,
Очып-очып, җиргә кундылар.
Әле ярый юмарт кара җир бар:
Ылыстан хуш исле җырым бар!

Ул—уңышым минем, җыяр өчен
Ни тырмам юк, ни бер сәнәгем.
Җир анадай туендыручы җыр
Җилгә очмас диеп санадым.

... Күккә карап хәбәреңне көтәм
Кош җаннары купкан чагында.
Кайтып киләсең күк—киләсеңдер:
Зәңгәрлектә йөзең чагыла...

Тик һаман да җилләр генә исә,
Җилләр генә коя яфракны.
Саф сөюдән тагы да сафракны
Табып булырмы соң—агракны?

## Күңлем юлы

Бара-кайта йөри күңлем юлы,
Белгән юлны ничек ташлармын?
Гүя көзен китеп, язын кайткан
Хәтер саклап очкан кошлар мин.

Җисмем йөри—синең янда түгел,
Үзем генә сине яклаучы:
Күңлем соңгы өметеңне саклый,
Гүя корал, дуска атмаучы.

Күңлем кошы, читлегеңне ачтым,
Югары оч, талпын, үс инде...
Катлы-катлы таслап сала торгач,
Сер сандыгым түзмәс ич инде?!

# ИХЛАС ҖАНЛЫ АВЫЛДАШЫМ

## ЯЗУЧЫ ГАБДЕЛХӘЙ САБИТОВНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

*Габделхәй Сабитов—авылдашым гына түгел, әби-бабаларыбыз ягыннан чыбык очы туган—абый да иде әле. Ул 1931 елның 28 июнендә Татарстанның Минзәлә районы Югары Тәкермән авылында туган.*

*Безнең балачак танышлыгыбыз бик аз булды: мин сугыш елларында Усай авылында, әниемнең бертуган апасында яшәдем. Ә сугыш тәмамланып, Югары Тәкермәнгә кайткан вакытымда Габделхәй Күзкәй урта мәктәбе укучысы иде инде. Димәк, без бары тик җәйге каникулларда гына күрешә ала идек.*

*Җирән бөдрә чәчле, ап-ак тәнле, битләре-муеннары да җирән сипкелләр белән чуарланган Габделхәйне мин бер күрүдә ук үз иттем. Аның ихласлыгы, башын артка ташлап шаркылдап көлүләре, ничектер, бик табигый-мөлаем булгангамы, юмартлыгы-гаделлеге ташып торгангамы—без малайларны ул үзенә магнит кебек тарта иде.*

*Габделхәй Сабитов урта мәктәпне тәмамлауга ук, унсигез яшеннән төрле авыл мәктәпләрендә укыта башлады. Бу инде аның авылдан чыгып китүе дигән сүз, һаман да шул җәйге айларда гына күренгәләп ала иде.*



*Ык буенда сәяхәттә. Жырчы-композитор Мәсгут Имашев, язучы Г. Сабитов, шагыйрь М. Шабаев. 1967 ел.*

*Габделхәйнең беренче шигырьләре Минзәлә район газеты «Ленин байрагы» битләрендә басылды. Берара ул шул газетта эшләп тә алды. Аның әдәби сәләте иртә ачылгандыр, ул М. Горький исемендәге Мәскәү әдәбият институтына укырга да бик җиңел барып керде. Монысы 1956 елда булды. Аның «Мәхәббәт һәм нәфрәт» комедиясе (1954) төрле үзешчән сәхнәләрдә уйнала, Габделхәй үзе дә артистлык сәләтенә ия һәм еш кына уйный да иде. Институтка иҗади конкурска Габделхәй шул комедиясен җибәргән иде.*

*Без Габделхәй Сабитов белән Казанда бары тик 1960 елдан гына яңаданныклап*

*аралаша башладык. Ул, сәламәтлеге какшау сәбәпле, Мәскәүдә укуын ташлап, Казанга кайтып төшкән иде. Элек-электән табигатькә гашыйклыгы, һәвәскәр балыкчы булып, елга-күл буйларында тәүлекләр буе йөрүе безне тагын да якынайтты. Без «өч мушкетер»—композитор Мирсәет Яруллин, Габделхәй Сабитов һәм мин—һәр атна ял көне бергәләп балыкка йөри башладык. Менә шунда мин авылдашымның йөрәк авыруы барлыгын аңладым да инде. Ябык, озын гәүдәле Габделхәй үзен-үзе шаярткандай итеп кенә «чатан йөрәк» дип йөртә иде.*

*Габделхәй Сабитов Казанда төрле газет-журнал редакцияләрендә бер ун еллап эшләп алды. Аннары 1970 елдан әдәби иҗат белән генә яши башлады. Ялгышмасам, аңа авыруы буенча пенсия дә билгеләгән иделәр. Габделхәй үзенә күп сорамады, барына канәгать булып яши бирде. Аның иҗаты да бик артык мулдан була алмады. Күрәсең, һаман да шул авыруы галәмәтедер...*

*Әмма Габделхәй Сабитов аз язса да, өздереп яза иде, аның әсәрләре чын мәгънәсендә югары кимәлдәге сәнгать әсәрләре булды. Бигрәк тә аның хикәяләре («Туган җир туфрагы», «Өч күңел», «Агач аяклы кеше», «Корбан ашы», «Сәйлүн чәе», «Урман кызы», «Үлемсез Акылгали» һ. б.) «җылы-мамыклы» халыкчан тел белән языла, һәрвакыт табигый вә кызыклы сюжетларга корылган, эчке кичерешләргә бай була иде.*

*Үзенең 1963 елда басылып чыккан «Туган җир туфрагы» исемле беренче хикәяләр җыентыгын ул миңа болай дип язып бүләк иткән иде: «Марс дус, агай-эне! Тәкермән туфрагын хур итмисе иде бит. Шулай дип хәер-фатихада тор! Ихтирам белән—автор. 28/III.64. Г. Сабитов».*



*Ык буенда балыкчы Г. Сабитов. 1967 ел.*
*Н. Нуретдинов фотолары.*

*Әйе, Габделхәй Сабитов туган җир туфрагын хур итмәде. Хикәяләреннән тыш, ул матур-матур сәхнә әсәрләре дә язды, алар театрларда уйналды, конкурсларда бүләкләр алды. Аннары әле Г. Сабитов бик оста тәрҗемәче дә иде. Ул атаклы Эрих Распеның «Барон фон Мюнхаузен маҗаралары»н, П. Трэверсның «Мэри Попинс», Ф. Залтенның «Урман әкияте» повестьларын татар теленә тәрҗемәләп укучыларга бүләк итте. Сүз уңаеннан, Габделхәй үзе дә кай ягы беләндер барон фон Мюнхаузенга охшаган һәм, туры килсә, ул аны сәхнәдә яки кинода оста гына итеп уйнап та бирә алган булыр иде.*

*Әйткәнемчә, Г. Сабитовның иҗаты әлләни зур булмады. Ул нибары җиде-сигез китап авторы иде. 1976 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы булды.*

*Бала җанлы авылдашым Габделхәй Сабитов турында тулырак истәлек язарга кирәк иде. Әмма әлегә шушы кереш сүз белән генә чикләнергә туры килә.*

*Габделхәй Сабитов фани дөньядан иртәрәк китеп барды: ул 1995 елның 29 октябрендә вафат булды. Без аны туган җире туфрагына—Минзәләгә алып кайтып җирләдек...*

*Ләкин язучының әсәрләре исән, алар һаман да укыла. Мин мәктәп китапханәләрендә аның укый- укый таушалып беткән китаплары белән очрашам. Г. Сабитовның бар язганнарын туплап, бер матур том итеп чыгарылган көннәрен дә күрермен дип өмет итәм.*

**Марс ШАБАЕВ**

## Габделхәй Сабитов

# ТУГАН ҖИР ТУФРАГЫ

хикәя

Әгәр Галәү бабайдан: «Дөньяда иң тәмле ашамлык нәрсә?»—дип сорасагыз, ул озын аксыл кашлары астыннан хәйләкәр генә карап куяр да:

—Көлгә күмеп пешергән бәрәңге,—дип җавап бирер.

Бер Галәү бабай гына түгел, учак көлендә күмерләнеп пешкән бәрәңгене ат сакларга килгән малайлар да бик яраталар. Гатуф кенә борынын җыерган була. Әнисе биреп җибәргән майлы күмәч, эремчек кебек тәм-томнарын чыгара да, иптәшләреннән читкәрәк китеп, авызын чапылдата-чапылдата чәйнәргә керешә. Ләкин, бәрәңге пешеп җиткәч, ул да калышмый. Галәү бабай, чабып ташлаган покостан бер кочак печән алып килеп, учак янына сузыла. Ә Галәү бабай бик шаян кеше ул, бәрәңгене ничек әләкте шулай алырга рөхсәт итми. Иң элек малайларны санап чыга, аннары, кеше санына карап, бәрәңгене өемнәргә аера башлый. Җаен китереп, бер өемгә бәрәңгеләрнең күмерләнеп беткәннәрен генә сала. Бүлү эше тәгәлләнгәч, аякларын бөкләп, җайлабрак утыра да Сәлимгә дәшә:

—Йә, Сәлимгәрәй энем, йом күзеңне... Кипкең белән капла, гаделлек булсын... Бу күч кемгә?

—Сиңа.

—Бусы кемгә?

—Әнвәргә.

—Ә бусысы кемгә?

Хәйләне алдан ук белеп торган Сәлим: «Гатуфкә!»—дип кычкыра. Шулай итеп, Гатуфкә гел начар бәрәңгеләр генә эләгә.

Галәү бабай бүген дә, гадәтенчә шаяртырга уйлап, бәрәңге бүләргә утырган гына иде, болын ягыннан аяк тавышлары ишетеп, эшеннән бүленде.

—Кем утыра, дисәм, үземнең авылдашлар икән. Исәнме, Галәү бабай!

Малайлар, сискәнеп, тавыш килгән якка борылдылар. Алардан ике-өч адым гына читтә зур гәүдәле бер солдат басып тора иде. Учак яктысында егетнең хром итекләре һәм җиз төймәләре ялтырап китте.

Галәү бабай, күзләрен кыса төшеп, бераз карап торды да, сөйләнә-сөйләнә, урыныннан кузгалды, кулларын егеткә сузды:

—Һи, Хәсәнҗан энем, син түгелме соң? Ничек әле болай кәтмәгәндә?

—Менә авылга кайтып киләм. Пристаньда Ширмә машинасы очрады. Илтеп үк куям, дигән иде дә, борылмада төшеп калдым. Җәяү генә кайтырга булдым. Төне бик дымык.

—Шулай шул, ие... Әйбәт иткәнсең. Нишләп аягүрә торабыз?! Әйдә, утыр әле. Мактап йөрисең икән! Кайнар бәрәңге ашап китәрсең. Каягыз, чыпчыклар, урын бирегез солдат абыегызга!

Галәү бабай бүлгән бәрәңгеләрне бер өемгә кушты. Шакмаклы кызыл ашъяулык өстенә ипи кисеп куйды. Хәсән кыстатып тормады, аркасындагы юл капчыгын салып, гөләп куагы төбенә куйды да Галәү бабай янына килеп утырды. Малайлар да уртак табын тирәсенә җыелдылар.

—Кичә әниең карчыкны күргән идем, кайтасыңны әйтмәде,—диде Галәү бабай Хәсәнгә.—Отпускагадыр инде.

—Отпускага түгел, бөтенләйгә җибәрделәр.

—Бик тиз булды түгелме соң? Шулай өч ел узып та киттемени әле?

—Ике ел да тулмады. Указ бар, Галәү бабай. Армияне киметәләр. Мин генә түгел, күп егетләр кайта.

—Ә, алай икән. Шундыйрак сүз ишеткән идем шул. Бик әйбәт иткәннәр. Ие... Әйдә, аша әле. Көйгәнен ташла, менә бусы бик әйбәт булып пешкән...

Алар шактый озак утырдылар. Хәсән армиядә күргәннәре турында сөйләде. Галәү бабай Хәсәнне авыл хәлләре белән таныштырды.

—Үзең ниндирәк ният белән кайтасың?—дип сорады ул.—Элгәргечә, тракторчы булыргамы исәп, башка эшкәме, дигәндәй?

Хәсән бу сорауга ни өчендер теләр-теләмәс кенә җавап бирде.

—Белгән юк әле, Галәү бабай,—диде ул.—Бер уйласам, читкә үк чыгып китәрмен. Авылда әллә ни майтарып булмас. Әнә, шәһәрдә урнашкан егетләрнең эшләре шәп, икешәр мең төшерәләр.

—Һи... Алай дисең икән...

Галәү бабай тынып калды. Малайлар да ашауларыннан туктадылар. Алар Галәү бабайның гадәтен яхшы беләләр. Ул сакалын учладымы, авызыңны ачасы булма, үзегеңә үтәрлек бер сүз белән томалап куяр. Җае чыккан саен мактанырга ярата торган Гатуф кенә түзмәде:

—Минем абый да шәһәрдә калды. Ул безгә акча җибәреп тора,—дип масайды ул.—Үскәч, мин дә китәм. Авылга яңадан кайтмыйм...

Галәү бабай, Гатуфкә мыскыллы карап усал итеп әйтеп куйды:

—Беткән ди читтә синең кебек һава бозучылар.

Учак тирәсендә пешәләнә-пешәләнә кайнар бәрәңге ашап утыручы малайлар пырхылдап көлеп җибәрделәр.

Галәү бабай учактан утлы кисәү алып тәмәке кабызды.

—Кайтырсың... Кайтмый хәлең юк,—диде ул йомшаграк тавыш белән.—Кеше генә түгел, хайван да туган җирен оныта алмый. Моннан күп еллар элек булган бер хәл бүгенгедәй хәтеремдә. Тыңлагыз, чыпчыклар, гыйбрәтле хәл. Китәргә ашыкмасаң, син дә тыңла, Хәсәнҗан энем...

Малайлар Галәү бабайга елышып утырдылар. Бабай, утырган урыныннан гына кузгалмыйча борылып, коры утын өеменнән берничә чыбык-чабык алды, сындыргалап, учакка ташлады, аннары юеш печән өстенә җәйгән бишмәтенә терсәге белән таянды да, гадәтенчә, әкрен генә сөйли башлады:

—Безнең әти гомере буе нужадан чыга алмады. Түбән очта, хәзер авыл Советы булган урында, Сираҗи исемле бик комсыз бер бай яши иде. Шуның атларын карады, ә үзе гомере буе ат күрмәде, мәрхүм, туфрагы җиңел булсын... Тик менә кайсы елны икәне төгәл хәтеремдә юк, иске мәчетнең түбәсе җимерелгән елда булса кирәк, ашлыклар бик уңган иде. Ташлы тау буендагы иманабызда арыш урак тыккысыз булды. Әтинең шатлыгы эченә сыймады. Ашлыкны сугып алу белән, ашарга да юньләп калдырмыйча, шәһәргә илтеп сатты да түгәрәк кенә бер бия алып кайтты... Ярлының авызы ашка тисә, борыны каный, дип дөрес әйткән булганнар икән: ике ел да тулмады, яңадан атсыз калдык. Казна бурычлары өчен алып чыгып киттеләр. Колыны бик кызганыч булды. Шешәдән сөт имезеп үстердем. Иртән торып чыгуымны баскыч төбендә көтеп ала торган иде бичара хайван... Тора-бара миңа шулкадәр ияләшеп китте—иптәшләрем белән җиләккә барсам да, Якты Күлгә кармак салырга төшсәм дә, артымнан калмый иде. Нишләтмәк кирәк аны...

Галәү бабай кеткелдәп көлеп куйды. Аннары, кулындагы таягы белән кисәүләрне өя-өя, сүзен дәвам итте:

—Тәки карап үстердем шул колынны. Өч елдан көр генә тай булып җитте. Карап торуга Сираҗи атларыннан бер дә калышмый иде. Ай-һай матур иде дә инде. Менә, Сәлимгәрәй энем, син тәрбияли торган кара айгырга тартымрак иде. Маңгаенда яңа туган айга охшаган кашкасы да бар иде. Шуңа карап, исемен дә Айдаш дип куштык.

Галәү бабай, утка карап, бераз уйланып утырды.

—Бер килгән кешегә килә бит ул, каһәр,—дип куйды ул бераздан.—Тәки игелеген күреп булмады бит. Берничә авылда сабан туенда чабышып, яулыклар алып калдым. Шул булды бөтен кинәнү.

Сәлим түземсезләнеп сорап куйды:

—Айдашны да алып чыктылармыни, бабай?

—Юк, тайны алып чыкмадылар чыгуын,—диде Галәү бабай.—Сатарга

туры килде аны. Инде атлы булдык, дип кенә торганда, күршеләрдән ут чыгып, йорт-җиребез янды. Казыгыбыз да калмады. Дүрт бала белән урамда калгач, нишләсен инде әти, тайны бер Себер кешесенә сатып җибәрде. Барышникның арба артына бәйләп куйгач, Айдашымны муеныннан кочып, үкси-үкси елаганым хәтеремдә. Хайван сизми, дип уйламагыз сез, сизә ул. Башын җилкәмә салып, бик озак торды. Китәр алдыннан, үпкән кебек итеп, йомшак иреннәре белән маңгаемны кытыклап алды. Ә кузгалып киткәч, урам яңгыратып, кешнәп җибәрде... Әти мәрхүм дә йомшап калды, эшләпәсен күзенә үк басып киде, аннан соң, ак сакалын сыйпаштырган булып, зимләнкәбезгә кереп китте. Мин атлар артыннан йөгердем. Басу капкасын чыккач, куе арыш арасына кереп яттым да арыганчы еладым...

Байтактан бирле кызып яткан коры агачлар кинәт кабынып киттеләр. Төн караңгылыгы берничә адым арткарак чигенде. Учак яктысы Хәсәннең уйчан йөзен, малайларның йомарга оныткан иреннәрен, Галәү бабайның җыерчыклы күз төпләрен яктыртты.

Узган яшьлегенең истәлекләре Галәү бабайның күңелендә авыр тойгылар уяттылар. Ул тирән сулап куйды, болын ягыннан ишетелгән тартар тавышларына, утлап йөргән колхоз атларының пошкыруларына колак салып торды:

—Ярты еллап вакыт узгач, Себер кешесеннән хат килде. Атның югалуы турында язган. «Бүре-фәләнгә юлыккандыр инде»,—дип куйды әти.

Шуннан соң ел ярым вакыт узгач, барыбызны да хәйран калдырган бер хәл булды. Әнә тегендә, Шәйми сыртында әти белән печән чаба идек. Бик эсселәгәч, коенып чыгыйм, дип яр буена төшсәм, ни күзем белән күрим: Идел аръягыннан бирге якка таба бер ат йөзеп килә. Әтине чакырдым... Ат ярга килеп чыккач, исебез китте. Әти бот чабып куйды. «Менә син агай, ә! Һәй, бичара хайван, бичара хайван!»—ди. Күрәм, үзенең күзләре яшьләнеп китте. Гаҗәпләнмәслек тә түгел шул. Ел ярым буе туган ягын эзләп йөргән бит, мескенем. Могҗиза... Сөяк белән тирегә генә калган. Маңгаендагы айга охшаган кашкасыннан гына таныдык. Шулкадәр бетеп җиткән, хайванкай, яр өстенә аяклары белән күтәрелә алмады, тезләрендә шуып менде. Менеп җиткәч, иң элек җирне иснәде, аннары берничә бөртек үлән кабып алды, тик чәйнәмәде, сарут төпләре авызыннан күренгән килеш калдылар. Бик нык гаҗәпләнгән кебек, Якты Күл ярындагы озын камышларга, еракта күренгән авыл өянкеләренә карап торды. Аннан соң, хәлсезләнгән аякларын көч-хәл белән генә сөйрәп, авыл юлыннан китеп барды.

Без кайтканда, Айдашыбыз янган сараебыз урынында басып тора иде. Капкадан кергәнемне күргәч, башын күтәреп, кешнәп куйды. Тик элекке кешнәү түгел иде инде бу. Әллә нинди хырылдавыклы, авыр ыңгырашуга охшаган авазлар гына чыкты. Янына килдем. Таныды хайванкай! Элеккечә башын җилкәмә салып бик озак торды. Өйгә кереп, икмәк кисәкләре алып чыктым, ашамады. Алдына солы салдым, иснәп тә карамады.

Икенче көнне иртән торып чыкканда, үлгән иде инде... Башын күмер белән аралашкан туфрак өеме өстенә салган, авызыннан ямь-яшел сарут бөртекләре күренеп тора. Туган җирендә үскән шул бер учма үләнне эзләп кайткан, диярсең...

Галәү бабай озак кына сүзсез торганнан соң, тирән сулап, барлык сөйләгәннәренә йомгак ясаган кебек итеп, әйтеп куйды:

—Кадерле ул туган як, кешегә генә түгел, хайванга да изге ул туган җир туфрагы...

Бераздан соң, Галәү бабай, малайлар белән бергәләп, Идел ярындагы карама төбенә йокларга ятты. Иртән ат белән кайтырга булып, Хәсән дә алар янында куна калды.

Болын җиле тәмле печән исе алып килде, караманың яфраклары ашыга-ашыга нәрсәдер турында пышылдаштылар. Ялкау гына тулы ай күтәрелде. Ул, ботакларны аралап, йоклыйлармы икән, дигән кебек, кешеләргә күз төшереп алды. Ләкин Хәсән йокламый иде. Ул йолдызлар атылганын карап ята. Ә колак төбендә һаман да бер үк сүзләр яңгырый:

—Кадерле ул, изге ул туган җир туфрагы...

*Хикәяне журналда бастыруга* **Мәгъсум ХУҖИН** *әзерләде*



## Сөләйман

### ҖИДЕ КҮККӘ КҮТӘРЕЛ ДӘ...

* * *

…Бу дөньяга ялгыш «кердем» гүя:
Ялгыш кереп, ерак үтелгән.
Кире кайтам, күңел җанга дәшә—
Җитеп барган сыман күпергә.—
Кылдан нечкә таныш күпергә…

Бу дөньяны якын күрдем ялгыш,
Ялгышканмын отып рәвешен,
Соң, аңлыйм ди, аңладым ди шуны,
Ни кылыйм соң, мин дә бит кеше?
Ялгышканмын отып рәвешен…

Ник бу сорау минем башка килә,
Нинди ачыш көтә бу юлда?
Безнең тормыш, имеш, уен гына…
Уен микән әле, и Хода?
Сер ачылыр сыман бу юлда…

Ничек баксаң, дөнья шулай икән,
Ничек күрсәң—дөнья шул икән.
Безнең күңел үзе үрмәкүчтәй,
Бер тибрәнү—үзе бер килбәт.
Ничек күрсәң—дөнья шул икән…

---

Җәүдәт СӨЛӘЙМАН *(1955 ) —шагыйрь, «Ямаулыклар», «Ташъязма», «Мин—минсез дөньядан» һ.б. китаплар авторы. Ул— фәннәр докторы, кибернетика белгече. Казанда яши.*

...Безнең күңел үзе үрмәкүчтәй,
Бер тибрәнү—үзе бер килбәт.
Күңел үргән дөнья-пәрәвездә
Чәбәләнгән киек мин, димәк...
Бер тибрәнү—үзе бер килбәт...

...Безнең дөнья—күңел талпынуы,
Пәрәвезнең бары бер төре.
Әкияттәге рәшә сыннар сыман,
Ә соң вакыйгада—кем тере?—
Пәрәвезнең бары бер төре...

...Май атлауга охшаш безнең дөнья:
Бәндәләрдән җан атлангандай...
Өлгергән җан аңлап китсен диеп
Ашыктырмый микән, и Ходай?
Безнең дөнья—җан атлагандай...

Юк, уен да, пәрәвез дә түгел,
Ни уйласаң, адәм, үз эшең.
Ахры берәү җирдән азык җыя,
Атлан майдай итеп өлешен...
Ни уйласаң, адәм, үз эшең...
...Уйларыңда туа өлешең...

• • •

Карурманда кояш нуры,—
кергәнең юк—
юк, димсең?

Кыяларда җил оясы—
менгәнең юк—
юк, димсең?

Табаннан түбән—тойма, ди,
корсактан ары—койма, ди,
маңгайдан өстә—кәпәч, ди,
томан—фикергә җиткәч, ди,—
ә син—
Ил туар, димсең?

...Карурманда бар нурлар,
кыяларда—оядыр,
бер басылыр ил тузаны,
затлы орлык җыя тор...

• • •

Шигырь ни ул?—
Махсус кайчы:
Фикерләр—пара-парә.
Шигырь—ятьмә,
алтын читлек,
Моң-хисләргә
мәгарә.

* * *

Җиде күккә күтәрел дә
Бер карап бак дөньяга,
Тәңре яралткан җаннармы
Тәңре корганояда?

Җиде күккә күтәрел дә
Бер карап бак үзеңә,
Акыл канат таккан микән
Телгә кунган сүзеңә?

Җиде күккә күтәрел дә
Бер карап бак җиһанга,
Җиһан чиксез, җиһан—тыныч,
Кемнәрдән—тыз-быз, гауга?

Җиде күккә күтәрел дә
Бер карап бак, и адәм.
Кемгәдер орчык кына ул
Без яшәп яткан галәм...

## Кара диңгез

Кара диңгез—мәгърур диңгез,
Кояш—алтын түбәтәй.
Зәңгәр күк тә шундый җайлы—
Күк Түрк корган түбәдәй.

Иркәли татар баласын
Ак калфаклы дулкыннар,
Мең еллардан
катлам-катлам
Җыелган сагынулар.

Күңелнең дә, диңгез сыман,
Дулкыннар бәргән чагы,
Эретә сагыш тауларын
Кара диңгез кочагы...

## Шәһре Биләр

Тау битендә изге чишмә—көмеш су,
Тал-чыбыкта былбыл сайрый, моңлана.
Хат юлыдай борма-борма Чирмешән,
Суларында Биләр таңы аллана.

Изге чишмә күңелемә пар канат,
Мин былбыл да, тал-чыбык та янында,
Биләр, диеп, канатланам, тын алам,
Шәһре Биләр рухы яши җанымда.

Биләр-судан сагыш җыя тулы ай,
Ай юлында Шәһре Биләр капкасы,
Алтын капка көтә булыр ачылып,
Татарларның асылына кайтасын.

Тау битендә изге чишмә—көмеш су,
Тыл-чыбыкта былбыл сайрый, моңлана.
Хат юлыдай борма-борма Чирмешән,
Суларында Биләр таңы аллана.

Көмеш тояк бәхет уя бәгырьгә,
Тулпар атта лачын-яугир—ут-яшен,
Курай-кубыз моңы исән йөрәктә,
Күңелемдә бөек Биләр шәүләсе.



# Сафуан Мулла Гали

## ТАЛЛАР НИДЕР ТЫҢЛЫЙ— БИК ТЫНЫП...

* * *

Сандугач күк сайрап тора бит ул,
Тальян теле кебек көмеш гел.
Рәхәтләнеп, намаз укы, татар,
Рәхәтләнеп җырла, уйна-көл!
Синдә—галәм сайлап биргән тел...

Ватаныңның сөтен киптерергә
Теләүчедән кала бер уч көл.
Рәхәтләнеп намаз укы, татар,
Рәхәтләнеп җырла, уйна-көл:
Синдә—галәм чарлап биргән тел!

### Минем дәрәҗәм

Ике катлы гади өйдә яшим,
Кыйбла якка карый тәрәзәм.
Көлмәк булып бераү сорый миннән:
«Ничә йолдыз синең дәрәҗәң?»

«Ничә йолдыз?»
Тәрәзәмнән карыйм—
Бик күп йолдыз галәм күгендә.
Һәркайсыннан нурлар тама минем
Газиз халкын сөйгән күңелгә...

Тәрәзәмнән карап киңәйтәмен
Алгысыган рухым киңлеген.
Кешелекле җаным киң галәмнең
Киңлегенә булсын тиң минем...

...Иңнәремдә канат барын тоям,
Киң галәмгә карый тәрәзәм...
«Ничә йолдыз?»,—дисең,
Дөнья сыя:
Бу тәрәзәм—минем дәрәҗәм...

Сафуан МУЛЛА ГАЛИ *(1927)— шагыйрь, «Биздерсәләр туган җиреңнән» исемле шигъри повесть, берничә шигырь китабы авторы. Казанда яши.*

## Авылны бар күрәсем

Яшен яшәгән бу башым
«Туган як» дип тилмерә.
Йөрәгем түзгән сагышка
Түзә алмас тимер дә...

Үткән юлым таулы-таулы,
Ташы сукты тезләргә.
Чатный-чатный, сынар идем,
Ант итмәсәм түзәргә...

... Бәлки түзеп тормас идем,
Авылны бар күрәсем—
Бәхилләшми җир астына
Ничек барып керәсең?!.

## Таллар нидер тыңлый

Ай-Кояш та шул ук—дөнья моңсу,
Таллар нидер тыңлый бик тынып.
Оеган күк, бөтен дөнья тып-тын,
Борчылдыра мине бу тынлык...

Тыныч яши халык: селкетми, дип,
Искән җилләр камыш кыягын.
Ә шулай да кирәк түгел микән,
Тулпарларыбызның тоягын

Дагаларга кирәк түгел микән?!
Борчылдыра мине бу тынлык...
Ай-Кояш та шул ук—дөнья моңсу,
Таллар нидер тыңлый—бик тынып...

* * *

Шәфкатьсез-аяусыз заман:
Туктаусыз сорый корбан.
Кеше кешене ауларга
Юлларга капкын корган...

Аяусыз аяуны белми:
Сындыра каеннарны...
Аяк-кулларны сындырып,
Иңбашка кайгыларны
Асып, үзеңне ыргыта
Җиде юлның чатына.
Бер гаебе юк ич диеп,
Кызганмый да чак кына...

...Ир-аты да, хатыны да
Ник бу кадәр аяусыз?
Вәхшиләр илне какшатты—
Чын кешеләр, кайда сез?

## Чәчәкләр сайлый-сайлый

...Юлда карлар бөтерелде,
Канатын җәйде буран.
Кар кызлары жырлый, бии,
Гөр килеп тора урам...

Ишеткән күк яуган карда
Гөрләвекләр гөрләвен,
Йөрәгемдә чәчәк ата
Атмый калган гөлләрем...

...Тышта буран, төшләремдә
Очам әле мин «сабый»:
Азатлык сөйгән халкыма
Чәчәкләр сайлый-сайлый,
Очам әле мин «сабый»...

Әлфәт Закирҗанов

# ЯҢА ҖИЛЛӘР ИСӘМЕ?

## СОҢГЫ ЕЛЛАР ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЕНӘ БЕР КАРАШ

Хәзер бездә әдәби тәнкыйтькә карата төртмәле һәм усал сүзләр шактый еш әйтелә. Мисал өчен соңгы ике елны гына алсак та, төрле басмаларда күренекле әдипләребезнең тәнкыйть турындагы кискен генә фикерләре дөнья күрде. Айдар Хәлим: «Барлы-юклы традицион тәнкыйтебез сүнеп калгандай булды» дип, Мансур Вәли: «Нишләп соң без үзебездә булган рухи-эстетик байлыкны күрә, аны тиешенчә бәяли алмыйбыз?» дигән сүзләр белән, Миргазиян Юныс: «Татар әдәби тәнкыйте жан тәслим кылган» дигән рәвештә, Зиннур Мансуров: «Тәнкыйть әдәби күренешләрне артык гади аңлата, бу өлкәдә нисбәт үзешчәннәр ягына авыша башлады» дип һ. б. язып чыктылар. Равил Фәйзуллин да: «Ориентир-маяклар күрсәтергә тиеш әдәби тәнкыйтебез бик зәгыйфь»—диде, Рифат Сверигин тәнкыйтьнең үз функцияләреннән читләшүен күрсәтте һәм аңа оеганлык хас дип белдерде. Башка әдипләр дә үзләренең чыгышларында һәм мәкаләләрендә әдәби тәнкыйтьнең чор, заман таләпләренә жавап бирмәвен билгеләп үттеләр.

Югарыда искә алынган авторларның һәм бүтән каләм ияләренең мәкаләләрендә әдәби тәнкыйтьнең соңгы елларда ни өчен торгынлык кичерүен аңлатучы кайсыбер сәбәпләрне ачыкларга тырышу да булды. Менә аларның кайберләре: житмешенче-сиксәненче елларда әдәбиятка, шул исәптән тәнкыйтькә килүчеләрнең саны аз булу, буыннар арасында билгеле бер күләмдә бушлык туу; И. Нуруллин, Ф. Миңнуллин, Ф. Зөлкарнәйләрне югалту. Ижади яктан алганда тагын мондый сәбәпләрне күрсәтергә мөмкин: иске стереотиплардан озак арыну, чорга бәйле яңача күзаллаулар кирәклегенә акрын төшенү; тәнкыйть язмаларында бертөрлелеккә йөз тотып, әсәр яисә әдип ижаты турында гомуми сүзләр белән язу, купшы стиль өстенлек итү; еш кына булмаганны бар итеп, күккә чөеп мактау һ. б.

«Авыруның сәбәпләрен белү һәм дөрес диагноз кую—ул инде дәвалый башлау» дигән гыйбарә бар. Соңгы вакытта матбугатта шактый киң колач белән әдәби тәнкыйть турында житди сүз алып баруны да шуңа тиңләргә мөмкин. 1999 елда «Казан утлары» журналы оештырган «Туксанынчы еллар әдәбияты»

---

Әлфәт ЗАКИРЖАНОВ *(1959)— әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче, педагогика фәннәре кандидаты. Әдәбият буенча дәреслекләр авторы. Казанда яши.*

дигән сөйләшү дә тулаем әдәбиятыбыз турында ачыктан-ачык фикер алышу белән бергә, тәнкыйть өлкәсендә эшләүчеләрне барлау да булды. Төрле характердагы мәкаләләрне укыганнан соң бездә шактый какшап, каушап калган тәнкыйть тармагына тернәкләнү өчен нигез бар икән әле дигән өмет тә туды.

Билгеле, агымдагы әдәби тәнкыйтьнең җанлануы иң беренче чиратта республикабыздагы басмаларга, аларның тулаем әдәбиятка һәм әдәби процесска, шул исәптән әдәби тәнкыйтькә дә ни дәрәҗәдә «җылы» караштa булуларына бәйле. Бу яктан алып караганда, ягъни әдәби тәнкыйть язмаларына теге яки бу басмада урын бирү ягыннан алганда, «Казан утлары» журналы белән «Мәдәни җомга» атналыгы һәм «Шәһри Казан» газетасы бигрәк тә аерылып тора дип билгеләп үтәсе килә. Бу басмалар әдәби тәнкыйтьне җанландыру максатыннан чыгып «Түгәрәк өстәл» сөйләшүләре уздыралар, әдәби темаларга анкеталар булдырып, анда куелган сорауларга күренекле әдипләрнең кызыклы-кызыклы җавапларын урнаштыралар. Бәхәсләр һәм дискуссияләр дә соңгы еллар матбугаты битләрендә ешрак үткәрелә. Мондый чаралар, әлбәттә, әдәбиятыбызга кагылган рухи-эстетик фикерне җанландыра, сафта күренгән азмы-күпме кадрларны шушы юнәлештә уйланырга һәм үзләренең фикри-эстетик куәтләрен матбугатта сынап карарга этәрә.

«Казан утлары» үткәргән рецензияләр конкурсын аерым билгеләп үтәсе килә. Сер түгел: бу тармак—рецензияләр язу—әдәби тәнкыйтьнең иң артта калган өлеше. Китаплар байтак басыла, ә аларга гадел бәя биргән рецензияләр гаять сирәк языла.

Әлеге конкурста басылып чыккан мәкаләләр бер дәрәҗәдә түгел, билгеле. Бу, бер яктан, һәркемнең әдәбиятны аңлавы, белеме, эстетик зәвыгы белән аңлатылса, икенче яктан, тикшерү өчен алынган материалның да төрлелегеннән килә: кемдер аерым бер хикәяне анализласа, икенче берәү җыентыкка күзәтү ясый.

Мисал өчен, танылган әдип, үткен фикерле тәнкыйтьче Миргазиян Юныс «Бәхетле мескенлек» мәкаләсендә А. Хәлимнең «Татар вакыты» исемле әсәрен халык менталитетына бәйләп тикшерә һәм үзенә хас кыюлык, кискенлек, фәлсәфи тирәнлек белән әсәрнең үзенчәлекләрен, тема-проблематикасын ачыклый. Автор бу кечкенә романны соңгы елларда дөнья күргән иң уңышлы әсәрләр рәтенә куя. Әмма шулай да биредә тәнкыйтьченең сурәтләү объекты, ягъни чор, заман күренешләре белән артыграк мавыгуы күренә, ә инде «Татар вакыты»ның сәнгатьчәлеге, әдипнең тормышны эстетик күзаллавындагы табышлары бераз читтә кала. Ф. Хатипов «Якты җирлектәге һәлакәт» мәкаләсендә исә М. Хуҗинның «Каңгый илендә» хикәясен, киресенчә, нигездә эстетика таләпләреннән чыгып анализлый. Тәнкыйтьче хикәя жанры үзенчәлекләренә бәйле әдәби детальләрнең ролен, психологик сурәтләрнең әсәр канвасындагы урынын төгәл билгели. Биредә геройлар эш-хәрәкәтен, күңел кичерешләрен, эчке драмаларын бирүдәге авторның осталыгы да ачыла. Проза турындагы язмасында Р. Сверигин «Каңгый илендә» хикәясен «бу жанрны иҗади үзләштерергә яисә хикәя-новелла язып карарга теләүчеләр өчен менә дигән кулланма» дигән иде. Әлеге фикерне дәвам итеп, Ф. Хатипов мәкаләсе әдәби тәнкыйть белән шөгыльләнүчеләр өчен менә дигән үрнәк дияргә дә була. Сүз уңаенда әйтеп китик: шушы ук авторның журналда 1999 елның май санында дөнья күргән «Иҗат серләре» исемле җитди хезмәте дә фикри тирәнлеге, фактик материал байлыгы белән истә калган иде.

Әдәби тәнкыйтьтә һәм публицистикада иң актив эшләүче авторларыбыздан булган Р. Шәрәфиев язмалары матур хикәя кебек укыла. Ул үзе тикшерә торган «Гомер тәлгәшләре» китабы авторының теләк-фикерләрен, уй-гамәлләрен оста тотып ала, сурәтләнгәннәрне бүгенге яшәеш белән мәгънәви бәйли һәм шуның белән әсәрнең асылын ачып сала. Тәнкыйтьче юл араларына яшерелгән яисә искәртеп кенә үтелгән, әйтеп бетерелмәгән фикерләрне дә күреп ала һәм алар турында укучыны да уйланырга этәрә. Аның Т. Галиуллин, М. Хуҗин һ. б. авторлар турында соңгы елларда басылып чыккан мәкаләләре матур тәэсир калдыра. Р. Шәрәфиевнең «Безне кемнәр аңлар?» мәкаләсен дә шигъриятне олылауның матур үрнәге дияргә була. Яшьлек, мәхәббәт шагыйре булып танылган И. Юзеевның фәлсәфи, гражданлык лирикасына тартылуын, иҗаты тулы өлгергәнлек чорына җитеп, яңа этапка күчүен дә билгели автор. Шулай

да әлеге язмада шагыйрьнең хис-кичерешләр байлыгына ничек ирешүенә, сурәтлелектәге табышларына, сәнгати теленә игътибар житеп бетми кебек.

С. Сөләймpraованың «Тормыш, исәнме» җыентыгына Кояш Тимбикова язган «Шагыйрьнең хыялында йөрткән китабы» исемле мәкалә дә күпләрнең игътибарын җәлеп иткәндер. Җан җылысы белән язылган язмада шагыйрәнең шигъри дөньясы, фикри хөрлеге, сихри хисләре, аларның үзара бәйләнеше ачыла һәм шуларда тәнкыйтьче С. Сөләйманова иҗатының матур чалымнарын бирә. Ләкин әлеге җыентыкны тулысынча күзәтү максат итеп куелмагангадыр инде, тәнкыйтьче аерым штрихлар белән чикләнә һәм төп игътибарын шагыйрәнең шәхесе, гаиләсе, иҗат лирикасы турындагы уй-гамәлләргә юнәлтә.

Әдәби тәнкыйтендә шигърият, проза, драма әсәрләренә бердәй тигез мөрәҗәгать итүче Н. Сафинаның активлыгы да бары хөрмәткә лаек. «Фидакарьләр вөҗдансыз булмый» *(«Казан утлары», № 4)*, «Юл катысын югалтмадыгызмы» *(Ватаным Татарстан, 2000, 4 февраль)* мәкаләләрендә ул әдәби тәнкыйтьнең бүгенге хәле турында җан ата, аны торгынлыктан чыгару юллары турындагы фикерләре белән уртаклаша. Ә инде «Ил турында «Ил» китабы» язмасында *(«Казан утлары», 2000—№ 12)* Р. Зәйдулла җыентыгына кыска, әмма әтрафлы бәя бирә. Тәнкыйтьчене әсәрләрнең сәнгати үзенчәлегеннән бигрәк, хикәяләрнең тематик киңлеге, күтәрелгән мәсьәләләрнең заманчалыгы күбрәк кызыксындыра, шулай ук Р. Зәйдулланың дөньяны, тормышны үзенә хас стильдә, алымнарда таныга һәм аңларга омтылуы уңышлы ачыла.

Төрле әсәр-җыентыкларга язылган рецензия һәм күзәтүләргә газета-журналлар шактый киң урын биреп килә. Мәсәлән, «Идел» журналында «Китап киштәсе», «Ватаным Татарстан»да «Әдәбият дөньясы: фикерләр, уйланулар» дигән яңа сәхифәләр ачылу да, һичшиксез, хуплауга лаек. Болардан тыш «Мәдәни җомга»да, «Шәһри Казан»да һәм әдәбият, һәм тәнкыйть мәсьәләләре игътибар үзәгендә торуын әйтеп үтәргә кирәк.

Соңгы вакытта Г. Тукай бүләгенә тәкъдим ителү белән бәйле рәвештә аерым авторлар иҗаты игътибар үзәгендә булды. Күпсанлы мәкаләләр арасында шигъриятнең эчке хасиятләрен ачу омтылышы киңрәк чагылган Р. Гаташ һәм М. Бакиров язмалары кызыклы иде. «Робагыйлар остасы» үз каләмдәше Зөлфәт иҗатын «йөрәк белән кушылган шигърият» *(«Ватаным Татарстан», 2000, 31 март)* дип бәяли һәм аның күп бизәкле сурәтлелеккә тугры калып, бүген инде сулышы тагы да киңәеп китеп, бер үк вакытта табигыйлеккә һәм «тылсымлы сүз дөньясына» омтылуына укучыны ышандыра. Әдәбият галиме М. Бакиров исә шул ук шагыйрьнең шигырьләр җыентыгын сурәтле ассоциатив фикерләү үзенчәлекләрен билгеләү яссылыгында тикшерә һәм шагыйрьдә төрле халәткә күчү тойгысының үскән булуын билгели. Ул аны «контрастлар шагыйре» дип атый. Әлеге фәлсәфи-диалектик һәм поэтик алым шагыйрьгә табигать дөньясы, кеше рухы турында хакыйкатьне әйтергә мөмкинлек бирә дип саный тәнкыйтьче *(«Мәдәни җомга», 2000, 11 апрель)*.

Аерым китапка яисә әсәргә күзәтүләр арасында К. Кәримовның «Ком сәгате» турында Я. Абдрәхимованың «Авыл кыйссасы» *(«Ш.К», 2000, 4 февр.)*, Л. Ихсанованың «Тулгак»ның тулган дөньясы» *(«Ш.К», 2000, 13 окт.)*, А. Юнысованың «Тоткасыз ишек» (Р. Харис) хакында «Каләм коткарачак» *(«В.Т» 2000, 21 гыйн.)*, Э. Шәрифуллинаның «Мәхәббәттән миндә күмер калды» *(Б. Рәхимова иҗаты «М.Ж», 2000, 3 март)* язмалары әйбәт тәэсир калдырды. Д. Заһидуллинаның Р. Зәйдулла китабы турындагы «Тәңре кылычы кайчан иңә...» *(«М.Ж», 2000, 18 авг.)* мәкаләсенә дә игътибар итегез әле. Монда хикәяләрнең сюжетын сөйләү дә, бик күпләребездә очрый торган кимчелек—тема һәм проблемаларның актуальлеген кат-кат искәртү дә (чынбарлыктан сайлап алынган вакыйга-күренешләрнең кайсы актуаль түгел!) юк. Тәнкыйтьче Р. Зәйдулла хикәяләренә генә хас үзенчәлекләрне ачуны максат итеп куя һәм әдипнең шигырьгә тартым образ-сурәтләр, символлар, әдәби детальләр белән оста эш итүен, шулар ярдәмендә кеше психологиясенә үтеп керә алуын, контексттагы эчке мәгънәне дә символларга йөкләвен билгели.

Танылган публицист М. Әхмәтҗанов соңгы елларда нәтиҗәле эшли. Мәкаләләре арасында Ә. Баянның «Кызыл ут» китабына бәяләмәсе *(«М.Ж», 2000, 4 февр.)* аеруча уңышлы. Әдипнең заманча фикерләвендә, тынгысыз җанында

укучыны битарафлыктан чыгара торган хис-тойгыларның үзенчәлекле чагылышын таба тәнкыйтьче. Ә менә Т. Әйдинең «Иблискә ришвәт» китабы турындагы мәкаләсендә нишләптер *(«В.Т», 2000, 9 июнь)* төрле мәгълүматлар бирү, сюжет эчтәлеген сөйләп чыгу белән чикләнә.

Китап күзәтү, яңа чыккан әсәрләргә рецензия язу—тәнкыйтьнең бик кирәкле бер формасы. Әмма, тәнкыйтьнең торышын, әдәби процесстагы урынын күләмлерәк һәм аналитик анализга нигезләнгән жанр билгели. Бу очракта иҗат портретларын, әдип иҗатына бер карашны, аерым әдәби төрләргә күзәтүне һ. б. күздә тотабыз. Моңа бәйле сүзне «Казан утлары» редколлегиясе утырышлары турындагы язмалардан башлыйк. Ф. Латыйфи 1999 ел прозасына әйбәт күзәтү ясап, бу төрнең төп үзенчәлекләрен, ягъни рациональ орлыкларын» билгеләп үтә. Проза әсәрләренә куелган таләпләрне дә кистереп әйтә: кыскалык-җыйнаклык һәм фикри җегәре ачык булу. Быелгы 3 санда 2000 ел прозасына бәя биргәндә Ф. Сафин да: «Яңа гасыр укучысы чорга адекват әсәрләр көтә. Җәмгыятьнең холык-халәтен белми торып, аның асылын аңламаган хәлдә язганынны укучыга тәкъдим итү авыр булачак»,—дигән нәтиҗә ясый.

Г. Гыйльмановның әдәби тәнкыйть торышы, вазифалары турындагы фикерләре дә кызыклы. Ул татар әдәби тәнкыйте бар дип саный һәм аның яңа чалымнарын да күрсәтә. Бу—тәнкыйтьтә публицистик аһәңнең көчәюе һәм аңа академик фәннең, әдәбият гыйлеменең үтеп керүе. Чыннан да, бүген чиста тәнкыйть мәкаләсе аз очрый. Язмаларның күбесендә иҗтимагый-сәяси, әхлакый-фәлсәфи мәсьәләләр турында уйланулар әсәр үзенчәлекләре белән тыгыз бәйләнештә бирелә. Әгәр без әдәби әсәрләрдә заман сулышы көчәюен, милләт язмышына, тарихка, телгә бәйле иҗтимагый һәм публицистик пафосның артуын таныйбыз икән, тәнкыйтьтә дә алар чагылмыйча калмый. Билгеле, тәнкыйть һәм публицистика бер-берсеннән шактый аерыла. Әмма алар якынаеп, үзара баетышалар икән, моннан куркырга кирәкми.

Соңгы вакытта дөнья күргән байтак публицистик язмаларда аерым әсәрләр, әдәби процесс хакында гаять кызыклы фикерләрне очратабыз. Л. Шагыйрьжанның «Сүзләр, сүзләр...» *(«К.У», 1999—№ 7)* язмасы, Ф. Урманченың «Борынгы миф һәм бүгенге шигырь» хезмәте *(«К.У», 1999 ел, № 6-7)* Г. Гыйльмановның Г. Морат иҗаты турындагы «Образ. Символ. Рухи кодлар» *(«К.У», 1999, № 4)*, Ф. Зөлкарнәй турындагы «Ул минем язмышымда калды» *(«Идел», 2000—№ 3)* мәкаләләре, Р. Юнысның Ә. Еники белән әңгәмәсе *(«Идел», 2000—№ 4)* әдәбият белемен баетуга хезмәт итә.

Игътибар юнәлтик, Л. Шагыйрьҗан мәкаләсендә ниндидер әсәр яисә иҗат кешесе турында сүз бармый. Әмма ул язма бөтен асылы белән эстетик зәвыклы укучы тәрбияләргә булыша. Сүзләр ярдәмендә сүзгә мәдхия укыла монда. Автор татар теленең бай лексикасын, сүзнең күпмәгънәлелеген менә дигән итеп ача. Теләсә кайсы язучы, Лена ханым әсәр теленә куйган таләпләргә минем иҗатым җавап бирә микән дип, әлеге язманы кабат-кабат ачып укыячак. Тәнкыйтьнең төп максатларыннан берсе шул түгелме соң? Бу унайдан Р. Фәйзуллинның «Китап гасыры китәме?» *(«К.У», 2000—№ 1)* публицистик язмасын да күрсәтергә мөмкин. Бу мәкалә сүз сәнгате, язучылык хезмәте, аның бүгенгесе һәм киләчәге, ягъни Галиҗанәп Китап турында. Авторның фәлсәфи уйланулары артында рухи һәм эстетик яктылык чыганагы булган әдәбиятыбыз алдына куелган бурыч-таләпләр дә ачык төсмерләнә.

Соңгы елларда Р. Сверигинның, спорт теле белән әйткәндә, икенче сулышы ачылды. Аның аерым әдипкә, әдәби чорга, еллык күзәтүләргә бәйле хезмәтләрендә без зәвыклы укучыны, сүз сәнгатен тирәнтен аңлаучы таләпчән тәнкыйтьчене күрәбез. Р. Свиригинның «Үткән ел прозасына бер караш» дигән мәкаләсе, «Казан утлары» анкетасына биргән җаваплары да моны раслый. Тәнкыйтьче әсәрләргә бер-ике җөмлә белән, әмма төгәл һәм гадел бәя бирә, кирәк урында итагатьле генә саллы сүзен дә әйтә. Аның өчен авторитет-дәрәҗәләрдән бигрәк, сәнгать әсәренең эчке хасиятен ачу мөһимрәк. Әлеге мәкаләсендә Р. Сверигин безнең игътибарны әсәрләрнең жанр ачыклыгы мәсьәләсенә юнәлтә. Бәя бирү кретерийлары итеп мавыктыргыч булуны, образлылыкны, фикер тирәнлеген ала һәм тәнкыйтьнең бурычларын да эстетик кыйммәтләрне ачыклауда күрә.

Хәзерге татар әдәбиятының драматургия жанры әдәби тәнкыйть игътибарыннан читтәрәк калып килә. Спектакль премьераларына язылган рецензияләрдән башка махсус мәкаләләр юк диярлек. Шуңа да журналда үткән ел басылган Ю. Сафиуллинның «Сәхнә әсәрләребез нинди?» *(№ 2)* һәм А. Әхмәдуллинның «Эзләнүләр бәрәкәтлеме?» *(№ 7)* исемле мәкаләләре игътибарны җәлеп итте. Ике автор да драматургиянең соңгы биш елдагы торышы турында сүз алып бара. Ю. Сафиуллин язмасында драма әсәрләренең театр белән бәйләнеше, спектакль буларак тамашачыга җиткерелүе турындагы фикерләр өстенлек ала. Автор театрның (нигездә, Г. Камал театрының) бүгенге хәлен, эчке халәтен шактый тулы ача. Пьесага куелган таләпләрне исә сәхнә әдәбияты кануннары белән бәйләнештә карый. Язма бу вакыт аралыгында басылып чыккан яисә төрле театрларда куелган пьесалар, аларның авторлары исемнәренә, һәртөр саннарга, фактларга бик бай. Автор сәхнә әдәбиятындагы кимчелекләрне дә тоемлый. Аның «Шундый чор килде, халык театрга кәмит карарга гына йөри, дип үз-үзебезне алдап ятсак, тамашачыны беркайчан да үз артыбыздан ияртә алмабыз,—дигән фикере белән кайсыбыз гына килешмәс икән. Драматургиянең җәмгыятьтәге урыны, аны үстерү өчен кирәк булган шартлар, тамашачы зәвыгы турындагы фикер-карашларын автор Көнбатыш Аурупа, урыс сәхнә әдәбияты мисалларына таянып билгели. Әмма биш ел эчендәге драматургия турында сүз алып барабыз икән, аның бүгенге хәленә ачык, анлаешлы бәя бирү, билгеле бер дәрәҗәдә төп юнәлешләрен, үсеш перспективаларын билгеләү дә сорала. Автор исә әлеге язмасында борчу тудырган мәсьәләләрнең күбесен читләтеп үтә. Үз максатын билгеләп, ул: «Мин монда кемне дә булса мактарга да, хурларга да җыенмыйм. Теләгем—драматургиядә 79 каләм тибрәтүче хакында гап-гади сүз әйтү»,—дип яза. Әмма сүз бит кемне дә булса мактау яисә хурлау турында бармый. Мәсьәлә халкыбызның рухи тормышында җитди роль уйнаган сәхнә әдәбиятының бүгенге хәлен ачыклауга кайтып кала. Белгәнебезчә, татар театрларына зәвыклы тамашачы белән бергә, әдәбият укымый торган, телен дә оныткан татарлар да, башка милләт вәкилләре дә күпләп йөри. Ә драматурглар, режиссерлар, аларга нәрсә тәкъдим итә? Спектакльләр халыкны битарафлык саллыгыннан чыгарырга, матурлык-яхшылыкны аңларлык эстетик зәвык тәрбияләргә ярдәм итәме? Халыкны, гомумән, җәмгыятьне борчыган әхлакый һәм фәлсәфи мәсьәләләр нинди яссылыкта куела? Менә бит сүз нәрсә турында бара.

Бу сорауларга өлешчә җавап А. Әхмәдуллин мәкаләсендә бар. Тәнкыйтьче соңгы еллар драматургиясенә этрафлы күзәтү ясый. Сәхнә әдәбиятында булган табышларны автор тематика-мәүзугның төрләнүендә, якындагы тарихыбызга мөрәҗәгать итеп, кеше һәм җәмгыять каршылыкларын кыю рәвештә ачуда, заман проблемаларын сәхнәгә чыгаруда һәм әхлакый мәсьәләләрне гомумкешелек проблемалары белән бәйләп карауда күрә. Ә менә сәнгати як «күкрәк кагарлык түгел» икән. Җитди кимчелекләр буларак, тәнкыйтьче сәхнә әсәрләрендәге конфликтларның артык гадилеген, җиңеллеген; сюжеттагы «үтә күренмәлелекне», ягъни алдан ук барысының да билгеле булуын; чор үзенчәлекләрен үзенә туплаган, милли характер дәрәҗәсенә күтәрелгән эре типлар булмавыны күрсәтә.

Драматургия турындагы ике язма да фактларны билгеләү һәм, әйтергә кирәк, мактау белән күбрәк шөгыльләнә. Монысы да кирәк билгеле. Чөнки нигез дә бар: төп театрларыбыз тамашачыны җыя, башка төбәкләргә гастрольләр белән чыкканда да әйбәт бәя ала. Әнә Г. Камал театры Төркиядән дә зур җиңү белән кайткан, шатланмыйча мөмкин түгел. Әмма аерым рецензия-язмаларда театрларыбызның еш кына түбән зәвыклы тамашачыга йөз тотуы, шау-шу, тамашаның күбәеп китүе, шул ук вакытта интеллектуаль пьесаларның, тамашачының җанын айкый торган, театр залыннан чыккач та озак вакытлар уйландырып, борчып тора торган спектакльләрнең азаюы турында борчулы фикерләр дә шактый. А. Әхмәдуллин үзе дә «күпчелек әсәрләрне «клип драматургиясе» диярга була», ди. Д. Гыймранованың андыйларны «ширпотреб» дип, З. Зәйнуллинның «тегермәнне файдасызга әйләндерүче буш орлыклар» дип атавын беләбез. Боларга тагын Г. Ахунов фикерен өстисе килә. «Мин бүген Татар дәүләт академия театры мәгънәгә, акыл сөрешенә корылган әсәрләрне куя алмый, аларга карата театрның мөнәсәбәте юк, дип әйтер идем. Академия театры тамашага корылган әсәрләрне генә кую ягында тора. Киләчәк буыннар

алдында әлеге мөнәсәбәт өчен театр җавап бирергә тиеш булыр әле»,—дип яза ул *(«К.У», 1998—№ 1)*.

Күрәсез, булганны күрсәтү һәм мактау белән генә чикләнергә ярамый. Игътибар итик, Ю. Сафиуллин мәкаләсен «Сәхнә әсәрләребез нинди?» дип, А. Әхмәдуллин «Эзләнүләр бәрәкәтлеме?» дип унышлы исем белән атаганнар. Әмма аңлашылганча, җавап биреп кенә бетермиләр, чөнки конкрет исемнәрне атарга, йомшак әсәрләрне, аларның кимчелекле якларын ачыктан-ачык әйтеп сөйләшергә кирәк. Кемгә ничек, минемчә, Г. Камал театрында соңгы елларда куелган яки бара торган спектакльләрдән «Әлепле артистлары» (Аманулла), «Казан егетләре», «Тагын Казан егетләре (М. Гыйләҗев), «Су төбендә сөйгәнем», «Һинд биюе», «Килә ява, килә ява» (З. Хәким), «Йөрәк маем», «Гөргери кияүләре» (Т. Миңнуллин), «Сөембикә егет сайлый» (Ф. Яруллин) кебекләре әлләни озын гомерле булмас кебек. Дөрес аңлагыз, әлеге спектакльләр куелмасын дигән сүз түгел бу. Башкасы булмагач, андыйлар куелды, куела һәм куелачак. Шулай да әлеге пьесаларның түбән зәвыклы тамашачыга гына исәп тотып язылуын дә әйтү кирәк. Ә Г. Камал театрының йөзен билгеләп, драматургия тарихында инде бүген үк классика дип аталырга хаклы «Әлдермештән Әлмәндәр» (Т. Миңнуллин), «Әни килде» (Ш. Хөсәенов) һ. б.лар калачак. Боларга тагын «Әниләр һәм бәбиләр», «Шәҗәрә» (Т. Миңнуллин) өстәлергә лаеклы.

Драматургиянең бүгенге хәлен мин бер урында таптану дип атар идем. Ә аннан инде яулаган үрләрдән чигенүгә дә күчәргә мөмкин. Соңгы вакытта әдәби тәнкыйть турында уйлану-сөйләшүне башлаган кебек, драматургия һәм театрның торышы да җитди сөйләшү сорала.

Аерым әдипләрнең иҗат портретын бирү һәм күзәтүләр арасында З. Мансуров иҗаты турында Ә. Баянов, Р. Гаташ мәкаләләрен *(«М.Ж», 2000, 14 июль һәм «КУ», 2000—№ 4)*, Р. Фәйзуллин шигъриятенә бәйле Х. Бәдигый язмасын *(«Мирас», 2000—№ 6)* билгеләп үтәсе килә. Л. Шагыйрьҗанның «Поэмалар заман героен сагына» *(«В.Т», 2000, 28 гыйн.)*, Р. Сибатның «Прозабыз Ахуны» *(«К.У», 2000—№ 9)*, Г. Ахуновның «Тел-стиль мәсьәләләре» *(«М.Ж», 2000, 29 сент.)* дигән мәкаләләре дә әйбәт тәэсир калдырды.

Тәнкыйть турында сүз барганда А. Хәлим эшчәнлегенә аерым тукталмый ярамас. А. Хәлим—әдәби иҗатның барлык өлкәләрендә дә актив, нәтиҗәле эшләүче авторларыбызның берсе. Әсәрләре кебек, аның тәнкыйтенә дә битараф калып булмый. (Гәрчә аның әдәби иҗатын өйрәнеп, тиешле бәясен бирергә алынучы һаман юк әле—куркабыз!) Тәнкыйтьнең бүгенге мөшкел хәле турында да беренчеләрдән булып ул аваз салды, үзенең усал, туры сүзе белән, күбебез икеләнеп торган арада, акны акка, караны карага аерып куя барды. Аның тәнкыйте публицистик эчтәлек белән сугарылган, җанга ятышлы тел белән язылган. Г. Афзал шигърияте турындагы «Яратам, нихәл итим?» язмасы исә *(«М.Ж», 2000, 18; 23 февр.)* аерым игътибарга лаек. Монда Г. Афзалның шигъри табигатен аңлау, милли хиссиятен ачык тоемлау, иҗатына чын мәгънәсендә мөкиббән китү һәм бөтен барлыгы белән кабул итү, тирән хөрмәт һәм ярату—барсы да бар. Тәнкыйтьче шактый күптән чыккан шигырь җыентыгы мисалында төрле тема-тармаклардагы әсәрләренербөтен итеп карый һәм халыкчан, милли шагыйрьне укучы каршында өр-яңадан ача.

А. Хәлимнең «Ирексездән ирекле турында» трактаты *(«Мирас», 2000—№№ 8, 9, 10)* матбугатта бәхәс уятып та өлгерде. Тәнкыйтьченең ирекле шигырь, аның үсү-үзгәрү тарихы, аерым әдипләр иҗатында чагылган үзенчәлекләре турындагы фикерләре әдәбият теориясе буенча дәреслекләрдә урын алырга хаклы. Шулай да әлеге язмадагы аерым фикер-карашлар бертөрле генә кабул ителми. Г. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре» хезмәтенә биргән бәясе, аңлатуы, Һ. Такташ фаҗигасе сәбәпләре турындагы фикерләре бәхәсле булып тоелды. К. Латыйпны «ирекле шигырь вәзенен байрак итеп күтәреп алга илткән» бердәнбер (!) шагыйрь дип күрергә теләве белән дә килешеп булмый.

Әдәби процессны тулаем күзаллап язган мәкаләләрендәге фикер ачыклыгы, дәлиллек, исемгә карап түгел, җисемгә карап эш йөртүе белән Мансур Вәлиев соңгы елларда хөрмәт казанды. «Ватаным Татарстан»да «Әдәбият дөньясы: фикерләр, уйланулар» дигән яна рубрика алып баруы да бары яклауга лаек. Р. Сибатның «Ялгызак» романына бәяләмәсе *(«К.У», 2000—№ 10)* һәрвакыттагыча

фикри җегәрле. М. Вәлиев тәнкыйтенә бер үзенчәлек хас: ул күзәтелә торган китапның иң әһәмиятле бер-ике компонентын аерып ала да, шулар аша әсәрнең асыл мәгънәсен ача. Әлеге мәкаләсендә ул романның йомшак якларын да ачык итеп әйтә, дәлилли.

Газета-журналларда әдипләребезнең юбилейлары унае белән чыккан язмалар шактый күп. Арада әдәби тәнкыйтьне, гомумән, әдәбият белемен баета торган уйлану-эзләнүләр, табышлар да бар. Җәмәгатьчелек Х. Туфанның 100 еллыгы аеруча зурлап билгеләп үтте. Бу унайдан басылып чыккан хезмәтләр арасында Волжскидан Илшат Вәлиулла язмасы игътибарга лаек. Ул Х. Туфанның фәлсәфи лирикасын тикшереп, шагыйрьнең тормыш-чынбарлык, яшәү һәм үлем турындагы уйлануларының эчке мәгънәләрен ачарга омтыла һәм, әйтергә кирәк, кеше тәне, җаны һәм мәңгелек арасындагы мөнәсәбәтләр турында Х. Туфанның шигъри фикерләренә ышандыра. Әлеге мәкалә тагын бер фикергә этәрә: без әдәбият тарихын Көнчыгыш һәм Көнбатыш фәлсәфи фикере һәм эстетикасы белән бәйләп карауга, тикшерүгә тиешле игътибар бирмибез икән. Әгәр безнең язучылар, мисал өчен, урыс, Аурупа, төрек әдипләренең, фәлсәфәчеләренең хезмәтләрен махсус өйрәнәләр һәм беләләр икән (ә моның шулай икәнлеген А. Гыйләҗевнең «Күңелем серләре» язмасында *(«К.У», 2000,—№ 11, 12)* һәм Р. Батулла, *(«К.У», 2000,—№ 2)*, А. Хәлим, *(«Мирас», 2000—№ 8, 9, 10)* мәкаләләрендә телгә алынган исемнәр раслый), бу аларның иҗатына да, бәхәссез, йогынты ясый. Тәнкыйть исә әнә шул бәйләнешләрне дә ачарга бурычлы. Әгәр А. Гыйләҗев күрсәтелгән хезмәтендә үзенең «Балта кем кулында» әсәре тиешенчә бәяләнмәде, тәнкыйть аңлата алмады дип борчыла икән, бу инде җитди уйланырлык мәсьәлә. Бер сәбәп—нәкъ әлеге фәлсәфи-эстетик якның ачылып җитмәве түгелме?

Тәнкыйть әдәбият тарихы һәм теориясе белән тыгыз бәйләнештә яши. Тәнкыйтьтәге гомумиләштерүләр әдәбият тарихына нигез булып торса, аларга хас үзенчәлекләр теоретик нәтиҗәләргә җирлек ролен үти. Шуңа да Ф. Хатиповның «Әдәбият теориясе», Ә. Мәхмүдовның «Матурлык тантанасы», З. Рәмиевнең «XX йөз башы татар әдәбияты: авторлык, төп текст һәм хронология мәсьәләләре», Д. Заһидуллинаның «Әдәбият кануннары һәм заман», «Татар әдәбиятын мәктәптә укыту» китаплары кебек соңгы вакытта дөнья күргән теоретик һәм методик хезмәтләр бу өлкәдәге арттa калуны беркадәр киметә һәм, аңлашылганча, әдәби тәнкыйтькә дә ярдәм итә.

...Әйе, әдәби тәнкыйтьтә соңгы елларда сан ягыннан шактый гына уңай үзгәрешләр күзәтелә. Ә менә сыйфат ягы әлегә канәгатьләнерлек түгел. Мәкаләләрнең күбесенә тарлык, образлы әйткәндә «үз казанында гына кайнау» хас. Әдәби әсәргә бәя биргәндә һаман да аның ниндидер «актуаль» темага язылган булуы үзәктә тора, ә язучының иҗат серләре, әсәрләренең сәнгати үзенчәлекләре читтә кала. Икенче яктан, кызык хәл күзәтелә: тәнкыйть мәкаләсендә теге яки бу әсәр яисә җыентык классика дәрәҗәсенә күтәреп мактала, ә бер-ике елдан аны телгә алучы да юк. Билгеле, әсәрнең уңышлы яклары күрсәтелергә, ачылырга тиеш. Р. Сибатның: «Мин хурлаучы түгел—мактаучы, җимерүче түгел—төзүче, күз йомучы түгел—булганны күрүче... Без болай да күп күз йомабыз, күп җимерәбез инде. Җитәр! Айнып вакыт: мактарга, төзергә, булганны күрергә» *(«К.У», 2000—№ 9)*,—дигән сүзләре белән кайсыбыз гына килешмәс икән. Әмма, шул ук вакытта, шактый йомшак әсәрләрнең китап булып таралуын, театрларыбызның репертуар кытлыгы кичерүен, әдәбиятыбызның әлегә Рәсәй күләмендә тиешле яңгыраш таба алмаганын таныйбыз икән, димәк, борчылырга, сәбәпләр турында уйланырга нигез бар. Ә бу исә тәнкыйтьнең төп бурычы. Шуңа да кимчелек-җитешсезлекләребез турында авыз тутырып әйтә башларга кирәк.

Тагын икенче бер мәсьәлә дә алга килеп баса—язучылар арасында нинди мохит хөкем сөрә? Үзара таләпчәнлек бармы? Ахыр чиктә, үзебезгә карата әйтелгән тәнкыйть фикерен аек акыл белән кабул итә алабызмы? Дөрес, тәнкыйтьче сүзенең ачык аңлаешлы, дәлилле, юк-бар бәхәсләргә урын калдырмый торган булуы да бик мөһим. Ә монысы, үз чиратында, тәнкыйть өлкәсендә эшләүчеләрнең әдәби-эстетик һәм теоретик әзерлеге белән бәйле.

# ХЫЯНӘТСЕЗ ИҖАТ

## ИҖАТ ПОРТРЕТЫНА ШТРИХЛАР

### I

Шулай, әдәби барыш (процесс) үтә дә кызыклы күренеш бит ул... Күнел биштәренә әллә никадәр жилкенү-өметләр төяп яңа гасырга аяк баскан мәлдә, үтеп киткән аһ-зарлы дәверне күздән кичәрсәк, моның шулай икәнлеге бигрәк тә ачык күренә. Шул үткәннәргә күз салсак, күрәбез ки: әдәби мәйданда кемнәр генә ат уйнатмаган да, кемнәрнең генә мангай шәрифләрендә тояк эзләре ярылып калмаган. Әйтик, берәүләр, «корифей» сыйфатында, дистә еллар буе әдәби аргамакның тезгенен үзләренең «ныклы» кулларында тотып килделәр дә, бер каермада тавыш-тынсыз гына иярдән төшеп калдылар. Әллә булган алар, әллә юк... Икенче яктан, бер төрле әдипләр хакында алтмыш-житмеш еллар дәвамында ике-өч кәлимә сүз әйтергә батырчылык итми яшәдек тә (әйтелсә дә, әдәбияттан үтә хәбәрдар ике зат очрашып, бер-берсенә пышылдап кына: «бар иде бөекләремез...» диюдән артмагандыр), менә сиңа мә, хәзер аларның, (үзләре булмаса да!) исемнәре мәйданның кап уртасында; әдәбият хакында үз фикере булган һәр каюсымыз шул бөекләрнең кәчтүн чабуын үпмичә китми. Ә тере бөекләр исә, үз исемнәре тирәсендә барган ызгыш-тартышларга һушлары китеп карап торалар, шомбай-саламторханнар сырып алган мәйданга тап булуларына үкенмиләр дә микән әле?..

Кызык әдәби барыш, кызык... Тора-бара кайбер атлы-дәрәжәлеләрнең дәрәжәләре иҗатларыннан башка гына торып кала, атсызлар ат ала, «йолдызлар» чүпкә оча, билгесезләр «йолдыз»га әверелә. Тоташ әверелеш, тоташ метаморфоза... Әлмисактан бирле шулай булган һәм шулай булып кала килә. Тукайга да, Такташка да, Туфанга да караш, чорына нисбәттә, бер генә төрле булмаган. Әдәби барышның кызыклыгы тагын шунда да күренә: ягъни мәсәлән, әле соңгы елларда гына бер язучымыз Гаяз Исхакыйны татарны адаштыруда, саташтыруда, көферлектә гаепләп ниләр генә язып бетермәде, бүген исә Гаяз Исхакый исемендәге премия бирүләре белән котлаулар кабул итә. Әгәр дә: «Миңа кирәк түгел иде»,—дисә, алдаша, бик тә аласы килә аның ул премияне, үзе тамга сукканча, әйтсәк, «көфер» Гаяз Исхакый исемендәге бүләкне. Чынлап та, андый «идейный» каһарманнарны һич кенә дә аңлап житкерә торган түгел.

Кемнәр килә дә, кемнәр китә... Җаннарны ятим калдырып бер-бер артлы прозабызның «алтын баганалары» булган Ф. Хөсни, Г. Бәширов, М. Мәһдиев, Ә. Еники, Г. Ахунов фани дөньядан бакыйга күчтеләр. Вакытсыз арабыздан киткән Х. Сарьян, Э. Касыймов, Г. Кашапов, Ф. Гыйльми, А. Сафин, Хәйдәр, Г. Сабитов исемнәрен дә санасак, югалтуларыбыз бихисап икән. Олыгайган әдипләребез ачыктан-ачык: «Без инде язасын яздык, әйтәсен әйттек, прозаның язмышы—киләчәк яшьләрдә»,—дип белдерделәр. Берара прозада зәмһәрир бушлык чалымнары шәйләнә башлаган кебек иде. Гариф ага Ахунов гел мактап телгә алган Арча төбәге дә, күп жимеш биргәннән соң ял итү фарызлыгын үтәүче алмагач сыман, әлегә дәшми тора... Шул чагында... Менә шунда халкыбызның талант чишмәләре саекмаганлыгын раслап, Мөслим төбәгеннән Фоат Садриев, Малмыж ягыннан Рафаэль Сибат, Чаллыдан Вахит Имамов, Башкортстанда туып, Казан әдәби мәктәбендә «керенгән» Галимжан Гыйльманов кебек урта буын каләмкярлар мәйданга чыктылар. Проза осталары булып танылган Марсель Галиев, Камил Кәримов, Нәбирә Гыйматдиновны да искә алсак, хәлләр бөтенләй үк мөшкел түгел

икән дип, шөкер итәргә генә кала. Шушы сафның алгы рәтендә танылган каләм остасы Флүс Латыйфиның да булуы әдәби барышны тагын да күркәмрәк итә, ана җегәр өсти, ямь бирә.

...Флүс Латыйфиның үзе белән ныклап соңгы елларда гына танышсам да, хәер... аны инде кырык елдан ашу беләм икән, ләбаса! Курчак театры куйган спектакль вакытында күрдем мин аны, ул чагында сөнге кебек төз гәүдәле, озын буйлы яп-яшь егетне.

Безнең Әмәкәй авылына курчак театры килгән иде. Мөслимнең үзеннән диделәр. Абыйларга ияреп барганмындыр инде: матур җәйге көннәрнең берсендә беренче мәртәбә клуб дигән хикмәтле бинаның тупсасын атлап кергәч, сәхнә алдына тезләнеп утырып карадым мин, ул тамашаны. Тере «артист»ларны да беренче тапкыр күрүем иде. Спектакль мәңге онытa алмаслык булып күңелгә кереп калды. Сәбәбе дә «җитди» иде: тамаша «яхшылык белән явызлык» көрәше хакында иде. Яхшылык—сылу кыз Кукурузбикә (исемен төгәл генә хәтерләмим, ләкин ул мина нәкъ шулай Кукурузбикә булгандыр кебек тоела) дуслары ярдәмендә, явызлыкны җиңеп чыга, димәк ки, шуннан соң илебез дә мул, тыныч тормышта яши башлый. Хрущев заманы бит бу. Әмма истә калганнары анда түгел, башкада иде. Спектакль ахырында ниндидер сәер машина хәрәкәткә килеп, тамашага җыелган бала-чага өстенә кәнфит-печенье яудыра башламасынмы! Менә бусы могҗиза дисәң дә могҗиза иде. «Аһ» итәргә өлгермәдек, «артист»лар, залга чыгып, «өлешсез» калган балаларга күчтәнәч таратып чыктылар. Тагын шунысы истә калган: арадан берсе, озын буйлы, хәрәкәтчән абый, мина ике кәнфит биреп китте. Без бичара бала-чага шушы спектакльдән соң, һәр курчак театрында «күчтәнәч» өләшәләр икән дип исәпли башладык...

Күп еллар үткәч, дөресрәге, үткән ел декабрь аенда гына ул тамашаны безгә Мөслим урта мәктәбенең «Йолдыз» курчак театры күрсәтүен, пьесалар авторы Флүс Латыйпов булуын, кибеттән үз акчасына кәнфит-прәннек алып, балаларга өләшеп йөргән артист абыйның да ул икәнен белеп шаккаттым. Әйтергә кирәк, театр Мөслим төбәгендә генә түгел, күрше-күлән район тамашачылары арасында да дан казана. Башкортстанга да барып чыга. Хәтта ниндидер хикмәт белән чакыру алып, Мәскәүдә дә осталыгын күрсәтеп кайта. Бер мәдәният сараенда аларны, ягъни осталарча спектакль куйган татар авылыннан килгән үсмер-артистларны, кытайлар дип белеп, аеруча алкышлап каршылыйлар.




Әдәбият мәйданына иркен керү өчен, беренче шарт, әлбәттә, шәхес булып өлгереп җитү. Бу яктан алганда, Флүс Латыйфи әдәбиятка зур тормыш мәктәбе үтеп килгән язучы. Иҗатка ул кинәт һәм көтмәгәндә тотынган әдип түгел. Аның ныклы иҗат эше белән шөгыльләнә башлавы мантыйкка сыешлы, законлы күренеш, чөнки әдәбият белән ул кечкенә чагыннан, хәреф таный башлаган вакытыннан ук кызыксына. Бу җәһәттән тагын бер истәлегем белән уртаклашыйм әле.

Моннан ун еллар элек булыр, «Аргамак» журналында эшләгәндә, редакциягә бер ханым килеп керде. Тәзелеш идарәләренең берсендә бүлек җитәкчесе икән. Мөслимнән. Урта мәктәптә укыганда,—ягъни илленче еллар ахыры, алтмышынчы еллар башы була бу,— мәктәптә әдәбият-иҗат берләшмәсе оешуы, берләшмәнең күп тиражлы журнал чыгаруы хакында сөйли-сөйли, сүзләрен расларга теләгәндәй, Розалия ханым өстәлгә уңлап мәҗмуга таратып ташлады. Вакытлар узып саргайган рәсемле дәфтәрләрнең тышына, төсле зур хәрефләр белән «Күнел энҗеләре» дип язып куелган. Журналның әдәби-иҗат берләшмәсе органы булуы, берләшмәнең җитәкчесе

һәм редакторы Флүс Латыйпов икәнлеге искәртелгән. Журналның чыгу датасы, тәртип саны, тиражы, бәясе күрсәтелгән, барысы да басмаханә кануннарына туры китереп эшләнгән. Кыскасы, менә дигән «самиздат». Аннан бер шигырь истә калган. Сюжеты гади—кышкы буранлы, салкын көндә бер малай урманга чыгып китә һәм яшел чыршыларга сокланып карап торганнан соң болай ди:

Әллә нигә, яшел төсне күрсәм,
Күнелемдә тылсым, сер арта...

Баксаң, Флүс Латыйфи шагыйрь дә икән бит әле, аның фикри моңхис чишмәсе менә кайдан башлана икән...

Әйтергә кирәк, Мөслим төбәгендә туып-үскән кеше буларак, якташым Флүс Латыйфиның иҗатын җентекләп күзәтеп барам. Әйе, иҗади уңышларына сөенерлек аның. Мөдәррис Әгъләм бер кичәдә сәхнәдән торып: «Мөслимнәремнән уңдым!»—дип белдергән иде. Мөслим «үзе» дә Флүс Латыйфи шикелле талантлы язучы үстерә алуы белән хаклы рәвештә горурланадыр дип беләм.



*Мөслим урта мәктәбендә эшләп килгән «Беренче чәчәкләр» әдәбият-иҗат түгәрәге членнары. Житәкчесе—әдәбият укытучысы Б. Шакирова (уртада), Ф. Латыйфи (икенче рәттә, сулдан икенче). 1958 ел.*

Флүс Латыйфиның хикәяләре, шигырьләре, төрле актуаль темаларга язылган мәкаләләре һәм очерклары республика матбугатында күп еллардан бирле даими басылып килә. «Кырагай» исемле беренче җыентыгы 1988 елда дөнья күргән иде һәм ул җәмәгатьчелек тарафыннан әдәбиятка үткен каләмле, сыгылмалы, шигъри телгә, үзенчәлекле фикерләү сәләтенә ия язучы килүен раслаучы вакыйга буларак кабул ителде. Шушы беренче җыентыгын укыганда ук аның язу куәсендә Фатих Хөсни, Хәсән Сарьян кебек тел осталарының шифалы йогынтысын тоясың. Әмма сурәтләүдә, хикәяләүдәге иҗат алымында ул үз юнәлешен тапкан әдип. Шул ук елны «Вөҗданыңнан сора» дигән китабы да басылып чыга. Очерк һәм публицистик мәкаләләр тупланган бу җыентык өчен язучы 1989 елда Татарстан журналистларының Хөсәен Ямашев исемендәге премиясенә лаек була. 1992 елда Ф. Латыйфиның күләмле «Ак-карага тимәскә» исемле китабы да укучыларга барып ирешә. Әлеге җыентыкны, шартлы рәвештә, язучының иҗатындагы башлангыч чорга йомгак дип тә карарга була. Бу чорда ул күбрәк үзе күргәнкичергән вакыйгаларга мөрәҗәгать итә, ягъни иҗатында, башлыча, биографик материаллардан файдалана. Яшермим, соңгы елларда кайбер каләм әһелләренең әсәрләрендә геройларны авторның күңелендә туган абстракт дөньяда яшәтеп гайре гамәлләр кылдыру, шуны тормышта булган яки булырга мөмкин дип укучыга тәкъдим итү таралыш таба. Шунысы бар, мондый әсәрләр укучыны хакыйкатьтән ераклаштыралар, дөреслекнең күзен томалыйлар. Андый әсәрләрдә вакыйгалар авантюр яссылыкка күчә, аларда агрессив романтизм өстенлек итә; сюжетка карап, үтә фаҗигале, йә кирәкмәгән идиллик чишелеш зиһенне саташтыра. Андый авторлар нинди рәк тормыш юлы үткәннәрдер, әмма Флүс Латыйфи мәгънәле гомер кичерә дип әйтә алам.

Флүс Фатыйх улы Латыйпов Икенче дөнья сугышының дәһшәтле, авыр көннәрендә—1943 елның 3 июнендә туган. Туган җире—алкын Ыгы, салкын чишмәләре, тугайлы болыннары, калын урманнары белән дан тоткан, табигатьнең ин гүзәл җирләреннән саналган, җырга-моңга бай тарихи Мөслим ягы.

Беренчедән, Ык елгасы үзенең ашкынулы агышы, бозлар актарылып аккан ярсу язлары белән күңелгә уелып калса, шул хисләр җанны әллә кайларга ашкындырса, илһамландереп торса, икенче яктан, тирә-якта галәми битарафлык белән Урал тауларының дәвамы булган мәшһүр калкулыклар таралып ятуын күреп, дөньяның без уйлаганга караганда күпкә катмарлы һәм үзгәрәк икәнен тоеп җан салмаклана, каударлана, сабырсызлана.

Шушы хиссият эчендә кайнаган Флүс исемле малай бер борчусыз уйнап кына үсмәгәндер (чоры ул түгел); бер капчык арыш яисә бодай салып, зәмһәрир суыкларда бәләкәй чана тартып Бишнарат тегерменәнә йөргән чакларында, Нарат Асты урманнарында кышлык утын әзерләгәндә, әтисе белән парлашып пычкы тартканда күңеленә гамь тулгандыр; тауларына менгәндә төрле-төрле уйлардан гаҗиз булгандыр. Кыскасы, кулы каләмгә үрелгән көнгә барып ирешкәндә, яшь башына чордашларына җиткерерлек хәйран сүз-фикер җыелгандыр.

Мөслимдәге урта мәктәпне тәмамлагач, ул Алабуга дәүләт педагогия институтының филология факультетына укырга керә. Ләкин әле Икенче бөтендөнья сугышыннан соң мантып та җитмәгән ил өстендә тагын болытлар куера, бөтен дөньяны атом һәлакәте алдында калдырган мәгълүм Кариб кризисы башлана. Һәм Флүсебез дә әнә шул кризисның шомлы тәгәрмәчләре арасына кереп китә. Меңнәрчә башка студентлар шикелле үк ул да икенче курстан армиягә алына. Ләкин уку дигән хикмәтле шөгыль армиядә дә тынгылык бирми, сугышчан дежурлыктан буш вакытларында ул үзлегеннән немец телен өйрәнә башлый. Иң зур хыялы армия хезмәтеннән соң чит телләр институына укырга керү, дөнья гизү, чит җирләр, яна илләр белән танышу була. Үткен зиһенле, тырыш егетнең әлеге мавыгуын командирлары да күреп ала, теләген ике куллап хуплыйлар, ярдәм итәргә алыналар. Аны—хәрби хезмәттәге егетне—ике көнгә институтка җибәрәләр. Бер елга җитәрлек немец теле дәресләрен магнитофон тасмасына яздырып кайткан егет баш-аягы белән чит тел дөньясына чума. Тагын бер елдан инде ул экстерн рәвешендә чит телләр институтының беренче курсы өчен имтиханнарын да тапшырып кайта. Флүс Латыйпов өчен яшел ут яндырыла, юллар ачыла. Бәхеткә каршы диик, ул акылына килеп, армиядән соң документларын Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына алып кайтып тапшыра. Бу гамәле хәерле сәгатьтә булгандыр, кешедә сәләт оеткысын үтә дә сизгер тоемлаучы галим, әдәбият белгече профессор Хатип Госман фатихасы белән ул, имтихан да биреп тормыйча, татар теле һәм әдәбияты бүлегенең турыдан-туры икенче курсына кабул ителә. Аны 1969 елда уңышлы тәмамлый. Укыган елларында ук матбугатта эшли башлый. 1967-1968 елларда «Татарстан кооператоры» исемле республика потребкооперациясе газетасендә әдәби хезмәткәр була, шул елларда милли хисләр белән адарынып йөрүнең ни-нәрсә икәнен үз башыннан кичерә. 1968 елдан Татарстан радиосында: репортер, мөхәррир, яшьләр өчен тапшырулар редакциясен җитәкли. Республикада ул булмаган район сирәктер. 1985 елның сентябреннән Ф. Латыйфи «Социалистик Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасендә эшли башлый; тагын бер елдан «Казан утлары» журналына күчә, бүлек мөхәррире, җаваплы сәркәтип вазифаларын башкара. 1991 елда латин хәрефләре белән «Dөnja» дигән халыкара татар газетасе чыгарыла башлагач, баш мөхәррир



*Ф. Латыйфи Татарстан радиосы корреспонденты. 1983 ел.*

урынбасары итеп чакырыла. Шунысын да әйтеп китү урынлы булыр, Ф. Латыйфи латин графикасын гамәлгә кертүнең татар мәдәниятенә файда китерәчәгенә ина-нып, жигелеп, конкрет эш алып баручы сирәк энтузиастларның берсе. Тагын бер елдан Флүс Латыйфи яңа чыга башлаган республика газитәсе «Татарстан хәбәрләре»нең әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире итеп билгеләнә, ә 1993 елның ноябрендә теоретик, ижтимагый-сәяси һәм әдәби-публицистик басма—"Татарстан" журналының баш мөхәррире урынбасары итеп раслана. Журналның чын мәгънәсендә әдәби-публицистик төсмер алуы, әдәбиятка, мәдәнияткә йөз белән борылуында аның өлеше зур. 1997 елдан язучы яңадан «Казан утлары» журналы редакциясенә чакырыла һәм бүгенгәчә баш мөхәррир урынбасары булып эшли. Күренгәнчә, бигрәк тә үзгәртеп корулар башланганнан соң, Флүс Латыйфиның исеме татар демократик матбугаты үсеше белән аерылгысыз. Шушындый тынгысыз дәвердә ул яңадан-яңа әсәрләр ижат итә.

Татар дөньясын шаулаткан, Флүс Латыйфины икеләнүсез зур әдипләр сафына куйган әсәре—1993 елда Татарстан китап нәшриятында ул чор өчен генә түгел, бүгенге көннәр өчен дә «коточкыч» тираж белән (50000 данә) басылып чыгып, тиз арада таралып беткән «Хыянәт» романы булды. Роман 2000 елда югары зәвык белән «Мәгариф» нәшриятында кабат басылды һәм ай күрде, кояш алды, әлеге затлы китапны да сатудан табып булмый. Аннан әдипнең бер-бер артлы «Чура Батыр» (1993), «Тамга»—«След» (1996), «Уяну»(1998) китаплары, «Казан утлары» журналында «Ишелеп төшкән бәхет» романы (1999) «Бәйсез этләрне атарга» әсәре (2000) дөнья күрде.

Әдәби тәнкыйть Флүс Латыйфи ижатына игътибарлы булды дип әйтмәс идем. Әсәрләре урта мәктәп, югары уку йортлары программаларына кертелеп өйрәнелгән, фәнни мәкаләләрдә, диссертацияләрдә еш телгә алынган язучы ижаты хакында төпле тикшеренүнең күренгәне юк әле.

## II

Флүс Латыйфины әдәбиятка үзгәртеп кору жилләре алып килде, дип исәпләүчеләр дә бар. Бәлки, бу дөрестер дә. Социализм шартларында цензура дигән монстр белән көн дә күзгә-күз очрашкан кеше буларак, күңелендә жыелган бар ашкынуларын, дөньяга карашын, ризасызлыгын кәгазьгә түгә алыр идеме ул? Юктыр, мөгаен. Ә менә аз гына мөмкинлек булып, сулыш ачыла төшкәч тә, бер-бер артлы әсәрләр ижат ителәә, әдәби жәмәгатьчелек аның һәр әсәрен күтәреп ала, вакыйга буларак кабул итә. Искәртеп китү зыян итмәс, кыюланып, үзгәртеп коруның беренче чорында сүз сөйләп йөрүчеләр күп булса да, уйлаганнарын язып, теркәп калдырырга батырчылык итүчеләр аз иде. «Дөнья хәлен белмәссең, бүген болай ул, иртәгә тегеләй... Агач башын жил бора, адәм башын сүз, дигәндәй...» Болай фикер йөртүнең "нигезле" булуын 1991 елның август вакыйгалары ачык күрсәтте. Гел «демократик» булып беткән басмалар тарихка ГКЧП дип кереп калган 19-22 август көннәрендә ниләр яздылар икән, үзгәртеп кору романтикасы белән адарынып, үз тавышларын шактый ачык ишеттерергә өлгергән кайсы әдипләр башына кусәк күтәреп өлгерделәр икән? Боларны киләчәктә кем дә булса өйрәнер әле. Үземә калса, мәсәлән, ул көннәрдә Чаллыда чыккан һәм иң хөр фикерле саналган гәзиттә «артык кинәеп» язганнарымны хөкем итә башлаганнар иде инде. Ни өчен язам? Нәкъ шул чорда Флүс Латыйфиның торгынлык чорының бар гариплеген күрсәткән әсәре дөнья күрде. Авторын күрмәсәм дә, аны фикердәшем, таянычым дип хис иттем.

«Ак-карага тимәскә» повесте язучының ижатында аерым урын тота. Язучының күләмле тәүге әсәрләреннән берсе буларак, әдәби эшләнеше ягыннан кимчелекләрдән дә азат түгел иде ул. Төп герой Рәис Хаков әле схематик калыпланган, эш-гамәлләре әсәр тукымасына табигый үрелеп бармый, күбрәк автор ихтыяры белән хәрәкәт итә. Шулай да яна геройны эзләү юлында бу әсәр, һичшиксез, авторның унышы дип бәяләнергә хаклы. Әсәрдә вакыйгалар үзгәртеп коруга кадәр башланып, бу хикмәтле реформа игълан ителгәннән соңгы ике-өч елны үз эченә ала. Хәзер кайберәүләр: үзгәртеп

коруга йөз тоткач та, илдә демократия җилләре исә башлады, тел ачылды, ни теләсәк шуны әйтә, яза башладык, дип ычкындыргалыйлар. Алай ук түгел шул. «Ак-карага тимәскә» уены тормышның бар катламнарына тирән үтеп кереп, бу уенны шулкадәр оста оештыручы номенклатура барлыкка килгән иде. Ул төзек системаны тәшкил итә һәм бу тутыкмас-күгәрмәс чылбырның асыл буынын журналистика, халыкның аңын-зиһенен томалап торуга корылган «хәбәрдарлык» чаралары тәшкил итә иде. Уен әле бүген дә аз гына үзгәргән шәкелдә яшәп ята, чәчәк ата. Козьма Прутков: «Тамырына күз сал!»—дигән. Шуның кебек Флүс Латыйфи «табу» дәрәҗәсенә җиткерелгән «радио» дип аталган серле йортка алып керә безне, торгынлык чорының рупоры булган оешманы эчке яктан ачып бирә. Мондый "ачыклык" өчен рәхмәт сүзе ишетергә туры килмәгәндер авторга.

Гаиләдә дә, совет мәктәпләрендә дә (ВУЗны да кертеп) Рәис Хаковны гадел, дөрес булырга өйрәтәләр. Җәмгыятькә иң гүзәл әхлак нормаларына ия булган белгеч кирәклегенә чын күңелдән ышанган яшь журналист радио бусагасын атлап керү белән бөтенләй икенче тормышка килеп эләгә. Аңа хезмәт юлын журналистикада әлифне таяк дип белмәгән җитәкче кул астында башлап җибәрергә туры килә. Басыйров һәнә-ри яктан надан булса да, системаның турылыклы бурзае, аның өчен хезмәткәрләр—көтүдәге сарыклар, партия-совет түрәләреннән калган сөякне кимереп-ялап симергән бурзай бичара «колларын» һәрдаим игътибар үзәгендә тота, ялгыш кына да читкә аяк атлау мөмкин түгел. Рәискә фәкать җитәкченең «особый» ышанычын» казанган хәлдә генә хезмәттә һәм шәхси тормышында ниндидер уңышларга ирешү мөм-кинлеген искәртеп куялар. Үрнәк тә бар—мондый «ышаныч»ны казанып өлгергән Синәкәев ул. Авылда туып-үскән, карап торуга сүздән чыкмаска охшаган, тырыш егетне күргәч Басыйров күңелендә башка уй-ниятләр дә уяна. Үз тирәсендә ниндирәк үрмәкүч пәрәвәзе үрелгәнен башына да китереп карамаган Рәис Хаков исә эшкә чума, беренче чыныгу, беренче сабакларны ала. Яшь җан хөрлек тели, эшкә дәрт бар, белем җитәрлек, ник әле ул кем әйткәнгә генә карап торырга тиеш? Аның үз сүзен әйтәсе, җитешсезлекләргә каршы көрәшәсе, сәбәпчеләрен ачып саласы килә дә бит... Хезмәт вазифаларын намус белән башкаручы һәркемнең коточкыч көчкә ия Системада кечкенә генә шөреп икәнен аңлар дәрәҗәдә түгел шул әле ул. Шөреп буласы килмәү, һәр нәрсәнең тамырына төшәргә омтылуы «яндыра да инде аны. Тышкы дөньядан өч кат тәрәзә белән аерылган бинада яшь егеткә артык җәелергә ирек бирмиләр, бер-бер артлы җәнҗал-интригаларга алып керәләр. «Матур яшәүнең» серен ачып биргәндә дә һаман үзенекен тукып торган киребеткән «хәсрәт журналист»тан үч алу өчен мең дә бер сәбәп табылып тора. Бер карауга Беляева, Хөснетдинов, Марат кебекләрдән бу дөньяда бер нәрсә дә тормый кебек, менә шуларның тәпиләренә китереп басып кара әле син, күрсәтерләр алар нинди көчкә, нинди кодрәткә ия икәнлекләрен. Бөтен хикмәттә шунда ки, әсәрдә сурәтләнгән хәлләрнең «торгынлык» дип аталган чорда түгел, үзгәртеп корулар башлангач булуы уйланырга азык бирә. Чынында исә система җимерелмәде, юкка чыкмады, киресенчә, Рәис Хаков кебекләрне сыта-изә һаман яши, фәкать косметик төзәтенү аркасында йөзен-чыраен гына үзгәртте. Флүс Латыйфи моны сиксәненче



*«Dөnja» газетасының беренче саны чыгу тантанасында. Сулдан уңга: «Сөембикә» журналы баш редакторы Р. Туфитуллова, Төркия бизнесмены Ф. Бичури, артистка А. Илһамова, язучылар М. Мәһдиев һәм Ф. Латыйфи. 1992 ел.*

еллар ахырында ук тасвирлап бирә алды, кисәтеп куйды, әмма бу нәрсәләргә игътибар итәргә әле безнең вакытыбыз юк. Әллә кычкырып әйтергә шикләнәбезме? Кыскасы, «Ак-карага тимәскә» уены дәвам итә...

Рәис Хаковның бу көрәштә җиңеп чыгуын күрсәсе килә, әлбәттә. Кызганычка каршы, алышта, артык күп көч сарыф итмичә, Басыйровлар кланы, димәк система өскә чыга. Монда тормышчанлык ярылып ята. Социалистик реализм ысулы белән язылган әсәр булса, Хаков теләктәшләр табып, партия боссы хуплавын тойган хәлдә, барысын да пыран-заран китереп, тар-мар итеп бетерер иде. Әсәрдә ул ялгыз кала, ярдәм итү түгел, ахырда аның хәлен белергә теләүче дә табылмый. Күңегелгән тормыштан берәүнең дә аерыласы килми. Тормышта татлы ялган ачы хакыйкатьтән кадерлерәк шул.

Повестьта хыянәт темасына да тап булабыз. Соңрак бу тема язучы иҗатында тагын да үстерелде, төрле төсмерләре ачыкланып, тулы бер әсәргә нигез булып ятты.

Флүс Латыйфи өлгергән «прозаик» буларак танылды, укучылар арасында популярлык казанды. Казан ханлыгының мөстәкыйль дәүләт буларак яшәгән соңгы унҗиде елында гаять четерекле вакыйгаларны эченә алган, ике яшь йөрәкнең кайнар мәхәббәт тарихы, егет белән кызның катлаулы маҗараларын тирән психологик кичерешләр аша зур осталык белән тасвирлаган «Хыянәт» романы 1991 елны «Казан утлары» журналында дөнья күрде һәм укучыларның яраткан әсәренә әверелде.

Беренче карашка сүз мәхәббәт хакында барса да, әсәрдә гаять катлаулы һәм әһәмиятле проблемалар күтәрелә. Хыянәт нигезендә гомерләр кыела, мәхәббәт мәхшәргә әйләнә, дәүләтләр юкка чыга. Хыянәт белән табылган бәхет—бәхет дип аталырга хаклымы, ул озын гомерле була аламы? Әсәрне укыганда, шундый сораулар бер-бер артлы туып тора, уку барышында, һәркем үз чамасыннан чыгып, аларга җавап та таба. Әсәр хакында әдәбият галиме Х. Әшрәфҗанов болай яза: «Романда тарихи шәхес булган Кол Шәрифкә зур урын бирелә. Ул рухани җитәкче буларак кына түгел, ә олуг галим, ватанпәрвәр, Казанны саклаучыларның, азатлык көрәшенең идеологы буларак та күз алдына килеп баса. Аның Иван IV гаскәрләренә каршы көрәшне җитәкләве тарихи чыганаклар белән раслана. Башка тарихи шәхесләр (Сафа Гәрәй хан, Ядегәр хан, Чапкын морза, Япанчы би, Камай морза, Иван IV, Адашев һ. б.) вакыйгаларда катнашсалар да, әсәрнең төп герое—сәүдәгәр Сәет—Углич сәүдәгәре Савелий Кузьмичның мәхәббәт язмышы белән Казанга килеп төпләнгән, мөселман диненә күчкән төпчек улы Санька (Александр Булгаков). Чор вәзгыяте, сулышы, тарихи колорит аның уй-кичерешләре, гамәлләре аркылы бирелә.

Икенчедән «Хыянәт»—югары дәрәҗәдә психологизм белән сугарылган тарихи роман.

Өченчедән, акрынлап традициягә әверелә барган Казан-Мәскәү мөнәсәбәтләрен бәян итүгә төп игътибар бирелми, ул, ике дәүләт идеологиясенең каршылыклары буларак, күпмедер дәрәҗәдә ике бертуган Василий һәм Сәет (Санька) мөнәсәбәтләрендә чагыла. Тышкы-сәяси вакыйгалар белән мавыкмыйча, Казан өчен 1552 елның көзендә барган сугышны сурәтләү, хәтта аның нәтиҗәсе белән түгел, ә дәвамы белән әсәрне тәгалләү дә бу очракта тулаем аклана.

Хыянәт!.. Бу сүзнең мәгънәсе романда төрле масштабта, төрле яссылыкта чагыла. Исем җисемгә туры килә. Бу—Саньканың мәхәббәт хакына үз диненнән, иленнән, әти-әнисеннән, туганнарыннан, ахыр чиктә, үзе тәрбияләнгән идеологик мохиттән ваз кичүе дә, Камай морзаның ватанын сатып, дошман ягына чыгуы да, әсәр ахырында ике бертуганның бер-берсен һәлак итүе дә.

Әсәрнең символик һәм мәгънәви бөтенлеген тәэмин итүче чикләре, башы һәм ахыры сәүдәгәрлек тамгасы белән бәйләнә; вакыйгалар тамгадан башлана, тамга белән тәгалләнә (Казан өчен барган көрәшнең тәмамланмый калуы белән бутамаска кирәк!).

Романның кыскача эчтәлеге түбәндәгедән гыйбарәт.

Казан. Сәүдә бара. Болакка чит мәмләкәтләрдән килгән көймәләр керә. Алардан кара киемле сәүдәгәрләр чыга. Шуларның берсе белән Сәет

кәрвансарайда очраша. Ул Сәетнең бертуган абыйсы, Углич сәүдәгәренең улы Василий Булгаков булып чыга. Васька энесен таный. Әчәләр. Бер-берсен чак кына үтерми калалар. Хикмәт Саньканың ата-анасыннан, иленнән, диненнән ваз кичеп, Казанда төпләнүендә: ул Гөлйөземгә гашыйк була, мәхәббәт хакына ислам диненә күчеп, Сәет дигән мөселман исеме ала. Шулай итеп, Александр Савельич Сәет Сәлим углы булып китә, әлбәттә, Кол Шәриф ярдәме, хәер-догасы белән. Гөлйөзем белән Сәет гаилә коралар, Җәгъфәр белән Галия исемле балалар үстерәләр. Тик куанычлы тормышны фаҗига бүлә—Казан өстенә Явыз Иван гаскәрләре ябырыла. Икеләнүләрдән соң Сәет гайрәтләнеп Казанны саклаучылар сафына баса. Хатыны Гөлйөзем белән углы Җәгъфәр дә, корал алып, дошманга каршы китәләр. Өйдә табиб карчыгы белән авыру кызлары Галия генә кала.

Абыйсы Василий исә Казанны камаучылар арасында. Ул аларны азык-төлек белән тәэмин итә. Көтмәгәндә аның карашларында тамырдан борылыш була. Василий, урысларның Казанны алу планының кайбер мөһим детальләрен күрсәтеп, Казан ханы исеменә хат яза; ханга хезмәткә күчәргә әзер икәнен өстәп яза да, хатны укка төреп, укны шәһәр эченә очырта. Хат Кол Шәрифкә барып эләгә. Тик урыс сугышчылары үзәгендә булган Василий чарасыз кала. Чарасызлыктан, төскә-биткә танымыйча, энесенә каршы ташлана. Агай-эне, белештермичә, бер-берсен үтерәләр. Үлем алдыннан энесе абыйсын таный, тик икесе өчен дә соң була...»

Татар әдәбиятында тарихи әсәр язучылар күп булмаса да, аларның милләтнең үзанын үстерүгә керткән өлеше бәяләп бетергесез. Ул шуның белән дә аңлатыла, тарихи әсәрләр язарга алынган әдипләребез укучыда милли иманга нигезләнгән әдәби зәвык тәрбияләп кенә калмыйлар, ә бәлки халык арасында аерым популярлык казанган мәгърифәтче миссиясен үтәүләре белән дә ихтирамга лаеклылар. Әсәрләре ялганга корылмыйча, озак вакытларга сузылган тикшеренү-эзләнүләр нәтиҗәсе буларак, тарихи фактларга нигезләнгән булыр, моның шулай икәнен профессиональ тарихчыларның теге яки бу мәсьәлә хакында язганда, иллюстрация сыйфатында татар язучыларының тарихи әсәрләренә мөрәҗәгать итүләре дә раслый. Ә менә урысның В. Пикуль кебек тарихи китаплар язуны конвейер дәрәҗәсенә куя алган язучыларны урыс тарихчылары үзләре үк «шарлатаннар» дип кенә атыйлар. Хәтта ки, милли хәрәкәтнең иң күтәрелгән романтик чорында зиһеннәребезне шактый илаәсләндереп өлгергән «Кыпчак кыры әреме» әсәре хакында академик Миркасыйм Госманов: «...Тарих өлкәсендә намуслылык һәм намуссызлык төшенчәсе дә бар. Һәм ул әлеге ике өлешнең кайсы ягына күбрәк авышу белән билгеләнә. Соңгы елларда чәчәк атып, киң таралган фальсификацияләр җөмләсеннән булган «Кыпчак кыры әреме» ише нәрсәләр исә элекке «яртылашларны» бер читкә ташлап, тарихи белемне миф-әкиятләргә әверелдерү омтылышыннан туган нәрсә генә. Дөрес, андый әсәрләрнең шактый сәләтле каләм белән оста итеп язылганнары да була. Морат Аҗиның китабы шундыйлардан...»—дип язуы юктан гына түгелдер. Тарихи дип аталган бөтен әсәргә дә чынбарлыкта булган хәлләр тасвирлангандыр дию, йомшак әйткәндә, артык самимилек ул. Флүс Латыйфига килсәк, аның «Хыянәт» романы фаразлардан да азат түгел; тик шунысы кызык—әсәр тукымасына килеп кергән автор фаразлары да чынга аша бара. Мисаллар эзләп ерак барасы юк. Соңгы елларга кадәр, тарихи язмаларда Казан шәһәренең стеналары уникенче гасырда ук таш булган дигәнрәк мәгълүматлар күренгәләсә дә, урыс «белгечләрен»ә ияреп, рәсми тарих Иван IV яу белән килгән көннәр дәверендә Казан кремле агач нигытма белән әйләндереп алынган дигән карашны алга сөрә килде. Романда Флүс Латыйфи кремльнең калын таш диварлы булуын, Казанны яклаучыларның туплардан галәмәт дәү таш җәдрәләрне дошман өстенә яудыруларын тасвирлый. Кайберәүләр моны уйдырма дип кенә бәяли килделәр. Үткән ел Казан кремле янында барган казу эшләре вакытында археологлар ханлык чорына караган гаять калын һәм зәвык белән эшләнгән таш стена калдыкларына, кирмән эчендә атылмый калган дәү җәдрә запасларына тап булдылар. Димәк, авторның күзаллавы, фаразлары тулысынча расланды! Тарихи дөреслек мәсьәләсе хакында филология фәннәре

докторы Т. Галиуллин болай дип язган иде: «Гегель тарихи материаллар белән шөгыльләнүче кешеләрне үткәнне күрәзәлек итүче пәйгамбәр дип атый. Чыннан да, тарихи вакыйга, хәйлә белән эш йөртә алмый, аның нигезендә анык концепция, зарури мәҗбүрият ята».

Автор агачлар артында урманны, аерым хәлләр, вакыйгалар куелыгында тарихи закончалык буларак вакыт хәрәкәтен сиземли, күрә белергә тиеш.

Тарихи үткәнне инләүне бүгенге көн мәнфәгатьләре, ихтыяжлары таләп итә. Эпик вакыт белән үзара кушылып, аралашып, бик күптәннән булып узган хәлләрне хәзерге кеше яшәгән мәшәкатьләргә китереп бәйли. Укучы романның исеме, беренче битләре буенча ук якынча анда нәрсә турында сүз барачакны сиземли һәм үзенең үзәккә алынган чор, анда урын алган вакыйгалар, геройлар турында элегрәк белгәннәрен эшкә җигә, мәдәни катламны уята. «Хыянәт»нең геройлары вакыт-вакыт белән безнең көннәр, янартып кору, империяне таркату чоры кешеләре теле белән сөйләп, фикерләп куялар. Бу табигый, чөнки Казан ханлыгының вәхшиләрчә, кыргыйларча юкка чыгарылуы тарихын белмичә, андагы алдынгы һәм кара көчләр хәрәкәтенә төшенмичә җөмһүриятебезгә тулы мөстәкыйльлек алу кыен булачак.

Кол Шәрифнең урыслар белән орыш алдыннан гаскәр башлыкларына, дин әһелләренә мөрәҗәгатен укып карыйк. "Инде янә шунысын да фараз итик, Казан кеби көчле, шанлы, тамыры нык мәмләкәтне тар-мар китергән көчургылып Идел буйлап китәр, Хазар, Азак, Кара диңгез ярларына таралыр. Ары таба—көнчыгышына таба, тамыры нык мәмләкәтләр юк... мул ризыктан бу кавем котырып үрчер... Хәзергә без сан ягыннан бер чама. Тора-бара икелатә, соңра, өчлатә, янә дүртлатә кимербез. Коллыгыбыздан котылмасак, тора-бара унлата... шулай дәвам итәр. Иң яхшы угыл-кызларыбыз коллыктан котылу өчен христиан кавеменә күчәр... Без шушыны телибезме?!" Тарих дин башлыгының күрәзәлеген тулысы беләнаклады.

Кол Шәрифнең мөрәҗәгате бер яктан караганда, әсәрнең иң югары фәлсәфи ноктасы, зирәк бабаларыбызның бүгенге көнгә килеп житкән васыяте, ил-халык язмышы хакында оран салу буларак яңгыраса, икенчедән, язучының телне югары кимәлдә белүен, аның җегәрен, көчен яхшы тоеп эш итүен күрсәтә. Теле булмаган каләмкяр язучы саналырга да тиеш түгел. Тарихи әсәр язарга тотынган каләм әһелләренең кайсыберләрендә нәкъ менә тел мәсьәләсе аксый. Иң эч пошыргыны—тарихи колорит бирәбез дип, әсәрне иске сүзләр белән чуарлап, корама тел белән язу. Бу яктан алганда, Флүс Латыйфи матур әдәби телгә ия булган сирәк язучылардан санала.




*«Хыянәт» романының икенче басмасы. «Мәгариф» нәшрияты, 2000 ел.*

Х. Әшрәфҗановка өстәп шуны да әйтәсе килә: «Хыянәт» романында колорит башка факторлар—кием-салым, көнкүреш әйбер-карасын, дәүләт төзелеше, идарә итүнең ханлыкка хас сыйфатларын белеп сурәтләү ярдәмендә дә ирешелә. Автор бу мәсьәләне җентекләп өйрәнгән, чорны «вак-төяк» детальләр ярдәмендә дә ачып булуын оста итеп күрсәтүгә ирешкән. Тагын игътибарга лаек нәрсә—автор тарихи документларны яхшы белә, аларны әсәр канвасына урынлы кертеп җибәрә. Кыскасы, роман бөтен булмышы белән Казанны яклаучы каһарман бабайла-рыбызга, кыю йөрәкле, сөя дә, сөйдертә дә белгән, кирәк булса яуга ташланып ил бәйсезлеге хакына үзләрен корбан итүдән дә курыкмаган хатын-кызларыбызга дан җырлый, хыянәт юлына басканнарга нәфрәт, каргыш буларак кабул ителә.

1993 елны әдипнең тагын бер китабы 50000 данә тираж белән басылып чыкты. Анысы—«Чура Батыр» дастаны. Ф. Латыйфи,

әдәбиятыбызда беренче тапкыр буларак, Добружа татарларының халык авыз иҗатына мөрәҗәгать итә, Румыниядә аеруча киң таралган «Чура батыр» дастанын Казан татар әдәби теленә күчерә, Румыниядә яшәүче милләттәшләребез тарихына, аларның бүгенге яшәеш вәзгыятенә багышланган «Бер ананың игез уллары» дигән күләмле мәкалә яза. Әлеге китап әнә шул тәрҗемә һәм мәкаләне берләштерә. Китап бигрәк тә галимнәребез тарафыннан игътибар үзәгенә алынды, дастанны фәнни өйрәнү юлында мөһим вакыйга буларак бәяләнде.

Язучының Казан университеты галиме Ринат Якуш белән хезмәттәшлектә язылган «Тамга», «Игезәкләр», «Соңгы кисәтү» дигән фәнни-фантастик повестьлары да татар әдәбияты өчен яңалык булды. Катлаулы, мавыктыргыч сюжетка корылган әсәрләр укучының мажаралары белән генә түгел, бәлки бүгенгене үткәннәргә тоташтыручы хыял һәм чынбарлык турында фәлсәфи уйланулары белән дә җәлеп итте. Повестьлар бай, йөгерек тел белән язылганнар, җиңел укылулары белән дә яшүсмерләрнең яраткан әсәрләренә әверелделәр. Алар бер-бер артлы башта "Идел" журналында Танир Сүлф тәхәллусе белән басылып чыкканнар иде. Ул чагында "Кем икән бу сәер исем-фамилияле яшь язучы?" дип баш ватучылар аз булмады кебек. Чөнки йөгерек тел белән язылган әсәрләр бер дә монарчы күзгә-башка чалынмаган авторны хәтерләтми, аларда фикер үткенлеге, тыгыз сюжет, композиция кору осталыгы, телгә маһир каләмкяр кулы ачык тоемлана иде. Әсәрләр шул ук елны рус теленә дә тәрҗемә ителә бардылар һәм, ниһаять, 1996 елда берьюлы ике телдә—татар һәм рус телләрендә «Тамга—След» исеме белән аерым китап буларак дөнья күрделәр. Флүс Латыйфи әдәбиятта шундый «мөгез» чыгарырга һәвәс сирәк язучыларның берсе икәнлеген тагын бер мәртәбә раслады.

Язучы һәм публицист Ф. Латыйфиның әдәби иҗат һәм журнал редакциясендә җаваплы вазифа үтәүдән тыш, тагын бер гаять олы эше бар, ул татар яшьләренең «Сәләт» хәрәкәтен оештыручыларның берсе. Балалар һәм яшьләргә милли тәрбия бирүдә актив катнаша, аларның милли үзаңын үстерү юнәлешендә нәтиҗәле эшли. 1995 елдан бирле балаларның җәйге «Сәләт» лагерьларында «Татар дөньясы», «Татар теле һәм әдәбияты» дәресләре алып баруы шуның бер мисалы. Милләтебез, туган телебез һәм татар дәүләтчелегенең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге хакында уйланулар белән сугарылган әдәби-публицистик «Уяну» исемле китабын «Сәләт» фонды 1998 елда бастырып чыгарды. «Уяныйк киләбез... Уяныйк та җиң сызганып эшкә тотыныйк. Безнең өчен беркем дә хыялларыбызны тормышка ашыру юлында эшләп йөрмәс. Барысы да үзебезгә бәйле. Үзебез эшлик!»—дип әйтүе белән әдип мең мәртәбә хаклы.

1999 елда язучының күләмле тагын бер әсәре—«Ишелеп төшкән бәхет» романы «Казан утлары» журналының 5-6 саннарында басылып чыкты. Әдәби җәмәгатьчелек романга унай бәя бирде. Язучы үзе бүгенге әдәби барышны күздә тотып болай дигән иде: «Әле һаман да «су күп кушылган», күпсүзлелектән җәфа чигүче романнар язу дәвам итү белән бергә, тыгыз концентрацияле, катлаулы сюжетлы, аз сүзле, әмма сурәтләү ягыннан киң колачлы романнар күренә башлады. Һәм бу аңлашыла да. Чөнки заман үзгәрде, югары тизлек, компьютер заманы килде, дөньяны информация ташкыны басып китте. Кешенең бишәр йөз, алтышар йөз битлек, хәтта меңәр битлек романнар укып утырырга вакыты да, түземе дә һәм теләге дә юк». Инде килеп, яңа романы хакындагы уйлары белән дә уртаклашу кирәклеген тоеп, укучыларга берничә сүз әйтүне кирәк тапты: «Ишелеп төшкән бәхет»—роман-эксперимент. Ул безнең традицион татар романнарында булмаганча, дөньяны эре штрихлар белән колачларга тырышып карау. Татар бәхете кайда? Татарстанда бәхетлеме ул? Чит илләргә күчеп киткән, качып китәргә мәҗбүр ителгән татарлар бәхетлеме? Беренче карашка мәхәббәт һәм Ватанга тугрылык хакында сыман тоелучы роман тукымасына урыс дәүләтенең татарга карата гасырлар буе дәвам иткән мәкерле сәясәте яшерелгән. Ничек тә булса татарның тамырын корыту, аның генофондын юкка чыгару сәясәте ул. Укыган кешеләр аңа үз бәяләрен бирер дип беләм». Бәхет эзләү дигәннән, әле тәүге китапларында

ук бу теманы ныклап өйрәнү юлына баскан иде автор, хәзер тагын да тирәнрәк, фәлсәфирәк яссылыкка күчерә ул теманы. Моның белән автор үзенең әдәбиятка очраклы килеп кермәвен һәм югары әдәби кимәлдә укучыга житкерә алырлык фикер байлыгы барлыгын раслый. Әйе, язучының татар халкын бик бәхетле итеп күрәсе килә, аны төрле тормышчан, әмма әдәби кануннар жирлегендә туган ситуацияләргә куеп карый. Халык вәкилләренә хас сыйфатларны барлый, шәхесне сындырып сыный, милләтнең ныклык шкаласын билгели кебек. Ә моны белү, минемчә, бик тә мөһим.

Әдәбият галиме Рифат Сверигин роман турында болай дип язды: «Ишелеп төшкән бәхет» романы—интелектуаль проза дип аталган тармакның бер чагылышы. Андыйларны заман романы дип тә атыйлар. Вакыйгаларны бәйләү алымы бик үзенчәлекле: элекке «Идел-Урал» яшьләр оешмасының сәркәтибе Әмиржан Акчура, совет солдаты Хафиз Сабиров һәм махсус бүлек майоры Гыймаев 1945 елда Чәнчүн шәһәрендә очрашканда өчесе өч вазифа башкаралар.

Һәм менә шул кешеләрнең балалары 1972 елның җәендә Казанда, шәһәребезне шаулаткан Америка күргәзмәсендә очраша. Аларның берсе Нью-Йорктан күргәзмәне алып килгән, электрон җиһазлар буенча эксперт Илдар Акчурин, икенчесе Казан фәнни-тикшеренү институтларының берсендә эшләүче фәнни хезмәткәр Сирин Сабиров һәм өченчесе—аларны карап, мәгълүматларны тиешле оешмаларга житкереп йөрүче елгыр егет Дамир Гыймаев була.

«Алар өчесе өч сыйфатта иде һәм, табигый ки, араларында дустанә мөнәсәбәт була алмый иде. Инде менә 27 елдан соң аларның балалары изге Казан тупрагында. Алар да бүген өчесе өч сыйфатта. Ләкин аталарының кайчандыр очрашулары хакында белмиләр һәм кайчан белүләре дә икеле. Дөнья дигәнең шундый сәер һәм катлаулы инде ул»—ди автор бу хакта әсәрендә.

Әсәрнең нигезенә шундый очраклы роман ситуациясе салынган. Ул уйланучан, анализлап укучан китап сөючеләргә атабрак язылган. Дөньялар үзгәрә-үзгәрә, дип сөйлибез—шулаймы икән соң? Дөрес, бу 1945—1972 еллар арасы. Ә тоталитар режимнан демократик дип аталганына күчкәндә нинди үзгәрешләр булды? Һәм бу үзгәрешләр кем файдасына бара? Гади халык файдасынамы? Флүс Латыйфи укучыны уйландыра торган әсәр иҗат иткән».

Шунысын да әйтеп китү урынлы булыр, Флүс Латыйфи әсәрләренә кат-кат кайтып эшкәртергә, «әсәр өстендә эшләргә» иренмәүчән сирәк прозаикларның берсе. Әгәр дә «Ишелеп төшкән бәхет» романы китап булып басылып чыкса, андагы гаять урынлы үзгәрешләрне, төзәтү-өстәмәләрне күрергә туры килсә, гаҗәпләнер урын юк. Автор һәр язганына таләпчән, җаваплы карый.

Үткән гасырның соңгы елында Ф. Латыйфиның «Бәйсез этләрне атарга» дигән гыйбрәтле роман-нәсерен укырга насыйп булды *(«Казан утлары», 12 сан).* Әсәр сугыш елларында туган һәм балачаклары сугыш, сугыштан соңгы авыр елларга туры килгән замандашларына арнап язылган. Монда инде без Мәһдиевчә җор теллелеккә, нечкә лиризмга, халыкчан фәлсәфәгә тап булабыз. Шушы зур булмаган әсәрдә язучы чорның бөтен катлаулылыгын, каршылыгын, гади кешеләрнең күнел байлыгын, түрә кыяфәтле бәндәләрнең җансызлыгын аңнарга үтеп керерлек итеп тасвирлый алган. Тормышта еш кына үткән дәверне сагынып искә алучылар белән очрашып торабыз. Әйтерсең, илне, халыкны тезләндергән, мылтык көпшәсе аша күзәтеп торган система коллары булып яшәмәгәнбез дә, әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларның күпчелегенә шаһит түгел идек. Әйтерсең, ул заманнарда барысы да ал да гөл булган. Алай түгел иде шул. Әсәрне укыгач, тагын бер мәртәбә җаннар өшеп куя, ул чорлар әйләнеп кайта гына күрмәсен иде...

Флүс Латыйфи чын мәгънәсендә хикәяләр остасы да. Аның хикәяләре тормышчан булулары, җыйнаклыклары белән күнелне җәлеп итәләр. “Кырагай”, “Аяклы каза”, “Истәлекле көн”, “Көмеш беләзек”, “Жирәнкәем” һ. б. әсәрләрендә өлкән буын, җәмгыять, милләт, табигать алдында кешенең җаваплылыгы, дуслыкка һәм мәхәббәткә тугрылык, туган җирне зурлау кебек мөһим әхлакый проблемалар күтәрелә.

**Факил САФИН**

Гыйлем
Фән

Вил Ганиев

# XX ЙӨЗ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

## ТАРИХИ-БИБЛИОГРАФИК КҮЗӘТҮ

XX йөз татар әдәбияты үсешендә 90 еллар гаҗәеп үзенчәлекле булып чыга, моны зур бер дәрьяга тиңләү дөрес булыр, әмма аның агымы тизлегенә күз иярерлек кенә түгел, аның муллыгын санап бетерерлек кенә түгел. 80 елларда ук башланган яңарыш галәмәте, рухи көчләрнең уянуы матур гына дәвам итә. Милли ренессанс идеясе белән дәртләнеп китеп, мәдәниятебезне яңадан торгызу һәм нығытуга өметләнеп, әдәби көчләр һәммәсе бергә туплана. Матди кыенлыклардан арына алмасалар да, язучыларның рухы күтәренке, чөнки алар борынгыдан килгән әдәбиятыбыз булуына сөенәләр, горурлык хисе кичерәләр. Татар әдәбияты, нәкъ гасырның башындагыча ук, халыкның үзаңы үсүен яңадан-яңа әсәрләрендә чагылдырып, элеккеге рухи байлыгын кайтарырга, рухият чылбырының өзелгән буыннарын ялгарга, динне дә эченә алган мәдәниятне тулаем торгызырга омтыла.

Бер генә юнәлештә барган идеология үзенең тәэсир итү сәләтеннән ваз кичә, кодрәтен югалта. Әдәбият белән сәнгатьтә төрле идеяләр тамыр җәя, төрле сәнгати-нәфис юнәлешләр үзенә юл яра. Моңа чаклы тәртәгә керергә теләмәгән яисә дин ягына авышкан язучылар да (мәсәлән, Ф.Бәйрәмова), искене сагынып искә алучылар да—барчасы хокук ягыннан тигезләнә.

Шул ук вакытта моңарчы яшәп килгән гадәтләрдән (әйтик, әдәбиятның өстән кушканны гына җөпләве, мәдәниятнең фәкать акча өчен яшәве) баш тартуның нәтиҗәләре күренә башлый. Җәмәгатьчелек беркайчан да коньюнктурага хезмәт итмәгән әдипләргә (Ә.Еники, А.Гыйләҗев, Н.Фәттах һ.б.) яки турыдан-туры хакимият белән «якалашкан» иҗат кешеләренә (С.Баттал) аеруча зур хөрмәт күрсәтә. «Идел» журналы 1994 елның февраль санында С.Батталның «Батый ханга ачык хат» дигән поэмасын чыгара. 1963 елны язылган әсәрнең шул вакытка чаклы дөнья күрмәве әдәбият өлкәсендәге тоткарлауның ачык мисалы.

Массакүләм мәгълүмат чараларына карата 1990 елда чыккан Рәсәй законы нигезендә Татарстанның матбугат оешмалары үзләре теләгәнчә эшли башлыйлар. Әдәбият идеология һәм цензура ише тоткарлык ясап торган органнардан арына арынуын, тик менә озакламыйча дилбегәне икътисад үз кулына алачак бит әле. Бүгенге көндә Татарстан Республикасында китап чыгару эше спонсор яки меценатларның ярдәм кулын сузуына бәйле.

Татар халкының этник яктан шактый фаҗигале хәлгә төшкәнен (туган телнең көнкүрештә керәге кимегәннән-кими барганын, җөмһүриятнең башкаласында һәм эре шәһәрләрдә милли мәктәпләрнең бетерелүен, мәдәният учакларының ябылуын, милли гореф-гадәтләрнең кысрыклап чыгарылуын, туган телне һәм нәсел-нәсәбен белмәгән «манкортлар»ның арткannан-артуын) исбатлап, зыялы иҗат әһелләре 60—70 елларда ук чаң суга башлаганнар иде инде. 80 елларның азагына таба әлеге мәсьәлә поэзиядә һәм публицистикада төп темага әверелә. Ниһаять, 90 елларның башында ук хакыйкать җиңә: милли телебезне һәм татар халкының милләт буларак саклануын кайгырту аерым кешеләрнең генә түгел, бәлки дәүләт эше икәнлеге тәгаенләнә. Нәкъ менә шул постулат зыялы иҗат ияләрен һәм хөкүмәт даирәләрен төпле бер

фикергә китерә: татар милләтенең язмышын хәл итәргә сәләтле, көчле һәм кодрәтле дәүләт булдыру зарур икән ләбаса! 1990 елның 30 августында җөмһүриятнең Югары Советы яңа Декларация кабул кылып, Татарстан Республикасын суверен дәүләт дип игълан итә. Озакламый татар телен рус теле белән бергә республиканың дәүләт теле буларак таныган закон да хуплана.

1990—91 еллар — суверенитет өчен көрәш дәвере, җәмгыятьнең кайнап торган чагы. Казан каласының төп мәйданында узган шаулы митингларда, ачлык игълан итүләрдә язучылар, бигрәк тә яшь язучылар аеруча актив катнаша. 1993 елда әдәби хәрәкәт янә буразнага төшә, әмма күптән түгел кичерелгән хәлләр әле иҗат әһелләренә һич тынгы бирми, аларның әсәрләрендә әледән-әле чагыла.

Яңа шартларда өлкән һәм урта яшьләрдәге шагыйрьләр дә иҗатларында зур активлык күрсәтәләр. Заманага да, үз-үзләренә дә авторларыбыз икенче төрлерәк күзлектән карыйлар: И. Юзеев — «Уйлый күңелем төрлесен» (1997), Р.Фәйзуллин — «Җил-Вакыт» (1996), Р.Харис — «Тоткасыз ишек» (1999), Р.Миңнуллин — «Талбишек» (1995) һәм «Уфа белән Казан арасы» (1998), К.Латыйп — «Иман кәрваны» (1997), Р.Гаташ (Р.Гатауллин) — «Догам сиңа багышлыйм» (1997) һәм «Гөлләр су сорый» (1999), Роберт Әхмәтҗанов — «Тургай тәрәзәсе» (1996), Г.Рәхим — «Замандашларга ачык хат» (1999) З.Мансуров — «Яшәү үзәне» (1998), К.Булатова — «Миләш кагы» (1991), Н.Әхмәдиев — «Яралы кук» (1994).

Сатира остасы Г. Афзал үзенең үткен генә әсәрләре белән чыга.

Прозада татар халкы кичергән иң олы михнәтләрне (1552 елда Явыз Иван гаскәрләренең Казан каласын яулап алуы һ.б.) сурәтләү, йә булмаса үз вакытында лаеклы бәя алмаган тарихи шәхесләрне гәүдәләндерү нияте калкып чыга. Һәммә нәрсәгә икенче күзлектән карау башлана, бәяләр-мөнәсәбәтләр баштанаяк үзгәрә. Р.Мөхәммәдиевнең «Сират күпере» (1994) дигән романында элек большевик булып та, соңыннан Совет хөкүмәтенең дошманы дип игълан ителгән М.Солтангалиевнең фаҗигале язмышы тасвирлана. Әсәрдә аның образы бүгенге көн өчен дә төпле фикер йөртүче акыл иясе буларак гәүдәләнә. С.Шәмсинең «Кубрат» (1997) драмасында, Батулланың «Сөембикә» (1992), Җ.Рәхимовның «Батырша» (1992), М.Хәбибуллинның «Шайтан каласы» (1993), «Хан оныгы Хансөяр» (1997) һәм «Аллаһы бүләге» (1999), Ф.Латыйфиның (1943) «Хыянәт» (1993) романнарында һ.б. әсәрләрендә татар халкының тарихыннан төрле дәверләр күрсәтелә.

Р.Кәрами «Каргалган кәрван» романында репрессияләр барган заманны сурәтли. Шул ук вакытта каһәрле язмышка үзләре дучар ителгән әдипләр әлеге теманы тәмам нокта куярлык итеп тасвирлап бирәләр: И.Салахов — «Колыма хикәяләре» (1991), Г.Тавлин — «Афәт» (роман-трилогия, 1996), А.Гыйләҗев — «Йөгез, бер дога!» (1997). Шунысын да әйтергә кирәк, А.Гыйләҗев бу романын язар алдыннан Караганда якларында үзе булган җирләрне күреп йөри. Әнә шул сәяхәтенең көндәлеген китабына эпилог рәвешендә урнаштыра. Миңа калса, автор әлеге эпилогны аеруча нык дәртләнеп яза һәм бүгенге прозабызның матур үрнәге дәрәҗәсенә җиткерә.

Гәрчә тарихи һәм лагерь темалары өстенлек итсә дә, прозабызның колачы 90 елларда да гаять киң. Р.Низамиев «Кызыл кар яугач» (1994) повестенда әфган сугышын күрсәтә; М.Насыйбуллин «Тукран тәүбәсе»ндә (1997) һәм «Елан елан булып кала» (1998) повестенда криминаль теманы күтәрә; Т.Галиуллин исә «Тәүбә» (1996) һәм «Әлмәк» (1998) романнарында бүгенге мафияләрне фаш итә; якташларына Ф.Садриев «Таң җиле» (1994), Ә.Галиев «Авылдашлар» (1995) романын багышлый; М.Юныс «Юлда уйланулар» (1990) китабында ерак җирләргә сәяхәт итүләрен тасвирлый; Ш.Галиев сугыш елларына туры килгән яшьлеген сурәтли; А.Вергазов «Без сезнең балаларыгыз» (1996) повестенда тәрбия керми торган яшүсмерләр, Н.Әхмәдиев «Амбирак, яки кара каен кыйссасы» (1999) повестенда халык авыз иҗатын һәм җирле сөйләмне өйрәнергә Себер якларына сәфәр кылучы студентлар тормышын күрсәтә. Р.Фәизов (1931) «Тәңре хөкеме» дигән фантастик повестенда замандашларын, алда безне экологик катастрофа көтүе бик ихтимал дип кисәтә. Бу әсәр Г.Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» дигән хыялый повестена аваздаш, Ф.Латыйфиның «Ишелеп төшкән бәхет»

(1999) романы хәзерге заман хәлләрен тасвирлауга багышлана.

Җәмгыятьнең рухи тормышына, милләтнең мәнфәгатенә үзләреннән зур өлеш керткән шәхесләр бүгенге әдипләрне бигрәк нык кызыксындыра. Ф.Бәйрәмованың «Метеор» дигән пьесасы (1998 елгы «Онытмагыз безне!» китабына кергән) даһи шагыйрь Һ.Такташка багышлана. Ә бит мәркәзнең кайбер тәнкыйтьчеләре В.Маяковскийны түбәнсетергә мәтәшкән кебек, безнең Такташыбызга кырын караучылар бүген дә юк түгел.

С.Поварисовның (1924) дилогиясендә татар әдәбияты классигы Г.Ибраһимовның якты образы гәүдәләнә (1 кисәге «Яшьлек иртәсе», 1996; 2 кисәге «Җиденче күктә» 1998). Автор шулай ук мәшһүр әдипнең һәм җәмәгать эшлеклесенең әһәмиятен кечерәйтергә тырышучылар белән бәхәс алып бара.

К.Миңлебаевның (1929) «Бакый» романында даһи иҗади зыялыларның берсе — нәкыш остасы, уем-сынчы, график һәм шагыйрь Бакый Урманче образы тасвирлана (журналда — 1997). Матур әдәбиятта бу әле сәнгатькяр образының беренче гәүдәләнеше. Б.Урманче ярыйсы ук озын һәм гыйбрәтле гомер кичерә (1897—1990), һәм романда шуның аерым дәверләре күрсәтелә.

90 еллар әдәбияты булган хәлләрне һәм кешеләрне документальрәк сурәтләү ягын каера, шуңа күрә азмы-күпме очеркка тартым әсәр язган автор гүя сәнгатьчә фикер йөртүне киләчәккә калдырып килә. Әйтик, Г.Ахунов гадәтенчә уңай каһарманны тормышның үзеннән эзли торгач, алдынгы хуҗалыгы белән бөтен җөмһүриятькә танылган Тимерхан Борһановка юлыга һәм документаль очеркка тартым трилогия язып ташлый: «Тимерханның күргән-кичергәннәре» (1999).

Р.Мөхәммәдиевнең «Кызган табада» (1996) романы да булган хәлләргә таянып язылган — 1993 елда Мәскәүдә парламентны тупка тоту кебек зур фаҗига тасвирлана. Автор үзе депутат һәм парламентның бер комиссиясен җитәкләүче буларак мәхшәрнең эчендә кайнаша. Үзе кичергән һәм күргән хәлләрне шулай күрсәткән роман Россия Федерациясе әдәбиятларының берсендә дә юк әле.

Замананың авырлыгы, кискен үзгәрешләр, мәхшәр-кырылышлар язучыларны яңа төр публицистикага этәрә. Иң актив публицистларның берсе А.Хәлим аны «рухи публицистика» дип атый, чөнки төп мәгънәсе милләтнең үткәне һәм киләчәге, рухи дөньясы, милли мәдәниятнең һәм ана теленең язмышына барып тоташа. Милләтнең булу-булмавы телнең саклану-сакланмавына бәйләнгән. Публицист язучылар (М.Юныс, К.Тимбикова һ.б.) тискәре хәл-күренешләргә каршы чыгып, җәмәгатьчелекне күтәрәләр, мәсьәләне уңай хәл итүгә ирешәләр. 90 елларда публицистик китапларын драматург Т.Миңнуллин («Утырып уйлар уйладым», 1997), прозаик М.Мәһдиев («Ачы тәҗрибә», 1993), шагыйрьләр Р.Миңнуллин («Шагыйрь булып кына калмадым», 1998), Ф.Яруллин «Заман сулышы (1997) һ.б. чыгара. М.Галиевнең «Догалы еллар» (1998) китабы да яңа публицистикага якын.

Драматургиядә яшьләр бәйге тота: Ю. Сафиуллин — «Идегәй» (1997), пьесалар китабы «Канатлар» (1997); Д. Салихов — «Яшьлегем хатасы — йөрәгем ярасы» (1998) һ.б. Әмма аларга Т.Миңнуллинны куып җитәргә ерак әле...

Ф.Латыйфиның «Тамга» (1996, Р.Якуш белән берлектә фантастик повестьлары берьюлы ике телдә («Тамга» — «След») басылып чыга, «Ишелеп төшкән бәхет» (журналда — 1999) романы — гасырның соңгы әсәрләреннән берсе.

Ф.Яруллинның таланты төрле яклап ачыла: ул шагыйрь дә, прозаик та, драматург та, публицист та.

90 елларда мәшһүр язучыларыбыз, иҗатларына йомгак ясагандай, әсәрләрен күптомлы итеп чыгару җаен табалар: А.Гыйләҗев белән Р.Фәйзуллин дүртәр том, Ә.Еники, М.Мәһдиев, Ә. Баянов өчәр том итеп чыгара.

Әдәбиятка килүче яшьләр 70—80 еллар белән чагыштырганда сан ягыннан да ишлерәк, яшь ягыннан да яшьрәк. Кайсыбер дебютантлар китапларын бик яшьли күрү бәхетенә ирешәләр. 1994-99 елларда Язучылар берлегенә 50дән артык кешенең әгъза буларак кабул ителүе дә шуны раслый.

Мәдәни-тарихи күзлектән караганда, 90 елларда нәшрият һәм басмаханәләрнең күбәеп китүен күрми калу һич мөмкин түгел (ә бит автономия

шартларында Татарстан 1920 елда оешкан бердәнбер китап нәшрияты белән чикләнергә мәҗбүр иде).

Яңа нәшриятларның арада бер зурлары: «Мәгариф» (гәрчә 1991 елда оешса да, үзен революциягә хәтле эшләгән «Мәгариф»нең варисы дип саный); «Татар китабы» (Язучылар берлеге каршында, 1996—99); «Матбугат Йорты» (1998дән); «Рухият» (1998дән); «Милли китап» (1998дән) һ.б.

1991 елдан «Мирас» дигән әдәби журнал чыга — ул татар мәдәниятенең төрле дәверләренә караган кыйммәтле ядкярләрне барлау һәм халыкка җиткерү юлында кирәкле эш башкара.

Шул ук 1991 елны Чаллыда «Аргамак» журналы чыга башлый. Бу журнал гәрчә Татарстан Язучылары берлеге Чаллы бүлегенең басма органы саналса да, үз төбәгендәге әдәби көчләрне туплап кына калмый, бәлки әле Казан, Уфа, Ульян, Мәскәү авторларына да ачык чырай күрсәтә.

Сабыйларга атап «Салават күпере», «Сабыйга» журналлары Казанда чыкса, Уфада татар телендә яшьләр өчен «Тулпар» дигәне чыга.

Альманахлар да бар әле: Казанда — «Аҗаган», Ульянда — «Сембер язлары».

1995 елдан башлап ана телендә беренче мәртәбә «Мәдәни җомга» исемендәге атналык әдәби гәзит чыга. Ул җәмһүрияттәге бөтен мәдәният дөньясының мәнфәгатен кайгыртуы белән тиз арада шөһрәт казанып өлгерә.

90 елларда, гасырның азагында, татар әдәбияты үзенең элеккеге мәйданнарын да кайтару дәртенә керешә. Мәгълүм булганча, гасыр башында Казаннан шактый ук ерак Ырынбур, Уфа, Әстерхан, Мәскәү, Петербург, Екатеринбург, Орск һ.б. шәһәрләр дә татар мәдәниятенең учаклары санала. Бүгенге көндә ул изге традицияне Әстерхан, Ульян, Мәскәү, Төмән, Себернең бүтән шәһәрләрендә яшәүче әдипләр һәм шагыйрьләр дәвам иттерә. Себер җирендә туып-үскән Якуб Зәнкиев (1917) хәзер Тубыл шәһәрендә яши һәм үз төбәгендә яшәүчеләргә багышлап «Иртеш таңнары» (1994, Казан) дигән киң колачлы чәчмә әсәр иҗат итә; бүген ул татар укучысының яраткан авторларыннан санала, дисәм дә хата булмас. Танылган шагыйрь, әдәбият галиме, тәрҗемәче Әдхәт Синугыл (1935) Ташкентта яши. Күренекле татар шагыйре Камил Мостафин (1932) Чиләбедә яши. Бүтән шәһәрләрдә яшәүче шагыйрь һәм әдипләребез дә ярыйсы ук актив иҗат итәләр, әдәбиятыбызны баетуга көчләрен кызганмыйлар.

Ә инде күршедәге Башкортстанда яшәүче татар язучылары 90 елларда үз китапларын Уфада ана телендә чыгару мөмкинлегенә ирешәләр. «Китап» нәшриятында талантлы шагыйрәләр Х.Мөдәррисованың «Үткән көз» (1995), Д.Булгакованың «Шигырьләр һәм җырлар» (1998), тагын әле шактый гына әдип һәм әдәбият галимнәренең китаплары дөнья күрә. Шунысын да әйтергә кирәк, бу нәшрият әле татар поэзиясе классикларының да, бүген бәйге тотучы күренекле шагыйрьләребез Р.Фәйзуллин, Р.Харис, Р.Гаташ, Р.Миңнуллин, Г.Рәхим һ.б. сайланма шигырь һәм поэмаларын да чыгара.

Чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез белән дә мәдәни аралашу җайга салына. Төркия белән Финляндиядә безнең халык вәкилләре күбрәк санала, шуңа күрә үзара бәйләнешләр да иң әүвәл шулар белән урнаша. Чит илдә татар әдипләре иҗат иткән әсәрләр дә, сәнгатькярләребез мәдәният өлкәсендә ирешкән казанышлар да «төп йортка» килеп җитә, әдәбият һәм сәнгать белгечләрендә билгеле бер кызыксыну уята.

Гасыр башындагы кебек үк, телебез-динебез ягыннан кардәш төрекләр белән аралашу яңадан башлана. Татар әдипләренең китаплары төрекчәгә тәрҗемә ителә һәм басылып чыга. Татарстан белән Төркия язучылары үзара йөрешәләр. Г.Исхакый, З.Вәлиди, С.Максуди, Г.Баттал-Таймас, Й.Акчура, К.Инан һ.б. татар эмигрантларының иҗади мирасы милли мәдәниятебездә лаеклы урын ала.

Төрле сәбәпләр белән һәм төрле вакытта мәдәниятебездә һәм тарихыбызда килеп чыккан чатаклыкларны 80 елларда төзәтү башланган булса, 90 елларда бу изге эш тагын да киңрәк колач җәя. Чынбарлыкның халыкка мәгълүм булуы аркасында күп нәрсәгә яшәп килгән караш-мөнәсәбәтләр үзгәрә. Татар әдәбиятының бөтен тарихына, бигрәк тә XX йөз башындагы әдәбиятына бөтенләй яңа күзлектән карау зарурлыгы сорала.

«Реабилитация» нәтиҗәсендә узган фактларга яңача фәнни бәя бирелә, әдәбиятыбыз тарихында булып узган вакыйгаларның олысына-кечесенә яңача карала. Бу җәһәттән Татарстан Фәннәр академиясе 1994 елда «Татар әдәбияты тарихын өйрәнүдә яңа аспектлар» дигән темага язучылар белән галимнәрнең конференциясен үткәрә. Ул конференция киләчәктә фәнни тикшеренүләр алып бару максатына юнәлдерелгән программа төзи, ФА һәм җөмһүриятнең югары уку йортлары галимнәренең көчен бергә туплап, милли әдәбиятыбызның чынбарлыгына тәңгәл килердәй тарихын булдыруны максат итеп куя. Әдәбият галиме Ф.Галимуллинның «Эстетика һәм социологизм» (1988) дигән китабы чыга; анда автор моңарчы хөкем сөргән һәм әдәбиятыбызга зур каза китергән берьяклы бәя бирүнең сәбәп һәм серләрен ача (галим фикеренчә, сәбәпләрнең берсе вульгар социологизмга барып терәлә).

Гасырның соңгы унъеллыгын — татар әдәбияты тарихында тулаем яңарыш дәвере дип бәяләргә мөмкин. Бу дәвергә, яңарыш белән бергә, милли идеяне раслау, туган телгә баш ию, киләчәккә якты өметләр баглау кебек рухи күтәренкелек хас. Күпчелек татар язучылары дөньякүләм аренага чыгуның зарурлыгын, моның өчен исә бөтендөнья әдәбиятының ирешкән уңышларга ирешү мәҗбүр икәнлеген тәкрарлыйлар. Ошбу максатның бүгенге көндә иң әһәмиятле максат икәнлеген һәркем икърар итә.

Гасырның ахыры — узган юлга анализ ясау, югалту һәм табышларны барлау, йомгакны төйнәү. ХХ йөз татар әдәбиятының үткән юлы гәрчә бик алай шома һәм такыр ук булмаса да, әдәбиятыбыз затлылыгын җуймады, нәфислегеннән ваз кичмәде, ә инде төрле сәбәпләр белән читкә тибәрелгәннең һәммәсен бергә туплауны дәвам иттерә.

Халык шагыйре Р. Фәйзуллин «Гасыр йомгагын төенләгәндә» (1999) дигән саллы мәкаләсендә мондый фикер әйтә:

«Ышанасы килә: дөнья халыклары, дөнья цивилизациясендә Татар милләте булачак», — ди.

## Гасыр йомгагы

**а)** Татар әдәбияты ХХ йөзгә аяк басканда милләтебезнең мәнфәгатьләрен яклау өчен бүтән бертөрле дә трибуна булмый. Шуңа күрә халкыбызның иң алдынгы вәкилләре ул мәнфәгатьләрне яклап, киләчәккә дөрес юл күрсәтү өчен әдәбияттан файдаланалар. Бу хәл ана телендә вакытлы матбугат чыгару хокукын яулап алганчыга кадәр дәвам итә. Әдәбиятның төп функциясе әнә шуннан гыйбарәт була.

Октябрь революциясеннән соң, 1920 елда үзебезнең автономия оешкач, вазифалар ничектер үзгәрә: милли мәдәният һәм вакытлы матбугат кебек мәсьәләләрне кайгырту эшен автономияле республика үз кулына ала, шуның белән әдипне яки шагыйрьне төп функциясен үтәүдән мәхрүм итә... Хәзер инде әдәбият үз милләтебезнең мәнфәгатьләре урынына бөтен бер халык мәнфәгатьләрен кайгыртып яшәргә тиеш була. Менә ни сәбәпле һәммә нәрсәне бер калыпка салырга тырышалар һәм Габдулла Тукайның 1906 елда иҗат иткән «Милләтә» шигырен русчага тәрҗемә иткәндә аның исемен «К народу» дип үзгәртәләр иде; ә инде 1913 елда язган «Олуг юбилей мөнәсәбәте белән халык өмидләре» дигән мәгълүм шигырьдә авторның вак милләтләрне яклап, аларга падишаһтан тигез хокуклар даулап язган юлларын русчага тәрҗемә итмиләр иде (38 юлдан тик 12 юлы басылып килде).

Милли үзенчәлекләрне бетерү тенденциясе, милләтләрнең мәнфәгатенә илтифатның елдан-ел кими баруы 70—80 елларда зур фаҗига китереп чыгара: Татарстанның күпчелек шәһәрләрендә татар мәктәпләре бөтенләй калмаган икән; ике телелек дигәннәре үзебезнең ана телен кысып чыгару ысулы икән... Татар зыялыларының, иҗат әһелләренең «милләтчелек» ягына авышуыннан котлары алынып, җөмһүрият башында торучы түрәләр, бәладән баш-аяк дип, халыкны адәм мәсхәрәсенә калдыралар: бер яктан караганда, милли мәдәниятне кайгырталар, татар әдәбиятын үстерү чараларын күрәләр; икенче

яктан, шул ук татар язучыларын укучысыз калдыру юлында зур тырышлык күрсәтәләр.

1991 елда татар зыялыларының зиһеннәре-аңнары ачылып киткән кебек була. Шуннан инде язучыларыбыз милли мәнфәгатьләрне кайгырту эшен үз кулларына алалар: җөмһүриятебездә ана телен дәүләт теле (ике теленең берсе) итеп яңадан раслатуга ирешәләр һ.б. хәлләр үзгәреп китә, күңелләргә өмет иңә.

90 елларда татар әдәбияты бик нык үсеп китә, һәм бу инде халкыбызның үзаңы үсүдән килүе бәхәссез. Димәк ки, XX йөзнең азагында татар әдәбияты үзенең элеккеге функциясен кире кайтарып ала — яңадан милли мәнфәгатьләрне кайгырту юлына, милли хәрәкәтнең алгы сафына баса. Әнә шул активлык аның бүгенге халәтен, милли ренессансны китереп чыгара.

**б)** XX йөзгә татар әдәбияты Шәрыкның алдынгы әдәбиятлары рәтендә килә. XX йөздә мәдәниятләрнең гөрләп үсеп китүенә сәнгати казанышлар, әдәби табышлар һәм үзгәрешләр хас дип бәяләгәндә, татар әдәбияты әлеге әдәби табышларга һәм әлеге үзгәрешләргә ярыйсы ук өзерлекле килә, дип әйтү дөрес булыр. Менә ни сәбәпле ул һәртөрле яңалыкны (символизм, футуризм, верлибр һ.б.) бик тиз кабул итәргә сәләтле була.

Әйтеп үткәнебезчә, гасыр башында татар әдәбиятының кыйбласы нык үзгәрә: көнчыгыштан көнбатышка әйләнә. Әмма тора-бара бу хәл тигезләнә диярлек. Бүгенге татар әдәбияты аларның икесенә дә карап эш итә. Шул ук вакытта ул аларның икесеннән дә шактый ук аерыла; чыгышы һәм теле белән гәрчә ул көнчыгыш әдәбияты саналса да, аның үз йөзе, үз мөстәкыйльлеге ярылып ята.


**в)** XX йөзнең азагында янә дә бер гаять күркәм хәл булып ала: метрополиядәге әдәбиятка эмиграциядәгесе дә килеп кушыла. Татар әдәбияты чит илләрдә иҗат ителгән үз әдипләребезнең әсәрләрен олуг хәзинәне, югалган мирасыбызны — төп йортка тулаем диярлек кайтара, һәммәсенә лаеклы бәяне дә бирә. Мәгълүм булганча, дөньяларның кинәт үзгәреп китүе нәтиҗәсендә татар халкы 75 ел буена хәзерге татар прозасына һәм драматургиясенә нигез ташын салучы Гаяз Исхакыйдан мәхрүм булып яшәгән иде. Хәзер әдипнең мирасы том-том булып дөнья күрә, һәйбәтләп өйрәнелә, әнә шул рәвешле XX йөз әдәбиятының югалган мәрҗәннәре үз урыннарына утыртыла, татар әдәбиятының чын йөзе нурланып та балкып ачыла.

**г)** XX йөзнең азагына таба татар әдипләренең үзләренә булган мөнәсәбәте кисәктән генә үзгәреп куя. Әгәр моңарчы үзләрен җитлекмәгән, провинциаль язучылар дип тойган булсалар, әдәбиятыбызның тулаем бер бөтен икәнен, метрополия буларак яшәгәнен, берәүгә дә ялынычы төшмәгәне, беркемнең дә читтән торып бәя бирүенә һич мохтаҗ түгеллеген күргәч, әлеге дә баягы мескенләнү хисеннән арыналар. Бүгенге көндә һәркемнең миендә бер генә теләк, бер генә өмет: ничек тә үзебезнең әдәбиятны дөнья мәйданына чыгарасы иде, лаеклы урынны яулап аласы иде. Хәер, Г.Исхакыйның күңелендә шундый теләк гасыр башында ук була — нигәдер таянып, ул безнең әдәбиятыбызны Европаның алдынгы әдәбиятлары сафына алып чыгарга өметләнгән була...

**д)** XX йөздә татар әдәбияты азмы-күпме халыкара мәйданда үзен танытып өлгерә — әдип вә шагыйрьләренең аеруча камил әсәрләрен, әдәби күренешләрне бөтен дөньяга өлге сыйфатында тәкъдим итә. Монда иң әүвәл Муса Җәлил калкып чыга, аның тоткынлыкта, үлем җәзасы алдыннан иҗат итеп, изге әманәт сыйфатында калдырган, искиткеч камиллек дәрәҗәсенә җиткән «Моабит дәфтәрләре». Шәхес буларак бер каһарманлык кылса, шигърияте белән — икенче. Андый батырлыкның дөнья күләмендә тиңе юк, бүтән бер генә әдәбиятка да ул тәс түгел. Иң әһәмиятлесе шунда ки, XX йөздә бөтендөнья әдәбияты картасына татар әдәбияты дигән исем языла, тамга куела.

# ТАУЛЫ АЛТАЙ—ТӨРКИ ХАЛЫКЛАР ЭТНОГЕНЕЗЫНЫҢ БЕР ҮЗӘГЕ

БЕЗНЕҢ ЭРАГА кадәр 1 мең еллар чамасы элек көнчыгыштан Монголиядән алып, көньяктан Һиндстан, Иран, Мисыр чикләренә, көнбатыштан Мажарстанга (Венгриягә) хәтле сузылган гажәеп киң Бөек Дала жирләре «патша» кабиләләре дип аталган кабиләләр буйсынуында була [Евразия тарихының скифләргә караган чорында—сүз нәкъ менә шул хакта бара—«патша» кабиләләре («скифләр», «сарматлар», «сакълар», «массагетлар», «даглар» һ. б.) юлбашчылыгында зур кабиләара берләшмәләр барлыкка килә—беренчедән, бу археологик яктан да Азия һәм Ауропа кинлекләрендә азмы-күпме бер тамырдан чыккан «патша каберлекләре» булу белән; икенчедән, язма грек (Геродот, Фукидид, Аристотель, Страбон, Птолемей һ. б.), фарсы, кытай чыганаклары буенча да аңлатыла], кайбер тикшеренүчеләрнең фикеренчә, аларның туган туфраклары Идел-Урал тирәләре дип исәпләнелә *(Лайпанов К.Т., Мизиев И. М. О происхождении тюркских народов.—Черкесск, 1993.—С. 45)*. Бу, барыннан да бигрәк, барлык шушы ареалга таралган (төрле жирле үзенчәлекләрне дә исәпкә алып) мәдәниятә чагылыш таба; сүз биредә башлыча б.э.к. III-




*Азия харитәсе.(Борынгы грек галиме Птолемей күзаллавынча).*

II меңенче елларда башланган—чәчәк атуы б.э.к. IX-VII гасырларга туры килә—«хайваннар стиле» дип аталган аңлатмада чагылыш таба. «Хайваннар стиле», аерым алганда, Төньяк Кытайның, Төньяк Һиндстанның, көнчыгыш һәм төньяк фарсы илләренең, Кече Азия, Балкан ярымутравының төньяк өлеше һәм Рейннан алып Дунай буе илләренең, ә Адриатикада, ихтимал, бик тә серле этрусларның да *(Ельницкий Л. А. Скифия Евразийских степей: Историко-археологический очерк.—Новосибирск, 1977.—С. 5)* мәдәни йөзен билгели. Скиф культурасы ядкарьләре Кытай чиге биләмәләрендә, Минусинск түбәнлекләрендә, Тувада, Жидесуда, Урал буйларында, Түбән Иделдә, Дон, Кубань, Днепр бассейннарында киң таралган. Бу гажәеп күренеш Таулы Алтай истәлекләренә караган материалларда да аеруча киң чагылыш таба (шунысын искәртеп үтү зарур, Птолемей Азия Скифиясен Имав тавы скифының ике як өлеше буенча бүлеп карый, ә соңгырак тикшеренүчеләр моны Алтай дип фаразлыйлар).

Таулы Алтай халыклары тарихының б.э.к. I мең ел элек булган өлешен тарихчылар төп хронологик этапка бүлеп карыйлар: майэмир чоры (б.э.к. VII-V гасырлар), пазырык чоры (б.э.к. V—III гасырлар) һәм шибин чоры (б.э.к. II-I гасырлар) *(История Сибири.—Т.I: Древняя Сибирь.—Л., 1968.—С. 227, 296)*. Беренче этапка караган истәлекләр Көнбатыш Алтайның Майэмир далаларында беренче тапкыр 1911 елда А. В. Андрианов тарафыннан өйрәнелә. Тикшерелгән майэмир курганнары[1] гадәттә рәт-рәт булып тезелгәннәр, ә нигезләренә кайчакта божра рәвешендә таш тезеп чыкканнар. Мәетләрне 1-3 метр тирәнлектәге чокырларга төшерелгән кечерәк кенә бураларга күмгәннәр. Аның арт ягына мәетнең шәхси кирәк-яракларын—сугыш коралларын (хәнҗәр, пычак, балта яки чүкеч, җәя белән ук һ. б.), бронзадан эшләнгән көзгеләрен һәм бизәнү әйберләрен куйганнар. Бурадан читтәрәк йола буенча барлык дирбиясе белән 2-3 ат та җирләнгән.



*Күчмәннәрнең күмү йоласында кулланылган әйберләр. (Әстерхан өлкәсенең Лапас авылы янында табылган каберлектән). X гасыр.*

Пазырык этабы истәлекләрен (бу исем Олы Улаган елгасы үзәнендәге Пазырык дип аталган табигый ызанда 1929 елда алып барылган беренче казу эшләре белән бәйләнгән) Таулы Алтайның бик күп почмакларында очратырга мөмкин. М. П. Грязнов, С. В. Киселев һәм С. И. Руденко житәкчелегендәге экспедицияләр тарафыннан өйрәнелеп, даны бөтендөньяга танылган Пазырык, Башадар, Туэктин кебек олы курганнардан тыш соңгы дәвердә Кош-Агач районының Ала Гаил һәм Уландырык табигый ызаннарында һәм Елангаш елгасының өске агымнарында яңа курганнарда казыну эшләре алып барылды. Археологик өйрәнүләр шуны күрсәтә, Пазырык курганы тибындагы тарихи истәлекләр Алтайдан шактый ерак төбәкләрдә—Көнбатыш Казакъстанда, Тувада, Монголиядә һ.б. җирләрдә дә күзәтелә.

Мондый курганнар, гадәттә, төньяктан көньякка сузылганнар, аларның саны йөздән һәм аннан да артыбрак китә. Шулай ук аерым-аерым курганнар һәм рәт-рәт булып тезелгән үрләр дә очрый. Әйтергә кирәк, Пазырык курганнары үзенең тарихи әһәмияте ягыннан Мисыр фиргавеннәре хәзинәләреннән бер дә ким түгел. Кызганычка каршы, талаучылар күмү бүлмәләренә галимнәргә караганда иртәрәк «үтеп керсәләр» дә, тарих фәненең «бәхете» бар икән: соңгылары исә борынгы төрки сәнгатенең чын мәгънәсендәге сәнгать әсәрләренә

---

[1] Курганнарның—кайбер белгечләр фикеренчә, «корган», «корылыш» дигән борынгы төрки сүздән ясалган булуы ихтимал, дигән фикерләр бар.

юлыктылар. Пазырык тибындагы курганнарның гаҗәеп әһәмияте шунда ки, мәңгелек туңлык катламнарында күмелеп калганлыктан, агач, тире, киез, тукыма әйберләр бик яхшы сакланганнар, ә гадәти шартларда аларның эзе дә калмаган булыр иде, әлбәттә. Олы курганнарда хәтта ат үләксәләре, карагайдан эшләнгән табутларда күмелгәннәрнең мумияләре хәтле безнең көннәргә кадәр килеп җиткәннәр. Пазырык курганнарында мәңгелек туңлыкның барлыкка килүенең сәбәпләре шуннан гыйбарәт, алар, бердән, диңгез өсте тигезлегеннән 1600 м биеклектә урнашканнар, калын таш үрләр үзенә күрә дымны тотып торучы конденсатор хезмәтен үтәгән: югары катламнарда җыелган су каберләргә үтеп кергән һәм анда боз булып катып, каберлектәге барлык әйберләрне каплап алган, безнең көннәргәчә саклаган.

Олы курганнар төрки «патшаларның» һәм « каһиннәрнең» төрбәләре булып хезмәт иткән *(Руденко С. И. Культура населения Алтая в скифское время.— М.—Л., 1960.—С. 176 и сл.; Ткаченко О. Принцесса Алтая—владычица скифов? // Наука и религия.—1999, № 10.—С. 44-46).* (Җәяләр эчендә генә әйтеп үтик, О. Ткаченконың әлеге мәкаләсе Азиядә хакимдарлыкка омтылучы һәм һәрвакыт яу йөрешкә ашкынып торучы матур-чибәр хатын-кызларның—амазонкаларның яшәве хакындагы антик чорлардан да яшәп килгән риваятьләрнең хаклыгын тагын бер кат раслый кебек.) Алтай җирендә алар олы-олы таш үрләр белән билгеләнеп куелганнар. Мәет күмү корылмаларының зурлыгын күз алдына китерү өчен 5 нче Пазырык курганының масштабларын искә алу да җитәдер, мөгаен: әйтик, үренең диаметры 42, биеклеге 4 метрга җитә. Кече курганнар (аларның диаметры 6-12 метрдан артмый) үзләренең корылышы ягыннан «патшалар» һәм « каһиннәр» кабереннән әллә ни аерылып тормый, бары тик күпкә хәерчерәк кенә «җиһазландырылган» була. Күрәсең, кече курганнарда югары этносоциаль кастага карамаган ярлы «скиф»ләрне җирләгәннәрдер.

Археологик материаллар күрсәткәнчә, Пазырык культурасы эзсез югалмаган, ә бәлки вакытлар үтү белән «буланкобан» дип аталган бер каберлек исеме белән аталып киткән һуннарныкына охшаш культурага трансформацияләнгән.

Таулы Алтайның Катанда, Каракол, Песчаная, Урсул елгалары үзәнлекләрендәге мәгълүм шибин этабы каберлекләре дә үзләренең күләмнәре, төзелешләре һәм күмү ритуалларының характерлары ягыннан Пазырык курганнарына охшаш. Унҗиде ат скелеты күмелгән Берельский курганнарында эзләнүләр алып барганда, Шибин курганнары тирәсендә (1865) һәм «хайваннар стилендә» эшләнгән гаҗәеп камил көнкүреш әйберләре һәм кием-салым үрнәкләре табылган. Моннан тыш, шибин чорында алтай скифләре бронза урынына ныклап торып тимер куллана башлыйлар. Катанда курганнарында беренче тапкыр В. В. Радлов казыну эшләре алып бара.

Скиф чорында таулы алтайлар киң күләмдә терлек үрчетү белән шөгыльләнәләр. Алар җәйләрен таулар итәгендәге үзәнлекләрдә күченеп йөриләр, кышын исә кар бик күп яумаган, мал-туар ризык-үлән табардай тау битләүләренә күтәрелгәннәр. Төп асрау хайваны булып ат исәпләнгән— ул йөк ташу хезмәтен башкарып, ите ризык итеп кулланылган, ә эшкәртелгән тиресе кием-салым «тегү» өчен файдаланылган. Үлүченең тормышта тоткан урынына, җенесенә һәм яшенә карамастан барлык каберлекләрдә дә атларның да күмелгән булуы, аларның алтайлылар хуҗалыгында мөһим урын тотканлыгы хакында сөйли. Атлардан тыш алтайлылар озын-озак күченеп йөрүләргә җайлашкан сарыклар да үрчеткәннәр. Үз чиратында, сарык йоны киез, ияр асты җәймәсе, йон тукыма хәзерләү өчен төп чимал булып хезмәт иткән; кыскасы, сарык йоны киендергән дә, сөендергән дә. Сарыктан кала алтайлылар кәҗә, сыер, як, йорт кошлары да асраганнар.

Болардан тыш алтайлылар көнкүрешендә аучылык зур урын алып торган, моның шулай икәнлеген поши, болан, тау кәҗәсе һәм бәрәне, бүре, барс һәм киек хайваннарның сурәтләре кием-салым, шулай ук башка көнкүреш әйберләрен бизәүдә киң кулланылуы раслап тора. Болан мөгезеннән бизәү һәм бизәнү әйберләре, каплан, кеш, тиен, ас һәм кама кебек киекләрнең тире-мехлары киң кулланылышта булу аучылыкның шөгыль

булудан битәр, һөнәр-промысыл дәрәҗәсенә күтәрелүе хакында сөйли.

Казыну эшләре материалларыннан күренгәнчә, ул чор төркиләренең торакларын өч төргә бүлеп карарга мөмкин булыр иде: болар—туздан эшләнгән чатырлар, киез тирмә-йорталар һәм буралаган агач йортлар. Пазырык курганнарының берсендә, мәсәлән, читәннән үреп эшләнгән тирмә табылган; шулай да өйрәнелгән Таулы курганнарының күбесеннән берәр һәм икешәр рәтле агач бураларның саклануы—бу төр торакның өстенлек итүе хакында сөйли. Шунсын да әйтергә кирәк, идән һәм түбән сайгакларының агачларны урталай ярып түшәлүе мондый йортларның даими һәм кыш көне тору өчен җайлангандыр, дигән нәтиҗә ясарга урын калдыра. Өйләрнең диварлары исә киезләр һәм йон келәмнәр белән эчләнгән була, күп кенә очракларда мондый келәм-җаймәләр идәнгә дә җәелгән. Алтай төркиләренең тораклары, Пазырык курганында табылган келәмнең зурлыгы белән исәпләсәк (6,5х4,5 м.), шактый ук иркен булгандыр дип фараз кылырга мөмкинлек бирә.

Алтайлыларның киемнәре бик тә үзенчәлекле булган. Ирләр киндердән сугылган күлмәк, юка итеп эшкәртелгән тиредән тегелгән ыштан һәм киез чикмән кигәннәр, каеш билбау буганнар. Аяк киеме түбәндәгеләрдән торган: иң астан тула оек, аның өстеннән югары куныччлы, үкчәсез, йомшак тире итек (читек) киелгән, ул төрле төстәге, дүрт почмаклы тире поскаклар белән бизәлгән. Башларын колакчынлы бүрек яки тире белән тышланган киез башлык белән каплаганнар. Хатын-кызлар киеме, әлбәттә, бизәклерәк булган. Курганнарның берсендә бик тә затлы итеп эшкәртелгән һәм төрле бизәкләр белән бизәлгән тиен тун табылган; тун өстеннән кама мех-тиресе белән каймаланган күкрәкчә киелгән, баш киеме дә затлы мехтан тегелгән. Читекләрем пар булса да, берсе-берсенә охшамаган дигәндәй, аның берсе каплан тиресеннән, икенчесе шулай ук башка затлы тиредән тегелеп, үкчәсе сәйлән һәм асылташ бөртекләре белән чигелгән, куныччлары исә затлы тире поскаклары белән чигеп бизәлгән. Болары рәешкә кия торган аяк киемнәре булган; монда шунсын да искәртеп үтү зарур: аяк киемнәрен болай бизәү-чигү азиатларга хас булганча чүгәләп утырганда кунакларга күренеп торсын дип эшләнгән.

Алтай халыкларының скиф чорында ук югары мәдәни-культурага ирешүе хакында көндәлек кирәк-яракларны да югары сәнгать осталыгына житкереп, киек-җанварлар стилендә башкарулары ачык сөйли; сәнгать әсәрләре, башлыча, агачтан һәм сөяктән уеп эшләнгән, тире һәм киез дә киң кулланылыш тапкан, бизәлештә силуэт, барельеф һ. б. алымнар кулланылган; ул гына да түгел, бер сурәтне тудыруда күп төрле материаллардан да файдаланганнар.



*Шәрык сугышчылары. Хар-хад тавындагы кыяларга уелган рәсемнәрдән*

Таулы алтайлыларның сурәтле сәнгате нигезен, әлбәттә, мифологик образлар тәшкил иткән: кешеләрне чолгап алган реаль киек-җанварлар (поши, болан, тау кәҗәсе) белән беррәттән фантастик аждаһалар (юлбарыс гәүдәле, кош канатлы, мөгезле һәм җәйран колаклы грифоннар, җәнлек колаклы, муены белән башы олы-дәү кикрик белән бизәлгән бөркетләр һ. б.) тәшкил иткән. Шулай ук төрле җәнлек-җанварларның көрәше сурәтләнгән күренешләр дә киң файдаланылган.

Һәр борынгы халыкларныкы кебек үк, Алтай скифләренең тормышына да һәртөрле куркынычлар янап торган. Әйтик, таулы алтайлыларның хәрби көнкүрешен курганнарда табылган бик күп төрле сугыш кирәк-яраклары—бөтен скиф дөньясына хас кыска тимер кылыч (акинак), бронза кыскычыргаклар һәм катлаулы конструкциядәге уклы җәяләр шуның ачык мисалы булып тора. Саклану коралларыннан исә тире белән тышланып, сыгылма-бөгелмәле таякчыклардан үрелгән сугыш калканнары мәгълүм. Алтайлыларның хәрби бәрелешләре 5

нче Пазырык курганы табылдыгы—атлы сугышчылар сурәте чигелгән киез келәмдә, Петр Беренченең Себер коллекциясендәге атлы сугышчы сыннарында, баш тиресе салдырылган юлбашчы-саргаскәрнең мәете кебек ядкарьләрдә сакланып калган.



*Скиф ханбикәсе. Урта Азия.*

Скиф чорының Таулы Алтай курганнары—мал-мөлкәт һәм иҗтимагый бүленеш процессының башлануын күрсәтәләр. «Патша» һәм «каһиннәр»нең олы курганнары белән беррәттән чагыштырмача бай кешеләрнең төрбәләре һәм кече курганнарда төп халыкның ярлы җиһазландырылган каберлекләре дә очрый. Кабилә юлбашчылары һәм дин әһелләренең байлыгы һәм иҗтимагый баскычта ничек югары торулары хакында күмү корылмаларының гаҗәеп зур булуы һәм байлыгы да дәлил булып тора: анда бик күпләп шәхси тамгалы атлар, кыйммәтле тукыма һәм келәмнәр, алтыннан һәм асылташлардан эшләнгән бизәнү әйберләре дә «күмелгән». Скифләр хәрби һәм рухи юлбашчыларының күмелгәч тә тере калулары турында житди кайгырткannар, моның өчен аларның баш сөякләрен трепанацияләгәннәр (трепанация—операция ясау өчен баш сөяге куышлыгын ачу) һәм мәетләрне мумияләштергәннәр. Әйтергә кирәк, бу өлкәдә алар шундый осталыкка ирешкәннәр ки, мумияләр җир астында 2 мең елдан артык ятуларына да карамастан, аларда тән тиресе табигыйлеккә якын ачык төсен саклаган.

Юлбашчылар күмелгән саркофаглар исә чын мәгънәсендә сәнгать әсәре булып торалар. Ирләрне, гадәттә, бәйрәмчә киемнәрендә, хатын-кызларны исә бизәнү кирәк-яраклары белән бергә күмгәннәр. Тәнгә төрле буяулар белән шулай ук «җәнлекләр стилендә» бизәк-рәсемнәр төшерү (татуировкалар) кешенең сәяси һәм рухани дәрәҗәсен билгеләп торган. Искәртеп үтик, тәнне татуировкалау, дошманыңның баш тиресен салдыру, бергәләшеп тәмәке тарту, (ә бәлки наркотик матдәләр куллану?) һ.б.ш. ритуаллар Америка индеецларының кайбер гореф-гадәтләре белән охшаш икән.


Таулы Алтай төркиләре бик күп илләр һәм халыклар белән мәдәни һәм сәяси бәйланышлар урнаштырганнар. Бу хакта курганнардан табылган Рим һәм Кытай көзгеләре һәм ефәкләре, Иранның йон һәм декоратив тукымалары, Урта Азия һәм Мисырдан китерелгән ювелир әйберләр, сәйләннәр, муенсалар, Һиндстан ярларыннан кайтартылган энҗе-кабырчыклар, Алгы Азиягә хас эфир-майлы үсемлекләр «хәбәр» итәләр. Китерелгән тауарлар, мөгаен, җәнлек мехларына алмаштырылганнардыр; таулы алтайлыларның тормыш муллыгын шулай ук алтын табылмалары да тәэмин итеп торган. (Антик авторлар Азия түрендә «алтын өемен саклап торучы грифоннар» турында язып калдырганнар. Кытайлылар «алтын саклаучы грифоннарны юэджи/юэчжи дип атаганнар; тикшеренүче Г. Галун исә үзгәртелгән «zguja» (юэчжи) формасының ассириялеләрнең «iskuza» (скифләр) формасына тәңгәл килә дип исәпли.



*Җиз савыт. Безнең эрага кадәр III-II гасыр.*

Терлек үрчетү белән шөгыльләнүче Таулы Алтай скиф кавемнәре, сүз дә юк, көнкүрешләре һәм мәдәнияте ягыннан (бәлки чыгышлары буенча да!) Бөек Далада яшәүче башка кавемнәрнең тугандаш-тамыр өлеше булып торганнар. Алтай скифләрендә, Кара диңгез


буе скифләрендәге кебек ук, Ауропача антропологик типлар өстенлек иткән. Әмма югары катлаулар арасында «монголоид» элементлары да очрый; аларның бирегә үтеп керүен галимнәр Үзәк Азия халыклары белән бәйләп аңлаталар (мәсәлән, б.э.к. V гасырда Укок калкулыгына күмелгән «Алтай чибәре» төз, озын буйлы (170 см. га якын) азрак монголоид каны катнашкан Ауропача типтагы хатын-кыз була. Болар барысы да Алтай халыкларының Кара диңгез буе һәм Урал-Урта Азия скифләре—сарматлар, массагетлар, саклар, даглар, дайларның якын кардәшләре булганнар дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Таулы Алтай төркиләрен күрше скиф-сак дөньясы белән терлекчелекне алып барудагы уртаклыклар, бердәй иҗтимагый үсеш, материаль һәм рухи культураның охшашлыгы туганлаштырган. Сугыш коралларының, ат җигү дирбиясенең охшашлыгы, сәнгатьтә уртак мотивларның еш очравы аеруча гаҗәпләндерә. Таулы Алтай культурасының материаль һәм рухи билгеләре вакыт сынавын үтеп, Евразиянең хәзерге төрки халыклар мирасында (шул исәптән, татарларда да) сакланып калган.



*Табут капкачына уелган бизәкләр*

Шулай итеп, Алтайда безнең эрага кадәр 1 нче мең еллар дәвамында ким дигәндә бронза чорыннан алып бердәй культуралар традициясендә эзлекле үсеш барганлыгын расларга мөмкин. Шул ук вакытта безнең эраның 1 нче меңьеллыгына караган Алтай ядкарьләре бөтенләй башка күренешне чагылдыралар. Таулы Алтай кабиләләре һәм аңа якын тирәдәге далаларда яшәүчеләр «Халыкларның бөек күчеше» чоры белән бәйләнешле давыллы вакыйгалар уртасында торып калалар. Кара чирү булып көнчыгыштан көнбатышка хәрәкәт итүче монгол кыяфәтле (монголоид) кабиләләре басымы астында, Алтайның терлек үрчетү белән шөгыльләнүче кабиләләре безнең эрага кадәр II-I гасырларда хәзерге Казакъстан һәм Көнбатыш Себер далаларына күченә башлыйлар. Аларның бер өлеше, әлбәттә, әлеге монгол кыяфәтле, төрки телле кабиләләр арасында эреп югалалар.

Безнең эрага кадәр II гасыр башларыннан алып, безнең эраның I гасыр ахырларына кадәр Алтай һуннарның—көнчыгыш скиф токымнарының (бу хакта һуннар культурасының күчемлелеге һәм һуннарның скифләр белән социаль-сәяси бәйләнешләрдә торуы да раслый), Төньяк Кытай сөнниләренең, Урта Азия «ак һуннарының» (эфталитларының) һәм Ауропа һуннарының сәяси йогынтысында бара. Бу яктан Шипуново районының Тугозваново авылы янындагы каберлек һуннарның Алтай чоры ядкарьләренең гаҗәеп бер үрнәге булып тора. Каберга 30 яшьләр тирәсендәге мәһабәт гәүдәле ир-ат күмелгән булырга тиеш, күрәсең, ул берәр башлык-фәлән булгандыр: янәшәсендә күпсанлы сугыш кирәк-яраклары, эш кораллары, кием-салым, аяк киеме үрнәкләре, бизәнү-ясану әйберләре табылу шуңа ишарәли. Тугозвановодагы каберлектәге кебек кирәк-яракларның Урта Азия, Казакъстан, Урал, Түбән Идел, Төньяк Кара диңгез буе, Көнбатыш Ауропа кинлекләрендә табылган безнең эраның IV-V гасыр тарихы ядкарьләре белән дә охшашлыгы зур. Аларның шулай киң таралышы хуннарның—һуннарның көнчыгыштан көнбатышка хәрәкәт итүе белән аңлатыла.



*Пазырык курганында табылган бизәкләр*

Алтайның алдагы тарихи үсеше бирeдә **жужаньнарның (жуань-жуаньларның)** сәяси өстенлек итүе белән бәйләнгән. Аларның дәүләте Гюйлюхой тарафыннан IV гасыр уртасында оештырыла (хан утары Хангай янында урнашкан

була). 420 елда, каты сугышлардан соң Енисей кыргызларын, Хулюя хан идарә иткән чорда себер хэвэй кабиләләрен, Кытайны, Датан хан идарә иткән чорда Урта Азия һуннарын һәм юэчжаларны кул астына төшергәннән соң, алар Бөек Далада үз хакимлекләрен урнаштыралар. Тагын шунысы әһәмияткә ия, 439 елда «төрле кабиләләр кушылуыннан» барлыкка килгән «**Ашиннарның** биш йөз гаиләсе» (минем тарафтан ассызыкланды, биредә тарихта үтә дә билгеле булган төрки кавемнән булган хакимдарларның нәселбашы турында сүз бара) «жужаньнарга качып китәләр һәм, Алтай тауларының көньягында тамыр җибәреп, жужаньнарга тимер коя башлыйлар» *(Бичурин Н. Я. Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена.—М.—Л., 1950.—Т. I.—С. 221).* 552-555 елларда жужаньнар ашина ыруыннан булган Бумын каган һәм аның угыллары тарафыннан тар-мар ителәләр...


*Борынгы төркиләрнең таш сыннары (балбал)*

Бу нәүбәттән абруйлы тюрколог һәм монгол тарихын өйрәнүче Сергей Кляшторныйның кызыклы фикерен билгеләп үтәргә кирәк: жужаньнар аварларның гына түгел, ә бәлки 552 елгы вакыйгалар белән бәйләнешле рәвештә беренче тапкыр телгә алынган Урта Азия татарларының да («утыз татар» вәкилләре Бөек Төрки каганлыгына нигез салган Бумынны җирләгәндә катнашалар) турыдан-туры бабалары булып тора. Шулай ук XIII-XIV гасырлар тарихчысы Рәшид-эд-диннең фикере игътибарга лаек; ул болай ди: «**борын-борыннан** ук (!) татарлар бик күп кабиләләр һәм өлкәләрне яулап алганнар һәм аларның хакимдарлары булганнар». Уйларга кирәк, биредә сүз X-XII гасырлардагы төрки дәүләтләр турында түгел *(Гумилев Л. Н. Поиски вымышленного царства.—М., 1970.—92, 102-103; Кляшторный С.Г. Государства татар Центральной Азии (дочингисова эпоха) // Mongolica: К 750—летию «Сокровенного сказания».— М., 1993.—С. 139-147),* ә бәлки шактый борынгы чорлар хакында бара.

Соңрак Алтай тарихы **«төркет»/»төрки»** (кытайча—«ту-кю»; соныннан бу атама фәндә аңарчы да, аннан соң да яшәгән барлык төрки телле кабиләләр һәм халыкларга ябышып кала) кабиләләре белән бәйләнгән. VI гасырның беренче яртысында алар төрки кабиләләрнең күпчелеген эченә алган берлек—Төрки каганлыкка нигез салалар, ә Алтай төркиләре аның үзәген тәшкил итәләр. Көнчыгыштан каганлыкның биләмәләре Кытай империясе, көньяктан Һиндстан, ә көнбатыштан Византия белән чикләнгәннәр (хөрмәтле С. Г. Кляшторныйның «төрки каганнар беренче Евразия империясенә нигез салучылар булганнар» дигән фикере белән килешмәскә җөрьәт итәм» *(кара: Кляшторный С. Формирование древнетюркской государственности: от племенного союза до первого Тюркского каганата/ / Панорама—форум.—1997.—№ 1.—С.121).* Безнеңчә, беренче Евразия империясенә әлеге биләмәләрдә безнең эрага кадәр VII-V гасырларда ук сәяси өстенлек урнаштырган «патша» кабиләләр—скифләр нигез сала. VI гасырның көньяк яртысында үзара ызгышлар нәтиҗәсендә Төрки каганлык үзәге Җидесу булган Көнбатыш, үзәге Монголия булган Көнчыгыш өлешләргә бүленә, 630 елда Көнчыгыш Төрки каганлык яшәвеннән туктый. 682 елда яңадан

аякка баскан Икенче Көнчыгыш Төрки каганлык 745 елга хәтле, ягъни Үзәк Азия далаларында шундый ук гайрәтле Уйгур каганлыгы пәйда булганчы яшәп килә.

Бу очракта тарих фәннәре докторы Әзһәр Мөхәммәдиевнең төркиләр (төркетләр)—Төрки каганлыкның нигез ташын тәшкил иткән кабиләләр—һуннарның турыдан-туры дәвамчылары дигән игътибарга лаеклы фикерен билгеләп үтми булмый. Төрки каганлыгына нигез салганда һуннар гомумдәүләти «төрки» дигән сәяси атаманы кабул итеп алалар, аның асыл мәгънәсе түбәндәгеләрдән гыйбарәт: 1) ил, дәүләт; 2) көчле, кодрәтле; 3) тәртип, закончалылык *(Мөхәммәдиев Ә. Һуннар һәм Туран язмалары.—Казан, 2000.—11 б.)*. Бу фараз, өлешчә, Кытай тарихчысы Шы-гу (VII) һәм Византия тарихчысы Симокатта (VII) фикерләре белән дә туры килә.

Төрки каганлыкларга кергән кабиләләрнең культурасы археологик материаллар, төркиләр үзләре язып калдырган рун язмалары һәм башка телләрдәге язма чыганаклар нигезендә өйрәнелгәннәр. Таулы Алтайның шушы чорга караган күпсанлы ядкарьләре булып, әлбәттә, каберлекләр санала, ә алар, үз чиратында, тикшеренүчеләр тарафыннан ике хронологик чорга—кудырган (V-VII) һәм катанда (VII—VIII) чорына бүленәләр *(Гаврилова А. А. Могильник Кудыргэ как источник по истории алтайских племен.—М.—Л., 1965)*.

Кудырган курганнары Катанда, Курота, Яконура, Туэкты һәм Кокса тирәләрендә өйрәнелгәннәр. Каберләр жир өсте тигезлегендә биек булмаган үр яки таш диварлар белән «билгеләп» куелганнар. Үрләрнең иң зурлары аркылыга 20 метр, биеклеккә 1,5 метрга житәләр. Мәетләрне башын көньякка яки көнбатышка каратып тирән булмаган канауларга аркасына яткырып жирләгәннәр. Мәеттән аз гына өстәрәк яки янәшәдә йөгәне һәм ияре белән ат мәетен күмгәннәр. Кайчакта «ат урынына» дирбияне генә «теге дөньяга озатканнар»; атның мәете бронза һәм көмеш тәнкәләр белән чукланган йөгән, тимер авызлыклар белән «бизәлгән» булган. VI-VII гасырларда Алтайда каты астарлы ияр барлыкка килә. Өзәнгеле (алар VII гасырдан билгеле), каты астарлы ияр төрки сугышчысына ат чабып барган жирдән уктан төз атарга һәм кылыч белән дошманын иркен чабарга мөмкинлек биргән; бу үз чиратында орышта күп файда китергән. Кудыргэ каберлегеннән табылган ияр очасының шомартылган сөяк түшәлмәсе төрки сугышчының гомуми тышкы күренешен күзалларга мөмкинлек бирә. Ул монголоид кыяфәтле, мыеклы булган, өстенә күлмәк, тубык сөягенә кадәр житкән киң чалбар, киң кунычлы итек кигән. Алар аркаларына озын садак асканнар, кулларыннан төшмәгән уклы җәя һәрчак орышка әзер булган. Алтай төркиләре һуннарныкына караганда кыскарак, әмма чабып барган жирдән атарга унайлырак катлаулы уклардан файдаланганнар. Каберлекләрдә сакланган каен тузыннан эшләнгән садаклар, гадәттә, эре тимер өч җәпле очлык белән төгәлләнгән уклар һәм сөяк шар-«сыбызгылар» белән тулы диярлек. Сугышчылар көбәләр, башлыклар кигәннәр; ук белән бергә ике ягы да үткенләнгән яки бер генә пычаклы озын кылыч, сөнге һәм хәнҗәр белән коралланганнар. Байлыгына һәм дәрәҗәсенә карап, сугышчылар бронза, көмеш һәм алтын тәнкәләр белән бизәлгән бил каешы буганнар.

Катандада, Туэктада, Кураеда һәм Шиба аймагында табылган Катанда тибындагы ядкарьләр төрки дөньяда таркалу башлануы хакында фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Табылдык әйберләр һәм күмү йоласы буенча курганнар өч төргә бүленә. Үзәк урын жайдакның атыннан казык койма яки жир үр белән каймаланып алынган (биеклеге 1 метр, аркылысы 9 метр) каберлекләр аеруча күпсанлы. Мондый каберләрдә бронза һәм көмеш белән бизәлгән тезген-йөгәннәр, асыл ташлы бил каешлары һ. б. әйберләрне табарга мөмкин. Ә тупас балчык савытлар һәм чит жирләрдән китерелгән әйберләр юк диярлек. Димәк, биредә ярлы кучмәләрне күмгәннәр, дип фараз кылырга мөмкинлек бар.

Әйткәнебезчә, аркылысы 40 метрга житкән курганнар—аларга баймөлкәтле кешеләр күмелгән—аеруча бай зиннәтле булулары белән аерылып торалар. Мондый курганнардагы кабер өстенә, гадәттә, агачтан түшәм түшәлгән,

ә мәетне төбенә киез салынган агач ялгашларга яткырганнар. Күмү мәрәсимен байларча бизәлгән жайдак-атлар озата барган. Бу курганнар белән шулай ук таш «балбал»ларның да бәйләнеше бар. Әлеге борынгы төрки таш сыннар көнчыгыш Евразия далаларында—Үзәк Азиядә, Җидесуда, Казакъстанда, Алтайда, Тувада һ. б. җирләрдә киң таралган; алар Төньяк Кара диңгез буйларында да житәрлек. Сыннарда һәрчак ир-атлар гәүдәләндерелгән. Аның каршында, күпчелек очракта сынны әйләндереп алган таш койма эчендә, борынгыдан килгән йолалар башкарылган. Борынгы авторлар шушыңа охшаш йола турында болай дип хәбәр итеп калдырганнар: «Аннан соң алар көлне күмәләр һәм истәлекле билге итеп кабергә агач багана утырталар. Кабер өстенә мәрхүмне һәм үзе исән чагында катнашкан уңышларны гәүдәләндергән бина житкерәләр. Әгәр ул кайсы да булса орыш вакытында бер дошманын үтергән булса, кабер каршына бер таш куялар. Ташлар кайчак йөзгә, хәтта меңгә кадәр житә» *(Федоров-Давыдов Г. А. Искусство кочевников и Золотой Орды.— М., 1976.—С. 90)*. Бу «мәгълүмат» Таулы Алтай күмү ядкарьләрендә, сүз дә юк, чагылыш тапмыйча калмый: ташлар мәрхүм шәхси үтергән дошманнарны гәүдәләндерә: гади сугышчы икән—эшкәртелмәгән таш, атаклы сугышчы икән—«балбал» (тупас эшкәртелгән таш) куелган. Үлүчеләрнең үзләрен сынландырганда сынчылар йөз төзелешен, сакал-мыеклар, кием-салымның аерым өлешләрен охшатып ясарга тырышканнар.

Мәгълүм булганча, Төрки каганлыкның Алтай чоры төркиләре, нигездә, күчмә терлекчелек белән шөгыльләнгәннәр. Алар сарык һәм атлардан тыш, кәжә, мөгезле эре терлек, дөя һәм як хайваннары асраганнар. Терлекләрне ел дәвамында жәйләүдә йөрткәннәр. Кешеләрнең бер өлеше иген иккән—«китмәнле игенчелек» үсеше хакында каберләрдә табылган орлык төйгеч һәм тары ярмасы калдыклары сөйли. Кайбер тикшеренүчеләр бу вакытта Алтайда ясалма сугару да кулланылган дип исәплиләр. Скифлар чорында да, һуннар чорында да аучылык хужалыкта ярдәмче роль уйнаган, мех житештерү «экспорт»ның нигезен тәшкил иткән. Алтай осталары чуен кою белән дан тотканнар; бронза, көмеш, алтыннан киек-жанвар сурәтендәге катлаулы бизәнү әйберләре житештергәннәр. Ташчыларның осталыгы исә сугышчыларның монументаль сыннарында һәм аерым ташларга, таш кыяларга, көнкүреш әйберләренә төшерелгән рун язмаларда сакланып калган (бу язу төркиләр тарафыннан, Урта Азия төркиләре язуы нигезендә, VI-VII гасырда тудырыла), аларда теге яки бу тарихи вакыйгалар, хужалык итү алымнары, көнкүреш хәлләре һәм социаль мөнәсәбәтләр тасвирланган. Әйтик, төрки гаскәр башлыгы Күл-Тәгин (731 елда үлгән) истәлегенә торгызылган рун язма ядкарендә, башлыча, «утыз-татар», «тугыз-татар» дип аталган Үзәк Азия татар кабиләләре арасындагы мөнәсәбәтләр хакында да хәбәр ителә...

**Булат ХӘМИДУЛЛИН**

# ГАРӘП ИЛЛӘРЕНДӘГЕ ТЕЛ ПРОБЛЕМАЛАРЫ

ТАТАРСТАНДА ЛАТИН ГРАФИКАСЫН ГАМӘЛГӘ КЕРТҮ МӨНӘСӘБӘТЕ УҢАЕННАН

НИГӘ ӘЛЕ гарәп дөньясына барып төштек соң без? Әллә үзебездә дә хәл итәсе мәсьәләләр җитәрлек түгелме? Моның үз хикмәте бар. Ераккарак карап күз йөртик әле.

Гарәп теле дөньядагы зур тарихлы телләрдән санала. Аның кайчан барлыкка килүенә бәйле теорияләр IX-XI гасырларда киң таралган була. Берәүләр гарәп телен Аллаһы Тәгалә бар иткән, ул аның барлык байлыгын Адәм галәйһи сәламгә өйрәткән диләр, икенче фикердәге галимнәр гарәп теленең нигезләре—Адәм галәйһи сәламгә һәм башка пәйгамбәрләргә дә бирелгән, алар да аның үсешенә өлешләрен керткәннәр, Мөхәммәт пәйгамбәргә генә гарәп теленең байлыгы камил итеп бирелгән дигән караштa торганнар.

Телнең барлыкка килүе кешеләр арасында килешеп яшәүнең нәтиҗәсе ул дип аңлатучы галимнәр дә булган. Бу фикерләрдә грекларның телнең барлыкка килүе турындагы теорияләре чагылып китә кебек. Мәгълүм ки, грек философлары да сүзнең-телнең иҗатчылары илаһи затлар һәм философлар дип санаганнар. Гарәпләрдә лингвистика традициясе VIII гасырларда башланып, XV гасырларга кадәр дәвам итә. Бу фәннең зур үсеш кичергән чорлары XI—XII гасырларга туры килә. Урта гасырлардагы чыганакларда беренче грамматика китабын төзүче итеп Әбу әл-Әсүәд әд-Дуәли күрсәтелгән *(Бу турыда кара: Әл-Мөбарәк.Ән-нәхү әл-гарәби.—1974, Бәйрут-әл-Каһирә).* Хәзерге гарәп илләрендә ана телен (гарәп телен) укытуны гамәлгә кую проблемалары бармы соң? Югары уку йортында ана телендә уку-укыту җайга салынганмы? Терминнар мәсьәләсе ничек хәл ителә? Дәүләт җитәкчеләре тарафыннан тел проблемаларына игътибар бирeләме? Бу сорауларга җавапларны табу катлаулы шөйдер, әмма гарәпләрнең гыйбрәтләнерлек бихисап эш-гамәлләре бар һәм аларның бәгъзеләре белән укучыларны да таныштырып узу зыян итмәстер, шаять.

Югарыда санап үтелгәннәрне урынсыз бирелгән сораулар дип кабул итмәскә кирәк. Төрле илдә, төрле дәрәҗәдә булса да андый проблемалар бар һәм гарәпләр ватанында да юк түгел икән шул. Бары бер генә гарәп илендә, Сәгуд Гарәбстанында гына мондый мәсьәлә хәл ителгән. Ә менә гарәп дөньясының көнбатышында урнашкан илләрендә аеруча әл-Җәзаир (Алжир) да гарәп телендә уку-укытуны гамәлгә кертүдә зур кыенлыклар бар. Әл-Җәзаир 132 ел дәвамында Франциянең колониясе булды. Моның аянычлы нәтиҗәсе һаман да үзен сиздерә. Әл-Җәзаир гарәпләренең яртысы үз ана телләрендә аралаша белмиләр яки бик начар сөйләшәләр. Гарәп илләре бергәләшеп бу мәсьәләне кичекмәстән хәл итүне кирәк табып, 1961 елда даими эшләүче «гарәпләштерү» координация бюросын төзеде. Бу оешмага фәнни китапларны тәрҗемә итү, югары уку йортларында төгәл фәннәрне дә гарәп телендә укытуга ирешү, гарәп терминологиясен унификацияләү, классик гарәп телендәге борынгы әсәрләрне тәнкыйди өйрәнеп нәшер итү, чит илләрдәге гарәп теленә өйрәтү үзәкләренә ярдәм итү һәм башка вазыйфалар йөкләтелгән иде. Куелган максатларны гамәлгә ашыру өчен Мәгърибнең башкаласы Рабат шәһәрендә 1964 елның июненнән «Әл-Лисану-әл-гарәбийү» («Гарәп теле») журналы басылып чыга башлады. Югары уку йортларында моңарчы төгәл фәннәр инглиз, француз телендә укытып киленде.

Галимнәр, җәмгать эшлеклеләре, укытучылар арасында исә гарәп телен яклаучылар саны көннән-көн арта барды. Алар барлык фәннәрне дә ана телендә укытуга күчәргә кирәклекне, милли горурлыкны торгызырга, үз ватаныңны хөрмәт итәргә кирәклекне исбатлый килделәр. Әмма Аурупада укып кайткан гарәпләр һәм элеккеге интеллегенция вәкилләре арасында моңарга каршы чыгучылар да булды, андыйлар хәзер дә юк түгел. Бу фикер тарафдарлары гарәп теле дөньядагы фән һәм техниканың үсешенә яраклашып өлгерә алмый, чит телләрдә нәшер ителгән фәнни чыганакларны тәрҗемә итүдә тоткарлыклар барлыкка килә, гарәп терминолексикасын булдыруда төрлелек һәм төгәлсезлекләр, буталчыклар барлыкка килә һәм башка сәбәпләр белән дәлилләргә маташалар.

Бер төркем гарәп галимнәре терминнарны ясауда классик гарәп теленә, борынгы фәнни хезмәтләргә мөрәҗәгать итәргә һәм телнең үз мөмкинчелекләрен тулырак файдаланырга кирәклеген әйтәләр. Башка телләрдән алынган сүзләрне файдаланган очракта да ул термин гарәп теле кагыйдәләренә буйсындырып ясалырга тиешлеге дә искәртелә. Мәсәлән, **сәйара—автомобиль** (сәрә-йәсийрү—хәрәкәт итү), **тайара—очкыч самолет** (тара—йатыйрү—очарга, очу һ. б.). Дөрес, терминнарны куллануда, ясауда чуарлыклар да җитәрлек. Еш кына инглиз яки француз алынмаларын бозып әйтүләр күзәтелә (**уксиҗин—кислород, исбират—запас частьлар, җенирәйтер**—генератор һ. б.)

Мәгълүм ки, фән һәм техника терминнарын тәртипкә салганда, гарәп әдәби теле белән халык сөйләмен мөмкин кадәр якынайту ихтыяҗы туа. Югыйсә, алар арасында булган каршылыклар артачак кына. Моны хәл итү өчен гарәп илләренең үзара бердәмлеген ныгыту, сәяси тотрыклылыкны булдыру һәм башка мәсьәләләрне хәл итү кирәк. Шул чагында фән һәм техника өлкәсенә караган яңа сүзләрне (терминнарны) ясау, аларны барлык гарәп илләрендә берүк мәгънәдә куллану (унификацияләү) мөмкинчелеге туачак. Бу юнәлештә зур эшләр башкарылды да инде. Проблеманың җитди төсмер алуын шуннан чыгып билгеләргә була, гарәп илләренең башлыклары да бу кыенлыклардан чыгу юлын эзлиләр.

Гарәп илләрендә ләһҗәләр (диалектлар) бик күп. Алар арасында «өстенлеккә» ия булганы да бар, ул—Мисыр диалекты. Гарәп дөньясында төшерелгән ун кинофильмның сигезе Мисыр студияләрендә төшерелгән, диләр. Мәдәният, сәнгать программалары, радио, телевидение тапшыруларының күпчелеге Мисыр ләһҗәсендә башкарыла. Шуңа күрә бу ләһҗәне Әл-Җәзаирда, Гыйракта, Сүриядә, Суданда, Иорданиядә дә аңлыйлар.

Гарәп диалектлары арасында зур аерымлылык булса да, аларның генетик кардәшлеге сакланган һәм сакланачак та. Күренекле галим Г. Ш. Шарбатов хәзерге гарәп теленең диалектларын сигезгә бүлеп карарга тәкъдим итә: Гарәбстан ләһҗәсе, Гыйрак, Сүрия, Ливан, Фәластыйн, Мисыр, Судан һәм Мәгъриб ләһҗәләренә (Ливия, Әл-Җәзаир, Тунис, Марокко һәм Мавритания керәләр).

Әл-Җәзаирда җитәкче булып эшләячәк кешегә гарәп теленнән имтихан тапшыру мәҗбүри. Бу канун 1980 елның 10 маенда ук гамәлгә кертелде һәм бүгенгә үз көчендә кала.

Согуд Гарәбстанында барлык чит ил оешмалары рәсми сөйләшүләрне, килешүләрне һәм эш кәгазьләрендә гарәп телендә генә алып баралар. Бу канунны бозылучыларга зур җәза—акчалата зур салым түләү яисә хезмәттәшлекне туктату кебек җәза бирү каралган. Димәк, бу илдә чит илләр белән аралашу бары тик гарәп телендә генә алып барыла.

Болар мәгълүмат буларак кына искә алынды. Административ чаралар белән генә барлык каршылыкларны хәл итү мөмкин эш түгел, әлбәттә.

Классик гарәп теле дистә гасырлар дәвамында яшәп килде, ләкин хәзерге вакытта аңарга да куркыныч яный башлады. Гарәп илләрендә җирле сөйләм телендә сөйләшүчеләрнең саны арта бара. Гаиләдә, хөкүмәт оешмаларында да җирле сөйләм телендә аралашалар, балалар мәктәпкә кергәч, барлык фәннәрне гарәп әдәби телендә

үзләштерергә тиешләр. Бу аларга шактый гына кыенлыклар тудыра. (Моны безнең өчен XVII—XVIII йөзләрдә гамәлдә булган язма татар телен өйрәнү белән чагыштырырга булыр иде.) Киләчәк 200 ел эчендә гарәп дөньясының җирле сөйләмнәрен, үзенчәлекләрен эченә алган өч яисә дүрт телнең барлыкка килүе дә ихтимал дип, фаразлаучы галимнәр дә бар (Ч. Фергюсон, Ф. Талмуди) Каһирә сөйләменә нигезләнгән Мисыр теле, Багдад сөйләменә нигезләнгән көнчыгыш гарәп теле, Димәшкъ сөйләме нормаларына нигезләнгән Сүрия һәм Омдурман-Хартум сөйләменә нигезләнгән Судан теле *(Ч. Фергюсон, 1964.—437 б.).*

Әмма монысы фаразлау гына әле, ләкин кара көчләрнең барлыгын да онытмаска кирәк. Мәсәлән, Аурупада, Америкада укып кайтучы гарәпләр арасында латин графикасына күчәргә кирәк дип, йөрүчеләр дә юк түгел. Бу яңалык түгел түгелен, чөнки христиан миссионерлары XII гасырлардан ук, мондый теләк-тәкъдимнәрен белдерә, әйтә килделәр. XIX йөз азагы XX йөзнең 20 елларында да Иранда да мондый бәхәсләр була килде. Гарәп язуына бәйләнү вакытлар узу белән бер яңарып ала-алуын. Әгәр бу реформа гамәлгә ашкан булса, һичшиксез, мөселман дөньясын таркатуга зур адым булыр иде. Совет империясендә яшәгән мөселман төркиләре мисалында мондый реформаның нәрсәгә китереп җиткергәнлеге ачык күренә булса кирәк. Грузин, әрмән, кытай, һинд, яһүд, бирма һәм башка халыкларның үзенчәлекле язулары бүген дә гамәлдә һәм аларның латин графикасын кабул итәргә әзерләнүләре турында ишетелгәне юк. Халыкның артта калуын, гарәп язуыннан эзләргә кирәкми, аның гаебе юк. Гаеп—бозык һәм империячел сәясәттә яшерелгән.

Гарәп илләрендә һәм ислам дөньясының шактый өлешендә гарәп язуы яши һәм яшәр дә. Монысы шик уятырга тиеш түгел.

Бүгенге көнгә кайтып, Татарстанда латин графикасын гамәлгә кертүгә карата мөнәсәбәтне белдерми булмый: өйләнә-тирә мохитне һәм киңрәк офыкларны күзаллап эш итәргә телибез икән, бу адымны курыкмыйча ясарга кирәк. Милли аңны үстерүгә моның ярдәме, һичшиксез, зур булачак. Гарәп язуы безгә бик газиз. Танымаган кешенең дә бу язуны күрү белән күңелендә җылы бер нур хасил була, ә танып укый башлаган татар кешесендә, борынгы тарихыбыз белән горурлану хисе туа һ. б. Димәк, без ул язуны беркайчан да онытырга тиеш түгелбез. Ни генә әйтсәк тә, туган телебезнең кануннарын уңышлы чагылдыра ала торган латин язуыннан башка язу хәзергә юк. Фән һәм техника үсеше белән генә бәйле рәвештә түгел, ә кардәш төрки халыклар белән киләчәктә дә бер гаиләдә яшәүне истә тоткан хәлдә, озакка сузмыйча латин язуын гамәлгә кертү бик зарури.

Сүзебезнең башы Әл-Җәзаир гарәпләре турында иде. Әлбәттә Тунис һәм Мароккода гарәп-француз ике теллелеге яшәп килә. Монысы зур шәһәрләрдә яшәгән татарларның, ягъни урыс сүзләрен бутап сөйләүчеләрнең теленә охшашрак. Ләкин гарәп теле беркайчан да буйсындырылган тел булмаячак. Шулай булгач, Әл-Җәзаирда, Марокко, Туниста француз яки испан, итальян, инглиз телләре, гарәп телен кысрыклап чыгара алмаячак. Алай гына да түгел, соңгы 20-30 ел дәвамында Африканың кайбер илләренә гарәп теленең йогынтысы көчәя генә барды *(Шагаль. Арабизация культуры в Алжире. Журнал «Народы Азии, Африки». 1981.—№ 3,—94-98 б.).* Көнбатышта пәйда булган лингвистик теорияләрне гарәп илләренә кертергә тырышуда урынсыз һәм кирәксез эш. Чөнки көнбатышта хөкем сөргән лингвистика теорияләре гарәп теленең бик борынгыдан формалашып килгән үз кануннарына, миллилегенә дә яраклы булмаячак.

Латин графикасына күчү процессында, әлбәттә, татар халкы да гарәп дөньясында булган һәм бара торган әлеге проблемаларны исәпкә алырга тиеш.

**Җәмил ЗӘЙНУЛЛИН**,
*профессор*

## *Дин һәм тормыш*



# ИСЛАМ ВӘ ХӘЯТ

***«Коръәннең бөтен аятьләрен камил аңлар өчен энциклопедик күләмле белемгә ия булырга кирәк. Мондый белемгә күп фәннәр белән шөгыльләнгән кеше генә ирешә ала».***

Морис БУКЕИЛЬ,
*философ, дин белгече*

Бүгенге фән гыйлемнәренең бихисап күпләре әүвәл Мөхәммәд пәйгамбәр заманыннан, бигрәк тә Өмәвия, Габбасия хәлифләре хакимлеге вакытыннан ук дөньяга җәелә башлаганлыгы галимнәргә мәгълүм. Габбаси хәлифә әбел Габбас әл-Мәэмүн 813 милади елда хәлиф булгач, борынгы грек фәйләсуфлары Платон, Аристотель, Сократ, Гиппократ, Архимед, Птоломей хезмәтләрен гарәп теленә тәрҗемә иттергән. Әл-Мәэмүн, милләтнең гыйлем дәрәҗәсенең югарылыгы, мөселманның рухи вә физик камиллеге дәүләтнең алгарышына сәбәп икәнлеген аңлап, хәлифәттә мәктәпләр төзеткән. Югары уку йортларында меңнән дә артып киткән шәкертләрнең түләүсез укуларын оештырган. Монда өч обсерватория, сәламәтлек гыйлемен өйрәнү мәдрәсәсе, хастаханәләр ачылган. Ошбу заман Кордовада химия гыйлеменә нигез салынган. Астрономия, математика гыйлемнәре яңадан күтәрелгән. Әл-Мәэмүннең (786—833) хәлифлек елларында җирнең шар рәвешендә түгәрәклеген тәсдыйкъ итү максатыннан, заманның гыйлемдә танылган Бәни Шакир Әхмәд Мөхәммәд, Хәсән Әхмәд бине Касыйр әл-Фиргани кебек белгечләр катнашында махсус гыйльми төркем төзелгән. Алар кызыл дингез буендагы Сангар чүлендә астролябия ярдәме белән җир котыбының (полюсының) офыктан бер градуслык югарылыгын үлчәп, түгәрәкнең барысы 360 градусның ни кадәрлеген хисаплап, 24 миль булганлыкны чыгарганнар,—дип, Галимҗан Ибраһимов безгә язма мәгълүмат калдырган. Ни гаҗәп, хәзерге хисапларда да әүвәлге үлчәүләрнең аермасы бик тә аз, юк дәрәҗәсендә дип әйтерлек.

Нәтиҗәдә, дөньякүләм беренче мәртәбә Җирнең планета буларак түгәрәклеге исбат кылынган, меридиан озынлыгы ачыкланган.

Урта гасырларда, инквизиция Европада хөкем сөргән дәвердә тыелган астрономия, геометрия, медицина, фармацевтика, ботаника, архитектура, география гыйлемнәре, Аурупаның олуг тарихчылары, Сиделло вә Дюрюи мәгълүматларына караганда, мөселман галимнәре тарафыннан дөньяга чыгарылган. Мөселман чолганышының дөньяда танылган галиме Әбүгалисинаның (980—1037) медицина вә төгәл фәннәр өлкәсендәге ачышлары, үләннәр, шикәр камышы, дөге, хөрмә белән дәвалау, төрле авыруларга операция ысуллары Аурупага мөселман илләреннән кергән вә дөньяга таралган.

Аурупа мәмләкәтләрендә компас, микроскоп, корыч кою, телескоп, җил тегермәннәре ясау, купол, манара төзү, мозаика һөнәрләрен мөселман галимнәре вә осталары өйрәткәннәр.

Көнбатышта Испаниядән алып, көнчыгышта Индонезия җирләренә кадәр, Коръән белән гамәл кылган мөселман илләрендә сәүдә, почта, гаскәр,

полиция, эшләрендәге тәртип, ислам шәригате нигезенә корылып, бәндәләр нинди генә милләттән булып, нинди генә телдә сөйләшмәсеннәр, нинди генә дин тотмасыннар үзара 700 йөз ел дәвамында килешеп-тигез яшәгәннәр. Милли, сәяси фетнәләр булмаган. Франция фәннәр академиясенең әгъзасы, танылган тарих галиме Дюрюи (1811—1894) үз язмаларында, урта гасыр елларында Кордова шәһәрендә 80 институт, 50 хастаханә, 90 мунча булганлыгын һәм шәһәрдә 1 миллион 200 мең ислам динен тоткан һәм башка диннәрдә булган халык яшәгәнлеген хәбәр итә. Миладиның 714—1492 елларында мөселманнар хакимлегендә булган Әндәлес (Андалузия) шәһәрләрендә Аурупадан, Якын Көнчыгыш, Төньяк Африка мәмләкәтләреннән килгән шәкертләр укып зур гыйлем дәрәҗәләренә ирешкәннәр. Алар урта дингез буе шәһәрләрендә мәдрәсәләр, югары уку йортлары, китапханә вә хастаханә биналарын төзеткәннәр. Бу заман Аурупа-Азия бәйләнешләренә Сүәеш, Җиддә, Аден шәһәрләрендәге сәүдә үзәкләре дә зур йогынты ясаган.

Ислам дине вә мәдәниятының алгарыш дәверендә мөселманнардан бихисап күп галимнәр—фәйләсүф, тел, хокук белгечләре, язучылар, моң-җыр, тәрҗемә осталары үзләренең иҗади гамәлләренең югарылыгы вә камиллеге белән дан тотканнар. Шуларның кайберләрен генә булса да исебезгә төшерик.

VIII—IX гасырларда ислам дине белән сугарылган белгечләрнең, бигрәк тә—Бану Мусаның, Әбүгалисинаның фәнгә беренче адымнары антик физика, фәйләсүфия галимнәренең әсәрләрен тәрҗемә итү, фәнни эшкәртү вә кинаяле аңлату булган. Соңра бу хезмәтләр, гарәпчәдән латинга күчерелгәч Аурупа Герон, Витрувий ачышлары белән танышкан. Дөньяда беренчеләрдән булып, X гасырда Әбүгалисина машиналар һәм аларны тоташтыру ысулларын классификацияләгән.

Механика өлкәсендә XII гасыр дәвамында Мерв шәһәрендә Әл-Хәзини «Үлчәүләр вә хикмәтләр» («Мизан әл хикмәһ») дигән хезмәте белән авырлыкларны тигезләү, тизләтү, этәрү, күтәрү; биеклек, тигезлек конструкцияләрен (йортларны, араларны, тауларны биеклеккә күтәрелмичә) үлчәү әсбапларын (инструмент-җайланмаларын) уйлап табуга ирешкән. Шушы ачышлардан соң геодезик, географик эшләрне төгәл үлчәү ихтыяҗы канәгатьләндерелгән. Геодезиянең механика белән бәйле өлешенә нигез салынган.

Дөньякүләм танылган олуг философ ибне Рәшед Әндәлеси дә XII гасырда иҗат иткән.

Хәлифәтнең төрле төбәкләрендә фәнни эзләнүләр алып барган галимнәр IX—XII гасырларда ук инде механиканың статика, кинематика бүлекләренә үзләренең ачышларын керткәннәр.

IX гасырда математика, физика гыйлемнәре буенча танылган Сабит ибн Корр физик (каты, сыек, газсыман) җисемнәрнең; геометрик, күктәге вә тәндәге матдәләрнең вакыт вә киңлектә күченеш теориясен исбатлаган. Җисемнәрнең тигез хәрәкәт куәтен, авырлык көчен, тартым үзәген табу ысулларын билгеләгән. Мөселман илләрендә кинематиканың үсүе галәмдәге җисемнәрнең хәрәкәт теориясенең эшләнеше белән бәйле. Бу мәсьәләләр ибн Сабит Коррның оныгы ибн Сина, әл-Баруни хезмәтләрендә дә чагылыш тапканнар. Алар Кояш хәрәкәтенең апогей вә перигей максимумында тизлекнең үзгәргәнен исбатлаганнар. Мөселманнар тарафыннан күтәрелгән бу теория Аурупада 300 елдан соң гына фән буларак танылган һәм үсеш тапкан. Бу дәвер фәндә искитмәле ачышлар ясаган галимнәр белән ничек кенә горурланмассың. Шулардан Әл-Хәзен параллель вә перпендикуляр яссылыкта «ыргытылган» җисем тизлегенең икегә бүленгәнлеге, ә Абдул Барага әл-Багдадинең төшә торган җисемнәрнең «егылу» тизләнеш теориясен ачуларына мөселманнар гына түгел, башка дин тотканнар да сокланганнар. Мөселман галимнәренең абруе география гыйлемен үзләштерүдә, физика, механика алымнарына таянып эзләнүләрдә, тикшеренүләрдә күтәрелгән.

Хәлифәтлектә дөньяда иң беренчеләрдән булып дары, компас, кәгазь уйланып табылган икәнлеге мөселман галимнәренә генә түгел, башка диндә булган гыйлем ияләренә дә билгеле булган. Шулай булуга карамастан, ислам диненә дошманлык кылган урта гасыр инквизитор тарихчылары: «компас,

дары, кәгазь кытай жирендә ачылган»,—дип хаклыкны халыктан яшергәннәр.

Хакыйкать өчен ислам галимнәренең тарихи мәгълүматларына таяныйк. Дары иң беренче мәртәбә 690 милади елда Мәккәдә селитраны синтезлау нәтижәсендә ясалган һәм Мисырда файдаланылган. Компасны да XI гасырда гарәп галимнәре уйлап тапканнар һәм география, астрономия өлкәсендә кин кулланганнар. Магнетизм, магнит кырлары турында иң беренче китап—«Сәүдәгәрнең хәзинәсе» дип аталган фәнни хезмәт—1282 милади елда Каһирә физигы Бәйләх әл-Кәбәйки тарафыннан язылган. Әйе, ул заман сәүдәгәренең иң олуг хәзинәсе компас булган. Компасның кытайда ачылышына, ясалышына, бүгенге көнгә кадәр берниндидә булса фән тарафыннан тәсдыйкъ ителгән гыйльми дәлил юк. Кытайлар исә XIX гасырга кадәр Төньяк котыпны «Янып торган ут жире» дип фараз кылганнар. Компас турында мәгълүматлары булмаган. Кәгазьне 706 миладида Мәккә шәһәренең абруйлы гыйлем иясе Йосыф бине Гомәр мамыктан ясаган. Сонра 850 елда аның үрнәгендә Бохара, Сәмәркand осталары кәгазьне ефәктән ясаганнар.

Дары куәте ижат ителгәч, туры металл көпшәдән ядрә (туп) ату ысулы да Мөхәммәдфатих хан тарафыннан уйланып табылган.

Ислами тарихында мәгълүм ки, Кызыл дингезне Нил елгасы белән тоташтыру өчен казылган «Колзам» каналы пәйгамбәребезнең иң яраткан сәхабәсе, 634 елдан хәлифә булган хәзрәти Гомәр житәкчелегендә эшләнгән. Аның кайгыртучанлыгы белән Сүәеш каналын төзү ин катгый бурычларның берсе итеп куелган. Хәзрәти Гомәр (591—644) һижри ел исәбен гамәлгә кертүдә, Раббымызның олуг нигъмәте Коръән Кәримне нәшер кылуда күп ижтиһад кылган хәлиф булган. Мөселман галимнәренең IX гасырдан ук башланган оптика өлкәсендәге гыйльми тикшеренү гамәлләре үз нәүбәтендә астрономия буенча гарәпләрнең зур ачышларына сәбәб булган. Бу фәнни ачышлар IX гасырда әл-Кинди тарафыннан, ә XIII гасырда ибн әл-Хайсанның «Оптика хәзинәсе» дигән хезмәтендә бәян ителгән, сонра бөтен Аурупага кулланма булып таралган.

Галактикалардагы күк жисемнәре хәрәкәте турындагы гыйлем (тәкъвим фәне) «Зиж» дип аталган. «Зиж» гыйлеме белән шөгыльләнгән иң мәшһүр мөселман галимнәреннән Ибне Юнысның, Әбү Хәнифә әд-Динуриның, Бәлхинең, Әбү әс-Сәмәх әл-Гарнатыйның, Әбү Хаммад әл-Әндәлесинең, Насыйр Тусиның, шулай ук Хәнин бине Исхак әл-Гыйбадиның, Сабит бине Көррәт әл-Харанинның, Олуг бәкнең, Бәни Шакир кебек галимнәрнең дәвер, заман сикәлтәләрендә язып калдырган китаплары бүген дә астрономия, география, математика белгечләренең игътибарына лаек.

Югарыда әйтелгән вә әле бихисап әйтелмәгән ачышлар фикер, фаразлар Аурупага урта гасырлардан соң килгән Яңарыш—Ренессанс (Ауропада фән, сәнгать, мәдәният үсеп киткән чор) дәверенә сәбәп булган. Бу замандагы ислам галимнәренең уңышларын кайберәүләр—шәһәрләр, каналлар төзү, авыл хужалыгын үстерү, сәүдә, сәяхәт ихтыяжларыннан күрәләр. Ә калганнары Раббымызның олуг нигъмәте Коръән Кәримнең фәнгә мәхәббәте белән аңлаталар. Бу фикерләрнең хаклыгына бәхәс юк. Вәләкин, без иманлы бәндәләр, Аллаһу Хак сөбханәһү вә Тәгаләнең рәхмәтеннән башка бер кузәнәкнең дә юктан бар булмаслыгын беләбез. Бу ачышлар мөселман галимнәренә Аллаһыбызның илһамы булып килгәнлегенә иманабыз. Чөнки ислам динендә хыялыйлык, хорафатлар юк. Ислам тәгълиматы хакыйкатькә нигезләнгән.

Органик вә матди дөньяның иң кечкенә микъдарыннан хасил торган күзәнәктән, электрон, протон, позитрон, нейтрон, элементар кисәкчекләрдән алып, галәм вә галактикаларның яратылышлары, хәрәкәтләре турындагы фәнни ачышлар моннан ундүрт гасыр әүвәл иңгән Коръән Кәрим белән тәсдыйкъ ителгәннәр.

Бу жөмләдән, бүгенге физика галименнән, электр тогы ул нәрсә дип сорасаң, ул: «электр тогы ирекле электроннарның тоташтырылган үткәргечтә электр куәтенең хәрәкәт көче йогынтысында тәртипләнгән бер юнәлеше»,—дип әйтәчәк. Шулай булгач, электр тогы ул тәртипләнгән хәрәкәт. Ә бу хәрәкәт гамәлдә ничек тәгаенләнә? Галәм вә галимнәрдәге хәрәкәтләрдә нәкъ

шулай түгелме соң? Планеталар, йолдызлар, Ай, Кояш һәм барлык күк җисемнәре һичкайчан да берләре икенчеләренә орынмыйлар, берләре икенчеләрен этәрмиләр. Үзләренә бирелгән, юнәлештәге тәртипләнгән хәрәкәттә үз күчәрләрендә әйләнәләр. Ә нинди куәт көче аларны вакыт вә кинлектә бар иткән вә бер юнәлештәге тәртипле хәрәкәткә салган? Шушы җисемнәрне, хәрәкәтләрне бар иткән, бер тәртипләнгән юнәлешкә салган, орбитада вә үз күчәрләрендә әйләнергә мәҗбүр иткән, бер адәм дә күрә алмый торган көч-куәтнең бар икәнлеген мөселман галимнәреннән соң, Ауропада Англиянең бөек физика галиме Исаак Ньютон фәндә «Дөнья күләми тартым» (ягъни, «Закон всемирного тяготения») канунын ачкан. Ә бу куәт-көч үзе нәрсәдән гыйбарәт? Ул куәт-көче Аллаһу Хак сөбханәһу вә Тәгалә икәнлегенә гакылы камил булган бер генә дә булса кешенең, галимнең шиге юк! Аллаһу Раббүл гыйззә мөбәрәк. «Әррахман» сүрәсендә:

(55:5) الشَّمْسُ وَالْقَمَرُ بِحُسْبَانٍ ۝

«Әшшәмсү вәл камәру бихүсбәән»,—«Кояш вә Ай (һәрбарча җисемнәр Раббыгыз тарафыннан) чикләнгән мәгълүм хисап белән генә йөрерләр»,—диде. XII гасырның олуг галиме Фәхретдин Рази вә аның чордашы мәшһүр Зәмахшәри (1075—1144) Җирнең шар формасында булуын, Кояш тирәли әйләнүен, җирнең тарту көче канунын 850 ел элек тәфсир китабында язып чыкканнар. Шушы ачыштан соң дүрт гасыр үткәч, Польшаның дөньякүләм танылган галиме Николай Коперник планеталарның әйләнеш хәрәкәте кояш тирәли икәнлеген яңадан исбат иткән.

Сонра Галилей, Кеплер—орбиталарның түгәрәк түгел, ә эллипс рәвешендә икәнлекләре турында игълан кылып, дөнья мәйданында танылганнар. Шунысы гаҗәп, бүгенге мәктәпләрдә әле һаман да бу ачышларны Коперник вә Галилей ясаган, дип өйрәтәләр. Фәхретдин Рази, Зәмахшәри, Әбүс Сөгүд, Бәйзави кебек галимнәрнең бу өлкәдәге ачышлары турында халыкка әйтмиләр. Әлбәттә, моның төп сәбәбе—исламга дошманлык икәнен һәр мөселман кешесе фәһемләргә тиеш.

Вәләкин, бу ачышлар кем тарафыннан гына булмасын, алар чынбарлыкка объектив Раббымызның Коръән Кәрим аяти-кәлимәләренең хаклыгына дәлил булып торалар. Кешелек дөньясына файда китерәләр.

Җәнабел хак сөбханәһү вә Тәгалә Рәгыд («Күк күкрәү») сүрәсенең икенче аятендә болай диелгән:

(13:2) اللَّهُ الَّذِي رَفَعَ السَّمَاوَاتِ بِغَيْرِ عَمَدٍ تَرَوْنَهَا

«Аллаһу әлләдии рәфәгассәмәвәти бигайри гамәдәт-тәрәүнәһа...»—Үзегез дә күрәсез, күкләрне күтәрүче Раббыгыз гарешкә касд кылды, кояш, айны буйсындырды...—диде».

Океан суларын, дингез тирәнлекләрен безнең заманда өйрәнгән Франциянең дөньякүләм танылган галиме Жан ив Кусто океандагы суларның хәрәкәттә икегә бүленгәнлекләрен, бу суларның бер юнәлештә акканнарының тозлы булуларын, ә икенче катламда акканнарының тозсыз икәнлекләрен ачты. Тозлы вә тозсыз бер юнәлештә аккан сулар арасында күзгә күренми торган пәрдә булуын, нинди генә куәтле дулкыннар чыкса да бу суларның катнашмаганлыкларын белдерде.

Ошбу глобаль фәнни мәгълүматлары илә дөнья галимнәренең мәрхәмәтенә лаек булган Жак ив Кусто, үз ачышының моннан 1400 ел әүвәл иңгән Коръән Кәрим аяти кәлимәләре белән бәян ителгәнлеген белгәч, хәйран калды. Галимнең калебендә Раббымызның бөек куәт көче икәнлегенә, пәйгамбәремезнең хаклыгына инану белән сугарылган иман уянды һәм Жан ив Кусто ислам динен кабул итте. Мөселман булды.

Чыннан да, җәнабел хак сөбханәһү вә Тәгалә Коръәндә болай диелгән.

(19) ۝ مَرَجَ الْبَحْرَيْنِ يَلْتَقِيَانِ ۝

«Мәраҗәл бәхрәйни йәлтәкыйәән»—«Ул Раббыгыз суы тозлы дингез суы белән (тозсыз) дингезне берсе берсенә күрше, янәшә булганнары хәлдә агызды,—диде».

(20) ● بَيْنَهُمَا بَرْزَخٌ لَا يَبْغِيَانِ

«Бәйнәһүмәә бәрзәхол ләә йәбгыйәән».—«Бу суларның арасында Раббыгызның кодрәт пәрдәсе бар. Сулары кушылмас».

(21) ● فَبِأَيِّ آلَاءِ رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ

«Рәби әййи әәләәәэи раббикүмәә түкәззибәән».—«Әй адәм белән жен!» Раббыгызның кайсы нигъмәтен танырсыз, ничек Аныкы түгел диярсез?!—диде». *(Коръән. Әррахмән сүрәсе, 19, 20, 21 аятьләр.)*

Вакыт вә кинлектә Жан ив Кусто кебек тәрәккъыяткә, хаклыкка омтылган галимнәрнең, әдипләрнең Коръән нигъмәтен фәнни вә рухи исбатлауга керткән хәзинәләре бәяләп бетергесез. Шулардан немец галиме Әхмәд Шмиде, француз галиме Роже Гароди, яшьләрне моң белән җәлеп иткән Майкл Джексон, спортта дан казанган Мөхәммәд Әли, Коръәнне кинаяле тәфсир белән тәрҗемә кылган Валерия Порохова һәм башкалар, ислам динен кабул итеп, әһле Ислам булдылар.

Коръәннең үзенә генә хас шигъри прозасында иксез-чиксез нур белән сугарылган аяти кәлимәләрендә нинди олуг илһам барлыгын фәһемләгән галимнәр XVIII гасырның башында ук инде Аурупа халыкларының милли телләренә Раббымыз нигъмәтен тәрҗемә иттеләр. Гете, Һейне, Байроннар артыннан Александр Пушкин 1824 елда Михаил Веревкин тәрҗемәсендә Коръәнне укып кына түгел, тулысы белән өйрәнеп чыккан. Әдип Коръәни Кәримнең 33 сүрәсен шигъри ысул белән тәфсир кылган.

Ниһаять, аның «Подражания Корану» дип исемләнгән шигъри тәфсир җыентыгы пәйда булган. Ә заманыбызның горурлыгы газиз Габдулла Тукаебызның иҗаты Коръән Кәрим белән сугарылганлыгы һәрбарча зыялы бәндәгә мәгълүм. Ни өчен бәндә Тукайны зурлый? Шуның өчен, чөнки Тукай галәмнәр хуҗасы Аллаһу Хак Тәгаләнең олуг нигъмәте Коръән Кәримнең бихисап аяти кәлимәләрен шигъри ысул белән тәфсир кылган, шуның белән мөселманны куандырган шагыйрь генә түгел—әдип, мәшһүр галим!

Татар исламы тарихында безнең тирәлектә ислам алгарышына Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Кандалыйлардан соң XIX гасыр мәгърифәтчеләре, җәдид дин галимнәре М. Мәрҗанинең, Р. Фәхретдиннең, К. Насыйринең, Г. Барудинең, М. Бигинең, Г. Курсавинең, З. Камалинең, Ә. Максуди хәзрәтләренең иҗади хезмәтләре сәбәп булган.

Шулай ук XIX—XX гасырлар бусагасында дини фанатизмга каршы татарлар белән бергә башкортлардан—Мөхәммәдсәлим Өметбаев, кабардалылар—Исмәгыйл һәм Сәфәргали Урусбиевләр, дагыстанлылар—Хаҗи Мәхәммәд, Хаҗи Чохи, Мөхәммәд Усман, адыгейләр—Шора Ногмов, Солтан Дәүләтгәрәй һәм башка бинихая күп әдипләр җәдидчелек өчен иҗтиһад кылганнар.

Мөселман галимнәре вә әдипләре вакыт вә кинлектә нинди генә дәвердә яшәп, нинди генә заманда ачышлар ясамасыннар, аларның һәрберсен тоташтырган бер гомумилек бар. Алар үз иҗатларында Коръәннең вә фәннең бергәлеге иҗтимагый тормышның, ислам мәдәниятының үсүенә куәт вә этәргеч икәнлеген исбат иткәннәр.

Бу җәһәттән бөтен дөнья Ислам галимнәре тарафыннан XX гасырның иң зур ислам галиме дип табылган, төрек милләтенең горурлыгы булып саналган шәхес—Бәдиуззаман Саид Нурсиның: «Акылның нуры фән гыйлемнәре, вөҗданның зыялыгы дин гыйлемнәре белән яктыртылыр. Икесенең берләшүе белән акылларда һәм күңелләрдә хакыйкать барлыкка килер»,—дип әйткән сүзләре искә төшә дә калебне гафиллектән уята, күңелне уйга сала. Уйланырлык шул. «Әгәр дин гыйлемнәре үзләре генә укытылса,—ди әдип, фанатизм барлыкка килә; фән гыйлемнәре генә укытылса, Аллаһны инкар итү, иман хакыйкатьләреннән шикләнү һәм атеизм туа».

Инсаннарның XX гасырның башында дини фанатизмда булгануы, йөзьеллыкның ахырында атеизмда таркалуы Бәдиуззаман сүзләренең хаклы икәнлеген һәрбер зыялы бәндә фәһемли. Бу дәвердә диннән аерылган фән, дәүләттән аерылган дин, диннән аерылган мәктәп яшь буынга әхлакый тәрбия бирә алмас хәлгә килде. Атеизм елларында фән үсте, ә әхлак

бозылды. «Дин ул халыклар агуы»,—дигән хорафат, афәт булып, халыклар башына төште. Бу афәтнең дәвамын бүгенге базар икътисадындагы инсаннар бик тә авырлыкта кичерәләр. Әле һаман элеккечә дин дәүләттән, фән диннән аерым булган мохитта «материя беренчел, аң икенчел»,—дип йөргән әүвәлге атеистларның кайберләре: «Мулла абзый, менә син Алла бар дип әйтәсең. Булгач, соң ул кайда? Америкалылар Айга менделәр. Вәләкин Айда Алланың да, мулланың да юк икәнен күрделәр. Безнекеләр Воркутада җирне 12 километрга тишеп төштеләр. Анда җәһәннәм булмаган кебек, җәннәтнең дә юк икәнен белделәр. Бар нәрсә бар. Юк нәрсәнең юк икәнлеге һәркемгә билгеле. Шуның өчен дә инде бар нәрсә—материя—чолганыштагы матди әйбер беренчел. Менә син булган кебек мин дә бар. Ай, Кояш, йолдызлар бар. Бер сүз белән әйтсәк—Табигать кенә бар»,—дип бәхәсләшәләр.

«Ә нәрсә соң ул Табигать?»—дигән сорауга, үзен атеист дип санаган бәндә: «Табигать ул нәрсәне күрәсең—шул. Татарстанда—урман, кыр, басулар, хайван, кош, кортлар, җирне тишеп, шуышып-шуышып көн күргән суалчаннарга кадәр—болар барысы да табигать! Бразилия Амазонкасындагы лианалар, маймыллар, сазлыклардагы крокодиллар—болар бар да табигать. Без табигатьне күрәбез. Ә менә, мулла бабай, Алланы күргән бәндә юк. Мөхәммәд Пәйгамбәр дә бит, күккә ашканда—мигъраҗда Алланы күрмәгән. Шулай булгач, Алла юк, табигать кенә бар!»,—дип сүзен йомгаклый. Анынча Алла юк. Табигать бар. «Булмаган» Аллага түгел, булган табигатькә—урман, кырларга, маймыл, крокодилларга табынуны ул дөрес дип таба. Чөнки, анынча, булган «материя—первична—беренчел, аң, мон, гакыл—икенчел?!» Шулай Аллаһуны инкарь кылган атеист: «Мин табигать баласы, миңа илһам куәтен, монны, талантны табигать кенә бирә»,—дип үзенә-үзе соклана, «мин илһам, аң иясе»,—дип куана, тәкәбберләнә.

Имансыз бәндә табигатьне шулай күзәтә. Әмма табигатьне барлыкка китерүче вә табигать белән идарә итүче бөек куәт көченең барлыгын инкарь итә. Чөнки ул үзенә тормыш биргән, дөньяга үз теләге белән килә алмаганын, бу дөньядан китә алмаганын аңларга сәләтсез. Ни өчен, бүгенге «базар» икътисады гавамында атеист Аллаһу Раббымызның барлыгын, пәйгамбәремезнең хаклыгын кире кага? Шуның өчен, чөнки Аллаһуны танысаң, фани дөньяда кыя тауларга тиңләрлек гөнаһларыңны танырга кирәк. Дөнья малын ауламак өчен адәм тилмертүләреңне, мескеннәр, фәкыйрьләр хакына харам юл белән җыйган байлыгыңны, адәмнәр тәненә кадаган наркотикларыңны... ай, һай,—танырга кирәк. Әйе, Аллаһуны танып, тәүбәгә килергә иде дә бит—хөсетлек, нәфес, комсызлык зур! Шул сәбәп илә имансыз бәндә Раббысын танудан баш тарта. Чөнки Аллаһуны танысаң—Аның газабын танырга кирәк. Ә имансызның «газап кичерәсе» килми. Кяфер Аллаһуны кире кага.

Үзен «проектлаган» һәм бар иткән, кальций, углерод, тимер һәм башка җансыз матдәләрдән җанлы адәмне яраткан иҗатчыны ул аңларга теләми.

Гавамдагы чолганышта һәр күренмәгән нәрсәне юк дип әйтү дөресме?

Гакыл вә фикер бармы? Бар! Алар күренәме? Юк!

Сулыш алу вә кислород бармы? Бар! Алар күренәме? Юк!

Электр тогы вә хәрәкәте бармы? Бар! Алар күренәме? Юк!

Шулай булгач, һәр күренмәгән нәрсәне, көч-куәтне «юк!»—дип әйтү, наданлык, мәгънәсезлек; моңа гакылның зәгыйфьлеге генә сәбәпче.

**—Фикернең булуына гакыл дәлил;**

**—Сулауның булуына кислород дәлил;**

**—Сусауның булуына су дәлил;**

**—Электр тогының булуына үткәргечтәге иректә электроннарның хәрәкәте дәлил;**

**—Органик дөньядагы күзәнәкнең барлыкка килүенә тереклек дөньясының булуына дәлил.**

**—Галәмнәрдәге җисемнәрнең хәрәкәтенә—бөтен галәмнәр тартым көченең булуы дәлил.**

Алай булгач, галәмнәрдәге иң олуг җисемнәрдән алып, матди вә

органик дөньядагы иң кечкенә микъдардан торган, беркемгә дә күренмәгән кисәкчекләрне юктан бар кылган вә тәртипләнгән хәрәкәткә салган Бөек Куәт көченең Барлыгына, Берлегенә, Мәңгелегенә гакылы зәгыйфь, үзен атеист итеп игълан кылган мәхлукъ кына ышанмас. Аның исеме «кяфер» булыр. Кяфер фетнәче буларак, асыл чын гыйлемгә юл таба алмый. Чөнки Аллаһу Хак сөбхәнәһү вә Тәгаләне ача алмаган бәндә, хакыйкатьне ача алмый. «Аллаһ юк»—дип әйткән зат Раббымызга зыян сала алмый. Аллаһу Раббы бернәрсәгә дә мохтаҗ түгел. Аңа бөтен галәмнәр, барлык нәрсә, җанлысы да, җансызы да, шул исәптән, имансызы да буйсынырга мәҗбүр. Аның рәхмәтеннән башка бер кузәнәк тә юктан бар булмас, булганы югалмас. (Бу җөмләдән Ф. Энгельсның: «Тереклек асымнарның яшәү рәвеше»,— дигән гыйбарәсе ислам тәгълиматыннан алынган икәнлегенә гаҗәпләнмик.) Хак Тәгалә адәмне иман, ислам әһле итеп дөньяга китерде, ата-анага амәнәт кылды, пәйгамбәрен җибәрде, Коръән Кәримне иңдерде. Ни өчен? Адәм хакны нахактан аера белсен өчен! Хакны—нахактан, изгелекне—явызлыктан, хәләлне—харамнан аера белсен өчен адәмгә Үзенең иң олугъ нигъмәтен—гакыл нигъмәтен бирде, Кешегә белем, фикер йөртү, уйлау сәләтен бирде дә хаклыкка бару юлында ирекле итте. Менә шушы ирек шартында адәмне сынау өчен... Ислам—ул буйсыну дигән сүз. Вәләкин буйсынуга көчләү, мәҗбүрләү юк.

(2:256) لَآ إِكْرَاهَ فِي ٱلدِّينِ ...

«Ләә икрәаһә фиддини».—Шулай ирекле хәлдә кеше үзенә охшаган яшәеш ысулын сайласын өчен, аңа үз теләге белән нинди динне, идеологияне, гамәлне үтәү, нинди юлда булу ихтыяры бирелде.

Коръәннең шушы сүзләреннән соң:

—Әй адәм, син изге юлда гамәлләр кылып, әһле ислам булырсыңмы? Үзеннен гыйлемен белән җәмгыятьне бәхет-сәгадәтле итәрсеңме!—дип әйтәсе килә.

Әллә киресенчә, «дин ул халыклар өчен әфиун»,—дигән булып, мәчет манараларын түнтәреп, дин әһелләрен үтереп, исереп, дөнья малын ауламак өчен бәндәләрне тилмертеп, әһле кяфер булырсыңмы! Сайла!

Мөселман булган галим, гыйлем иясе:

**—Фән өлкәсенә тирәнрәк кергән саен, аның Аллаһуга ышанычы арта барыр. Ул Раббымызга башын ияр;**

**«Иям башым мин сәҗдәгә: «Аллаһе Хак! Аллаһе әкбәр!»—дим». (Г. Тукай.)**

**—Фәндә табигать кануннарына төшенер һәм кешелек дөньясы файдасына җирнең яшерен байлыкларын ачар;**

**—Җирдә, күктә булган һәр нәрсәне файдаланырга үзе өйрәнер, башкаларны өйрәтер;**

**—Мөселман галим фәндә гаҗәеп ачышлар ясап, Ислам динен, Коръән Кәримне тәсдыйкъ кылыр;**

**—Тарихтан, үткән тәҗрибәдән дөрес сабак алыр, җәмгыятьнең үсешенең вә түбән тәгәрәүнең сәбәпләрен ачар. Мәдәниятләрнең үсешенә фәнни киңәш бирер;**

**—Тынычлык, гаделлек, кеше хокукларын яклау, саклау сәясәтен алып барыр;**

**—Фәнне, фәнни ысулларны ялгыш җимерүләрдән саклар;**

**—Мәктәпләрдә ислам вә дөньяви диннәр тарихын өйрәнүне вә исламның әхлак дәресләрен кертергә тырышыр.**

**Исламның вә фәннең, вөҗдан вә гакылның берлегенә инанып, дин вә фән гыйлемнәренең бергә укытылуның бүген ни дәрәҗә зарурлыгын аңлар, фанатик секталар, экстремистик вахабит өйрәтүләренә каршы җәдидчелекне күтәрүдә иҗтиһад кылыр.**

**Харис хәзрәт САЛИХҖАН,**
*имам хатиб, Россия гуманитар фәннәр академиясенең әгъзасы*



Qør'ən tatar telendə
Коръән татар телендә

# 10—ЮНЫС (ЮНЫС) СҮРӘСЕ

**(Юныс сүрәсе 109 аятьтән тора. Юныс кавеме турында сөйләнгәнлектән, сүрәгә шушы исем бирелгән. Мәккә халкы үз арасыннан пәйгамбәр чыгачагына ышанмый иде.)**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Әлиф. Ләм. Ра. Менә болар хикмәтле Китапның аятьләре.
*(Мәуланә Алидә: Мин-Аллаһ—барысын да күреп торучы.)*

**2.** Араларыннан чыккан бер адәмгә *(хәзрәти Мөхәммәдкә)*:

—Кешеләрне кисәт, иман китергәннәргә Раббы катында югары дәрәҗәләр биреләчәге турында әйтеп сөендер,—дип вәхий төшергәнебез кешеләргә шаккаткыч бер нәрсә булып күренде ме иканни соң?

Кяферләр:

—Бу, шик юк ки, сихерче,—диделәр.

*(Соңгы җөмлә төрлечә аңлатыла. И. Крачковскийда: Конечно, это—явный колдун!.. Х. Чантайда: Бу, шиксез, шөбһәсез вә ап-ачык бер сихербаздыр... В. Пороховада: Он—явный чародей!.. Бу тәфсирчеләрнең шәрехләвендә кяферләр хәзрәти Мөхәммәд турында шулай әйтә. Ш. Ногманида гына фикер башкача: Әлбәттә, бу Коръән—ачык сихердер, диелә.)*

**3.** Шөбһәсез ки, Раббыгыз күкләрне вә Җирне алты көндә яралтты, сонра бөтен эшләре белән идарә иткән хәлдә Гарешкә *(тәхеткә)* җирләште. Аның рөхсәтеннән башка беркем дә шәфкатьче була алмас. Менә шул Раббы сезнең Аллагыз булыр. Шуңа күрә, Аңа баш орыгыз. Акылыгызга килерсез шәт? **(4)** Хак вәгъдәсе буенча сез Аллаһка кайтарылачаксыз. Чөнки Аллаһ башта бар кылыр, сонра иман китереп, игелек кылганнарга гаделлек белән әҗерен бирер өчен, аларны үтереп, янадан тергезеп, үз хозурына кайтарыр. Кяферләр исә инкарь иткәннәренә күрә, шау-кайнар су эчәчәк вә хәтәр җәза алачаклар. **(5)** Аллаһ Кояшны яктылык чыганагы итеп кабызды, Айны нурлы итеп яралтты, елларның санын вә хисабын белер өчен аңа *(Айга)* фасыллар тәгаенланды. Аллаһ боларны *(тикмәгә генә түгел)* Хакыйкать өчен яралтты. Ул мәгълуматлы кавемгә аятьләрен ачык аңлата. **(6)** Төн белән көннең берсе артынна берсе озыная, кыскара, алмашынуында, күкләрдә вә Җирдә Аллаһ яралткан нәрсәләр *(Күкләрдә—фәрештәләр, Ай, йолдызлар, җисемнәр, чиксез галәм; Җирдә—җәнлекләр, кош-кортлар, кешеләр, таулар, диңгезләр, елгалар, үсемлекләр)* Аллаһ каршында гөнаһ эшләүдән курыкканнар өчен гыйбрәтләр һәм кисәтүләр бардыр. **(7)** *(Кыямәт көнендә)* Безнең белән очрашуга ышанмыйча, дөнья тормышына разый булып, шуннан ләззәт алып яшәгәннәр һәм аятьләребезгә битараф булганнар арагызда юкмыни? **(8)** Менә шулар инде җыйган гөнаһлары аркасында ялкын эчендә үзләренә ятак табар. **(9)** Иман китереп, игелекле эшләр башкарганнарны, иманлы булганнарына күрә, Раббы нигъмәт тулы җәннәтләрдә, астыннан ермаклар агып торучы бакчаларга урнаштырыр. **(10)** Аларның:

—Аллаһым, Синең кимчелекле сыйфатларың юк,—дигән сүзләре дога булыр.

Анда бер-берсе белән очрашканда әйтә торган сүзләре: «сәлам», булыр.

---

Журнал өчен **Рабит БАТУЛЛА** әзерләде.

Аларның сәлам соңындагы догалары да:

—Бары тик галәмнәрнең Раббысы Аллаһка гына мактау тиеш,—дигән сүз булыр. **(11)** Әгәр Аллаһ инсаннарга, ашыгыч бүләк теләгәннәре кебек, җәза бирүне дә ашыктырса, аларның әҗәле белән эш беткән булыр иде. Безнең белән *(Ахирәттә)* кавышу көтмәүчеләрне Без азгынлыклары эчендә коенсыннар дип *(үз ихтыярларына)* буталып йөрергә калдырабыз.

*(«Кяферләр: йа, Аллаһ, әгәр Коръән Синең тарафтан иңдерелгән булса, Мөхәммәдне Пәйгамбәр итеп син җибәргән булсаң, боларга ышануыбызны теләсәң, күктән таш яудыр яки безгә хәзер үк бер җәза бир,—диделәр.*

*Шуннан соң өстәге аять иңдерелде. Димәк ки, Аллаһ Тәгалә гөнаһлы колларына шундук җәза бирми, бәлки тәүбә итәрләр, кылмышларына үкенерләр, тугры юлга басарлар, дип җәзаны кичектерә икән. Тәүбә итмәгәннәргә ул тәкъдирләрендә язылганча гомер бирер, җәзаны ул аларга соңрак бу дөньяда ук бирер яки Ахирәт көненә калдырыр».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**12.** Кыен хәлләрдә калган чакларда кеше кырын яткан килеш тә, утырып та, аягөсте дә Безгә *(ялвара, бәладән коткаруыбызны өмет итеп)* дога кыла; Безнең ярдәм белән бәла-каза узып киткәч, әйтерсең лә, ул ярдәм сорап Безгә ялвармаган. Хәттин ашканнарга үз кылмышлары шулай яхшы гамәл булып күренә. **(13)** Хактыр ки, үзләренә ап-ачык дәлилләр *(аятьләр)* китереп тә *(аларны ялганга чыгарганнары, Аллаһка каршы өзлексез көфер иткәннәре аркасында)*, гаделсез булганнары, иманга килмәгәннәре өчен, Без сездән әүвәл яшәгән халыкларны һәлак иттек. Гөнаһлыларга Без әнә шундый әҗер бирәбез. **(14)** Соныннан алар урынына Җир йөзенә сезнең кавемне китердек, карап карыйк, сез ни кылырсыз икән? **(15)** Аятьләребезне дәлилләр белән ап-ачык итеп укыгач, *(Ахирәттә)* Безнең белән кавышырга теләмәгәннәр *(мөшрикләр сиңа)*:

—Юк! Безнең өчен син башка бер Коръән китер яки монысын *(безнең файдага)* үзгәрт,—диделәр.

Әйт син:

—Аны алыштыру яки үзгәртү минем көчемнән килә торган нәрсә түгел. Мин вәхий булып килгәннән башкасына иманмам. Әгәр дә Раббыма каршы баш күтәрсәм, шик юк ки, хәтәр Көннең *(Кыямәтнең)* газабыннан куркам,—диген. **(16)** Әйт:

—Әгәр Аллаһ ихтыяр итмәсә, аны сезгә укымаган булыр идем, Аллаһ аны *(минем аша)* сезгә белдермәс иде. Мин моннан әүвәл дә гомерем буе сезнең арада *(кырык ел)* яшәдем. Әле һаман акыл утыртмадыгызмыни? *(Әле һаман минем намуслы, ялгансыз кеше икәнемә ышанмадыгызмы?)* **(17)** Шулай булгач, Аллаһка каршы уйдырмалар *(сөйләүче)* яки Аның аятьләрен ялганга чыгаручылардан да залим *(гаделсез, әхлаксыз)* кем бар икән бу дөньяда? Хактыр ки, гаепләләр беркайчан да *(Аллаһ каршында)* уңыш казанмас. **(18)** Аллаһны инкарь итеп, алар үзләренә зарар да, файда да эшли алмый торган нәрсәләргә табыналар һәм:

—Алар *(безнең потларыбыз)* Аллаһ катында безне яклап-саклап калачак,—диләр.

Әйт:

—Сез күкләрдә вә Җирдә Аллаһ белмәгән нәрсәләр турында хәбәр итәсезме? Сөбханалла, Ул аларның тәңрегә санаган нәрсәләреннән ерак *(өстен, югары)* тора.

**19.** Кешеләр бер өммәт булып оешкан иде, ләкин аеры-чөере килеп беттеләр. Әгәр дә Раббыннан бер сүз килмәгән булса иде, *(ягъни, гөнаһлыларның бу дөньядагы җәзасын кичектерү турындагы сүзе булмаса иде)* бәхәс чыганагы булган каршылыкларны бетергән булыр иде *(ягъни аларны шундук һәлак иткән булыр иде)*.

**20.** Алар:

—Ана *(Мөхәммәдкә)* Раббыдан бер могҗиза иңдерелсен иде, *(шуннан соң без аңа ышана башлар идек)*,—диләр.

Әйт:

—Яшерен нәрсәләр бары тик Аллаһ ихтыярында гына. Көтегез, мин дә сезнең белән бергә көтәчәкмен,—диген. **(21)** Зарар күргәннән соң кешеләргә муллык бирәсең, шуннан карыйсың да шаккатасың: алар аятьләребезгә карата хәйлә-тозак корып яталар. Әйт:

—Аллаһның тозагы хәтәррәктер. Шик юк ки, илчеләребез *(кятибиннәр)* сез корган хәйлә-мәкерләрне язып бара,—диген.

*(«Бу аять Мәккә халкы турында. Аллаһ Тәгалә җиде ел буена яңгыр яудырмый. Мәккәне корылык,кытлык, чир баса. Кешеләр, җанварлар кырыла. Шуннан соң Аллаһ мул яңгыр яудыра башлый. Мәмләкәт яңадан муллык вә бәрәкәткә ирешә. Ләкин кяферләр бу бәрәкәтне Аллаһтан түгел, йолдызлар һәм потлар-сынымнардан килде, диләр. Аллаһның аятьләрен ялганга чыгарырга тотындылар».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**22.** Сезне коры жирдә, дингезләрдә йөрткән Улдыр. Сез көймәдә чакта уңай, йомшак жил алып китеп барганда, эчегез тулы шатлык булыр. Кинәт кенә каты давыл чыгып, һәр тарафтан куркыныч дулкыннар һөҗүм итә башласа, чолганышта һәлак булабыз, дип алар Аллаһка ихлас ышанып:

—Әгәр дә безне бу гарасаттан коткарсаң, валлаһи, шөкер итәр идек,—дип ялвара башлаячак. **(23)** Ләкин Аллаһ аларны коткаргач, багыгыз сез, алар тагын Жир йөзендә урынсызга башбаштаклык кылалар. Әй, адәмнәр! Сезнең ул башбаштаклыгыгыз үз башыгызга булыр, дөньяда озак башбаштаклык кыла алмассыз. Ахырда хозурыма килерсез. Менә шул вакытта Без сезгә ни кылганнарыгыз турында әйтербез. **(24)** Дөньядагы тормыш Күктән яуган янгырга охшаш. Шул янгыр кешеләр, җәнлекләр ашый торган үсемлекләр белән бергә аралаша. Ниһаять, Жир йөзе шулай гүзәллек белән капланагач, кешеләр үзләрен шушы гүзәллекнең хуҗасы дип саный башладылар. Төн вакытындамы, көндезенме әмеребез *(гарасат)* килер, Жир йөзен, кичә генә бернинди дә гүзәллеге булмаган кебек, тамырыннан куптарып, хәрабәләр хәленә китерербез. Менә, Без зиһене булганнарга аятьләребезне шулай аңлатабыз.

**25.** Аллаһ Үзенең бәндәләрен иминлек йортына чакыра вә Ул теләгәннәрне тугры юлга күндерә. **(26)** Игелек кылганнарга мулдан-мул игелек булыр. Аларның йөзенә кара тап та, хурлык та килмәс. Менә шулар җәннәттә яшәячәкләр дә инде. Һәм алар анда мәңгегә калачак.

**27.** Яманлык кылганнар исә, яманлыклары кадәр җәзасын алыр. Алар рисвайга калыр. Аларны Аллаһтан *(җәзасыннан)* коткарырлык беркем дә булмас. Аларның йөзе дөм караңгылык парчасы белән капланган кебек кара булыр. Менә шулар җәһәннәм кешеләредер. Алар анда мәңгегә калачак. **(28)** Аларның барысын да бер җиргә туплаячакбыз. Шунда Аллаһка тиң зат тапканнарга әйтербез:

—Үзегез дә, сыннарыгыз-потларыгыз да урыннарыгызда көтегез,—дип. Шул көнне без аларны аерырбыз. Шуннан соң аларның табынганнары әйтер:

—Сез безгә табынмадыгыз,—дип. **(29)**—Бу мәсьәләдә безнең белән сезнең арада шаһит буларак Аллаһ житәр. Шик юк ки, безгә табынганыгызны белми идек.

**30.** Анда һәркем фани дөньядагы кылганнарына күрә әҗерен алыр. Алар хакыйкый Раббы булган Аллаһка кайтарылыр. Уйдырма тәңреләре аларны ташлар, юкка чыгар. **(31)** *(Рәсүлем и Мөхәммәд)* әйт:

—Сезгә Күктән вә Жирдән кем ризык бирә? Һәм дә кем *(барысын да)* ишетеп, күреп торуга ия? Җансыздан җанлыны кем чыгара, терене кем үтерә ала? Бөтен эшләр белән кем идарә итә?—дип сора.

—Аллаһ!—диячәкләр.

Әйт:

—Алайса, ни өчен *(гөнаһ эшләп тә)* Аллаһтан курыкмыйсыз?—диген. **(32)** Менә сезнең чын Раббыгыз булган Аллаһ шулдыр. Хактан гайре бозыклыктан башка ни калыр? Ни кадәр сез Аллаһтан ераклаштырылгансыз. **(33)** Аллаһның юлдан язганнар турындагы:

—Алар беркайчан да инанмаячаклар,—дигән сүзе расланды. (34) Әйт:

—*(Аллаһ дип)* табына торганнарыгыз арасында иң беренче *(яралтучы)*, юктан бар итүче *(җансыздан җанлы ясаучы)*, соныннан юк итүче *(җанын алучы)* һәм *(яңадан бар итүче)* тергезүче бирәрсе бармы?—диген. Әйт:

—Әүвәл яралтып *(юктан бар ясап)*, аны *(юк итеп)* үтергәннән соң Аллаһ кына янадан терелтә ала. Шулай булгач, ни өчен дөрес юлдан чыктыгыз?—диген. **(35)** Әйт:

—Аллаһ урынына табына торганнарыгыз арасында хак юлга илтүчеләр бармы?—диген. Әйт:

—Хакка бары тик Аллаһ кына илтә. Шулай булгач, хак юлга илтүче артыннан иярү яхшымы? Әллә ияртүче булмаса үзен-үзе дә йөртә алмаган мәхлукка иярүме? Сезгә ни булды? Нишләп сез шулай ялгыш фикерлисез? **(36)** Аларның күбесе фаразлардан башкага буйсынмас. Шик юктыр ки, Хакыйкатьтән фараз коткармас. Аллаһ аларның ни кылырга теләгәннәрен бик яхшы белеп тора. **(37)** Бу Коръән Аллаһтан башка бер зат тарафыннан уйлап чыгарылган нәрсә түгел. Ул бары тик үзеннән *(Коръәннән)* элек килгән башка китапларны раслаучы һәм дөресләүче, аңлатып бирүче Китап. Монда һичнинди шик-шөбһә булуы мөмкин түгел. Ул *(Алла)*—галәмнәрнең Раббысыдыр. **(38)** Бәлки алар әйтер:

—Аны ул *(Мөхәммәд)* үзе уйлап чыгарган,—диярләр. Әйт:

—Әгәр дә сез әйткәннәр дөрес, дип уйласагыз, көчегездән килсә, Аллаһтан башкаларны ярдәмгә чакырыгыз да *(Коръәндәге кебек гүзәл, мәгънәле)* бирер сүрә китерегез,—диген. **(39)** Юк шул, үзләре аңламаган нәрсәләрне, үзләренә аңлатмасы да килмәгән көе, алар *(Коръәнне)* ялганга саный. Алардан әүвәлге өммәтләр дә *(пәйгамбәрләрне, китапларны)* шулай итеп, ялганга чыгардылар. Бакчы, ул залимнәрнең ахыры ни белән бетте? *(Болары белән дә шул ук хәл кабатланачак.)* **(40)** Аларның кайберләре аңа *(Коръәнгә)* ышана, ышанмаганнары да бар. Раббың бозыкчыларны яхшы белеп торучы. **(41)** *(Рәсүлем)* әгәр сине ялганчыга чыгарсалар, әйт:

—Минем эшем үземә, сезнең эшегез үзегезгә. Мин эшләгәннәрдән сез ерак торасыз, сез эшләгәннәрдән мин ерак торам,—диген.

*(«Хәзрәти Мөхәммәднең вазифасы инсаннарны кисәтү, хәбәр бирүдән тора. Кешеләрне иманга китерү аның кулыннан килми. Чөнки тугры юлга бастыру Аллаһның гамәле. Шуңа күрә, хәзрәти Мөхәммәд үз гамәлләре һәм адәмнәрне кисәтү өчен генә җавап тотачак. Кисәтүләргә, өндәүләргә карамастан, иман китермәгәннәр үзләре өчен үзләре җавап бирәчәк. Аларның иман китермәгәненә Пәйгамбәр җаваплы түгел».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**42.** Алар арасында сине ишетүчеләр дә *(тыңлаганга салышучылар да)* бар. Саңгырауларга *(җитмәсә, аңгыра да булсалар, дөреслекне)* син ничек аңлатырсың икән? **(43)** Алар арасында сиңа карап торучылар, сине күрүчеләр дә бар. Ләкин алар Хакыйкатьне күрми. *(Күңел күзләре тома)* сукырларгамы син тугры юлны күрсәтерсең? **(44)** Шөбһә юктыр ки, Аллаһ инсаннарга һичничек тә золым итмәс. Ләкин инсаннар үзләренә үзләре золым китерә. **(45)** Ул Көнне *(Кыямәттә Аллаһ)* барысын да бер урынга туплаячак. Алар фани дөньяда көндезнең бер сәгате кебек тә тормагандай булырлар, бер-берләрен таныйрлар. Аллаһ белән *(Кыямәттә)* очрашуны инкарь иткәннәр *(ялган санаганнар)*, тугры юлдан язганнар, һичшиксез, хәтәр зарар күрәчәк. **(46)** Аларга вәгъдә иткәннәребезнең *(биреләчәк җәзаларның)* бер өлешен генә булса да сиңа күрсәтермен яки синең җаныңны алырмын. Ләкин алар барыбер минем хозурыма кайтачак. Аллаһ аларның ни кылачагына шаһиттер.

**47.** Һәр өммәтнең үз пәйгамбәре бар. Рәсүлләре килгәч, алар арасында гаделлек белән хөкем йөртелер вә алар хаксызлыкка очрамаячак. **(48)** *—(Ий, Мөхәммәд)* әгәр дә син сөйләгәннәр хак булса, вәгъдә иткәнегез *(Кыямәт көнегез, биреләчәк җәзаларыгыз)* кайчак булачак соң?—диярләр. **(49)** Әйт син:

—Мин үземә Аллаһ әмереннән башка бер генә зыян да, бер генә файда да эшли алырлык көчкә ия түгелмен,—диген. Һәр өммәтнең әҗәле бар. Әҗәл килгәч, бер генә сәгатькә дә калалмаслар, бер сәгатькә алдан да китмәсләр. **(50)** Әйт син:

*—(Әй, мөшрикләр)* Ни әйтерсез? Аллаһның җәзасы сезгә төнлә яки көндез килеп төшсә, нишләрсез? Гөнаһлылар шуларның кайсысын ашыктыра алыр икән? **(51)** Башыгызга бәла килгәннән соң гына Аңа иман китерәчәксезме? Әллә хәзер үкме? Сез *(газап килүне)* ашыктыра идегез. **(52)** Ахырда золым итүчеләргә:

—Мәңгелек газапны татыгыз,—дип әйтелер. *(Фани дөньяда)* үзегез җыйганнарыгызга *(гөнаһларыгызга)* күрә җәзасын аласызмы? Кылмаган гөнаһларыгыз өчен җәзаланмыйсыздыр бит! **(53)** Кяферләр синнән сорый:

—Ул *(җәзалар, чыннан да, киләчәкме)* дөресме?—диләр. Әйт:

—Әлбәттә, Раббым исеме белән ант итәмен ки, *(валлаһи)*, чыннан да дөрес *(ул газаплар киләчәк)* һәм сез Аллаһны гаҗиз итә алмассыз,—диген. **(54)** *(Фани дөньяда)* гаделсезлек кылган һәркем, әгәр дә бөтен дөнья малына ия булып алса, *(газаптан котылыр өчен)* бөтен малын бирер иде. Әче газапны күргәч, аларның күңелендә яшеренгән үкенүләре өскә чыгар. Барысы да гадел хөкемгә тартылыр, тиешеннән артык җәза аларга бирелмәячәк.

*(Тәфсирчеләр «әче газапны күргәч, аларның күңелендә яшеренгән үкенүләре өскә чыгар» җөмләсен төрлечә аңлата: «газапны күргәч, хафага төштеләр», «газапны күргәч, эчтән яна башладылар», хәтта «газапны күргәч, кылган гөнаһларын яшерергә маташырлар» кебекләре дә бар.)*

**55.** Аң булыгыз, күкләрдә вә Җирдә булган һәрнәрсә Аллаһныкы. Аллаһның вәгъдәсе хактыр, ләкин бу турыда күбесе белми. **(56)** Ул җан өрүче дә, җан алучы да, бары тик Аның хозурына кайтачаксыз. **(57)** Әй, инсаннар, сезгә Раббыгыздан бер үгет *(Коръән-и Кәрим)*, күнелләрегездә булганнардан *(икеләнү, кайгы, имансызлык борчуларыннан)* бер шифалы дәва, мөэминнәр өчен бер тугры юл вә рәхмәт килде. **(58)** Әйт:

—Аллаһның юмартлыгына һәм рәхмәтенә сөенсеннәр. Бу *(Коръән күрсәткәнчә яшәү)*—алар җыйганнан *(дөнья байлыгыннан)* хәерлерәк,—диген. **(59)** Әйт:

—Аллаһ сезгә иңдергән ризыкларның бер өлешен хәләл, бер өлешен харам иттегез, моңа ни әйтерсез икән?—диген. Әйт:

—Аллаһ рөхсәт иттеме сезгә, әллә Аллаһ турында җыен юк-бар сөйләп йөрисезме? **(60)** Аллаһка каршы уйдырмалар чыгарганнарның Кыямәт көнендә күрәчәкләре турында ни уйлыйлар икән? Шик юк ки, Аллаһ инсаннарга мәрхәмәтле. Ләкин аларның күбесе шөкер итмәс. **(61)** Син берәр эш белән мәшгуль булганда да, Коръәннән берәр аять укыганда да, берәр эшкә бирелеп, мавыгып китсәң дә, һәрвакыт өстеңдә шаһит булып торырбыз. Кайда булса да, Күктәме, Җирдәме булсын, тузан бөртеге авырлыгындагы нәрсәләр дә Раббының иркендә булыр *(Аның игътибарыннан яшенереп калалмас)*. Тагын да кечерәге дә, зуррагы турында да *(Ләүхел Мәхфүз дип аталган)* изге Китапта язылган. **(62)** Әйе, шулай, Аллаһның дусларына куркыныч юк; алар хәсрәттә калмаячак. **(63)** Алар—иман китереп, тәкъвалыкка ирешкән кешеләр. **(64)** Дөньяда яшәгәндә дә, Ахирәттә дә аларга сөенеч бар. Аллаһның сүзләрендә үзгәреш юк. Менә бу бөек котылышның үзедер.

**65.** *(Ий, Рәсүлем)* аларның *(инкарьчыларның)* сүзләре синне хафага салмасын. Бөтен гыйззәт *(бөеклек)* Аллаһтандыр. Ул ишетә, белә.

**66.** Яхшы белеп торыгыз, күкләрдә, Җирдә ни булса, барысы да Аллаһныкы. Аллаһтан башка ялган тәңреләргә табынганнар нәрсәгә иярә соң? Дөресе шул, алар уйдырмадан башка нәрсәгә иярмиләр, алар бары тик ялган сөйләүчеләр. **(67)** Ул *(Аллаһ)* караңгы төшкәч, ял итсеннәр дип, төнне, *(эшләп ашарыгыз өчен)* көн яктылыгын яралтты. Шик юк ки, тыңлаганнар өчен *(аңларга теләгәннәр өчен)* монда гыйбрәтләр бар.

**(68)** —Аллаһ бала атасы булды,—диделәр. Әстәгъфирулла! Ул мондый эштән азаттыр. Аның ихтыяҗы юктыр. Күкләрдә, Җирдә ни булса, Аныкыдыр. Бу мәсьәләдә кулыгызда бернинди дәлил дә юк. Аллаһ хакында белмәгәнегезне сөйлисез. **(69)** Әйт:

—Аллаһ турысында ялган, уйдырмалар сөйләгәннәр *(җәзадан)* котыла алмас,—диген. **(70)** Фани дөньяда аз микъдарда рәхәт чиккәннән соң, алар безнең янга кайтыр. Инкарь иткәннәре өчен ахырда алар хәтәр җәзага тартылыр.

**71.** Аларга Нух турындагы хикәяне укы; үз халкына ул нәрсә диде:

—Әй, кавемем, әгәр сезнең арада яшәвем һәм Аллаһның аятьләрен исегезгә төшереп торуым ошамаса, мин бары тик Аллаһка гына тәвәккәл кылдым. Сез дә Аллаһка тиңдәш кылганнарыгызны җыеп һәм ни кылачакларыгыз турында карарланыгыз. Ләкин аң булыгыз, соңыннан үз башыгызга булмасын. Ахырда мине теләсәгез нишләтегез, селкенергә дә форсат бирмәгез, **(72)** әгәр йөз чөерсәгез. Мин сездән әҗер көтмимен. Минем әҗерем Аллаһ тарафыннан булыр, башкадан булмас, миңа мөселман булу боерылган,—диде. **(73)** Ләкин

алар *(Нух пәйгамбәрнең)* сүзләрен ялганга чыгардылар. Без дә аны һәм дә аның якыннарын көймәгә утыртып, коткарып калдык. Аларны *(Җиргә хуҗа)* халифәләр иттек. Аятьләребезне ялган дип атаучыларны суга батырдык. Бакчы, *(үгетләп тә)* үгет алмаганнарның тәкъдире ничек булды? **(74)** Соңыннан аның артыннан үз халкы арасына байтак кына пәйгамбәрләр юлладык. Аларга могҗизалар *(аятьләр)* китердек. Ләкин алар элек тә ялган санаган нәрсәләргә ышанмадылар *(иман китермәделәр)*. Хәттин ашканнарның күңелләрен Без менә шулай итеп бикләп куябыз.

**75.** Аннан соң Без Муса белән Һарунны аятьләребез илә Фиргавен һәм аның яраннарына күндердек. Ләкин алар *(мөшрикләр)* йөз чөерделәр, гөнаһкяр халык булдылар. **(76)** Безнең тарафтан Хакыйкать *(аятьләр)* килгәч: алар:

—Бу, әлбәттә, күренеп торган сихерчелек,—диделәр.

**77.** Муса:

—Ничек итеп сез Хакыйкать өстенә шулай әйтә аласыз? Моны сез сихер дип уйлыйсызмы? Сихерчеләр беркайчан да бәхеткә ирешәчәк түгел,—диде. **(78)** Алар әйтте:

—Сез *(Муса белән Һарун)* безне аталарыбыз тоткан диннән биздерер өчен һәм Җир йөзенә икегез генә баш булып калыр өчен килдегезме? Без сезгә ышанмыйбыз,—диделәр. **(79)** Фиргавен әйтте:

—Бөтен мәшһүр сихерчеләрне монда китерегез,—диде. **(80)** Сихерчеләр килгәч, Муса аларга:

—Ыргытасы әйберегезне ыргытыгыз,—диде. **(81)** Алар атасыларын аткач, Муса әйтте:

—Сез кылганнар бары тик *(күз буу)* сихер генә. Аллаһ сезне фаш итәчәк. Чөнки Аллаһ бозыкларның эшен хупламый,—диде. **(82)**—Гөнаһлыларның һушына китмәсә дә, Хакыйкатьне Аллаһ Үз сүзләре белән раслар. **(83)** Фиргавен һәм аның яраннарының уч алуыннан куркып, шул кавемнен берничә яшь кешесеннән башкасы иман китермәде. Чөнки Фиргавен Җир йөзендәге иң рәхимсез һәм хәттин ашкан *(азгын)* хөкемдарларның берсе иде. *(Фиргавен: мин үзем Аллаһ, дип игълан иткән бәндә.)* **(84)** Шуннан Муса әйтте:

—Әй, кавемем, әгәр дә Аллаһка иман китереп, Аңа баш органсыз икән, бары тик Аңа гына буйсыныгыз,—диде. **(85)** Алар да әйттеләр:

—Аллаһка тәвәккәлләдек. Йа, Раббыбыз, безне залимнәр кулы астындагы сынау әсбаплары итмә,—диделәр.—**(86)** Һәм рәхмәтең илә безне кяферләр токымыннан коткар. **(87)** Без дә *(ягъни Аллаһ Үзе)* Муса белән энесенә:

—Кавемегез өчен Мысырда өйләр житкезегез, ул өйләр намаз укый торган гыйбадәтханәләргә әверелсен, намазларыгызны җиренә җиткезеп укыгыз. *(Һәй, Муса)* мөселманнардан сөенче ал *(җәннәткә керәчәкләрен хәбәр ит)*,—дидек. **(88)** Муса әйтте:

—Йа, Раббыбыз, чынлыкта Син Фиргавенгә һәм аның токымына фани дөньяда күпме зиннәт, күпме маллар бирдең *(аларны баеттың)*. Йа, Раббыбыз, алар *(шул байлык белән кызыктырып)* кешеләрне Синең тугры юлыңнан яздырсын, дипме *(шул муллыкны бирдең?)* Аларның малын юк ит, җаннарына әрнү сал; шундый әрнеткеч җәзаларны күрмичә, алар иман китермәс,—диде. **(89)** *(Аллаһ әйтте)*:

—Икегезнең дә *(Муса белән Һарунның)* догасы кабул булды. Тугры юлда нык торыгыз һәм наданнарның юлына басмагыз,—диде. **(90)** Без Исраил угылларын *(Ягькуб токымын)* диңгез аша кичтердек. Фиргавен һәм аның гаскәре хәтәр дошманлык белән алар артыннан куа чыкты. Ниһаять, *(диңгездә)* батып үләчәкләрен аңлагач, *(Фиргавен)*:

—Чыннан да, Исраил угыллары инанган Тәңредән башка тәңре булмаганына мин иман китердем. Мин дә мөселман булдым,—диде.

**91.** Хәзер иман китердеңме? Гәрчә, моннан алда син гыйсъян кутәрдең һәм азгынлык таратучылардан идең.

*(Муса белән Һарунны куып барганда Фиргавен үзенең гаскәре белән диңгезгә барып керә һәм дулкыннар аны каплый, Фиргавен үлеме алдыннан иман китерә, ләкин аның тәүбәсе кабул кылынмый.)*

**92.** *(Әй, Фиргавен)* Синнән соң киләчәк буынга гыйбрәт булсын дип, бүген синең гәүдәңне коткарачакбыз. Тик кешеләрнең байтагы хак аятьләребездән хәбәрсез.

*(«Фиргавеннең гәүдәсен бәлзәмләп катыралар, бүген дә кешеләр Фиргавен гәүдәсен күреп гыйбрәт ала».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**93.** Хактыр ки, Без Исраил угылларын гүзәл бер йортка урнаштырдык вә аларга пакь нигъмәтләрдән ризык бирдек. Алар үзләренә гыйлем килгәнчегә кадәр үзара низаглашмадылар. Шик юк ки, Раббың Кыямәт көнне аларның гаугалары турында нәтиҗә чыгарыр.

**94.** *(Рәсүлем)* Әгәр сиңа индергәнебезгә шикләнеп карыйсың икән, сиңа кадәр ингән Китапны *(Тәүратны)* укыганнардан сорап бак, хактыр ки, Раббыңнан сиңа Хакыйкать килде. Шикләнүчеләрдән булма. **(95)** Аллаһның аятьләрен ялганга чыгаручы да булма. Соңыннан зыян күрерсең. **(96)** Хактыр ки, өсләренә Аллаһның хак сүзе төшкәч тә, алар иман китермәс. **(97)** Хәтта алларына бөтен могҗизаларны *(аятьләрне)* китереп салсаң да, әрнетүле газапларны күрмичә, алар инанмаячак. **(98)** *(Вәгъдә иткән җәзаларыбыз килеп топкач кына)* иман китереп тә файда күргән берәр халык бармы икән? *(Андый халык юк!)* Бары тик Юныс токымы гына искәрмә булып тора, алар иман китергәч, фани дөньяда аларга биреләчәк мәсхәрәле җәзаларны кичектердек һәм аларга бераз вакытка *(үлемнәренә чаклы)* иркен тормыш бирдек.

*(Хәзрәти Юныс халкына әйтте: иман китермәсәгез, өч көн эчендә өстегезгә Аллаһ Тәгалә җәза җибәрәчәк, диде. Башта ышанмадылар. Юныс аларны ташлап китеп барды. Өч көн узганда, Күктә утлар уйный башлады. Тегеләр куркып, Юнысны эзли киттеләр. Тапмадылар. Хәтәр утлар якыная башлагач, барысы да иман китерде, тәүбә итте. Аллаһ аларны газапламады.)*

**99.** Әгәр Раббың ихтыяр итсә, Җир йөзендәге барча кешеләр дә иман китергән булыр иде. Шулай булгач, син мөселман ясыйм дип, кешеләрне ирексезләр идеңме? **(100)** Аллаһның рөхсәтеннән башка беркем дә иман китермәс. Ул аңларга теләмәгәннәрне мордар *(инкарьчы)* ясар *(җәза бирер)*. **(101)** Әйт:

—Күкләрдә, Җирдә ни бар, багыгыз да, *(гыйбрәт алыгыз)*,—диген.

Ләкин имансыз халык өчен дәлилләр дә *(аятьләр дә)*, кисәтүләр дә файда бирмәс. **(102)** Алар үзләреннән алда яшәп-киткән кавемнәр көненә калмакчы булалармы? *(Шул мәсхәрәле җәза көнен көтәләрме?)*

Әйт:

—Көтегез. Шик юк ки, мин дә сезнең белән бергә көтәрмен,—диген. **(103)** Соныннан Без пәйгамбәрләребезне вә алар кебек үк иман китергәннәрне коткарачакбыз. Иманлыларны коткару минем эш, бары тик минем вазифамдыр. **(104)** Әйт:

—Әй, инсаннар, минем динемә шикләнеп багасыз, *(белеп торыгыз)* мин Аллаһтан йөз чөереп, сез табынганнарга табынмам, мин бары тик сезнең җаныгызны алачак Аллаһка гына буйсынам. Миңа мөселман булу тәкъдир ителде,—диген. **(105)**—Миңа ханиф *(Аллаһның берлеген танучы)* булырга, йөземне туры дингә борырга, мөшрик булмаска боерылды,—диген. **(106)** Аллаһны танымыйча, сиңа файда да, зарар да китерә алмаган нәрсәләргә табынма. Әгәр шулай эшләсәң *(потларга табынсаң)*, син мотлак залимнәрнең берсе булачаксың. **(107)** Аллаһ синең башыңа берәр бәла җибәрсә, Аннан башка ул бәлане беркем дә ала алмас. Әгәр сиңа бер игелек кылса, аны да синнән тартып алалмаслар. Ул Үзе ихтыяр иткән колларына игелек бирер. Вә ярлыкар, гафу итәр. **(108)** Әйт:

—Әй, инсаннар, сезгә Раббыгыздан Хакыйкать *(Корьән)* килде. Кем туры юлга баса, бары тик үзе өчен файдалы. Кем туры юлдан яза, үзе гаепле. Мин сезне җитәкләп йөрүче түгел,—диген.

**109.** *(Рәсүлем)* син вәхий ителгәнгә *(Корьәнгә)* ияр вә Аллаһтан әмер килгәнчегә чаклы сабыр ит. Ул хөкемдарларның иң игелеклесеедер.

صَدَقَ اللَّهُ الْعَظِيمُ

Tarix
Тарих



# Мөсәгыйт Хәбибуллин

## ХАЗАРЛАР

КЕРЕШ СҮЗ

Мин мәктәптә укыган елларымнан ук тарих белән кызыксына башладым. Ә инде исәя төшкәч, Русиянең «Повести временных лет» елъязмасын укый-укый бернәрсәгә төшендем: тарих—һәр кеше, һәр халык, һәр ил өчен дә үрнәк һәм гыйбрәт алырлык гаять дәрәҗәдә җитди фән икән. Фән исә, төгәллекне, дөреслекне ярата. Тик менә Русия тарихы, тоташ диярлек була, риваять-легендалардан гына тора. Чынлап та, Русия тарихын укып, һич тә тарихта булган теге яки бу вакыйгага төгәл һәм дөрес бәя таба алмыйсың. Чөнки Русия тарихын тәхеткә килгән һәр кенәз, һәр патша, һәр түрә үзе уздырган сәясәткә җайлаштырып, үзгәртеп яздырган. Шул сәбәпле, Русия тарихының, гомумән, асылына төшенүе кыен, беренче карашка хәтта мөмкин дә түгел. Шул мәсьәләдә халыкларны һәм киләчәк буын тарихын язучыларны кисәтеп, XII гасыр башында ук Ауропаның мәшһүр галиме болай дип язып калдыра: «Әгәр дә мәгәр тарихчы үз чоры халыклары турында хакыйкый дөреслеккә йөз тотып, теге яки бу халыкның тарихын язарга тели икән—моның белән ул үзенә дошманнар гына җыячак, ә инде хакыйкатьтән качарга тели икән, ул тарихта булган хак тарихны яшерергә мәҗбүр ителәчәк. Бу юл исә тарихчы өчен бик тә яман чир, чөнки тарихта булган хакыйкатьне яшерү, тарих язучыны хатадан-хатага, ялганнан-ялганга илтәчәк. Ә инде тарих язучы тарихта булган хәлләрне тәгаен дөрес итеп бирә икән һәм хакыйкатькә тугры калып эш итә икән—бу хәл дә тарихчыга карата күпләрдә канәгатьсезлек билгесе уятачак. Моны исә болай гына аңлатып булыр иде: «Ялагайлык—дусларыңны ишәйтсә, хакыйкать дошманнарыңны ишәйтер». Инде теге яки бу тарих язучы оятсыз төстә ялагайлык юлына баса икән һәм булган хәлләргә вә вакыйгаларга үзеннән ялганнар өсти икән, бу хәл аны соңрак шул чиккә җиткереп түбәнсетүгә китерәчәк ки, аңа тарихчы булудан бигрәк булмавы мең тапкыр хәерлерәк булачак, шул исәптән тарихи хезмәтен багышлаган җәмгыятькә дә.

Тарих язучыга хакыйкый булган хәлләрне яшерү—үзе үк чиркангыч бер хәл булырга тиеш. Чөнки хакыйкатьне ялган аша ялганга төреп тарихта бирү—җиңел ышанучан киләчәк буынны ялган вә ялгыш юлдан алып китәчәк. Ахыр килеп, тарих язарга керешкән кешегә янә бер яман куркыныч бар: тарихта булган хәлләр коры тел белән язылмаска, тарихта булган хәлләр ялкынлы һәм ышандыргыч тел белән

---

Мөсәгыйт ХӘБИБУЛЛИН *(1927)—язучы, Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Кол Гали исемендәге премия лауреаты. «Чоңгыллар», «Кубрат хан», «Илчегә үлем юк», «Шайтан каласы», «Хан оныгы Хансөяр», «Аллаһы бүләге», «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный» һ.б. романнар авторы. Казанда яши.*

язылырга тиеш. Һәр сүзтезмә, гомумән, тарих язучы өчен һәр сүз тарихта кылынган гамәлләргә тәңгәл килергә һәм тарих язучының теле шул чорда булган вакыйгалардан һич тә калышмаска тиеш *(Вильгельм Тирский. Belli Sacri Historice Paris. 1185.—жур., «Радянский письменник».—Киев, 1975)*.

Русиядә хакыйкатьне эзләү Каф тауларының түбәсенә таба хәрәкәт итсә—яшәү дәверендә кылган кырын эшләре, кылган гамәлләре һәр чорда да «түбән таба» тәгәрәде. Русия империя булып яшәү дәверендә дөньядагы бер генә илгә дә уңай яктан үрнәк була алмавы белән бергә, илләр белән тыныч рәвештә сәүдә итү урынына, дөньядагы илләр арасыннан сугыш өчен дус-ишләр эзләде. Иң гаҗәбе, гасырлар буена чимал һәм корал сатып, империянең экономикасын күтәрергә тырышты. Ә ул камил дигән кораллар күп очракта рус халкының үзенә таба борылды.

Русия империясе бүген дә бары тик бер максат белән яши: солдат озак йокларга тиеш түгел, озак атмаган мылтыкның көпшәсе тутыккан кебек, озак йоклаган солдатның да итек астына суккан кадаклары тутыгырга мөмкин. Шуның өчен солдат һәрвакыт сугышып торырга тиеш. Шуңа таянып нәтиҗә ясарга мөмкин: сугыш империяләр өчен һәр чорда да яшәү чарасы булган һәм ул бүгенге империяләрдә дә шул ук рольне үти. Һәм тарихы да күз угында сугыш каһарманнарын тотып языла. Россия исә сугышка балаларны мәктәп елларыннан ук хәзерли. Шул сәбәпле кул астына кергән башка милләт балаларына да бары тик Россия тарихын гына укытты. Ни хикмәт, Россия аягына тагылган авыр гер хәлендәге Союз республикаларыннан (кайчандыр бабалары яулаган халыклардан) арынса да һәм гасыр азагының туксанынчы елларында дөньядагы цивилизацияле илләргә тиңләшергә теләп, шул илләрнең әхлакый юнәлешенә йөз тотса да, империя чорындагы ялган тарихын үзгәртмәде генә түгел, киресенчә, империяне көчәйтергә юнәлтелгән яңа тарихын язарга кереште. Иң гаҗәбе шул, гәрчә татар халкы Россиядә калып, сан ягыннан икенче урында торса да, Россия бу халыкка карата империячел сәясәтен мыскал да үзгәртмәде. Хак, соңгы елларда йомшаграк караш сизелә, ләкин бу хәл хакыйкый дөреслекне аңларга тырышкан түрәләр даирәсендә генә шулайрак, Россия шовинистлары исә, татарларга карата булган мөнәсәбәтләрен мең еллар элек ничек булган, шулай дәвам итәләр. Бүгенге көндә дә Татарстан халкы ирешкән уңышларга көнләшеп карау бар. Шаклар катмалы хәл, бүгенге Россиядә мәктәп дәреслекләреннән алып, югары уку йортларының уку-укыту программаларында да, матбага, радио-телетапшыруларда да империянең тәүге дәверенә мәдхия укыла—үткәнне тансыклау дәвам итә. Россия империясенең үткән юлына, бигрәк тә язылган ялган тарихына объектив бәя бирү кебек гадел вә хакыйкый караш, гомумән, матбугат битләрендә була торган сирәк күренеш. Ул гынамы, татар халкының мәдәниятенә, сәнгатенә һәм аларның вәкилләренә кимсетеп карау һәм ачыктан-ачык нәфрәт белдерү еш күренә башлады.

Татар баласын, татар үсмерен, татар кешесен үз ана телендә укыту, аңа үз ана телендә белем бирү, үз халкының тарихын укыту тыелды. Татар милләтеннән булган кешене Россиядә үз ана теленнән, диненнән һәм тарихыннан биздерү өчен империянең пропаганда чараларын уздыручылар кулларыннан килгәнне барысын да эшләделәр—татар кешесен «поганый» дип атап, аны вәхшиләргә тиңләүгә кадәр барып җиттеләр. Шул сәбәпле, күп кенә татар милләтеннән булган кешеләр манкортка әверелделәр, ә беришләре исә үз милләтеннән ваз кичеп, христианнарның исем-фамилиясен алып, руслашып киттеләр; бәгъзеләре исә без «болгарлар», бабаларыбыз «болгарлар» булганнар дип, паспортларына «болгар» дип яздыра башладылар. Россия тарихчыларында татарларга карата мөнәсәбәт шул чиккә барып җитте ки, кара этнең бәласен ак эткә, дигәндәй, Россия башына нинди генә афәт вә фаҗига килсә дә татарлар кылган булып чыкты. Әнә шул хәлләрдән соң татар атамасыннан качу, татар булудан оялу, башка милләт вәкиле булып китү совет чорында үтә яман төс алды. Чөнки Россиядә яшәгән һәр кеше бары тик рус телендә генә сөйләшергә тиеш иде. Шул сәбәпле татар зыялыларының күбесе Мәскәү арбасына күчеп утырырга, империя җырын җырларга мәҗбүр булдылар.

Шул чиккә килеп терәлгәч, Россия тарихчылары «тәмләп» кулланган «татар» атамасына да тукталып китик әле. Россия тарихында кайсы гасырларда массакүләм төстә кулланыла башлый соң бу атама?..

Өч гасырга якын татар дәверендә яшәсәләр дә Россия тарихчылары «татар» сүзенә XIX гасырда гына игътибар итәләр. Һәм бу атаманы кем дә түгел, Россия

тарихы карифейларына П. А. Наумов дигән гап-гади бер гимназия укытучысы тәкъдим итә. Ул 1823 елда кечтеки генә күләмле китапчык бастыра һәм анда мондый юллар була: «... все историки между собой согласны, что они свирепые завоеватели были не татары, а монголы... лишь по мере приближения их к пределам нашего отечества их странам Западной Азии были усилены местными татарами, т. е. народами турецкого племени. Далее надо их назвать татаро-монголами».

Иң гаҗәбе шул, Петербургның карифей тарихчыларына гимназия укытучысы биргән атама бик тә ошый һәм бу ярлык Идел буенда меңнәрчә еллар дәвамында яшәп килгән төрки халыкларга да тагыла. Тик ни хикмәт, Идел буе төркиләренең күбесе бу исемне кабул итәргә теләми, әмма Россия тарихчылары «татар» атамасын бөтен дөньяга тараткан булалар инде. Әйе, гәрчә Алтын Урда империясе таркалганнан соң Үзбәк хан алып киткән төркиләрне үзбәкләр дип атасалар да, беркемгә дә, бер илгә дә баш бирми йөргән качкын качакларны (руслар аларны үз тарихларына «казак»лар дип кертеп җибәрәләр) казакълар дип атасалар да һ. б. «Татар» атамасы, ни сәбәпледер, үз заманында иң зыялы булган һәм туар-туганнан бирле утрак тормыш алып барган Идел буе төркиләренә ябышып кала. Ни кылмак кирәк, кайберәүләр паспортларына «болгар» дип яздыра калсалар да, «татар» кушаматын без ташлый алмабыздыр. Болгарлар болганырлар-болганырлар да барыбер бер «безнең арага» кайтып төшәрләр. Бит, ахыр чиктә, бүгенге русларның да төп исемнәре «рус» түгел, ләбаса, бу атаманы бүгенге руслар баскынчы варяглардан алалар. Һәм нигәдер бер генә рус та мин рус булмыйм, мин рус түгел, паспортларына мин «норман» дип яздырырга ашкынып тормыйлар.

Моннан ике дистә еллар элек Россия шовинистлары алдынгы карашлы рухани Александр Меньны үтерделәр. Бу кеше чын гуманист рухани була. Ул үзенең «Талмуд пәйгамбәрләре» дип аталган хезмәтендә болай ди: «Ана теленә, милләтенә, тоткан диненә карап кына теге яки бу халыкка каршы оештырылган геноцид—Җир йөзендә Ходай тарафыннан куелган тәртипне бозу гына түгел, иң әүвәл, гавамга карата булган Аллаһы Тәгалә кануннарына каршы килү дә ул. Аллаһы Тәгалә алдында барлык милләтләр дә тигез—яһүд котүчесенең төп вәгазе әнә шуннан гыйбарәт» *(Александр Мень. Ветхозаветные пророки.—Ленинград, 1991).*

Бер күрше икенче күрше халкын беркайчан да яратып бетермәгән, әлбәттә. Әйтик, борынгы мисырлылар һәм һиндлылар үзләренә әсир төшкән кешеләрне «иблис уллары» дип атаганнар; ә борынгы греклар үзләренең күршеләре булган скифләрне (безнең борынгы бабаларыбыз сөннәрне) варварлар дип атап йөрткәннәр; ул гынамы, аларны Хода тарафыннан кол итеп яратылганнар дип язганнар.

Христиан дине дә үз чорында халыкларга яңа тәртипләр, яңа төшенчәләр алып килә: «Күпне алганнан—күп сорала да», «Без барысыннан да өстен, без Аллаһы Тәгалә сайлаган милләт, дип күкрәк какканнарны ахыр чиктә үкенү, үртәлү һәм ачы хәсрәт көтә, чөнки Хода хакыйкатьне бары тик гаделлектә, тигезлектә һәм татулыкта күрә. Аллаһы Тәгалә хөкеменнән берәү дә кача алмас!»—кебек изге вәгазь-гыйбарәләрне бер генә тарих язучы да читләтеп үтмәскә тиеш. Борынгы Бавил (Вавилон) шагыйрьләре батыр улларына дан җырласалар, Мисыр шагыйрьләре—мәҗүси аллаларына, фиргавеннәренә, хатын-кызларына мәдхияләр укыганнар. Бөек грек шагыйре исә (Гомер) үзләренең каһарман улларына һәм камил коралларына дан җырлаган. Ни гаҗәп, Русия шагыйрьләренең дә генералларына мәдхия укудан туктый алганнары юк. Россия империясен алга өндәгән, җиңүләрдән җиңүләргә алып барырга теләгән түрәләрнең берсе дә гаделлек аша гаделлеккә омтылмады һәм аны сәяси юлдашы итеп алмады. Гимназия укытучысы кертеп җибәргән «татар-монгол» явы һәр түрә өчен «татар-монгол» явы булып калды. Мәктәпләрдә тарих фәне укытканда мин дә шулай сөйләргә мәҗбүр булдым.

Соңгы елларда миңа матбагада чыгып килгән татар халкына кагылган бик күп әдәби, фәнни һәм төрле фаразлауларга йөз тоткан хезмәтләр белән танышырга туры килде. Шул хезмәтләрне укый-укый бернәрсәгә инандым: татар халкының чын тарихын, ихлас күңелдән язарга алынган бер генә рус кешесе дә—язучысы вә галиме дә үз үлеме белән якты дөньядан китмәгән. Татар галимнәрен исә тарих тирәсенә борын-борыннан ук якын җибәрмәгәннәр. Җибәргән хәлдә һәрберсенә шарт куйганнар—йә русларга мәдхия укыйсың, йә бу хакта язмыйсың... Хак, Октябрь революциясенә кадәр, ягъни 1905 елдан соң, татар халкының Русия империясендә тоткан урынын ачыкларга теләп,

иҗтимагый фикер иясе философ Шиһабетдин Мәрҗани милләт тарихының чишмәсен ерып җибәрүгә ирешә. Дәрәҗәле Русия тарихчысы Василий Бартольд (1869—1930) татарның бер мәшһүр тарихчысы турында: «Татарлар арасында прогрессив агымга нигез салучы»,—дип язып чыга. Олы бәһа бу. Татар халкының тарихын дәвам итүчеләр табыла. Төрле сәяси давыллар аша уза-уза Зәки Вәлиди тарихта үз сүзен әйтә. Соңрак Һади Атласи, Газиз Гобәйдуллин, татар халкы тарихына аерата тирән төшәргә омтылган Риза Фәхретдинов, ары таба Гайнетдин Әхмәров, Фоат Вәлиев, алардан эстафетаны үз кулларына алучылар Альфред Халиков, Мирфатих Зәкиев, Миркасыйм Госманов, Әбрар Кәримуллин, Равил Фәхретдинов, Әзһәр Мөхәммәдиев, Фирдәүс Гарипова, Гамир Дәүләтшин, Дамир Исхаков һ. б. саллы-саллы хезмәтләр яздылар. Чит өлкәләрдә яшәүче М. Сәфәргалиев, Р. Безертдинов, А. Сөләйманов, Мурат Анджи, Рәхим Теләшев, Ф. Мухаметов, Ф. Рәшитов һ. б. Америкада яшәүче Ишбулдин, Мәмәд Сәдияр, төркияле татар Казим Миршан һ. б. татар халкы турында көнләшерлек хакыйкатькә йөз токтан хезмәтләр иҗат иттеләр.

Казан татарлары тарихына чыгышы белән немец булган Карл Фукс та үз өлешен кертә. Казан ханлыгы турында төпле һәм ихтирамга лаек хезмәте белән рус тарихчысы Михаил Худяков Сталин җәлладлары тарафыннан атыла, шул исәптән аның фикердәше Н. Фирсовны да читләтеп үтмиләр. Совет чорында исә А. П. Смирнов «Волжские булгары» хезмәтен яза. Бу тарихчы, гәрчә Идел буе төркиләрен славяннар итәргә тырышса да, Ибн Фазланның юлъязмасындагы «сакалиб» сүзен «славян» сүзе дип язса да, ул гынамы, борынгы төрки болгарлар бүгенге чувашлар ул дип расларга маташса да—хезмәт бар, язылган, калган.

Империя явыз кылана татар халкының тарихын язарга керешкән язучылар һәм галимнәр белән. Шуның өчен күп кенә Россия тарихчылары татар халкының тарихын язудан баш тартты. Һәр галим, кулына каләм алуга, Михаил Худяковның язмышын күз алдына китерде. Советлар чорында исә татар халкының тарихын язу тискәре яктан сурәтләүгә кайтып калды. Тюркология белән шөгыльләнгән галимнәрнең күбесен сөргеннәргә озаттылар. Шулар арасында гомерен тюркологиягә багышларга җыенган яшь галим Лев Николаевич Гумилев та була. Бу галим-тюрколог, Евроазиядә көн күргән төркиләрнең тарихыннан башлап, бүгенге татарларның тирәннән килгән хакыйкый тарихын өйрәнүчеләрнең берсе буларак, һәрчак кемгәдер комачаулый, иң әүвәл, әлбәттә, Россиянең шовинист һәм тарихта булып та, тарих фәненнән ерак йөргән булдыксыз бәндәләргә. Лев Николаевичны төрки-татар халыкларының тарихын язарга керешкән өчен Себер лагерьларына озаталар. 15 ел гомерен Себер лагерьларында уздыра яшь галим. Лагерьдан чыкканда аңа инде 43 яшь була. Туган каласына кайтуга, ул янә яшьлегендә сайлаган эшенә керешә. Аңа бу темага кагылмаска кушалар, аны кисәтәләр, әмма Лев Николаевич яшьлектә сайлаган темасына тугры кала. Ил-каласына кайта-кайтуга ул янә төрки-татар халыкларының тарихын язарга керешә. Уннарча хезмәт языла. Әнә шулай моңа кадәр Россия шовинистлары тарафыннан тыелган тема ялтырап китә һәм күптән үз бабаларыбызның ихлас тарихын зарыгып көткән татар кешесенең өстәленә ята. Шушы темага үҗәтләнеп керешкәне өчен кадими карашлы академик Б. А. Рыбаков кебек фән әһелләре аңа каршы чыгалар, аны Россия империясенең төп идеологиясеннән тайпыласың дип каһәрлиләр, әр яудыралар. Империя цензурасы Лев Николаевичның зур хезмәтләрен генә түгел, төрки-татар темасына язылган кечкенә мәкаләләрен дә әнә күзеннән уздыра. Галимне тавыш-тынсыз гына эзәрлекләү башлана, аңа ялагай яшь галимнәрне өстерәләр, империянең алтын баганасын какшатасың дип әр-яла яудыралар. Бу хәл 1986 елларга кадәр дәвам итә. Әйтергә кирәк, татар халкының тарихын язган, татар халкын төрле тарихи һәм фәнни дәлилләр китерә-китерә яклаган һәм дөнья халкына җиткергән галимне торгынлык елларында төрки республикаларның бер генә түрәсе дә яклап чыкмады. Хак, 1991 елда СССР таркалгач, Азәрбайҗанда галимнең «Тысячелетие вокруг Каспия» дигән хезмәтен китап итеп бастырып чыгардылар. Төрки-татар халкының мөмкинлекләре чамалы икәнен белеп булса кирәк, көннәрдән бер көнне Лев Николаевич көндәлегенә болай дип язып куя: **«Я, русский человек, всю жизнь защищаю татар от клеветы...»** Миңа калса, галим «ә алар» дип өстәргә теләгәндер, әмма дәвам итмәгән. Һәм бик дөрес эшләгән. Мөхтәрәм галимне татар халкы онытмады. Титаник хезмәтләрен искә алып, Татарстан республикасы Президенты Минтимер Шәймиев инициативасы белән галим

вафатыннан соң ул яшәгән өй-йортка мемориал такта-һәйкәл куелды. Олуг галимнең татар халкына күрсәткән фидакарь хезмәтен билгеләүче бүләк-һәйкәл иде бу. Шушы һәйкәл куелганнан соң мин Санкт-Петербург каласында булдым. Һәйкәл куелган өй кырында алтын хәрефләр белән язылган сүзләрне укый-укый мәрхүм Лев Николаевичны янә искә алдым. Бит миңа да ул тарихи әсәрләр язарга үз фатихасын биргән һәм тарихи мәгълүматларны ничек, кайлардан эзләргә өйрәткән иде. Шунда мин аңа кат-кат рәхмәт укыдым. Шушы олуг галим татар халкының тарихы турында минем фикеремне кузгатып җибәрмәгән булса, мин беркайчан да тарихи әсәрләр язарга керешмәгән булыр идем—рәхмәт аңа, татар-рус халкының олуг гуманистына! Борынгы бабаларыбыз тормышына багышлап, «Кубрат хан» әсәремне язарга да мин Лев Николаевич киңәше белән керешкән идем. Мин ышанам, татар халкының тарихына алагаем зур өлеш керткән галимгә—Лев Николаевич Гумилевка—Казанда да һәйкәл куелыр. Ә инде аның исемен тагын да мәңгеләштерү өчен татар халкының азау тешенә кадәр тия башлаган башкалабыз үзәгендәге Карл Макс, Киров, Бауман, Ершов, Большая Красная, Профсоюз һ. б. шул чылбырга кергән урамнарның берсенә Гумилев исеме бирелер дигән өметтә яшим мин.

Борынгылар: «Тарихы юк халыкның киләчәге дә юк»,—дигәннәр. Мин әйтер идем, тарихы юк халык гүя көзге уҗымга хуҗасыз чыккан бозау ул, саташып йөри ул—мескен хайван!—теләсә кайсы малга да ияреп китәргә мөмкин, хәтта чучкага да. Һәр кешегә, һәр милләт вәкиленә туган туфрак көч бирә. Ә туган туфрак-ананың көчен чын күңелдән тою өчен үз халкыңның тарихын белергә кирәк. Безнең бабаларыбыз V гасырда Ауропа халкын мәңгелек Рим империясе коллыгыннан азат итәләр, бер сүз белән әйткәндә, коллар исәбенә яшәгән империягә нокта куеп кайталар. Рәхмәт укырга тиешләр кебек иде ауропалылар безнең бабаларыбызга. Әмма бу хәлгә гасырлар үтүгә карамастан, XX гасыр башында ук демократиягә йөз тота башлаган Ауропа халкы үзләрен мәңгелек коллыктан азат иткән Атилла кебек каһарманнарга каһәр укудан ары уза алмадылар. Ни гаҗәп, төп империя тәртипләрен Византиядән кулдан-кулга алгангамы, Россия тарихчылары да үз тарихларын ауропалыларга ияреп язудан ары китә алмадылар. Ә бит Ауропа халкын коллыктан азат итеп кайтканда һун-төркиләр арасында Атилла ханга ант иткән ант-славяннар да булалар, гәрчә соңрак Киев Русе славяннары баскынчы варяглар кушаматы «рус» исемен алсалар да. Нәкъ менә шул тарихи факттан качалар да өрәктән курыккан кебек Россия тарихчылары. Чөнки соңгысын таныганда, «Повести временных лет» елъязмасын бөтенләй яңабаштан язарга туры киләчәк. Ә ул елъязма бүгенге көнгә кадәр галим-голәмәләрне ашатучы алтын табак булып кала бирә.

Кем һәм кайчан, нинди халык чишмә башында русларга Ауропада бер булган зур державага әверелеп китәргә ярдәм иткән дә һәм нинди халык империягә кораб җилкәне булган?

Җавап бер булыр: гомер буйларына Киев Русенда, ахыр Идел буенда көн күргән төрки болгарлар, соңрак шул ук рус тарихчылары татарлар дип атаган халык.

Галимнәр арасында Киев Русе тарихы, гомумән, Россия империясе тарихы XI гасырда Киев Русенда языла башлый дигән фаразлау бар. Ләкин моны раслый торган дәлилләр юк хәлендә. Шуңа карамастан, елъязма бар, елъязма йөрештә. Безгә билгеле булганы шул—елъязманы Радзивилов язмасы йөзендә Петр I патша Кенигсберг каласыннан алып кайта. Бу буладыр 1713 елда. Гәрчә бу тарихи елъязма XIX гасырда гына укучыларга барып җитсә дә, әнә шуннан башлана Россия империясе тарихы.

Алдагы язмамда минем максатым исә әнә шул тарихтан дини вә сәяси яктан борынгы монахлар гына түгел, кенәзләр һәм патшалар да җуйдырган төрки болгарлары һәм бүгенге татарларның тарихын нинди дәр күләмдә тулыландыру гына иде. Теләгән максатыма ни дәрәҗәдә ирешкәнмендер, анысын инде Сиңа калдырам, кадерле укучым!

Без, нигездә, Рим, Византия, Россия һәм аз-маз Иран тарихчылары чыганаклары аша үз бабаларыбызның үткәнен өйрәндек. Анда да чикләнгән рәвештә генә. Соңрак Н. Я. Бичурин, В.С. Таскин, Э. Х.

Шефер һәм бераз гына Владимирцев хезмәтләре аша Кытай тарихчылары чыганаклары белән танышырга мөмкинлек туды; әлбәттә, В. В. Бартольд, Н. А. Баскаков, М. И. Артамонов, А. Н. Бернштам, бигрәк тә Л. Н. Гумилевның күпкырлы хезмәтләренә таяна-таяна күзебез ачыла төште. Мин дә үз чиратымда, Байкал күле тарафларыннан алып, Кубань (Көбән—бай, буаз сүзен аңлаткан) далаларына кадәр җирләрне биләгән һәм гасырлар буена безнең эрага кадәр үк яшәп килгән империяләрнең саруын кайнаткан, тәмам тешләренә тигән сөн-төркиләр тарихына Кытай тарихчылары хезмәтләре аша да күз ташларга булдым. Хак, төрки һәм сөн-төрки бабаларыбыз тарихына моңарчы да татар галимнәре дә теге йә бу яктан килеп, әмма нигездә бары тик Русия һәм Гарәп тарихчылары хезмәтләренә генә таянып, ачыклык кертергә тырышканнар. Әйтик, мөхтәрәм олуг галимебез Шиһабетдин Мәрҗани бу хакта үз хезмәтенең берсендә болай да: «... Тарих фәне—барлык милләт һәм кабиләләрнең хәлләрен эченә ала, гыйльми тармакларны һәм фәнни бәхәсләрне тикшерә. Гади халык һәм белмәүчеләр аны белергә тели... Әмма безнең бабаларыбыз монгол һәм татар таифәләре бу бөек тарих гыйльме һәм халыклар тормышы белән кызыксынмаганлыктан, тарих фәненнән өлешсез калып, дөньядагы хәлләр, вакыйгалар һәм маҗараларны беркетеп бармаганнар. Шуңа күрә бөек галимнәребез, патшаларыбыз һәм олуг акыл ияләребез турындагы хәбәрләр, ата-бабаларыбызның, нәсел-нәсәбебезнең һәм туганнарыбызның хәлләре вә гамәлләре... билгесезлек пәрдәсе астында капланып калган...» *(Шиһабетдин Мәрҗани. Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр.—Казан. 1989).*

Бабаларыбыз тарихын Әхмәт-Зәки Вәлиди атлы тарихчыбыз да читләтеп үтми. Бабаларыбыз тарихы турында ул болай ди: «Төрек кауеменең һәммәсенең дә теле бер—төрки телдер... Алтайдагы төрекләр теле гарәптәге Кырым татарлары илә тәрҗемәсез сөйләшә алалар» *(Әхмәт-Зәки Вәлиди. Кыскача төрек-татар тарихы.—Казан, 1992).*

«Дөньяда гарәп һәм фарсы, һинд һәм әфган, кытай һәм япон, француз һәм инглиз, итальян һәм урыс исемнәрендә милләтләр булган кебек, төрки исемендә дә олуг бер милләт бар. Төрки милләте—безнең үз милләтебез, без төрки милләтеннәнбез»,—дип яза янә бер мөхтәрәм галимебез (Ризаэтдин Фәхретдинов. Болгар вә Казан төрекләре.—Казан, 1993).

Төрки халыклар көн күргән ил-җирләрне билгеләгәндә тарих фәнендә хаталар җибәргән (ул Россиядә хезмәт иткән) немец галиме Миллер җәнабларына җавап итеп, тарихчы Һади Атласи да үз сүзен әйтә: «Аурупа халыкларына скиф, сармат, һун-гун, авар, кыпчак-половец, татар исемнәреннән чыгып әтрафка таралган төрки (түрк) балалары иде. Һәрвакыт Кытайны хафаландырганы сәбәпле, чинлылар (кытайлылар) тарафыннан башбаштаклыклар кылынды» *(Һади Атласи. Себер тарихы. Сөембикә. Казан ханлыгы.—Казан, 1993).*

Татар тарихчысы Газиз Гобәйдуллин да бу теманы читләтеп үтми, чөнки бабаларыбыз тарихы һәр чорда да һәммә гыйлем иясен кызыксындырып үзенә тартып тора. Әйтик, канкардәшләребез угызлар Хазар каганаты җирләренә яу йөргәч һәм андагы бакчаларны, сала-калаларны җир белән тигезләгәч, төрек-яһүд карты елый-елый болай ди: «... Хәзәр исемле дәүләтнең башына килгән һәлакәтләр, шимальдән килгән гаскәрләр, Урал тавы артыннан чыккан күчмәләрнең һөҗүмнәрен сөйләп, бу мәгъмүр шәһәрне шуларның уклары көл иткәнен, шуларның кылычлары халыкларны кискәнлеген, шул һөҗүмчеләрнең ат аяк асларында харап булганлыгын сөйләде...»—ди тарихчы *(Газиз Гобәйдуллин. Тарихи сәхифәләр ачылганда.—Казан, 1989).*

Элегрәк заманда да Аурупа һәм Россия тарихчылары тарафыннан тудырылган төркиләр турындагы күзне ертып торган ялганны соңрак бер генә илнең тарихчысы да, бер генә илнең сәяхәтчесе дә вә мосафиры да фаш итмәде һәм аларның бу гамәлен яманламады һәм хурламады. Аурупа тарихчылары, әйтик, Атилла хан төркиләрен башта вак-вак халыкларга, ахыр килеп халыкчыкларга бүләләр, Россия тарихчылары исә бер тотам калмый аларга ияргәләр, төрекләрне килмешәкләр дип атыйлар, хәтта кыргыйларга тиңли башлыйлар. Ахыр чиктә, Византия тарихчылары төркиләргә яңа исем—

һуннар дигән атама тагалар. Әүвәл бу исем төркилек белән тәңгәл йөргән. Бер Византия тарихчысы хезмәтендә бу хакта менә мондый юллар бар: «Шул чакта элек без төркиләр дип атаган һуннар килделәр...» Ары таба византиялеләр өчен «һун» сүзе тәмам сүгенү сүзенә әверелә. Россия тарихчылары идеологияне Византиядән алганга күрә, һуннар турында Аурупа тарихчыларыннан да арттырыбрак яза башлыйлар. Әйтик, һуннар турында энциклопедиядә мондый юлларны укырга була: «II—IV гасырларда Урал төбәкләрендә оешып киткән күчмә төрки телле һуннар җирле угор һәм сармат халыкларын изртеп, көнбатышка таба «бөек» күчеш башлыйлар (IV гасырның 70 еллары). Шушы башлангыч, халыкларның Бөек күчешен башлап җибәрә. Барыр юлларында һуннар герман кавемнәренең беришен һәм башкаларны буйсындырып, кабиләләр союзы төзиләр. Әнә шул халык бик күп илләрне җир белән тигезләп уза. Яуларның иң яманы Атилла хан чорына туры килә. Һуннарның көнбатышка таба яуларын Каталун кырындагы сугыш туктата (451 ел). Атилла хан үлгәч (453 ел), кавемнәр союзы таркала» *(Советская энциклопедия.—М., 1963.—стр., 300).*

Энциклопедиядәге тарихи мәгълүматның һәр юлында ялган тулып ята. Әйтик, тарихи фактлар шуны раслый: Бөек күчеш энциклопедиядә IV гасырда башлана дип бәян ителә, чын тарихта исә ул II гасырда ук Уралдан да түгел, ә Алтайдан кузгала. Дөресрәге, Бөек күчеш II гасырдан, IV гасырга кадәр төрки халыклар тарафыннан оештырыла гына әле. Төрки халыклары бу дәвердә олуг бер Хәрби союзга берләшәләр. Төркиләр союзы бары тик 372 елда гына Баламир хан җитәкчелегендә Дон елгасын кичеп, Аурупага таба юнәләләр. Ахыр килеп, күп кенә Россия тарихчылары расларга тырышканча, сарматлар бер дә фарсылардан чыккан халык булмый, бу халык туа-туганнан бирле төрки телдә сөйләшкән. Сарматларны Иранан чыкканнар дип башлап Аурупа тарихчылары язалар, табигый инде аларга ияреп Россия тарихчылары да моны сүзгә-сүз диярлек кабатлыйлар. Бу хакта кытайлы тарихчыларның хроникасында мондый юллар бар: «Рим империясе һәм Византия—Аурупаның Бөек илләре Дәште-Кыпчакка IV гасырдан башлап ясак түлиләр».

Хәер, ни гадел булырга теләгән Англия тарихчылары да Атилла хан төркиләре турында Россия тарихчыларыннан бер дә калышмыйлар. Державалар барлыкка килгәч, империяләр сүз куешкандай сәясәтләрен һәм эмоцияләрен генә үзгәртеп калмыйлар, ә бәлки, тарихларын да яңабаштан язарга керешәләр. Нәтиҗәдә, Дәште-Кыпчак инде бу бөек державаларга кертелми. Ә бит төркиләр җитәкләгән Дәште-Кыпчак кул астында Байкал күленнән алып, Дунай елгасына кадәр сузылган җирләр була инде. Византия империясе сановнигы Зимарх һәм гарәп Ибн Батута төркиләрнең ил-җирләрен сигез ай буена үтәргә кирәк, дип язалар. Дәште-Кыпчак державасына шулай ук төркиләр каганаты—Кубрат хан төзегән (VII) Бөек Болгар дәүләте дә кергән. Бүгенге Татарстан Республикасы җирләре Дәште-Кыпчакның төньяк төбәге дип саналган.

Төрки болгарларның хазарлар белән тыгыз элемтәдә булулары хакында «Повести временных лет» елъязмасы авторлары да читләтеп үтмиләр. «Когда же славяне, как мы уже говорили, жили на Дунае, пришел от скифов, то есть, от хазар, так называемые болгары, и сели по Дунаю...» *(ПВЛ.—Ч. I.—С.—210).*

Бу ни хакта сөйли соң? Бу шул хакта сөйли, «скиф» дигән халык, б. э. к. тарих атасы Геродот та телгә алганча, төркиләр булганнар, алар арасында славяннар бөтенләй булмаганнар. Ахыр килеп, Дунай буена кем дә түгел, үз ыруы белән Кубрат хан улы Аспарух күчеп килә. Бу чорда баш бирмәгән яшь ханны хазарлар эзәрлеклиләр. Әйе, кардәш ыру булса да. Аспарух башта Киев тарафына таба чигенә. Киев төбәгендә баштан ук Хазар каганы канаты астына үзе теләп кергән Батбай ханның улы Айдар утыра. Әмма Айдар хан, туганы булса да, Аспарух ханны кабул итә алмый, әмма үз җире аша уздыра. Аспарух хан ыруы белән Днепрны кичә һәм Византия империясе җирләренә таба юнәлә. Ахыр килеп, атасы Кубрат хан белән дустанә-тату яшәгән империя ич. Ә Хазар каганының төп максаты Аспарухны җиңү түгел, башбирмәс ханны илдән куу була. Һәм ул моңа ирешә дә. Ә бит хазарларга кадәр Бөек Болгар

иленә Түбән Дон буйлары, Азов диңгезе төбәкләре, Төнья Кавказ һәм Кырым кергән була һәм, әлбәттә, Идел буе Болгары төбәкләре дә. Моны күренекле археологлар да үз хезмәтләрендә раслыйлар. Мәсәлән, В. А. Бабанко, В. А. Городцов, Д. Т. Березовец, С. А. Плетнева, В. А. Михеев, К. И. Красильников кебек галимнәр. Нәкъ менә шул галимнәр бүгенге Харьков каласыннан ерак түгел, Кубрат хан чорында чәчәк аткан 120 гектарга җәелгән кала табалар. Кала-кирмәндә күптөрле һөнәрчеләр эшләгән, сәүдәгәрләр яшәгән һәм кала халкы белән Бөек Болгар ханына буйсынган тархан идарә иткән. Мәгълүм ки, 860 елларда Бөек Болгар дәүләте хазарлар тарафыннан туздырыла башлый. 870 елларда Кубрат хан үлгәч (Кубрат хан 668 елда үлә дип язалар Орлов Р. С., Рассомакин Ю. Я. үзләренең хезмәтләрендә.—*Новые памятники VI—VII вв. из Приазовья // Материалы I тыс. н.э. археологии и истории Украины и Венгрии.—К., 1996).* Тарихта булган бу вакыйганы яһүд һәм хазар язмаларын тикшергән тарихчы болай дип раслый: «Они *(болгары)* оставили свою страну и бежали, а те *(хазары)* преследовали их, пока не настигли их, до реки имени Дуна» *(Коковцев П. К. Еврейско-хазарская переписка X в.—Л., 1932).* Янә өстәп шуны да әйтергә була, бу вакыйганың тарихта булуын Византия хронисты рухани Феофан Исповедник та үз язмасында раслый. Ошбу җирләр, Византия биләгән җирләр белән чагыштырганда, иксез-чиксез ил дип күзаллана. Вә ләкин, әнә шул кечкенә дип саналган Византия империясе үзенең тарихын шул тикле оста һәм хакимләштереп яза барган ки, бүген шул тарихны һәр Аурупа кешесе «дөрес» дип танырга мәҗбүр. Җитмәсә, XIX гасырда моны Русия тарихчылары күтәреп алалар; идеологияне шул тарафтан алу сәбәпле, үзләре белән иңгә-иң яшәгән төркиләр йөзендәге татарларны каһәрләргә керешәләр һәм бу өлкәдә шактый зур уңышка ирешәләр. Нәтиҗәдә, төркиләр тарихы күләгәдә кала, ә исемнәре дә тарихта рәтләп ачылмаган урыс тарихы бүлтәеп чыга һәм ул канун итеп Русиянең бөтен халыкларына таратыла. Үз заманында чыгышы белән мисырлы булган атаклы Византия тарихчысы дөнья халыклары тарихына кагылып болай дигән: «Акыл тарафыннан тудырылган иң җитди нәрсә—тарих: тарих һәр кешегә укыган саен рәхәтлек китерә, тән өчен генә түгел, җан өчен дә зур мәктәп, тәрбия булып тора; күп белергә теләгән кешегә тарихтан да мавыктыргыч фән юк. Тарих—бөтен кешелеккә сабак бирә... Аннан гыйбрәт ала белгән җитәкче һәрчак акыллы, һәрчак алдан күрүчән була» *(Симокатта Ф. История.—Москва, 1957).*

Танылган татар галиме дә бу мәсьәләгә кискен туктала һәм болайрак әйтә: «Безнең төрки-татар тарихы иң бай тарихлардан булуга карамастан, без үз тарихыбызны язуда соңга калдык. Бетәргә юл токан халык кына үз тарихына игътибарсыз кала... Тарихта язу өчен иң авыр һәм җаваплы чор—этногенез чоры, чөнки борынгыга ни дәрәҗәдә тирәнрәк төшсәң, төрле мәгълүмат бирердәй чыганаклар шул дәрәҗәдә азая ки, аларны аңлау һәм кайсы этник тамырга карату торган саен читенләшә генә бара» (Зәкиев М. З. Төрки-татар этногенезы.—Казан-Мәскәү, 1998).

Бүгенге көндә тарих фәне укытучы галим Хазар каганатының чикләрен билгели һәм болайрак яза: «Иделнең түбән ягында сабар кавемнәре көн күрәләр, аларны «чабар» исемле иректе күчеп йөрүчеләр дип атыйлар. Күрәсең, «сабар-чабар» тора-бара «хазар» атамасы булып киткәндер. Бу иректе төрки халкы берәүгә дә ясак түләмәгән. Шуннан тарихта «хазар» этнонимы барлыкка килгән» *(Безертдинов Р. Н. Татары, Тюрки—потрясатели вселенной.—Н. Челны, 1997).*

Бу мәсьәләгә кереп киткәч, алга куелган бурычны тагын да тәгаенләргә нигез эзләп, янә бабаларыбыз тарихына багыйк әле.

Бик тирәнгә төшмичә, безнең эраның гасыр башыннан башлыйк. Эра башында ук безнең бабаларыбыз булган төркиләр турында Кытай тарихына мондый мәгълүматлар кереп калган. Олуг тарихчы Лев Николаевич Гумилев хезмәтләренә нигезләнеп әйтә алабыз: Кытай тарихчылары Ашин кабиләсенә кергән ханнарны—Ту-кю дип атаганнар. Тарихчы галим П. Пелье исә бу сүзне Түр-йорт», «Тюр-ют» дип яза, ягъни «төрки»—кытай телендә бу сүзгә «көчле, нык бәдәнле» дигән мәгънә салынган. Ә Ашин сүзе кытай телендә Бүре дигән мәгънәне аңлата. Димәк, Кытай чиге тарафларындагы далаларда

Бүре нәселеннән чыккан халыклар көн күргәннәр. Бүре исемен аларга кытайлылар бер дә тиккә генә бирмәгәннәр булса кирәк, без беләбез, бүре җанвары гадәттә адәм баласына буйсынмый, һәр дәвердә дә мөстәкыйль вә бәйсез яшәргә тырыша, шул ук вакытта адәм баласы белән тыныч яшәүне дә күз угында тота.

Әнә шул зур ыру башына V гасыр башында Бумын каган менә. Һәм бу каган күрше жужан халыклары белән берничә тапкыр сугыша, аларны җиңә, күбесен әсир итә. Бу хәлгә кадәр Бумын каган жужаннар ханы Анахуанга кызын сорап яучы-илчеләрен җибәргән була. Әмма тәкәббер жужан ханы аны мыскыл итә, чөнки Бумын каган кешеләре бу ханга тимер коеп торган һәм сатып яткан булалар. Шуңа күрә булса кирәк, жужаннар ханы Бумын каганның илчеләренә болай ди: «Син бит минем бары тик тимер коючым, ничекләр син кыйдың минем кызым кулын сорарга!»

Кытай тарихчылары әйтүенчә, Бумын каган моны махсус эшли—ул бераз чамалый, Анахуан хан аңа кызын бирмәячәк, ә аңа шул гына кирәк була да. Бумын каган Анахуан ханга җавап биреп тормый—ханның җавап белән килгән илчеләрен җәзалый, ә үзенең илчеләрен икенче күршесе булган император Вәй-Ди иленә җибәрә һәм аның кызын кияүгә сорый. Император Вәй-Ди карусыз риза була һәм Чәчле исемле кызын илчеләргә биреп тә җибәрә. Бу буладыр 552 елда. Үзенә аркадаш табу белән үк Бумын каган жужаннарга яу йөри. Яу килеп җитәр-җитмәс үк, Анахуан хан гарьлегеннән үз-үзенә кул сала, ә гаскәрен җитәкләргә тиеш улы илен ташлап кача.

Әмма Бумын каган яшь хатын белән озак тора алмый—ул Илхан титулы алып, 552 елның азакларында вафат була. Тауларга качкан жужаннар да тик ятмыйлар. Алар үзләренә төркиле Кара Иссек ханны дәшәләр һәм ил тәхетен тәкъдим итәләр. Әмма шул ук елда Кара Иссек хан үлеп китә. Тәхеткә утырырга тиешле Иссек ханның улын жужаннар кабул итмиләр, чөнки бу углан «талау» эшләре белән шөгыльләнә торган була. Тәхеткә Кара Иссек ханның кече улы Мәңгүк ханны күтәрәләр.

Жужаннар белән туганлашып киткәч, төркиләр бердәм союз төзү максаты белән, канкардәшләренә илчеләр җибәрәләр—берләшергә һәм союзларына керергә чакыралар. Ә инде риза булмаганнарын көч белән мәҗбүр итәләр. Әнә шулай итеп 554 елда Мәңгүк хан башта кыргызларны, аннары киданнар ыруы белән утыз татар кавемен буйсындыра.

572 елда Мәңгүк хан үлә. Ил тәхетен аның улы Табахан били. Ошбу яшь хан Кытай императоры белән солых төзи. Солых төзелүгә үк төркиләр иленә Будда миссионерлары килеп төшәләр. Кытай империясе белән солых төзегән төркиләр уңалар, 580 елларда инде аларның даны еракларга тарала. Бу ил түрәләрен Кытай тарихчылары да күреп алалар һәм тарихларына терки башлыйлар. Данга күмелгәч кенә, 581 елда Табахан каган көтмәгәндә үлеп китә. Төркиләр каганатының тәхетен Бумын каганның кече туганы Истеми били. Истеми каган тәхеткә менә-менүгә көнбатышка таба яу йөри, хәтта Каспий диңгезе буйларына кадәр килеп җитә. Күп тә үтми төркиләр Иделнең сулъяк ярына чыгалар. Бу тарафларда җәйли башлау белән үк төркиләр аварларга яу йөриләр, ә аварлар көнбатышка таба кузгалалар. Аварлардан бушап калган җирләрне һәм җәйләүләрне Истеми каган үз канаты астына ала. Һәм ул Идел-Урал төбәкләрендә көн күргән халыкларны берләштерергә керешә. Берләштерүне тәмамлагач, аңа хәбәр ирештерәләр: эфталитлар Ефәк юлын япканнар. Аварларны яулап вә буйсындырып бетермәгән Истеми каган табынга җыелган аксакалларына болай ди: «Аварлар кош түгел, минем кылычтан качырга теләп, һавага күтәрелә алмаслар, алар балыклар да түгел—су төбенә китәргә, алар җир адәмнәре, эфталитларны җиңгәч, мин аварларны да юк итәрмен, алар миннән качалмас».

Тарихта мәгълүм булганы шул: Истеми каган эфталитларны җиңә, Ефәк юлына сакларын куеп, Идел буена әйләнеп кайта. Һәм аварларга яу кузгалырга җыена башлый. Әмма аңа хәбәр итәләр, имеш, аварлар ерак киткәннәр, ул гынамы, авар каганы Византия императоры белән Иранга каршы сугышырга солых төзеп ята икән.

Аварларның империя белән солых төзүенә Истеми каганның кәефе бозыла. Әмма чарасыз калмый, үзенә аркадаш әзләргә керешә. Башта ул Ефәк юлында йөрүче бай Согдиан сәүдәгәрләре белән килешү төзи, аннары Дон елгасының өске тарафларында көн күргән кәтригурлар белән элемтәгә керә. Византия тарихчылары Тәрксинаф, Кытай тарихчылары Тәнхан дип язган каган үзенең ярдәмчесе Бүрехан белән Византия империясенең колониясе, дөресрәге ярымколониясе булган Боспор дәүләтен яулыйлар. Төрки халыкларының легендаларына каһарман булып кергән Истеми каган Иран шаһиншаһы белән аркадашлыкка исәп тотып, шаһиншаһка илчеләрен җибәрә. Каган илчеләренә Урта Азиягә узарга туры килә. Бу вакытта әле Ефәк юлы Урта Азиядә көн күргән эфталитлар кулында була. Борынгы Согда каласына җитәрәк, эфталитлар Истеми каганның кәрванын талыйлар, илчеләрен үтерәләр. Илчеләрдән бары тик үтә елгыр егет кенә котылып кала һәм юлда булган яман хәбәрне Истеми каганга ирештерә. Истеми каган ашыгыч төстә эфталитлар ханы Гатфарга илчеләрен җибәрә һәм аңа катгый рәвештә шарт куя: «Төркиләр кәрванына баскынлык иткән һәм минем илчеләрне үтергән юлбасарларны миңа тотып бирәсең».

Эфталитлар ханы Гатфар Истеми каганның үтенечен кире кага. Бу хәбәр ирешүгә, Истеми каган Гатфар хан иленә яу кузгата, Урта Азиягә җитә, тиз арада Чәчә (бүгенге Ташкент) каласын яулый, ә алдынгы атлы гаскәренә Чирчек елгасын кичеп, Маймир каласын алып тукталырга куша. Эфталитларның төп көче Бохара каласына таба чигенә һәм шунда туктала. Истеми каган гаскәре белән шунда таба юнәлә. Ләкин төркиләрнең якынлашуын күреп, Гатфар хан гаскәре белән Нәсибә тауларына таба чигенә. Төп орыш Нәсибә таулары итәгендә була. Эфталитлар төркиләр тарафыннан тармар ителә, күпләре тауларга качып котыла, халыкның күбесе Гатфар ханнан ваз кичәләр һәм төркиләргә килеп кушылалар.

Ефәк юлының күп өлешен кулына төшергән Истеми каган дөнья илләре арасында сәяси яктан гына түгел, экономик яктан да күзгә күренеп күтәрелә. Кытай тарихчылары төркиләрнең бу җиңүен ассызыклап язалар. Шул елдан алып, төркиләр Ефәк юлына ия булып китәләр һәм тамга-ясакны да сәүдәгәрләрдән Төркиләр каганы җыя башлый. Әмма төркиләрнең бу уңышы белән Иран шаһиншаһы килешми. Шаһиншаһ Ефәк юлының үз иле аша үткән җирендә төркиләрнең сәүдәгәрләреннән икеләтә-өчләтә салым җыя башлый. Бу хәбәр янә бик тиз Истеми каганга барып ирешә. Истеми каган Иран шаһиншаһы Хәсрәүгә илчеләрен җибәрә. Шарты бер: «Каган сәүдәгәрләреннән югары бәядә салым алуны туктат!»

Тик Иран империясенең илбашы Хәсрәү дә нindидер килмешәк Төрки каганының катгый сүзләрен ошатмый һәм илчеләргә: «Сезнеңчә булмас!» дип кенә әйтә. Каганның илчеләре бернигә ирешә алмый борылып кайтып китәләр. Кайткач, илчеләр барысы хакында да Истеми каганга түкми-чәчми сөйләп бирәләр. Истеми каган табын җыя һәм аксакалларына булган хәлләрне җиткерә. Табында барысы да бер фикергә киләләр—каган дипло-матиясендә сыгылмалылык җитми, шаһиншаһ Хәсрәүгә янә илчеләр җибәрергә кирәк. Илчеләр җибәрелә, бу юлы инде каган илчеләре гаять дәрәҗәдә тыйнак кыланалар, әмма каты маңгай шаһиншаһ Хәсрәү Истеми каганның мөнәсәбәтен аңламый, Төркиләр каганына мыскыллы сүзләр әйтеп, илчеләрне куар дәрәҗәгә җитеп, илдән чыгарып җибәрә.

Истеми каганга берденбер чара кала—сугыш.

Яу чыгуга, Истеми каган юл өстендәге сәүдә калаларын кулга төшерү нияте белән уң канат гаскәрен Аму-Дәрья аша җибәрә. Үзе исә төп гаскәре белән туры Иранга юнәлә. Әмма ул юл өстендә яткан фарсылар V гасырда күтәргән кирмән-каланы ала алмый, чигенергә мәҗбүр була. Иленә кайтуга ук Истеми каган көнбатышка таба яу кузгала, тәүге елларда буйсындыра алмаган аварларны кул астына җыярга тели.

571 елда, ниһаять, төркиләр тулысы белән диярлек Кавказны яулыйлар һәм Кара диңгез буйларындагы далага чыгалар.

572 елда олуг каганлык тәхетендә утыручы Мүгән каган үлә. Аксакаллар

табыны олуг каганлыкка аның туганы Арыслан ханны тәкъдим итәләр. Аксакаллар тәкъдиме белән төмәнбашлар да килешәләр. Шул ук елда олуг каганлык табынына чакырылган Истеми каган үз иленә юл тота һәм үзе белән кардәше Бүреханны да ияртеп алып кайта. Илгә кайтуга, Истеми каган үз кул астындагы төрки ыруларын җыеп, табын уздыра. Әнә шулай көнбатыш төркиләренә яңа кавемнәр өстәлә. Көнбатыш төркиләренең көчәеп китүләрен күреп, Иран шаһиншаһы һәм Византия императоры көнләшеп карыйлар. Яңа империя туып килә ич. Моның өстенә бер дә аларга ошамаган, динтелләре белән генә түгел, иҗтимагый-сәяси һәм гореф-гадәтләре дә үзгә империя. Шуңа да карамастан, баштагы мәлдә бу ике империя дә төркиләр йөзендә җитди дошман күрмиләр. Әмма һәр икесе дә бу кинәт кенә калкып чыккан каганат белән элемтәгә керергә тырышалар. Дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштыру нияте белән Византия императоры Истеми каган ыстанына илчеләрен җибәрә. Чөнки Истеми каган Византия империясенә бер тапкыр игелек кылган була: Боспор дәүләтен яулый, әмма күп тә үтми аннан гаскәрләрен чыгара. Император илчеләре Истеми каганның бу адымын дустанәлеккә юрыйлар һәм төркиләр белән тату яшәргә теләүләре турында белдерергә телиләр. Император илчеләре Боспорны ташлап киткән каган алдында әйләндерә-тулгандыра бик озак нотык тоталар. Истеми каган аларны тыныч кына тыңлап утыра, бер тапкыр да бүлдерми. Бары тик император илчеләре тынып калгач кына Истеми каган тамак кыра, янәсе, кадерле илчеләр, минем дә сезгә әйтер сүзем бар.

Тарихта хакыйкать шулай ачыла бит ул. Истеми каганның җавабын илчеләр арасында булган вәкил тарихка сүзгә-сүз диярлек теркәп калдырган. Менә нәрсә ди Төрки каганы Истеми Византия илчеләренә: «Сезмени ул ун телдә сөйләшкән халыкны ун телдә алдаучы римләннәр! Без төркиләр ялганның да, алдауның да ни икәнен дә белмибез. Мәгәр белеп торыгыз: минем аварларны яклаучы, колларымны минлекләүче, әмма үзе минем белән дустанә яшәргә телим диюче илбашыгызга әйтегез—мин аңардан моның өчен ничек һәм кайчан үч алырга җаен табармын».

V гасыр башларында Алтай тарафларыннан кузгалган безнең бабаларыбызның бабасы, IV гасырда Урал-Идел буйларыннан кузгалып, Ауропага кадәр барып җитеп, мәңгелек коллык империясе Римне туздырып, монда яшәгән барлык халыкларны коллыктан азат итеп дөньядан киткән Атилла ханның канкардәше Истеми каган үлә. Ил тәхетенә аның улы Кара Чурин утыра.



*IX гасырда Азия*

Тәҗрибәле сугышчы, оста укчы вә сөңгече, батыр һәм кыю Кара Чурин углан чакта ук атасы белән яуларга йөри һәм каганның уң кулында йөргән төмәнбаш була. Атасы вафатыннан соң тәхеткә утырган каган Кара Чурин ике фронтка сугыш башлый—аварларны тәмам буйсындырырга керешә һәм Византия империясенә сугыш игълан итә. Сугыш башлана һәм ике канатта барган сугыш 683 елларга кадәр дәвам итә. Ниһаять, сабыры текәнеп, Кара Чурин баһадир Бүрехан белән Дербент кирмәненә таба юнәлә. Бу чорларда

төрки халкы Дербентны Тимер Капка дип атаганнар. Тимер Капка кальгасы бу тарафларга яу йөрүчеләр өчен чынлап та тимер капка булган, моның өстенә Төньяк Кавказга үтү өчен бердәнбер юл шул кала аша узган. Бу кала-кирмәнне заманында нигездә күчмә халыкларны империя җирләренә уздырмас өчен Иран шаһиншаһы Хәсрәү күтәртә. Кала-калганың ныклыгы, мәһабәтлеге әле дә сокландыра. Кальганың бөек диварлары 40 километрга кадәр сузыла. Стенаның биеклеге, рельефка карап, 20 метрдан да артып киткән урыннары бар. Моның өстенә диварларга 30 саклану манарасы утыртылган. Өч капкасы тоташ тимердән тегелгән һәм суктырылган була. Көнчыгыш тарафындагы дивар-стена шактый тирәнгә диңгезгә кертеп салына.

Күрәсең, бу кальга-каланы алу төркиләргә җиңел булмагандыр. Ләкин төркиләргә монда әнә шул ирекле дигән төрки халыклары—хазарлар ярдәмгә киләләр. Менә кайчан дөнья халыкларына беренче тапкыр «хазар» атамасы килеп керә. Һуннар заманнарыннан ук далада, Каспий диңгезе буйларында көн күргән һәм беркемгә дә буйсынмаган, үзбаш яшәгән төрки халкы була хазарлар. Хазарлар килеп кушылуга, төркиләр союзы гаскәре Тимер Капка кирмәнен ала һәм Иран калаларының ныклы кирмәннәренең берсе булган Тифлискә кадәр барып җитәләр.

Тарихта бу хакта мондыйрак мәгълүмат бар. Төркиләр Тимер Капканы алгач, фарсылар арасында каушау башлана. Төркиләр чик буенда торган фарсылар гаскәрен тиз арада туздырып ташлыйлар. Исән калган фарсылар вассаллары булган гөрҗиләрнең Тифлис кирмәненә кереп бикләнәләр. Шуны да искәртеп үтик, бу вакытта, гадәттәгечә, Византия империясе белән Иран империясе арасында Алгы Азия җирләре өчен сугыш бара. Хәер, бу ике империя гасырлар буена ил-җир бүлешеп яши. Төркиләр Тифлис каласын камап ятканда, көтмәгәндә, алар кырына үз гаскәре белән Византия императоры Ираклий килеп туктый. Үзара сөйләшүләрдән соң алар берләшеп алалар—кальга-калага бергәләп һөҗүм итәләр. Әмма кальга диварлары гаять дәрәҗәдә биек һәм нык булу сәбәпле, калага үтеп керә алмыйлар. Бу хакта тарихчылар болай язып калдырганнар: «Ираклий үз кешеләрен кызганды, Кара Чурин үз кешеләрен» (Артамонов М. И. История хазар.—Л., 1954). Артамонов исә Кара Чуринны—Түр-яу-хан дип яза. Бу исә яубаш каганга аксакаллар табыны биргән титул гына. Иң гаҗәбе шул, Византия тарихына да ул шул исем белән кереп китә. Ә аның ярдәмчесе, ике туган энесен исә Бүрешад дип язалар, нигездә исә аның чын исеме Бурехан була. Тантаналы төстә гаскәрләрне берләштергәндә, император Ираклий әнә шул яшь баһадир Бүреханга үзенең кызы Евдокияне кияүгә бирергә вәгъдә итә. Шушы вакыйга уңаеннан Тифлис кальгасының стенасы буенда зур мәҗлес оештырыла. Император Ираклий булачак киявенә алтын-көмештән торган бөтен табак-савытларын бүләк итә.

Шул мәлдә олуг каганатта эчке чуалышлар башлануы хакында хәбәр килеп ирешә. Кара Чурин җансакчылары һәм бер өлеш гаскәре белән олуг каганлыкка ашыга. Император Ираклий исә, булачак кияве Бүреханны Тифлис кальгасы янында калдырып, үз гаскәре белән Иран империясенең эчке өлкәләренә юнәлә. Шул вакыт булачак кияү Бүрехан император Ираклийга үзенең иң елгыр мең атлы сугышчыларын биреп җибәрә.

Тарихта билгеле булганы шул, император Ираклий әнә шул кушылган гаскәр белән җиңүләр артыннан җиңүләргә ирешеп, фарсы шаһиншаһының башкаласына кадәр барып җитә, әмма тылга ерак керүен исенә төшереп, кире борыла. Мурад Аджи кебек тарихчылар Аурупа халкының нигезен төркиләр тәшкил итәләр, дип баралар. Бу сүзләрдә, бәхәссез, хаклык бар, чөнки Атилла хан чорында ук инде күп кенә төркиләр, греклар, итальяннар, французлар, испан-португаллар ягында сугышканнар, хәтта гот-немецләр белән бергәләп империягә яу йөргәннәр. Император Ираклийга Бүрехан биреп җибәргән мең атлы сугышчы исә төркиләрнең Ауропада калган бер тамчысы гынадыр.

Кара Чурин киткәндә камалышта торган фарсылар кирмән стенасы өстенә галәмәт зур кабак менгезеп утырталар һәм кабакка каганның йөз

сурәтен ясыйлар. Бу аларның шул рәвешле каганны мыскыл итүләре була. Бу хәлне каган онытмый. Яубаш буларак, ул ошбу тарафларга янә килә һәм фарсылар ничек кенә каршы торсалар да каланы ала һәм былтыр аның сурәтен ясатып, мыскыл иткән кала түрәләрен халык алдында сукрайтырга боера. Күп тә үтми яуланган һәм егылган кала кырына Византия императоры илчеләре килеп төшәләр. Алар кулында олау-олау байлыклар төялгән зур кәрван була һәм, әлбәттә, император кызы—булачак ханбикә Евдокия дә— алар арасында. Ләкин ни чара кылмак кирәк, батыр баһадир кальга-каланы алганда батырларча һәлак булган була. Император кызы Евдокиягә барлык байлыклары белән кире кайтып китәргә туры килә. Кызганыч ки, яшь йөрәкләр кавыша алмый калалар...

Шул хәлдән соң төркиләр дә биредә калмыйлар, меңнәрчә әсирләр, таланган маллар белән илләренә кайтып китәләр. Бу буладыр 630 елларда.

Ә менә төркиләр белән бергә ошбу тарафларга аркадаш йөзендә яу йөргән хазарлар яубашы Туранхан 651 елларда ук инде ил-халкын бер кул астына җыеп, ил-ватан төзи башлый. Туранхан үзенең Хазар каганатын 630 елларда Бөек Болгар дәүләтен төзегән Кубрат хан дәүләте өргә-нигезенә таянып оештыра. Дулу ыруыннан булган Кубрат хан үз дәүләтен Византия императоры ярдәме белән төзегән булса, Туранхан үз дәүләтен Кубрат хан дәүләте нигезенә утырта. Әнә шулай итеп, көнбатыш төркиләре оештырган дәүләт тулысы белән Ашин ыруыннан булган хазар төркиләренә күчә. Дон буйлары, Таман ярымутравы төбәкләре, Кырым даласы, Кара Болгар (бүгенге Киев төбәкләре) Идел буе Болгары тора-бара Хазар каганатына буйсынырга мәҗбүр булалар. Византия императоры гәрчә үз вакытында Кубрат ханның уллары белән дустанә яшәсә дә яңа аякланып киткән Хазар каганаты белән дә араны бозарга теләми. Дулу һәм Ашин ыруларын нәкъ менә Туранхан берләштерә башлый һәм шактый уңышларга ирешә. Заманында Кубрат ханның уллары бердәм булырга, бер халыктай тату яшәргә аталарына вәгъдә-иман иткән булсалар да, аталары үлгәч, угланнар арасыннан гүя кара мәче уза: баш углан Батбай Хазар каганына баш ия. Ханның икенче улы Кодрак өске Идел буйларына күчеп китә һәм үзенә бер ил оештыра. Өченче Аспарух угланы агасы Шамбат тарафына юнәлә. Ә Кубрат ханның энесе Шамбат бу вакытта Киев каласы төбәгендә хан сурәтендә утырган була һәм X гасырда Византиядә император булып утырган тарихчы Константин Багрянородный язуынча, бу хан Киев каласына нигез сала һәм император яшәгән чорларда бүгенге Киев каласын «Шамбат» каласы дип атый, Киев сүзен хәтта бер тапкыр да телгә алмый.

Хак, бу хәлдә икенче бер караш та бар. Чыгышы белән украин милләтеннән булган Англиядә яшәүче тарихчы «Киев» сүзенә карата үз сүзен әйтә. Бу исем Киев халкыннан ясак җыеп торучы Куя (Җыя) булырга тиеш, ди. Без янә «Повести временных лет» елъязмасына Әскәр каганнан башка аерым түрә булып тарихка кертелгән Дир сүзенә тап булдык. Дир ул бер дә шәхес булмаган, ул халыктан ясак җыючы, ягъни Җим җыючы, Әскәр (Аскольд) каганның кушаматы. Шамбат ханнан килгән нәсел чыбыгы. Бары тик.

Ни чара кылмак кирәк, төрки дөньясы булганга, Шамбат ханга да Туранхан белән тыныч яшәргә туры килә, ике арада сәүдә итү башлана. Шул рәвешле, әкрен генә, төрки болгарлары төзегән кала-илләр Хазар каганы кул астына керә баралар.

Аз гына кайта-чигенә төшсәк, Аурупа төбәкләрендә Хазар каганаты дәүләт оештырып ятканда, 662 елда Мөхәммәд пәйгамбәрнең тарафдарлары Әрмәнстанны яулыйлар. Мәдинә каласында тупләнеп калган гарәпләр яңа диннәрен—Исламны дөнья халыкларына чыгарырга керешәләр. Гарәпләр тарафыннан Ислам динен дөнья халыкларына тарату ике юл белән алып барыла: кәнфит һәм кылыч белән. Мөхәммәд пәйгамбәр вафат булгач, (632) гарәпләр Өммәйләр хәлифәтен төзиләр.

Нәкъ менә VII гасырда Хазар каганаты көчәя, чикләрен киңәйтә, сәүдә юлларын үз кулына ала. Хазарлар чорында Көнчыгыш Аурупада төркиләр— халык буларак беренче урында торалар һәм күпчелекне тәшкил итәләр. Әнә шул халык арасына Фәләстиннән Византия императоры куган яһүдләр әүвәл

Иранга барып оялаган булсалар, ахырдан аларны шаһиншаһ та кысрыклый башлый. Яһүдләрнең шома сәүдәгәрләре диннәргә, гомумән, битараф булган Хазарстан каганатына җыела башлыйлар. Һәм биредә ныклы җирлек табалар. Күп кенә сәүдә юлларын үз кулларында тоткан яһүдләр—коллар сатуда Ауроазиядә беренче урында торган халык. Римдә алар сенатка үтеп керергә тырышалар, әмма барып чыкмый, римләннәр яһүдләрнең диннәрен генә түгел, үзләрен дә кысрыклый башлыйлар. Яһүдләр төркем-төркем булып кабат Иранга юнәләләр. Монда алар шаһиншаһ сараена чибәр кызлар китерәләр, шул ук вакытта үзләренең диннәрен тарата башлыйлар. Шаһиншаһка бу ошамый һәм ул аларны эзәрлекләргә керешә. Әнә шулай яһүдләр төркиләр арасына сыена. Бу чорда каган бихисап күп хатын тота, аңа һәр көн диярлек кызлар китереп торалар. Һәм моны яһүд сәүдәгәрләре үз өсләренә алалар. Яһүдләр үз кызларын бай төрки гаскәрбашларга, әмирләргә, тарханнарга кияүгә бирәләр, ә ул хатыннардан туган балаларны сарай каршындагы синогогларда яһүдләр динендә тәрбиялиләр. Ә яһүдләрнең нәсел тамыры анадан килә. Һәм бу тәртип-кагыйдә яһүдләрдә әле дә булса саклана. Торабара Хазар каганы сарае куштаннары да яһүдәләр динен кабул итәләр. Ә ул балалар исә бары тик яһүдләргә генә кияүгә чыгалар, яһүдләргә генә өйләнәләр. Бу халыкның күбесе бары тик сәүдә эше белән генә шөгыльләнгән. Әнә шул сарай куштаннарын көтү көткән, бакчаларда бил бөккән, елгакүлләрдә балык тоткан төрки халыклары кара имгәкләр дип атаганнар. Шул исем белән бу халык аерым бер милләт—караимнар булып тарихка да кереп кала. Гәрчә төрки телдә сөйләшсәләр дә, алар инде төрки дөньясыннан читләшкән булалар. Шуңа карамастан, караимнар безнең канкардәшләребез һәм туганнарыбыздыр.


*Кырымдагы хазар кирмәне хәрабәләре. VIII—X гасыр*

Ни генә булмасын, VIII гасырда инде Хазар каганаты Көнчыгыш Ауропада чәчәк аткан иң зур илләрнең берсенә әверелә.

Ләкин әнә шул илгә дә көндәшләр табыла. Ул да булса, Өммәйләр хәлифәте. 710 елда илләрне яулый-яулый, халыкларны буйсындыра-буйсындыра гарәпләр Тимер Капкага хәтле килеп җитәләр. Башлана хазарлар белән канлы сугыш. Кальга-нгытма кала берничә тапкыр кулдан-кулга күчә, ике як та бихисап югалтуларга дучар итела. Ниһаять, 735 елда гарәпләр Хазар каганатын җиңүгә ирешәләр.

750 елларда Өммиләр династиясен Габбасилар алыштыралар. Габбасилар башкалалары итеп Багдад шәһәрен сайлыйлар. Габбасилар ил башына киләкилүгә, Хазар каганаты йөзендә көчле дошман күреп, бигрәк тә биредә «Иудаизм» диненең таралуын искә алып, хәлиф Мансур (754—775) Кавказ тарафындагы гарәп сәүдәгәре Гаязетдингә каган Багатурның кызын үзенә кәләшкә сорарга куша. Хәлиф үзе үк бу хакта сорап каганга илчеләрен җибәрә. Каган кызын бирергә риза була, әмма хәлифтән берничә 100 мең дирһәм сорый. Хәлиф бирнә бәясе белән килешә. Әнә шулай ике арада яучы-димчеләр йөреп туктаганнан соң, каган гүзәл кызын хәлиф иленә юллый. Иң гаҗәбе шулдыр, гүзәл кәләшне 10 мең дәрәҗәле гаилә башлыклары озата баралар. Шул ук вакытта бирнә йөзендә кыз ягыннан 4000 бия, меңнән артык елгыр айгыр, 10 меңлек дөя һәм 10 меңлек куй көтүен куып китерәләр, кызны карарга бер мең карачы килә. Моның өстенә кыегы көмеш тәңкәләр белән кадакланган ябулы һәм сиртмәле 10 мең җиңел арба. Арбаларның эчләре

парчалы чүпрәк һәм кеш тиреләре белән җиһазландырылган була, яшь кәләш өчен 20 арбага кирәк-яраклар—алтын-көмеш савыт-сабалар, чиләк-комганнар һәм башка җиһазлар төялә.

Бу олы кәрванны башта калага кертмиләр. Мөселман миссионерлары иң элгәре кәләшне мөслимә итәргә тиеш булалар. Шуңа күрә озатучы карачылар кала кырында чатыр корырга мәҗбүр булалар. Һәм шунда гарәп имамнары кәләшне мөслимә итәләр. Шуннан соң гына кәләшне озатучы кәрван калага керергә хокук ала. Бу кадәр зурдан кубып зурлауга Ходай үзе каршы килгәндерме, каган кызы дүрт ел бергә яшәгәннән соң ир-канатына ике углан бала таба һәм көннәрдән бер көнне ул ике баласы белән бергә якты дөньядан китә. Хазар каганы кызы һәм оныклары белән булган фаҗигадә гарәпләрне гаепли һәм гаскәр туплап, 762 елда кияү тарафына таба яуга кузгала. Беренче орышта ук хазарлар сәрдар Муса Ибн Кәабенең гаскәрен җиңүгә ирешәләр һәм 50 мең гарәплене әсир итеп илләренә кайталар.


764 елда каганның гаскәрбашы Астархан янә кайчандыр гарәпләр яулаган җирләрне кире кайтару өчен—Әрмәнстан белән Гөрҗистан җирләренә яуга кузгалалар. Тиз арада биредәге хәлиф горнизонын туздыралар, үтә диндар гарәпләрне илләренә куып җибәрәләр. Ләкин хазарлар бу җирләрдән китүгә, әрсезләнеп киткән гарәпләр янә бу илләрне яулыйлар. 798 елның азакларында хазарлар янә ошбу илләргә яу йөриләр һәм янәдән бирегә килеп оялаган гарәпләрне илләренә качарга мәҗбүр итәләр. Шушы яулар ук әйтеп тора, VIII гасырда да Хазар каганаты үз көчендә була.

Бу чорда Хазар каганаты Ауропада мажарлар дәүләтен оештыруда да зур роль уйный. Борынгы мажарлар Урал таулары төбәкләрендә көн күргән төркиләр белән гасырлар буена күрше-шабра булып яшиләр, бу ике халык арасында кушылу-аралашу Атилла хан заманнарында ук башланган була. VIII гасырда бөҗәнәк (Россия тарихчылары бу халыкны «печенег»лар дип язалар) төркиләре мажарларны илләреннән куалар. Хазар каганаты аларга, ягъни мажарларга Днепр белән Дунай елгалары арасыннан ил-җир бирә. Бу төбәкне Атылкүз дип атыйлар. Мажарларның нәсел-нәсәбәсен саклап калу максаты белән аларга Идел буе Болгары Алмас ханның улы Арпадны илбаш итеп җибәрәләр. Арпад җитәкчелегендә мажарлар Дунай-Тисса елгалары арасында үзләренә ил-дәүләт оештыралар, соңра бу дәүләтне бүгенге венгрлар дәвам итәләр. Ошбу дәүләттәге Арпад углан белән килгән болгар төркиләре XVI гасырга кадәр рунида язалар һәм белем алалар.

Хазар каганаты Киев Русе дәүләтен аякландырып җибәрүгә дә күп көч сала. Мәгълүм ки, каганат дәвамлы рәвештә Скандинавия халыклары белән сәүдә итә. «Урыс» атын йөрткән әлеге варяглар, безнең телгә тәрҗемә иткәндә—«ишкәкчеләр» булалар. Әнә шул ишкәкчеләр Идел буе Болгары, Хазар каганаты белән тыгыз элемтәдә торганнар. Хактыр ки, Русия тарихчылары язганча, варяглар арасында «Вещий Олег» җитәкчелегендәге башкисәр юлбасарлар да булган. Әнә шул Хельг-Олег кенәз алдау-йолдау белән 882 елда болгар төркиләре Кара Болгар дип йөрткән дәүләтне кулга төшерә. Хазар каганы Кара Болгарга ярдәмгә килә алмый, гарәпләр белән сугышкан чагы була. «Вещий Олег», Атилла ханнан килгән Дулулар нәселен корыту өчен, Аскольд каганны үтереп, үзен тәхеткә күтәрә (Кара Болгар төркиләре үзләренең каганнарын Әскәр дип йөрткәннәр, шул ук вакытта аның «Җимҗыяр» дигән кушаматы да булган). Кабат әйтәм, Русия тарихчылары бу кешене «ике» итәләр, кушаматын да аерым шәхес итеп, елъязмаларына кертеп җибәрәләр. Шунсын да белеп торыйк: Варяг кенәзе Олегның мәкерле гамәленә Хазар каганы соңрак нокта куячак һәм узурпатор кенәзне Киевтән кудыртачак.)

Галим Гамир Дәүләтшин үзенең шактый саллы хезмәтендә—«Төрки-татар рухи мәдәнияты тарихы» китабында *(Казан, 1999)*: «Кемнәр соң алар хәзәрләр, каян килеп чыкканнар, бабалары кемнәр?—дигән сорауны куя да үзе үк болай дип җавап та бирә:—X гасыр испан яһүде Хасдай Ибн Шафрут хатына җавабында хәзәрләр патшасы Иосиф Яфәт улы Тогарманның (Төрекнең) Савир, Болгар белән бергә Хәзәрне 10 улының берсе итеп күрсәтә. Бу легендар хәбәр булса да, хәзәрләрнең төркилеге һәм аларның болгар,

суарлар белән кардәшлеге фәнни нәтиҗәләргә дә туры килә. Аларның Көнчыгыш Ауропага килеп чыгышлары Һуннар һәм Төрки каганлыклар халкы белән бәйле булуы һич кенә дә шик тудырмый» *(ассызык минеке.—Х.М.; Гамирҗан Дәүләтшин. Төрки-Татар рухи мәдәнияты тарихы.—Казан, 1999).* Хак әйтә Гамирҗан Дәүләтшин, Хазар аксөякләрен «тархан» дип йөрткәннәр, алар арасында югары дәрәҗәдәге «ишханнар»да булганнар. Хазар каганатына Төньяк Кавказ, көньяк Урал, Көнчыгыш Кырым киңлекләре, Идел, Дон, Азов җирләре кергәннәр. Хазар иленең борынгы башкаласы—Итил, Әтил. Бу кала Идел елгасы тамагы буйлап бишалты километрга кадәр сузылган була. Ягъни аны Ауропаны Азия белән тоташтыручы сәүдә юлында урнашкан дип әйтергә мөмкин. Саркель каласында исә нигездә болгар-аланнар яшәгәннәр, Русия тарихчылары раславынча, бер дә славяннар түгел. Сарыкала, яки Аккала аша каганат сәүдәгәрләре Ауропага йөргәннәр.



*Борынгы агач арба*

Тарихта мәгълүм булганы янә шул: Хазар каганлыгында VII—VIII гасырларда диннәргә карата талымсызлык булган. Каганат калаларында мәчетләр белән рәттән чиркәүләр, синогоглар да төзелгән. Ләкин нәкъ менә бүген Русиядә христиан дине өстенлек иткән кебек, Хазарстанда да иудаизм дине күтәрелеп китә, дөресрәге, бу динне баштарак Каган сарае куштаннары кабул итәләр, соңра каганнар да аларга ияраләр. Яһүдиләр динен кабул итүче каган Булан (Болан) була. Нәкъ шул каган тәхеттә утырганда, Хазарстанга Иран һәм Византия тарафларыннан дәрәҗәле вә исемле раввалар күчеп килә башлыйлар. Ил башына раввалар ярдәме белән яһүдә хатыннан туган Булан каган менә, атасы төрки булгангамы, хазарлар моңа әлләни игътибар итмиләр. Күчеп килгән яһүдләр җирле төркиләр белән тату яшиләр. Сәүдәгә хирыс яһүдләр сәүдә юлларын үз кулларына алалар. Бу калаларда байлык, муллык, һәрчак җитешлелек була. Тора-бара яһүд сәүдәгәрләре Хазар каганаты өчен төп акча чыганагына әвереләләр, чөнки каганат булса да Хазарстанда акча сугылмый, йөрештә буладыр—дирһәм. VIII гасыр азакларында Габбасилар династиясе түбәнгә таба тәгәри башлый. Тулысы белән гарәпләр кулына төшкән фарсылар төшенкелеккә биреләләр, утка табынучылар сирәгәя, Ефәк юлы әкренләп Хазарстан сәүдәгәрләренә күчә, яһүд сәүдәгәрләре Ауропа һәм Азия халыкларын бәйләүчеләр булып китәләр. Нигездә Саркель каласы да шул ният белән Византия осталары тарафыннан күтәртелгән була. Кирмән кала дүрт почмаклап салына. Әмма Византия императоры Феофил киңәше белән осталар кала-кирмәнне бик начар сыйфатлы итеп төзиләр. Дүрт метр калынлыктагы диварның нигезе бөтенләй булмый диярлек. Русия тарихчылары бу каланы үз тарихларында Белая Вежа дип кертәләр.

Бу чорның иң кыйммәтле тауары ефәк санала. Яһүд сәүдәгәрләре алып кайткан Кытай ефәген византиялеләр алтынга сатып алалар. Күп кенә тарихчылар Төрки ханнары күчмә булганнар, дип язалар. Ләкин болгар ханнары борын-борын заманнардан бирле калаларда яшәгәннәр һәм көн күргәннәр; болгар төркиләрен күчмә итеп күрергә теләгән Русия тарихчылары, «нигәдер» бүгенге көнгә кадәр болгар төркиләрен кыпчаклар белән саташтыралар, хәтта үзебезнең кайбер тарихчыларыбыз да төрки-болгарларны җәйләрен дала-болыннарга чыгып җәйләгәннәр дип язарга кыялар, вәләкин бу аларның җәйге манзараларга чыгулары гына булса да, нигездә болар кыпчак-башкортларга, кыргызларга һәм башка күчмә төркиләргә кагыла. Русиянең барлык Көнчыгыш Ауропадагы калаларына диярлек болгарлар һәм хазарлар нигез салганнар, моны тарихи язмалар аша да расларга мөмкин.

Әмма кайда гына көн күрмәсеннәр, борынгы төркиләр һәммәсе дә мөселман динен кабул иткәнче 6 мең еллар буена Тәңре диненә табынганнар. Тәңре ул—бер Аллалык, бер Аллаһка табыну. Мөселманнар да бер Аллаһка йөз тоталар. Димәк, хәтта бу яктан килгәндә дә бу ике дин арасында якынлык, бердәмлек бар. Шуңа күрә төрки халыкларның аксөякләре Ислам динен кабул итүдән әлләни зур зыян күрмәгәннәр, ислам динен шактый җиңел кабул иткәннәр. Шул исәптән бер Аллалыкка йөз тоткан яһүдләрдән дә йөз чөермәгәннәр. Моның өстенә яһүд сәүдәгәрләре илне баетканнар—базаркалалар көнчыгыштан һәм көнбатыштан китергән тауарлар белән тулы булган. Яһүдләрнең бай сәүдәгәрләре төрки ханнарына вә тарханнарына затлы әйберләр бүләк иткәннәр, ә ханнар аларга илнең сәүдә эшен генә түгел, дипломатик сөйләшүләрне алып баруны да ышанып тапшырганнар. Яһүдләр ханнар кушкан йөкләмәләрне җиренә җиткереп башкарганнар, уңганлыкларын күрсәткәннәр. Әнә шул чорларда төрки халыкларының күбесе, бигрәк тә түрәләр, яһүд кызларына өйләнгәннәр. Сарай куштаннары турында әйтеп тә торасы юк—һәр икенче кеше яһүдәгә өйләнгән. Ә яһүдәләрдән туган балаларның күбесе батыр төрки сугышчылары белән бергә яу йөргәннәр, күбесе түмәнбашлар булып киткәннәр.

Шуңа карамастан, Хазарстан яһүдләрен һәм Булан каганны израилтәннәр үзләренеке итеп танымаганнар. Ярымяһүд, ярымтөрки телдә сөйләшкән катнаш никахтан туган балаларны Кырым тарафларына куалар. (Караимнар дигән халык бүген дә шул тарафларда көн күрә һәм бу халык төркиләрнең канкардәшләре.)

802 елда патрикий Никифор Византия империясе тәхетенә утыра.

Шул ук 802 елда гарәпле хәлиф Харун ар-Рәшид үзенең иң якын ишләрен—бармәкадләрне җәзалый.

803 елда Хазар каганаты тәхетенә көтмәгәндә яһүд Обәдәй утыра. Ул яһүд әтисе ягыннан төрки була, әмма яһүд раввper раввaларыннан белем ала. Нәкъ шул яһүд динен дәүләт дине итүгә ирешә.

Тарихчыларга ышансак, Обәдәй каган зыялы кеше була, иң мөһиме, яһүд сәүдәгәрләре белән тыгыз элемтәдә тора. Бер тарихчы каган Обәдәй турында болайрак яза: «Ул гадел хаким, тугры кеше. Ул илне ныгытты, мәктәпләр ачты, синоголар күтәрде һәм Израилдән бик күп мөгаллим—раввалар китертте һәм аларга алтын-көмеш түләп, изге хезмәтләрен бәяләде. Аңа раввалар аңлаттылар: 24 изге Мишнә, Талмуд китаплары турында аңлаттылар, гыйбадәт кылу тәртипләрен өйрәттеләр. Обәдәй каган Алладан курыкты, канунnарны саклады һәм борынгылардан килгән ата-бабаларның васыятьләрен үрнәк итеп алды» *(Коковцев П. К. Еврейско-хазарская переписка—Х век.—Л., 1932).*

Хазарстан хакимияте алышудан иң әүвәл яһүдләр оталар. Шушы ук вакытта Ашин ыруыннан килгән төркиләргә зыян да китермиләр, чөнки төркиләр диннәргә карата тыенкы караштa торганнар.

Ә раввaларга йөзе белән борылган Обәдәй бар яктан да ота. Ул үзен бәк дип тә, малик дип тә, каган дип тә атый. Каган Обәдәй катнаш гаиләләрдән килгән яһүдләрне генә үз сараена хезмәткә алып калмый, бәлки Ашин ыруыннан чыккан төрки кардәшләрен дә онытмый, аларга да үсәргә мөмкинлек бирә. Күп хатыннар тоткан төрки ханнар гына түгел, гади меңбашлар, йөзбашлар да бай яһүдләрнең кызларына өйләнә башлыйлар. Алардан туган балалар төрки телдә сөйләшсәләр дә раввалар җәмәгатьчелегендә булырга тиеш саналганнар. Әнә шул балалар үсмер чактан ук раввалар җыйган җыеннарга йөриләр, Тора, Талмуд китапларыннан белем алалар, үз чиратларында, бай яһүд сәүдәгәрләренең кызларына өйләнәләр. Төркиләрнең моңа бер дә исләре китми, мул тормыш, тыныч яшәү, белем алу үз чарасын кыла. Ләкин төркиләрнең иске вә борынгы династияләре дә Хазарстанда көн күрә бит әле. Ошбу халык моңа кадәр барысына да күз йомып килсә дә, IX гасырда уянып киткәндәй итә. Төрки бәкләре вә тарханнары сарай куштаннарыннан, гомумән, каганның үзеннән дә читләшә башлыйлар. Әнә шулай итеп, IX гасыр башларында ук инде Хазарстанда төрки-хазар һәм

яһүд-хазар династияләре, хәтта фиркагә оеша башлаган төркемнәр барлыкка килә. Бер-берсенә капма-каршы сәясәттә булган фиркаләрнең яшәеш рәвешләре дә бер булмый, кызыксынучан чаралары да. Төркиләр хазарларны балалар белән куандырсалар, яһүдләр ул балаларны тулы канлы яһүдләр итеп тәрбияләүләре белән кинәнәләр. Шул ук вакытта яһүд раввалары Хазарстанның барча халыкларын да яһүди дингә тартырга теләмиләр, гомумән, максатлары ул булмый: аларның бөтен теләге, Аллаһ сайлаган халыклар буларак, яһүдләрне дәүләт өскормасының элитасы итүдән гыйбарәт була. Ләкин төрки халыклар да дөнья арбасыннан төшеп калганнардан түгел шул, алар бу хәлгә канәгатьсезлек тудыралар; төркиләр ягына мәҗүси маҗарлар авышалар; ә төрки бөҗәнәкләр яһүдләрне якларга ук керешәләр. Илдә җәнҗал чыгу куркынычы туа. Каган ике якны да тыюдан тәмам гаҗиз кала. Ләкин теге якны да, бу якны да яклый алмый. Әнә шулай илдә гражданнар сугышы башлана. Бу сугыш хакында X гасырда Византия тәхетендә утырган тарихчы Константин Багрянородный мондый юллар язып калдыра: «Хакимият халыктан аерыла башлагач, хазарлар үзара сугыша башладылар. Үзара сугышта хакимият өстен чыкты. Баш күтәрүче гади халык кылычтан уздырылды, ә беришләре маҗарлар иленә качтылар» *(Багрянородный К. Об управлении государством.—М.—Л., 1934).*

Нинди яулар вә сугышлар гына булмасын, нигездә хазар яһүдләре үзләре корал тотып сугышмаганнар, үз мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру өчен гадәттә, сугышчыларны яллаганнар. Башта алар, ягъни IX гасыр азакларында бөҗәнәкләрне маҗарларга яу җибәрәләр, шул ук вакытта күршеләре угызлар белән солых төзиләр. Әмма тарих тәгәрмәче үзенчә әйләнә тора: 889 елда угызлар бөҗәнәкләрне Днепрга кадәр куа киләләр, шул ук вакытта Хазар каганы акчасына маҗарлар белән дә сугышны дәвам итәләр. Әнә шунда беренче тапкыр Киев Русе чикләрендә бөҗәнәкләр күренәләр дә инде. Һәм буладыр бу 915 елда.

Әмма угызлар хазарлар белән элемтәне бик тиз өзәләр. Шул сәбәпле Хазарстан каганына яңа сатлык сугышчылар эзләргә туры килә. Яһүд дипломатлары аңарга Каспий диңгезе буйларында көн күргән һәм инде ислам динен кабул иткән мөселманнарны тәкъдим итәләр. Каган яһүд киңәшчеләре белән килешә. Яһүд сәүдәгәрләре тиз арада төрки-мөселманнарыннан торган 7 мең атлы сугышчы яллыйлар. Бу хакта гарәп тарихчысы Әл-Масуди дә искәртеп үтә. Мәгәр бу мәлдә Хазар каганаты илләр яулаудан һәм аларны канат астында тотудан баш тарткан була инде, ялланган сугышчылар, нигездә, сәүдә юлларын кулда тотарга һәм каганның тынычлыгын сакларга тиеш булалар. Җиде мең атлы сугышчы белән генә илдә тәртип саклап булмаячагын каган яхшы белгән, әлбәттә. Ләкин аңа өстәмә сугышчылар сатып алу мөмкин булмый башлаган. Чагыштыру өчен генә әйтеп үтик, бу вакытта Багдад хәлифе кул астында 70 мең сатлык сугышчы хезмәт иткән һәм хәлиф аларга елына 2 миллион дирһәм түләп торырга мәҗбүр булган.

Акчасы чамалы булса да, гаскәр саны хәлифәнекеннән күп тапкырга аз булса да, Хазар каганы сатлык сугышчыларга бик тә каты шарт куйган: орышларда җиңелү, орыш кырын ташлап качу булмаска тиеш; гаскәрбаш әмерен үтәмәгән һәм сугыш кырын ташлап качкан сугышчы үлем җәзасына тартылачак. Әмма һаман да бер тәкә башы, дигәндәй, каган яһүдләргә, ягъни яһүдләрдән вә яһүдәләрдән туган бәкләргә, мең баш һәм йөзбашларга нindидер күләмдә өстенлек биргән. Әйтик, аларга сугыш кырын ташлап качкан хәлдә дә үлем җәзасы бирелмәгән.

Шуңа да карамастан, X гасырда Хазар каганаты көчле дәүләт була әле. Идел-Урал, Дон елгаларының түбән якларын үз кул астында тоткан Хазар каганатында зур-зур калалар, сәүдә үзәкләре калкып чыккан. Илдән-илгә генә түгел, каладан-калага да бертуктаусыз сәүдәгәрләрнең кәрваннары йөреп торган. Шәһәрләр үскән. Каганат башкаласы үзе генә дә бу чорда тиңе булмаган мәйданны биләгән. Әмма ни хикмәт, Хазар каганаты илендә дөнья халыкларына чыгарып сатардай җүнле бер генә тауар да җитештерелмәгән. Бу хакта Ибн-Хәүкәл болай ди: «Хазарлар бернәрсә дә җитештермиләр,

бернинди тауар да читкә чыгармыйлар, бар булган тауарлары—балык җилеме».

Баштагы мәлдә яһүд сәүдәгәрләре ил-дөнья халыкларына коллар саткан булсалар, X гасырда инде бу оятсыз шөгыль белән мөселман сәүдәгәрләре эш итәләр. Мөселман сәүдәгәрләре кыйммәт бәягә бөҗәнәк, славян егетләрен җирле түрәләрдән сатып алалар, ә яһүд сәүдәгәрләре алар өчен арадашчылар булалар. Ни генә булмасын, X гасырда Хазар каганаты өстенлеген югалта барып, вассал йөзендә аңа кергән Кара Болгар—Киев Русе дә, Идел буе Болгары да, Таман ярымутравында көн күргән төрки болгарлары да каганга буйсынмый башлыйлар.

Каганның кала-сараен, нигездә, мөселман азатлары саклаган. Төп сарайны исә 4 мең кеше караган. Күренекле татар галиме нумизмат Әзһәр Мөхәммәдиев раславынча, гарәп сәрдаре каганны җиңгәннән соң, җиңелгән каган 737 елда ислам динен кабул итә, гарәп шрифте белән суктырылган дирһәмнәр йөрешкә керә. Хазар каганы ислам динен кабул иткәннән соң, каган сараена кереп оялаган яһүдләр арасында бер мәлгә югалып калу сизелә. Игътибар итик, башта яһүдләр Хазарстанны тулы канлы империя иткән булсалар, каган ислам динен кабул иткәч, каганлыкны бердәм таркатырга керешәләр. Бай яһүд сәүдәгәрләре һәм дипломатлары каганга каршы мажарларны, бөҗәнәкләрне, ахыр килеп, урыс кенәзләрен котырталар. Урыс кенәзләре Хазар каганы калаларына 864, 884, 908, 910, 913, 943 елларда талауларга йөриләр. 964 елда исә Святослав кенәз Саркель каласына кадәр килеп җитә. Орыша, әмма каланы ала алмый, буш кулы белән кайтып китә.

Хазар каганатының тарихта тоткан урынын кимсетеп күрсәтү өчен Россия галиме Б. А. Рыбаков хазарларны гади күчмә төрки халыклары итеп күрә һәм шул хакта хезмәт яза. Алай гына түгел, хәтта Хазарстанның җирләрен Калмык далаларына «китереп урнаштыра». Панславанизм томанынннан соңгы көннәренә кадәр арына алмаган галим хазарларны күчмә халыклар дип расларга тырышуы белән бергә, аларның, гомумән, урта гасыр тарихында урын алырга хаклары юк дип язарга кыя.

Дөнья тарихчылары (шул исәптән, тарихи әсәрләр язучы буларак, без бахырыгыз да), Хазар каганатын Кубрат хан төзегән Бөек Болгар дәүләтенең дәвамы итеп таныйлар. Һәм тарихта ул шулай була да, гәрчә бертуган канкардәшләр еш кына теге яки бу империяләрнең түрәләре котыртуы буенча үзара сугышкаласалар да.

Хазар каганаты таркалганнан соң, Көнчыгыш Ауропа халыклары ике зур фиркагә аерылалар. Беренчеләре, Ислам дине аша дөньяга чыксалар, икенчеләре, христиан дине аша дөнья тарихына керәләр. Яһүдләр исә, һәр чордагы кебек, ике арада тулганалар. «Сезнең дошманнарыгызның дошманнары—безнең дуслар»,—дигән фәлсәфәгә таянып корылган Хазар каганаты әнә шулай әкрен генә дөнья арбасыннан төшеп кала башлый, ел аралаш диярлек була Исмәндәр, Биләмҗир (искәреп үтим, Биләмҗир каласы төрки болгарлары күтәргән һәм колонияләре сурәтендә кулларында тоткан кала була), Сары кала (Саркель), Сүр, Саугар, Байда калаларын югалта. Ләкин хазарларның башкаласы (төрки халыклары бу башкаланы Ханбалык дип йөриләр) Атил-Итил әле каган кулында. Каган сарае, кальга йөзендә, Ал-Байда, ягъни Ак кала дип атала. Калада күп санлы мунчалар, базарлар, мәчет, чиркәү, синагоглар һәм мәдрәсәләр була. Әнә шул куәтле каганат җимерелүгә таба юл ала.

Ә тарих дәвам итә.

871 елда ук инде король Людвик II Византия императоры Василий Македонянга болай дип яза: «Безнең өчен куркыныч булган дүрт каганат калды—Аварлар каганаты, Норманнар каганаты, Хазарлар каганаты, Болгарлар каганаты» *(Артомонов М. И. История Хазар.—Л., 1954).*

Мәгълүм ки, яһүдләр Хазарстанда 200 елга якын гомер итәләр. Алар инде Византиядә һәм Иранда булган хәлләрне онытканнар—гади халык, ләкин раввалар түгел. Рим белән Византиядә яшәгәндә, алар сарай тирәсендәге түрәлеккә төрле мәкерлекләр, хәтта кан коюлар аша үрләгән булсалар, Иранда шул юлны дәвам итеп фаҗигага дучар ителсәләр—шаһиншаһ аларны көчләп

илдән куа—Хазарстанга күчеп килгәч, яһүд раввалары тәүге хаталарын кабатламаска тырышалар, сарай тирәсенә кереп оялагач, яһүд раввалары бөтенләй башка юлны сайлыйлар һәм, әйтергә кирәк, уңалар. Катнаш никахлар аша тәхеткә үрләү Хазарстанда яһүд равваларының төп максатла-рына әверелә, аларның бу сәясәте Хазарстан төркиләре арасында тирән тамыр җибәрә.

Тарихчылар әйткәнчә, Хазарстан калалары бакчаларга күмелгән булалар. Халык мул яши. Сәүдә чәчәк ата. Төп халык мал асраса да, күп кенә кешеләр ашлык үстерәләр, елгалардан балык тоталар һәм отышлы гына сәүдә итәләр. Идел һәм Кама буйлап, хәтта Агыйдел буйларыннан башкалага кыйммәтле вә затлы итеп эшкәртелгән тиреләр, бал килә. Дала халкы бу тауарларны югары бәягә сатып алган. Хазарстан башкаласы Итилгә Каспий диңгезе аша Хәрәземнән ефәк, парчалы ситсалар килеп тора. Сәүдәгәрдән тауарын сату өчен бары тик 10 процент керем җыела. Хазарстан каганатының ил чикләре елдан-ел киңәя, бер чиге Тимер Капка (Дербент) белән чикләнсә, икенче чиге бүгенге Удмурт республикасына кадәр сузыла. Көнбатышта исә каганат чиге Днепрга кадәр җитә. Бу хактыр, гәрчә Русия тарихчылары Киев Русе Хазарстанны IX гасырда ук буйсындырды дип язсалар да, елъязмалары белән моны үзләре үк инкарь итәләр. Елъязмада мондый юллар бар: «... хазары имаху на полянах и на северах, и на вятичах, и махупо белку и выверице от дыма». Бу буладыр 858 елда. 862 елда Киевкә хазар ясак җыючылары киләләр, елъязмачы бу хакта да искәртеп үтә: «И мы сидим род их платим дань хозарам».

Моннан соң мин берни өсти алмыйм.

Киев Русенең Хазарстан каганына буйсынып, аңа дань-ясак түләп яшәве хакында янә бер рәсми документ сакланып калган. Бүген ул документ Американың Кембридж югары уку йортында саклана. Тарихчылар раславынча, документ X гасырда язылa. X гасыр башында тәхеттәге ярымяһүд Булан (Болан) каганны тулы канлы яһүд Обәдәй (Үбәдәй) алыштыра. Ахырда илбашына яһүдләр җәмәгатьчелегеннән Йосыф килә. Нәкъ менә шул каган Испаниядә утырган көртләр хәлифе Габдрахман III сараенда хезмәттә булган Хасдай Ибн-Шафрут сәүдәгәр-илче Исаак бен-Натан аша Йосыф каганга хат юллый. Һәм Хазарстан ил башыннан илдә булган хәлләр турында язуын үтенә. Йосыф каган кардәше Хасдайның үтенечен карусыз үти һәм бер тапкыр гына түгел.

Бу документтагы юллар безнең бабаларыбыз төркиләргә дә кагылганга күрә, Йосыф хатларындагы кайбер юлларны-өзекләрне китереп үтү мәслихәт булыр: «... буртас, болгар, арис, чирмеш, венед, сувар, славян һ. б.—алар барысы да далаларда, ныгытылган калаларда яшиләр һәм барысы да миңа салым түлиләр»,—дип яза Йосыф каган. Шул ук вакытта Йосыф үзен Багдад хәлифнең варисы-вассалы булуын да искәртеп үтә: «Мин елга тамагын саклыйм һәм урысларны түбәнгә таба уздырмыйм. Алар елга аша диңгезгә чыгарга телиләр. Мин аларны җибәрмим, алар белән сугышам. Мин аларны тынычлыкта калдырсам, алар Багдадның үзенә кадәр барып җитәрләр һәм бөтен мөселман дөньясын җимергән булырлар иде» *(Коковцев П. К. Еврейско-хазарская переписка X в.—Л., 1932).*

Канкардәше Хасдайга шулай дип мактанса да, ил башында утырган Йосыф каганның хәле хәтта язганча бер дә ал да, гөл булмый шул. Каганат башында утырган яһүдләргә, коллар сатып, гомумән, сату итеп кенә баеган яһүд сәүдәгәрләренә каршы далаларда мал асрап, бакчаларда бил бөгеп, басуларда йөзем-җимеш үстергән, тез тиңентен сулы ләмдә йөреп дөге җитештергән, елгаларда балык тоткан җирле халыклар баш күтәрәләр. Моңа кадәр акчадан башканы кулына да тотып карамаган яһүд аксөякләре корал тотып сарай мәнфәгатьләрен якларга мәҗбүр ителәләр. Ләкин рухи дарылары озакка бармый, сарайны һәм каганның тынычлыгын саклаган мөселман атлы сугышчылары да куштаннарын ташлап китәләр. Каганатның гаскәрсез калуын күреп, куптәннән каганат кул астыннан чыгарга атлыгып торган Идел буе Болгар ханы канкардәше угыз ханы белән элемтәгә керә һәм аны каганат өстенә яу йөрергә чакыра. Дөрес, тарихта Идел буе болгарларының Хазар каганаты җирләренә яу йөрүләре күрсәтелми, ләкин каганатны җимерүдә Идел буе Болгар дәүләте төп идеологик рольне уйный (һәм бу бер минем

фикер генә түгел). Кучмә угызлар Хазарстанның бай калаларын туздыралар, Дон далаларына кадәр барып җитәләр, Днепрга якынлашалар. Һәм шунда аларны Киев сәүдәгәрләре күрәләр, чөнки Сары каланы угызларның җимерүләрен үз күзләре белән күргән булалар. Әйтергә кирәк, «Повести временных лет» елъязмасында бу хакта мондый юллар бар: «... и встретил вятичей, и сказал вятичам: «Кому дань даете?» Они же ответили: «Хазарам— по шелягу с сохи даем». Ягъни Святослав кенәз хазарлар тарафыннан куыла. 965 елда исә каганның горнизоны Итилне угызлардан сакларга киткәч, Святослав кенәз ашыгыч рәвештә Сары калага, ягъни Саркельга юнәлә һәм вятичләргә ясак сала. Бу вакытта угызлар Днепрга җитеп кенә калмыйлар, елганың аръягында хәтфәдәй болыннарны күреп, елганы кичәләр һәм анда көн күргән маҗарларны утырган урыннарыннан кузгаталар. Ул гынамы, маҗарларның ирләре яуга китүдән файдаланып, аларның хатын-кызларын һәм бала-чагаларын кулга төшереп, Атылкүз дип аталган илнең хуҗалары булып китәләр. Күп тә үтми маҗарлар яудан әйләнеп кайталар, әмма ил-ватаннарының көчле дошман кулында булуын аңлап, Карпат тауларына таба юнәләләр, тауларны узалар, Дунай буендагы Панонния төбәкләренә барып чыгалар һәм андагы Моравия патшалыгын туздыралар, нәкъ угызларча ир-аттан калган морава хатын-кызларына өйләнеп, үзләренә бер этнос-венгр этносы төзиләр. Авар каганлыгының төп көчен эченә алган бүгенге Венгрия дәүләте әнә шулай аякланып китә.


*Сарыкалада табылган кирпичләрдәге тамгалар*

Бу буладыр 899 елда.

Мәгълүм ки, бөҗәнәкләр (печенеглар) дә, угызлар да төрки кавемнәре булалар. Әмма Ауропа тарихчыларына ияреп, үзләре исем-атамалар өстәп, Русия тарихчылары борын заманнардан ук һуннарны—болгарлардан, кыпчаклардан—казакъ, үзбәк, кыргыз, татар, башкорт, төрекмән, әзәрбайҗан һ. б. төрки кавемнәрдән аерып карыйлар һәм тарихларында да бу халыкларны бер-берсенә дошман итеп сурәтлиләр. Әйткәнебезчә, әнә шул бозып сурәтләүләргә каршы, Русия галим-тарихчыларыннан беренче булып, хөрмәткә ия галим Лев Николаевич Гумилев чыга.

Төрки Хазарстаны эчке һәм тышкы каршылыклар аркасында IX—X гасырларда көчен вә куәтен киметә барганда, Идел буе Болгары белән Киев Русе көчәя баралар.

882 елда кенәз Олег Киевне кулга төшерә. Ләкин әле бу варяглар кенәзе далага чыгарга кыймый. Моннан элгәрерәк, Олег тарафыннан үтерелгән Әскәр каган 860 елда Константинопольгә яу йөреп хәтта Патшакала капкасына калканын кадаклап кайткан була. Ләкин «Повести временных лет» елъязмасында бу вакыйганы урыс монахлары 907 елда булган хәл итеп, калканны Константинополь капкасына Олег кенәз кадаклап кайтты дип язалар. Дөрес, автор өчен фантазиянең чиге юк, елъязмачы монахлар әлләни хилафлык та кылмыйлар кебек—чөнки, әйткәнебезчә, Киев каганы 860 елда Константинопольгә калканын кадаклап кайткан була бит инде, нигә шул вакыйганы гади бер кенәзне «Вещий Олег» итү өчен аңа ябыштырып куймаска? Һәм ябыштыралар да. Әнә шул ялганга таянып, Русия язучылары, мәсәлән, А. И. Красницкий кебекләр «Вещий Олег»ка да, Игорь кенәзгә дә багышлап романнар яздылар һәм моның чын булуына укучыларны инандырырга тырыштылар. Святослав турында ул болай яза: «Святослав настоящий варяг... Он по мужеству сущий воин». Чынында исә Святослав шундый буламы? Юк,

әлбәттә. Елъязманы язучы монахлар 866 елда булган яуны тоталар да 907 елга күчерәләр. Ә елъязма үзе монахлар тарафыннан бу вакыйгалардан соң 200 еллар үткәч, ягъни 1100—1113 елларда гына языла.

Олег кенәз кебек узурпаторның ялган яуларын һәм кылмаган батырлыкларын тарихка кертеп калдыру нигә кирәк булды икән елъязмачыларга дигән сорауга җавап бер булыр: бу вакытта инде Киев Русе Византиягә йөз белән борылган, хәтта рәсми төстә христиан динен кабул иткән була. Ахыр килеп, Святослав кенәзгә багышланган хазарларны туздыру әкияте дә Хазар каганатын христианлашып киткән Киев Русенә каршы кую максатыннан кылына—елъязмага кертелә.

Мәгълүм булганча, ислам дине Хазарстан аша VIII гасыр башларында ук инде Идел буе Болгарына үтеп керә башлый. Ниһаять, 922 елда ислам динен Идел буе Болгары ханы Алмас рәсми төстә кабул итә. Алмас хан үтенече буенча 922 елда Багдад хәлифәтеннән Болгарга миссионер Ибн Фазлан килеп төшә. Ярдәм килә, ләкин Алмас ханның теләге хәлифкә язган хатта колачлырак була, әлбәттә. Хазар каганы кул астыннан тәгаен котылу өчен ул хәлифәттән Болгарда кальга-кирмән күтәрергә осталар җибәрүен һәм шуның өчен акча юллавын үтенә. Ләкин нишләмәк кирәк, сәясәткә кереп баткан хәлиф илчесе Болгарга буш капчык тотып килә, ягъни Алмас ханның теләгән акламый. Болгарда кирмән-кала күтәрелми. Бу хәлгә кәефе кырылган сувaз кавеме башлыгы үз халыкларын алып, Болгар илен ташлап китә. Болгар дәүләте таркалу алдында кала: каган кул астыннан чыга алмый, моның өстенә кардәш дип йөргән Кара Болгарга (Киевкә) яңа хуҗа килә—варяг, юлбасар, талаучы. Ул гынамы, яһүд сәүдәгәрләре Киевкә үтеп керә башлыйлар, андагы Идел буе Болгары сәүдәгәрләренә урын калмый. Яһүд сәүдәгәрләре Киевкә дөнья халыклары белән сәүдә итү өчен көмеш акча—дирһәм алып киләләр. Әнә шулай итеп, X гасырда Киев Русе сәүдә дөньясына кереп китә. Ул ай саен Хазар каганына, гадәттәгечә, ясак җибәреп тора һәм яһүд сәүдәгәрләренә бәйле була, димәк, шул исәптән Хазар каганына да. Каган мәнфәгатен һәм яһүд сәүдәгәрләре теләген үтәргә теләп, Олег кенәз көймәләрдә Каспий диңгезе буйларына кадәр яу йөри, мөселманнар белән сугыша.

Бу буладыр 909—910 елларда.

Әлеге сугышларда чит-ят җирләрдә меңнәрчә төрки-болгар һәм антславяннар ятып калалар. Шуңа охшаш югалтуларга Олег кенәз 914 елда да дучар ителә. 913 елда яһүдләр башлыгы Вениаминга акчага ялланып яу йөргәндә, гомумән, гаскәрсез кала яза. 920 елда Днепр буенда көн күргән бөҗәнәкләрдән җиңелә. Күрәсез, укучым, Олег кенәз Русия елъязмаларындагы кебек ул хәтле бер дә җиңүләрдән җиңүләргә генә бармый, киресенчә, Киев халкына зыян артыннан зыян гына китерә. Шуның өчен булса кирәк, Русиянең бер танылган тарихчысы Олег кенәз турында болай дип язып куя: «... сборщик дани с беззащитных славянских племен...»

Елъязмачыларга ышанган хәлдә, безгә бернәрсә ачык булып ярылып ята: 920—941 елларда дөнья халыклары күз алдында урыслар куркаклар гына булмаганнар, гаять дәрәҗәдә тар карашлы халык итеп сурәтләнгәннәр. Бу хакта Лев Николаевич Гумилев болай ди: «Если верить летописи, не отмечающей с 920 по 941 года ни одного события отечественной истории, то надо признать русичей трусами и обывателями, не способными ни отомстить за преданных и убитых соотечественников, ни отстоять свое добро от сборщиков дани, переправляющих награбленное в Итиль» *(Гумилев Л. Н. Древняя Русь и Великая степь.—М., 1989).* Белгәнебезчә, Итил Хазар каганатының башкаласы булган. Ары таба тикшерә торгач, олуг галим шундый нәтиҗәгә килә: «... Поводов для восхваления Олега Вещего нет». Һәм галим-тарихчы Лев Николаевич Гумилев моны ассызыклап яза. Ә, бәлкем, Олег кенәзгә мәдхия укыган елъязмачыларга да шуны кылырга кирәк булгандыр...

Әйткәнебезчә, Хазарстан яһүдләре сугышчыларны, нигездә, Урта Азия мөселманнарыннан туплаганнар. Һәм бер аннан гына түгел, әлбәттә, инде Дала халыкларыннан да, Идел буе төркиләреннән дә.

Хазар каганы кул астыннан беренчеләрдән булып Идел буе болгарлары

чыгалар, аннары бөҗәнәкләр, ә Киев Русе әле һаман Хазар каганатына ясак түләп ята. Әмма Хазар каганының кул астындагы халыкларның берсен дә ычкындырасы килми: чөнки, беренчедән, Ефәк юлы кулдан ычкыначак; икенчедән, калалар арасындагы сәүдә юллары сүнәчәк. Иң мөһиме, гасырлар буена җыелган байлык юкка чыгачак. Ә бу байлык Хазарстан көн күргән яһүдләр өчен вәзгыять кенә түгел, яшәү рәвеше дә. Шуның өчен байлыкны югалту исәбенә булса да каган хакимиятне сакларга тырыша.

Ләкин көннәрдән бер көнне карусыз ясакны түләп торган Киев Русе дә каганатка салым салудан баш тарта. Менә кайчан Хазарстанда башлана мәхшәр. Халык илдән китә—тарала башлый. Ялланып хезмәт иткән мөселман сугышчылары Идел буе Болгарына күчеп китәләр, христиан динендәгеләр Киев Русенә барып елышалар, ә күпләре Византия җирләрен сайлыйлар.

Хазарстанның төп этносы булган төркиләр турында гуманист галим әлеге дә баягы Лев Николаевич Гумилев болай дип язып калдыра: «Һуннарның, табгачларның һәм төркиләрнең акыл белән яшәүләренә, гомумән, яшәү рәвешләренә тиешле бәя бирү зарур. Чит-ят җирләргә китеп, кемнәрне һәм нинди халыкларны гына буйсындырмасыннар вә яуламасыннар, кайларга гына җитеп дәүләт оештырмасыннар, беркайчан да, вандаллар кебек, варварлык дәрәҗәсенә төшмәгәннәр. Төрки халыклары нәкъ менә шул сыйфатлары аркасында гасырларга сузылган көрәштә җиңүчеләр булып калалар, үзләре яулаган халыкларны илләреннән кууга яисә кырып бетерүгә юл куймаганнар, киресенчә, һәр яуланган халыкларга үзләренең тарихи һәм мәдәни нигезләрен саклап калырга мөмкинлек биргәннәр—яуланган халыкларга туган җирләрен Ватан итеп күрергә комачауламаганнар. Нәкъ шул сәбәпле, бүгенге Русия даласында 1500 ел буена төрле милләт халыклары исән-имин көн күрәләр, ул гынамы, төркиләр бу сыйфатларын соңрак монголларга биреп калдыралар, хәтта XVI гасырда империя төзергә керешкән русларга биреп калдыралар—мәңге-мәңге җиңелмәс Бөек Даланы».

Мәгълүм булганы шул, Хазар каганлыгы империя буларак 1064 елларда яшәүдән туктый. Хазар каганатының яшәү дәверен җентекләп тикшергән Русия галиме бу хакта болай дип яза: «1064 году и остатки хазар численностью 3000 семей прибыли в город Кахтан (Казан) из страны Хазарии, отстроили его и поселились в нем» *(Новоцельцев А. П. Хазарское государство.—М., 1990).*

Тарихчы галим нигәдер «построили» дими, ә «отстроили», ди. Димәк, безнең якташларыбыз үзләре Хазар каганатында билгән Биләмҗирдән кайталар һәм күп тә үтми безнең бүгенге башкалабыз Казанны Идел буендагы зур сәүдә үзәгенә әверелдерәләр.

XX гасыр башында яшәп һәм 1905 вә 1917 елларда булган революцияләрне үз күзе белән күргән Русия галиме киләсе буыннарга васыять итеп болай ди: «Русский человек шел в науку, как в солдаты, покорно, но скрепя сердцем, зная, что это нужно царю, но не уверенный: угодно ли это Богу и Народу» *(Ключевский В. О. Западное влияние и церковный раскол.—Т. I, М., 1987).*

Әлегә Русия халкы, галим әйткәнчә, яшәвен дәвам итә: сугыш, җимерү һәм җимергәнне торгызу хисабына.

Миңа калса, яңа гасырга, яңа меңъеллыкка аяк басканда да Русия мең еллар элек булган Хазар каганаты язмышын кабатлый—сүзгә-сүз, гамәлгә-гамәл.

*2001, гыйнвар.*
*Казан*

# Гарәфи Хәсәнов

## ЯЗМЫШЛАР УРТАКЛЫГЫ

### ГАРӘФИ ХӘСӘНОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

*Балалар язучысы Гарәфи Хәсәнов үзенең язмасын әнә шулай исемләгән: «Язмышлар уртаклыгы»... Әлегә кадәр беркайда да басылмаган бу истәлек язма—аның күренекле шагыйребез Хәсән Туфан белән бергә Казанның Пелатән төрмәсендә «халык дошманнары» булып утырган еллары турында. Хәер, монысын укучы, истәлекне укып танышкач, үзе күрер әле...*

*Теге яки бу шәхесне күптәннән беләм дип йөрисең, ә чынлыкта аның турында бик аз белгәнсең булып чыга. Шәхсән мин дә Гарәфи Хәсәновны танылган балалар язучысы һәм итальян әдибе Джанни Родариның атаклы «Чиполлино маҗаралары» китабын татарча тәрҗемә итүче дип кенә белә идем. Ә баксаң...*



*Менә Гарәфи Хәсәновның биографиясенә кагылышлы кайбер мәгълүматлар:*

*Ул 1921 елның 13 июнендә Казан шәһәрендә туган. 1940 елда урта мәктәпне тәмамлагач, 1942 елның ахырларына кадәр заводта эшли. Шуннан соң, «Совет Татарстаны язучылары» дигән биобиблиографик белешмәдә (Татарстан китап нәшрияты, 1986) аның турында: «1943—1956 елларда Татарстаннан читтә—Себер якларында яши һәм эшли: Краснояр краеның Зур Улуй районы Симоново авылындагы балалар йортында һәм интернат-мәктәптә эшче, тәрбияче хезмәтендә була»,—дип кенә әйтеп узыла. Унөч ел буена нишләп ул якларда эшләп йөрде икән Гарәфи Хәсәнов? Бу сорауга тәгаен җавапны ул үзенең истәлек язмасында тулы һәм төгәл итеп бирә.*

*Гарәфи Хәсәнов Казанга гаиләсе белән бары тик 1965 елда гына әйләнеп кайта...*

*Чандыр-какча гәүдәле, кечкенә буйлы Гарәфи абый җыерчыклар телгәләгән йөзе белән балкып елмаеп килеп керер иде дә, агара төшкән сыек саргылт чәчләрен кулы белән сыпырып исәнләшер иде. Аннары тиз-тиз генә сөйләп китәр:*

*—Йә, минем китап ни хәлдә? Кайчан чыга? Бераз акчасын алып булмасмы?—Аннары тавышын баса төшеп, як-ягына каранып алыр:—Бик киселгән чак иде бит, малай...—дияр иде.*

*Минем Татарстан китап нәшриятында баш мөхәррир булып эшләгән елларым иде бу. Аның әнә шулай гади генә, үз итеп «малай...» дип куюы җитә һәм без аңа кулдан килгәнчә ярдәм итәргә тырыша идек.*

*Әлбәттә, Гарәфи Хәсәновның төрмәләрдә утырып, сөргеннәрдә йөреп кайтканын белә идек. Ул әдәбиятка ун яшьләрендә үк килгән һәм 1932 елдан «Яшь ленинчы» газетында даими автор буларак катнаша башлаган. 1934 елда Татарстан язучыларының беренче*

*съездында балалар әдәбияты хакында чыгыш ясый. Унөч яшендә! Максим Горький аның бу чыгышын «Известия» газетындагы бер мәкаләсендә дә искә ала. 1938—1941 елларда Г. Хәсәнов бик актив иҗат итә: «Яр башында болан», «Чуар таракан фаҗигасе», «Куркак куян һәм усал селәүсен», «Тәүфикъле яшь бүреләр» һ. б. хикәяләре газет-журналларда, төрле җыентыкларда дөнья күрә.*

*Әгәр дә озак еллар «Себер якларында» йөрмәсә, Гарәфи Хәсәнов ни-нәрсәләр генә иҗат итмәс иде икән!.. Казанга кайткач, ул яңадан иҗатка чума. Беренче китабы исә бары тик 1968 елда гына («Унике матур») дөнья күрә. Ун яшьләреннән яза башлаган әдип әнә шулай кырык җиде яшендә генә кулына беренче китабын ала...*

*И язмыш, язмыш...*

*Гарәфи Хәсәнов балалар өчен язды. Табигать турында, табигатьтәге кош-корт, җәнлек-җанварлар турында җиңел йөгерек тел белән, балаларга аңлаешлы итеп язды. Ул бу җәһәттән русның Михаил Пришвин кебек мәшһүр әдипләренә тиңдәш булырлык язучы иде.*

*Үз гомерендә Г. Хәсәнов нибары 5-6 китап нәшер итеп өлгерә алды. Ул шулай, «Себер якларында йөреп» сәламәтлеген нык югалтып кайтса да, үзенең җитмеш яшен тутырып, 1992 елда Казанда вафат булды.*

*Гарәфи Хәсәнов 1974 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.*

*Ә хәзер, әйдәгез, аның төрмәдә Хәсән Туфан белән бергә утырган еллары турындагы* истәлеген укыйк.

**Марс ШАБАЕВ**

* * *

Бер көнне чуен кою цехының ашханәсендә кичке ашны чөмереп утырабыз. (Безгә көндезге һәм кичке ашка бер-ике кычыткан яфрагы йөзеп йөргән «аш», йә булмаса күксегән арыш оныннан калын итеп җәелеп, бармак кинлеге итеп киселгән чиле-пешле токмач ашы бирәләр иде. Ә икмәкне мин алган минутта ук, баскан урынымнан да купмыйча, ашап бетереп куя идем.) Менә шунда, түрдәге озын такта өстәлләрнең берсе артында, кыш булса да, өстенә юка көзге кара пальто белән башына юка соры кепка гына кигән Хәсән абый да тоз тәме килгән, аш икәне шуннан гына сизелгән баланда чөмереп утыра. Янында урта яшьләрдәге калын кара мыеклы таныш түгел бер абзый да бар иде. Бу кара мыеклы абзый кесәсеннән сак кына итеп сохари кисәге ала да, аны ашаган ашы өстендә сак кына сындырып, Хәсән абыйга да өлеш чыгара. Хәсән абый аны «аш» дип аталган болганчык җылы суга салып куя. Чөнки ул «аш», ач булсаң да, тамактан авыр үтә иде.

Мин Хәсән абыйны чуен кою цехы ашханәсендә күреп, башта аптырап калдым. Ник дисәң, иң нык, иң таза кешеләрне генә чуен кою цехына китерәләр иде. Чөнки цех түгел—тәмугъ иде ул. Газ, төтен... Вагранкадан кечкенә генә түгәрәк бөкесен бәреп төшерү белән, ак-кызыл төстәге су кебек булып, утка чыдамлы озын-озын саплы астагы авыр чиләккә эссе металл ага... Металл эсселегенә озын цех буйлап аллы-артлы үтәли исеп торган салкын җил килеп өстәлә... Шуларның бөтенесе өстенә—көндәлек авыр хезмәт... Болар барысы да иң нык, иң таза кешенең дә бик тиз җелеген суыра, аны бик тиз эштән чыгарып ташлый, шәүләсен генә калдырып куя иде. Менә шундый хәлне гел күрә килгәнгә, шактый озын буйлы, янак сөякләре калкып торган, юка гына гәүдәле Хәсән абыйны цех-тәмугъ ашханәсендә күреп, гаҗәпләнгән идем дә мин.

Мин инде цехка, төнге сменага йөгерергә тиеш идем. Шуна күрә, соңга калмагаем дип, Хәсән абый белән исәнләшеп тә тормыйча, аны

күрсәм дә күрмәмешкә салынып, ашханәдән тиз-тиз табан ялтыратуны карадым. «Бүген күрешмәсәм, иртәгә күрешермен әле. Көннәр иректә чакта гына сизелмичә үтә дә китә. Ә монда... Бер көн дә ел булып тоела. Шуна күрә, бер-беребезне туйдырып бетерербез әле»,—дип табан ялтыраттым да мин.

Хәсән абый кайсыдыр каты режимлы колониядән чуен кою цехына түгел, термик цехка җибәрелгән булып чыкты. Термик цех исә, эссе һәм газлы булганлыктан, теге мин эшләп яткан чуен кою цехы ашханәсенә беркетелгән иде.

Хәсән абый иректә чагында укучылар белән очрашу өчен мәктәп һәм китапханәләргә еш килгәли иде. (Миндә мәктәптә укып йөргән чагымда аның белән бергә төшкән фоторәсем әле дә саклана), шуңа күрә без шушы Пеләтән төрмәсендә, хәзергечә әйтсәк, каты режимлы хезмәт белән төзәтү колониясендә, күптәнге танышлар рәвешендә очраштык. Мин шундый очрашуларның берсендә, сүз иярә сүз чыгып, минем иректән мәхрүм ителүемдә Кави абый Нәҗми белән аның да бераз гына «гаебе» булуын әйтеп ташладым. Эш шунда ки, безнең илдә утызынчы еллардан башлап авыл җирләреннән бала-чагалары белән «кулакларны» сөргенгә җибәрү, бигрәк тә 37-38 елларда авыл һәм шәһәр җирләрендә «халык дошманнарын» фаш итү, аларны кулга алу, юкка чыгару чоры башланды. Менә шушы чорда безнең иң зур, иң талантлы каләм осталары җибәрелгән җирләреннән кайтмый калдылар да инде. Бу дулкын, әлбәттә, Кави абый белән Хәсән абыйга да кагылмый калмады. Хәсән абыйга бигрәк тә «Ант» поэмасы өчен каныкканнар иде. Китаплары җыелып алынды, әйберләре газет-журнал битләрендә дә күренми башлады... Ләкин, дөреслектә, аларга әле кагылмаганнар, аларны күпмедер вакытка тынычлыкта калдырган иделәр. Хәсән абыйның газет-журналларда сирәк-мирәк булса да әйберләре күренде, хәтта кечкенә генә бер китабы да чыкты бугай әле. Һәм мин бер сабакташ иптәшемә: «Бу бит хөкүмәткә ни тикле зыян! Башта кешене нахакка утырталар, китапларын җыеп алалар, аннары шул әйберләрен яңадан чыгаралар»,—дип зарланып әйтеп тә ташлаганмын. Бу вакытта мин мәктәпне бетергән идем инде. Сугыш башланган иде, мин, паровоз кадәр зур станок артына басып, норманы гел арттырып үти-үти, матур гына эшли дә башлаган идем. Ләкин шунда, нindидер сәбәп белән, теге элеккеге сабакташымны да кулга алганнар булып чыкты. Һәм ул, менә бу кеше мәктәптә укып йөргән чагында халык дошманнарын мактаган иде, дип, мине дә күрсәткән. Ә мин берсеннән-берсе кечкенә өй тулы эне-сеңелләрне, саулыкка туймаган әнине, үлем түшәгендә яткан әтине (ул мин кулга алынганнан соң бер ай үтүгә үк вафат булып куйды) тәрбияли башлаган идем. Икмәк карточкалары алган чагымда, миннән еш кына: «Үзең бер малай кисәге генә, үзеңнең санап та бетергесез бала-чагаларың бар икән инде!»—дип көләләр дә иде. Ә бит мин кулга алынгач «җыйган малларымны» алып китү өчен йөк машинасы кадәр йөк машинасы белән өйгә дә килгән булганнар. Шунда безнең ишле гаиләне, безнең ярлылыкны да күргәннәр. Ләкин, шуңа да карамастан, берсе-бер: «Бар, тай тизрәк моннан! Эшли башлагансың икән, бар, эшләвеңне бел. Ләкин, кара аны, тишек авыз булып, кирәкне-кирәкмәсне лыкылдап йөрмә!»—дип, артка тибеп чыгарып җибәрмәгән...

Мине Черек күл янындагы мәшһүр кызыл йорт подвалындагы иң аскы, иң салкын, кабер тикле генә бер кешелек камерага яптылар да куйдылар! Мин шунда, түзеп тә булмаслык салкын кабер-камерада, мине монда кайсы почмактан торып атарлар икән, дип ничәдер ай утырдым. Ник шулай атылу көтелүне әйткәндә, эш шунда иде ки—әллә майлы эш киеме белән утыртылган булудан, әллә айлар буе чишенү белмәүдән—бөтен өс-башымны вак бет баскан иде. Ә бездә, татар халкында, кешене үләр алдыннан вак бет баса, дигән бер ырым бар. Утыра торгач, «эш»емне карау барышында үзем ише җыен «тел бистәләрен» бер төркемгә берләштереп, бездән «Советка каршы яшерен оешма» ясадылар да куйдылар! Нindидер күз күрмәгән, колак ишетмәгән «Особое совещание» дигән «суд» тарафыннан 8

елга лагерь хезмәтенә хөкем ителүемне күрсәтеп, өч кенә юлдан торган, мәче теле тикле генә бер юка кәгазьгә кул куйдырдылар.

Башта сигез елга хезмәт белән төзәтү лагерына, аннан соң ун елга— сөргенгә, Себер якларына... Хәер, бу соңгысы турында хөкем карарында ләм-мим сүз әйтелмәгән иде. Яшьлегемнең иң матур еллары шулай үтте дә китте минем. Менә шуларны, ягъни минем иректән мәхрүм ителүемдә аның да чак кына «гаебе» барлыгын сүз иярә сүз чыгып кына Хәсән абыйга сөйләп биргән идем. «Нишлисең, энем,—дигән иде Хәсән абый, сүлпән генә итеп,— безнең язучылар союзыннан утыртылмаган кеше дә калмады диярлек. Бары Кави абыең гына ничектер иреккә чыга алды. Ә үземнең әле хәзер дә шуңа исем китә: ул чагында, көн саен була торган гадәт буенча, язучылар гомуми җыелышында минем турыда сүз китә иде... Шунда соңгы сүзне минем үземә биргәннәр иде. Мин анда ике сәгать буе үзем һәм иҗатым турында сөйләгән идем! Әйе, ике сәгать буе! Ләкин мине ул гына коткармады, билгеле... Мине «Вакытлы матбугат битләрендә даими рәвештә советка каршы агитация алып баруым өчен» ун елга хөкем итеп куйдылар».

Хәсән абый да, үзем кебек үк, шушы ун елы тулгач та, Себер якларына сөргенгә җибәреләчәген белми иде әле.

Без Пеләтән төрмәсендә Хәсән абый белән шул дәрәҗәдә дуслашып киттек ки, әгәр мин берәр җирдән бәрәңге-мазармы, тамактан үтәрлек бүтән берәр нәрсәме табам икән, аны тизрәк Хәсән абыйга, термик цехка китереп бирә идем. Ул аны цехның һава керми торган эссе миче эчендә теленне йотарлык итеп пешереп бирә иде. Һәм без, бәрәңгенең бераз суына төшүен дә көтмичә, икәү ялт иттерә идек.

Беркөнне ул термик цехта төнгә үзе генә калган иде. «Бер буш ара тап та, килеп җит минем янга. Кара аны. Сыйланабыз!»—дип алдан әйтеп тә куйган иде ул. Менә мин килеп җитү белән кереп киттек без чолан кадәр генә начальник «бүлмәсенә». Анда икәүләп Луиза апа (хатыны) китереп киткән күчтәнәчләр төенен чишәргә керештек. Ләкин «төен» эченнән бер-ике юка гына арыш икмәге телеме белән аяк киемнәре чистарта торган кремнан бушаган, бик шөпләп юылган түгәрәк банкага салынган, мәче яларлык кына, кибеп беткән вак балык уылдыгы килеп чыкты. Әйе, ике ач кешенең түгел, бер тук кешенең кече теленә дә йокмаслык вак балык уылдыгы. Ләкин өй ризыгы иде ул! Йөзенә чыккан шатлык билгеләренә карап, менә мондый күнелле нәтиҗә чыгаруы күренеп тора иде Хәсән абыйның: «Әгәр аз булса да уылдык кадәр уылдык алып килә алган икән, димәк, кызым Гөлгенә белән Луиза ачлыкка тилмереп ятмыйлар!» Ләкин ул вакытта Луиза апаның халык дошманы булып саналган иреннән ваз кичмәгәне өчен эштән куылуын, үзенең хәләл канын тапшыру бәрабәренә кызын туйдыруын, хәтта ара-тирә аңа да өлеш чыгара алуын башына да китермәгәндер Хәсән абый. «Без, ичмасам, иллә—иректә яшибез. Ә иллә чыпчык та үлми»,—дип хатлар язгалап тора иде бит ул аңа.

Хәсән абый белән тоткынлыкта яшәгән чагыбызда аның көтмәгәндә генә авырып китүе истә калган. Барып кердем бер иртәне эштән кайтышлый ул торган такта баракка, күрәм: утыра Хәсән абый аскы нарның почмак баганасын кочаклап. Гел ачылып-ябылып кына торган ишектән салкын пар ишелеп керә иде. Шушы почмак багана янында гына мөлдерәмә тулы, әле һаман да чыгарылмаган сасы параша тора... «Нишләвең бу, Хәсән абый?!— дип шаккатып сорап куюым әле дә хәтердә.—Тышта каты салкын, ә син ишек буенда, җитмәсә, ташып идәнгә ага башлаган параша янында утырасың!» «Һай, энекәш,—дип җавап биргән иде Хәсән абый, чак ишетелерлек итеп, сүрән тавыш белән,—нилектән икәнен үзем дә белмим, ә менә аякны-кулны һич кенә дә кузгата алмыйм». Санчастька барып йөрүнең файдасыз бер нәрсә булуын мин инде үз җилкәмдә татып белә идем. Шуңа күрә мин, башка кинәт кенә бер уй килеп, шушы салкын да, тынчу да баракта чуен кою цехына чыгып йөгердем. Кайдан андый калын, утка чыдам киндер капчыклар тапканмындыр инде—анысын хәтерләмим, ләкин шуларны һәм ике чиләк ут күк кызарып торган эссе ком алып (анда ком киптерелә

торган киң һәм озын мичләр дә бар иде), очтым гына теге такта баракка Хәсән абый янына. Барып та кердем, ике чиләкне дә «дык» иттереп нар өстенә куеп, андагы кып-кызыл комны ике капчыкка да салдым. Алар урыны-урыны белән яна башладылар дип тә тормадым. Хәсән абыйның тәне пешү-пешмәвен дә уйламыйча, яшьлек җүләрлегем белән, шушы эссе комлы ике капчык белән аның аяк-кулларын чорнадым да куйдым.

Әле шуннан соң да утка чыдамлы, калын-калын киндер капчыклар эзләп табу, чиләк белән ут кук ком ташып тору... Шулай атна-ун көн дәвам иткән иде. Ләкин беркем белән киңәш-табыш та итеп тормыйча, бары үз белдегем белән, тәки аякка бастырган идем мин Хәсән абыйны! Бастыруын бастырган да идем, ләкин аңа мин бирәр төрле зыян китереп куймадым микән? дигән курку хисе күңелдән китмәгән иде. Мин аннан бу турыда күп еллар үткәч кенә, исән-имин килеш лагерь һәм сөргеннәрне әйләнеп кайткач кына сорый алдым. «Хәсән абый, хәтерегездә микән, сез бервакыт, ниндидер авыру бәреп егып, кулсыз-аяксыз калган идегез. Ә мин сезне, ут янып торган эссе ком белән чорнап, дәвалаган булып маташкан идем. Белмим, тере тәнне ут кук ком белән чорнарга ничек җөрьәт итә алганмындыр инде... Әйтегез әле, Хәсән абый, мин ул чакта дөрес эшләгән булганмын микән? Юкса бу башсызлыгым минем, менә бүгенге көнгә кадәр борчып, күңелдән китми тора». Ләкин Хәсән абый, башыннан үткән күңелсез хәлләрне тагын бер кат исенә төшерәсе килмәгәндерме: «Дөрес эшләгәнсең, дөрес дәвалагансың»,—дип әйтүдән узмаган, бу турыда артык җәелеп китмәгән иде. Миңа шушы бер-ике сүзе дә җитеп куйган иде. Бары шуннан соң күңелем тынычланып калган иде минем.

Мин тоткынлыкта чакта Хәсән абыйның бер түзем кеше генә түгел, аның чын артист икәнен дә күрә алдым. Ләкин аның чын артистлык сәләтен дә күрсәтә алуы күңел күге түгәрәк булудан, кайгы-хәсрәтсез яшәүдән түгел иде, билгеле. Бу аңа үзе кук ирекгән мәхрүм ителгәннәрнең бераз күңелләрен күтәрү, бүгенге хәлләрен бераз онытгырып тору өчен кирәк булган иде. Мин моның нәкъ шулай булуын тоткынлыкта чакта түгел—менә хәзер генә, күп авырлыклар кичеп илгә кайта алгач кына, аңлауга-төшенүгә ирештем. Әле дә хәтердә, беркөнне Пелетән төрмәсендәге татар «артистлары», ясалма сәхнә укмаштырып, концерт куярга булганнар. Концерт номерлары арасында Мирсәй Әмирнең бер пәрдәлек комедиясе дә бар иде. Бер чибәр генә хатын, үзенең ире белән алдан сүз куешып, күршеләрендәге азгын мулланы акылга утыртмакчы, кызык итмәкче була. «Юкса, очратканы саен миңа гыйшкы төшкәнен сөйли. Мине шуның белән тәмам туйдырып бетерде, тәмам гарык итте»,—ди ул иренә. Менә ире беркөнне ат җигеп калага китеп бара, чибәр хатын шуннан файдаланып мулланы кунакка чакыра. Менә хуҗа кеше артыннан капка да ябылып өлгерми, гашыйк мулла инде сәке түрендә аяк бөкләп утыра. Хатын аны-моны табынга китергән арада, күзен майландырып, аңа кагылгалап куя, үзе шул арада ризыктан авыз итәргә дә онытмый. Тәкәллефлек, муллаларда гына була торган салмак хәрәкәтләр... Мин шунда, боларның бөтенесенә бер күз ташлап алу белән, көлмәс җиремнән кычкырып көлеп җибәрдем. Мин генәме? Клубтагы барлык йөзләрчә тоткыннар көлә белүләрен күрсәтеп, эчләрен тотып, тыелгысыз шаркылдарга кереште. Әйе, алар «Кара син аны, ә!»—дип, эчләрен тотып, туктала алмыйча, шаркылдапмы-шаркылдыйлар иде. Чөнки мулла да мулла, Хәсән абый да чын мулла кебек иде. Шундый көлке итеп, шул тикле җиренә җиткереп, килештереп уйный алыр икән! Хәсән абыйны гомерен мулла булып кына, кеше хатыннарын аздырып кына гомер иткән диярсен! Менә «мулла» инде табын янында ук теге чибәр хатынга үрелә, аны тоткалый-сыпыргалый башлады. Ләкин эшләр шунда житкәч... Көтмәгәндә атка чөңгергән, капка ачылган тавыш ишетелмәсенме? Һәм азгын мулла, корт чаккан кебек утырган урыныннан сикереп тормасынмы! Менә сәке өстеннән сикереп идәнгә төште, менә итәгенә ут капкан кебек, кая барып бәрелергә белмичә, тыз-быз йөри-йөгерергә башлады. Үзе бертөзлексез: «Менә бит, гөнаһ шомлыгы! Китәргә өлгермәде, кайтып та җиткән!—инде нишләргә?!»

дип мыгырдана-сукрана иде. Чибәр хатын исә сәке астыннан бер яшел сандык тартып чыгарды, капкачын да ачты, «мулланы» этә-төртә шунда кертеп тә яшерде. Аннары ул сәке өстендәге ашалмаган ризык-сыйны җыештырырга кереште. Хатын шуның белән азгын муллага ирен үзе дә көтмәгән булуын күрсәтергә теләде. Әмма үткен һәм хәйләкәр ире аның, ишектән килеп керү белән үк, туп-туры яшел сандык янына килде, шундук капкачын ачып ташлады, аннан якасыннан сөйрәп мулла-пәрине тартып чыгарды. «Пәри» дип шуның өчен әйтәм, чибәр хатын гашыйк мулланы йон-каурый саклаган сандыкка яшергән булган икән! Мулланың йон-каурый арасыннан кигән киеме түгел, йөзе дә күренмәде.

Мәктәптә укып йөргән чагымда ук, дәреслекләр буенча ук, Хәсән абыйның зур шагыйрь булуын белә идем инде. Ә аны мулла ролендә күргәч... Аның әле талантлы артист та булуына шигем калмаган иде. «Уйнаса да, шул тикле килештереп уйный алыр икән!»—дип тагын бер кат таң калуымны әле хәзер дә хәтерлим.

Минем тоткынлыкта чакта Хәсән абый белән соңгы тапкыр очрашуым Казан белән хушлашканда булды. Беркөнне безне, утыру сроклары бер-ике генә ел калган тоткыннарны, кечкенә тәрәзәләре юан тимерчыбыклар белән челтәрләнгән, элек төрмә хезмәтен үтәгән, хәзер баракка әверелгән, калын ишекле бер зур гына таш йортка җыйдылар да, өстән йозаклап бикләп куйдылар. Ләкин шуннан соң күп тә үтми ишек янына берничә йөк машинасы килеп туктады, безне шуларга аягүрә генә бастырып, каядыр алып киттеләр. Мин Хәсән абый белән бер машинага эләгергә тырыштым. Менә кырый урамнардан бардык-бардык та, зур урамга чыктык. Томанлы һәм салкын иртә иде. Шуңа күрә урамда без кешеләрне түгел этле адәмне дә күрмәдек. Опера театрының яртылаш салынып беткән чагы иде бу, без шуның яныннан узып киттек. «Безнең кайларга китеп барышыбыз? Илгә әйләнеп кайта алырбызмы? Әллә илне күрү насыйп булмыйча калырмы?» Башта шушы уйлар бөтерелә иде. Әйе, яхшы хуҗа этен дә урамга чыгармый торган, җилекләргә үтәрлек каты суыклар башланган иде, җитмәсә. Хәсән абыйның өстендә юка көзге пальто, башында соры кепка гына иде. Колакларын, пальтосының тар, юка якасын күтәреп, «каплап» та куйган иде куюын... Ләкин кая инде алай гына колакларны өшүдән коткару? Ә капчыкта минем өр-яңа бүрек белән бер дә киелмәгән, сырган бишмәтем бар иде. Менә срок туларга бер генә ел калып бара. Аннары—иреккә!»—дип хыялланган бер чагым иде бу. Һәм шушы өр-яңа бүрек белән бер дә киелмәгән шушы сырган бишмәт, иреккә шуларны киеп чыгармын дип, ашыйсы икмәк паегын ашамыйча, тиенләп җыйган акчага сатып алынган иде. Ләкин капчыгында җылы кием ятсын, ә син бер туган абыеңдай якын кешеңне күрәләтә торып катырып үтер, янәсе... Һәм мин, ике дә уйлап тормыйча: «Хәсән абый,—дидем,—менә киеп җибәр әле шуларны: баш исән булса башка бүрек, табылыр». Шулай дип әйттем дә, бүрек һәм бишмәтне капчыктан тартып чыгарып, кепкасын кесәсенә тыктым, аның урынына өр-яңа колакчын бүрекне кидердем. Язгы-көзге пальтосы өстеннән өр яңа сырган бишмәтне кидердем дә куйдым. Минем бу турыда тел тибрәтүем моны язар өчен кулыма каләм алуым—бу, әлбәттә, үземне яхшы итеп күрсәтү өчен эшләнгән кук тоелуы ихтимал. Ләкин укучы ничек уйласа да уйласын, бу аның үз ирегендә, әмма үзем мин иң кирәк вакытта кешегә яхшылык эшли алуыма әле хәзер дә шөкерана кылам...

Менә без машиналардан төштек тә, бер җирдән икенче җиргә күчерү пунктының, әби патша заманында ук салынган калын стеналы Кремль асты төрмәсенең, шактый тыгыз мунчасы алдына кереп тулдык. Шул менә анда, кара-каршы ике ыгы-зыгыда, җирдә тентүләр башланды. Ә Хәсән абый, теге Пелатән төрмәсе дип аталган, хезмәт белән төзәтү колониясенә иялән еп беткәч, шигырьләр язгалый башлаган иде. Алар арасында эчтәлеклесе һәм ин озыны бакча һәм бакчачы турында иде. Ул да, бүтән шигырьләре кебек үк, бер бик юка гына тар кәгазьгә, лупа аша гына күренерлек итеп, вак гарәп хәрефләре белән язылган иде. Аны Хәсән абый, бүтән шигырьләре белән

бергә, жиз калайдан ясалган, жыйнак кына бер көпшә эченә яшерер алдыннан, бер төнне мина да укып чыкты. Укып бетергәчтен, таңга калып, сорап куюымны хәтерлим: «Әйтче, Хәсән абый, моны ни арада язып ташладың син?! Шундый зур, шундый әйбәт нәрсәне?!» Хәсән абый исә, йөзенә горурлык һәм елмаю төсмерләре чыгарып: «Илһам галәмәте!»—дип җавап биргән иде... Хәсән абый, укып бетерде дә, бакча һәм бакчачы турындагы зур шигырен дә, бүтән вак шигырьләре белән бергә, юка калайдан ясалган, жыйнак кына түгәрәк көпшә эченә яшерде дә куйды. Аның шушы жыйнак кына жиз көпшәне ничек ясавын да күргән идем. «Күрче, кулы аның игәү тотарга да ябышып ята икән!—дип сокланган да идем.—Димәк, Хәсән абый зур шагыйрь генә түгел, ул әле талантлы артист кына да түгел, ул әле тимер эше булып тимер эшен җиренә җиткереп эшли алучы чын оста да икән!» Менә шушы кулъязмалар тулы жиз көпшәне ул шактый кысан төрмә мунчасы алдына—андагы ыгы-зыгыда аяк астына ташлаган да иде. Аны ул типкәләп алга этәрү, шулай тентү аша үткәрү өчен ташлаган иде. Ләкин кая инде йөзләгән аяклар арасыннан нәни генә жиз көпшәне күрү, аны издермичә генә алга таба тибә-тибә этәрү... Хәсән абый шушы жиз көпшәне эзләгән, типкәләгән чагында мин бер төркемгә, ул икенче төркемгә эләктек тә инде. Һәм без икебез ике җиргә җибәрелдек тә. Ул—Новосибирск өлкәсенә, ә мин—Красноярск өлкәсенә китеп барган идем. Үзем мин срок тулганчыга кадәр язмышташ иптәшләрем белән, бары пычкы һәм балта ярдәмендә, Тайшеттан Братскига китәчәк тимер юл өчен урын хәзерли башладым. Шулай өч километр ара тимер юл салу өчен туры һәм тигез урынга әйләнде. Әйе, ул чагында һәр өч километр саен каты режимлы бер лагерь иде биредә. Шушы авыр эштә калган срогымны тутырган да идем. Ләкин мине, иш өстенә куш булсын дигәндәй, инде өйгә кайтарырлар, дип өметләнеп торганда, теге өч юлдан торган хөкем карарында бу турыда ләм-мим сүз әйтелмәгән булса да, әле бүтән бер яңа урынга, бу юлы урман кисү эшенә җибәрделәр дә куйдылар. Мине бер «эш» өчен икенче мәртәбә җәзаладылар. Үзем мин шушы җибәрелгән өлкәмдә, Чулым буендагы бер авылда, андагы балалар йортына урман кисү белән көн күрдем. Хәсән абый исә... Ә ул бу вакытта, соңыннан үзе сөйләп күрсәтүе буенча, шул җибәрелгән өлкәдә, анда урман эчендәге бер авылда еллар буе сыер көтүе көтеп, шул яңа һөнәргә дә күнеккән, шуның белән җан асраган икән. Ләкин ул гына җитмәгән, безне әле, күпмедер вакыт үткәчтен, бүтән бер яңа урынга, бары ак аюлар йөргән ерак төньягына, җир читенә җибәрмәкче булганнар. Ләкин тора-бара шундый вакыт килде—инде тар маңгайлы тиран—мыекбай[1] да дөмекте, «эшләр» шунда янадан каралды. Һәм без, исән-имин килеш, туган илгә кайтып егыла алдык...



[1]Тар маңгайлы тиран—мыекбай—сүз Сталин турында бара. *Ред.*

# БЕР СОРАУГА – БЕР ҖАВАП

*–Җөмһүриятебездә әдәбият-сәнгать эшлеклеләренең мәнфәгатен кайгыртучы татар интеллектуаль милек агентлыгы (ТАИС) бар. Бүген ул ни хәлдә?*

Бу сорауга аның директоры язучы **Рәфкать Кәрами** җавап бирә.

–Татар интеллектуаль милек агентлыгы (ТАИС) президентыбыз М. Ш. Шәймиевнең 1993 ел 2 июнь Указы нигезендә оештырылды. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенең 1994 ел 22 март карары белән ТАИС турындагы Положениены раслады. Бу документларда ТАИС ка йөкләнгән бурычлар, вазифалар һәм аңа бирелгән хокуклар күрсәтелгән.

Җиде елдан артык вакыт эчендә ТАИС иҗат кешеләре турында чын-чынлап кайгыртучы дәүләт органына әверелде. Безгә көн саен авторлар яки авторларның варислары киләләр. Аларның йомышлары төрлечә: китап чыгарганда килешү төзүдә киңәш-табыш итү, авторлык хокукы бозылган очракта ярдәм күрү, гонорар юллап алу... һ. б. Шунысын да басым ясап әйтү кирәктер: без авторларны профессионал яки үзешчәнгә, дәрәҗәле яки исемсезгә аермыйбыз, безнең өчен барысы да бертигез. Шуңа күрә берсе дә игътибардан читтә калмый. Бүгенге көндә ТАИСта теркәлгән авторлар саны сигез йөзгә якын.

ТАИС, нигездә, театрлар, концерт бригадалары, теле-радиотапшырулар компанияләре, тавыш язу студияләре белән эш итә. Чөнки без алардан, авторларның әсәрләреннән файдаланган өчен, акча җыярга тиеш. Кызганыч, бөтенесе дә авторлык хокукына кагылышлы закон-норматив актларны төгәл үтәми, кайчагында арбитраж судка да мөрәҗәгать итәргә туры килә. Мәхкәмәгә барып җиткән дүрт процессны да ТАИС отты. Шунысы да мәгълүм булсын: без эчке эшләр министрлыгы, прокуратура, салым инспекциясе һәм салым полициясе белән дә кулга-кул тотынышып эшлибез.

Мәгълүм ки, Мәскәүдә Русия авторлык җәмгыяте (РАО) эшләп килә. 1995 елда без алар белән үзара хезмәттәшлек турында Килешү төзедек. Ай саен авторлык гонорары алмашабыз, авторларны һәм аларның туганнарын барлауда бер-беребезгә булышабыз, хокуклары бозылса, бергәләп яклау юлларын эзлибез.

ТАИС, хәленнән килгәнчә, реклама эшләре белән дә шөгыльләнә. Химаячеләр табып, без җиде плакат чыгардык: «Халык язучылары», «Мәшһүр композиторлар», «Күренекле рәссамнар», «Сәхнә осталары» (4 плакат). Боларның һәммәсе дә мәктәпләргә һәм китапханәләргә бушлай өләшенде.

Әлбәттә, ТАИС ка йөкләнгән төп функцияләрнең берсе–исән-сау авторларга һәм вафат булганнарының варисларына акча җыю, бүлү, тарату. Мәгълүм ки, авторлык хокукы 50 ел саклана. Узган ел, мәсәлән, республикада яшәүче авторларга 1 миллион 600 мең сум гонорар җибәрдек, Әдәби фондка–146 мең сум, Композиторлар берлегенә–132 мең сум, салым рәвешендә республика бюджетына 202 мең сум акча күчердек.

Димәк, ТАИС бүгенге көндә үзенә йөкләнгән бурыч-вазифаларны эзлекле рәвештә башкарып килә.

*Яшь тәнкыйтьче сүз ала*

# КЕШЕЛӘРНЕҢ ЧЫН ЙӨЗЕ

Сиксәненче-туксанынчы елларда татар әдәбиятында яна тема калкып чыга: «Кеше, табигать, билгесез көчләр» Бу теманын беренче карлыгачлары—төрле ырымнар, мистик күренешләр, карангы гамәлләр, жаннын бер материядән икенчесенә күчүе турындагы мәкаләләр, хикәяләр. Кеше үзен табигать белән бербөтен итеп карарга тырыша, төрле йолдызнамәләрдән үз язмышын белергә омтыла. Мондый кызыксынуны иллә булган болганчык хәлдән, начар сәясәттән качу, һәр кешенен үз дөньясында бикләнергә теләве, үз-үзен яхшырак беләсе килү теләге белән дә анлатып була.

Менә шул елларда әдәбият күгендә хатын-кызлардан язучы Нәбирә Гыйматдинова исеме калка. Тасвирларга алынган темаларнын яналыгы, геройларынын эчке кичерешләрен табигатьтәге үзгәрешләр белән үреп бирүе, әсәрләренә хас киеренкелек Нәбирә Гыйматдинованы башка язучылардан аерып тора. Анын әсәрләрендә табигать белән кеше берлеге матур аһән тудыра, бербөтен итеп карала. Бу алымны Әмирхан Еники әсәрләрендә дә күзәтеп була. Сазда үсеп утыра торган бер оя ут чәчәкләренә Шакир Мостафин («Саз чәчәге») башта сокланып туя алмый. Гәрәбәдәй янып торган чәчәкләр—чыннан да матур, бик матур, әмма агулы икән. Алар сазда гына үсә, ут чәчәкләрен хайван да читләтеп үтә икән. Бу көтелмәгән алдану Мостафинны гажәпләндерә, чөнки анын тормышы да шуна охшаш.

Нәбирә Гыйматдинова үз әсәрләрендә традицияне дәвам иттереп кенә калмый, үзенчәлекле юлдан китә. Анын геройлары—табигать баласы, һәм ансыз яши алмыйлар. «Болан» повестендагы Сузгын карчык белән Акчәч, «Сихерче»дәге Маһруй әби белән Сәвилә, «Ут күбәләге»ндәге Мөнәвәрә әнә шундыйлардан.

Эшләгән явызлыклары, кылган гамәлләре өчен, әйтерсен лә, табигать кешедән үч ала. Табигать һәм кеше арасында ниндидер күренми торган жепләр сиземләнә. Тәминдар Сәвиләне алдап, «хуш» дип тә әйтмичә, калага юнәлгәч: «Кояш тоташ янгырга күмелде», «Көзге янгыр койды, койды». Табигать тә Сәвияне яклагандай, Тәминдарга киртәләр тудыра. Әйтерсен лә ул бичара «сихерчене» кызганып елый *(«Сихерче»)*.

Икенче бер урында чөгендерче хатыннар ана торнаны кәтмән белән кыйнап үтергәч, «төн уртасында давыл башланды. Өй кыекларында сызгырып, сәлам генә биреп үтәрдәй тоелган жил, отыры көчәя, кулбармаклар үстергән дәжжал кебек ишек-капкаларны, тәрәз янакларын йолкый, тарта иде». Автор табигатьнен көчлелегенә безне ышандыра. «Табигатьне рәнжетергә ярамый» дигән сүзләр әсәрнен төп идеясен тәшкил итә. Авыл тикле авыл кыска вакыт эчендә юк була: «Юк иде авыл, тирә-юньдә бүрәнә, такта, калай өемнәре генә иде . Ә инде Сәриянен: «Ак торна каргышы бу-у!» дип кычкыруы «жансыз авылны урталай телде».

Әгәр игътибар белән күзәтсәк, Нәбирә Гыйматдинова әсәрләренен исемнәре дә табигать белән бәйле: «Күке төкереге», «Ак торна каргышы», «Ут күбәләге», «Кара кош», «Бүре каны», «Болан». Бу сайланыш очраклы түгел. Язучынын барлык әсәрләре аша үткән фикере—бары тик табигать белән берлектә генә кешенен эчке дөньясын тулы күрсәтеп була.

Нәбирә Гыйматдинованын һәрбер әсәре уйландыра, күнелдә ниндидер дулкынлану уята, кешенен жанына үтеп керә. Язучынын кайсы гына әсәрен алма, анда сурәтләнгән вакыйганын ахыры кызганыч, кайбер вакытта хәтта фажигале.

Бу хәл авторның әсәрләрен чынбарлыкка якынайта: тормышта да бәхетсез, фаҗигале язмышлы кешеләр бик күп бит. Шул ук вакытта уй бер туа: укучы өчен бәхетсез булып күренгән геройлар, бәлкем, тормышларының кайбер мизгелләрендә үзләренчә бәхетледер.

Кешенең табигать кочагында күрсәтелүе геройның кичерешләрен тагын да тирәнрәк ачарга булыша. Дөньядан бизгән, кешеләр янынннан куылган Хаятның күнелендә жылы калмаган. Табигать тә моны раслый. «Бүген тышта төкерсән, төкерегенне куырырлык салкын иде, агач кайрылары чырт-чырт ярылды, кошлар очмас булды. Кичкә таба һава тагын да суынып, сулышка капты. Урман эче бозлы баз кебек иде. Әйтерсен, күк йөзен чуарлаган йолдызлар, жир өстенә туктаусыз суык нур бөрки иде». *(«Пәри утары»)*.

«Ут күбәләге»ндәге урманның һәр почмагын белгән Мөнәвәрә дә, «Сихерче»дәге болыннар, инешләр өчен кайгыртып йөргән Сәвилә дә шундыйлардан.

Нәбирә Гыйматдинованың геройлары табигатьтә яшәп кенә калмыйлар, алар үз хисләренең нечкәлеге, теләкләренең зурлыгы аркасында хәтта табигатьнең бер өлешенә әйләнеп китә ала. «Беркөнне Акчәч урманда боланга тап булды. Болан искиткеч матур иде. Сылубикәдән көнләшеп, кыз үлә язды. Әчен яндырып бер теләк тә уянды: «Болан күк чибәрләнсән иде дә... Рыскалның күзенә чалынсан иде... Бир мина буй-сынынны, бир илаһи матурлыгынны... Бир, бир... Күчер мина матурлыгынны!». «Анына килгәндә, Акчәч үзен болан итеп күрде. Болан-кыз арт тоягы белән озын муенын кашыды, тирә-якны күзәтте, үлән чемченде». *(«Болан»)*.

«... күбәләктәй бөтерелеп очкан кыз табигать белән бербөтенгә әверелгән, аларны аерып алырлык түгел иде. Табигать үз баласын жылы тамчылары белән назлый, иркәли сыман иде. Әллә күз алышынды, әллә могжиза булды, берзаман кызның гәүдәсе югалды, алан уртасында бары тик гүзәл сын гына торып калды». *(«Сихерче»)*.

Язучы геройларының кешеләргә мөнәсәбәте дә табигать аша туа. Кешенең хисләре, эчке дөньясының тышкы дөнья белән каршылыкларга керүе язучының «Сихерче» повестенда сурәтләнгән. Табигать кочагында яшәүче Маһруйны кешеләр анламый, хәтта анларга да тырышмый. Маһруй да табигатькә рәхимсез кешеләргә нәфрәт белән карый: «Жансыз тугайлар, жансыз болыннар, әрәмә-су буйлары арта. Таптады, изде кеше, рәхимсез изде». Карчык исемен атап та, төртеп күрсәтә алмаган үлән-чәчәкләр күп иде, алар жир өстеннән эзсез югалган иде. «Тагын да югалыр,— диде карчык шомлы тавыш белән,—тагын да югалыр. Адәм туфрагы-ние белән йотадыр, адәм—аждаһадыр».

Геройларның эчке хисләренең тышкы дөнья белән каршылыкка керүен Нәбирә Гыйматдинова «Ак торна каргышы»нда уңышлы чагылдыра. Кешеләргә шәфкатьле Арысланның чиста матур күнелен авылдашлары анламыйлар, аның миһербанлык кылуын «хурлык» дип тамгалыйлар. Мона тагын бер мисал булып «Болан» хикәясе тора. Әбисе тарафыннан дусларыннан мәхрүм ителгән Акчәчнең күнеле «әбисеннән разый түгел иде». «Әбисенә каршы дәшмәде оныг, сүзсез генә тынлады... Алай да яшь йөрәк ризасызлыгын белдереп дулап алды:

—Мәктәпне ташла, имеш!»

Геройның үз эчендә барган хисләр көрәше әсәрдәге күнел көрәшен көчәйтә. Иренә тугрылыклы Мөнәвәрә жаны белән Юлчыга тартыла. «Хезмәтче хатын иде Мөнәвәрә иренә, бары тик хезмәтче хатын гына иде. Ә бу егет аны чәчәккә тинли! Аның белән күпме генә бәхәсләшсә дә жанына рәхәт, барыбер рәхәт бу сүзне ишетүе! Килмимени яшь хатынның чәчәк буласы? Килә, бик тә килә! Жанында яралган мәхәббәте үлмәде бит, кояш кебек батты гына. Бәлки ул янә калкыр? Чөнки өмет сүнмәде әле, өмет исән. Төннәрен ул йокыдан уята, йөрәкне сызып-сызып ала, шул чагында кемгәдер: «Ярат, ярат мине»,—дип пышылдый Мөнәвәрә. Кем ул «берәү»? Сәфәрме? Сәфәр үз хатынының хыялында шулай янарамы? Юк шул, охшамаган ул Сәфәргә, кырыс, салкын Сәфәргә!..»

Әсәр буйлап үткәрелгән фикер укучыны үзенә җәлеп итә. «Егетнең бармаклары арасыннан чишмә кебек челтерәп моң агылды. Мөнәвәрә өчен ят көй иде бу. Нинди сагышы бар әле аның! Ире исән-сау, тиздән җинеп кайтабыз, дип яза. Урман да үсә, матурая. Ә җан барыбер разый түгел. Җанда яра бар. Юлчының уйнавы шул яраны кузгата бугай. Уйна, уйна, егет. Күмә инде сагыш Мөнәвәрәне,

күмә, котылу юк хисләр өермәсеннән! Сулкылдап-сулкылдап авырта йөрәк... Акланмаган өметләр, үлгән хыяллар өчен генә бу сулкылдау аз әле! Күз яшьләре Мөнәвәрәнең кайнар яңакларына тамды. Ул егеттән оялмады, чөнки үзе түгел, җаны инрәп елый иде. Аның караңгы тормышына давыл үтеп керергә җыена» һәм шунда ук: «- Уйнама, житәр...—Мөнәвәрә каударланып урыныннан купты.—Мин урманны әйләнәм.

Сәфәр атарга өйрәткән имәнгә килеп төртелгәч кенә, хатынның зиһене ачылды.—Ярлыка мине, Ходаем,—дип пышылдады ул. Колагында һаман скрипка кыллары чыңлый иде.—Күңелемдә бозыклык юк минем. Уемда да, күңелемдә дә. Минем бары тик яраттырасым гына килә. Сусадым мәхәббәткә. Изге мәхәббәткә. Тәнем белән Сәфәргә хыянәт итмәм, тәнем—никахлы иремнеке, ә җанымны ул аңларга теләмәде, җаным иясез иде». *(«Ут күбәләге»).*

Геройның үз-үзенә каршы килүе әсәрне тормышчан итә. «Хаят үз-үзен аңламады. Бая гына Рөстәмне ярсый-ярсый куган йөрәк, үкенгән сыман, күкрәк читен чәнчеп-чәнчеп сулкылдый иде. Нидер югалды. Нидерме, кемдерме? Яраббым, кая соң пәйгамбәрләрдән калган сабырлык, кая? Дилбегәсен бушатып, ярсу атка утырып чапкан җүләр хәлендә бит ул!» *(«Пәри утарында»).*

Геройның монологы, әсәрнең интонациясе бәхетсезлек, ялгызлык төшенчәләрен тагын да кискенләштерәннәр. «Киткән... Бөтенләй саубуллашып киткән. Син инде моны төшләргә борып, үзеңне алдый алмыйсың! Киткән, киткән! Һәм дөрес эшләгән. Бер бәхетсез иттеләр бит Хаятны, күңел чишмәсе бәхетсезлектән мөлдерәмә аның, тагын шуңа хәсрәт өстәп ник тилмертергә ди!» *(«Пәри утарында»).*

Игътибар белән укысак, язучының күп кенә геройлары—ялгыз кешеләр. Аларны башка кешеләрдән аерып күрсәтү, ялгызлыкка дучар итү—аның эчке дөньясының барлык якларын: көрәшне, каршылыкларны, ризасызлыкны, көчсезлекне, икеләнүне күрсәтү өчен мөһим алым. Ялгыз, бәхетсез, хыялларын тормышка ашыра алмаган кешеләр—Нәбирә Гыйматдинованың күп әсәрләренең каһарманы. Ялгызлык турында шундый бирелеп язган кеше—йә үзе дә ялгыз кеше, йә кешенең эчке дөньясының бар тайпылышларын бик яхшы белүче психолог дигән фикер туа.

Атасының туган авылында үзен ялгыз хис иткән Сараны кызганмыйча булмый. Аның ялгызлыгы кешеләрнең битарафлыгы, кансызлыгы җирлегендә үтә ачык күренә. «Ут күбәләге»ндәге Мөнәвәрә, ялгыз яшәүдән туеп, озак уйлап тормыйча, юлчыны үзендә калдыра.

«Пәри утарында»гы ялгыз бүре образы Рөстәмнең һәм Хаятның ялгызлыгын тагын да көчәйтеп күрсәтә. Бүре образы бөтен әсәр буйлап бара. «Суыктыр, күрәсең, тавышын калтыратып бүре улады». «Кинәт «мин дә бар дөньяда» дигәндәй, бүре улап җибәрде». «Бүре улавы да җанны актара. Бу кичләрдә бичара отыры ямансулады, яз житкәч, югалту сагышы тагын да көчәя, күрәсең. Йә, нигә китте соң ул, нигә? Сөйләмәс иде бернәрсә дә Хаят, ялгызлыкның никадәр авыр икәнен әйтмәс иде. Тел тибрәтерлек көче дә юк аның хәзер, дәрте дә юк. Эчендә—буш дала». Рөстәм дә соры бүре кебек ялгыз: «... бу—соры бүре иде, ул ыңгыраша-улый куаклар арасыннан чыгып килә иде...» Рөстәмнең дә хәлә бүренекедәй.

Бүре образы геройларның ялгызлыгын, аерым бер сыйфатларын, аларга янаган куркынычны ачып килсә, урман образы—геройларны саклаучы, яклаучы. Урман—геройның ышыклану, күңеленең тынычлану, үз-үзенә ышану урыны. Урман язучының әсәрләрендә яши, үзенә бер дөнья. Ул—җанлы образ: «Урман йокысыннан уянды.» Нәбирә Гыйматдинованың әсәрләрен урмансыз күз алдына китерү авыр: «Ут эчендә кайнасам да, урманны уйлыйм.»

Урманның язын яңаруы геройларны да сөендерә, аларның күңеленә яшәрү кертә. «Мөнәвәрәне һәр елны сөендергән нәрсә—табигатьтәге үзгәреш иде. Урман йокысыннан уянып, ашыга-ашыга төс үзгәртергә керешә. Башта агач-куаклар сизелер-сизелмәс кенә ачык яшел төскә буялды, ә бөреләр ачылып зурая барган саен бу төс куерды, куерды да утар тирәсе яшел чуклы яшел шәлгә төренгәндәй булды. Һавага таралган татлы ис—яшел үлән исе, бөре исе, каусәсеннән саркып тып-тып җиргә тамган каен суы исе сулаган саен сулыйсыны китерә, алай гынамы, ширбәт эчерткән сыман, җиңелчә генә башны әйләндереп, күңелне иләсләндереп куя иде.» *(«Ут күбәләге»).*

«Күке төкереге» повестендагы Оныk күршесеннән гел явызлык күргәч, Карачутыр тәэсиренә эләгә, кара көчләр, сихер дөньясына кереп китә. Ләкин жан газабына түзә алмыйча, Акъәни сүзләрен искә төшереп, үзен мондый сүзләр белән камчылый: «Син кеше түгел, син коточкыч явыз хәшәрәт, бу сина жәза, жәза...». Повестьнын кайбер битләрен укыганда, жан өши, хәтта кайвакыт китапны ябып куясы килә башлый. Димәк, әсәрнен тәэсир көче бик зур. Язучы төрле күпертелгән алымнар ярдәмендә геройларнын эчке дөньяларын гына ачып калмый, ә укучыны ышандыра, уйландыра.

«Сихерче»дә хәтта жаннын икенче төрле материягә күчүе турында сөйләнә. Биредә автор «геройнын жаны үлемсез» дигән фикерне күтәреп чыга һәм унай геройнын киләчәгенә ышаныч тудыра. «Ул яшәр. Ул жирдә бер тапкыр яшәп китте бит инде... Убыр кыяфәтендә йөз ел яшәде.»

Геройнын вөждан газабы аны тоткарлау көченә әверелә. «Нишләп жанымны тотып торасын, жибәр! Тотма, жибәр!»—дигән кыргый тавыш укучынын колагында чынлый.

Югары әхлаклылык язучынын барлык әсәрләрендә диярлек геройларнын төп сыйфаты булып тора. Алар үзләренен кылган гамәлләренә нәтиҗә ясыйлар, уйланалар, кешеләр алдында пакь йөзләрен саклап калырга тырышалар. «Күке төкереге»ндәге Галия Гыйлемдарны яратса да, ул анын «хатынлы ир» икәнен белеп, үз янына якын жибәрми.

Ә геройларнын, образларнын исемнәренә килсәк, алар сонгыларынын эчке дөньяларына бәйле рәвештә бирелгән дип әйтсәк, ялгышмабыз. Бер яктан: Акъәни, Акчәч, Оныk (Галия—бөек, олы), Ак торна, Мөнәвәрә (нурлы, якты). Икенче яктан, Карачутыр, Каракош, Соры бүре. Гомумән, автор «ак» сүзен аерым бер мәгънә белән куллана. Изге күнелле Акъәнинен оныгы күлмәге турында (ул да—ак) кайгыртуы, ак күнелле Акчәчнен сөйгәнен саклап калу теләге белән боланга әверелеп жан бирүе, пакь жанлы Саранын ап-ак торна булу теләге—барысы да Нәбирә Гыйматдинова әсәрләренә үзенә бер аклык, рухилык, күтәренкелек, матурлык өсти. «Ак» сүзе геройларга билгеләмә булып килә, аларнын эчке дөньяларын ачыкларга ярдәм итә.

Язучынын әсәрләрендә урынлы кулланган сурәтләү чаралары ярдәмендә тулаем сәнгатьлелек, аһәнлелек арта. «Төн сискәнеп куйды.» Тагын: «Жәй уртасында куак ботакларында берән-сәрән сары яфраклар күренә, һәм әле узмаган гомернен дә саргаюын искәртә. Хаят күнелендә дә сары яфраклар, күнел сарыга манчылган... Чөнки ул сагыштан көя, яна, өтелә» *(«Пәри утарында»)*. Бу шулай ук геройларнын халәтен ачыкларга ярдәм итә. «Пәри утарында» Хаят «читлеккә эләккән жәнлек», «хыял куагында сайраган сандугач», «жансыз агач», «тун кучән» дигән сурәтләү чаралары ярдәмендә тасвирлана. «Йөрәкне каната», «ут сулап яши», «күк—чиксез, уйсыз, күнел төсле буш» дигән сүзтезмәләр әсәрләрнен телен жанландыра.

Әйе, Нәбирә Гыйматдинованын әсәрләре үзенчәлекләргә бай. Анын әсәрләрендә кеше жаны, кин һәм тирән чагылдырылган. Татар поэтик прозасынын гүзәл традицияләрен дәвам итүче Нәбирә Гыйматдинова үзе дә кеше күнеленен тасвир остасына әйләнгән.

**Гөлнара ШӘМСИЕВА,**
*Казан дәүләт университеты студенты*

## «КОТАДГУ БЕЛЕК»НЕ БЕЛӘБЕЗМЕ?

*Чыннан да, без beләбезме бу бөек әсәрне? Урта гасырның төрки шигърияте калдырган иң камил шигъри әсәр санала ул—XI йөздә, Караханилар дәүләте чорында язылган, Иранда—«төрки Шаһнамәсе» дип дан алган, шулай ук Кытай һ. б. дәүләтләрдә дә үз чорында ук билгеле булган шигъри «белек». Ул—чыннан да бәхеткә илтүче белем булып исәпләнгән; дәүләт идарәсен һәм җәмгыять тормышын акыллы итеп кору өлгеләрен, шул чорның иҗтимагый-фәлсәфи идеяләрен чагылдырган. Шунсы әһәмиятле: әсәрдәге мәсьәләләр, югары әхлакый идеаллар—бүген дә актуаль, безнең чорга да авараздаш. Һәм бу бөек әсәрнең йогынтысы да Котб, С. Сараи, Мөхәммәдъярлар аша безнең көннәргә кадәр килеп җиткән шигъри мәктәп санала. Егерменче гасырда ул төрек, үзбәк һ. б. телләргә тәрҗемә ителеп, дөнья күрде, Кытайда уйгыр телендә басылды һ. б. Безгә ул урысчага Н. Гребнев, С. Иванов тәрҗемәләре аша таныш иде. Аерым бүлекләрен шагыйрә Лена Шагыйрьҗан тәрҗемә итеп, матбугатка чыгарды. Бу санда тәкъдим ителә торган өзекләрне исә Әдхәт Синугыл оригиналдан—иске төркичәдән тәрҗемә иткән, безнең көннәрдә дөнья күргән басмалардан да файдаланып эшләгән дип беләбез.*

## Йосыф Хас Хаҗиб-Баласагунлы

## КОТАДГУ БЕЛЕК

ӨЗЕКЛӘР

### Дөнья хафасы, дуслар җәфасы

6565 Йөреп бер, гизеп бер дөньяны күрим,
Кем икән вафалы дөньяда, белим.

6566 Чын адәм табу ул хәзер зур кытлык,
Мин аны табалсам, булыр зур шатлык.

6567 Чын адәм тапмадым, барын тапсам да,
Табалсам, туймамын көн-төн баксам да.

6568 Вафага зур кытлык, дөньялар жәфа,
Багып бер күрикче, бар микән вафа.

6569 Табалсам мин әгәр вафалы адәм,
Җилкәмә күтәреп, кылырмын бәйрәм.

6570 Ашмаса чынга бу соңгы өметем,
Кыргыйлар белән мин тереклек итим.

6571 Ашыйм мин гел тамыр, куныйм тышта төн,
Эчкән су янгыр гел, булсын тирем тун.

6572 Булып мин бер ерткыч вәхши, көн итим,
Бизеп мин кешедән, дөньядан китим.

6573 Күренсә бу да аз, ничек мин түзим,
Агып мин дәрьядай, тузандай тузыйм.

6574 Вафасыз дөньяга мин ничек чыдыйм,
Вафалың кем, Ходам, мин сәждә кылыйм.

6575 Кешеләр үзе бар, кешелеге юк,
Кешелек кайда ул, җавап биргәне юк.

6576 Кайда ул шәфкатьлек, кайда кечелек,
Шәфкатьсез—дөньяда гамь юк, кешелек.

6577 Күрсәм мин күз тегеп кемне үз итеп,
Шайтандай бер дошман булды ул, өтек.

6578 Кемне мин үземдәй күрсәм үз ишем,
Гел жәфа күрдем мин, инде ни эшлим?

6579 Күнелгә тел сүзе бер ачкыч иде,
Телләр дә алдашкач, ышаныч үлде.

6580 Бүген мин бәладә, кемне дус итим,
Кемнәрне дус-иш дип таянып әйтим.

6581 Кемгә соң ачылып сер чишү мөмкин,
Мин мөшкел хәлдәмен, әйтеп бер үтим.

6582 Яр сөйсәм, ул ярым әйләнде ятка,
Кардәшләр күбесе ят булды хәтта.

6583 Ышаныч, иманның шарты булса ант,
Бу антны кем үти—саналыр ул мәрд.

6584 Икмәкнең хакласа кем дә кем хакын,
Алтын вә көмештән түләрмен хакын.

6585 Сөенеч-кайгыны табылса бүлгән,
Кайгылар таралыр исбатлау белән.

6586 Ярына табылса ышанганнар ул,
Үзен бәк ясармын, үзем санап кол.

6587 Кешедән кеше мин эзләп ут янам,
Ул кеше табылса, сөенеч алам.

6588 Адәмдә адәми сыйфат ташланды,
Кайсы соң заманда яшәү башланды?

6589 Әллә соң мин үзем тиле-милеме,
Сөйләгән сүзем нинди ул—юньлеме?

6590 Әллә соң, үт ташып, түндеме мием,
Күренә биш булып күзгәме минем?

6591 Әллә бу адәмнәр гел миңа тапмы,
Ул чакта мин үзем әллә ахмакмы?

6592 Вафаны алайса кем киткән ташлап,
Кайсыгыз чын адәм, языймчы мактап.

6593 Бу канун, тәртипләр кем язган, белмим,
Табалсам мин аны, тәбрикләр идем!

6594 Әйтсен ул кануннар нинди булганын,
Аңа жай түр жирдән, каулыйм калганын...

6595 Изгеләр үлгәч тә, изгелек үлде,
Түбәннәр килгәч тә, кешелек бөлде.

6596 Адәмгә охшаган тыштан бар бәндәң,—
Бары да түгел шул фәрештә, Аллам.

6597 Изгеләр үлделәр, мин болар белән...
Ничек мин көн итим, ярашып гелән.

6598 Күпме сөйләсәң дә сөйләргә мөмкин,
Файда юк сөйләүдән,—мин моннан китим.

6599 Адәмдә булмагач адәмчә әхлак,
Мин китим шәһәрне, кышлакны ташлап.

6600 Китсәм мин калдырып туган ил-йортым,
Тапмассыз, белмәссез хәтта сез атым.

6601 Чаяндай чагадыр бу чебен кавем,
Этләрдәй кабалар, кайсысын каулыйм?

6602 Хәсисләр өерен күреп шаккаттым,
Бу бозык галәмдә бер урын тапмыйм.

6603 Жәберләр, жәфалар жаныма тиде,
Дөньяда яшәүдән тәмам жан бизде.

6604 Раббым, син күрсәт Рәсүлнең үзен,
Күрсәт һәм дүрт аның ярының йөзен.

## Китап иясе Йосыф олуг Хаҗиб үз-үзенә үгет-нәсихәт укый...

6605 Һәрчак жай[1] тап, белем алып, түрдән бер,
Гыйлем бик нык үзең корган кирмәндер.

6606 Белеме юк йөрәк, тел нигә ярый,
Гыйлем, су кук, иң мөһим шифа дару.

[1]Жай —урын.

6607 Күпме белмә, белгәнен аздыр гелән,
Тынгысыз тик теләккә житә белгән.

6608 Беләм дигән—белемнән торыр ерак,
Белемленең алдында булыр өрәк.

6609 Белем ярсыз вә төпсез бер диңгездер,
Су эчеп канмаган багнының үзедер.

6610 Белем генә ачса ачадыр күзне,
Белеме сай «мин»леккә корыр сүзне.

6611 Белем алып адәм бул, гакыл үстер,
Йә хайван атал да бер, койрык үстер.

6612 Белемле ул уй диңгезендә йөзәр,
Белемсезгә дөнья түгәрәк, гүзәл.

6613 Белемлегә дөнья көлке түгелдер,
Надан—сыгындай[1] уйнаклап йөридер.

6614 Белемле гел кешәнле, чапмас алдан,
Белемсез—теләк колы булган надан.

6615 Кешәнләнсә галим, надан Ил гизә,
Кешәнләнсә, надан, кешәнне өзә.

6616 Менә мин белемгә канып кул суздым,
Сүзләрне сүзләргә ялгап тау уздым.

6617 Төрки сүзләрнең бик күп серен чиштем,
Тау аучыларыдай эзенә төштем.

6618 Сыйпалагач иркәләп, сүзләр күнде,
Җимешләрен шулай да саран бирде.

6619 Баш бирмичә ипардай йә ис сачты,
Тоттырмыйча кайчак уйнаклап качты.

6620 Сөйләдем мин сүзне суган-борычлы,
Туры сүзне сөйгән калмас бурычлы.

6621 Укырга бик авыр булмаска бары,
Анык вә бик ачык яздым мин аны.

6622 Туры булмаса сүз, башка сүз сүзме,
Туры белән бөкре—ак, кара үзе.

6623 Дүрт йөз алтмыш икенче елда язын,
Җаным әрнеп ошбу сүзләрне яздым.

6624 Унсигез ай тәгәл сүзләр яздык без,
Аердык, сайладык сүзне сүзгә сүз.

6625 Чәчәкле таждай сүз хуш ипар исле,
Сүзләрне яздык без, кушып бар хисне.

6626 Сүзне күпме сөйләмә, туймас һичкем,
Аккан чишмәдән сүз бер дә түгел ким.

---

[1]Сыгындай—тау кыр кәжәседәй.

6627 И, Йосыф, син һәрчак кирәк сүз сөйлә,
Кирәкмәгән сүзләрдән зарар килә.

6628 Сүзеңнең, күп сөйләп, тәме китмәсен,
Инсаннар бу сүздән арып бетмәсен.

6629 Бу дөньяда жәфа белән күп хафа,
Акылсызлар корыр күп кәеф-сафа.

6630 Дөньяга син бик нык ябышып алдың,
Фаныйлыгын да онытма һич анын...

6631 Бу дөньяга табынма, кызып малга,
Табын тик гел гөнаһсыз бер Ходайга.

6632 Дөньядан күп үтте һәртөрле халык,
Азган-тузган күпме—имансыз калып.

6633 Синең торган бинаң нәкъ туйның яры,
Бик сөенмә аңа, фанидыр бары!

6634 Азмы дәүләт-илләр җан тәслим итте,
Үлмәс тойган патшалар бар да китте.

6635 Егетчаклар буш үткән юкка һәркөн,
Кояшым да инде баерга якын.

6636 Мең яшә, тик әҗәлдән юктыр чара,
Күпме җыйма малны, бары да кала.

6637 Синдә фәкать бар өмет, Раббым, сакла,
Саташканда кылган гөнаһым акла.

6638 Бу гөнаһлы дөнья языгы күптер,
Яхшылыкка илткән юлларга китер.

6639 Минлегем тик Сине ят, кәфер итте,
Ярлыкавың сорар көн килеп җитте.

6640 Мин нәрсәгә табынган булсам элек,
Инанганмын гел аңа, кире күреп.

6641 Мин сайлаган Хак булсын хәзер юлым,
Ике дөньяда да булсын түр урным.

6642 Өч көнлек шатлыктан торган дөньяда
Бар таләбе катгый булды миңа да.

6643 Телең тый, нәфесең... бик күп йоклама,
Күп күрмә, ишетмә, тавыш куптарма.

6644 И, Раббым, ярлыка мөэмин колларың,
Кодрәтең киң синең, мәгъмур кыл барын.

6645 Төмән мең житкез син Рәсүлгә сәлам,
Аның дүрт ярына моннан күп сәлам!

*(Тәмам).*

*Караханилар теленнән*
**Әдхәт СИНУГЫЛ** *тәрҗемәсе*

# ТУРЫ ЮЛДАН

## ЯЗУЧЫ РАДИК ФӘИЗОВКА 70 ЯШЬ

«Беренче адымнар» дигән хикәядә төп геройның исеме юк, әдип вакыйганы беренче заттан сөйли. «Мин» авырлык килгәндә тез буыннары йомшаруын, сайлаган юлының дөреслегенә икеләнүләрен яшерми. Аның күңеле чынлыгы-сафлыгы, тормышны матур итеп күрергә омтылуы укучыда, бу яшь егетне үземә һич шикләнмичә дус итәргә ризамын, бу ышанычлы юлдаштан үрнәк алырга шатмын, дигән теләкләр уяталар. Яшәешебез турында уйлана белүче бу егет тормышта чалуларга тәгәрәп төшмәячәк, яшьләй акыл утырткан сәфәрче максатын-мәсләген тотачак, ярты адымыннан берегә борылмаячак.

Мондый ныклыкка ул өлкәннәрнең һәм, беренче чиратта, әти-әнисенең киңәшләрен кечкенәдән үк колагына элеп күнегә килгән. Урта мәктәпне тәмамлагач, завод эшенә китәргә карар кылган егет, әнә, әтисенең хәтта сүзсез елмаюында да: «Әле әтәч булып кычкырасың кычкыруын, соңгарак кем булып кытакларсың икән? Карап карарбыз!»—дигән кисәтү укый.

Тагын да кәттәрәк тәрбия чарасы бар икән бит әле әтисенең. Ул башлаган эшеңне юл уртасында калдырып ташласаң, сине каршысына тезләрне тезләргә терәтеп утырта да, мыегын юан бармагына чорнап, эче катканчы көлә икән... Их-х, болай ук кәмит итмичә, хезмәте юлы башыннан бирле тимер чүкегән кулын йодрыклап, саллы итеп, берне сылап кына җибәрсә икән соң әтисе! Юк шул, авырту онытылыр, ә әлегечә сабак күңелеңә гомерлеккә сеңә!..

Радик Фәизовның шушы әсәре исемендәге беренче җыентыгына (1963 ел) кергән хикәясен укыгач, мин башта әйткән гомумиләштерүләремә барып чыктым. Әйе, Хәбибрахман улы шушы нәни генә хикәясендә әле әдәби иҗаты башланган чорда ук тормышка олыдан кубып һәм ихластан соклана белгән. Игътибар итик, миләшкә кунып төн үткәрә торган ала карга беренче көннәрендә эштән физик һәм рухи бетәшеп кайтучы «Мин»не мыскыллы каркылдап каршыласа, көннәрдән бер көнне, егетнең яктырган йөзен һәм җир селкетүче ышанычлы адымнарын күреп, хатасына оялудан башын канаты астына яшерә...

Хикәядәге вакыйга, әйе, Радик Фәизовның үз тормышыннан, ягъни мондагы «Мин»—аның үз «Мин»е. Шулай да бу кечкенә әсәр туп-турыдан автобиографик санала алмый. Дөрес, Радик та паровозда кочегар һәм машинист ярдәмчесе булган. Һәм тагын ул, язучы каләмен кысып тотканчы, туган авылы Дусымда (Әтнә төбәге) балалар укыткан, армиядә хезмәт иткән, финанс серләренә исәп-хисап эшендә төшенгән, слесарь һәм токарь һөнәрләрен үзләштергән. Минемчә, «Беренче адымнар» хикәясе Радик Фәизовның, язучы хезмәтен төп һөнәре итеп сайлаганда, иҗат эшенең чамадан тыш авырлыгын, тормышны төпченеп өйрәнергә һәм белемеңне инә белән кое казып баетырга кирәклеген аңлавына-белүенә дә ишарәли. Шушы җәһәттән генә—иҗат дәрьясына кереп, анда батып калмаска үзендә ышаныч ныгытуны тасвирлау җәһәтеннән генә хикәя күчерелмә мәгънәдә автобиографик дип аталырга мөмкин.

Әйе, Радик күп белергә тырыша. Ул Казан дәүләт университетында

читтән торып укып югары белем алды, Арча район газетасы редакциясендә озак еллар эшләве дәвамында авыл тормышын бирелеп өйрәнде, аңа китапка текәлү дә бик хас. Хәер, соңгысы язучы өчен мәҗбүри кагыйдәдер. Әмма Радик Фәизов әдәби әсәрләр уку һәм әдәбият серләрен өйрәнү белән генә чикләнми. Аның газеталарда басылган күпсанлы (һәм мәгълүматлы) мәкаләләрен укучылар хәтерлиләрдер: Радик, төрледән-төрле серләрне ачканда, күккә дә «күтәрелә», җир астына да «төшә», диңгез төпләрендә дә «җәяүләп йөри».

Гыйлем дөньясына мондый сәяхәтләр исә аңа, хыялын көчәйтеп, фантастик һәм маҗаралы әсәрләр иҗат итү өчен кирәк икән. Мәгълүм булганча, ул балалар өчен андый хикәя-повестьлар да яза. Маҗаралы һәм фантастик хикәяләре генә тупланган «Галәм кызы» исемле китабын да (1983 ел) чыгарды.

...Радик белән очрашып, гадәттәгечә:

—Хәлләрең ничек?—дип сорагач, ул гел:

—Әйбәт, әй,—ди һәм шундук синең хәл-әхвәлеңне белешүгә күчә.

Тормышы һәм иҗаты барышы гел үк әйбәт тә булмыйдыр, әмма Радик кыенлык кичерүен сиздерми, аның боегуын күрмәссең. Ә бит аны, шәхси мәсьәләләрдән тыш, заман чатак-чотаклары да борчый, язучы боларга битараф кала алмый ич. Һәм Радик Фәизов яшәештәге китек-митекләргә, чоңгыл-упкыннарга үз бәясен, ертлач-комсыз адәмнәрне күрәлмавын (соңгысы үзе үк гуманлык лабаса!) юмористик һәм сатирик әсәрләрендә белдерә. Мондый хикәяләрендә ул олыдан купмый да кебек, үзәккә вак детальләр куйгандай да тоела. Мисалга «Кара таяк» хикәясен алыйк. Радикның бу әсәре дә иҗатының башлангыч чорында язылган, монысы да иҗаты буе барачак юнәлешнең тәгаен билгеләнүе белән бәһале.

...Әкрәм бабай шактый еллар инде коры ютәлдән интегә. Монысы гына җитмәгәндәй, ул урамнан барганда җир убыла да бабай чокырга оча, сул аягы сызлаулы кала. Чирне—«җен кагылган» аякның сызлавын Сәхипҗамал әби генә бетерә алыр. Һәм имче карчык Әкрәм бабайга кара артыш таягы бирә, аны, болын чишмәсендә юып, сазлыкка ыргытырга куша. Шуннан соң аягы сызлавы ялап алгандай бетәчәк. Ләкин... кара артыш таягы дигәне гап-гади юкә ботагы икән бит! Тик аны алдакчы карчык утта көйдереп кенә каралткан икән...

Күрәсез, монда бәлагә таручының бәхетсезлегеннән акыллы баш әби үзенең комсыз мәнфәгатенә җай чыгара, аның күңеле саф түгел, ул хәрәм мал җыюын инде бәяли алмый, кешеләргә игелек кылу аңа ят, ул—иң афәтлесе—изгелек итүдән кешеләрне яшертен талау кәсебенә күчкән. Тагын бер детальнең мәгънәсен искәрик: упкан төш кайчандыр кое булган, аны тирес белән күмгәннәр, һәм менә шул кое-чишмә бәгъзе аяусыз кешеләрнең хилаф эшенә—тирес белән бууларына үзенчә җәзасын бирә...

Радик Фәизовның юмор-сатира әсәрләре дә китапларына керде, ул хәзер дә андый хикәяләрен газета-журналларда (аеруча «Чаян»да) еш бастыра. Шулай—усал итеп тә, яратып та көлә белә әдип. Елмаюы-көлүе дә—аның тормышны үз итеп яшәвенә бер дәлил. Моңа, бәлки, әти кешенең эче катканчы көлүенең дә файдасы тигәндер...

Китаплары, дидек. Әйе, Радик шактый санда китаплар чыгарды. Шуларның кайберләрен атап үтик: «Бәхет», «Дусларым», «Юлда», «Күңел кыры», «Адымнарым»... Мине, үзем дә хикәяләр язгач, әдипнең бер сыйфаты-хезмәте аеруча куандыра: Радик Фәизов иҗаты буена хикәягә тугры булды. Аның әдәбиятыбызда шушы жанрны армыйча-талмыйча һәм авырыксынмыйча тартып баручыларның берсе булуы бәхәссез. Һәм, ниһаять, Радикның хикәя остасы булуы хаклы бәяләнде, быел аңа Татарстан Язучылар берлегенең елның иң әйбәт хикәясе өчен булдырылган Фатих Хөсни исемендәге бүләге бирелде!

—Уңышлар сиңа, Радик туган! Иҗатың кырлары тарая күрмәсен!

Бу теләкләрне сиңа, каләмдәшең булуына өстәп, синең белән бер үк көндә галәмгә аваз салган кеше буларак та ирештерәм. Тик яшьләрдә бераз аерма бар шул. Сиңа быел май аенда җитмеш яшь тула—котлы булсын бәйрәмең! Ә мин тормыш юлының бу төшен былтыр ук (!) узып киткәнмен... Синнән—ышанычлы юлдаштан үрнәк алып, әллә яшәрәсе инде...

Юбилее уңаеннан Радик Фәизовның иҗатына кабат күз салганда, мин аның хикәяче булуына игътибарымны юнәлтә төштем, һәм моның сәбәбен өлешчә әйттем дә инде. Радикның башка жанрдагы әсәрләренә күз йомуым түгел бу. Ул очерклар, публицистик һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре язды һәм яза, аның укучы күңеленә хуш килгән повестьлары да ишле. Соңгы елларда ул, нигездә «Казан утлары» журналында, берничә күләмле әйбәт әсәрен бастырды. Аларда язучы каләменең көче-куәте арта баруы иҗатта җитмештә дә үсеш тукталмавын раслый.

Каләм, дигәннән, әдипнең иҗат лабораториясеннән кечкенә генә деталь. Радик гап-гади каләм-карандаш («прос-туй» ди ул аны кайчакта) белән яза. Алдында ук бетергече ята, язучы аны да карандашы кебек «эшләтә»—колагын тырнаган сүзләрне, хәтта рәттән берничә җөмләне бетергәләп бара, бу кадәресе дә аңа иҗат рәхәте бирә. Шулай булмыйни, укучыга барып ирешмәскә тиешле кытыршылыкларны үзе үк күреп-сизеп алды бит!

Радик Фәизовның язу рәвешенә-стиленә хас гадилек-төгәллек, кыскалык, сүз кадерен тою-белү, тормышчанлык, көләчлек (һәм бүтән) сыйфатлар турында, мисаллар китереп, озын-озак сөйләп була, һәм болары да әдипне тиешле-гадел мактау исәбенә керер иде. Әмма укучыда бер сорау туарга мөмкин: Радик Фәизов әсәрләре бөтенләй дә кимчелексезмени?.. Моңа җавабым кыска—бар алар. Ләкин әдипнең үз җитешсезлекләрен үзе үк табарга һәм бетерергә сәләтле икәнен беләм, шуңа күрә мин аны—әдәби иҗатта үз юлын сала белгән язучыны өйрәтергә алынмыйм. (Өйрәтә белсәң икән әле...)

Очрашканда аңардан:

—Балык тотарга йөрисеңме?—дип сорасаң, ул:

—Әлгә, әй!—дип төгәл җавап кайтара, бераздан:—Әле кичә генә... бер шыртлака тоттым!—дип елмая.—Өйдә мәче малае зарыгып көтеп тора ич...

Икенче чакта соравыңа башка җавап ишетәсең:

—Әлкми, әй... Үткән якшәмбедә, ничәмә-ничә бәке тишеп, чәнти бармак хәтле сыңар ташбаш та әләкмәде. Песинең кәефе яман да кырылды, әй!..

Миңа калса, Радикның җәен-кышын Казансуга, Шушмага һәм Мишәгә кармак салырга йөрүе, балык тотудан бигрәк, хикәяләр сюжеты «әләктерү» максатыннан булса кирәк. Аның иң әйбәт хикәяләреннән берсе саналучы «Әбигә, кунакка» (1975) исемле әсәре вакыйгасын да елга ярында, балык чирттерергә онытып, уйланып утырганда тапкандыр ул.

...Абыйлы-сеңелле Фәрит белән Фәридә басу юлын уятып баралар. Зурлар икән ләбаса алар—абыйсына инде җиде яшь, ә сеңлесенә биштән дә артып киткән. Тик нигә соң әле ак болыт йомарламнарына сокланучы бу дәү-ү кешеләр таңнан ук тиешсезгә әрләмәүче Маһирә әбиләре яши торган Дуслар (!) авылына кача-поса сәфәр чыкканнар? Ата-ананың үз «канәфер бөртекләре»нә игътибарсызлыгы-җавапсызлыгы сәбәп икән моңа. Шушы гафу кылынмаслык ваемсызлык ике кечкенә бала фикерләве аша йөрәкне чеметтерерлек итеп тасвирлана. Күпмедер ара узгач, кызчык, мине әни эзлидер, дип борчыла башлый. Һәм алар кирегә борылалар, арыган балаларны күршедә яшәүче Ризван абыйлары машинада алып кайтып җиткерә. Әмма Фәрит белән Фәридә, ишегалдына тавыш-тынсыз гына керүгә, «ботканың иң тәмле вакытында әрепләшеп» китүче ата-ананың үз гадәтләрен шомартырга керешүләрен ишетәләр. Һәм ике кечкенә баланың, капканы шыгырдатмыйча гына ачып, тагын әбигә—кунакка китүдән башка чаралары калмый.

Димәк, алар тагын борылдылар. Хикәя вакыйгасындагы фаҗигане тулырак искәртүем әдипнең иҗаты башында ук дөрес сайлаган максатына тугры булуын, ягъни яхшыны—яхшыга, яманны—яманга чатырдатып аеруда боргаланмавын шиксез дәлилли булыр.

—Шулай, Радик туган, Канатлы атың иҗатыңның туры юлыннан һичкайчан читкә дә тайпылмасын, кирегә дә борылмасын!

**Мәгъсум ХУҖИН.**

*март, 2001 ел*

# ШӘФКАТЬЛЕЛЕК

Берәүләр әдәбиятка яшьтән үк шаулап-гөрләп килеп керә, ә икенче берәүләр исә, укучылар күңеленә акрынлап, сабыр гына юл саба. Роза Хәлиуллина әнә шундыйлардан. Ул поэзиягә иплән кенә, кызларча тыйнаклык һәм, хәтта, оялчанлык белән килеп кергән шагыйрә. Килеп кергән һәм... үз урынын тапкан, үз сүзен әйтә алган шагыйрә.



Роза Заһит кызы Хәлиуллина 1931 елның 14 июнендә Актаныш районының Әҗәкүл авылында туган. Җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, курсларда укып, шәфкать туташы һөнәрен ала—күз авыруларын дәвалый. Сугыш елларындагы авылның бихисап авыр хезмәтен татып өлгергән үсмер кызны Казан 1948 елда үз кочагына сыендыра. Монда ул белем ала—Казан медицина институтын тәмамлый, төрле медицина учреждениеләрендә һәм промышленность предприятиеләрендә эшли. Утыз елдан артык гомерен медицина өлкәсендә эшләп, кешеләргә шәфкатьлелек күрсәтә.

Р. Хәлиуллина иҗат эше белән алтмышынчы елларда шөгыльләнә башлый: шигырьләре республика балалар газетасы «Яшь ленинчы»да, «Татарстан яшьләре», «Социалистик Татарстан» газеталарында, «Ялкын», «Азат хатын», «Казан утлары» журналларында басыла.

Шагыйрәнең аерым әсәрләре күмәк җыентыкларга кертелә («Беренче карлыгачлар», 1968; «Беренче адымнар», 1971; «Кызлар җыры», 1977-1979), аннары балалар өчен «Бөрлегәнгә медаль» (1973), «Чүкеч—нәни булышчы» (1977) исемле мөстәкыйль китаплары басылып чыга. Болар—шагыйрәнең эзләнү, үсү юлындагы тәҗрибәләре.

1978 елдан Р. Хәлиуллина—профессиональ язучы. Бу елларда ул «Каенана» исемле поэмасын һәм күпсанлы лирик шигырьләрен яза. Аның «Агыйдел—аккош иде» (1980), «Идел суы илле батман» (1984) исемле җыентыкларга тупланган шигъри бәйләмнәрен һәм поэмаларын шигърият сөючеләр яратып кабул итте.

Яшь язучыларның 1978 елда Арчада узган конференциясендә ясаган чыгышында Сибгат Хәким шагыйрә турында: «Роза шәхси кичерешләрен башка бик күпләрнең уртак тойгылары дәрәҗәсенә күтәрә белә. Нәтиҗәдә аның лирик герое язмышында тамчы судагы кояш төсле ил-көн язмышы чагыла»,—дигән иде. «Татар поэзиясе антологиясе»ндә Роза Хәлиуллинаның нәкъ шундый рухтагы «Минем тауларым» шигыре урнаштырылган. Яшьлеге Бөек Ватан сугышы елларына туры килгән лирик герой—үсмер кыз бала халык мәнфәгате, ил гаме белән яшәргә, үзе тир түгеп эшләргә өйрәнгән. Күкрәгенә медаль, орденнар тагып кайтучылар гына түгел, баржаларга икмәк, тимер төягән, көне-төне колхозда эшләгән шул чактагы үсмер балалар да, окоп казыган, орлык ташыган, икешәр смена станок артында торган аналар да—чын геройлар. Аларның бәһасе алтын белән генә исәпләрлек түгел.

Тар гаилә кысаларындагы язмышларны сурәтләүдән башланган «Каенана» поэмасы Себергә, БАМ төзелешенә алып китә. Зур төзелешкә атлыгып чыгып киткән «чая баш каенсенел», аның йомшак күңелле мөлаем әнисе һәм лирик герой—килен образлары—илкүләм әһәмияте булган шушы төзелешкә үзләреннән өлеш керткән һәм шуңа ихластан куана белгән замандашлар буларак күз алдына килә.

Р. Хәлиуллинаның иҗатына, гомумән, халыкның күркәм гореф-гадәтләрен, милли колоритын оста чагылдыру һәм йөгерек тел хас.

Роза Хәлиуллина 1981 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

*«Казан утлары» журналы редакциясе юбилярны кайнар котлый, иҗат эшендә уңышлар, бәхет һәм сәламәтлек тели.*

**Тәслимә СИБГАТУЛЛИНА**

*Bezneŋ kalendar'*

## YARLI KƏRİMNEŊ TUUINA 100 YIL

Yarlı Kərim atlı şağirebez barın küplər, bəlki, onıtqan da bulğandır. Əmma, hiç uylamağanda, citmeşençe yıllar başında anıŋ şiğerenə ber populyar cır—«Nazlı gəlkəyem»—məydanğa çığıp, kiŋ yanğıraş aldı: ul—«Səyəm gel sine...» dip başlana torğan süzlərgə kompozitor Fasıl Əxmət kəye ide... Küplər xəterlider ul cırnı: «Tatar poeziəse antologiəse»neŋ 1957 yılğı basmasınnan alınğan ide ul. Ğəcəp: çaq qına aldaraq, onıtıla təşkən «Sin sazıŋnı uynadıŋ» şiğerenə (Nəqi İsənbət)—İlhamıbız ğəcəyep matur kəy belən qanat quyıp, xalıqqa qaytarğan ide bit. Şiğer, cırlarnıŋ da üz yazmışı, üz tarixı!

Yarlı Kərim (Çın atı—Ğabdulla Əxmətwəli ulı Kərimov. 1901—1937. «Yarlı» bulu səyeneçe, psevdonim bulıp, yegermençe yıllar başında, Demyan Bednıy şawlağan çorda tua. Qızıqlı xəl: əle bit Demyan Fətxi təxəllüsen alğan ber əybət şağirebez də kilep çığa ul çorda!) də ğıbrətle yazmış iyəse, məğayın. Cır-moŋğa, şağirlərgə bay təbək—elekke Bələbəy əyəze (Ufa gubernası) Ayıt awılında tuğan ul. Bu awılnı bez kürenekle şağirebez, yawgir həm qaharman şəxes Fatix Kərim awılı bularaq yaxşı beləbez (ə alar—bertuğannar, yəştən suqır qalğan, üze də şiğerlər çığarğan Əxmətwəli mulla malayları!). Bu təbək—məşhür Aqmulla tuğan yaq, başqa küp ədiplər, şağirlərgə də ilham birgən güzəl Dime belən ataqlı yaq! Bügenge kəndə ul Bələbəy şəhəre belən ruxi yalğanıp, yıl sayın biredə «İlham çişmələre» isemle şigriət festivale ütkərelə, Tatarstan, Başqortstan, Çuwaşiə ədiplərenə Fatix Kərim isemle ədəbi premiyə tapşırıla. Həm, əlbəttə, Yarlı Kərim iseme də yad itelə bu—bay, şiğrilek belən danlı, matur təbəktə!

Ə Yarlı Kərimneŋ ğomer yulı bolay: üz awılında, annan Orenburgtağı «Xəsəyeniyə» mədrəsəsendə uqıy, uncidençe yılda, inqıylabtan soŋ, anı taşlap çığa—revolütsiə yulına kerep kitə. Kommunist bulıp ala, Kızıl Armiyəgə yazıla—agitatsiə həm propaganda eşendə bula, Petrogradnı saqlap, Yudeniçqa qarşı suğışta qatnaşa, qatı yaralana... 1921-1922 yıllarda Məskəwdə Kənçığış xezmət iələreneŋ kommunistik universitetında uqıy (məğayın, Soltanğəlievneŋ yalqınlı leksiələren də tıŋlağandır!). Anıŋ bu çorda yanıp şiğerlər yazuın, dawıllanıp, Z. Bəşiri belən polemikağa kerüe turında N. İsənbətneŋ Taqtaş turındağı bik qızıqlı istəleklərendə əytep ütelə («Miras» jurnalında 2001 yıl, 2-3 sannarda basıldı.). Məğayın, iŋ qızıqlı icadi çorı da şunda bulğandır Yarlı Kərimneŋ.

Uqıun təmamlap, Kazanda, Ufada, annan Beloret kantonında (Başqortstan) ğazeta həm partiyə eşendə berniçə yıl eşləgəç, ul 1926 yılda qatı awırıy başlıy... xastaxanəgə eləgə həm, front yaralarınnan inde terelə almıyça, urın əstendə ozaq yatqaç, 1937 yılda Ufada ülə. Şunda kümelə də... İsən-saw çağında enese Fatixqa gel yərdəm itə, anıŋ şəxes həm şağir bularaq üsüendə, şiksez, abıysınıŋ zur yoğıntısı bula—monısın da onıtmasqa tieşbez. İcatına kilgəndə, anıŋ yazğannarı küp tügel, front ğazetalarında, Məskəw, Qazan, Ufa matbuğatında şul çornıŋ ideyələre belən suğarılğan kəraş ruxlı şiğerlərə basılğan. Əytkənebezçə, cırğa nigez bulğan, cılı xisle lirik şiğıerlərə də bar.

«Tatar poeziəse antologiəse»neņ yaņa basmasında da (1992) Yarlı Kərimgə unn birelüe yuqqa ğına tügelder. Dimək, onıtılmıy ul – Bələbəy yağı, Dim buyı yegete!

**Rədif ĞATAŞ**

# Yarlı Kərim

## Bügenge marş

Xəzer tormış beznen ildə
Tınıçlandı, caylandı;
Tınıçlandı, caylandı;
Eşçelərneņ yərəklərе
Qızıllandı, allandı...
Eşçelərneņ yərəklərе
Qızıllandı, allandı...

Xəzer gərləp, bergə-bergə
Cimerek ilne təzibez,
Cimerek ilne təzibez,
Üzebez – təxet, üzebez – patşa –
Üzebez, üzebez, üzebez!
Üzebez – təxet, üzebez – patşa –
Üzebez, üzebez, üzebez!

Əydə, çükeç, əz timerne!
Yaņğırasın Cir şarı!
Yaņğırasın Cir şarı!
İşetelməsen küp-küp yıllar
Şawlap kilgən il zarı!
İşetelməsen küp-küp yıllar
Şawlap kilgən il zarı.

İşetelməsen mesken, ğərip,
Yətimnərneņ yığlawı;
Yətimnərneņ yığlawı;
İşetelməsen daņğır-donğır
Çirkəwlərneņ qıņğırawı;
İşetelməsen alla-walla
Məçetlərneņ ıņğrawı!

Bezne alar artqa taba –
Artqa taba əndilər;
Artqa taba əndilər;
Citər-citər, bik küp bezdən
Şarqıldaşıp kəldelər!..
Citər-citər, bik küp bezdən
Şarqıldaşıp kəldelər!..

Təxte-tacı patşalarnıņ
Cimerelsen, taptalsın!
Cimerelsen, taptalsın!
Bəten dənya eşçelərе
Monı belsen, şatlansın!
Bəten dənya eşçelərе
Monı belsen, şatlansın!

## Nazlı gəlkəyem

Səyəm, bel, sine,
Səyəm gel sine.
Moņ-zarlarımnan
Kəyəm şul inde.
Moņ-zarlarımnan
Kəyəm şul inde,
Gəlkəyem, bəğerem,
Nişlim soņ inde?!

İrtə min uylıym,
Kiç tə min uylıym.
Kürsəm üzeņne,
Hiç tə min tuymıym.

Kürsəm üzeņne,
Hiç tə min tuymıym.
İrkə baladay,
Kilçe, kil, uynıym!

Kilçe, kil, bəğerem!
Kil, kil, serləşik,
Al çəçəklərdən
İlham ezləşik,
Al çəçəklərdən
İlham ezləşik,
Bılbıllar kebek
Gər-gər gərləşik...

## Ictimağï-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНДА

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2001 ел, 11 маенда булып узган сигезенче пленар сессиясендә Министрлар Кабинетының яна составы расланды. Сессия раслаган Кабинетны янартылган иске хөкүмәт дип атап булса да, анда, кыскартулар хисабына күп кенә үзгәрешләр дә бар. Өч министрлык һәм ун комитет бетерелде. Аларның функцияләре бүтән министрлыкларга күчте. Әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау, һәм шулай ук, Урман хуҗалыгы министрлыклары белән бергә Матбугат эшләре, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникация чаралары министрлыгы да бетерелде. Президент тәкъдиме белән Татарстан Республикасы Премьер-министры итеп моңарчы инде бу постта өч ел эшләгән **Рөстәм Миңнеханов** билгеләнде. Премьер-министрның биш урынбасары расланды. Алар арасында урынбасар—вице-премьер буларак, социаль-мәдәни өлкә, матбугат чаралары өчен җаваплы **Зилә Вәлиева** да бар. Ул моңарчы Матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникация чаралары министры булып эшләгән иде. Бу сессиядә, шулай ук, **Рәфкать Алтынбаев** Федерация Советына Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкиле итеп расланды.

### ТУКАЙ КӨННӘРЕ—ШИГЪРИЯТ БӘЙРӘМЕ

Бөек шагыйрьнең 115 еллыгы дөньяның татарлар яши торган төрле төбәкләрендә киң билгеләп үтелде. Шул җөмләдән, мәсәлән, Уфада Башкорт дәүләт опера һәм балет театры бинасында зур әдәби-музыкаль кичә узды. Төркия башкаласы Анкарада зур бер урамга Тукай исеме бирелде. Самарада шагыйрьгә багышлап әдәби бәйрәмнәр узды. Татарстан башкаласы Казанда, республикабыз шәһәрләрендә һәм районнарында да бу датага багышлап күпсанлы чаралар үткәрелде. Әлбәттә, төп вакыйга—опера театры янындагы Тукай һәйкәле янында үткән Шигырь Бәйрәме булды. Бәйрәмне, поэзия һәм Тукай турындагы кереш сүз әйтеп, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин ачты һәм алып барды. Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, Татарстан Президенты Указын укып, быелгы Тукай премиясе лауреатларын—шагыйрь **Роберт Әхмәтҗановны** һәм дирижер **Анатолий Шутиковны** тәбрикләде. Аннан соң Шигырь бәйгесендә шагыйрьләр мәйдан тотты: Зөлфәт, Ш. Галиев, Л. Шагыйрьҗан, К. Латыйп, Г. Мөхәммәтшин, С. Мулла Гали, Р. Вәлиев, Б. Рәхимова, Р. Мингалим, Р. Вәлиева, Р. Гаташ, Х. Әюп, И. Гыйләҗев, Ә. Рәшитов, Ф. Тарханова... Бәйрәмдә нәфис сүз бәйгеләрендә җиңеп чыккан балалар, атаклы сәнгать осталары, Казанда белем алучы төрек яшьләре һәм яшь башкаручылар катнашып, шагыйрь рухы белән балкыган мәйданны тагын да ямьләттеләр.

### СӘНГАТЬКЯРЛӘР ИСТАНБУЛДА

Апрель урталарында Төркиянең Истанбул каласында татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре булып узды. Бирәдә башкалабызның данын Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбле, кинематография вәкилләре, эстрада җырчылары Зәйнәп Фәрхетдинова белән Зөфәр Билалов, К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры артистлары һәм башка иҗади коллективлар яклады. Делегация составында Татарстан мәдәният министры Илдус Тарханов, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе академик Индус Таһиров, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәгариф һәм милли мәсьәләләр буенча даими комиссиясе рәисе Разил Вәлиев, Салих Сәйдәшев исемендәге Татарстан дәүләт Зур концерт залы директоры Мансур Шиһапов бар иде.

### ХАЛЫК ШАГЫЙРЕН ЗУРЛАУ

21 апрель көнне Камал театрында **Фәнис Яруллинга** «Татарстанның халык шагыйре» исеме бирелү уңаеннан Татарстан Язучылар берлеге, «Казан» милли мәдәният үзәге, «Татнефть» акционерлык җәмгыятенең «Рухият» фонды әдәби-музыкаль кичә уздырды. Анда әдипнең «Ярала язмышлар» исемле китабы киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителде. Кичәдә күренекле язучылар һәм сәнгать осталары чыгыш ясады.

### «РУХИЯТ»ТӘ—ШИГЪРИЯТ

Мәгълүм булганча, «Татнефть» карамагындагы «Рухият» нәшрияты күренекле татар шагыйрьләренең иң яхшы әсәрләрен туплап, махсус серия рәвешендә китаплар чыгарып килә. Соңгы елларда бу нәшриятта Г.Афзал, С. Сөләйманова, Ф. Яруллин, Рәшит Әхмәтжанов, Зөлфәт, К. Булатова, Н. Әхмәдиев һәм Ф. Гыйззәтуллинаның саллы җыентыклары дөнья күрде. Әнә шул китапларны халыкка тәкъдим итү республикакүләм әдәби-мәдәни бәйрәмгә әверелде. Әлмәткә дистәдән артык күренекле әдәбият-сәнгать вәкилләре килгән иде. Аларны «Татнефть»нең генераль директоры урынбасары Р. Әбүбәкеров кабул итте. Китап бәйрәмендә «Казан утлары» журналыннан Р. Фәйзуллин, Ф. Латыйфи, Н. Гамбәр катнашты. Алар нефть промышленносте предприятиеләрендә, мәктәпләрдә, культура сарайларында булдылар һәм чыгыш ясадылар, журнал эшчәнлеге турында сөйләделәр, шулай ук «Татойлгаз» ширкәтендә (генераль директоры—Р. Фәссахов), торба житештерү производство базасында (директоры—Р. Рахманов) эшлекле сөйләшүләр үткәрделәр.

### САМАРАДА ОЧРАШУЛАР

Самарадагы татар милли мөхтәрият җитәкчелеге һәм «Бердәмлек» газетасы редакциясе (баш мөхәррире Р. Әһлиуллин) чакыруы буенча **Равил Фәйзуллин** җитәкчелегендәге бер төркем язучылар Самара шәһәрендә булдылар. Алар «Бердәмлек» газетасы хезмәткәрләре белән очраштылар, Радио-7 радиостудиясендә булдылар, «Яктылык» дип исемләнгән татар мәктәбендә һәм «Заря» мәдәният сараенда чыгыш ясадылар.

### УФАЛЫ ӘДИПЛӘРЕБЕЗ КИҢӘШӘ

Башкортстан язучыларының XIII корылтаенда татар язучылары берләшмәсе рәисе һәм яңа бюро составы сайланган иде. Күптән түгел бюроның киңәйтелгән утырышы булып үтте. Утырышны берләшмә рәисе, шагыйрь Марат Кәримов ачты һәм алып барды. Анда берләшмәнең ике секциясе оештырылды. Шигърият секциясе җитәкчесе итеп шагыйрь Марис Нәзиров, ә проза белән драматургиянекенә Суфиян Сафуанов сайланды. Утырышта бүтән байтак мәсьәләләр дә каралды. Язучылар Рәиф Әмиров, Суфиян Сафуанов, Равил Шаммас, Рәшит Сабит, Рәшит Фазлыев, Азат Магазов һ. б. иҗади эшне җанландыруга юнәлтелгән күп кенә файдалы тәкъдимнәр белән чыгыш ясадылар.

### ҺАМАН САФТА

Быел Чиләбе өлкәсенең Троицк шәһәрендә яшәп иҗат итүче шагыйрь **Басыйр** ага **Рафиков**ка 80 яшь тулды. Басыйр Рафиковның шигырьләре 1963 елдан матбугатта күренә башлый. «Җырым сина минем» исемле беренче шигырьләр җыентыгы Казанда 1968 елда басылып чыга. Аннан соң «Кадерле минутлар», «Туган тупсалар», «Кара каен», «Дала» дигән шигъри китаплары дөнья күрә. Аның күп кенә китаплары рус теленә тәрҗемә ителеп, күпмилләтле Урал халкының мәхәббәтен казанды.

### ЯКТАШЫБЫЗ КҮРГӘЗМӘСЕ

19 апрельдә Казанның сынлы сәнгать музеенда Санкт-Петербургта яшәүче милләттәшебез—рәссам **Рәшит Гыйләҗев**нең күргәзмәсе ачылды. Рәшит тумышы белән Яшел Үзәннән. Ул башта Лениногорск сәнгать училищесында укый, аннары Репин исемендәге институтны тәмамлый. 1970 елдан бирле төрле күргәзмәләрдә катнашып килә. Аның картиналары илебездәге һәм чит илләрдәге күп кенә җыелмаларда саклана. Ул пейзаж, натюрморт, портрет жанрларында эшли.

### КҮРШЕЛӘРЕБЕЗДӘ

Ижевск шәһәрендә Удмуртия татар иҗтимагый үзәге оешуга 10 ел тулуга багышланган бәйрәм булды. Тантаналы кичәдә Удмуртия Президенты А. Волков, Дәүләт Советы Рәисе И. Семенов, Мәскәү, Татарстан, Башкортстан кунаклары катнашты. Казаннан Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты активистлары А. Мөхәмматҗанов һәм Л. Харрасова да бар иде. Анда Удмуртия ТИҮ адресына күпсанлы котлаулар яңгырады. Үзешчән сәнгать артистларының зур концерты бәйрәмгә ямь өстәде.


## *Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** «Җәйге хозурлык»—фотоэтюд.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** язучы Рәшит Гариф.


# ЯҢА КИТАПЛАР

Салих СӘЙДӘШЕВ. **Әсәрләр**: 3 томда. I т.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2000.—224 бит. Тиражы—3000 данә.




Өч томлыкның бу беренче китап-альбомына татар профессиональ музыкасына нигез салучы мәшһүр композитор Салих Сәйдәшевнең 20 елларда иҗат ителгән музыкаль әсәрләре тупланган. Тулы күләмдә алар беренче тапкыр басыла. Китап профессиональ һәм һәвәскәр башкаручыларга, музыка белгечләренә, композиторның иҗат мирасына битараф булмаган киң катлам музыка сөючеләргә тәкъдим ителә. Төзүчеләре: **Р. Ә. Еникеев, Д.Җ. Саинова-Әхмәрова.**

**Бишек җырлары**: Җырлар җыентыгы—Казан: Татар. кит. нәшр., 2000.—104 б. Тиражы—5000 данә.




Заманча полиграфик югарылыкта нәшер ителгән бу басмага татар халкының, профессиональ һәм һәвәскәр композиторларның тавыш һәм фортепиано өчен эшкәртелгән утыздан артык бишек җырлары тупланган. Барлык җырлар фортепиано аккомпониментлы белән бирелгән. Җыентыкка яшь музыкантлар башкару өчен бишек көйләреннән төзелгән инструменталь пьесалар да кертелгән. Авторлар арасында шагыйрьләрдән—Г. Тукай, Дәрдмәнд, М. Җәлил, Ә. Ерикәй, М. Хөсәен, Г. Зәйнашева, Р. Харис, Б. Рәхимова, Р. Вәлиев; Композиторлардан—Н. Җиһанов, З. Хәбибуллин, Җ.Фәйзи, А. Ключарев, Р. Яхин, Ә. Бакиров, Ф. Әхмәтов, А. Монасыйпов, Р. Еникеев, М.Яруллиннар һ. б. бар. Җыентыкны төзүче—**Илдус Алмазов**.

Индекс 73210



Рәшит Гариф

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)